
ISSN 0206—41



# КАЗАН УТЛАРЫ

3.1989






**Әдәбиятыбыз классигы**
**Галимҗан Ибраһимов**

**(1887—1938)**

*А. Тимергалина рәсеме.*

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

1989

3

(797)

КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН


## Бу санда


М. ШӘЙМИЕВ, М. ЗАРИПОВ. **Мөстәкыйльлек.** *Әңгәмә.* . . . 3

ПРОЗА ҺӘМ ПОЭЗИЯ

Н. АРСЛАНОВ. **Каршыла.** *Шигырьләр* . . . . 15
М. ӘГЪЛӘМОВ. **Остаз.** *Шигырьләр* . . . . . 21
М. ЮНЫС. **Европа ат сагына.** *Повесть-сәяхәтнамә* . . . . . . . . . . . . . . . . 25
К. ЛАТЫЙП. **Мин синеке.** *Шигырьләр* . . . . 141
Ф. ЗЫЯТДИНОВА. **Уйлану.** *Шигырьләр* . . . 143

Ә. ЕНИКИ. **Халыкның күзен ача белү дә кирәк** . . . . . . . . . . . . . . . 145

ӘНВӘР ДАВЫДОВНЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Р. МИНГАЛИМ. **Чорлар чатында** . . . . . 153
Ә. ДАВЫДОВ. **Буран.** *Шигырьләр* . . . . . 155
Ә. ДАВЫДОВ. **Ярослав Смеляковка.** *Хат* . . . 158

ПУБЛИЦИСТИКА

Ф. ГАЛИЕВ. **Авылым гадәтләре** . . . . . . 159

БӘХӘС ДӘВАМ ИТӘ: «ЗАМАН ҺӘМ ШИГЫРЬ»

Г. ГЫЙЛЬМАНОВ. **Заман тойгысы бармы?** . . 170
М. ГАЙНЕТДИНОВ. **Ышаныч — талантларда!...** 174
Р. БАЙТИМЕРОВ. **Мөгамәлә турында** . . . . 177

БӘХӘСКӘ УКУЧЫ КУШЫЛА

Л. НУРЕТДИНОВА. **Кара күмер калмасын** . . 177
Г. МОЗАФИН. **Әдәбият турында сөйлик!** . . . 178

БИБЛИОГРАФИЯ

Ф. САФИУЛЛИНА. **Яңа сүзлек** . . . . . . 179
Р. НИЗАМИЕВ. **Чәчәкләр китерегез аңа** . . . 182

ГАРӘП ӘЛИФБАСЫ НИГЕЗЕНДӘ ТАТАРЧА УКУ ЯЗУ

**Җиденче дәрес** . . . . . . . . . . . . 185

Культура тормышы көндәлеге . . . . . . 190

Тышлыктагы сурәтләр . . . . . . . . . . 192

*Баш редактор*

РЕНАТ ХАРИС

*Редколлегия*

МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ

ӘХӘТ ГАФФАР

МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ

АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ

МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ

МӘДИНӘ МАЛИКОВА

САЛИХ МАННАПОВ
*(баш редактор урынбасары)*

ТУФАН МИҢНУЛЛИН

ФЛҮН МУСИН

РИНАТ МОХӘММӘДИЕВ

РӘФЫЙК НӘФИКОВ

НУРИХАН ФӘТТАХ

РИЗВАН ХӘМИД

НИЛ ЮЗИЕВ

АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН

Безнең адрес: 420066.
Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар:
баш редактор — 53-07-60,
баш редактор урынбасары —
53-07-09,
җаваплы секретарь — 53-07-09,
*бүлекләр:*
проза, поэзия, очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать,
хатлар — 53-07-63.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

Беседа председателя Совета Министров Татарской АССР М. ШАЙМИЕВА с писателем М. ЗАРИПОВЫМ о проблемах внедрения хозяйственного расчета в республике.
Стихи Н. АРСЛАНОВА, М. АГЪЛЯМОВА, К. ЛАТЫПА, Ф. ЗЫЯТДИНОВОЙ.
Повесть М. ЮНУСА «Европа тоскует по коню».
«Публицистика». Отрывок из книги председателя колхоза «Искра» Арского района Ф. ГАЛИЕВА «Обычаи моей деревни».
«Литературная критика». Продолжение дискуссии «Время и поэзия»: статьи Г. ГИЛЬМАНОВА, М. ГАЙНУТДИНОВА, Р. БАЙТИМИРОВА; письма читателей.
В рубрике «Библиография» помещены рецензии Ф. САФИУЛЛИНОЙ на новый «Татарско-русский словарь» и Р. НИЗАМИЕВА на книгу И. НУРУЛЛИНА «Фатих Амирхан» из серии «Жизнь замечательных людей».
В номере отмечается 70-летие поэта Э. Давыдова. Читатели журнала ознакомятся со статьей Р. МИНГАЛИМА «На перекрестке эпохи», стихами из архива поэта и письмом Э. ДАВЫДОВА поэту Я. Смелякову.
Аксакал татарской литературы А. ЕНИКИ в беседе «Надо уметь пробуждать народ» размышляет о судьбе и будущем народа, литературы и языка.
«Навыки чтения и письма на основе арабской графики». Занятие 7-ое.
Дневник культурной жизни.
На наших обложках: изделия сабинских ювелиров; вид Казани в XIX веке. Сенная площадь и соборная мечеть. Репродукция старинной открытки.

Җаваплы секретарь *Флүс ЛАТЫЙПОВ*
Техник редактор *Р. Сөләйманова.* Корректорлар *Т. Сибгатуллина. Г. Салихҗанова.*

Производствога бирелде 30.12.1988 ел. Басарга кул куелды 27.02.1989 ел. ПФ 05083. Офсет ысулы белән басыла.
Кагазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 77049. Заказ А-569. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1989 ел.

# МӨСТӘКЫЙЛЬЛЕК

**Татарстан АССР Министрлар Советы председателе М. Шәймиев белән язучы М. Зариповның региональ хуҗалык исәбенең киләчәге, яңача хуҗалык итү юлларын эзләү турында әңгәмәсе**

Үз-үзен финанслаучы республика, чыгымнарын үзе каплаучы өлкә, хуҗалык исәбендәге автономия... Мондый төшенчәләр озакламый, күрәсең, эшкуар даирәләрдә, экономик һәм политик әйләнештә гадәтигә әйләнер. Әмма болай оештыруда әлеге тәҗрибә тупланмаган, әзер система һәм модельләр дә юк. Региональ хуҗалык исәбе дигән идея үзе үк төрле фикер каршылыклары һәм кайнар бәхәс тудырды. Аны кулланырга җыенучылар үзләре бу идеяне ничек күз алдына китерә?

Мәгълүм булганча, илебез хөкүмәте 1990 елдан башлап экономика белән идарә итүдә региональ хуҗалык исәбе принципларын куллану турында карар кабул итте. Иң элек бу ысулны Балтик буе республикалары, Белоруссия, Россия Федерациясенең Свердловск өлкәсе һәм Татарстан АССР үзләштерә башлый.

Язучы Марсель Зарипов Татарстан АССР Министрлар Советы председателе, хуҗалык исәбенә күчүне хәзерләү комиссиясе җитәкчесе Минтимер Шәрипович Шәймиев белән очрашты һәм берничә сорау белән мөрәҗәгать итте.

**М. Зарипов:** Хуҗалык исәбенә күчү тәҗрибәсен нәкъ менә Татарстан җирендә үткәрү очраклы түгелдер, табигый ки, аның нигезе бардыр. Шулай да, беренче итеп мондый сорау бирәсе килә: республика җаваплы һәм катлаулы бу адымны ясарга әзерме һәм, әзер булса, ни дәрәҗәдә? Гадәти тормыш-көнкүрештә, әйтик, башка чыгасы, тормыш йөген тулаем үз җилкәсенә аласы яшь гаилә иң элек килерен уйлый, кайдан күпме керәсен һәм чыгасын исәпли; тамак өчен генә яшәп булмый, киенәсе дә, йорт җиһазлары аласы да, ялга чыгасы да бар, кем әйтмешли, кара көнгә мая тупларга да кирәк. Хәзер, күрәсең, республика «кесә»сендәге керем белән чыгымны, җыеласы маяны исәпли торган чордыр.

**М. Шәймиев:** Әйе, бездә андый исәп-хисап ясалды. Эшләп алынган керем һәм барлык чыгымнарны чагыштырып карау Татарстанның үз-үзен финанслауга күчәрлек егәре барлыгын күрсәтте. Гомумән алганда, республикабызның экономик сурәтен болай тасвирларга мөмкин: 3,6 миллион кеше яшәгән туган ягыбызда 15 миллиард сумлык промышленность һәм 3 миллиард сумлык авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерелә. Машина төзелеше һәм металл эшкәртү, нефть чыгару, химия һәм нефтехимия, энергетика, җиңел һәм азык промышленносте төп тармаклардан исәпләнә. Республика азык-төлекнең төп төрләре белән үзен тәэмин итеп кенә калмый, гомумсоюз өстәленә дә шактый күләмдә ит, сөт, бәрәңге җибәрә.

Ә хәзер, сез әйткәнчә, «кесәдә»ниләр барлыгын санап карыйк. Татарстан АССРның дәүләт бюджеты 800 миллион сум чамасы тәшкил итә. Бу — республика җирендә алынган керем һәм тотылган чыгымның уннан бер өлеше генә. Ләкин без бюджетка гына ябышып ятмыйча, акчаның һәр тиенен санарга өйрәнергә дә тиешбез. Шунсыз үзфинанслау турында сүз дә булырга мөмкин түгел. Әйдәгез, саныйк. Былтыр Татарстан 8 миллиард сумнан артык керем алды. Моңа предприятиеләрнең табышы, әйләнеш налогы, амортизация

исәбенә чигерелгән акча, керемгә салына торган налог һәм озак сроклы кредит акчалары керә. Ә чыгымнар болай: 2,5 миллиард сум — капиталь төзелешкә (биредә җирле төзелешләр дә, үзәк чыганаклардан финанслanучы объектлар да исәпләнә), 1 миллиард сум — пенсия түләүгә, тагын бер миллиардка якын — авыл хуҗалыгына акчалата ярдәм, 500 миллион сум — социаль сферага (сәламәтлек саклау, мәгариф, культура), предприятиеләр дә бу максатка тагын шул кадәр акча тотты, миллиард ярым сумга якын акча хезмәт коллективларын экономик кызыксындыру фондына күчерелде.

Бөтен чыгымнар 7 миллиард сумга җыела. Шулай итеп, керем чыгымнардан 1 миллиард сумга артыграк. Күрәсез, Татарстан үзен-үзе туйдыра ала.

**М. Зарипов:** Һәм, әйтер идем, шактый уңышлы туйдыра ала. Мин кайбер саннарны карап чыктым һәм Татарстанны экспериментта катнашучы башка төбәкләр белән чагыштырып карадым. Татарстан җан башына промышленность продукциясен Балтик буендагы теләсә кайсы республикадан күбрәк җитештерә, авыл хуҗалыгы буенча да алар дәрәҗәсенә якынлашып килә. Шул ук вакытта Эстониядә яшәүче елына 90, Латвиядә — 85, Литвада — 86 килограмм ит куллана. Татарстанда исә нибары 64 килограмм. Сөт ризыклары куллануда да шактый ук аерма бар. Эстониядә бер кешегә күчереп исәпләгәндә торак мәйданы 20 квадрат метр туры килә, Латвиядә 19. Литвада 18. Татарстанда, бөтен Россиядәге кебек ук — 15. Дөрес, эшчеләр һәм хезмәткәрләрнең эш хакы бер чама. Ләкин, мәгълүм булганча, әгәр акчаны үзеңә кирәк товарга алыштыра алмыйсың икән, югары хезмәт хакы да кызыксындыру чарасы булудан туктый.

**М. Шәймиев:** Моңа кадәр без мондый чагыштыруларны бик четерекле мәсьәлә дип карадык. Кемнең ничек яшәвен чагыштырып ни файда, янәсе. Ә, мөгаен, чагыштырырга кирәк булгандыр. Вакыты җиткәндер. Карасак, санасак, бик күп файдалы нәтиҗәләргә килергә, шактый күп нәрсә турында уйга калырга мөмкин.

Балтик буе бездән ерак. Үзебезнең Идел буе экономик районын гына алыйк. Татарстан АССР бу төбәктә агропромышленность комплексының нәтиҗәлелеге буенча беренче урында тора. Авыл хуҗалыгы җирләренең бер гектарына бездә Идел буендагыга караганда ике тапкыр күбрәк продукция җитештерелә. Шул исәптән, ит — 90 центнер (Идел буендагы уртача күрсәткеч — 51), сөт — 329 центнер (уртача күрсәткеч 168). Ә аларны куллануга килсәк капма-каршы хәлгә тап булабыз.

Җан башына ит куллану буенча Татарстан Куйбышев һәм Саратов өлкәләреннән 6-7, сөт һәм сөт ризыклары буенча 23 һәм 68 килограммга калыша. Бездә шулай ук халыкка аерым төр товарларны, бигрәк тә катлаулы көнкүреш техникасын сатуда артка калу күзәтелә.

Региональ хуҗалык исәбенә күчүнең киң яклау табуы очраклы хәл түгел, чөнки ул өлкәләр, республикалар, районнар һәм шәһәрләр арасындагы урынсыз тигезләүчелекне бетерергә, гаделсезлеккә чик куярга, хезмәтнең сыйфатын тормыш сыйфаты белән тыгызрак бәйләргә мөмкинлек бирә.

**М. Зарипов:** Моңа кадәр барлык республикалар, өлкәләр, гади генә итеп әйткәндә, уртак табактан кемгә күпме бүлеп бирелсә, шуңа разый булып яшәделәр. Әмма бөтенесен яңадан, хәтта гадел итеп бүлү нәтиҗәсендә кемдер элеккегедән күбрәк өлеш алганнан гына без баерак булырбызмы соң?

**М. Шәймиев:** Яшәү шартларын яхшыртуга, матди байлыкларны күбрәк туплауга элеккегә караганда нәтиҗәлерәк эшләү белән генә, яңа чимал ресурсларын, материалларны әйләнешкә кертеп кенә ирешеп була, иң мөһиме — кеше факторы активлаша. Региональ хуҗалык исәбенең иң югары гаделлеге, территориаль үзидарәнең асылы әнә шуларда чагылырга тиеш. Җитештергән әйберне генә үзара бүлергә мөмкин. Баерак булырга телибез икән — күп тапкыр яхшырак эшләргә өйрәнергә, акчаның кергән хәтлесен санап кына туздырырга, тупасрак булса да әйтим, юрганыңа карап аяк сузарга өйрәнергә дә кирәк.

Күптән түгел без бер төркем белгечләргә Татарстан экономикасында якын арада нинди резервларга исәп тотарга мөмкинлеген исәпләргә кушкан идек. Ул, кызганычка каршы, бик күп югалтулар булуын ачыклады. Кайбер предприятиеләрнең, мәсәлән, теләсә кайсы чит ил фирмасы көнләшерлек югары җитештерүчән җиһазлары бар. Ләкин алар ярымкуәтенә генә файдаланыла. Шул ук вакытта предприятие аны күрше заводка биреп торырга теләми яки булдыра алмый. Чөнки күрше завод башка министрлыкка буйсына. Исәпләү техникасын, транспортны, склад һәм производство биналарын, произ-

водство калдыкларын, төзү оешмаларын файдалануда да шундый ук кимчелекләр бар.

Татарстанның иң зур предприятиеләреннән саналучы КамАЗ берләшмәсе инде үнике ел эшли, әмма хәзергә кадәр ул проект куәтенең 90 процентын гына файдалана. Ул кадәр игътибар бирелмәгән, даны азрак булган башка предприятиеләр турында сөйләп тә торасы юк. Министрлыклар исә бу хәлгә артык борчылмый, чөнки предприятиеләр бирелгән планнарын 100 һәм хәтта 101 процентка үтәп килә. Ә территориаль идарә органнары нишли соң? Кулга керәм-керәм дип торган акчаның агып китүен күреп, алар моннан котылу юлын эзләргә тиеш иде кебек: бәлки продукциянең бер өлешен чит илләргә сатаргадыр, шул акчага әлегә җитеп бетмәгән металл һәм кирәкле җиһазлар алыргадыр. Нәрсә дә булса эшләргә кирәк бит инде. Иң сәере шунда, Советлар хәзер министрлыкларга караганда да ныграк битарафлык күрсәтә. Ни өчен? Җавабы бик гади. Гигант заводлар табышларыннан үзләре урнашкан җиргә, эшчеләре яши һәм көн күрә торган җиргә бик авырыксынып кына өлеш чыгаралар. КамАЗ, мәсәлән, дүрт процентын, ә Түбән Кама «Нефтехим» берләшмәсе нибары бер процентын гына Советлар карамагына бирә. Тагын бер мисал. Татарстанда 2 миллиард тоннадан артык нефть чыгарылды, нефть чыгаручы районнарның җире төрле коммуникацияләр белән «җәрәхәтләнеп» бетте. Әмма нефть индустриясенең үсүеннән Татарстан сизелерлек файда алмады, ул гына да түгел, промыселлар сөрүлек мәйданнарны кысрыклыйлар, туфракның уңдырышлылыгы кимегәннән-кими бара.

Без халык кулланучы товарлары турында да әйткән идек. Республикабызда алар дүрт миллиард сумга якын җитештерелә. Шул күләмдә хезмәт хакы түләнә. Ләкин шунысын искәртергә тиешбез, беренчедән, алар халыкның ихтыяҗын канәгатьләндерергә җитәрлек түгел, икенчедән, аларның сыйфаты дөнья стандарты үрнәкләреннән түбән, ассортименты тар. Алга таба ни эшләргә? Предприятиеләргә боерык биреп, аларны товар эшләп чыгаруны киңәйтергә мәҗбүр итәргәме? Без күптәннән шулай эшлибез. Ләкин шунысын аңладык, әмер бирү ысулының мөмкинлекләре бетте һәм алар бернинди алга ыргылыш тудыра алмаячак. Хәзер экономик ысуллар эзләргә, территориаль хуҗалык исәбенең мөмкинлекләрен оста һәм колачлырак файдаланырга кирәк.

**М. Зарипов:** Сез китергән мисаллар предприятиеләрдә, тармакларда хуҗалык исәбе мөмкинлекләренең әлегә йомшак файдаланылуын күрсәтә. Региональ хуҗалык исәбе боларга тагын ни өстәр, нәрсә белән ярдәм итә алыр соң?

**М. Шәймиев:** Иң беренче чиратта, производство белән социаль үсеш арасындагы кискен диспропорцияне йомшартачак. Андый тигезсезлекнең, территориаль мәнфәгатьләрне санга сукмыйча идарә итүнең тармак принцибы нәрсәгә китергәнен без ачы тәҗрибәбездән чыгып беләбез.

Соңгы егерме биш елда Чаллы һәм Түбән Кама шәһәрләре, нефть чыгару үзәкләре ашкынып үсте, республиканың бу төбәгендә шәһәр халкы бер миллионга диярлек артты. Шуның белән бергә алдыбызга четерекле мәсьәлә килеп басты: азык-төлек җитештерүне, яшәү өчен шартлар тудыру инфраструктурасын да шундый ук колач белән ничек үстерергә? Иделдә һәм Камада ике гигант — Куйбышев һәм Түбән Кама гидростанцияләре төзелү кыенлыкларны берничә тапкырга арттырды, иң уңдырышлы, су баса торган тугайлардан ярты миллион гектар җир ясалма диңгез дулкыннары астында калды.

Министрлыклар һәм ведомстволар теге яки бу предприятиене төзү, киңәйтү, реконструкцияләү турында план корганда аларда эшләүчеләрне ашату, киендерү, тормыш шартлары тудыру турында баш ватып тормыйлар. Аларны акча әйләнешенең тигезсезлеге дә, экологик хәлнең катлаулануы да борчымый. Нефтьчеләр, энергетиклар, нефтехимиклар, автомобиль төзүчеләр — барысы да үз эшләренә бары тик промышленностьны үстерүне генә алалар. Ә инде азык-төлек табу, комплекслы социаль программаны тормышка ашыру кебек «вак-төяк» мәшәкатьләр җирле партия һәм Совет органнарына кала. Республикабыздагы яңа җирләрне үзләштерүнең вакыйгаларга бай елъязмасы — җирле власть органнарының үзәк министрлыклар белән бетмәс-төкәнмәс даулашутарткалашу тарихы да ул. Кызганычка каршы, алар күп очракта соңгыларының җиңүе белән тәмамланып килде. Республикада үзфинанслау кертелү хәлне кискен үзгәртер дип өметләнергә урын бирә.

Территориаль хуҗалык исәбе коллективларның мөстәкыйльлеген ныгытыр, министрлыклар һәм ведомстволарның предприятиедәге финанс һәм хуҗалык эшчәнлегенә тыкшынырга омтылуына, бернинди нигезсез бар табышны үзләш-

теруләренә каршы торырлык көч бирер. Ә хәзергә министрлык фондына акча күчерүнең катгый нормативлары хәтта бюджетка түләү суммасыннан да артып китә.

Менә бер мисал. СССР Минхимпромы «Казаньбытхим» берләшмәсенә министрлык фондына акча күчерү нормативын 9,2 миллион сум итеп куйган. Бу — предприятиенең дәүләт бюджетына түләячәк суммасыннан 1,7 миллион сумга күбрәк. Тармак штабының исәпләвенчә, бу аерма 1989 елда 2,7 миллион, ә 1990 елда 2,9 миллион сум тәшкил итәчәк. Уйлап карыйк, предприятие акчалата кемгә ярдәм күрсәтә: союз бюджетынамы, әллә үз өстендәге министрлыккамы һәм аның аркылы тармакның начар эшләүче предприятиеләренәме? Менә шундый авыр һәм гаделсез салымнар җирле бюджетны булдыруга комачаулап кына калмый, гомумән, хезмәт коллективларында югары җитештерүчән хезмәт белән кызыксынуны бетерә.

**М. Зарипов:** Соңгы елларда Советларның ролен күтәрү юнәлешендә хөкүмәтебезнең берничә мөһим карары кабул ителде. Аерым алганда, аларда җирле власть органнары белән килешенмичә төзелгән планнар һәм исәп-хисапларның юридик көче булмау күздә тотылган иде.

**М. Шәймиев:** Ләкин бу кагыйдә еш бозыла, башкарма комитетларның визасы куелмаган документлар элеккечә юридик көчкә дә, матди көчкә дә ия. Шул ук вакытта мин предприятиеләрнең план проектларын тикшергәндә һәм раслаганда җирле Советлар катнашкан очракларны, моның сизелерлек экономик файда бирүен сөйләүче мисалларны күп китерә алыр идем. Мәсәлән, соңгы ике елда эшләүчеләр саны өстәмә рәвештә 30 мең кешегә кыскартылды, ә товар эшләп чыгару күләме 300 миллион сумга артты. Хезмәт коллективлары туплаган средстволарны социаль төзелешкә юнәлдерү моннан алдагы ел белән чагыштырганда 30 процентка үсте. Болар барысы да тармак планлаштыруын территориаль планлаштыру белән бәйләүнең сизелерлек нәтиҗә бирүе турында сөйли.

Ләкин, тулаем алганда, министрлыклар һәм ведомстволар әле һаман да иске алымнарга ябышып яталар, предприятиеләрнең план проектлары җирле Советлар белән килешенмичә кабул ителә. Соңыннан тикшерүләр күрсәткәнчә, җитештерү күләме предприятие мөмкинлекләреннән чыгып билгеләнми, халык куллану товарлары эшләп чыгаруга киметелгән задание җиткерелә, эшчеләрнең социаль ихтыяҗлары кирәгенчә искә алынмый.

Күргәнебезчә, тармак һәм ведомстволарга «таркатылган» хуҗалык исәбе үзенә йөкләнгән оештыру һәм экономик бурычларны тулы күләмдә хәл итә алмый. Һәр район, шәһәр һәм тулаем республика үзидарә, үз-үзен финанслауга күчкәндә генә ул чын мәгънәсендә эшли башлаячак.

**М. Зарипов:** Хәзерге вакытта республика чыгымнарының 70 процентка якыны гомумдәүләт финанс ресурсларыннан тәэмин ителә. Килернең чыгымны каплавы, үзфинанслау, территориаль хуҗалык исәбе шартларында республика производствога һәм социаль ихтыяҗга агымдагы чыгымнарны каплау өчен акчаны каян алачак?

**М. Шәймиев:** Әйдәгез, башта ук ачыклап куйыйк: ул саннар республика ала торган акча аның үзе эшләп тапкан акчасы түгел дигәнне аңлатмый. Татарстанда урнашкан предприятиеләр табышларының төп өлешен Союз яисә Россия бюджетына күчерәләр, ә аннан соң ул акчаларның бер өлеше инде исемсезләнеп, кире безгә кайта. Финансистлар күзлегеннән караганда, бернинди аерма юк кебек. Барыбер акча бит. Ләкин шул исемсезләнү хезмәт белән аның нәтиҗәсе арасындагы турыдан-туры бәйләнешне өзә, аның күзгә күренеп торган кызыктыргыч матурлыгын югалта.

Территориаль үзфинанслау менә шул исемсезләнүне бетерүгә, бөтен нәрсәнең үзәккә бәйлелегеннән котылуга юнәлдерелә дә инде. Без биредә акча ресурсларын гомумсоюз бюджетыннан тулыландыру кирәклеге турында сөйләмибез. Оборона чыгымнары, гомумдәүләт программаларын үтәү кебек чыгымнар да бар бит әле. Предприятиеләрнең союз бюджеты алдындагы йөкләмәләре, бурычлары барысы да үтәлергә тиеш. Территориаль хуҗалык исәбе аерым өлкә яки республиканың тулаем ил алдындагы җаваплылыгын һичничек киметергә тиеш түгел. Без барыбер безгә кайтачак әйләнеш средстволары турында сүз алып барабыз. Ул акчалар барыбер безгә кире кайта, ләкин аларны кулга төшергәнче күпме ялыктыргыч сөйләшүләр, раслаулар, ярдәм сорап ялварулар кирәклеген үзебез генә беләбез. Менә шул акчалар баштан ук җирле Советларга бирелсә начар булыр идемени! Аларның кимендә яртысы төп производство фондлары өчен түләү рәвешендә кайтырга, таби-

гать, хезмәт ресурслары өчен барлык чигерүләр дә тулысынча җирле Советлар карамагында калдырылырга тиеш.

Безнең фикеребезчә, региональ хуҗалык исәбе шартларында республика бюджеты яңача оештырылырга тиеш. Иң элек, предприятиеләрнең табышыннан чигерүләрнең ныклы нигезләнгән нормативлар буенча җирле бюджетка күчерелүенә, аларның кискен арттырылуына ирешергә кирәк. Һәм моны һич кичекмәстән, җирле Советларда союз һәм республика министрлыкларына буйсынган предприятиеләрнең ахыргы эш нәтиҗәләре белән экономик кызыксынучанлык итеп эшләү зарур.

**М. Зарипов:** Региональ хуҗалык исәбенең төп этәргеч көче, аның канаты һәм алга әйдәүчесе — хезмәттә үз-үзеңне аямау, бөтен барлыгыңны җигеп эшләү, керемнәргә карап акча тота алу. Әйләнештә акчаң күп икән — тормышны да яхшырак оештырырга мөмкин. Үзара бәйләнеш бик ачык күренә. Идарә итүнең хуҗалык исәбенә нигезләнгән принциплары гамәлгә кертелгәч республика хезмәт иләре нинди уңай үзгәрешләргә өмет итә алалар?

**М. Шәймиев:** Беренче нәүбәттә, әлбәттә, күп нәрсә үзләренең оешканлыгына, тапкырлыгына, яхшы мәгънәдәге эшкуарлыгына, резервлар эзләүгә һәм табып, аларны эшкә җигә алуга бәйле. Бөтен эшчәнлектә аркылыдан буйга үткән хуҗалык исәбе һәркемнең кулын чишәр, иҗатка, инициативага, төрле эзләнүләргә канатлар куяр иде.

Сер түгел, әле күптәнме генә хуҗалык инициативасы күрсәткән теләсә кайсы кеше җәзасын тапмый калмый иде. Дөрес, болар «Әйдә, әйдә, эшлә» дигән яңгыравык өндәмәләргә төрелеп, рәсми рәвештә игълан ителмичә генә алып барылды. Ләкин беләбез, хуҗалык практикасында кем дә булса берәү өстәмә продукция җитештерә икән, «артык» продукция шунда ук планга кертелә һәм дисциплинар тәртиптә, мәҗбүри рәвештә гомумдәүләт фондына күчерелә иде. Мондый шартларда кем генә өстәмә резерв яки мөмкинлек эзләп баш ватар икән?! Тыныч эшлисең килсә, эзләнмә, тик утыр! Хәзер мөнәсәбәт үзгәреп килә. Бу бишьеллыкта, мәсәлән, азык-төлек белән эш башкачарак тора. Союз фондына бирү планын үтәгәннән соң калган барлык продукция республика карамагына күчте. Шушы кагыйдә гамәлгә кергәч, соңгы ике елда шәһәрләрдә һәм эшчеләр поселокларында фондларга өстәмә рәвештә 8 мең тоннага якын ит, 121 мең тонна сөт, 20 миллион данә йомырка сатылды. Терлекчелек продуктлары сатуны тагын да арттырырга кирәк иде дә бит, ләкин килеп чыкмый — производство үсеше ихтыяҗлар үсешенә җитешә алмый. Әгәр без җан башына мөһим продуктлар куллануда Балтик буе республикаларыннан калышабыз икән, кибет киштәләрендә сөт ризыкларының төре азрак икән, ит, колбаса кебек әйберләрне күбрәк кооператив кибетләреннән эзләргә мәҗбүрбез икән — монда иң элек үзебезнең эшне тагын да яхшырту турында уйларга кирәк. Чөнки безнең фермаларда җитештерүчәнлек түбәнрәк, мал азыгын азрак әзерлибез, терлекләрдән алардагы кадәр югары артым һәм савым ала алмыйбыз. Хуҗалык исәбе дәүләт ресурсларына салынып ятучыларны түгел, ә җиң сызганып эшкә керешкән, хыялын тормышка ашыра белгән кешеләрне хуплый.

Үз-үзеңне тәэмин итү стимулы, башлангыч планда искә алынмаган өстәмә продукцияне шул төбәктә калдыру тәртибе — хөкүмәтнең махсус карары нигезендә билгеләнде. Әмма ведомстволар диктаты шул кадәр гадәткә кергән ки, һәрбер артык шөреп яки кадакны югарыда исәпкә алу һәм кемгә бирергә күрсәтеп тору әле хәзергә кадәр дәвам итә. 1987 елда, мәсәлән, Түбән Кама «Шин» берләшмәсе заводларында заданиегә өстәмә рәвештә 186 мең җиңел машина шины җитештерелгән иде. Шулардан 29 мең «артык» шинны Татарстанда сатарга рөхсәт алу өчен Миннефтехимпром белән күпме җан кыйганны, күпме кәгазь язылганны аңлатып бирү мөмкин түгел. Өстәмә җитештерелгән продукциягә хуҗа булу, аны үзең теләгән максатка тоту — ә ул Татарстанда елына 100 миллион сумлык диярлек була — региональ эшчәнлекнең гаять нәтиҗәле стимулы, аны чикләргә түгел, киресенчә якларга һәм һәртөрле ярдәм күрсәтергә кирәк.

Сүз уңаеннан, бу кагыйдәне җирле бюджетны төзегәндә дә кулланырга ярар иде. Әгәр пландагы табыш алынмаганда җирле бюджетка акча керү автомат рәвештә киметелә икән, предприятие көтелгәннән күбрәк табыш бирсә, ни өчен әле ул җирле Советларның әйләнеш капиталын тулыландырырга тотылмаска тиеш ди? Җирле эшлеклелекне чикли торган ялгыш һәм көтелгән нәтиҗәне бирмәүче гадәтне бетерергә күптән вакыт. Чимал һәм технологиянең яңа резервларын әйләнешкә кертү, кеше факторын активлаштыру нәти-

җәсендә алынган планнан тыш табыш гомумдәүләт бюджетына түгел, ә оешкан төстә эшләгән, кешеләрне туплый белгән, кыенлыкларны җиңәргә өйрәнгән җирдә бирелергә тиеш. Инициатива һәрвакыт һәм һәркайда, бернинди чикләүсез хупланырга тиеш! Халыкара хезмәттәшлектә дә уңай мөмкинлекләр ачыла. Татарстан маркасы дөньяның 70 илендә билгеле, республика экспортка самолетлар, йөк машиналары, приборлар, компрессорлар, ясалма каучук, фанер, полиэтилен, аяк һәм өс киемнәре чыгара. 1988 елның беренче яртысында экспорт күләме 211 миллион сум тәшкил итте.

Элегрәк экспорт сәүдәсенең шулай ук үз йөзе юк иде. Татарстан чит илләрдәге партнерлары белән турыдан-туры элемтәгә керә алмады, аны Внешторг оешмасы эшләде. Хәзер предприятиеләр чит ил фирмалары белән үзләре үк килешү төзиләр. Казан күнчеләре, мәсәлән, чит илләргә ярты миллион данә тире җибәрүгә контракт төзеделәр. Вахитов исемендәге химия комбинаты 100 тонна кер юу порошогы, Түбән Кама нефтехимиклары ясалма каучук, стирол, «Идел» агрокомбинаты чимал җибәрү, машиналар, технологик җиһазлар кайтарту турында килешенделәр. Хезмәттәшлек ике як өчен дә файдалы, чит ил сәүдәгәрләре «Спартак» берләшмәсе, «Аромат» парфюмерия фабрикасы, кооператорларның мех фабрикасы өчен җиһазлар җибәрәчәкләр. Экспортта катнашучылар кулында ирекле валюта тупланачак, аларны машиналар, станоклар, җиһазлар алу өчен дә, Сәүдә министрлыгы аша халык куллануы товарлары кайтарту өчен дә файдаланырга була. Ул әйберләрне исә валюта тапкан хезмәт коллективларында сату мөмкинлеге туа.

Чит илләр белән сәүдә итү кагыйдәләре 1985 елның апреленнән соң кабул ителгән иде. Ул һәркем өчен уртак, әмма төрле җирдә төрлечә гамәлдә йөри, һәр министрлыкның үз уставы бар. Казан күн берләшмәсендә чимал артык күп тупланган, хәтта биредә аны кабул итүне туктатырга мәҗбүр булсалар да, Роскожпром аны чит илләргә җибәрүне ике айга диярлек тоткарлап торды. Татарстан нефтьчеләре кара алтынның дүрттән өч өлешен экспорт кондициясенә җиткерәләр, бу гаять катлаулы, күп хезмәт сорый торган эш белән ике меңгә якын кеше мәшгуль, алар ике дистәгә якын махсус установкага хезмәт күрсәтә. Продукциянең һәр тоннасына өстәмә рәвештә таңкә ярым чыгым тотыла. Экспорт өчен миллионлы чыгымнарга барсалар да, нефтьчеләр үзләре бернинди валюта алмыйлар, барысын да тармак штабы йотып бара. Региональ хуҗалык исәбенә күчкәндә исә валютаны ниндидер локаль бурычларны түгел, ә гомумтерриториаль максатларны тормышка ашыруга юнәлтеп булыр иде. Республикада экспорт һәм импорт белән шөгыльләнүчеләрнең тырышлыгын бер йодрыкка туплау мөмкинлеге турында да уйланырга вакыт. Бу чаралар халык хуҗалыгының әлеге тармаклары белән тирәннән уйлап җитәкчелек итүдә Советларның кызыксынучанлыгын нык арттырыр иде.

**М. Зарипов:** Сүз дә юк, җирле бюджетның предприятиеләр алган табыштан тулылана баруы бик мавыктыргыч перспектива. Әмма территориянең үзүзен финанславы ике якның да җаваплылыгын күздә тота. Моңа кадәр Советлар промышленностьның нәтиҗәле эшләвеннән чынлыкта бернинди файда күрмәгән кебек, зыянга эшләп утыручы производстволар өчен дә артык пошынмадылар. Алар өчен министрлыклар җавап бирде. Ә хәзер читләр кесәсенә керүче завод-фабрикаларның бурычларын кем түләр? 1987 елда, мәсәлән, илле предприятие кырык миллион сумлык зыян китергән иде. Зыянга эшләүче колхоз һәм совхозларны кая куясың?! Финанс ярдәменнән башка алар да озакка суза алмаячак. Хуҗалык исәбенә күчкән Татарстанга үз өстенә шактый күп мәшәкатьләр өяргә туры киләчәк.

**М. Шәймиев:** Бәхәсләшмим, зыянга эшләүче предприятиеләр һәм хуҗалыклар үзфинанслауга күчүне шактый кыенлаштыра, әлбәттә. Ләкин мин киләчәккә өмет белән карыйм. Эзлекле һәм тулы канлы хуҗалык исәбе гаҗәпләнерлек хәлләр тудырырга сәләтле. Менә агропромышленность комплексын алып карыйк. Гаять катлаулы һәм зур тармак. Ул үз-үзен финанслауга күчерелгән иде. Соңгы ике елда Татарстанда корылык хакимлек иткәнен һәркем белә. Ләкин шундый шартларда да, элек әйтелгәнчә, «табигать шартларының уңайсыз килүенә карамастан»— хуҗалыкларның рентабельлеге үсә бара! Тагын икенче бер четерекле мәсьәлә бар: колхоз-совхозлар муеннан бурычка баткан. Озак һәм кыска сроклы кредитларның чиге юк. Бу йөк белән территориаль мөстәкыйльлеккә омтылу, чыннан да, бик шикле. Мондый хәл бер Татарстанда гына да түгел. Мәсьәләне хәл итү юлын гомумдәүләт күләмендә эзләргә кирәктер.

**М. Зарипов:** Тагынмы? Инде ничәнче кат хуҗалыклар әҗәтләрен кайтармый котылалар булып чыгамы? Үзфинанслауга күчү алдыннан яхшы фал түгел... Шулай да фараз итеп карыйк, бурычлар алып ташланды, ди. Шуннан соң нәрсә килеп чыгар? Яңа бурычларны һәм зыянга җитештерелгән продукция хакын кем түләр, хуҗалыклардан сатып алу бәясе белән халыкка сату бәясе арасында туган аерманы кем хисабына капларбыз? Әгәр территориаль хуҗалык исәбе кертелгәч азык-төлеккә бәя күтәрелә икән, аны алдан ук уңышсызлыкка дучар дип әйтергә мөмкин: мондый хуҗалык исәбенә халык ничек карар? Мин моны бер дә юктан гына әйтмим. Редакцияләргә бәяләр үзгәрү турындагы мәсьәлә буенча килгән һәр ун хатның тугызында бердәнбер үтенеч, ялвару ярылып ята: зинһар азык-төлеккә бәяләрне күтәрүгә юл куя күрмәгез!

**М. Шәймиев:** Моңа юл куярга ярамый, әлбәттә. Без бүген халыкның тормыш хәлен яхшыртуны региональ хуҗалык исәбенең беренчел һәм иң мөһим бурычы итеп сүз алып барабыз. Бюджетны, идарә итү структурасын үзгәртеп кору, республиканың үз-үзен финанславы — болар барысы да яхшырак хуҗалык итү исәбенә яхшырак тормышка ирешү чаралары гына. Әйдәгез, җентекләбрәк, бөртекләбрәк санап карыйк.

Бер килограмм сыер ите җитештерү бездә 4 сум 76 тиенгә төшә, кибетләрдә исә ул 1 сум 90 тиенгә сатыла. Татарстан хуҗалыкларына ит һәм сөт җитештергән өчен өстәмә рәвештә биш йөз миллион сум түләнә. Ә барлык төр продукция өчен дотация күләме — бер миллиард сум. Үзфинанслауга күчкәч мондый вариант тәкъдим ителә: зыянга җитештерелгән һәм бөтенсоюз фондына җибәрелгән авыл хуҗалыгы продукциясе өчен, элеккечә, дәүләт түләячәк, ә инде дәүләт заданиесеннән тыш җитештерелгән кадәресе республикада калдырыла һәм аның өчен без үз бюджетыбыздан түләячәкбез. Шунысын да әйтим, чыгымнарның бу статьясын без алдан ук уйлап куйдык һәм аны исәп-хисапка керттек. Ә алга таба юл бер генә — продукция җитештерүне арттыру һәм аның үзкыйммәтен киметү, хуҗалык итүнең яңа, тагын да нәтиҗәлерәк юлларын эзләү һәм, барыннан да элек, аренда подрядын куллану. Күптән түгел без кооператив кибетләрендә сыер итенең бәясен 3 сум 50, дуңгыз итенекен 2 сум 50 тиенгә кадәр төшерә алдык. Тормыш аны тагын да төшерергә мөмкинлек барлыгын күрсәтә.

Шундый ук юл белән коммуналь һәм көнкүреш хезмәте өчен түләү, шәһәр транспортында билет бәяләрен үзгәртү мәсьәләләрен дә хәл итәргә була. Һәр Совет үз җирендә хуҗа булырга, бюджетның мөмкинлекләрен һәм халыкның ихтыяҗын искә алып бәяләрне дә үзе куярга тиеш.

**М. Зарипов:** Сүздә ышандыра, ә эштә, кызганычка каршы, әлегә шикләндерә. Моның өчен сәүдә, җиңел промышленность һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү сферасында хуҗалык исәбе кертүнең нинди чатаклыклар чыгаруын искә төшерү дә җитә. Теләсә нинди юл белән табыш алырга омтылу, ахыр чиктә, бәяләрнең артуына китерде. Юкса, барысы да дөрес кебек. Халыкның тормыш хәлен яхшыртырга кирәк. Ә моның өчен акча җитми. Акчаны исә табыш кына китерә. Ә табыш алуның иң гади юлы — продукциягә бәяне күтәрү. Әмма бәя күтәрү — ул халыкның тормыш дәрәҗәсен төшерү дигән сүз. Әкияттәге сыман, каян чыгып киткән булсак, тагын шунда кайтып кердек. Кулга тоттырмый торган әйбер артыннан серле бөҗра эчендә йөгереп йөрмибезме? Бу бөҗраны кем өзә ала соң? Территориаль хуҗалык исәбенә күчкән җирле Советмы? Алай дисәң... Хәзер ул үзе үк предприятие күбрәк табыш алсын өчен тырышачак бит.

**М. Шәймиев:** Шәхсән мин үзем бу серле бөҗраны нәкъ менә территориаль хуҗалык исәбе белән Советларның экономик эшчәнлеге генә өзәчәгенә ышанам. Предприятие планнарын төзегәндә формаль рәвештә «Килешенде-килешенмәде» дип мөһер сугып утыручы гына булмыйча, Советлар предприятиеләрнең үз финанс хәлләрен халык хисабына яхшыртырга маташуларына да чик куячаклар, продукциягә акланмаган югары бәяләр куюны, халыкка кирәкле, әмма арзан товарларның бетерелүен чикләячәкләр. Советларны килешмәүчән булырга нәрсә мәҗбүр итә соң? Монысы — аларның сайлаучылар алдында турыдан-туры һәм катгый җаваплылыгы. Бер генә министрлыкның да андый җаваплылыгы юк. Шулай итеп, территориаль идарә органнарындагы вәкилләре аша предприятиеләр эшчәнлегенә халык үзе контрольлек итәчәк. Региональ хуҗалык исәбе тармак хуҗалык исәбенә караганда күпкә демократрак.

**М. Зарипов:** Ләкин демократия аерым төркемнәргә хас җирле эгоизмны каплаучы пәрдә булып та хезмәт итә ала бит. Хәзер, мәсәлән, яңа пред-

приятиеләр төзүгә каршы «экологик» митинглар һәм демонстрацияләр дулкыны кузгалды. Аларның таләбе бер төрле: теләсә кайда төзегез, ләкин бездә генә түгел. Әгәр мондый таләпләрнең барысын да канәгатьләндереп барсак, территориаль йомыклыкка һәм экономик прогрессның сүнүенә килеп чыкмабызмы?

**М. Шәймиев:** Татарстанга килсәк, ул берничек тә йомыла алмый. Безнең республикада, промышленность белән шыплап тутырылган булуга карамастан, предприятиеләрнең үсеше тукталмый. Атом электр станциясен һәм гидростанцияне төзү дәвам итә, минераль ашламалар заводы, Алабугада аз литражлы автомобильләр комплексы корыла. Дөрес, җәмәгатьчелек басымы астында республика җирендә табигатькә һәм кешеләргә кире кайтарып алгысыз зыян китерерлек предприятиеләрне урнаштырудан баш тартырга туры килде. Һәм бу мәсьәләне дөрес, законлы хәл итү. Әйтик, «Оргсинтез» берләшмәсенең яңа куәтләре, синтетик каучук производствосы, биохимия заводы шәһәр эчендә һәм ял зонасында урнаштырылырга тиеш иде. Моңа берничек тә юл куеп булмый.

Ләкин, әйдәгез, проблемага киңрәк караш ташлыйк. Чыннан да, ведомстволар һәм территорияләрнең капма-каршы мәнфәгатьләрен ничек килештерергә соң? Әлбәттә, проектларның экологик яктан тирәнтен эшләнүе хакында хәзергегә караганда күпкә артыграк кайгыртырга кирәк булачак. Шул ук вакытта министрлык,— ә аның йөзендә дәүләт — химия объектлары төзүне бу җирләрдәге халыкны кызыктырырлык та итә ала бит. Нинди юл белән? Иң ышанычлысы — экономик юл. Предприятиенең табышыннан җирле бюджетка зурайтылган өлеш чыгарылса, районның социаль-культура үсешенә һәм табигатьне саклауга акча бүлеп бирелсә... тормышның сыйфатын яхшырту максатларында теге яки бу төбәк үз карамагына яхшы табыш бирүче предприятиене алырга теләмәс идемени?! Бәлки әле җирле Советлар үзләре үк планлаштыручы оешмаларга гамәлдәге производстволарны киңәйтүне, экономик яктан нәтиҗәле яңа объектлар төзүне сорап мөрәҗәгать итәрләр иде.

Региональ хуҗалык исәбе — тармак белән идарә итү принципларын өлкә яки республика экономикасына механик күчерү түгел. Ул — хуҗалык итүнең сыйфат ягыннан бөтенләй башка ысулы, төбәк һәм дәүләт интересларын, коллектив һәм аерым һәр кешенең ихтыяҗларын гармоник кушарга мөмкинлек бирүче сыгылмалы механизм.

**М. Зарипов:** Минтимер Шәрипович, республикада хуҗалык белән идарә итүне үзгәртеп кормый торып, региональ үзидарә һәм үзфинанслау принципларына күчү мөмкин булыр микән? Әлегә кадәр җирле Советлар бары тик үз подразделениеләре белән генә эш итте. Ә алар республика экономик потенциалының бик аз өлешен генә алып тора. Региональ үзидарә шартларында исә союз һәм Россия масштабындагы предприятиеләр эшчәнлегенә нәтиҗәле тәэсир ясарлык дәрәҗәгә күтәрелергә кирәк булачак. Моңа ирешү өчен идарә итүнең нинди формалары һәм алымнарын куллану кирәк дип саныйсыз?

**М. Шәймиев:** Бөтен илебездәге кебек үк Татарстанда да хәзер дәүләт һәм хуҗалык үзидарәсе органнарын камилләштерү бара. Без идарә итү звеносыннан алты меңнән артык кешене бушаттык, билгеле бер күләмдә күпбаскычлылыктан котылдык, бер-берсен кабатлаучы оешмаларны кыскарттык, әмма әлегә ведомствоара киртәләрне, таркалганлыкны җиңә алмадык. Төбәк һәм дәүләт интересларын кушуны тәэмин итү өчен автономияле республикага, крайга яки өлкәгә халык хуҗалыгының төрле подразделениеләре белән идарә итүче органнарны оештыруда, структурасын һәм эшчәнлеген билгеләүдә тулы мөстәкыйльлек бирелергә тиеш дип саныйм. Төзелешне генә алыйк. Республикада бу тармакка капитал салым елына өч миллиард сумга җитте. Һәр өченче промышленность объекты норматив срокларда төзелми. Сәбәбе мәгълүм: төзелеш индустриясе базасы артка сөйри, төзү материаллары җитми, көчләр таркалган. Ни өчен «таркалган», ни өчен «артка кала?» Эш шунда, республикада биш йөздән артык подряд оешмасы бар, аларга 34 ведомство «җитәкчелек» итә. Төзү материаллары җитештерү заводлары 17 тармакка буйсына. Уйласаң, исең китәрлек! Бу оешмаларның биштән бер өлеше елына бер миллион сумлык та эш башкармый, яртысыннан артыгы бер миллионнан өч миллион сумлык чамасы төзи, бары тик 30 проценты гына — олпатлы подрядчиклар. Шушы вакланганлык аркасында республика зур югалтуларга дучар була да инде. Төзелеш техникасы начар файдаланыла, болай да кырлә комбинатларның куәтләре җитәрлек түгел, бары тик ведомство графикларын өзмәс өчен генә бер үк төрле материаллар кирәксезгә бер урыннан икенче

урынга ташыла. Өлкә партия комитеты, республика Министрлар Советы инде күп еллар дәвамында барлык бу оешмаларны бердәм комплекска туплау турында тәкъдим итеп киләләр. Бу аларны мәгънәсез, ведомствочыл күзәтчелектән коткарыр иде. Ләкин бүгенге көнгә кадәр уңышка ирешә алганыбыз юк. Республика хуҗалык исәбенә күчсә, ниһаять, бу мәсьәлә дә хәл ителер дип уйлыйм.

Башка тармаклардан да мисаллар китерергә була. Республика җирендә җиңел һәм туку промышленностеның 16 берләшмәсе һәм предприятиесе урнашкан. Аларга йөкләнгән бурычлар бер үк төрле диярлек, кайберләре технологик яктан да бер-берсенә бәйле, әмма буйсыну ягыннан алар аерылган. Монда да бердәм структура булдыру таләп ителә.

**М. Зарипов:** Министрлыкларга ябышып яту хәзерге вакытта катгый мәҗбүриятлектән килеп чыга. Фондлар, ресурслар — барысы да алар кулында. Конвейерның төгәл эшләвен теләсәң, аларга баш ими хәлең юк. Теләсә-нинди кыен вакытта коллектив тармак штабына мөрәҗәгать итә ала, ә башкача ул җирле ресурслар эзләргә мәҗбүр булачак. Алары турында без күп сөйлибез, әмма каян алырга кирәклеген генә белмибез. Предприятиеләргә яхшы тәэминат булачагын берәр оешма ышандыра алам ы?

**М. Шәймиев:** Шактый предприятиеләрне министрлык буйсынуыннан алып җирле власть органнары карамагына тапшыру мәсьәләсен куябыз икән, үзеннән-үзе материаль-техник тәэминат подразделениеләренең статусын үзгәртү зарурлыгы да килеп чыга.

Мәгълүм булганча, СССР Госснабының территориаль органнары хуҗалык исәбендәге мөстәкыйль предприятиеләргә әйләнә, алар предприятие һәм оешмаларны тәэмин итү белән шөгыльләнә. Инде 1988 елда ук 800 гә якын төр продукция Госснаб номенклатурасыннан алынып кулланучыларга ирекле сатыла башлады. Якындагы биш елда барлык предприятие һәм оешмаларны тулаем тәэмин итүгә күчерү күздә тотыла.

**М. Зарипов:** Региональ хуҗалык исәбенә күчү буенча экспериментның Татарстанда, ә тулаем сатуны оештыру тәҗрибәсенең Түбән өлкәсендә үткәрелүен ничек аңлатыр идегез? Монда берәр төрле каршылык күрмисезме?

**М. Шәймиев:** Татарстан белән Түбән өлкәсен капма-каршы куярга теләмим. Бу турыдагы карарлар төрле вакытта кабул ителде. Ләкин шунысын беләм, берсе икенчесеннән башка яши алмый. Региональ үзидарә кертелгән җирдә, һичшиксез, тулаем сәүдә дә булырга тиеш. Тәэминат органнары иң элек төбәк ихтыяҗларын канәгатьләндерү белән шөгыльләнергә тиеш. Уйлавымча, җитештерү һәм тәэмин итү даирәләренең үзара эшчәнлеген без урында тизрәк һәм нәтиҗәлерәк хәл итә алабыз. Теләсә нинди очракта да материаль-техник тәэминат яхшырачак.

Заман рухына җавап бирүче бер мисал китерәсем килә. Күптән түгел республиканың 23 союз министрлыгына һәм ведомствосына караган алтмыштан артык хезмәт коллективы көчләрен берләштерергә карар бирделәр һәм, «Дуслык» дигән символик исем куеп, Татарстанның тармакара промышленность эксперименталь акционерлык комплексын оештырдылар. Бу структураның башкалардан принципиаль аермасы — аның акционерлык нигезендә корылуы. Җәмгыятькә кооперативлар да, аерым кешеләр дә керә ала. Үзләренең төп максатлары итеп акционерлар бүгенге көндә аерым-аерым берсенең дә кулыннан килмәслек, әмма уртак көч белән ерып чыгарлык мөһим проблеманы — халык куллануы товарлары җитештерүнең четерекле мәсьәләләрен хәл итүне куйдылар. Бу — барыннан да элек, катлаулы көнкүреш техникасы җитештерүдә кооперацияләшү; теге яки бу товарга ихтыяҗны өйрәнү һәм прогнозлаштыру (монысы республика күләмендә генә түгел, ә бәлки илдәге һәм чит илләрдәге сорауны өйрәнүне дә күздә тота); яңа товарларга инженерлык документациясе әзерләү; һәр предприятиенең мөмкинлегеннән чыгып технологик кирәк-яраклар булдыру. Болар барысы да югары эстетик таләпләргә җавап бирерлек һәм конкуренциягә сәләтле итеп эшләнәчәк. Шул ук вакытта аларны сату мөмкинлеге 3-3,5 елга алдан гарантияләнә. Моның өчен зур инженерлык һәм коммерция үзәге, дизайн үзәге, технологик кирәк-ярак заводы һәм башка формированиеләр оештырыла. Шуның белән бергә, кооперациянең теләсә нинди формасын куллану мөмкинлеге чикләнми.

Башкарылган эшләр республика предприятиеләренә иң якын арада халык куллануы товарлары җитештерүне сизелерлек арттырырга һәм, иң мөһиме, аларның сыйфатын тамырдан яхшыртырга мөмкинлек бирер дип уйлыйм.

**М. Зарипов:** Илебезнең, Россия Федерациясенең теләсә кайсы төбәге,

шул исәптән автономияле республика, өлкә яисә милли округ шул җирләрдә яшәүче төп халыкның рухи культурасы үзәге дә булып тора. Татарстанны да Советлар Союзында һәм чит илләрдә экономикасы — нефте һәм электрон-исәпләү машиналары, КамАЗлары һәм төгәл приборлары, самолетлары һәм вертолетлары, сәгатьләре һәм бик күп төрле химия продукциясе белән генә түгел, ә үзенчәлекле бай рухи культурасы аша да беләләр. Республикада яшәүче һәр өч кешенең берсе студент, мәктәп яисә бакча баласы; бездә дистәләрчә югары уку йортлары, йөзләрчә мәктәп эшләп тора, театрлар, музейлар, консерватория, художество һәм театр училищесы бар. Әгәр экономикада продукция реализацияләүдән алынган табыш чыгымнарны каплап бара икән (һәрхәлдә ул шулай булырга тиеш), рухи дөнья сферасында матди байлык җитештерелми, киресенчә, мәктәпләр, институтлар, театрлар җитди ярдәмгә мохтаҗ. Социаль һәм рухи инфраструктурага идарә итүнең күп еллар дәвамында урнашкан тәртибе буенча ул акчаның шактый өлеше гомумсоюз һәм Россия бюджетыннан бүленеп килде. Төбәкнең тулаем хуҗалык исәбенә күчүе элек гомумсоюз һәм гомумроссия фондыннан алынган ул акчаны да үзебезгә эзләп табарга кирәклеген аңлата, сумын сумга, тиенен тиенгә исәпләп барырга туры киләчәк. Татарстан халкының рухи һәм мәдәни тормышын киләчәктә тагын да үстерү, аны киңәйтү һәм үзгәртеп кору юлында Сез нинди мөмкинлекләр күрәсез?

**М. Шәймиев:** Әүвәл шунысын ачыклап куйыйк: хуҗалык исәбенә күчкәндә дә экономика, сакчыллык, халык хуҗалыгы механизмының барлык буыннарында эшлеклелек һәм югары оешканлык принциплары саклана; республика бюджетына нигез булып ятучы табыш суммасы рухи дөньядагы һаман үсүче ихтыяҗларны канәгатьләндерерлек булырга тиеш. Мәсәлән, 1989 елда социаль-культура чараларына республика бюджетыннан 600 миллион сум чыгым тоту каралган, бу 1988 елдагыдан 55 миллион сумга күбрәк. Мәктәп китапханәләренә китап алуга, классларны мини-компьютерлар белән җиһазлауга акча күбрәк тотылачак.

Ләкин социалистик хуҗалык исәбенең төп кагыйдәсе — акчаны белеп тоту, тиенен тиенгә исәпләп бару — рухи дөньяда эшләүчеләр өчен дә мәҗбүри шарт булып калачак.

**М. Зарипов:** Әйбәт теләк. Әмма тормышта башкачарак түгелме? Язучы, композитор, артист, музыкант, укытучы яки балалар бакчасы тәрбиячеләренең хезмәтен бүгенге, бер минутлык ихтыяҗлар, бүген саналырга тиешле сумнар һәм тиеннәр белән үлчәп буламы? Көнчыгыш илләре халыкларында бер бик матур әйтем бар: иртәгәсен уйлаган кеше ашлык чәчә, ун ел алга карап яшәгәне бакча утырта, ә инде ерак киләчәк турында хыялланганы — бөтен көчен бала тәрбияләүгә бирә.

**М. Шәймиев:** Табигый ки, теге яки бу язучының яңа басылып чыккан китабы, яңа куелган спектакль, балет яки симфониянең, бүген генә төгәлләнгән рәссам хезмәтенең күпме акча төшерүен чутлап утыру олы ялгыш булыр иде, әмма мәдәният дөньясындагы күпсанлы иҗатчыларның хезмәтенә карата матди, гражданлык һәм политик җаваплылык хисен югалтсак дөрес юлдан китәрбезме? Сер түгел, безнең барлык театрлар дәүләт исәбенә яши. Хәтта билетлары берәр ай алдан сатылып бетә торган данлыклы Г. Камал театры да очын очка ялгый алмый. Республика театрларына елына өч миллион сумга якын ярдәм күрсәтелә. Әмма, республика Культура министрлыгы аларның эшен хәзерге заман сәнгать таләпләре югарылыгында оештыруда бу сумманы җитәрлек түгел дип саный. Еллык ярдәм суммасын тагын ике миллион сумга арттырырга кирәк. Тагын бер сан. Татарстан дәүләт филармониясе тамашачыларга елына биш меңләп концерт күрсәтә, аларны оештыруга да дәүләт кесәсеннән 400 мең сум акча түләнә. М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры гастрольләре вакытында 55 мең сумлап акча җыя, ә чыгымнары 200 мең сумнан артып китә. Гәрчә соңгы елларда, бигрәк тә Шаляпин фестивальләре үткәрү уңае белән спектакльләрнең популярлыгы артса да, театрның үз сәхнәсендәге спектакльләре дә чыгымнарын каплый алмый.

Китап басу эшендә дә шундый ук хәл. Мәктәп дәреслекләре чыгару гына түгел, шигырь җыентыклары, тәнкыйть китаплары, хәтта проза әсәрләре дә еш кына табыш бирми. Югалтуларны каплар өчен Татарстан китап нәшрияты зур тиражлар белән чит ил, рус һәм совет классиклары китапларын бастырырга мәҗбүр.

Табигый ки, биредә сүз милли культурабыз эшчәнлеген тарайту турын-

да бармый. Киресенчә, җәмгыять тормышында милләтара мөнәсәбәтләрнең роле үсә барган саен, XIX Бөтенсоюз партия конференциясе күрсәткәнчә, илебездәге барлык милләтләр һәм халыкларның культурасын тагын да үстерү күздә тотыла. Җиде миллионлы татар халкының рухи башкаласы булган Казанда, Татарстан республикасында (халкыбызның дүрттән өч өлеше читтә яшәвен дә онытмыйк) китапларны тагын да күбрәк чыгарырга, спектакльләрне күбрәк куярга, яңа музыка һәм рәсем сәнгате әсәрләре тудырырга, гастрольләргә ешрак чыгарга кирәк. Зур шәһәрләргә генә түгел, татар халкы яшәгән һәм язучы, җырчы, артист сүзен ишетергә зар булган авылларга да барырга кирәк. Чувашиядә, Удмуртиядә һәм Мари АССРда, Ульяновск, Куйбышев, Оренбург, Пермь һәм башка өлкәләрдә, бүтән төбәкләрдә яшәүче татарларның, Башкорстан АССРдагы милләттәшләребезнең үпкә-рәнҗешләрен аңларга мөмкин. Техник һәм эшне оештырудагы башка сәбәпләр аркасында аларның күбесе Татарстан радиосы һәм телевидениесе тапшыруларын карый алмыйлар. Бу техник яктан гына түгел, бәлки матди һәм финанс ягыннан да бик катлаулы мәсьәлә. Ләкин моннан да чыгу юлы бар. Әгәр Казанда кыска дулкында эшләүче көчле радиостанция төзесәк (якынча исәпләүләргә караганда моның өчен 5 миллион сумлап акча кирәк), эфирда буш урын тапсак, радиотапшыруларны тотрыклы тыңлау радиусын 900 километрга арттырырга мөмкин булыр иде. Әлбәттә, зур чыгым, бернитчә йорт, мәктәп төзүне кичектереп торырга туры килер, әмма, мондый чыгымга барырга кирәк.

**М. Зарипов:** Димәк, рухи һәм матди тормышыбыздагы четерекле мәсьәләләрне тагын экономика җилкәсенә өяргә туры киләчәк?

**М. Шәймиев:** Әйе. Иҗади яктан караганда, бу язучыларга җитдирәк, кызыклырак китаплар язарга кирәк дигәнне, зур тиражлы китапларның да кибет шүрлекләрендә аунап ятмаслык булуы дигәнне аңлата. Композиторлар яхшырак музыка язарга, театрлар телевидение белән ярыша алырлык, тамашачыны җәлеп итәрлек спектакльләр куярга тиеш булачак. Шунда гына тамаша заллары хәзердәгечә буш булмас, хәтта өстәмә спектакльләр бирергә туры килер. Монысы иҗади абруй гына түгел, ә матди табыш алуга, дотацияләрне кыскартуга китерер иде. Дотацияне кыскарту турында очраклы рәвештә генә әйтмәдем. Безнең илебездә генә түгел, бөтен дөньяда шундый хәл: культура дотациясез, ягъни дәүләт ярдәменнән башка яши алмый, сәнгать, мәгърифәт булганча, корбаннарсыз булмый.

Хуҗалык исәбенең кызыксындыргыч көче дә нәкъ менә шунда: ул гадәткә кергән бик күп кысаларны ватарга, яңача уйларга мәҗбүр итә. Республикабыз региональ мөстәкыйльлек алгач, экономияләнгән, янга калдырылган ресурсларның хуҗасына әйләнгәч, без һәр эш урынындагы артык чыгымнар өчен җавап бирү генә түгел, һәр иҗат коллективында, рухи сфераның барлык буыннарында эшчәнлегебезнең матди нәтиҗәлелеген күтәрү юлларын да эзләргә тиеш булачакбыз.

**М. Зарипов:** Монысы аңлашыла, әмма телемне кычыттырып торган сорауны бирми кала алмыйм. Татар язучыларының китаплары, милли театр һәм музыка, гомумән халкыбызның рухи культурасы иң беренче чиратта туган тел аркылы кабул ителә. Ә татар телен куллану өлкәләре елдан-ел тарая бара, республика җәмәгатьчелеге телнең бүгенгесе, киләчәге өчен борчылып хаклы рәвештә дау кубара. Телебез дүрт стенага бикләнгән өй теленә әйләнеп бара. Теле булмаган халык — ул беткән халык. Шундый хәлне дә күзәткәнем бар: өч татар кешесе җыелып бүгенге иҗтимагый, техник я булмаса әхлакый проблемалар турында сөйләшә башласа, аларның сөйләме чит тел сүзләре белән шулкадәр чуарланган булыр ки, аларны аңлау өчен, һич арттырусыз әйтәм, тылмач кирәк булыр иде.

**М. Шәймиев:** Миңа калса, бу очракта бернинди Министрлар Советы да, закон чыгаручы башка орган да мәсьәләне бер селтәнүдә хәл итә алмый. Идарә итүнең көчле һәм нәтиҗәле экономик рычагларын кулланып, хуҗалык исәбен декрет буенча кертеп була. Әмма тел, рухи культура халык аңына указ белән түгел ә аның үз ирке белән, мәдәни ихтыяҗы белән генә керә. Чынбарлык белән исәпләшми мөмкин түгел, һәм безгә халыкның аңына тәэсир итәрлек үтемле чаралар, яңа юллар эзләргә генә кала. Халкыбызда «Татар акылы төштән соң» дигән үзтәнкыйтьле, үкенүгә охшаш мәкаль бар. Шул уңайдан ерак түгел тарихыбыздан бер мисал китерәсем килә. Илленче елларда Казан мәктәпләрендә татар балаларына туган тел һәм әдәбият мәҗбүри укытыла иде. Ә аларның әти-әниләреннән үзәк оешмаларга капчык-капчык шикаять яуды: имеш, боларның газиз балаларына икеләтә авырга туры килә.

«Крокодил» журналында республика мәгарифе башында торучыларны милләтчелектә гаепләп хәтта фельетон чыкты һәм... мәктәпләрдә «татар теле» бетерелде. Кызганыч, ул чакта язучылар да, галимнәр дә, татар мәдәниятенең башка патриотлары да авызларына су каптылар. Һәрхәлдә, халыкның милли үзаңын уяту, телсез халыкның халык түгеллеген аңлату өчен чыгыш ясаучылар булмады. Ул вакыттагы «телсезлек»не бәлки аңлап та буладыр. Татар телен тергезү, халыкның тарихын тирәнтен өйрәнүне яклаган иҗтимагый көчләр 1985 елның апреленнән соң, коммунистлар партиясе илдәге политик системаны үзгәртеп кору, демократик үзгәрешләр кертү, көндәлек тормышта чын-чынлап халык властен тормышка ашыруга таба курс алганнан соң гына хәрәкәткә килде. Ул принциплар партиянең XXVII съездында һәм аннан соңгы КПСС ҮК Пленумнарында тагын да ныгытылды, нигезләнде. Күп вакыт узган, менә шунлыктан безгә югалганны кире торгызу өчен тагын да тырышыбрак, икеләтә энергия белән эшләргә кирәк тә. Хәзерге вакытта республикада тагын йөз мәктәптә татар теле һәм әдәбияты укыту кертелде, балалар бакчаларында милли тәрбия группалары оештырыла. Халык мәгарифе министрлыгы коллегиясе татар теле һәм әдәбиятын барлык укучылар өчен дә мәҗбүри итү турында карар кабул итте. Алдыбызда зур, җитди эшләр тора. Мәктәпләрдә укытучылар, бакчаларда тәрбиячеләр җитми. Ләкин иң мөһиме һәм иң катлаулысы — кешеләрдә милли культураны һәръяклап тирәннән өйрәнү ихтыяҗы уяту, аның зарурлыгын төшендерү. Моны инде әмер биреп һәм декрет чыгарып кына хәл итеп булмый, тирән инанганлык, югары милли үзаң таләп ителә. Димәк, беренче нәүбәттә язучылар, сәнгать осталары — милли культураның энтузиастлары һәм яклаучылары булырга тиешләр. Һәм милли культура — барлык совет халыкларының интернациональ байлыгының бер өлеше дә ул. Шунысын истән чыгармыйк. Бүгенге катлаулы заманда, яңарыш һәм үзгәртеп кору шартларында рухи дөньябыздагы теге яки бу мәсьәләне хәл иткәндә иң элек үзебездән сорарга тиешбез. Кызганычка каршы, көндәлек мәшәкатьләрдә һәм кыенлыкларда, милли үзаңны тергезү кебек катлаулы бурычны хәл итәргә алынганда, төбәкнең экономик мөстәкыйльлеге турында сүз алып барганда үз йортыбыздагы чатаклыклар өчен җаваплылыкны читләр җилкәсенә, бигрәк тә идарә һәм власть органнарына гына өяргә тырышу борчылу тудыра. Ә иң элек үз ялгышларыбызны һәм хаталарыбызны табарга иде бит! Культурада, рухи сферада җаваплылыкны иң элек үзеңнән — аерым кешедән һәм тулаем халыктан гына сорарга мөмкин. Үз гаебең, хаталарың өчен иң беренче чиратта үзеңне җаваплы тою, башкаларга аудармау — халыкның милли үзаңы, гражданлык өлгергәнлеге турында сөйләүче дәлил дә ул.

# ПОЭЗИЯ

## Нури Арсланов

### Каршыла

Былбыл идем, гомер үтте инде
«Ирек» дигән алтын читлектә.
Кисәттеләр: «Сайра безнең көйне,
Уйларыңа бер дә шик кертмә!»

Тимердәнме читлек, алтыннанмы?—
Аерма күрмәдем мин анда:
Киң илдә тар сулыш кысты тынны,
Ил язмышы калгач тиранга...

Кул чаптык без шау-гөр килеп: «Ура!»—
Аермадык яхшы-яманны.
Буып тотты шәхси диктатура,
Яңа диктаторлар яралды.

Бер-бер артлы очты буш куыклар,—
Һәр түрәне күккә чөйдек без,
Изге дидек алар әйткән юк-бар
Һәм тарихи кыйммәт дидек без.

Булсак та тик йөздән алты гына,[1]
Алтыдан бер җирне биләп тә
Мохтаҗлык йөк булды халкыбызга,
Бай тормышта яшәү кирәктә...

Ничә миллион бездә сөрген китте!..
Башкаларда күпме булгандыр?
Төрмәләрдә җәллад хөкем йөртте,
Шунда газап чикте уннан бер.

Ләкин тарих үз дигәнен кыла,
Килеп җитү белән мөддәте:[2]
Тугры кулы белән, сабыр гына,
Бугазыннан алды мөртәтне.

Уян, уян! Хаклык килеп җиткән,—
Күңел читлекләре ачыла.
Күптән нәүмиз булып, зарыгып көткән
Ихтыярны, халкым, каршыла!

[1] СССР халыклары дөнья халкының йөздән алтысын, ә СССР территориясе дөньядагы коры җирнең алтыдан бер өлешен тәшкил итә.
[2] Мөддәте — үз вакыты, срогы.

---

Нури АРСЛАНОВ *(1912) — шагыйрь, тәрҗемәче, күп санлы шигырь китаплары авторы. Ул — ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

## Ат бирделәр

Бераүләре ат бирделәр: «Мен дә оч!»
Бераүләре тезгенемнән алды: «Төш!»
Такым кысу[1] белән тарпып[2] чапты ат,—
Хурлык, оят җаяү калды аптырап.

Җаяүлегә атлы булалмый юлдаш!—
Яраннарын бәйгегә дәште бу баш:
Кайтавазын ишетер микән киләчәк?..
Тик киләчәк моңа җавап бирәчәк...

## Мин милләтче түгел

Мин милләтче түгел, ләкин минем
Милли хисләремә кагылма!
Якын иту үзенең халкын, илен
Туадыр ул ана карынында.

Бар Моцартлар, Листлар...
Ләкин миңа
Татар моңы иң-иң якын моң,—
Хисләр генә түгел, милли моңга
Сабыры бетә тыйнак акылның.

Еракларда, чит җирләрдә йөреп,
Кинәт — туган телне ишетсәм,—
Сабый бала булып күңелем күлеп
Сикереп төшәр сыман бишектән.

«Хуҗа булыр затлар бу дөньяга
Без генә!» дип кемнәр түш кага?—
Шулар юлы илтә канлы дауга,
Андыйларның җаны буш, кара.

Мин милләтче түгел, сүзләрем хак!
Тик җан фида милләт дигәндә.
Тел тидерсә аңа берәр ахмак,
Мин санармын миңа тигәнгә.

Күз төшерсәң әгәр, таң калырлык
Үзганыма, ләкин масаймыйм:
Милләтләр күп җирдә мактанырлык!—
Тарих фолиантларын ачам мин.

Мин халкыма охшаш!
Халкым шундый,—
Изге җанлы элек-электән,
Ул дустанә, аның холкы шундый,
Кешелеккә күңеле береккән.

## Айсур

Очраттык без паркта бер айсурны,[3]
Йөргән чакта таңнар аттырып,
Һөнәр иткән итек чистартуны,
Рәхмәт әйтә,— бирсәң арттырып.

Мин дә аңа:— Яле, егет, дидем,
Торсалар да күннәр ялт итеп.
Һәм, сүзара, никтер сөйләп киттем
Борынгыны бераз яд итеп:

— Беләсезме бу егетнең чыгышын?
Патшалыкка аңа җиһан тар!—
Бабилләрен[4] Якын Көнчыгышның
Буйсындырган Ашшурбанипал[5].

Ассирия дип данлы бу патшалык
Чәчәк аткан илдән саналган.
Кайда ул ил хәзер, кайда халык?!—
Көлләр генә калган алардан...

---

[1] Такым кысу — шпорлау.
[2] Тарпу — арт аякларына басып күтәрелү.
[3] Айсур — Ассирияле.
[4] Бәбил — Вавилон.
[5] Ашшурбанипал — Ассириянен иң соңгы патшасы.

Бөек дауда — давылларда янган
Месопотамия[1] туфрагы.
Бу егет тә хәрабәдән калган
Бер адашкан вәкил шундагы...

Эшен бетереп, сикереп торды егет
Һәм тезләнде, үпте кулларым:
— Очрамаган иде Сезнең кебек.
Һич юк болай горур булганым!

— Тор,— дидем мин, акча суздым аңа.
Ул баш тартты:— Юк, юк, аламмы!
Мин бурычлы Сезгә, изге ата,
Искәрдегез ерак бабамны...

Сулышыннан бөек милли хиснең
Йоклап яткан күңел уяна!—
Адашкан кош кебек айсур мескен
Кайткан төсле булды ояга...

Халкы беткән, дәүләт юкка чыккан,
Язмыш кәфене алар өстендә:
Талда калган көзге яфрак сыман
Һаман тере милли хис кенә.

## Йөзләремне тут алды

Йөзләремне тут алды,
Йөрәгемне ут алды,—
Уйларымны саташтырып
Яхшы-яман буталды...

Яткан тимер тутлана,
Җанда күмер утлана:
Тимер рухың корыч булсын —
Син янудан туктама!

«Халкын сөеп зар иде,
Киң дөньялар тар иде...
Янып көлләргә әйләнгән
Нури бабай бар иде»,—

Диярләр, дими калмаслар,
Үз булгач, оныта алмаслар!

## Җан белән Йөрәк турында

Җан — күбәләк, оча-китә,
Ирек эстәсә әгәр...
Йөрәк тугры хезмәт итә,
Ташламый гүргә кадәр.

Ул тамырланган күкрәктә,—
Аның үз оясы бар.
Җан охшамаган йөрәккә,
Аның үз дөньясы бар.

Шуңа «Җаным!» димәгез,
Әгәр чынлап сөйсәгез.

## Бәйрәм иртәсендә

Бәйрәмгә кер юган килен төсле,
Яңгыр явып киткән,
Тузаннарын басып, җирнең өстен
Ул ямь-яшел иткән.

Һаман истә, яшел яшәү төсе
Кызыл канда иде...
Походларда батыр солдат өсте
Тирдән кара иде.

Җиңү көне кояш булып килде,
Кипте яшьләр, тирләр...
Туган илне алкышларга күмде
Җиңеп чыккан ирләр.

Мин шуларның берсе,— шатлансын җан,
Бер елмаеп кара.
Ләйсән явып, яшәрсен киң җиһан,
Сызланмасын яра...

---

[1] Месопотамия — Ассирия һәм Бабил дәүләтләре урнашкан жир.

## Күке

Кычкырма, күке, каршымда,
Сагышлы тавышларың...
Минем дә кайгы башымда,
Юк синнән калышканым.

Юрамыйм, тагын да күпме
Калгандыр гомерләрем,
Тик моңың үзәккә үтте,—
Мөлдери күңелләрем.

Әллә син дә миңа пармы?—
Ялгызлыктан ял тапмый
Гизәсеңме урманнарны,
Ояларга тал тапмый?..

## Яңа елда

Балкый январь көмеш тунын киеп,
Җирдә бүген бәйрәм, тантана:
Карап торам башым күккә тиеп!
Хәтер һаман мирас актара.

Туй күлмәге кигән кызлар сыман
Ап-ак тюльдә утыра каеннар:
Һава тып-тын, дөнья бәскә чумган.
Искә төшә иске Саиннар.[1]

Идел-Йортта, шушы Саин-Йортта
Дәүран сөргән әлек бабайлар.
Ул заманнар инде чыккан юкка,—
Күпме баткан кояш һәм айлар...

Минем төсле бер яныр, бер туңып
Борчылырлар микән мин юкта?!.
Аерылышу сагышы, яшен булып,
Кинәт төшә тәннән тубыкка.

Сыным катып, мин һәйкәлгә охшап
Калам, тирәм энҗе кар гына.
Нинди тылсым мине алган тышап,—
Үзем өнсез, күңелем талпына.

Каеннарга бәллүр бәстән күлмәк
Килешә икән!— ахры, купшыга.
Мин дә, юкса, бәйрәм итәм күкрәп,
Күңел генә нидер юксына...

## Кәнәфидә

Бөтен рухын алган ваем,—
Тыңлап утыра:
Гаҗәп! Йөрәк типкән саен
Тән тетрәп тора.

Әллә каушый микән инде,
Әллә шикләнә?
Диме:— Болай типмәс иде,
Бер дә тикмәгә.

Талпына йөрәк, талпына!
Син дә талпын, тән.
Яшәү кыллары тартыла,—
Чара юк бүтән...

Йөрәк арыган гына бераз,—
Юл бит гел үргә.
Гомер буе, сынганчы саз,
Яна ул бергә!..

## Гомер узар

Айыйм тәрәз төбемдәге миләшләрне,
Купшылыгы бетәр тиздән, кышлар килер:
Җимешләрен кырырга дип яу гаскәре —
Очлы бүрек кигән көрән кошлар[2] килер.

---

[1] Саин-Йорт — Изге йорт. Бабайлар үз илен шулай атаганнар.
[2] Көрән кошлар — урман чыпчыклары.

Үтәгән үз вазифасын миләш җәйдә,
Чәчәк аткан, җимеш биргән кызыл чуклы.
«Яшен яшәп, ашын ашаган»сың, бәндә,
Уфтанмачы син дә уйлап бер дә юкны.

Һәр нәрсәнең җирдә үз мөддәте булгач,
Кадерен белеп яшә, миләш төсле кызар!
Вакыты җиткәч хәтта сүнә диләр кояш...
Узган гомер, уза гомер, шиксез узар.

## Шаярып та, җитди дә

Мәхәббәт — шаян яр,
Килгән күк тиз китә...
Ә хөрмәт, игътибар
Кешене үз итә.

Хөрмәткә таянса,
Мәхәббәт гомерле.

Яшәүнең ләбаса
Шартлары мөһерле,—

Өрекми мөһердән
Яшәгез дустанә:
Өйрәтсәң, эт белән
Песи дә дуслана...

## Кара шәүлә

Сусылулар йөзә калкып кына:
Суда энҗе-мәрҗән балкып тора.
Бер сусылу җырлый айга багып,
Тирә-яклар тора моңга талып:
Сихерле музыка күккә үрелә...
Дөнья миңа җәннәт булып күренә,
Дулкын сиртмәсендә мин тирбәләм,
Минем милкем бүген бөтен галәм!

Тетрәп китәм мин бер ямьсез хәлгә,
Ак уйларга сырыша кара шәүлә:
Кәеф кырып каян төшә искә
Океан арты шомы шундый кичтә?!
Хәйям әйткән: «Кайгы салса яра,
Юаталмас хәтта Мәрьям ана...»
Галәм, юатма да, тирбәтмә дә,
Сал-Сал рухын иңдер мин матдәңә:

Халкы белән сыный чын ир көчен,
Ил язмышы изге анын өчен!

## Ялгызлыкта

Күңел үсми, кайгым үчми,
Нишләргә дә белмим...
Ник шомнарга, борчуларга
Дучар икән гел мин?!

Өзелә үзәк, ни хәл түзмәк!—
Сагышлардан талдым...
Үтте тостлар, китте дуслар,
Япа-ялгыз калдым.

Тик үлгәннәр — күмелгәннәр
Бәхил булсын инде...

Эстәгәнем: исәннәрнең
Бәхете булсын иде.

Минем кебек янып-көеп,
Ялгыз калмасыннар.
Язмыш түгел, язмышны гел
Алар алдасыннар.

Алдадым да, алдандым да,—
Калмады берсе дә.
Зарланырга, ялварырга
Юк бит тәңресе дә...

## Кичке диңгезгә карап

Кояш алтын күпер салган диңгез аша,
Шул күпердән атлап китәр идем мин дә,
Батмаенча, имеш, суга баса-баса
Атлаган бит бер изге җан Фәләстыйн[1]да.

Изге җаннар, ни әйтсәң дә, изге җаннар!—
Тынычлыкка халыкларны өндәгәннәр.
Тәхет өчен сугышкан патшалар, ханнар,—
Ил язмышын кирәк дип тә белмәгәннәр...

Тынып ята диңгез шәфәкъ нурларында,
Өстә балкып тора яңа туган аем:
Нинди моңлы кичә, нинди матур дөнья!
Гүзәлләнә бара хәят торган саен.

Тереклекнең шундый гаҗәп манзарасын
Мөмкинмени бөтен рухың белән тоймау!
Кузгатмаска иде кабат җан ярасын,
Җиткән инде сугыш-дәһшәт белән уйнау!

## Янартавым бар

Кем күргән дә аны, кемнәр белгән:
Йөрәгемдә янартавым бар!
Гаделсезлек, рәхимсезлек белән
Мәңге көрәш ачтым, давым бар!
Давым бар!

Газраил! Син һәлакәткә комар,
Ә җанымда минем давыллар!
Бер көн бәлаң тими калмас, мордар,
Беләм, күптән корган авың бар...

Син аулы, мин янартаулы шагыйрь,—
Сагышларым көйри җанымда!
Син гомерләр сүндерергә маһир:
Я, сүндереп кара янартауны,
Кукрәп күккә ашкан чагында!

Беләм, мин дә сиңа карыздар[2]...
Тик ашыкма исәп-хисап сорап,
Сыналганны бертуктаусыз сынап:
Кабынырсың үзең факел сымак,—
Яндырырмын, янартавым бар!

---

[1] Фәләстыйн — Палестина.
[2] Карыздар — бурычлы.

# Мөдәррис Әгъләмов

## Остаз

1

Озын буйлы, арык тәнле,
Сөяк тырпайган бәдәнле —
Чал чәчләренә кадәрле
Гамьле...
гамьле...
гамьле...

Әйтеләсе сүзе — кынлы,
Әйтелгәне — зифа сынлы,
Өмет тулы ике күзе
Моңлы...
моңлы...
моңлы...

Үткән юлы — чытырманлы,
Үтеләсе — бакый данлы,
Шигыре — камчы... һәр үреме
Тамчы-тамчы канлы...

Мал утларлык кабынганмы?
Әллә чабып алынганмы?—
Аның өчен һәрбер үлән
Җанлы...
җанлы...
җанлы...

Авырда да ил-көн санлы,
Ир-егетләре инсанлы —
Йомры, тере һәм тәгъбире
Саллы...
саллы...
саллы...

Бәгырькәен ачып ярды,
Шигъри иман телеп алды,
Табага май салган сыман
Безнекенә салды...
...Җанга җиңеләеп калды.

2

Күңелләр таба күк кызган,
Уй-фикер май кебек сызган,
Инде эш уеннан узган —
Буып алган иҗат.

Салынганмы тоз һәм борыч?
Әнис сибеп җибәр бер уч —
Остаз булып карый Бурыч:
— Нишләр икән бу зат?!.

— Нәрсә эшлисең, сукин сын?
— Чынлап, мин кая киттем соң?—
Остаздан башка кем суксын —
Кулны булмый тыеп.

Юатмагыз сыйпап баштан,
«Үчти-үчти» баштан ашкан,
Җәмгыятьнең ояты качкан,
Үз гаебен тоеп.

Ә күләсә зыр-зыр килә,
Намусына элеп кенә,
Гали затлар мыр-мыр килә:
— Бетә, егет, бетә!

Арты юеш булган хаклы,
Инде бугазыңа чаклы
Шакаллар тезгән шакмаклы
Такмак күмеп китә.

Сынып, сыгылып өметең,
Гомум җырга күчеп бер көн,
Үзең ышанырга мөмкин:
«Чыннан да, дип, бетәм».

Ялгышы да дөрес булган,
Җыр башыңа кереш булган,
Табаңа май салып торган
Остаз кирәк икән.
...Кыл өстеннән үтәм.

---

Мөдәррис ӘГЪЛӘМОВ *(1946) — шагыйрь, «Кыңгырау», «Учак урыннары», «Киләчәккә кайту» һ. б. шигырь китаплары авторы. Казанда яши.*

## 3

Аккош күлендәге бер эт,
Исеме дә саллы — Бөркет —
Тик татарча түгел.
Аягына чыра кергән,
Тубал кадәр шеш йөгергән —
Аны аңлау җиңел.

Бер гади нарат чырасы,
Якын баралмый хуҗасы —
Ул да авыр хәлдә.
Унике язучы тора,
Ә аякта гади чыра —
Йөрәктәме әллә?!.

Йөрәктә юк!
Юк йөрәктә,
Моны Бөркет белә хәтта.
Нигә «хәтта»? Ул — эт.
Боларның исемнәре бар,
Эче буш җисемнәре бар —
Ә ул бары Бөркет.

— Нәрсә булды?
Салмак кына,
Үзен-үзе аңлап кына
Остаз чыкты. Сабыр.
Гәп оралар:— Шулай-шулай,
Котkарып та булмый бугай,
Авыр хәле... авыр.

Күздә яшь, килә елыйсы.
— Кая, бирегез, җылы су...
Йөрәктәге чыра
Әрнүе кушыла бугай,
Этнең аягыннан шулай
Чыра чыга... чыга.

Эт аягы... гади чыра...
Унике язучы тора,
Бер ноктага беркеп.
Күз яшьләрен аглый-аглый,
Чын бөркетнең кулын ялый
Бөркет атлы бер эт.
...Алыр гыйбрәтләр күп...

## 4

Бер заман ул зур түрәгә
Шулкадәр ярсыды,
Сыгылып чыкты эче сүзләр:
— Сталин ярчыгы!

Тетрәнеп, сискәнеп киттем,
Корып кипте тамак.
Каты тешле тарак үтте
Акылымны тарап.

Сүтә иде шигыремне
Ижекләрен санап,
Ә бит монда мин-шәкерткә
Зур сәяси сабак.

Күренсә берәр зур эшнең
Барып чыкмаслыгы:
Бу — үзен искә төшерә
Сталин ярчыгы.

Кан коюдан җан кыюга
Кадәр барсын кыла,
Рәхәтлек булмасын бары
Тик халыкка гына.

Ватан диеп авыз суын
Корытса да гәрчә,
Халык дигәнчә булмасын,
Булсын ул дигәнчә.

Кояш чыкты. Һәр үләндә
Кара төннең чыгы —
Калтыранып ялтырый күк
Сталин ярчыгы.

Мәхәббәттән сагышланып
Йөз коябыз айга.
Уйладыкмы, ә нәфрәтнең
Чыганагы кайда?

Уйласакмы? Уйласак шул
Бер йомарлам булып,
Тарих кадәр чал тарихың
Килә куырылып.

Акланырга сәбәп тә бар:
Чоры шундый, чоры —
Һәр гаиләнең тәнендә
Сталин ярчыгы.
...Чынлыкның бар чыны.

5

Шөкер, илнең иртәсендә
Аның остаханәсендә
Адаштым мин бер көн.
Ышанмаслык, әмма ышан:
Булса никадәрле кысан,
Шулкадәрле иркен.

Шундый кысан, туган тел күк
Җиргә беркеп беткән өркеп,
Күзе тулы өмет.
Шул өметкә дөнья сыйган,
Гүли ул биектән койган
Зур шарлавык кебек.

Шундый иркен... Шаулый еллар...
Агач Себер... Корыч Урал...
Нәни йөрәк — зиндан.
Бернәрсә гадәти түгел,
Салкыннан җылынган күңел,
Эсселектән туңган.

...Аның остаханәсенә
Чистарырга килдем янә —
Килдем, калдым күпкә...
Аккошта — Кече тирән күл,
Керәсең икән — тирән кер!
Хаклык тирән — төптә.

Иң өстенә алгач йөкне,
Кем гаепсез, кем гаепле
Заман бәласендә?
...Какты йөрәк, кысты тыным
Совет чоры Тукаеның
Остаханәсендә.
...Кулны сузыйм кемгә?..

❁

*...Дулкынга дулкын...*

Ф. Шәфигуллин

*Мәрхүмнең җидесендә минем шигъри дулкынга аның авазы килеп керде.*

Автор. 14 октябрь 1982 ел

— Авылымның нәни инешләрен
Яратканга океаннарга чыктым,
ишелеп килеп аягүрә басты
дулкынга дулкын,
дулкынга дулкын.

Уйлаганмын ялгыш, уйлаганмын:
шундадыр дип минем җырлар җырым,
белә идем юкса океаннарның
нәни тамчылардан торганлыгын.

Океан белән Идел арасында
йөзәр еллык карагайлар ектым —
актарылды алда яшел океан
дулкынга дулкын,
дулкынга дулкын.

Җырлыйм әле дисәм...
Туган якның
карурманы җанга керде бәреп —
йөгереп узды Казан артындагы
карлыганнар җыйган әрәмәлек.

Кабат илгә кайтып, заводларда
сандалларга салып корыч суктым —
металл белән металл бәрелделәр
дулкынга дулкын,
дулкынга дулкын.

Кеше эзли үзен гомер буе.
Кая гына барма, хезмәт олы —
киерелеп ачыла кеше җаны,
кеше җаны — океан,
хикмәт тулы.

Очкыннары чәчрәп чыга җаннан
караңгыны җиңгән яктылыкның —
кеше әле үз-үзендә килә
дулкынга дулкын,
дулкынга дулкын.

Уятырга теләп, кешеләрнең
тәрәзәләренә үрел генә —
утлар кабына...
Әллә ничә язмыш
тәрәзәдә түгел, бер өлгедә.

Җимерелде инде, бетте, димә,
мөмкинлеге чиксез чынбарлыкның —
гаҗәпләнмә, ир һәм хатын килсә
дулкынга дулкын,
дулкынга дулкын.

Маңгай белән маңгай бәрелә дә
кочаклашып аннан китеп бара —
көлдереп тә, елатып та менә
иҗатында шуңа житеп кара!

Кешеләрне бер елмайта алсаң,
шатлык яше тама матурлыкның —
тормыш дәвам итә, көрәсезме,
дулкынга дулкын,
дулкынга дулкын.

Күккә житкән йортлар күтәрелә,
җиргә карый кеше, эзләп терәк —
югарырак менгән саен әле
кирә бару кирәк... тирәнрәк.

Кеше җаны өчен көрәш бара,
үзәгендә янгын дөньялыкның —
системалар, илләр килә әнә
дулкынга дулкын,
дулкынга дулкын.

Иҗатчылар!
Онытмагыз, бәхет
дулкын белән дулкын уртасында...
...Кеше җаны өчен көрәш бара,
Миннән башка бара,
миннән соң да...

**Миргазиян Юныс**

# ЕВРОПА АТ САГЫНА

ПОВЕСТЬ-СӘЯХӘТНАМӘ

*Ак кешеме, негрмы, син? Баймы, ярлымы? Нинди урында эшлисең? Бу турыда мин синнән сорарга теләмим. Нәрсә газаплый сине? Бәгырең нидән сыкрана? Нинди шом кыса йөрәгеңне? Кешелек вазифасы шушы сораудан башлана...*

Луи Пастер



Соңгы сәяхәт турында язарга җыенам. Хәтер, минем гомерлек бимазам, онытылып беткән вакыйгаларны чокып чыгарып, алдыма китереп сала тора. Ул хәзер миңа сәяхәттә күргәннәремне ташый. Ниләр генә очрамады ул җиде айга сузылган йөзүдә! Ике дистә беркетмәдә генә калган җыелыш, киңәшмәләр, дүрт йөз егерме тапкыр вахта алышыну, давыллар, коеп яуган яшенле тропик яңгырлар, корабны озата барган акчарлаклар тавышы, чайкалулар, өйдән хат көтү газаплары, хат алу куанычлары, сүнеп килгән кояшка карап кайнар палубада серләшеп утырулар, аяусыз сагынулар, сагынуларга түзә алмыйча йөзне мендәргә каплап өзгәләнгән йокысыз төннәр...

Язмышың аша узган күп нәрсә онытыла, юкка чыга. Министрлыкта утырган көннәрдән бер генә искә алырлык якты манзара таба алмыйм мин. Чорында гаҗәп мөһим, хәлиткеч тоелган вакыйгалар, комга сеңгән яңгыр суы шикелле, эзсез югала. Андыйларны берничек тә искә төшереп, кайтарып булмый. Көрәшсез, каршылыксыз, җиңеллектә узган мизгелләрне хәтер кире җанландыра алмый. Нигә соң үткән гомер, кайтмас көннәр мине болай бимазалый? Яшәүнең тере өлеше — бүгенгелектә яшәргә тырышам. Бүгенге кайгылар, бүгенге мәшәкатьләр дә җитәрлек бит. Киләчәкне кайгыртырга, аны лаеклы каршыларга кирәк. Бала чактан алып, үзгәртеп кору чорына кадәр безне киләчәк шәүләсе белән туклandырып тордылар. Нинди гүзәл, нинди соклангыч иде ул газета битләрендә сурәтләнгән киләчәк! Илленче елларда — ташып, читләреннән агып торган муллык. Алтмышын-

---

Миргазиян ЮНЫС *(1927) — прозаик. «Тозлы җил», «Энҗе эзләүчеләр», «Шәмдәлләрдә генә утлар яна» һәм башка китаплар авторы. Мәскәүдә яши.*

чы елларда — безнең буын коммунизмда яши. Житмешенче еллардан башлап — тагын муллык, ожмах тормышы. Бүген исә каршыбызда — яңартып кору, хәбәрдарлыкның аяусыз көрәше һәм катлаулылыгы арта барган тормыш...

Хәтерне мин йөгәнләргә тырышам. Житәр, дим, туйдырдың, тукта, ял бир миңа, тыныч, гамьсез яшисем килә! Тыңламый. Хәтер миңа һаман баштан кичкәннәрне ташый. Үткән көннәр кайтавазы мине кабат бимазалый. Нәкъ шул катлаулы сораулардан, чишеп булмастай мәсьәләләрдән котылырга теләү кулга каләм алырга мәҗбүр итә. Тынгысыз уйларны ак кәгазьгә ыргытып, котыласым, аларны укучы белән бүлешәсем килә...

Безнең гомер аяз көндә зәңгәр күктә эрегән сыек төтенне хәтерләтә. Ул һаман өскә, һаман биеклеккә омтыла, сыегая, эри, юкка чыга. Хәтер — шул юкка чыгуны тар-мар итү өчен туган көрәшче. Ул үткән гомернең сурәтләрен генә кире кайтара алуын әллә белми, әллә белергә теләми. Яшәүне кабатлау мөмкин түгел. Их, шушы чарасызлык!

...Жданов каласы. Аның элекке исеме Мариуполь. Минем борынгы болгар бабаларым яшәгән җир. Бу төбәктә аларның сөякләре күмелгән. Бу җирдә безнең бер катлам тарихыбыз ята. Бәлки мине шул сөякләр, шул тарих тартып китергәндер бирегә? Ждановтан унсигез чакрымда, Калка елгасы буенда, 1223 елның маенда берләшкән рус һәм кыпчак гаскәрләре татар-монголлар белән очраша. Ул чакта минем ерак бабаларым Идел буенда яшиләр. Бүгенге көндә «татар» исемен йөрткән халыкның тарихчылары, әдипләре, галимнәре: «Без татар-монгол явын оештыручылар түгел, ул яу Рус дәүләтенә барып житкәнче иң әүвәл безнең илебезне таптап узды»,— дип сөрән сугалар. Кызганыч: бу авазга колак салучы, хакыйкатьне ачыкларга теләүченең генә шушы көнгә кадәр табылганы юк.

...Сәяхәттә күргәннәр. Әнә, Белград белән Дубровник арасындагы таулар. Упкын төбендә боргаланып көмеш елга ага... Согуд Гарәбстаны. Жиддә порты. Мәзин әйткән азан тавышы. Докерлар, бетон причалга намазлык җәеп, сәҗдә кылалар. Эш тукталды... Британ атавының акбур ярлары. Лондон белән Бристоль арасындагы автострада. Машиналар агымы. Жентекләп эшкәртелгән кырлар, вак-вак квадратларга бүленгән хосусый болыннар... Унике баллы дулкын куган ачы давылда океанга чыга алмыйча, Бристоль култыгында дрейфта яту... Гамбург каласы. Сан-Паули кварталындагы кәеф-сафа индустриясе. Йортларның урамга караган пыяла витриналары эчендә «кунак» көтеп утыручы фәхеш курчаклары... Бремен каласының үзәк соборы. Собор каршында кечкенә генә бронза һәйкәл: ишәк сыртына эт, эт өстенә мәче, мәче аркасына әтәч кунаклаган — Бремен музыкантлары... (1937 елның май ае. Икенче классны тәмамлаган көн. Мәктәп бүләге — «Бремен музыкантлары» дигән китапны кулыма тотып өйгә кайтуга, Баулыда мәктәп директоры булып эшләүче туганыбызны «халык дошманы» итеп төрмәгә ябу көтеп тора иде...) Калькутта музее. Көмештән коелган поход комганы, алтын бизәкле, саплары асылташтан ясалган кылыч-хәнҗәрләр, Коръән аятьләре язылган түгәрәк калканнар — Бабыр, Жиһангир, Әкбәрләрнең сугыш кораллары.

Шул жиде айга сузылган сәяхәттә очраган байлык һәм хәерчелек, ирек һәм коллык, бәхет һәм бәхетсезлек, меңләгән, йөз меңләгән кеше сурәтләре. Шуларның һәммәсен дә үз илеңдәге, үз җиреңдәге кешеләр, тормыш чынбарлыгы белән чагыштырып барасың. Күзаллауның офыклары киңәя, хәбәрдарлык арта.

Буржуаз Бельгиядә бер иртә. Урам буш. Халык әле йоклый. Сөт сатучы кичтән баскычта калдырган буш шешәләрне алып, алар урынына сөтле шешә куеп китә. Сөтче артыннан яшелчә, җиләк-җимеш сатучы, аның артыннан ипи пешерүче Антверпенда яшәүчеләрне азык-

төлек белән тәэмин итеп йөриләр...

Бу дөньяда адәм баласы нәрсәгә мохтаж? Аңа ипи һәм тынычлык, ихтирам һәм хакыйкать, шатлык һәм тигезлек кирәк. Адәм баласы гомерен акчага эшләп уздыра. Акча — тирес, ул безнең көндәлек тормышны ашлап тора.

Диңгезчеләрнең төп йорты — җир шары. Планета тирәсендә тыргагына атом бомбасы кыскан тимер кошлар оча башлагач, тынычлык юкка чыкты. Океанның иң ерак, иң аулак җирендә дрейфта ятасың. Һавада горурлык кошы — альбатрос оча. Шундый аулак һәм тыныч. Кинәт су болганып китә дә су өстенә атом көче белән йөрүче субмаринның лайла каплаган мәкерле кара рубкасы калкып чыга. Көймә карынында — миллионнарга җитәрлек афәт, фән-техниканың иң соңгы казанышына таянып эшләнгән үлем. Тынычлыкның дөньядагы иң зур байлык икәнлеген шундый чакларда аңлый башлыйсың.

...Франция. Марсель порты. Газета-журнал сата торган киоск. Витринада әле яңа чыккан «Эспрессо» журналы. Тышлыкта Франциянең культура министры Андре Мальро портреты. «Максим» ресторанында ат казылыгы ашап утыра. Без әле күптән түгел генә ат казылыгы яраткан кешенең маңгаена «милләтче» дигән мөһер суккан заманда яшәдек. «Кешелекнең яшәү шартлары», «Өмет», «Антимемуарлар» авторы, Жан Поль Сартр, Альбер Камю, Роб Грийеләр белән экзистенциализм философиясенә нигез салган, Испаниядә интербригада составындагы эскадрилья командиры булып сугышкан интернационалист төрки кабиләләр азыгы — ат казылыгын мактый.

Диңгезче күпне күрә. Диңгезче дөнья халыкларының гореф-гадәтләре белән таныша ала. Диңгездә йөзгәндә китап укырга, үзлегеңнән белемеңне үстерергә мөмкинлек бар. Ләкин диңгез сәяхәтенең бер куркыныч ягы бар: диңгез эше сине халкыңнан аера. Сәяхәттә күргәннәр — чит күренеш, йөзү вакытында үзләштергән культура — ят культура. Әгәр син шуларга ышанып, халкың белән элемтәне өзсәң, тора-бара тамырың корый. Тамырсызлык — бүгенге көннең иң зур афәте, чорның иң куркыныч билгесе. Рухи ашлама, җан азыгы бары тик туган халкыңа береккән тамыр аша гына килә ала. Тамырларың өзелдеме син — тере робот, манкорт.

Озак еллар мине туктаусыз сәяхәткә куып торган каһәрле көчнең каян барлыкка килүен аңларга тырышам. Авыруын яшергән үлгән, диләр. Озак еллар мин, дөнья күрү теләге, романтика куа, дип сылтау табып йөрдем. Туган җирне ташлап китеп, сәяхәттә нужа күреп йөрүнең сәбәбе исә анда гына түгелдер?

Безне Сталин культы заманы тәрбияләде. Безнең җитлеккән чак Брежнев тудырган торгынлык чорына туры килде. Миләребез диктатор боерыгына буйсынып фикер йөртергә көйләнгән иде. Без, теләсә нинди фәрманны үтәп, сүзсез, шәхси теләксез күндәм кол булып яшәдек.

1945 ел. Хәрби авиация курсантлары арасында политзанятиедә утырам. Сталинның Ватан сугышы полководецлары мәҗлесендә әйткән тостын өйрәнәбез. «Тигезләр арасында беренче булган бөек рус халкы хөрмәтенә тост тәкъдим итәм». Политдәреснең темасы — шушы җөмлә. Җитәкчебез майор Гусаров, Коръән аятен тәфсирләгән шикелле, җөмләнең эчтәлеген безгә аңлата: «Сезнең арада, тигезләр арасында беренче дә, икенче дә булмый, дип ялгыш фикер йөртүче очрарга мөмкин. Сталин — даһи. Шунлыктан, ул тигез хокуклы, интернациональ дуслыкта яшәүче милләтләр арасында кемнең беренче, кемнең икенче һәм кемнең иң соңгы милләт булуын да аера ала. Безгә, җәмгыять механизмының винтикларына, андый даһи сәләт бирелмәгән...» Тәнәфескә чыккач, винтиклар, йодрыклашу хәленә җитә язып, кайсы милләтнең икенче, кайсы халыкның җиденче һәм җитмешенче урында булуы турында бәхәсләшергә тотындылар.

Тагын бер эпизод. «Фән һәм дин» журналында эшләгәндә Үзәк Комитет оештырган комисия составында Әзербайҗанның рухи тәрбия эшен тикшереп йөрибез. Поезд безне Иран чиге буйлап Нахичеваньга алып бара. Чикнең коймасы югары көчәнешле электр тогы җибәрелгән, керпе дип аталган, тәненә кадала торган чәнечкеле тимерчыбыктан эшләнгән. Илле метр киңлегендәге контроль зона. Чакрым саен эт ияртүкән кораллы чик сакчылары.

— Кош та очып үтә алмый,— дип аңлата застава командиры.— Чикне үтеп чыгу асылда мөмкин түгел...

Ә мин нәкъ шушындый чәнечкеле тимерчыбык белән уратып алынган, эт ияртүкән кораллы солдатлар саклаган лагерьны Сахалинда күргән идем. Күңелдә тетрәндергеч ачыш: «Безнең тормыш бит төрле яктан чәнечкеле тимерчыбык белән уратып алынган, аннан ничек котылырга?»

Әти-әни һәм ватан — болар бәяләү бизмәнендәге иң югары, иң изге өлешендәге урыннар. Туган иленә, халкына, әти-әниенә хыянәт итү җинаяте бәхиллексез. Бу хакыйкатьне аңлатып торасы юк. Чәнечкеле тимерчыбык белән уратып алынган, кораллы солдатлар саклаган зона эчендә яшәүне ирекле кабул итүчеләр күпме икән безнең арада?

Оста әдип коллизия серен әсәрнең азагында гына ача. Мин укучыга әсәрнең планын алдан сөйләдем. Ни өчен? Без бит хәбәрдарлык чорында яшибез. Мавыктыргыч нәрсәләр белән укучыны ымсындыру миңа урынсыз тоела.

## Ике йөз унҗиденче тәүлек. Валенсия. 11.00

Сәяхәтнең соңгы көннәре искә төшкәндә гаҗәпләнеп куям. Андый шартларга ничек түзгәнбез икән? Тән генә түгел, хәтта теләкләр дә, күңел дә арыган иде. Баш тәмам диңкегән. Минем кыймылдыйсы, фикер йөртәсе килми. Кешене поездда бару да ялыктыра. Ике йөз егерме дүрт тәүлек! Җиде ай буе поездда туктаусыз барып кара әле? Кораб янынннан туктаусыз су агып торуы, офыкларның сәгать саен үзгәрүе, ярлар, утраулар, тулы бер материкларның күренеп юкка чыгуы, меңләгән яңа шәхесләр, чит телләрнең яңгыравы тора-бара сине шомландыра, әллә нишләтә. Таныш тормышны, күнегелгән көнкүрешне инде беркайчан да күрә алмам дип хәвефләнә башлыйсың. Йокыдан уянган саен яңа күренеш, көн аралаш диярлек яңа ил, ә туган җир һаман кайдадыр еракта. Сәяхәтнең беренче көннәрендә син яңалыкка куана идең, ә хәзер, алҗыгач, һәр яңалык күңелгә шом сала. Күз үзгәрешләрдән туйган. Колаклар машина гөжләвеннән, шторм үкерүеннән томалана башлаган. Тән калтыраудан арыган. Җан тынычлык тели.

Кеше табигате — чиксез карурман. Кеше күңелен, аның эчке дөньясын өйрәнү өлкәсендә без әле һаман «а» хәрефе тирәсендә, сукыр чебен шикелле әйләнеп йөрибез.

Гибралтар бугазын узып, Урта диңгезгә керү безне беркадәр җанландырып җибәрде. Бу инде өйгә кайтып житүнең яртысы дигән сүз. Урта диңгез безнең өчен ындыр арты гына. Атна-ун көннән син өйдә.

Валенсия портының тышкы рейдына якорь салганда төн урталары иде инде. Иртәнге җидедә лоцман килде. Ул безгә яңалык алып килгән: бүген Валенсия каласында фиеста — испан халкының милли бәйрәме. Порт, билгеле, эшләмәячәк. Ял һәм бәйрәм көннәрендә эш хакын икеге, өчкә тапкырлап, докерларны эшләтергә була. Диңгезчеләр телендә бу хәл овертайм игълан итү дип атала. Фиеста көнне эш хакын йөз тапкырга арттыр, йөрәге испанча типкән докер акчага кызыгып эшкә чыкмаячак, өметләнмәгез, дип аңлатты безгә лоцман. Төштән соң Валенсия аренасында үгез сугышы — коррида булачак.

Кыр эшләре бетүне күп халыклар бәйрәм белән билгеләп узалар. Ялыктыргыч авыр эштән соң кеше күңелен шау-шулы тамаша, уенкөлке белән уятып җибәрмәсән, хезмәткә дәрт сүнәчәк. Борынгылар шушы мәсьәләне аңлаганнар һәм әнә нинди матур чаралар тапканнар: фиеста, бәйге, карнавал, әтәч сугышлары. Бәйрәм сылтавы белән кунак чакырырга була. Уртак шатлык, күңел ачу. Күмәк куанычлар. Эчкә моң җыелган. Аңа юл бирергә, ирекка чыгарырга кирәк. Бураз-на таптап аяклар алҗыган, аякларны биеп язылдырырга кирәк. Фиестаның күңел күтәрү, дәрт кабызу сере нәкъ сабантуйныкы шикелле — ирекле хәрәкәттә. Дөрес, фиестаны туристлар зәвыгына көйләп шактый үзгәрткәннәр, безнең сабантуй да хан заманындагыча түгел бит. Сабантуй элек сабанга чыгар алдыннан уздырыла торган булган, ә хәзер язгы чәчү эшләре беткәч үткәрелә.

Сабантуйның үзәк тамашасы — ат чабыштыру, көрәш, фиестаның үзәк номеры, җаны — коррида. Казан каласы белән Валенсия шәһәре арасындагы ераклыкларга биек таулар, елгалар, ашлык басулары, карурманнар, кеше үтә алмаслык сазлыклар, күлләр сыйган. Шуңа карамастан, ара ераклыгы шушы ике халыкны бер-берсенә охшамаслык итеп үзгәртә алмаган. Җир йөзендә яшәүче кешеләрнең табигате уртак, шушы уртаклыкны тар-мар итәрлек яисә үзгәртә алырлык көч тә, сихер дә юк. Планетабызда яшәүче барлык халыкларның шат һәм бәхетле буласылары килә. Милләтләрне зәңгәр һәм кара канлыга, культураны Европа һәм Шәрык культурасына бүлергә өйрәнгән шовинистларга, билгеле, татар белән испан халкы арасындагы уртаклык ошап җитмәс. Милли гореф-гадәтләрне өйрәнергә, аларны бәяли белергә вакыт җитте.

Испаниягә барып коррида карап кайткан язучыларның мәкаләләрен күптән күзәтеп барам. Аларның һәрберсе, нигә үгезне шулай интектереп үтерәләр, дип испанлыларга бәйләнә башлый. Чит монастырьга үз уставың белән керергә ярамаганны оныту гадәти хәлгә әверелеп килә. Мал кызгану ни сәбәп коррида караганда гына уяна? Кибеттә үгез ботының итләчрәк җирен сайлаганда, янып-пешеп учак янында шашлык пешергәндә һәм табын янында шатыр-шотыр сөяк кимергәндә нилектән бу тойгы уянмый икән? Чыннан да, үгез сугышын миллионлаган тамашачы карый. Испаннарга кан коюның нәрсәседер ошый. Алар, ни сәбәптер, үлем белән качышлы уйнауны кабул итә. Алар гына түгел, экипаж әгъзалары, көндәлек тормышта юаш кына бәндәләр, кино экранында атышу, кан коюны үлеп яраталар. Каян килә ул канга сусау? Аңа нәрсә сәбәп? Мине шушы сораулар тынгысызлый.

Казан тирәсе борынгы йолалардан иртәрәк арынгандыр, бәлки? Безнең Баулы районы авылларында әле мин белгәндә генә җыеннар, бәйгеләр, карга боткасы, бәбәй туйлары, су сибешеп яңгыр теләүләр — мәҗүсилек чорыннан сакланып калган борынгы йолалар исән иде. Колхозлашу елларында Кандыз базарына бару хәтеремдә калган. Ул чакта күргәннәрне бәяләргә көч җитмәгән. Европа белән Азиянең, дала һәм урман халыкларының очрашкан урыны иде ул Кандыз базары. Дөя җигеп килгән кыргызлар, хан атласыннан теккән чапаның салмый йөрүче үзбәкләр. Ак ыштыр өстеннән чабата киндерәләрен тезләренә кадәр урап җибәргән чуваш абзыйлар. Себер татарлары, башкортлар, пенза мишәрләре, арлар, мукшылар, нугай татарлары — мин белмәгән тагын әллә кемнәр. Алыш-биреш белән генә чикләнми ул шәрык базары. Шәрык базары ул — клуб та, җыелыш та, тормыш корылтае да, яшәргә өйрәнү мәктәбе дә. Шәрык базары ул — гигант театр һәм этнография семинары. Җир йөзендә базар үтәп килгән шундый чиксез мул вазифалы башка җәмгыять институты бармы икән?

Кордова хәлифәте заманында испан гарәпләре — морисклар гарәп, фарсы, төрекләр белән бер казанда кайнаганнар. Бу кайнашу нәкъ

Болгар дәүләте һәм Казан ханлыгы дәверенә туры килә. Безнең ерак бабаларыбыз ул чакта испанлылар белән хаҗ юлында һәм Мәккәдә генә очрашмагандыр бәлки? Ул чакта «чик буен ябу» хәлен белмәгәннәр әле. «Лә илаһы илля аллаһы...» паспорты белән Кордовадан Джакартага, Шәһри Болгардан Босрага кадәр бер тоткарлыксыз үтеп йөрергә мөмкин булган. Ерак бабаларыбыз Һиндстанга барып кайтуны ерак юл санамаган. Шуңа күрә, Исергәп авылы тарихында испан корридасын мин беренчеләрдән булып күрдем, дип әйтергә телем бармый.

Җиңел машинага кыңгырау тагып йөргән кешене күргәнем юк минем. Атка ияреп, безнең көнкүрештән шактый күркәм йолалар да китте, югалды. Сабантуй көнне йокыдан кыңгырау тавышы уята иде. Тимер хутлы арбаларга пар атлар җигеп, яшь-җилбәзәк урам урап йөри. Бизәкле дугаларда җиз кыңгырау. Атларның ялында чиккән яулыклар җилферди. Әле кичә генә көч-хәл белән сабан сөйрәп йөргән бахбай гармун тавышына ярсып йөрәк кага. Испан фиестасында кыңгыраулы пар атка утырып йөрүчене очратмадым мин. Ләкин фиестаның мохите, аның сулышы һәм бәйрәм иткән кешеләрнең өстендәге күлмәкләре, аларның йөзләренә бәреп чыккан елмаюлар, өйләрдән аңкыган таба ашы исләре, музыка яңгыравы, хәтта кояшлы көннең аеруча саф, чиста һавасы — барысы да сабантуйны хәтерләтә иде. Бәйрәмдәге нурлар, сөйләп тә торасы юк, алар бөтенләй башка. Испан күгенең зәңгәргә манылган чиксезлеге бүген тагын да көчәеп, җетеләнеп киткән. Тыштан бераз ялкау, эчендә утлар кайный торган испан музыкасы бүген аеруча моңлы яңгырый. Йөрәкнең иң сизгер урынына китереп бәрүче алты кыллы испан гитарасы, кастаньетлар (кастаньо — каштан чикләвеге) шакылдавы. У-у-у! Әйттер, кызым!..

Кеше күңеле — чиксез дәрья. Хисләр океанының иген-чиген әле беркем үлчи алмаган. Бәйрәм театрына катнашучыларның һәммәсе — артистлар. Бәйрәм безне сабый чак куанычларына кире кайтара. Бу көнне син бала чактагыча беркатлы, саф, самими. Бу көнне син сәләтле. Каян килә сиңа бу сәләтләр? Бүген җырлый да, бии дә беләсең. Әгәр сабантуй бәйрәмендә җырга, биюгә, көрәшкә, ат ярышына үзең катнашмасаң, йөрәгең катнаша. Бу көнне син җиңүче. Җиңүчеләр шатлыгы — иң көчле, иң бөек, шифалы шатлык.

Таңда рейдтан кузгалып, портка керә башладык. Порт ял итә. Бер кран эшләми. Порт эчендә бернинди хәрәкәт юк, бер кеше заты күренми. Корабны Муэлле ди Тьерра пирсына куйдылар. Иртәнге чәйдән соң палубага чыктым. Тауларны күзәтәм, тау битенә кунаклаган авылларны, аерым йортларны. Шундый бер йортка урнашып, түтәл казып, бакча үстереп яшисе килә башлый.

Кораб янына зәңгәрсу перламутр төскә буяган япон машинасы «ниссан» килеп туктады. Ишек тавышсыз гына ачылды, машина хуҗасы пирска төште. Хуҗаның өстендә өр-яңа костюм, ак батист күлмәк, яка астыннан зәңгәрсу кара күбәләк галстук күренеп тора.

— Буэнос диас, примо![1] — «Ниссан» хуҗасы миңа сәлам биргәч, палубага күтәрелеп кулымны кысты. Франсиско Доминген бит бу! Минем дустым Пако, Валенсия портында эшләүче агент. Мин аның белән моннан җиде ел элек «Михаил Светлов» корабында эшләгәндә танышкан идем.

— Буэнос диас, Пако.— Һәм испанча белүем шуның белән чикләнә, итальянчага күчәм.— Комэ стаи, каро?[2] — Агентның болай киенеп-ясанып килүенә һаман күнегеп җитә алмыйм, сорарга мәҗбүр булам: — Әллә өйләнергә җыенып йөрисезме, синьор Доминген?

— Бүген фиеста, примо. Испан халкы бәйрәм ярата. Испан до-

[1] Буэнос диас, примо! — Хәерле көн, беренче! (испанча).
[2] Комэ стаи, каро? — Ничек яшисең, кадерлем? (итальянча).

керларын сездәгечә давай-давай белән генә эшләтеп булмый. Бер атна эшләсә, бер ай ял сорый испан докеры.

Аңлашылды. Башка вакытта Доминген шактый таушалган «сеат»ка утырып йөри иде. Аның өстендә инде күптән ял сораган иске свитер һәм дөнья күргән күн пиджак була иде. Безнең агентның атлап йөрүләре дә үзгәргән — тора салып биеп китәр шикелле тоела.

— Бүген фиеста, примо. Капитан үз каютасындамы? Сез киенә торыгыз. Мин сезне коррида карарга алып барам.

— Капитан әнә бассейн янында йөри. Валенсиядә бәйрәм икәнен белгәч, аның кәефе кырылды. Безнең тизрәк өйгә кайтасыбыз килә, Пако.

— Буэнос диас, баркадор![1] — диде агент капитанны күрү белән.— Сәламәтлек ничек? Рейс тыныч кына узамы?

— Сәламәтлеккә зарланырлык түгел,— диде Михаил Александрович Гремин.— Сезнең монда бүген порт эшләми, шунысы начар.

— Бүген фиеста, капитано. Бүген эшләргә ярамый. Фиеста көнне фундадор эчәләр, биниләр, кызлар кочалар. Мин сезне коррида карарга алып барам, җыенегыз.

— Рәхмәт, мин бармыйм,— диде капитан.— Иртәгә эш көнеме соң?

— Испан фиестасы, капитано, бер атнага сузыла. Ә сезгә, әгәр эшне тизрәк бетерергә теләсәгез, иртәгә докерлар табарбыз. Ә бүген коррида карарга барабыз.

— Мин бармыйм. Безнең беренче ярдәмче андый тамашага һәвәс кеше. Ул барыр бәлки?— диде капитан миңа күрсәтеп.

Капитанның корридадан баш тартуы мине куркыткан иде. Үзе бармагач, беркемне дә җибәрмәс, дип уйлаган идем. Беренче ярдәмче андый тамашага һәвәс дигәч, эчемә җылы кереп китте. Аның белән шәһәргә чыксаң, ун минуттан сәгатенә карап, кыбырсый башлый. Капитанның иң яраткан бүлмәсе — үз каютасы, иң яраткан тамашасы — пароходчылыктан килгән рәсми кәгазьләр. Белмим, диңгезчелек эшенә керешкән елларны ул шәһәргә чыгып йөрдеме икән? Мин аның белән инде дүрт ел эшлим, шул вакыт эчендә причалга төшкәнен дә сирәк күрәм. Ят вакыйгалардан, чит күренешләрдән күңелен бикләп, үзенең эчке мохитендә яши торган кешегә әйләнгән безнең капитан. Ял вакытында да ул өендә бикләнеп утыра. Иртән иртүк сөткә барып кайта да, көне буе телевизордан башка бер җан иясе белән очрашмыйча ялы беткәнче яши. Миңа Михаил Александровичның башкалардан калышмаска теләп, яңалыклар, үзгәрешләр артыннан кумыйча, хәбәр ташкыныннан читтә, тыныч кына үз көенә яшәве ошый.

Инструкция чит илдә ялгыз йөрергә рөхсәт итми. Миңа корридага барырга иптәш эзләргә кирәк иде.

— Коррида карарга син бармыйсың инде?— дидем мин капитанга.— Белмим, кемне алырга икән соң?

— Өлкән ярдәмчегә тимә. Ул тревога расписаниесен яңартып утыра. Өлкән механикны ал. Кубань казаклары чая халык, аларга канлы үтереш ошарга тиеш.

Мин өлкән механик Горбаненконың каютасына юнәлдем.

— Юрий Семенович, агент безне коррида карарга чакыра, әйдә, киен. Тизрәк бул, ул көтә.

— Эш муеннан. Моточистка оештырасы бар. Бара алмыйм, гафу ит.

— Икенче механик оештыра алмыймыни ул эшне? Син аңа нигәдер ышанмыйсың. Аңа бит инде күптән өлкән механик булып эшләргә вакыт.

— Әгәр берәр ялгышлык җибәрсәләр, судка мине тартачаклар. Юк, берәүгә дә ышанмыйм.

[1] Баркадор — кораб хуҗасы (испанча)

— Министрның бер йөз туксан икенче приказында нәкъ шул хакта сүз бара. Житди эшләрне күбрәк ярдәмчегә йөкләргә, аларны җаваплылыкка өйрәтергә, диелгән ул әмердә. Ә син ачыктан-ачык әлеге приказга каршы эшлисең. Ярамый алай.

Министр боерыгы, югарыдан төшерелгән күрсәтмәләр — өлкән механикның иң сизгер, нәзберек урыны. Мин юри аның шушы сизгер кылына чирттем.

— Нәрсә соң ул коррида? Коррида, коррупция, корреляция — чуртыммы белеп бетергән шундый сүзләрне,— Горбаненко ялгышлык ычкындырды. Гадәттә, ул галимнәрчә сөйләшергә ярата. Узган елны гына читтән торып институт бетерде. Билгеле, диплом алганга карап, белеме дә, акылы да артмады, үзен галим санап масаюы гына көчәйде. Вуз значогын һәрвакыт түшендә йөртер.

— Югары белемле кеше, Юрий Семенович, корриданың нәрсә икәнлеген белергә тиеш. Син бит курортка йөрергә яратасың. Анда берәр яшь кенә фән кандидаты белән танышырсың, коррида турында сүз чыгар, ә син, югары белемле кеше, шуның нәрсә икәнлеген белмисең. Юк, «бабакай», алай ярамый. Син бит чит илләргә йөрүче морякларның исеменә тап төшерәсең.

Горбаненко уйга калды. Соңгы дәлил, чыннан да, көчле иде. Кубань казаклары күп гасырлар җирле төрки кабиләләр белән аралашып яшәгән. Алар, кавказлылар шикелле үк диярлек, кайнар канлы. Тышкы яктан безнең өлкән механик та кавказлыларча кайнар күренә иде, ә эчендә таштай каты торгынлык, дөм-кара пошаманлык ята. Аның шушы ягын исәпләп, мин тагын бер козырьны чыгарып салдым:

— Коррида ул, Юрий Семенович, аренада үгез белән сугышу. Ул сугышта ат та катнаша. Мин үзем, мәсәлән, шул атлы сугышчы, пикадорны карарга барам. Мондый мөмкинлекләр безгә тагын кайчан очрар? Бармасаң, үкенерсең, Юрий Семенович.

— Ул сугышта, чыннан да, ат катнашамы?

— Пикадор — корридада төп фигура.

— Алай булгач, барырга туры килер. Унбиш-егерме минут көтә аласызмы? Мин машина бүлегенә төшеп, икенче механикка боерык кына биреп киләм.

— Төгәл унбиш минут. Франсиско көтеп торырга яратмый.

Мин агентны каютага чакырдым:

— Фиеста хөрмәтенә әллә бераз эчне дә чылатып чыгыйкмы? Эрнест Хемингуэйның фиеста турындагы китабында әсәрнең геройлары эчләрен туктаусыз «фундадор» һәм шәраб белән юып торалар.

— Юк, примо, бүген ярамый. Мин бит машина йөртәм. Фиеста көнне испанлылар әкрен йөрергә яратмыйлар. Юк, бүген мин бер тамчы капмыйм.

Сабантуй көнне дә минем якташларым әкрен йөрергә яратмыйлар иде. Белмим, машинага кучкәч, ул гадәт бетмәдеме икән?

Горбаненко фиеста хөрмәтенә иң яңа костюмын киеп җибәргән, түшендә институт значогы ялтырый.

Причалга төштек. Машинага кереп утырдык. Машинаның исеме дә «ниссан» бит — Дәрдмәнд шигырьләрендәге фарсы сүзләре шикелле яңгырый.

Машинаның затлы икәнлеген мин шуннан беләм: андыйның эченә кереп утыру белән ниндидер кодрәтле көч сине хәйран калырлык зур, бөек шәхескә алыштырып куя. Андый машинада дөньяның гел якты якларын гына күреп йөрисең. Бу юлы да шулай булды. Машина эченә кергәнче мин бары тик капитанның беренче ярдәмчесе генә идем. Кереп утыргач, теге Хемингуэй әсәрләрендәге коррида карарга баручы геройларга әвереләдем. Зәңгәрсу хамелеон тәрәзәләр яктылыкны хисаплап, кирәк кадәр генә кертә. Хамелеон пыяла тылсымы аша җир йөзе бөтенләй башкача күренә. Машина яныннан гади йортлар — патша са-

рае, куаклар — гигант баобаб, тротуардан җәяү титаклаучылар — кырмыска шикелле генә күзгә чагылып китә. Патша заманында кешеләр байга һәм ярлыга бүленгән, безнең чорда исә — машиналы һәм җәяүлегә.

Кузгалып китүне сизми дә калдым мин. Башта кораб урыныннан кузгалгандай итеп куйды. Аннан соң контейнерлар тавы, порт капкасы, Муэлле дель Кабаньял причалының шома асфальты тоташ тасма булып артка таба шуыша башлады. Күз ачып йомган арада без Армада ди Испаньола мәйданында идек инде. Түбәләренә яшел җилпәзә элгән орчык пальмалар безгә башияргә өлгерә дә алмый калалар. Койма өстеннән бүселеп төшеп торган бугенвилия чәчәкләре, муеннарын сузып, безгә елмаялар, аларның букет булып кулга керәселәре килә. Чәчәкләргә гамь салып торырга вакытыбыз юк — без бит, «ниссан»га утырып, коррида карарга барабыз! Мавритан ысулында уелган тәрәзәләр, биек манаралар, яннарыннан узганда үрә катып, безгә честь бирергә телиләр. Без җил шикелле очып кына узабыз. Карап торырга вакыт юк.

Йортлар арасыннан ак комлы пляж — Плайя Мальваросса килеп чыкты. Әнә җәйге «Нептуно» рестораны. Узган ел без шунда гаҗәп матур утырган идек. Диңгездә яшәүче җан ияләренең барысын бергә җыеп табада кыздырган ашамлык — фрутто дель маре, солтан балыгы, ак шәрабтә кыздырылган мерлуза, устрица, каракол[1], шуларны «Тео пепе»[2] белән чылатып ашап утырдык. Десертка әфлисун, банан, берничә төрле чикләвек һәм шуннан соң өстенә нескафе сибеп, виски белән чылатылган мороженое китерделәр.

Авенида дель Пуэрто проспекты шәһәр үзәгенә илтә. Урам күзеңнең явын алырлык, әйтерсең аңа язгы чәчәкләрне таратып ташлаганнар. Бәлки фиеста көнне генә күреп буладыр мондый төсләрне. Үзәккә якынлашкан саен машиналар агымы тыгызлана, бару һаман әкренәя иде. Бераздан безнең «ниссан» көч-хәл белән генә шуыша башлады. Каян җыелган бу кадәр кеше? Әллә инде дөньядагы барлык машина шушы урамга агылып кергән?

Музыка кояш нурлары белән күктән коела шикелле. Нинди генә музыка кораллары юк монда. Фиестаны тәбрикләргә профессиональ музыкантлар белән һәвәскәрләр дә чыккан.

Кипкән, яңгыр вакытында гына җан керә торган елга — Турия аркылы салынган Арагон күперен уздык. Баруыбыз тагын да әкренәйде. Тиздән шәһәр үзәге башланырга тиеш. Бу тизлек белән барганда шәһәр үзәгенә кичкә кадәр дә барып җитеп булмас шикелле.

— Сыталар безне,— диде өлкән механик як-ягына карап алгач.— Мин юләр, юкка риза булдым. Хәзер инде үкенәм.

Машина эчендә ясалма климат. Салкынча. Рәхәт.

Без инде Колумб урамында. Бездән алда барган машина бер генә карыш шуышып ала да туктый. Без дә шулай бер генә карышка алга шуышып куябыз. Франсиско борчыла башлады:

— Карамбо! Соңга калабыз! И-и-их!

Артта да тоташ машиналар стенасы. Мәҗүсилек чорында кыргый хайваннарны көтүләп үзәнлеккә куып кертә торган булганнар. Пако машина тәрәзәсенең пыяласын төшерә башлады. Кабина эченә кайнар һава ургылды.

— Миннән калышмаска тырышыгыз. Калсагыз, адашасыз,— Франсиско Доминген ачык тәрәзә аша машинадан үрмәләп чыга башлады. Без аңа иярдек.

Бер-берсенә терәлеп туктаган машиналар түбәсеннән түш белән пластунча шуышып барабыз. Алда тар гына тротуар. Мүкәйләп шунда төштек. Җәяүлеләр агымы эләктереп алды. Аяклар җиргә тияр-

[1] Каракол — кәҗә мөгезенә охшашлы кабырчык эчендәге моллюск.
[2] Тео пепе — шәраб төре.

тимәс кенә атлап бара. Агым безне Пласа де Торос мәйданына китереп ташлады. Каршыда кызыл кирпечтән салынган түгәрәк корылма. Коррида уздырыла торган бина — арена Римдәге Колизейны хәтерләтә. Бина эчендә сүлпән генә шикелле оркестр уйный. Чәчрәп торган гайрәтле ярсу көй эченә яшеренгән. Бу ягы белән испан моңнары безнең борынгы җырларны хәтерләтә. Кем белә, бәлки бу көйләр арасында тарихи уртаклык та бардыр? Ерак бабаларыбызның йөрәк серләрен шул борынгы көйләр аша аңлап булыр иде, ләкин, кызганыч, аларга колак салып торырга вакытыбыз юк.

Һавада бәйрәм сулышы. Көйгән ит, кайенна борычы, лавр яфраклары исе борын эчен кытыклап, бәйрәм тантанасын көчәйтеп җибәрә. Арена стенасы буена җыелган ирләр тире капчыкка тутырган виноны өскә күтәреп учлары белән кысалар. Ирләрнең авыз эчләренә кызыл ахакка охшашлы кызыл шәраб чаптырып керә дә турыдан-туры карынга ук төшә.

Һәр бәйрәмнең төп максаты — кешеләрне очраштыру, кыска вакытка булса да аларның күңелләрен берләштерү. Бәйрәмсез без үзара таралышып, бер-беребезне күздән югалтып бетерер идек.

Агым безне тимер капкага китереп кысты. Капка саклаучыларга Франсиско Доминген билетларны сузды.

— Авансе мас![1]

Капка белән стена арасында ярык барлыкка килде. Без шул ярыкка тыгылдык. Амфитеатрга узганда Пако дерматин тышлы өч мендәр сатып алды.

— Кирәк булачак,— диде ул серле елмаеп.

Җилкәсенә озын чуклы кара шәл салган яшь чибәр кыз кыстыбыйга охшашлы таба ашы сата. Доминген аны да алды. Бәйрәм көн. Бездә дә бит сабантуй көннәрендә күз — матурлык, колак — моңлы көйләр, тамак — татлы ашлар тели. Кызның җилкәсендәге шәлне күзәтәм. Мин әле хәтерлим, без бәләкәй чакта татар кызлары җилкәләреннән агылып төшеп, тәннәренә сыланып торган озын чуклы шәл яраталар иде.

Фиеста махсус кояшлы көннәрдә үткәрелә. Кояш — көләчлек һәм шатлык символы. Тирә-юньдәге йорт түбәләренә менеп кунаклаган, арена тирәсендә үскән агач ботакларына атланган бала-чага бәйрәмне күркәмләп, бизәп җибәргән. Әгәр агачларның ботаклары сынса, балалар пешкән алма булып җиргә коелыр шикелле. Бала-чагасыз бәйрәм тозсыз ашка охшар иде. Коймаларга атланып каршылаган бәйрәм ләззәтләре, сез кайда хәзер? Авыл башына чыгып урам капкасын саклаулар... Пар атларга төялеп сабан туена килүчеләрнең конфет чәчеп китүләре... Сакланамы икән ул йолалар?

* * *

Аренаның як-ягына куелган таблоларда неон ут кабынды. Белдерүләр. Тамашачылар укый. Аренага чыгасы үгезгә дүрт яшь — хайванның нәкъ житлеккән чагы. Иске Кастилия болыннарында үскән. Авырлыгы 585 кило — алты центнерга якын мускул, гайрәт һәм тәвәккәллек. Буыннар ныгып өлгергән. Дәрт житәрлек. Егәрлек мул. Адәм баласы белән чагыштырсак, егерме-егерме бер яшьлек житкән егетләр шундыйрак була.

— Бозау чын сугыш үгезе булып житлексен өчен аның тирә-ягында кырык гектар күләмле иркенлек булырга тиеш,— дип аңлата башлады Франсиско Доминген.— Кысанлыкта үскән үгездә азатлык дәрте уянмый кала, шуңа күрә ул батыр була алмый.

Эчемнән генә чамалап куям. Кысынкылыкта үскән кеше дә батыр була алмый. Кысынкылыкта кешенә мескенлек баса. Иван Грозный бу кагыйдәне аңлап, тормышка ашырган. Казан ханлыгын яулап ал-

[1] Авансе мас (испанча) — эчкә узыгыз.

ганнан соң, ул татарларның җирләрен кисеп алып, илбасарларга, сатлык җаннарга өләшә торган. Бу процесс берничә гасыр дәвам иткән. Җирен, иреген, хокукын югалтып хәерчегә әйләнгән татар халкы туган җирен ташлап китеп, Урта Азиягә, Себергә, әллә кайларга таралып беткән. Азатлыксыз ирек хисе, горурлыксыз шәхеслек тойгысы уяна алмаганын Сталин культы чорында да яхшы белгәннәр. Гел буйсынып, гел югарыдан төшерелгән боерыкны үтәп яшәргә өйрәнгән кеше әкренләп колга әйләнә. Культ чорының максаты нәкъ шул иде. Бу канун кешегә генә түгел, хайванга да тәэсир итә икән. Домингенның әлеге сүзләре күземне ачты.

Тамашачылар иркенлектә дүрт ел горурлык туплаган җан иясенең аренага чыкканын көтәләр. Иске Кастилия болыннарының сафлыгы, тау чишмәләренең чисталыгы, һәм азатлык сөю хисе тиздән аренага сирпеләчәк.

Коррида. Домингенның сөйләве мине 1943 елның язына кайтарды. Ул елны яз соңгарак калып килде. Атлар ач иде. Колхоз атларын аркан белән өрлеккә асып тотабыз. Азык беткән, мескеннәргә череп беткән түбә саламы бирәбез. Сабанга колхозчыларның сыерларын җигәргә югарыдан фәрман килде. Фәрманны йорт саен күрсәтеп, имза алып чыктылар. Безнең якта сыер җигүне белмиләр. Исергәплеләр бу эшне мәсхәрәгә саныйлар иде. Сыер җигеп хур булганчы ачка үлүең артык, дип, күпләр бу эштән баш тартты. Ата-бабадан калган катгый канун яши иде безнең авылда: ат — ирләр, сыер — хатыннар карамагында. Кыр эше, мал табу, гаиләнең, җәмгыятьнең иминлеген саклау ат белән ир карамагында. «Ир-ат» дип бу ике сүзне парлап язу юкка гына кагыйдәгә әйләнмәгән. Сыерсыз көнең — сыйсыз көнең, ди татар әйтеме. Элекке заманда ир белән хатын арасында эш бүлешеп бәхәсләшү, гауга куптару булмаган. Кемнең нәрсә эшләргә тиешлеген ат белән сыер күрсәтеп торган.

Исергәп авылы тарихында беренче булып бригадага сыер җитәкләп килдем. Күршебез Нәфисәттәй дә сыерын алып килгән. Шушы ике сыерны парлап сабанга җигәргә куштылар. Ат камыты сыерга ярамый икән ул. Камытны сүтеп, ботарлап кидерергә туры килде. Сыерларны парлап бер төрәнле сабанга җиктек. Мин дилбегә тоттым, Нәфисәттәй, алга чыгып, малкайларны йөгәненнән алды. Урамга чыктык. Җир әле кибеп җитмәгән. Сыерлар бәкәлләренә кадәр җиргә батып бара. Капка төбе саен бала-чага, карт-коры, авылга сыер җигү могҗизасы килүенә хәйран калып карап торалар. Мескен хайваннар карыша, ләкин чыбыркы белән дәгъвалашуга барып җитмиләр. Җир башына җитеп туктадык. Яз җиле җылына башлаган татлы җир исен ташый. Баш өстендә тургай сайрый. Сабанымны көйләп, төрәнне җиргә утырттым.

— На-а-а, мөгезле бахбайлар!

Мескеннәр кузгалып кына киткәннәр иде, төрән җиргә кадалу белән шып туктадылар. Чыбыркымны шартлатып берне тамызып та алдым. Нәфисәттәй тезгеннән тарта. Сыерлар тагын кузгалдылар һәм тагын туктадылар. Күзләрен мөлдерәтеп безгә карап торалар.

«Балаларыбызны ач калдырып, соңгы тамчы сөтебезне сезгә бирәбез. Ул да әз тоеламыни сез туймас тамакларга? Көз килгәч, газиз бозауларыбызны иткә чаласыз. Сыер дигәч тә аңламый дип беләсезмени? Озакламый итебез, тиребез, хәтта сөякләребез дә сезгә булачак. Ул да әз тоелдымыни? Хәзер инде сабанга җигеп интектермәкче икәнсез...»

— Гөнаһы безгә түгел, Гитлерга төшсен,— дип, Нәфисәттәй сыерларның муеннарын кочаклап елый.

Шулай да тугармадык сыерларны, хәлдән тайдыртканчы җир сөрдек.

...Уйларымны бүлеп, алкышлау тавышлары яңгырады. Аренага өч куадрилья[1] сугышчы килеп чыкты. Өсләрендә алтын һәм көмеш белән

[1] Куадрилья (испанча) — төркем, команда.

чиккән жыйнак киемнәр. Оркестр марш уйный. Тореролар арена әйләнеп атлый башлады. Алда матадорлар. Испаниядә аларны тореро дип атыйлар. «Матадор» испан сүзе «матар» — «үтерү»дән алынган. Алтын белән чиккән тыгыз камзул, балтырларына сыланып торган алтын жепле кыска чалбар һәм ак оек — матадорлар киеме. Тореодорлар, пикадорлар һәм бандерильерлар өстендә көмеш белән чиккән кием. Үзләрен гади һәм горур тоту — испанлыларга хас күркәм сыйфат. Аренаны урап чыккач, өч куадрилья койма артына кереп югалды.

Арена капкасын киереп ачтылар. Капкадан үгез чабып чыкты. Мәйдан уртасына житкәч, капыл туктады. Үгезнең алгы аяклары тезгә кадәр диярлек комга баттылар. Арена тирәсендә — егерме биш мең тамашачы. Егерме биш мең пар күз үгезгә текәлгән. Аның башы иелгән, танау тишекләре киңәйгән. Үгез аңларга тырыша: нәрсә бу? Нигә шушы кадәр халык жыелган?

Үгез атылып урыныннан кузгалды. Чабып йөри башлады. Кая дошман? Ул кая поскан? Нигә чыкмый ул куркак миңа каршы?

— Аренага чыгарыр алдыннан үгезнең сыртына пневматик пистолеттан тимер ыргак атып кертәләр,— дип аңлатты Франсиско.— Күрәсезме кызыл тасмадан ясалган бантны? Шул бант тимер ыргакка беркетелгән.

Кызыл бант астыннан кан саркып тора иде. Хайванның сыртыннан тезенә ялтыравыклы кан юлы сузылып төшкән.

Ганадериянең[1] иркен болыннарында, табигатьнең рәхимле кочагында ирекә чумып, назланып яшәгән жан иясенең тәненә тимер ыргак кадап кара әле! Кем чыдар мондый кыргыйлыкка? Кем түзәр мондый мәсхәрәгә? Очып барган жиреннән үгез коймага тондырды. Үткен мөгезләр биш бармак калынлыгы койма тактасын челпәрәмә ярып ташлады. Тамашачылар өстенә йомычкалар очты. Читтән караганда күренми торган койма ярыгыннан үгезгә каршы тореодор килеп чыкты.

— Торо!

«Менә кайда икән минем дошманым!»— дип шатланып китте сугыш үгезе.— Үлем ерткычларга! Бер гөнаһсыз жан иясенең тәненә тимер ыргак кадаучы вәхшиләргә үлем! Үгез тореодорга ташланды. Моңа кадәр ул кешеләрнең кансызлыгын белмәгән икән. Үлем кеше затына! Мөгезгә эләп ыргытыйм дигәндә генә тореодор читкә тайпылып калды. Тагын һөжүм һәм тагын тайпылу...

Өченче һәм жиденче һөжүм дә нәтижәсез калды. Үгез тәмам ярсыды. Мөгезләр тореодорның гәүдәсенә төбәлгән, алар нигәдер бушлыкны айкыйлар. Үлем сезгә, хәйләкәр куркаклар! Бер тамчы шәфкать юк сезгә хәзер!

Тореодор койма эченә кереп яшеренде. Үгез алданды. Ул көченә ышана иде. Көчлегә хәйлә кирәкми. Беркатлы, эчкерсез хайван адәм баласының мәкерен аңламый иде. Ирекtә чакта аның башка үгезләр белән сөзешкәне булды. Андый сөзештә бары тик көчле генә жиңә. Өстенлек — көчтә. Көчсез алдыра алмый, баш бирә, буйсына. Табигатьнең кануны шундый. Тореодорның үгездән көчсезрәк булуы күренеп тора иде. Бер тапкыр мөгезгә эләктереп һавага күтәрсәң, эш бетәчәк. Үгез шуңа ышана иде. Хәйлә белән эш итүне белми иде ул. Куркакларның көче — хәйләдә. Хәйлә ул — гаделсезләр акылы.

Көчнең юкка исраф булуы, тырышуның нәтижәсез калуы үгезне чиктән тыш ярсытып жибәрде. Эчтә ут яна. Үлем хәйләкәрләргә!

Капка кабат ачылып китте. Аренага атлы сугышчы — пикадор чыкты. Пикадорның кулында озын саплы сөңге. Үгездән куркып өрекмәсен өчен атның күзен каештан ясаган күзлек белән каплаганнар. Мөгез үтеп кермәслек итеп аның кабыргаларына калын сырма асканнар.

Үгез атка ташланды. Мөгезенә эләктереп, атны коймага китереп

[1] Ганадерия — сугыш үгезләре үстерә торган ферма.

кыскан арада пикадор үгезнең сыртына өч тапкыр сөңгесен батырып алды. Авыртуга түзә алмыйча үгез үкереп җибәрде дә, корсак астыннан эләктереп алып, атны һавага чөйде. Атның алгы аяклары койманың эчке ягында, арт саны һәм бүселеп чыккан эчәгеләре койманың тышкы ягында асылынып калды. Тореодор үгезгә ташланды. Үзенә ияртеп үгезне читкә алып киткән арада пеонеслар[1] атны койма өстеннән сөйрәп төшерергә өлгерделәр. Мескен бахбай эчәгеләрен сөйрәп капкадан кереп китте.

Үгез һаман төшенә алмый иде. Аны нигә җәберлиләр? Нигә аның тәнен җәрәхәтлиләр? Мескеннең күзләрен кан басты.

Корриданың хәлиткеч өлеше башланды. Аренага куадрилья башлыгы — матадор үзе чыкты. Шундый матур, җиңел хәрәкәтле, җыйнак егет иде матадор. Әйтерсең, аның эчендә корыч пружина. Шундый иркен, шундый гамьсез кыяфәттә үгез каршысына атлап бара. Каян биргән аңа табигать бу кадәр күркәм сыйфатларны? Матадордагы тынычлык белән сугарылган көчәнүсез өлгерлек, җиңел чыгасына икеләнмичә ышану, ышануын күрсәтә алу тамашачыларның мәхәббәтен шундук яулап алды.

Матадор кулындагы кызыл плащын комга салып таптады. Комдагы юешлек тукыманы авырайтты. Җил искәндә кызыл тукыма хуҗа ягына сырышып китмәсен өчен кирәк иде бу авырлык. Үгез матадорга таба чабып килә. Мөгезләр һаман якыная. Мөгез белән бергә үлем якыная. Бер метр, ярты, чирек метр. Аяусыз тизлек... Матадор очып килгән үлем каршында гамьсез генә басып тора бирде.

— Торо!

Матадор үлем каршында япа-ялгыз. Аңа беркем дә ярдәм итә алмый хәзер. Дуслар да, туганнар да, сөйгән яр да. Үлем белән яшәү арасында кыл нечкәлеге ара калды. Матадор, гәүдәсен артка ташлый төшеп, кызыл тукыманы янбашына терәп тоткан, ургылып ташланган үгездән тайпылмыйча басып тора. Мөгезләр егетнең ботына ышкылып узды. Бер мизгелгә кеше белән хайван бергә кушылып өлгергәннәр иде. Үлем матадорга килеп терәлде дә ерагая башлады.

Тореро үгезнең әйләнеп килүен көтә. Йөзендә гамьсезлек. Биш йөз сиксән биш килолы котырган көч янә егеткә ябырылды. Бу юлы да үлем белән яшәү йөзгә-йөз очраштылар. Матадор тайпылмады. Тамашачы егетнең бөек матадорлар токымыннан, даһи Виляльте, мәңге онытылмас Монолетто шикелләләрдән икәнлеген аңлап алды. Ав-ви-ва!

Адәм баласы үлемнән куркырга тиеш. Үлемнән бары тик мактанчык кына курыкмый. Андый куркакның максаты — куркаклыгын яшереп, үзен батыр күрсәтү. Батырның батырлыгы исә күрсәтмәсә дә сизелеп тора. Безнең төп максат — яшәү. Яшәүне данга да, байлыкка да, дөньядагы башка бернәрсәгә дә алыштырырга ярамый. Яшәү белән чагыштырганда аларның барысы да арзан. Шуңа карамастан, куркуны яшерергә, батыр күренергә теләү безне үлем белән мәйдан тотарга мәҗбүр итә. Кимчелекне яшерү теләге көчле бездә. Булдыксыз адәм гомер буе уңган кеше булып күренергә тырыша, саран юмарт булып кылана, халтурачы язучы лауреатлыкка үрмәли. Коррида карарга мин акча түләгән, димәк, матадорның батырлыгын мин сатып алдым, дип ышана тамашачы.

— Торо!

Матадор, үгезне яныннан җибәрмичә, үзенең тирәсендә әйләндереп йөртә. Читтән караганда мөгезләр торероның тәнен тишеп эчкә кергән шикелле күренә. Бер уңга, бер сулга әйләндерә матадор үлемне. Тамашачылар акылдан шашып алкышлыйлар. Бер генә сантиметрга ялгышса да үлем егетне үзенә алачак. Канга батып яткан торерога алкыш нигә кирәк?

---

[1] Пеонес — арена эшчеләре.

«Кит аренадан, кач үлемнән»,— дип кычкырасым килә матадорга. Тамашачылар аны мактыйлар, алкышлыйлар, үлем уенын дәвам иттерүне таләп итәләр.

— Нигә ул үгезне үтерми? Әнә бит, шпагасы кулында, ул нигә аның йөрәгенә кадамый?— дип сорый Горбаненко.

— Үгез әле әзер түгел,— дим өлкән механикка.— Корриданың үз кагыйдәсе бар. Матадор кагыйдәне боза алмый.

— Нинди әзерлек көтә ул? Мөгезгә эләксә, соң булачак.

Сират күпере кылдан нечкә, кылычтан үткен, дип аңлата иде безнең әби. Матадор белән үгез шул күпер аша узалар. Шуларның кайсы алданрак упкынга чумачак?

— Торо!

Галимнәр корриданы Крит-микен культурасы заманыннан килә дип аңлата. Минос патшаның казылма сараенда сөзәргә килгән үгезгә каршы йөгерүче сурәтләнгән фрескалар бар. Крит утравының борынгы Фест шәһәрен казыганда табылган түгәрәк тактага язылган серле сүзләрне Нурихан Фәттах төрки телләр ярдәмендә укып аңлата алды. Гаҗәп катлаулы нәрсә тарих. Гасырлар астында күмелеп калган вакыйгаларны файдага да, зыянга да, халыкның данын күтәрергә янсә абруен төшерергә дә көйләп була. Тарихны беренчел чыганаклар аша өйрәнергә безнең вакыт та, мөмкинлек тә юк. Шуңа күрә без үз тарихыбызны юньләп белмибез. Безнең Исергәп авылында корриданы хәтерләткән бер борынгы йола бар иде. Кемдер сине кимсетте, абруеңа кагылды, ди. Шул намус кодексын бозган кешене аулаграк җирдә очратып җиңеңне сызганасың да:

— Торо!— дисең.

Утызынчы елларда ул йола юкка чыкты. Үчне башка юл белән ала башладылар. Гайбәт тарату, итәк астыннан ут йөртү, анонимка язу. Болары үзәктән, Мәскәүнең үзеннән, бөек юлбашчы Сталин кулланган көндәлек ысулдан, аның шәкертләре кулланган икейөзлелектән, трибунадан төче сөйләп, эшне канга батырып эшләүдән туды. Элек-электән намус сафлыгын, иман пакьлеген саклау шундый катгый куелган Исергәп авылында хөкүмәткә каршы әйтелгән сүз эзләү, шымчылык, халык дошманнарын фаш итү утызынчы елларда көндәлек гадәткә әйләнеп китте. Киләчәктә, белмим, ул юкка чыккан кырыс, гадел йоланы кире кайтарып булырмы икән?

Һәр ялгышу үгезнең канын кыздыра. Ачу сукыр бит ул. Үч хисе! Күпме көчне, күпме егәрлекне аласың! Син бит үгезне генә түгел, үзен акыл иясе санаган адәм баласын да сукырайтасың. Көрәш барганда салкын акыл, чама белән эш итүгә ни җиткән! Минем ерак бабаларым, үгезкәем, нәкъ синең шикелле үз көчләренә ышанганнар. Хәйләне инкярь иткәннәр алар, астыртынлыкны хәрәмләүгә санап, кабул итмәгәннәр. Нәтиҗәдә...

Көрәш башланганга утыз биш минут. Үгез лачма тиргә батты, җәрәхәтләреннән аккан кан оеды. Әлегә үгез дә, матадор да исән. Уенның кагыйдәсе аяусыз: кемдер үтерелергә тиеш. Финал — котылгысыз.

Матадор коймa эченә кереп юкка чыкты. Аренага бандерильеро чыкты. Аның ике кулында да сабы укалы кызыл бәрхеткә төрелгән ыргаклы авыр ук — бандерильо. Бандерильеро кулларын өскә күтәреп үгезгә таба йөгерә башлады. Кносс сарае хәрабәләрендәге фрескалар күз алдына килеп басты. Үгез каршы чабып килә. Ара якынлашкач, бандерильеро, кинәт борылыш ясап, юнәлешен үзгәртте дә үгез белән янәшә йөгерә башлады. Һава сугышында кулланыла торган истребительләр алымы иде бу. Бандерильеро, гәүдәсен артка ташлый төшеп, бар көче белән ике укны берьюлы үгезнең җилкәсенә батырды. Очрашу тагын ике тапкыр кабатланды һәм үгезнең җилкә сөягенә кадалган алты авыр ук чайкала иде. Ыргаклы уклар нерв бәйләмнәрен тишеп умыртка сөягендә туктаганнар. Авыртуга түзә алмыйча, үгез башын чайкый.

Үлем сезгә! Үлем сезгә, ерткычлар!

— Торо!

Матадорга төбәлгән үткен мөгезләр кызыл тукыма артындагы бушлыкны сөзәләр. Дошман янәшә. Мөгезгә эләктереп бер генә тапкыр чайкап ыргытсаң да, җаны чыгачак. Дошман исән. Бер генә мизгелдә хайванның миендә дошманның хәйләгә таянып эш итүе, аның гаделсезлеге чагылып китте. Соң иде инде. Йөрәк дөпелдәп тибә. Тән сызлау буыннарга төшкән. Җир йөзен кызгылт томан каплаган. Битарафлык, авыр кургашын шикелле, күкрәк эчен, баш миен томалап алган.

Үгезнең бар туккән көче, тырышуы юкка чыкты. Хәйләгә, мәкергә каршы гадел көрәш күп очракта шулай тәмамлана. Киләчәктә дә шулай булачак. Үгез алгы аякларын киң басып, башын аска иеп карап торган арада тореро җиргә тезләнде, кызыл тукыма белән шпагасын җиргә ташлады. Бу да әз тоелды дуамал башка, ул үгезгә арты белән борылып утырды. Башны бер генә тапкыр чайкап алу житә — мөгез матадорның йөрәге аша үтеп чыгачак. Ләкин мескен үгез шушы мизгелдә таркаулыгын җиңә алмады. Тамашачылар шашынып кул чабалар. Кычкыралар. Ав-ви-ва!

Хәйлә, гаделсезлеккә каршы ничек көрәшәсен аңлый алмады мескен үгез. Андый хәлләр тарихта да була. Аерма шунда — халыкны, милләтне үгез шикелле берьюлы, тулысынча үтереп булмый, аны гасырлар буе, әкренләп үтерәләр.

— Торо!

Үгез урыныннан кузгалганда, матадор торып өлгергән иде инде. Ул үзәк трибуна каршына барып баш иде, президенттан үгез белән исәп-хисапны өзәргә рөхсәт сорады. Хөкем кыска булды — рөхсәт. Матадорның җиңел шпагасын сугышчан шпагага алыштырдылар. Хәлиткеч минут, матадорлар телендә «хакыйкать мизгеле» башланды.

Үгез кызыл тукымадан читкәрәк, матадорның касыгына турылап ташланды. Тореро шпагасын кысып тоткан, кулларын өскә күтәреп, алга таба иелә төшкән. Үгез белән кеше бер-берсенә ургылдылар. Үткен шпага җилкә кимерчәген тишеп кереп, йөрәк аша үтеп чыкты. Үгез капыл туктады. Авыртуны сизәргә дә өлгерә алмый калды ул. Башта авыз-борыныннан кан китте. Алгы аяклар кинәт йомшарып, бөгелеп төштеләр. Хайван гөрселдәп җиргә ауды. Җир йөзендә бер җан иясе кимеде. Бер генәме?

Оркестр марш уйный. Алкышлау. Кул чабулар. Кычкырулар күкләргә чөелә. Президент аренага йөгереп чыккан пеонесларга ике бармагын күрсәтә. Пеонеслар үгезнең ике колагын да кисеп алдылар һәм матадорга тоттырдылар. Мондый бүләк батырларның батырына гына эләгә. Коррида сезоны тәмамлангач, һәр матадорның алган колаклар санын хисаплап, быелгы сезонның чемпионын беләчәкләр.

Пастромкалап җиккән өч качырны чаптырып аренага чыгардылар. Үгез гәүдәсен тимер ыргакка эләктерделәр. Чыбыркы шартлады. Үгез мәете койма эченә кереп югалды. Икенче мизгелдә арена хезмәткәрләре үгез гәүдәсеннән сыдырылып калган юлны, аның аяклары актарган чокырларны тигезләп йөриләр иде инде.

Матадор куадрильясы белән аренага чыкты. Ул алда. Аңа тореодор, пикадор, бандерильерлар ияргән. Батырлар өстенә музыка авазлары, алкышлар ява.

— Ав-ви-ва! Афәрин!

Триумф. Матадорның өстенә чәчәкләр оча. Аның алдына эченә шәраб тутырылган күн капчыклар килеп төшә. Матадор — испанлы. Мөмкин булса, ул шәраб капчыгын өскә күтәрер дә, учлары белән як-яктан кысар иде. Хуш исле йөзем шәрабының тыгыз агымы туптуры матадорның тамагына ургылыр иде. Әлегә ярамый. Матадорның тагын аренага чыгасы, тагын бер үгез белән мәйдан тотасы бар. Матадор күн капчыкны җирдән күтәреп ала да хуҗаларына кайтара. Аңа янчык-

лап акча ыргыталар. Акчаны да ул хуҗаларына кире ыргыта. Бу дөньяда җиңүдән дә зур, җиңүдән дә ләззәтле байлык бармы икән? Алкыш та зур байлык. Алкыш бәлзәм булып матадорның тәненә тарала.

Минем янда утыручы ак күлмәкле испан кызы торерога җилпәзәсен ыргытты. Җилпәзәне матадор җирдән күтәрде, үпте, хуҗасына кире кайтарды. Хатын-кызлар, шашынып, кулларындагы беләзекләрен, муенсаларын салып томыралар. Минем алда утыручы, кара шифонга төренгән ханым беләкләрен, муенын капшап карады да, беләзек тә, муенса да юк икәнлеген аңлагач, күлмәк эченә кулын тыкты, күкрәкчәсен суырып чыгарып, матадорга томырды. Аның матурлыгы, уттай кайнар, кискен хәрәкәтләре, тирә-якка электр кырына охшашлы тынгысызлык таратуы мине Кол Галиләр чорына алып китте.

Матадор очып килгән күкрәкчәне эләктереп алды, битенә каплады, баш иеп, хуҗасына кире кайтарды.

* * *

Соңгы, алтынчы үгез җиргә егылды. Аның мәетен койма артына сөйрәп алып киттеләр. Корридада катнашучылар аренага чыкты. Алар өч куадрилья иде. Утыздан артык яшь, матур, алтын һәм көмеш тукымадан тегелгән киемле кешеләр. Оркестр җиңүчеләр маршы уйный. Алкышлар. Һаваны сызгыру тавышы айкый. Амфитеатр, ложалар, йорт түбәсендәге, агач башларындагы тамашачылар — меңләгән, ун меңләгән халык акылдан шашып җиңүчеләрне тәбрикли. Кыямәт көне. Без дә кычкырабыз, кул чабабыз. Алкышлау давылы безне дә эләктереп алды. Без дә башыбызны югалттык.

Аренаны кораллы сугышчылар саклый. Коррида сөючe фанатиклар нинди юл белән аренага үтеп керә алганнар? Алар матадорларны һавага чөя башладылар. Бер таза егет иелде, башын матадорның аяклары арасына тыкты, язылды. Матадор, ат менгән шикелле, тамашачының җилкәсендә утыра иде. Башка матадорларны да тамашачылар җилкәләренә утырта башладылар.

Адәм баласын бернәрсәгә дә көчләп табындырып булмый. Табыну объектын ул үзе сайларга тиеш. Читтән караганда кешенең мәш килеп юк нәрсәгә табынуы безгә көлке тоела. Ләкин, ни сәбәптер, без табынусыз яши алмыйбыз. Табынусыз яшәү тозсыз ашны хәтерләтә. Аның тәме юк. Футболмы, джинси чалбармы, Владимир Высоцкиймы, лауреат исеме яки сирәк очрый торган почта маркасымы, әллә чибәр кызмы, я булмаса һәр кич эштән кайтып табын янына утыруга бер калҗа итме... Син табынган нәрсә теге рыцарьлар заманындагы оек бавы гына да булуы мөмкин. Бары тик синең табынуың кыйммәт. Әгәр ихлас күңелдән инанып табынсаң, табыну объекты, кумирың чиксез кыйммәткә әйләнә. Без һәрвакыт бөек идеалларга гына табынып идек. Бөек идеаллар күп вакыт зур түрәләр кулына эләгә дә, алар аны чыбыркы урынына безне куып эшләтү, буйсындырып яшәтү өчен куллана башлыйлар. Ә без, кызганыч ки, табынмыйча яши алмыйбыз. Табынусыз яшәү шундый тонык, шундый мәгънәсез тоела безгә.

Табынуга мохтаҗ чакларда бәйрәм кирәклеге сизелә башлый. Бәйрәм ул күңел ачу, ял итү генә түгел. Тормыш юлы ком чүлендәге сукмакка охшаш. Бәйрәм — шул юлдагы матур оазис. Шул оазиска туктап без ял итеп, хәл җыеп чыгабыз. Башкача булмый. Башкача без үзебезне гомер буе шахтада күмер тутырган вагонны сөйрәп сукырайган ат итеп сизә башлыйбыз. Гомер буе гел тамак ягын, өс-башны, торак һәм эш мәсьәләсен генә кайгыртып яшәп булмый. Үзеңнең адәм затыннан икәнлегеңне тою өчен күмәк шатлык, уртак куанычлар кирәк. Ике генә сәгатькә булса да бер-береңне бер үк потка табынган чакта күрү безне ялгызлыктан коткара. Адәм баласы — күмәкчеллек колы. Күмәк яшәүнең кагыйдәләреннән мәҗбүри канунnар төзү безне хайваннан аерган. Күмәклекне без, кызганыч, эштә һәм бәйрәмдә генә тулысын-

ча тоя алабыз. Ялгызлык куркыта. Бер генә сәгатькә булса да без үзебезнең ялгыз түгел икәнлегебезгә ышанырга тиешбез. Без галәмгә башка кешеләр аша тоташабыз. Шушы тоташлык тойгысы яшәүгә көч һәм дәрт бирә.

Халык тарала башлады. Без Пласа де Торос мәйданына чыктык. Кояш баеп килә. Таулар сыена башлаган. Диңгез ягыннан бриз җиле исә. Мәрхәмәтле, тыныч, җылы җил. Озакламый җир өстен караңгылык каплар. Валенсия урамнарында таң атканчы фиеста кайнар. Тау битендәге төнге утлар ялкынлы испан биюе — фламенконы күзәтер. Ә без корабка ашыгабыз. Машиналар, бер-бер артлы урыннарыннан кузгалып, китеп торалар. Аларны куера башлаган караңгылык йота.

Машинабыз калган җиргә килеп туктадык. Урын буш. Машинабыз юк.

— Урлаганнар!— диде Горбаненко.— Менә сиңа коррида! Күңелем сизде. Белдем мин урлыйсыларын. Гел шул турыда уйлап утырдым. Соң юл уртасында шундый затлы яңа машинаны ташлап китәләрмени? Бикләргә кирәк иде. Э-э-эх!

Пако елмая. Ул муенын кашый.

— Полиция алып киткән. Фиеста көнне алар уңыш җыя. Ун мең песо штраф...

Штраф түләүне Франсиско чын ир-егетләрчә горурлык белән әйтте. Шәхеслеген исбатларга аңа тагын бер җай табылды. Безнең Исергәп ирләре искә төште. Сабантуй көннәрендә алар да ел буе бөртекләп, кара саранлык белән җыйган акчаларын нәкъ испанлы Франсиско Домингеп шикелле берәр пүчтәккә туздырырга тиешләр иде. Үзенә күрә кысынкылыктан, ел буе кытлык белән көрәшеп бил бөгүдән үч алу була иде исергәплеләрнең тотанаксызлыгы.

Пако автоматтан полиция идарәсенә чылтыратып карады.

— Абонданато[1],— диде ул.— Аларга хәзер ничә мең кеше шалтырата. Иртәгә дә өлгерермен әле. Мин сезне корабка такси белән генә илтәм.— Франсиско штрафка әзерләгән акчасын чыгарып күрсәтте. Елмайды.— Бу акчага тияргә ярамый,— диде ул горурлык белән.— Испан полициясе шундый хәйләкәр, фиеста көнне алар кирәк-яракларына акча җыя.

* * *

Кояш таулар артыннан чыгып килгәндә без Валенсия порты белән саубуллаштык. Испан сабантуе — фиеста дәвам итә иде әле. Мин ерак испан портыннан балачак хатирәләрен алып китәм. Әйтерсең, унҗиде мең чакрым көнбатышта яткан чит ил портына түгел, үземнең туган Исергәбемә кайтып сабантуй карадым. Шул кадәр сирәк була бит ул балачакка кире кайту.

Коррида Мәскәүдә, РСФСР язучылары съездында булган бер вакыйганы яңартып исемә төшерде. Ул чакта татар язучыларының җитәкчесе Гариф Ахунов иде. Аны президиумга, Сергей Михалков янына диярлек менгереп утырттылар. Сүзне дә Михалковтан соң ук диярлек бирделәр. Без, рядовой язучылар, Гарифка күрсәткән ихтирамның җылысына әлсерәп, шатланып утырабыз. Ахунов трибунага күтәрелә. Кулында көрән күн папка. Менеп басты. Галстугын төзәтте. Чәчен сыпырып алды.

— Иптәшләр!— диде ул.— Без бүген зур һәм җаваплы сабантуйга җыелдык.

Зал кинәт тынды. Менә, дидем мин горурланып, безнең җитәкчебезне ничек тыңлыйлар. Шул хакта уйлавым гына булды — зал урыныннан кубып, өскә күтәрелде. Меңләгән язучы эчләрен уа-уа үкереп көлә

---

[1] Абонданато — буш түгел (испанча).

иде. Без, татар язучылары, делегатларның бу халәтен аңламыйча, күзләребезне челт-мелт йомып, аптырап утырабыз.

Ни хәл бу? Ни көлке таптылар «сабантуйга җыелдык» дигән метафорадан?

Ниһаять, зал тынды. Тынлыктан файдаланып, «зур һәм җаваплы сабантуйга» җыелуны Гариф тагын кабатлады. Язучылар тагын бөгелеп төштеләр...

Ахуновның рус телен әйбәт белүенә шик саласым килми. Ул тәрҗемә эше белән дә шактый шөгыльләнде, әдәбият түрәсе булып зур кешеләр белән дә шактый аралашты. Эш Гарифта түгел. Рус телендә «сабантуй» сүзе бөтенләй башка мәгънәдә яңгырый һәм бөтенләй башка хис, эмоциональ тойгы уята. «Сабантуй» русның гадәти аңында эчемлек кулланып, былагайланып йөрүне аңлата. Революциягә кадәр Казанда яшәгән зур галимнәр, Рыбаков һәм Фукс, татарларның сабантуйда тәртип саклауларына, бәйрәмнең әдәпле үтүенә сокланып язып калдырганнар. Гадәти аң фәнни эшкә дә, логикага да төкерә. Хәтта бөек совет шагыйре Александр Твардовский да «Василий Теркин» поэмасында «сабантуй» сүзен фашистларга карата аларны дөмбәсләү мәгънәсендә куллана.

Китабымны рус теленә тәрҗемә иткәндә «иман», «моң», «кыйбла» шикелле сүзләргә русча эквивалент таба алмыйча күпме интеккәнем бар. Шул ук «сабантуй» безнең татар телендә уңай фикер уятса, русчада, киресенчә, минус белән билгеләнгән тискәре фикер. Шунысы кызык, безнең Исергәп авылы ирләренең «кәҗәсе кыйбат түгел, мәзәге кыйбат» аталган баламишкинлыкларын аңлар өчен испанлыларның фиеста үткәрүләрен күрергә кирәк булды. Тормыш сәхнәсенә бүген чыккан исергәпләләр бәлки «мәзәге кыйммәт түгел, кәҗәсе кыйммәт» дип тә яши башлаганнардыр, кем белә? Безнең Исергәп халкы нәкъ испанлыларча яши дип горурлану җаныма рәхәтлек бирде.

Сәяхәттә мин Карлос Рохасның «Корбаннар үзәне» исемле китабын укып чыктым. Карлос Рохас кечкенә китапка испан халкының мең еллык тарихын сыйдыра алган. Испаниянең данлыклы диңгезчеләре яңа атаулар, яңа кыйтгалар ачканнар. Испан тарихында туктаусыз сугышлар кабынып торган. Тарих бу халыкка башка мөмкинлек тәкъдим итә алмаган. Бу ягы белән испанлылар безнең татарны хәтерләтә. Яулап алулар, күтәрелүләр һәм югалтулар. Канлы вакыйгалар гасырдан гасырга туктаусыз кабатланып торган. Карлос Рохас испан тарихын Франсиско Гойя ясаган рәсемдәге үзе тапкан балаларын кире йотучы Сатурн, үгез мөгезенә эләккән матадор һәм Наполеон солдатының штыгына ташланган инсургентка тиңләп күрсәтә. Менә шул ул «Корбаннар үзәне». Һәм шул китапны укыганда бер генә минутка да татар тарихын күздән югалтып торып булмый.

Без нигә туклык, кием-салым, җылы торакка гына куанып яши алмыйбыз икән? Бу дөньяда бәхетле булу өчен чын тарихны, тарих тирәнлегенә сузылган тамырларыңны тою, шул тамырларның син үлгәч тә имин сакланачакларына ышану кирәк. Шунсыз яшәү мәгънәсез тоела.

Валенсия аренасындагы коррида йөрәктәге җәрәхәтләрне яңартып җибәрде. Офык артына кереп югалган портта испанлылар бәйрәм итәләр. Алар, бәйрәмнән файдаланып, йөрәкләренә шатлык, горурлык туплыйлар. Үзеңнең бөек милләт вәкиле булуыңа ышаныр өчен күпме горурлык кирәк...

## Беренче тәүлек. Жданов аэропорты. 13.20

Жданов аэропротында такси көтәм. Автобус килеп туктады. Такси көтүчеләр дәррәү автобуска йөгерделәр. Гавам инстинкты мине дә эләктереп алды, җилтерәтеп автобуска таба алып китте. Ярты юлга житкәч

айныдым, такси тукталышына кире кайттым. Озак көттем, күпме вакыт әрәм булды, тагын әзрәк көтәргә кирәк инде, дип уйладым мин. Юкка әрәм булган вакыт кызгандыра иде. Автобус кузгалып китте. Кире таксига килүемә үкенә башладым. Әгәр такси тагын шулай озак көттерсә? Үкенү — ул икейөзле. Тыштан ул сине кайгырткан шикелле кылана, ә эчтән йөрәгенне әрнетә. Соң бит, автобус синең таксиеннән элегрәк «Моряк» гостиницасына барып җитәчәк. Өстәвенә, автобус ун тиен, ә такси өч сум илле тиен. Ялгыштым...

Адәм баласы нинди генә очракта да юанырга яраклык дәлил таба. Таксига утырып йөрүе рәхәтрәк. Авыл чорын тиз оныттың син, абзыкай, ди канга сеңеп калган игенче саранлыгы. Такси рәхәтлеге өчен кило ярым ит хакы түлисең... Таксига утырып йөрүнең акчадан кыйммәтрәк яклары бар. Җәяүлеләр таксига утырып йөрүчене шәхес итеп күрә. Зур түрәләр юкка гына машинада йөрми. Министр җәяү йөреп карасын әле! Әниләр буыны искә төшә. Татар авылын һәм ул заманда яшәгәннәрнең психологиясен белмәгән кешегә саран, чиктән тыш комсыз тоелыр иде әниләрем буыны. Автобуслар йөрми иде әле ул чакта. Кырык чакрымдагы Бөгелмәгә, аркаларына капчык асып, врачка каралырга баралар иде. Суга чылатып ашалган коры ипи. Соң бит Бөгелмәдә ресторана да, ашханәсе дә бар юкса. Туздырмыйлар иде акчаны бисмилласыз пешерелгән ресторан ашына. Шул ук вакыт, әгәр юлчы ишек шакыса, кем булуына карамастан, чәй эчертмичә чыгару юк иде. Әҗәткә алып булса да, бөлеп-җөтеп, соңгы сынык мосафирга куела иде, хәтта балалары ач утырган очракта да. Саранлык түгел иде безнең әти-әниләр буынының кысынкы яшәве. Саранлык — кешедән кызгану, бар булганны үзе өчен генә тотудан гыйбарәт. Безнең әти-әниләр буыны үз тамаклары, үз кирәкләре өчен генә саран иделәр.

Ватан сугышы башланган көнне, колхоз подвалына дезинфекция ясаганда, әтием агуланган иде. Мең тугыз йөз кырык беренче елның 24 июнендә ул якты дөнья белән саубуллашты. Өлкән абый сугышта, өлкән апа Горький өлкәсендә торф чыгара. Уртанчы апам авырып ята. Әни белән без икәү бармакларыбыз белән җир тырнап биш тамакны туйдырырга тырышабыз. Эшкә чыккан көнне — дүрт йөз грамм он, икенче көнне эшкә чыкмасаң, ач яшь башлыйсың. Өч-дүрт атна рәттән чыкмадың исә, ачка үләсең. Еллар авыр иде. Сыерны да сатарга туры килде. Сыер акчасы әниемнең гомер буе тиенләп җыйган маясына кушылды. Күрше авыл Тымбарлыда гармун сатачаклары турында ишеткәч, әни, бер генә минутка да икеләнеп тормыйча, тамчылап җыйган акчасын миңа тоттырып гармун алырга җибәрде.

— Әй, Нәфисә ахирәт, аталарын югалттылар, дөньялары шундый авыр, ичмасам, балакайларым гармун уйнап булса да юансыннар...— дип аңлатты әни ташкынланып тышка бәреп чыккан юмартлыгын.

Авиациядә хезмәт иткән чакта айлык акчаны ресторанга бер керүдә туздырып бетерә идек. Буйдак елларны ерак сәяхәттән кайткач, Одессадан самолетка утырып Мәскәүгә чәч алдырырга оча идек. Башкалардан калышмаска тырышып шапырынсам да, әти-әниләр буынындагы акча кызгану миндә һаман яшәп килә. Кай чакларда ул тышка да бәреп чыккалый. Менә әле дә автобуска утырып китмәгәнгә үкенү шул өянәкнең уянуыннан иде.

Тукталышта без өчәү калдык. Миннән алда унсигезләр тирәсендәге яшь, чибәр кыз. Өстендә күн пиджак, вельвет чалбар, шуларга өстәп, йөзенә бәреп чыккан ата тәкәбберлек. Шундый сылу булыр идең син, сеңелем, әгәр шул мещан мимикасын йөзеңнән кырып ташлый алсаң! Нәрсә булды безгә алмашка киләсе яшь буынга? Затлы киенмәсеннәр дип әйтәсе килүдән түгел. Нигә алар киенеп-ясанып йөрүне шул кадәр ихтирам итәләр? Киенү бүгенге көндә сугыш елларындагы бер сынык ипи табып ач тамакны туйдыруга охшый башлады. Кытлык елларда бер тапкыр туйганчы ашау өчен җанынны бирергә риза торсаң, яшь буын

кием өчен үзенең азатлыгын сатарга риза диярлек. Борын асты кибеп житмәгән унсигез яшьлек үсмер өстендә әнисенең сигез ай бил бөгеп алган хезмәт хакы.

Миннән артта буаз портфель күтәргән Муссолинига охшашлы бер бәндә. Үзе мышный, ара-тирә машиналар туктый торган җиргә ачулы караш ташлап ала. Аны учреждение машинасы каршы алырга тиеш булган, күрәсең. Кемгәдер эләгәчәк. Алла ярдәм бирсен ул кешегә!

Ниһаять, яшел ут күренде. Такси килеп туктады. Утырыр алдыннан кыз, борылып, безгә караш ташлады: күн пиджак белән вельвет чалбарданмы икән бу хәтле тәкәбберлек?

Хәзер мин беренче. Йөрәкне куаныч җылытып җибәрде. Ташка үлчим чират торудагы беренчелек куанычын. Мондый куанычлар белән язмыш безне еш бүләкли башлады. Күршем үлгәч, аны зиратка урнаштыру мәсьәләсен үз өстемә алган идем. Табут ясатырга заказ бирергә бардым. Ике кыз табут өстенә «Вечерняя Москва» газетасын җәйгәннәр, колбаса, ак ипи туралган, бер шешә кызыл эчемлекнең бөкесе ачылган. Мәҗлес. Баш өсләрендә лозунг: «Безнең коллектив коммунистик хезмәт коллективы исеме өчен көрәшә». Утыздан артык кеше бусага артында чират көтә. Крематорийга тапшырыр алдыннан тагын чират торырга туры килде һәм, беренчелеккә җиткәч, нәкъ менә әлеге шикелле шатлык уянганнан сизеп алган идем. Туган көннән алып гүргә кергәнче безнең даими юлдашыбыз — чират тору.

Ниһаять, тагын бер машина килеп туктады.

— Миңа үзәккә, ә сез кайсы якка?— дип сорый буаз портфельле бәндә. Тавышында боз, интонациясендә тәхет бизәкләрендәге алтын чыңы. Шул беренчелек ярпачлыгы харап итте, күрәсең:

— Мин бөтенләй башка якка,— дигән сүзләр телемнән ычкынып өлгерде. Их, әгәр син, дускаем, җөмләңне «миңа» сүзеннән башламаган булсаң! Әгәр мөнәсәбәтеңнән боз суыклыгы бәреп тормасамы? Уравыч булса да, утырта идем мин сине. Йөз метр чамасы китеп өлгердемме икән — инде кешене тукталышта калдырып китүемә үкенә башладым. Ваклашу булды бу. Хәерче өстенлеге. Таксига утырып баруымның тәме югалды, авызымнан әрем тәмнәре килә башлады...

Такси таш багана янынннан уза. Баганага ат башы зурлыгы алты бетон хәреф беркетелгән: «Ж д а н о в». Әнә, багана астында, кулына озын саплы болгаткыч тотып, корыч кайнатучы басып тора.

Нихәл, дустым? Илгә корыч бирәбезме? Мин бит, менә, Ждановка тагын килдем. Рәхмәт каршылавың өчен. Бер генә тапкыр да каршы чыкмый калмадың. Мең яшә!

Корыч кайнатучы, билгеле, җавап кайтармады. Һәр узган кеше белән сөйләшеп торырга аның вакыты юк иде. Илгә корыч кирәк. Сабан һәм танк, таба һәм ракета ясар өчен. Өстәвенә, ул сөйләшә белми, цементтан коеп ясалган корыччы иде ул.

Корыч кайнатучыны узгач, диңгез күренде. Төрки телдә «Азак» диңгез дип аталган ул, соңгы диңгез.

Менә унҗиденче микрорайон. Менә Нахимов проспекты, Адмирал Лунин урамы. Унда — почта, «Азов морягы» газетасының редакциясе, сулда диңгез порты, пакгаузлар, краннар, диңгез кораблары. Таксист машинасын «Моряк» кунакханәсенең пыяла ишеге янына китереп туктатты. Монда ваклашмыйлар. Диңгезчелек абруе шушындый чакларда сынала. Таксист чемоданымны гостиницаның вестибюлена илтеп куйды — канәгатьлек билгесе.

Пыяла ишекне ачып эчкә үттем. Администратор урынында Зинаида Васильевна утыра. Исәнләштем. Ул да сәлам бирде. Карашы җылы. Аның ире боцман Саша Морза белән мин елдан артык «Чолым» пароходында эшләдем.

— Саша кайларда йөри?

— Киткәненә инде биш ай. Вьетнамда йөк бушаталар.

— Күп калмаган икән, егерме-утыз көннән өйдә булачаклар.

— Өйдә? Йөкләрен бушатып бетергәч, бодай төяргә Австралиягә китәчәкләр.

— Нишлисең бит, Зинаида Васильевна, Саша диңгезче, ә сез диңгезче хатыны...— Калганын әйтмәдем. Бу хакта тугарылмау әйбәтрәк. Диңгезче язмышын аңлап та, аңлатып та булмый. Юатырга тырышып, сүз куерта башласаң, әңгәмәчененң канына тоз салып, аның иске яраларын яңартып кына җибәрәсең.— Ә балалар ни хәлдә, Зинаида Васильевна?

— Кызыбызны кияүгә бирдек. Кияү дә диңгезче. Малаебыз диңгезчеләр мәктәбенә укырга керде. Мин сезне бүген дүрт урынлы номерга урнаштырып торам. Пароходчылыкта профсоюз киңәшмәсе бара. Әйбәтрәк номерларда делегатлар яши. Бер төнгә генә түзәрсез әле. Иртәгә конференция бетә, табарбыз әйбәт урынны.

Администраторның җылы сүзе миңа иң затлы люкстан да кыйммәтрәк иде. Без бит елдан-ел әйбәтрәк яшибез. Тамак тук, өс бөтен, бар нәрсә бар. Тормыштан да зарланырлык түгел, ләкин җылы сүзгә мохтаҗлык кимеми, киресенчә, арта бара.

Чемоданымны күтәреп, өченче катка мендем. Утыз бишенче номер, эчкә уздым. Дүрт карават, дүрт тумбочка, өстәл, дүрт урындык. Бүлмә буш. Бүлмәдәшләрем кайдадыр йөри. Мин аларны әле күрмәгән, шуңа карамастан, тулай торак, кунакханә кануннарына таянып, шушы бүлмәдә үтәчәк язмышымны алдан әйтә алам. Өч кешенең берсе, һичшиксез, сыра яратучы булачак. Кич белән морадына ирешкән кешеләрдә генә очрый торган канәгатьлек белән елмаеп, номерга кайтып керәчәк ул. «Сыра таптым!» Тиз генә дусларын җыеп алып киләчәк. Өстәл янына утыргач, әле эчләрен чылатып җибәргәнче үк сине сыра эчәргә кыстый башлаячаклар. Синең баш тартуың алар тарафыннан санга сукмау итеп кабул ителәчәк. Син бүлмәдән чыгып торган арада сырачылар сине чишендерәчәкләр: «Сыра эчми, ә? Нигә эчми икән ул, шуны беләсе иде. Авырудыр бәлки? Юк, авыруга охшамаган. Димәк, подонок. Мин шундук сизеп алдым аның кем икәнлеген. Юньле кеше сырадан баш тартамыни? Кабахәттер, я булмаса,— бу сүзне әйтүче як-ягына каранып алачак,— стукачтыр?».

Шул язмыш берләштергән өч кеше арасында эчми, тартмый торган кеше дә булачак. Ул, билгеле, синең ягыңны тотачак. Тыйнак һәм әдәпле күренәчәк ул сыра яратучылар белән чагыштырганда. Әйтәсе сүзен алдан уйлап, чама белән, ярым пышылдап вәкарьле сөйләшәчәк. Ул бәндәнең мендәре астында Валентин Пикуль китабы булачак. Үзен культуралы санаган кеше ничек инде Пикульны укымыйча яши алсын? Ул сине файдалы киңәшләр белән күмеп ташлаячак. Һәр киңәше бушлай, рәхим ит, без биргән киңәшкә акча сорамыйбыз...

Шушы бәндә белән бер бүлмәдә яшәгән арада син кырыктан узгач ит ашарга ярамаганны, тәрәзә белән ишекне бергә ачудан сквозняк барлыкка килеп, сәламәтлекне җимергәнен, шулпа итнең үзеннән дә зыянлы булуын, ит шулпасы яраткан кешенең кан тамырлары эченә юшкын утыруы турында бушлай лекция тыңлаячаксың. Телевизор күзне боза... Шикәр ашыйсың түгелме? Ташла, тоз һәм шикәр — «ак үлем»... Син кибеттән сөт алып кайттың. Бала чагыңны искә төшереп, сөткә ипи турап ашамакчы буласың. Ялыктыргыч күршең, синең сәламәтлегең өчен көрәшүче үзешчән әйтеп сала: «Сөтне? Кайнатмыйча? Тукта, харап буласың. Анда бит бруцеллез авыруы бар!» Кунакханәдәге тормышың шушы минуттан тоташ газапка әйләнә. Бүлмә тынчу. Һәр ашаган азыгыңда миллионлаган бактерия төннәрен төшеңә ямьсез сурәтләр рәвешендә керә башлый. Кунакханәдән корабка күчкәч, теге сыра яратучылар белән дуслашудан баш тартуыңа үкенүдән бавырларың сызлый башлый.

Өченче күршең номерга таң атканда гына кайтып йөрүче булып

чыгачак. Күпме тырышсаң да син аның исемен, кайда эшләвен, холкын, зәвыгы турында әйтеп тә торасы юк инде, белә алмыйсың. Бар ул йорт анасы, албасты, пәри шикелле кеше күзенә күренмичә, кайдадыр читтә, ниндидер яшерен мохитта яши белүчеләр. Алар кайда да очрыйлар.

Вакыт үзгәрдеме, без үзебезме? Сугыш елларында вокзал идәнендә төн кунарга ярарлык урын табу безне җиденче күкләр бәхетенә тиң зур куаныч китерә иде, ә хәзер тәрәзәсе урам якка караган номерга эләгү сине кара кайгыга батыра.

## Икенче тәүлек. «Моряк» кунакханәсе. 07.40

Буфетка төшеп чәй эчтем. Ждановның суы каты, ниндидер тозлы су. Жданов суы чәйне харап итә. Бөерләрендә таш йөртүчеләр саны буенча бу шәһәр Союзда беренче урында диярлек. Кызганыч ки, картаю чәй яратуга ияреп килә булса кирәк. Әле күптән түгел генә Фатих ага Хөснинең бөтендөнья проблемасын хәл иткәндәге җаваплылык белән чәй әзерләп йөрүеннән көлеп утырган кеше идем мин. Менә инде үзем дә чәй колына әйләнеп барам. Төрек шәһәрләрендә чәйгә дигән чишмә суын урамда стаканлап сатып йөриләр. Чәй яратучы сатып алганда иң башта суның кайсы чишмәдән булуы белән кызыксына. Төрекләр искә төшкәч, портка юнәлдем. Юләр кеше шикелле, вахтада торучы матрослардан корабның кайсы илдән кайтуы турында сорап йөрим. Марина де Карраре портыннан кайткан корабтан бер шешә су сорап алып кайтып, чәй кайнатып эчкәч кенә башым җибәрде.

Чәйдән соң капитанга чылтыраттым.

— Исәнлек-саулыкмы?

— Ә комиссар, синме бу? Ждановка килдеңмени? Рәисә ханым ни хәлдә? Кыз ничек укый? Кая урнаштың?— Михаил Александрович бөтен сорауларын берьюлы биреп бетерә. Аның тизрәк эш турында сөйләшәсе килә. Без бит, кызганыч, ял вакытында эштән башка нәрсәне белмибез. Ә эштә һәрвакыт ял турында. Чын эшчәннәр, мәсәлән, инглизләр, беркайчан да эш турында сөйләшмиләр. Күптән сынап йөргәнем бар: эш турында туйганчы сөйләшкәннән соң ял итәсе килә башлый.

— Инна Ивановна ни хәлдә?— дип сорыйм.

— Оныкны тәрбияли.

Телефон трубкасын учым белән каплап, елмаеп алам. Инна Ивановнага тәрбия эшен армиядә алып барырга кирәк иде. Армиядә ул әллә генераллыкка ирешкән булыр иде. Ул хатын Михаил Александровичны да «тәрбияләп» кенә тора.

Михаил Александрович Гремин — корабсыз капитан. Мин аның беренче ярдәмчесе. Без аның белән корабсыз экипаж белән житәкчелек итәбез. Безнең экипажны туган иленә кайта алмыйча күп айлар йөргән диңгезчеләрне алыштырырга җибәрү өчен тоталар. Пароходчылыкның Беренче алыштыру экипажы дип аталабыз без.

— Кайсы корабка җибәрүләре билгеле түгелме әле?

— Менә бит син нинди, комиссар!— ди Михаил Александрович шелтә һәм соклану аша.— Дубровник портына «Алексей Щусев» экипажын алыштырырга баруыбызны бөтен дөнья белә.

— Күпмегә җибәрүләре билгеле түгелме?

— Алты айдан соң алыштырырга вәгъдә бирәләр.

— Син аларның вәгъдәсенә ышана башладыңмыни?

— «Щусев» экипажын да алты айдан алыштырабыз дип ышандырып җибәргәннәр. Аларның Союздан чыгып китүләренә тугыз ай тулды.— Капитан бер тын сүзсез торды.— Ало, сиңа кадрлар бүлегенә кереп чыгарга кирәктер. Унсигез яңа кеше. Шулар борчый мине. Күбесен теге «йонлач куллар» урнаштырган булса кирәк. Син бит Мәскәвенә китәсең дә олагасың. Күз-колак булып тормасаң, экипажны тулысынча

алыштырып бетерәләр иде. Тукта әле, без нигә соң телефон чылтыратып кына сөйләшәбез. Очрашырга кирәк безгә...— кинәт капитанымның тавышы өзелде. Мин аңлап алдым. Ул хәзер капитанша алдында җавап тота. Телефон трубкасы Михаил Александровичның учында. Мин бит аның белән инде өч ел эшлим, шунлыктан, ир белән хатынның үз квартирларында сөйләшүен өч чакрымнан ишетеп торам:

— Син, башсыз, әллә чакырырга уйлыйсыңмы?— Бусы Инна Ивановна тавышы.

— Соң бит... Минем аны соңгы күрүемә өч ай үтте. Чакырып бер мәртәбә чәй эчерсәк, бөләрбез дип куркасыңмыни?— Бусы капитан Гремин тавышы.

— Син ярдәмчеңнең колы булып беттең инде. Бөтен пароходчылык көлә үзеңнән. Капитан аталып йөри! Бозау син. Үзеңә буйсынган кешеләрне биетеп торырга тиешсең. Ә син,— Инна Ивановна бер мескеннең маскасын ясап күрсәтә,— Чакырып чәй эчерсәк, имеш...

— Ярый алай булгач,— ди Михаил Александрович телефон трубкасын учыннан алып,— Очрашкач, туйганчы сөйләшербез.

Ниһаять, мин кадрлар бүлегендә. Ишек алды, коридорлар тулы кеше. Бичләр. Кайбер «диңгезче»нең гомере шушында чуалып уза. Диңгезгә чыкмас өчен бич инспекторның ботинкасын чистартып яшәргә риза.

Бичләрне ерып коридорга үттем. Хәзер икенче катка менәргә кирәк. Исәп бүлеге шунда. Шул бүлеккә кереп унсигез кешенең «Шәхси эш»ләрен карап чыгарга кирәк, ә характеристика исә яңа кеше турында сиңа бернинди мәгълүмат бирә алмый. Анда шаблон язылган сүзләрдән башка бернәрсә юк. Мин коридорга җыелган кешеләр арасыннан танышларны эзлим. Кораблар җир шарының төрле почмакларында берберсеннән утызар мең чакрымда йөзеп йөриләр. Шуңа карамастан, диңгезче халкы бер-берсе турында бар нәрсәне белә. Әйтерсең алар, пароходчылыкның алты мең диңгезчесе, бер юрган астында йоклый.

Кырык минут коридорда сөйләшеп торганнан соң, мин экипажның унсигез яңа әгъзасы турында бар нәрсәдән тулысынча диярлек хәбәрдар идем инде.

Соңгы йөзүдән кайткач, безнең экипажга өч ай ял бирделәр. Шул өч ай эчендә күп нәрсә үзгәреп өлгергән. Ришвәт алганнары өчен ике инспекторны төрмәгә утырткannaр, кадрлар бүлеге башлыгын эшеннән куып чыгарганнар.

Яңа инспектор — интеллигент кыяфәтле яшь, чибәр егет. Түшендә университет значогы. «Кач тизрәк, әле соң түгел. Кит бу урыннан җаның каешланып беткәнче. Синең карамакта егермедән артык кораб. Һәр корабта утыз-утыз биш кеше эшли. Җиде йөзгә якын бәндә һәм шуларның һәммәсенең яхшырак корабка, әйбәтрәк илләргә йөри торган пароходка урнашасы килә. Күпчелек шул теләкне күңелендә тотып картайса да, диңгезчеләр арасында теләккә ирешер өчен нинди генә сылтаулар кулланмый, инспекторның нинди генә кылларына чиртеп карамый торган шома егетләр бар. Бер көнне ялгызың утырганда кабинетыңа шундый бәндә килеп керер дә кайсы корабта йөзәргә теләгәнен әйтер. Ул чыгып киткәч, өстәл тартмасын ачып карасаң, анда бер учлам акча яткан булып чыгар. Ычкын тизрәк, кит бу урыннан, егеткәем»,— дип әйтәсе килүдән көчкә тыелып калдым.

Экипаж исемлеген укып чыктым да тагын уйга калдым. Исемлек капитаннан башлана. Телефоннан сөйләшү күз алдыма килеп басты. Ни сәбәп ирләрнең иң затлылары гаугадан тыш бернәрсәгә ярамаган хатыннарга буйсынып гомерләрен исраф итәләр? Лилия Брикның колы булып яшәгән Маяковскийны, икейөзле хәйләкәр Чармианның аяк астында туфрак булып дөнья күргән Джек Лондон — мондый мисалларның иге-чиге юк. Чын ир-егет хатын-кыз белән ваклаша алмый. Гаилә ефрейторлары әллә шуннан файдаланалар? Хатыны аркасында Михаил Александрович беркем белән дә озак дуслаша алмый. Иренең

ихтирамы, аның җылы мөнәсәбәте дусларына китүдән куркып, Инна Ивановна ул мескеннең бугазыннан эләктереп алган, бер генә адымга да үзеннән читкә җибәрмичә тота.

Бер заман безнең капитан бик каты «салган». Абруеңа бер тапкыр тап төшсә, тиз генә юа алмыйча озак вакытлар интегәсең. Гөнаһ эшне, ни сәбәптер, озак хәтерлиләр. Изге эш кенә ул күзгә чалынып тормый, чалынса да, тиз онытыла. «Бу кеше миннән гөнаһлырак. Моныкына караганда минем кимчелекләрем бөтенләй юк диярлек». Менә шушы җайланыш гавам дикъкатен начарлык ягына каратып тота.

«Я ничек, Михаил Александрович һаман эчәме?»— дип сорыйлар безнең капитанны белгән кешеләр. Шушындый сорау бирүчеләрнең күбесе үзләре — беткән бәндәләр. Көнләшү тойгысы тудыра андый сорауны.

* * *

Ялга китәр алдыннан безнең капитан белән бер күңелсез хәл булып алды. Ул көнне без Жданов портында тора идек. Пароходчылыкта бүлек башлыгы булып эшләүче бер түрә министрлык түрәсен безнең корабка алып килде. Указ һәм Үзәк Комитетның мәгълүм карары чыкканчы, тикшерергә килүчеләрне корабка алып килеп сыйлау даими гадәткә әйләнеп беткән иде инде.

— Башка корабка алдан сөйләшмичә Мәскәү кунагын алып килмәс идем. Сезнең экипажның тәртипле булуын, кораб төзек, чиста булуын белгәнгә күрә, алдан кисәтеп тормыйча килдек,— диде бүлек башлыгы.

Мондый эш, гадәттә, кораб караудан башлана. Бу эш гаилә тормышында да нәкъ шулай эшләнә бит. Кунак килер алдыннан йорт җентекләп җыештырылган, борыны китек чәйнек ераккарак яшеренгән, балалар тәти киенгәннәр. Кунак көткәндә генә үзара бугазлашып алган ир белән хатын да шундый тату, шундый сөйкемле гөрләшәләр. Кунакларга башта квартира күрсәтелә. Алар килгәнче «Потемкин авылы» ясалып өлгергән. Бүлек башлыгының Мәскәү кунагын безгә алып киләсен разведка безгә белгертеп куйган иде. Без, билгеле, әзерләнеп тордык. Мин кунакларга спорт залын, сауналы, бассейнны, пөхтә яшәүче диңгезчеләрнең каюталарын күрсәттем. Очраклы сыман гына итеп, үтешли:

— Капитан каютасы. Теләгегез булса, аны да карап чыгарга була,— дигән булып, мастерның апартаментларына алып кердем.

Кунакларны Михаил Александрович үзе каршылады. «Бусы кабинет, менә монысы йокы бүлмәсе, ванна, туалет»,— дип аңлатырга тотынды каюта хуҗасы.

— Бу ишек күперчеккә чыгарамыни?— дип сорады Мәскәүдән килгән тикшерүче. Сорау аның кем икәнлеген ачыклады. Диңгезче түгел иде бу түрә. Аның моңа кадәр кораб күргәне булмаган, күрәсең. Аллага шөкер. Кораб тормышын татымаган кешенең күзен буяу сукыр бер тиен тормый. Шторм, давыллар, корабның төнлә йоклап яткан кит балыгына килеп бәрелүе турында сөйлисең, Малакка бугазында кораб артыннан куып килгән пиратлар турында. Диңгезчелек гыйлемен үзе татып караган кешегә мондый азык батмый. Аңа күз буяу кирәк тә түгел. Диңгездәге озын, ялыктыргыч көннәрне үз язмышы аша үткәргән кеше сине сүзсез аңлый һәм ул сиңа шәфкатьлерәк була.

Бүлек башлыгы «күперчеккә чыгара» торган ишекне ачты. Капитанның салонында өстәл әзерләнгән иде. Бәллүр вазаларда чын гәрәбә шикелле эчтән ялтырап, яктылык балкытып торган балык уылдыгы, лимон ярчыклары белән бизәлгән краб консервасы, казылык, кыздырылган тавык, кайнар ыслаулы балыклар. Коньяк, виски, джин, аракы. Адәм баласын юлдан яздыру өчен искиткеч зур тәҗрибә белән эшләнгән ымсындыргычлар өстәл өстенә тезеп куелган. Чит илләрдә эшләнгән шешәнең үзен генә ал, аңа ябыштырылган этикетканы, аның бөкеләрен.

Капиталист, гомумән, һәр эшне белеп эшли. Мондый шешәләрне күргәч, гөнаһ кылуны, дуңгыз булып аунап ятуны күз алдына да китерү мөмкин түгел. Мондый шешә эчендә фәрештәләр авыз чылата торган зәмзәм суыдыр дип ышанасың, ә ул синең әхлагыңны җуйдырасы, сине юлдан яздырасы, синнән кешелек исемен юып төшерәсе агу булып чыга.

— Рәхим итегез, кадерле кунаклар, ходайның язганы,— диде Михаил Александрович.

— Ходай хәйран тырышкан, саранланмаган икән,— диде бүлек башлыгы.

— Сез минә монда, түргә узыгыз,— диде капитан министрлык вәкиленә.

— Юк, юк, рәхмәт. Ашыгабыз. Безнең әле тагын берничә корабны тикшерәсебез бар,— дип ишеккә таба юнәлде Мәскәү кунагы.

— Диңгезчелек гадәте буенча, корабка кергән кешене ашатмыйча чыгарырга ярамый,— дип бүлек мөдире аның юлына аркылы төште.— Юк, әзерләгән сыйдан авыз итмичә китәргә ярамый. Алай китү традицияне бозу санала.

Указ чыкканчы кунакчыллык күрсәткән булып, гореф-гадәт сылтавы белән кирәк кешене майларга шул кадәр остарып җиткән идек без. Бу эшкә Үзәк Комитет карары чик куймаган булса, белмим, нинди генә җинаятьләр эшләмәгән булыр идек. Тикшерергә килүчеләр кулларын юып, табын янына утырдылар.

Сүз башта, билгеле, эш турында, план үтәү, портларда чират көтеп вакыт югалтулар турында барды. Мәскәү вәкиле флот яңалыкларын, булачак реформалар, үзгәрешләр турында сөйләде. Без, билгеле, күз буяп, аның шундый күпне белүенә, диңгезчелек эшенең катлаулылыкларын аңлавына сокланган булып утырдык. Алдында татлы ашамлыклар, вәсвәсәле шешәләр өелеп торганда эш турында озак сөйләшеп буламыни. Мәзәкләргә күчкәнебезне сизми дә калганбыз. Һәм шулай матур гына коры куык кабартып утырганда бүлек башлыгы капитанга бәйләнә башлады:

— Туктагыз әле, иптәшләр. Без ашыйбыз, эчәбез, ә хуҗа үзе, әйтерсең, ураза тотучы гарәп, рюмкасына авызын да тигереп карамады. Юк, иптәшләр, болай ярамый.

— Без бит таңга каршы диңгезгә чыгабыз,— диде Михаил Александрович.— Миңа ярамый.

— Димәк, безгә ярый? Шулаймы? Димәк, безнең эш җаваплы түгел, синең эшең генә җаваплы, иптәш Гремин? Михаил Александрович, син безне бу корабка эчәр өчен килделәр дип уйлый торгансыңдыр бәлки? Әйт, комиссар, капитан шулай уйлый бит, әйеме?— диде ул минем якка борылып.— Министрлыкта эшләүче дә Греминның корабына бер рюмка аракыга өметләнеп килгән. Шулай булып чыга бит инде бу, әйеме?

— Юк, мин алай уйламыйм,— дип аклана башлады безнең капитан. Хәзер ул дәресен белмәгән укучы шикелле кызганыч хәлдә иде.— Әйттем бит, йөк төялеп бетү белән документларга кул куясы, таможенник һәм чик сакчыларын чакырасы да кузгалып китәсе калды дип. Син үзең, Гриша, капитан булып эшләгән кеше, җаваплылыкны аңларга тиешсең.

— Каюта хуҗасы безне эчәргә ымсынып килүчеләргә саный, әйдә, киттек,— диде бүлек башлыгы министрлыктан килгән кешегә. Алар икәүләп урыннарыннан тора башладылар.

— Юк, китмәгез,— диде капитан. Ул чыннан да куркып калган иде. Нәрсә әйтсәң дә, без бит бүлек башлыгына буйсынабыз. Теләсә ул безне план үтәлә торган әйбәт линиягә куя ала, теләмәсә, планетаның Вьетнам кебек кайнар нокталарына, туплар атып, снарядлар ярылып торган җирләргә җибәрә ала.— Кунаклар хөрмәтенә,— диде Михаил Александрович рюмкасын күтәреп. Мин аның кабыргасына төртеп карадым. Ул бер чөмерүдә рюмкасын бушатып куйды.

Елмая иде безнең капитан. Аның бите маскага әйләнде. Ул тыштан кунак сыйлаучы юмарт кешегә әверелде, әмма аның рәнҗүенә, йөрәге әрнүгә каютаның стеналары, түшәм һәм идәннәр ыңгыраша иде. Мин аны, йомыш тапкан булып, коридорга чакырып чыгардым.

— Нәрсә эшлисең син, Михаил Александрович. Син үзеңне белмисеңмени? Бер башлагач тыела алмыйсың бит. Харап итәсең үзеңне, аңлыйсыңмы?

— Без синең белән түрәләр биргән боерыкны үтәргә тиешбез. Бүлек башлыгы эчәргә боерды. Министрлыктан килгән кеше аның боерыгын хуплады. Син дә эчәргә тиешсең, комиссар. Әйдә, эч! Бу минем фәрманым. Мин сиңа эчәргә боерам.

Төн урталарында пароходчылык башлыгының персональ машинасы чакырылмаган кунакларны алып китте. Йөк төяү тәмамланып килә иде. Корабны әйләнеп, вахтада торучыларны карап, тикшереп чыккач, капитан каютасына кердем. Ни күзем белән күрим, Михаил Александрович шешә авызыннан аракы чөмереп утыра. Мине күргәч, шешәсен чүплек савытына томырды.

— Ташлыйм мин бу кабахәт эшне. Урам себерергә ялланам. Төнге каравылка керәм. Түзәр хәлем калмады! Ташлыйм, китәм диңгездән. Гриша Тищенко шикелле карьеристларның күңелләрен күреп, холуй булудан туйдым. Ташлыйм, мать якасын!

— Диңгезне ташлау мәсьәләсен рейстан кайткач хәл итәрсең. Ике сәгатьтән йөк төяләп бетә. Ятып бераз ял ит, Михаил Александрович. Бу килеш син диңгезгә чыга алмыйсың. Әйдә, ят, ял ит.

— Без бит бүген Инна белән театрга барырга тиеш идек. Я хода! Инна белән театрга барырга тиеш идек...

Хатыны искә төшү белән капитанның аскы ирене асылынып төште, ияге дерелди башлады. Менә кемнән курка иде ул. Мин бу хәлдән файдаланырга ашыктым.

— Хәзер үк ятмасаң, Инна Ивановнаны пароходка чакыртам,— дидем мин.

— Ятам. Хәзер ятам. Чакырма. Йөк төяләп бетүгә пыяладай саф булачакмын, чакырма.

Төнге дүрттә корабка комиссия килде. Чик сакчылары башлыгы таможнячылар житәкчесенә: «Капитан авырыбрак тора, мөмкин булса, тикшерүне аннан башка гына алып барсагыз иде»,— дидем. Тикшерделәр. Чикне яптылар. Кораб әле причалга терәлеп тора, ә рәсми яктан без инде чикнең теге ягында. Әнә, жилкәсенә автомат аскан солдат трап янында сакта тора. Әгәр берәр кеше корабка керсә, аның шул күренмәс сызыкны үтүе чик бозуга саналачак. Күпме ясалма катлаулылыклар бар бу дөньяда!

Ниһаять, лоцман килде. Аврал уйнадык. Мин рубкага мендем. Рубкада дүртенче ярдәмче, өлкән рулевой һәм өлкән штурман. Өлкән штурман капитанга чылтыратты. Җавап юк. Өлкән штурман миңа карый. Сорау бирергә курка. Мин тиз генә аска төштем, капитан каютасының ишеген тарттым. Ишек бикле. Капитан каютасының ачкычы миндә дә бар. Экстремаль очракта, әгәр диңгездә чакта янсә чит ил портларында торганда корабка һөҗүм итсәләр, мин капитан каютасында саклана торган яшерен документларны юкка чыгарырга тиеш. Тиз генә ачкычны алып килдем. Ачкыч керми. Ишекне эчтән бикләп, ачкычны йозакта калдырганнар. Ишек шакырга керештем. Артык тавыш чыгарырга да ярамый. Җавап юк. Аңлашылды.

Чик ябык. Причал бушаганын көтеп рейдта берничә кораб тора. Шуларның берсенә инде лоцман китте. Диңгезгә чыга алмыйбыз, дип диспетчерга хәбәр итү белән безне тикшерергә портнадзор вәкилләре, диспетчер, тагын әллә кемнәр ябырылачак һәм Греминның капитанлыгы... Югарырак урынга күтәрелүе генә кыен бит ул. Аннан төшүе, текә таудан аска очкан шикелле, тиз һәм җиңел.

Кире рубкага мендем.

Инде тынгысызлык башланган. Өлкән штурман, дустым Виталий Федорович Веденко җавап көтә.

— Виталий, корабны порттан чыгара аласыңмы? — дидем пышылдап кына.

— Нәрсә булды?

— Капитан кинәт авырып китте. Хәлен экипажга белгертәсе килми. Ышаныч синдә, Виталик.

— Пайлот,— диде Веденко боерык көтеп торган лоцманга.— Кораб белән идарә итүне капитан миңа тапшырды. Кузгалабызмы?

— Ярый, кузгалабыз.

Кораб ачык диңгезгә чыккач, каютама кердем. Нишләргә? Инструкция буенча капитанның кораб белән идарә итәргә сәләтсезлеген мин пароходчылыкка һәм парткомга шундук хәбәр итәргә тиешмен. Бусы минем рәсми вазифам. Ә кешелек вазифасы? Әхлак канунынннан караганда бу эш капитанны сату, өч еллык бергәлекне, өч ел күргән авырлыклар тудырган дуслыкны сындыру, өзү була. Мин хәзер ут белән су арасында. Тукта, ашыгырга ярамый. Башта капитанның хәлен белергә кирәк... Каюта эчтән бикле. Телефонны алдым, чылтырата башладым. Җавап юк. Сволочь син, бүлек башлыгы! Син бит министрлыктан килгән кеше алдында, капитанны үзеңә буйсындыра алганыңны күрсәтер өчен, аны эчәргә мәҗбүр иттең. Власть. Өстенлек. Буйсындыра алу. Ата җенесләрнең канындагы куркыныч сыйфатлар бу.

Электромеханикка кереп отвертка, каргаборын алып чыктым. Йозакны ватарга туры килде. Кердем. Эссе. Тынчу. Иллюминаторларның барысы да ябык. Тын да алырлык түгел. Каютада бардак. Мондый тәртипсезлек каюта хуҗасы исерек чакта гына була. Ә болай Михаил Александрович — пөхтәлек колы, педант. Аның өстәлендәге берәр кәгазьне мыштым гына урыныннан кучереп куйсаң, ул аны шундук күреп ала, кире урынына кайтара. Гомумән, каты куллы хатын белән яшәгән ирләр көндәлек тормышта солдат шикелле җыйнак һәм тәртипле булалар.

Каютаны тикшерергә керештем. Йокы бүлмәсе ишегенә янәшә чөйдә Михаил Александровичның тужуркасы, тужурка кесәсендә сейфның ачкычы булырга тиеш. Тужурка идәндә. Кулым түш кесәгә сузылды, капшыйм, ачкыч юк. Күз алларым караңгыланып китте. Сейфтагы документлар икебез карамагында. Сейф ачкычының бер генә минут урыныннан югалып торуы турында да без югары инстанциягә хәбәр итәргә тиешбез.

Йокы бүлмәсенә уздым. Кергәндә капитанның туфлиенә абындым. Икенче туфли аның аягында. Салып өлгермәгән. Йөзтүбән караватына ауган. Күлмәге сыдырылып өскә күтәрелгән. Киң, итләч аркага карап бер тын уйлап тордым... Безне бит, дус кеше, төрмәгә парлап утыртачаклар... Устав буенча капитан — иң баш кеше, партия каршында капитан эшләгән эшләр өчен мин җавап бирәм. Яшерен документлар буенча без икебез дә тигез җаваплы. Менә ничек хәйләкәр эшләгәннәр җаваплылык мәсьәләсен!

Йокы бүлмәсеннән чыгып салонга юнәлдем. Өстәлдә ипи сыныклары, буш шешәләр аунап ята. Өчесе аракынныкы, икесе шәрабтан бушаган. Литр ярым кырык градуслы, литр ярым сигез-ун градуслы агу. Йөз грамм алкоголь атны үтерә, диләр... Төштән соң сәгать дүрттә Керчь бугазы. Гадәттә, безнең капитан аны лоцмансыз уза. Бу юлы лоцман чакырырга туры киләчәк. Пароходчылыкта гел юләр кешеләр генә утырмый бит. Ничә еллар бугаз аша мөстәкыйль йөргән капитанның бу юлы лоцман чакыруының сәбәбе белән кызыксына башлаячаклар. Без капчыкта ятмый. Бу турыда уйларга кирәк. Өлкән ярдәмчегә юнәлдем. Ул иртәнге сигездә вахтадан алмашынып ял итәргә ята. Уятырга туры килде.

— Виталий, капитанның эше начар. Ул Керчь бугазыннан узганга

да тора алмас шикелле, нишлибез?

— Керчь бугазын мин яхшы беләм, ләкин, лоцмансыз үтәргә әмер белән расланган рөхсәт кирәк. Андый рөхсәт миңа бирелмәгән. Лоцман чакырырга туры киләчәк.

— Ничек уйлыйсың, пароходчылыкта: ни сәбәптән лоцман чакырдыгыз, дип төпченә башламасалармы?

— Лоцман чакырган заявкалар Керчь порты капитаны конторасына туплана. Самборский безнең капитанның дусты. Берни булмаячак,— диде өлкән штурман Веденко.

— Хәл иттек, алай булгач. Ышаныч синдә, Виталик.

— Хәзер заявка язам. Радиограмманы алты сәгать алдан бирергә кирәк,— һәм өлкән ярдәмче, урыныннан торып, радиограмма язарга утырды.

— Капитанның авырып ятканын башка штурманнар беләме? — дидем мин Веденкога.

— Сез бит, Миргазиян Закирович, диңгезчелектә беренче ел эшләмисез. Шушы каютада төчкерсәң, аскы палубадагы мотористлар каютасында, сәламәт бул, дип җавап бирәләр. Без бит утыз биш кеше бер юрган астында йоклыйбыз.

— Капитан Босфорга җиткәнче тора алмаса, нишләрбез?

— Анда күз күрер,— диде Виталий Федорович. Мин аны нәкъ шушы гадәте өчен яратам. Кайбер кеше, бигрәк тә куркаклар һәм вакчыллар, әз генә бер кырынрак мәсьәлә тудымы, аны катлауландыра, әллә нинди куркыныч, фаҗигале нәтиҗәләргә китереп тоташтыра. Виталий, киресенчә, иң катлаулы мәсьәләләрне дә гадиләштереп, җиңеллеккә, иминлеккә юл саба белә. Экипаж төзегәндә капитанның Веденконы аласы килмәгән иде. Әле дә, мин экипаждан китсәм, Михаил Александрович бу егеттән тизрәк котылырга ашыгачак. Алар икесе ике төрле кеше. Психологик уртаклык юк алар арасында, шунлыктан капитан белән өлкән штурманның үзара мөнәсәбәтләре һәрвакыт диярлек минем аша җайлана килә.

Чара күрергә кирәк иде. Капитан янына юнәлдем. Кемдер мин ваткан йозак белән кызыксынган. Экипажда күз-колак булырга яратучылар җитәрлек. Аларның кайберләре кызыксынудан гына түгел, рәсми рәвештә капитан белән минем һәр адымымны күзәтеп, исәпкә алып торалар. Эше шундый бит, нишлисең?

Чит ил портларында безнең белән эш итүче агентларны, стивидорларны, порт вәкилләрен сыйлап чыгару өчен һәр корабка вәкиллек аракысы, затлы кабымлыклар бирелә. Аларның барысы да капитан каютасында, аның карамагында саклана. Корабка килгән чит ил вәкилләрен сыйлаучы юмарт капитаннар да очрый, билгеле. Күп капитаннар... Бу инде артыгын сайрау дип атала. Капитан каютасындагы суыткычны ачып, чит ил портларында торганда килгән кунакларны сыйларга алынган барлык шешәләрне җыеп кладовкага илттем дә йозак белән бикләп куйдым. Тәҗрибәле капитаннар суыткычтагыдан тыш кагылгысыз запас итеп бирелгән эчемлекләрне башка урынга яшереп тә торалар. Төрле чаклар була һәм беркайчан да запас эчемлек булу зыян итми. Билгеле, капитан үзе салырга яраткан бәндә булмаган очракта.

Кинәт кәефем күтәрелеп китте. Хәзер инде һәр очракта капитан Босфорга җиткәнче «терелергә» тиеш. Башка чара калмады аңа. Баш төзәтү әмәленнән мәхрүм иттем мин аны. Хәзер инде өстәү мөмкинлеге юкка чыкты. Шулай да капитанның хәлен белергә кирәк. Һәм мин эчтән бикләнгән йокы бүлмәсенең ишеге каршында туктап калдым. Димәк, мин генә түгел, ул да чара күрә. Астыртын көрәш башланды. Нәкъ детектив кинодагы шикелле. Көлке дә, шул ук вакытта елатырлык хәлгә дә китереп куюы бар мондый шапшак уенның. Салырга яраткан кеше белән тапма да, югалтма да. Моңа Михаил Александрович мисал. Шундый әйбәт тоела ул айнык чакта. Киң күңелле. Кешелекле. Кайгыртучан.

Әгәр мин гомер буе кешеләрне өйрәнмәгән булсам, капитанның шундый куркәм гадәтләренә чын күңелдән ышанып, их, эчә торган гадәте булмаса, бу кеше — ир-егетнең иң асылы булыр иде дип алданыр идем. Инде менә кырык елга якын мин кеше дигән җир йөзендәге иң катлаулы, иң аңлашылмас һәм четерекле механизмны өйрәнәм. Адәм баласының чын холкы, аның эчке сыйфатлары исерек чакта ачыла. Исерек чакта кеше юләр икән, ул чыннан да дурак. Аның айнык чакта акыллы күренүе — сәхнә уены гына. Күз буяу осталыгы гына ул айнык вакыттагы әйбәтлекләр. Чын-чыннан кешелекле, юмарт, киң күңелле кеше исереп китсә, тагын да әйбәтләнеп китә. Бу турыда һәркем белергә тиеш. «Эчмәсә, аңа тиң әйбәтне табып булмас иде», дип алданмаска тиеш без.

Бу юлы Михаил Александрович ачкычын скважинада калдырырга оныткан. Үз ачкычым белән ачып, йокы бүлмәсенә кердем. Чишенеп юрган астына кереп яткан. Чал төк баскан бите үлгән кешенекен хәтерләтә. Каны качкан бу кешенең битеннән, тиресе күмгәкләнә башлаган, күгәргән, балавыз төсе кергән. Иреннәр пешеп, кабарып чыкканнар. Авыз кипкән. Телләр, аңкаулар, иреннәрнең эчке ягы пешкән шикелле, кыпкызыл, әйтерсең, аның авыз эчен кайнар күмер салып ыслаганнар. Сулышы шундый авыр. Тын алганда үпкәсендә гыжлаган, тонык итеп сызгырган тавышлар ишетелә.

Йокы бүлмәсен кабат тикшерә башладым. Почмакта, пароходчылыкка барганда олпатрак күренер өчен тотыла торган атташе-кейс янында буш аракы шешәсе аунап ята, ванна бүлмәсендә буш одеколон шешәсе. Мин бит җентекләп тикшергән идем. Эчәргә ярарлык бернәрсә калмаган иде каютада. Кем белгән шушындый ир одеколон эчү мәсхәрәсенә барып җитәр дип? Рәчәй! Рәчәй бу, мин ялгышмыйм.

* * *

Тагын бер тәүлек узды. Босфор котылгысыз якынлаша. Капитанның серен докторга ачарга туры килде. Гиппократ анты биргән кешегә ышанырга ярар дип уйладым. Алексей Теунов белән моңа кадәр эшләгәнем булмаса да. Доктор капитанга айныта торган укол кадады, клизма ясап эчен юды. Ул, гадел һәм тәҗрибәле белгеч буларак, Михаил Александровичның агулануыннан курка иде.

Яңа экипаж әгъзалары белән танышу мәшәкате аркасында көн тиз үтеп китте. Вахтада торучыларны тикшереп чыктым. Өлкән штурман белән Босфор мәсьәләсе турында киңәштек. Виталий Федорович җаваплылыкны өстенә алды.

Каютага кереп, Ждановта торганда җыелган хат-хәбәрләрне карап чыктым да йокларга ятарга әзерләнә башладым. Ишек шакыдылар.

— Рәхим итегез.

Башта мин аны таный да алмадым. Кем соң бу? Күз аслары капчыкланып асылынып төшкән. Җилкәләр салынкы. Куллар калтырап тора. Каршымда бөкрәеп беткән бер кызганыч, кешелек кыяфәтен югалта башлаган бәндә басып тора. Күзләр идәндә. Кеше түгел бу — бакча карачкысы, шәүлә.

— Бер йотым... Зинһар бер генә йотым! Бирмәсәң — үләм. Үләм мин, зинһар бер йотым!

Күкләр шаһит, кызгандым мин аны. Хөкүмәт һәм партия корабта тәртип, дөреслек, эштә сыйфат һәм гаделлек саклаган өчен миңа эш хакы түли. Тәртип бозуда, җинаятьтә катнашсам, мине эшемнән пычрак себерке белән куып чыгарырга тиешләр. Яңа ел каршылаганда бокал күтәрер өчен алган шампанскийны ачып, капитанга бер стакан шәраб агыздым. Голт-голт йота. Шәраб тын юлына китте булса кирәк, буылып ютәлли башлады. Кызганыч һәм костырырлык җирәнгеч. Кешене башка җан ияләреннән — маймылдан, җанвардан, бөҗәкләрдән бөек сыйфатлар — акыл, иман, вазифасы каршындагы җаваплылык аерып тора. Шу-

шы сыйфатларның тамчысы да калмаган бу бәндәдә. Кешелек исеме тар-мар. Каршымда җир корты, деградант...

Миңа шул нәрсә аңлашылмый. Айнык чакта аң да, әзме-күпме вөҗдан да бар шикелле бу кешедә. Аның ерак сәяхәттән урап кайткан чакта җиңнәренә алтын ука шеврон теккән кара тужуркасын, диңгезчеләр фуражкасын, ак яка арасыннан күренеп торган галстугын тагып властьларны каршыларга чыккан чагын күрәм. Пароходчылыкта үткәрелгән киңәшмәләрдә сүз алып, «без, диңгезчеләр...» дип күкрәк киереп сөйли башлаганы күз алдыма килеп баса. Кая аның хәзер горурлыгы? Кая иргетлеге? Ниһаять, кешелеге кая? Без менә өч ел бергә эшләп, бер-беребезгә «син» дип дәшкәндә һаман тартынып китүебезне сизеп уңайсызланып куябыз күп чакларда. Уйлап, чама, зәвык белән эш итәргә тырышабыз. Үзара ярышып, экипаж әгъзалары каршында зур җаваплылык белән абруй сакларга тырышабыз. Каршымда басып торган бу бәндәдә андый сыйфатларның бөртеге дә калмаган иде. Һәм андый катлаулы әхлак мәсьәләсен аңларлык та түгел иде бу шәүлә, бу өрәк, бу карачкы... Мин читкә борылып, яка сәдәфләрен ычкындырып җибәрдем. Иллюминаторны ачып, саф һава йоттым.

— Зинһар китегез. Күрәселәрем килми!

— Рәхмәт. Бирмәсәгез, үлә идем...

Ишек ябылган тавыш ишетелгәч кенә борылып карадым. Күрергә туры килмәде, бәлки карак шулай чыгып тая торгандыр тотылудан куркып. Коридордагы аяк тавышларында икейөзлелек, әхлакый пычраклык ишетелә иде.

Босфор бугазына кергәндә капитан йөртү рубкасында иде инде.

— Өч градус уңга. Шулай тотырга! Сулга тайпылмагыз!

Шушы көнгә кадәр баш ватам: җаваплылык, гаделлек чыгардымы икән Михаил Александровичны, әллә Босфор аша лоцмансыз үткәнгә түләнә торган акча шаукымымы? Чит кеше күңеле — карурман. Бу турыда беләм, дип бары тик мактанчыклар гына әйтә ала.

* * *

Тагын ун сәгать узды. Дарданелл бугазыннан чыгып киләбез. Каршыда җылы зәңгәрлек. Борынгы мифлар төбәге. Кораб вак атаулар янында уза. Күңелемдә тегермән ташы. Капитанның теге «эшенә» күз йомып узу — җинаять. Партия каршында да, вөҗдан каршында да җинаять. Спардекта, палуба читендәге релингка таянып, диңгезне күзәтәм. Кемнеңдер кулы җилкәмә килеп ятты.

— Закирыч, аңлыйм мин сине. Син, кадерлем, миңа ачуланасың. Әйдә биш кенә минутка минем каютага керик әле.

Каютага кердек. Мин утырдым. Михаил Александрович ишекле-түрле йөри. Сул кулы белән уң кулының бармакларын шартлата.

— Киңәш бир, экипаж күзенә ничек күренim? Ничек мин аларга боерык бирә, тәртип бозмагыз дип әйтә алыйм?

Каршымда кыйналган эткә охшашлы мескен, кызганыч бер бәндә утыра. Күзләр тонык, ияге асылынып төшкән, җансыз куллар тезендә ята.

— Оят булгач нигә эчтең? Хайванга әйләнеп каютада аунап ятканда оят түгел идемени?

Тешен кысудан капитанның яңак мускуллары бүртенеп чыкты. Миңа каршы әйтәсе, сүгенәсе килә. Түзә.

— Бүлек башлыгы Тищенко. Адәм актыгы ул. Пароходчылыкта минем беренче капитан саналуымнан көнләшә. Ул бит миңа эчәргә ярамаганны белә. Кабахәт! Шул аракы аркасында күргән газапларымны сөйли башласам... Гафу ит, Закирыч. Кичер. Ант итеп әйтәм, бусы соңгысы.

— Михаил Александрович, син бит бала-чага түгел. Бу хакта сөйләшкәнебез булды лабаса. Син бит капитан вазифасын, аның җаваплы-

лыгын өстеңә алган кеше. Утыз биш экипаж әгъзасы, аларның хатыннары, балалары. Кораб белән исерек кеше идарә итә. Син бит бер эчүеңдә корабны батырасың. Күпме корбан, күпме ятим ясыйсың тыела алмавыңнан. Кесәңдә партбилет. Соңгы эшеңне мин чарасыз калдыра алмыйм. Бүген ял ит. Кеше кыяфәтенә керергә тырыш. Иртәгә партия җыелышында тәртибеңне тикшерәчәкбез. Бу минем соңгы сүз.

Гремин йөрүеннән туктады. Бүреләрчә, маңгай астыннан миңа карый. Нәфрәт чәчеп торган кан сауган соргылт күзләр. Тешләрен шыкырдатып алды.

— Теләсәң нишлә. Мин синең кулыңда. Ә бит мин сине шәфкатьле кеше дип йөри идем.

Объективлык, үзтәнкыйть турында туктаусыз тукып торабыз. Беркемнең дә ирекле көннән янасы, юкка чыгасы килми. Аңламады мине капитан. Теләсә нишләсен лә!

Каютама кердем. Җыелышта белгертәсе хәбәрне яздым, көн тәртибе билгеләдем. Капитанның персональ эшеннән соң кораб йөртүдә иминлек саклау, йөзү эшендә уяулыкны көчәйтү мәсьәләсен соңгы вакыйгага бәйләп хәл итәргә кирәк иде. Шул турыда карар проектын яздым. Хәзер коммунистлар белән киңәшергә, аларны җыелышка хәзерләргә кирәк иде. Әүвәл партоешма секретаре — өлкән электромеханик Александр Николаевич Давыдов белән сөйләшергә ниятләдем.

Бу эшнең уңышлы тәмамлануына ышаныч әз иде. Пароходчылык башлыгы — партия эшеннән күчерелгән кадр. Диңгезчелекне, диңгездә йөзүнең экономикасын, шартларын начар белә. Пароходчылык белән идарә итү аның беренче ярдәмчесе Королев кулында. Королев исә, капитаныбызның сабакташы һәм иң якын дусты. Һәм, шуңа өстәп, шәһәр комитетының беренче секретаре, өлкә комитетының икенче секретаре — Королевның әшнәләре. Рейстан кайту белән безнең кораб янына пароходчылык башлыгының «шәхси» «Волга»сы килеп туктый да, чит ил портларында торганда агентларны, стивидорларны сыйлау өчен сатып алынган вәкиллек эчемлекләрен, затлы азыкларны капитан каютасыннан алып китә. Пароходчылык башлыгы, үз нәүбәтендә, аларны өлкәдә, Киевтә һәм Мәскәүдә утыручы түрәләргә өләшә. Капитан Гремин тәртибен тикшерү пароходчылыктан башлап, өлкә, республика һәм башкала түрәләренең бакчаларына таш томыру, аларның иминлекләренә кизәнү иде. Алар бит Ждановка килү белән сыйланырга юкка гына безнең корабка килмиләр. Гремин — ышанычларын яулаган, аларга якын кеше.

Давыдов машина бүлегендә иде. Мин аны чакырып электромастерскойга алып кердем.

— Александр Николаевич, капитанның ике тәүлек исереп ятуы сезгә мәгълүм инде. Иртәгә аның персональ эшен партия җыелышына куябыз,— дидем мин.

Давыдов кулын сөртә башлады, учы белән битен каплап, бер тын уйлап торды.

— Бу, Миргазиян Закирович, бик җитди мәсьәлә. Каютагызда кеше юкмы?

— Юк.

— Әйдәгез, шунда кереп сөйләшик. Монда безне тыңлап торулары бар.

Минем каютага кердек. Давыдов әрле-бирле йөри, әллә башларга сүз тапмый, әллә артык дулкынланудан бераз тынычланырга тели.

— Безнең капитан белән Королев арасындагы мөнәсәбәт сезгә мәгълүмме?

— Алар үзара ахирәтләр.

— Сез бит экипаж ялга чыгу белән туры Мәскәүгә кайтып китәсез. Мин монда, Ждановта яшим. Королев пароходчылык башлыгының ярдәмчесе саналса да, чынлыкта Донецк өлкәсендәге, хәтта министрлыктагы җитәкчеләр мафиясенең башлыгы. Сез әле бу экипажда өч кенә

ел эшлисез, ә мин — тугызынчы ел. Тугыз ел эчендә безнең капитан каютасында түрәләрнең кайсылары гына сыйланмады. Гремин югарыда утыручылар өчен чит илдән күпме бүләк кенә алып кайта. Сез бит аны белеп торасыз.

— Мин партоешманың коммунистларына ышанам. Без бит аларны дөрес юлдан алып барабыз. Кырын эш эшләгәнебез юк. Начальствоның безнең пароходка килеп сыйланып йөрүен дә беркетмәгә кертәбез. Бөтенесен фаш итәбез.

— Миргазиян Закирович, сез психология фәнен үзләштергән кеше. Оешманың бер генә партия әгъзасы да Греминга каршы кул күтәрмәячәк. Дөрес, алар сезне дә ихтирам итәләр, хәтта яраталар да, шуңа карамастан, алар капитанга каршы чыкмаячаклар. Менә күрерсез. Капитан түрәләрнең дусты булганлыктан, экипаж иң әйбәт рейсләргә йөри. Иң зур премияләрне безгә биреп торалар. Пароходчылыкта экипажыбызның һәр теләгән үтәп баралар. Без бит аерым исәптә. Әгәр Михаил Александровичны бу экипаждан алсалар, аның урынына кемне куюлары билгеле түгел. Башка капитан экипажга әйбәт рейсләр, премия оештыра алыр дисезмени? Аның нинди кеше булуы да билгеле түгел. Гремин исә, беркемне дә җәберләми. Экипажның туксан тугыз проценты — аның белән унар, унбишәр ел эшләгән диңгезчеләр.

— Персональ эшне барыбер куярга кирәк. Без бит коммунистлар,— дидем мин.— Әгәр парткомда, шәһәр, өлкә комитетында ярдәм таба алмасак, мин Үзәк Комитетка, «Правда» газетасына язам.

Давыдов уйга калды.

— Эшегезне ташларга уйлыйсызмыни? Әгәр алай эшләсәгез, сезне ашаячаклар. Менә күрерсез, сезне ялган бәла ягучы, җәнҗалчы дип бөтен пароходчылыкка гайбәт таратачаклар. Минемчә, иң дөресе, капитанның үзе белән эш итү. Ул сездән куркамы, ихтирам итәме, белмим, күптән күзәтеп йөрим, капитан сезнең сүзегезне тыңлый. Минемчә, аның белән ныклап сөйләшергә, соңгы тапкыр кисәтергә кирәк. Минем киңәш шул, ә калганын үзегез карагыз.

Кичке вахтадан соң өлкән штурман Веденко белән сөйләшергә туры килде. Капитанның персональ эшен җыелышка чыгаруга ул да каршы иде. Әгәр алай эшләсәгез, көлкегә каласыз сез, Миргазиян Закирович, диде ул. Пароходчылыкның мактау тактасында Греминның портреты эленеп тора, әле ел башында гына орден алды, җыелыш, конференция, киңәшмә саен аны мактап, башка капитаннарга үрнәк итеп куялар. Беренче ярдәмче капитан белән ызгышкан да аннан үч ала, дип пароходчылык, партком, бөтен җәмәгать оешмалары сезгә каршы көрәш башлаячаклар.

Гремин каютамнан чыгып киткәндә таң ата башлаган иде инде. Кораб Гибралтар бугазына якынлашып килә. Һава тып-тын. Диңгездә чын штиль. Күкрәк эчендә генә әле һаман давыл басылып житмәгән. Өстәлемдә ак кәгазьгә мин әйткән сүзләрне язган капитанның анты. Антның соңгы җөмләсе: «Мин, капитан Гремин, корабта чакта авызыма бер йотым аракы капсам, беренче ярдәмчем Юнысовка ияреп парткомга барам да кораб йөртергә яраклы булмавым турында үз иркем белән гариза язам». Шул җөмләдән соң дата һәм капитанның имзасы.

Җиңүме бу, җиңелүме? Тәҗрибәсез чакта: «Капитанны җиңдем, мин аңа эчү мөмкинлеге калдырмадым»,— дип куана алыр идем. Вөҗдан миңа нәрсә сөйли: «Җиңелдең син, дускаем. Экипаж әгъзаларының туксан проценты дөреслеккә битараф. Җиңел, файдалы рейс, зуррак эш хакы, премия аларга хакыйкатьтән, әхлак кануннарыннан, вөҗдан сафлыгыннан кыйммәтрәк. Син биргән тәрбия җилгә очты. Бу экипажда син бер тиенлек файда китермичә эш хакы алып яттың».

Экипажның штаттагы боцманы Никита Николаевич Прокопенконың эче авырта башлаган. Озын юлга чыгасы билгеле булу белән берничә кеше авыруга сабышты. Дөрес, ашказаны таза диңгезче сирәк очрый. Тутык тәме килеп торган, тропикларда бозылып сасый торган су, тынгысызлык, төнге авраллар һәм заманыбызның модалы хастасы — стресс ни сәбәптер иң башта диңгезчеләрнең ашказаннарына бәрә. Өлкәнәя башлагач йөрәк авыруы, һәм... чорның иң аяусыз чире — прагматизм.

Боцман Прокопенко капитаныбыз белән егерме елдан артык эшли. Соңгы вакытта сизенүемчә, боцманга ошамаган кешегә безнең капитан нәфрәт белән карый. Боцманга ошамаган кеше экипажыбыздан китәргә мәҗбүр була. Прокопенконың эшкә чыкмавы мине шатландырып җибәрде. Мәшәкать кимеде. Яңа боцманның фамилиясе Савчук, Олег Викторович. Кырык җиденче елда туган. Фоторәсемнән җимерек кашлы, текә тар маңгайлы берәү текәлеп карап тора. Әгәр яңа боцманның бер күзен кара чүпрәк белән томалап куйсаң — ул нәкъ пиратка охшап китәр иде. Бу кешене төшеңдә күрсәң, куркып уянырсың. Кай чагында бандитка охшашлы шушындый җимерек кашлы кешеләр искиткеч ягымлы булып чыга. Мин боцманнан шуны көтәм. Кызганыч, күп вакытта безнең йөзебез — күңелебезнең көзгесе.

Экипажда өч хатын-кыз. Буфетчы Татьяна Карамзина бездә елдан артык эшли. Таняның буе йөз туксан өч сантиметр, юанлыгын әйтмим, кыз кеше бит... Гомумән, үз үлчәмнәрен хатын-кызлар онытырга тырыша. Тән бар бу кызда, гайрәт тә җитәрлек. Таня көлгәндә стенадагы шкафлар селкенеп куя, өстәлдәге савыт-саба палубага коела. Безнең буфетчыдан, аллага шөкер, егетләр шөллиләр. Әгәр Танюша сине ихлас яратып кочып алса, ай-һай, исән чыга алырсыңмы икән аның кочагыннан? Безгә, ир-атларга, хатын-кызның көчсезлеге, йомшаклыгы ошый. Ирләр көче бары тик көчсезлек, икенче төрле әйткәндә хатын-кызга хас йомшаклык, наз белән генә уңышлы берләшә ала. Кем белә, әгәр сәяхәт чиктән тыш озакка сузылса, бәлки Татьянадан да курыкмый башларлар?

Дневальныйга утыз җиде яшь. Ирсез хатын. Баласыз. Брюллов картинасындагы «Төрек хатыны»на охшаган. Кәеф кырылып китте. Бу дөньяда тәрбия эшеннән дә катлаулы, аннан да четерекле һәм рәхимсез эш бармы икән? Авылга кайтып умартачылыкка, я булмаса бакча каравылларга урнашырга. Инде ничә еллар шушы хакта хыялланам, диңгезне һаман ташлап китә алмыйм. Иң зур аянычы шунда — диңгез тормышын ныграк каргаган саен, ул йөрәгеңә, бәгыреңә шул кадәр тирәнрәк кереп оялый.

Ипи пешерүчегә егерме яшь. Инде ике ел диңгездә эшләп өлгергән һәм, билгеле, «диңгезчелек» гыйлемен дә шактый үзләштергән. Әнә, чәчләрен ничек итеп маңгаена төшереп куйган да чәч арасындагы ярыктан ничек карап тора. Тукта әле! Бу бит таныш кыз. «Художник Куинджи» теплоходында ипи пешергән Людмила Ткач. Нәкъ шул. Бердянск шәһәреннән, Бирде елгасы тамагында туып үскән кыз.

Ливиянең Триполи, Көньяк Ямәннең Аден һәм Мукалла портларына барып кайткан идек без ул сәяхәттә. Керчьтә аны каршы алырга уникe яшьлек кече кызын ияртеп Людмиланың әнисе килгән иде. Әнисен сыйларга Люда Ткач өч шешә шампанский сатып алган. Ашарга утырганнар. Чит илләрдән урап кайткан, дөнья күргән кыз әнисе белән сеңлесен сыйларга тотынган. Уникe яшьлек үсмер шампань шәрабеннән баш тарта икән. Әнисе аны үгетләргә керешкән. Үгетли, кыстый торгач, мескенне эчәргә мәҗбүр иткәннәр. Шампанский — затлы эчемлек санала, шуңа карамастан үсмер бала организмы аны кабул итмәгән. Кыз аңын югалткач кына, каютага докторны чакырганнар.

Людмила «Монтана» фирмасы теккән куртка, «банан» чалбар киеп, беләгенә «Сейко» фирмасы ясаган сәгать тагып йөри. Ткачларның кара-

шы буенча, шундый «затлы» киенеп йөргән кыз, билгеле, токмач ашап, компот белән генә яши алмый инде. «Монтана» дәрәҗәсенә күтәрелгән «шәхескә», билгеле, француз одеколоны, шампань шәрабе һәм утырып йөрергә бары тик такси гына фарыз. Ул бит инде хәзер, күпләр шикелле, кара халык түгел. Кызның шәрабкә һәвәсләнүенең психологик тамыры шушында идө. Бәлки инде ул катыракка да күнегә башлагандыр? Людмила Ткачны сәяхәткә алмаска кирәк. Мин шундый фикергә килдем.

Менә тагын бер таныш бәндә: моторчы Николай Иванович Сусликов. Шушы иблис белән мин «Академик Арцимович» корабында эшләдем. Сусликов безнең канга учлап кына түгел, көрәкләп тоз салып торды. Николай Ивановичның «шәхси эш»ендәге үз кулым белән язган характеристиканы укыйм: исең-акылың китәрлек — монда бит бер генә дөрес сүз дә юк. Һәм шушы шыр ялган документны гомер буе дөреслек өчен көрәшәм дип алданып йөргән кеше, үз иркем, үз кулым белән язганмын. Әгәр Сусликов тискәре сыйфатларының йөздән бер генә өлеше шушы характеристикада чагылган булса, хәзер аннан баш тартып, башка моторчыны алырга була иде.

Һәр елны декабрь азагында кадрлар бүлеге бездән характеристика сорап ала. Характеристика язар вакыт житкәч, мин киңәшмә җыйдым. Әле дә хәтеремдә, капитан, партоешма секретаре, өлкән командирлар, халык контроле вәкиле, судком председателе, комсорг — барысы бер тавыштан характеристика объектив булырга, анда һәр уңай һәм кире сыйфат чагылырга тиеш дигән карарга килеп, кул күтәрделәр. Һәм мин, шул карар белән коралланып, характеристикалар язарга керештем. Әле дә хәтерлим, иң авыр, иң эзлексез кеше булгангамы, нәкъ Сусликовтан башладым. Тәҗрибәле моторчы, дип яздым мин, эшли дә, эшләгән булып күз дә буйый белә. Тупас, әхлаксыз, рухи яктан сай һәм дорфа, дидем. Дөрес һәм объектив характеристика килеп чыкты. Характеристикада дүрт имза булырга тиеш, мин туры капитанга юнәлдем.

— Сез нәрсә, әллә акылдан яздыгызмы? — диде капитан Грязевский характеристиканы укып чыккач.

— Соң бит объектив язарга дип карар чыгардык. Сез беренче булып кул күтәрдегез.

— Юк, болай ярамый, Миргазиян Закирович. Дөрес, ул тупас. Дөрес, ул ялганчы, дорфа, икейөзле, нахал. Боларның барысы да дөрес. Шул ук вакытта Сусликовның чит илләрдә йөргәндә үтәлергә тиешле кагыйдәне бозганы булдымы? Юк, булмады. Таможня кодексын? Аны да бозганы булмады. Тәртипсезлекләре күп булды. Аларны санап та бетерерлек түгел, ләкин чын-чыннан җавапка тарттырырлык дәрәҗәдә, күзгә күренеп торырлык итеп боздымы ул тәртипне? Юк. Шуңа күрә, без аңа шелтә дә бирә алмадык, хәтта премиясез дә калдыра алмадык. Юридик яктан ул пыяла кебек чиста, гөнаһсыз. Әгәр сез язган шушы характеристика кадрлар бүлегенә эләксә, әгәр характеристиканың эчтәлеген Сусликов үзе белсә, күрерсез, пароходчылыкның астын өскә китерерлек гауга кубачак. Сез болай акыллы кеше, Миргазиян Закирович, ләкин чиктән тыш беркатлы икәнсез. Галиҗәнап эшчеләр сыйныфы белән без сак кыланырга тиеш. Аңладыгызмы? Акыллы кеше Сусликов шикелле гаугачы белән бәйләнми. Без болай эшлик, язгыз шунда уңай да, кире дә түгел характеристика. Бер сүзенә дә бәйләнә алмаслыкны язгыз. Сусликовтан без башка юл белән котылырбыз. Устав буенча экипажны капитан сайлый. Мин аны корабка алмам һәм шуның белән бетте китте.

Партоешма секретаре, судком председателе, әйтерсең, алдан сүз куешканнар, барысы да капитан киңәшен бирделәр. Кирәкми аның белән гауга куптарырга, үкенерсез соңыннан, диделәр. Мин аларны күпме үгетләп карадым, алар һаман, экипажга тап төшерү, ыгы-зыгы килү була бу, дип сүзләрендә тордылар. Мин башка характеристика язарга мәҗбүр булдым. Тешләремне кысып, сукрана-сукрана Сусликовка тонык кына,



А. Тимергалина рәсеме.

аңа бернинди зыян китермәслек характеристика сырлап ыргыттым. Шушы кәгазьне язганда көндәлектә «олаксана!..» дигән бер уй гына куерып торды һәм эш беткәч, ниндидер җинаятьтән, пычрактан арынган шикелле, иркенләп сулыш алып җибәрдем. Белмим, ни сәбәптер, көндәлек эштә күз буяу оят эш саналмый башлады. Башта безнең белән җитәкчелек итүче зур түрә күз буйый, аңа карап без һәм, безгә карап, бүтәннәр...

Унсигез яңа кешенең «шәхси эш»ләрен карап бетергәч, капитанга чылтыраттым:

— Михаил Александрович, бергә барсак әйбәтрәк булыр, экипажга ике бик начар кеше эләккән, шуларны кадрлар бүлеге башлыгы белән сөйләшеп, алыштырырга кирәк булыр.

Без капитан белән кадрлар бүлегендә утырабыз. Башлык безне мактый:

— Менә шушылай капитан белән беренче ярдәмченең бердәм эшләве ошый миңа. Нинди соравыгыз бар?

— Моторист Сусликов белән ипи пешерүче Людмила Ткачны алыштырырга кирәк. Алар урынына башка кеше билгеләвегезне сорарга килдек,— диде Михаил Александрович.

— Аны элегрәк әйтергә кирәк иде. Хәзер соң инде,— диде бүлек башлыгы.— Без бит Одессага махсус барып, паспортларыгызга Югославия консулының визасын салдыртып кайттык. Аларны алыштырып булмый инде хәзер. Сез киткәнче берничек тә өлгерә алмыйбыз.

Дубровник портында безне кораб көтә иде. Корабның бер тәүлек эшсез торуы җиде мең ярымга төшә, яңа билгеләнгән кешеләрнең паспортларына виза салдыртып кайту өчен ким дигәндә ике тәүлек вакыт кирәк. Кул селтәргә туры килде. Әллә чыннан да тәкъдир дигән нәрсә бар инде бу дөньяда? Сусликовның тагын мин эшләгән экипажга килеп эләгүен башкача ничек аңлатасың?

## Дүртенче тәүлек. Жданов. 11.00

Каштан яфракларының читләре куырылып саргая башлаган чак. Җылымса һавада, кояшта ялтырап, үрмәкүч җепләре йөзә. Үләннәрдән — бал, бакчалардан алма исе аңкый. Көзнең хуш исе шундый көчле, рәхәтлектән баш әйләнеп киткәнне сизәсең. Чат саен чиртсәң ярылып китәргә торган карбызлар саталар. Базарларда кызарып пешкән помидорлар тавы. Кабыклары балавызланып ялтырап торган, ярылып киткән җирләреннән аксыл шикәр күренеп торган, итләч, эре, алсу помидорлар. Тамчы рәвешендәге вак томат сорты, саргылт ананас төре — нинди генә булып үсми бу татлы ашамлык. Ниндидер затлы металлдан коеп эшләнгән төсле көрәнсу-шәмәхә бадымҗаннар. Урам чатларында чиләкләп йөзем җимеше саталар. Карасу шәмәхә шашла, яшькелт гәрәбә төсендәге кызлар бармагы, хуш исле, нәзберек лидия. Йөзем җимеше саткан җирдән узганда авыздан сулар килә.

Таза килеш картайган акыл ияләренчә уйчан, аналарча рәхимле, тымызык иде көзнең бу көне. Чәчәк бәйләменең кәлтәсе утыз тиен. Сигезенче мартта Мәскәү базарларын айкап, юртып чәчәк эзләп йөргән чаклар искә төшеп йөрәкне әрнетә. Ул чакта әрем ботагына охшашлы грузин мимозасының бер чеметеме — мең алтын. Чәчәк аласы килә. Кемне бүләкләргә? Кемгә тапшырырга шушы матурлыкны?

Кышкы хафалар, язгы киеренкелек, җәй китергән әлсерәүләр — хәзер боларның эзе дә калмаган. Бүген әбиләр чуагы — елның иң күркәм, иң моңлы чагы. Күкрәк эчендә җиңелчә ямансулык. Җир шарын кочаклап үбәсе, хуш исле җылы үләнлеккә ятып онытыласы, хыял дөньясына очып китеп югаласы килә. Күз — адәм баласының тырышлыгын, аның түземлеген котлап бирелгән ел фасылы. Күзге муллык, һаваның сабыр рәхәтлеге — җаның ни теләсә шул бар. Тирә-юньдә моңсу акварель төслә-

ре. Җәйге эсселек, шөкер, сүнгән. Коеп явасы көзге яңгырлар, ачы җилләр исәргә иртә әле. Яшә. Рәхәтлән. Рәхимле фасылның кадерен бел, ә без шушындый көндә аерылырга әзерләнәбез.

Алда — озын юл. Аерылышу. Син аңа беркайчан да күнегә алмыйсың. Адәм баласы гаилә җылысында яшәр өчен яралган. Йөрәк шуны белә, күңел шуны аңлый, җан тәкъдиргә каршы баш күтәрә. Дөнья гизү теләге, сукбайлык та бар безнең табигатьтә. Алар бәлки ирек сөюдән, иркенлеккә омтылудан тугандыр? Ләкин бу теләкләр көндәлек тормышның вакчыллыгына гыйсъян, җанга ятмаган мәҗбүри эшкә каршы кузгалган өянәкләр генә. Күкрәгебездә ике төрле тойгы — торгынлык һәм туктаусыз яңалыкка омтылу — үзара туктаусыз көрәшеп тора.

Без — диңгезчеләр. Вазифага тугрылыклы океан сукбайлары. Кирәк-яракны чемоданга ыргытып өйдән чыгып китү, бер кузгалгач, Җир шарын, абзар артыннан әйләнеп кергән шикелле, урап чыгу безгә берни тормый. Даими бер урында яшәү безне арыта гына. Гел бер урында төпләнеп яшәгәндә нидер җитми. Җиргә берегеп утырган таш йортларның, гомер буе бер урында басып торган телеграф баганаларының һәм җиргә ябышып яткан асфальт мәйданнарның хәрәкәтсезлеге бер көнне нигәдер нервага тия башлый. Юк, алай түгел. Бу сүзләрне без күз буяу, аерыласы килмәгәнне яшерер өчен генә уйлап чыгарганбыз. Кузгалып киткән минутта ук гаилә җылысын сагынып җирсенә башлыйсың. Туганнар, дуслар, эшкә ашмый калган өметләр — аларның барысы да ярда, ә син куласа эченә бикләнгән тиен, прожектор чаткысына эләккән куян шикелле, нәрсәдәндер өркеп, һаман алга, билгесезлеккә, каһәрле хәрәкәткә, егылып үлгәнче ирешелмәс ераклыкка омтыласың.

Бу юлы сәфәргә корабсыз чыгабыз. Корабсыз юлга чыгу безгә шундый сәер, хәтта бераз куркыныч та. Ждановтан Донецкигә безне автобус илтә. Донецкидән Киевка поезд белән барабыз. Киевтән Югославия башкаласы Белградка тагын поезд белән, аннары Дубровник портына автобус илтергә тиеш. Анда безне «Алексей Щусев» исемле кораб көтә, дөресрәге — шул корабның экипажы. Ул экипаж, туган илгә кайтмыйча, Көнбатыш Европа һәм Ерак Көнчыгыш портлары арасында тугыз ай ярым эшләгән. Диңгездә шимбә көн дә, якшәмбе дә, бәйрәмнәр дә юк. Атнасына җиде тәүлек, аена утыз көн, көн саен, тәүлек саен эш һәм эш анда. Төннәрен кораб туктап тормый. Төннәрен дә ял юк диңгезчеләргә.

Без алыштырасы экипаж тугыз ай ярым ялсыз эшләгән. Алар арыган. Алар безне ашыктыра. Дөрес, Колумб, Магелланнар заманында диңгез сәяхәте өч-дүрт, кай чакларда хәтта сигезәр елга сузыла торган булган. Өстәвенә җилкәнле корабта эшләү: җилкәннең күләмен үзгәртү өчен риф алу, тырнак астыннан кан саркып чыкканчы чыгыр әйләндерү безнең эштән күп тапкыр авыррак булган. Шуңа карамастан, алар стресс дигән хастаны белмәгәннәр. Беренчедән, океан кичеп «Яңа дөньяга» житкәч, алар атналар, айлар буе кәеф-сафа кылып ял итә һәм, бер тапкыр сәяхәт кылганнан соң, төпләнеп, соңгы көннәренә кадәр бер урында дөнья көтә торган булганнар. План дигән нәрсәне дә, «йөкләмә» сүзен дә белмәгән алар. Ә бездә... Туган портка кайтып төшү белән комиссия артыннан комиссия. Ел саен диярлек имтихан — аттестация, төпченүләр, тикшерүләр. Безнең буын уйлап чыгарган бимазаларны Колумб һәм Магеллан заманындагы диңгезчеләр күз алларына да китерә алмаслар иде. Тормыш катлаулана. Без аны, кирәккә түгел, рәсмилек зәхмәтенә, бюрократия хастасына бирелеп, үз иркебездән катлауландырабыз.

Үз эшемне генә алыйм. Читтән караганда ул чын хезмәткә охшамаган да. Бу вазифадагы вакчыллыклар... Бар эшең дөрес, һәр нәрсә үз урынында. Карамагындагы механизмнар төзек. Кул астында эшләүче диңгезчеләр эчми, тәртип бозмый, устав һәм иксез-чиксез күрсәтмәләр кушканча яшиләр. Укулар, өйрәнүләр уңышлы бара. Экипаж тату. Беркем дәүләт милкенә кулын сузмый. Диңгезчеләрнең күңелләрендә ватандарлык, туган илне сөю, интернационализм һәм тагын әллә ничә мең

рәсми «изм»нар. Иптәш Юнысов тәрбия алып барган экипаж ал да гөл. Ләкин пароходчылыкта утыручы түрәгә акчаны: Миргазиян Закирович, егет син, экипажны дөрес юлдан алып барасың, шулай дәвам ит, дип әйтеп өстәл артында тик утырган өчен түләмиләр. Юк, үзенең түрәлеген аклар өчен, ул сәяхәттән кайтып төшү белән эшеңне тикшерергә килә. Кашын җимереп корабка килеп керә дә: бер мең тугыз йөз фәләненче елның фәләненче аенда Диңгез флоты министрлыгы коллегиясендә расланган әмерне ничек үтисез? — ди. Әйбәт үтибез, дип җавап бирәсең. Юк,— ди ул,— сүзләреңне папкага теркәп киштәгә куя алмыйм. Син миңа гомуми җыелышта расланган планнарны, шул планнарның үтәлешен күрсәткән кәгазьне, җыелыш, утырыш беркетмәләрен, шул беркетмәнең дөреслеген тикшергән халык контроле актын һәм башка, һәм башка нәрсәләрне күрсәт. Син инде ул түрәнең алдына кәгазь тауларын кочаклап өеп куй да тыныч кына тикшерү беткәнен көтеп утыр. Юк, адәм баласының эчке төзелеше шундый, тикшерү вакытында син үлсәң дә тыныч утыра алмыйсың. Һәр тикшерү сиңа егерме-егерме биш процент инфаркт алып килә һәм дүрт-биш тикшерүдән соң инде син Газраил белән очрашырга тулысынча әзер.

Менә бүген дә, диңгезчегә хатыны, балалары белән соңгы тапкыр чүкердәшергә мөмкинлек бирәсе урында, безне кадрлар бүлегенә инструктажга җыялар. Аңлыйм: кадрлар бүлеген бездән дә ешрак тикшереп торалар. Әгәр безнең экипажда ул-бу чыкса һәм тикшерүче кузгалыр алдыннан инструктаж үткәрелмәгәнен ачыкласа, кадровикларның барысына да эләгәчәк.

Сәгать тугыз. Без чакырганны көтеп, ишек алдында таптанып йөрибез. Көлке сүзләр әйткән булабыз. Шаярабыз. Ә күкрәк эчендә нәрсәдер тырмаша. Тынгысызлык, курку инде күптән, Сталин заманында ук, күкрәк эченә кереп оялаган, һәм шуннан баш миенә, нервaларга туктаусыз агу таратып тора.

— «Алексей Щусев»ка алмашка баручы экипаж, сезне иптәш Пархоменко чакыра.

Коридорга кердек. Басынкы гына, башларны ия төшеп, икенче катка мендек. Дерматин белән тышланган ишек каршысында, мәчет картларына охшап, тукталдык. Ишек ачарга беркемнең дә кыюлыгы җитми. Әйе, безнең бит капитаныбыз бар. Ишекне ул ачты. Башлап ул керде һәм башлыкның өстәле каршындагы урындыкка барып утырды. Мин капитан янына урнаштым. Экипажны күзәтәм, һәр кергән кеше начальник өстәленнән ераграк урынны сайлый. Без инде беренче класстан, юк, балалар бакчасыннан ук шул гадәткә өйрәнгәнбез: үзебезгә кирәк чакта — якынрак, түрәләргә кирәк чакта — ераграк урнашырга.

Утыз өч кеше. Экипаж әгъзаларының барысы да килгән — Рәсәй тарихында сирәк очрый торган хәл.

Пархоменконы якыннан белгән кешеләр аны гадел, гади, кешелекле, дип сөйлиләр. Түрәләрдән җылы сүз, орденнар ай-һай сирәк килә. Аның каравы, шелтә, күк күкрәүгә охшашлы боерыклар бик еш. Бәлки шуңа күрәдер, түрә булып утырган кешедән игелек көтмибез. Нинди генә кеше булуына карамастан, ул, иң әүвәл — безнең начальник. Бу турыда гаскәрдә искиткеч даһи бер кагыйдә бар: Син түрә — мин юләр, мин түрә — син юләр.

— Алдан ук искәртеп куям: сәяхәт кыска булмаячак. Эш тә җиңел булыр дип өметләнмәгез. Алты ай узгач алыштырырга тырышырбыз. Ләкин һәр очракта син теләгәнчә булып чыкмый бит, аңларга тиешсез.

— Партиянең соңгы пленумында алай әйтелмәде.

Реплика кыстыручыга күз ташлыйм — Николай Иванович Сусликов. Бәрәңгегә охшаган тупас кызыл борын, бәләкәй кызгылт күзләр һәм гел юешләнеп торган авыз читләре. Әйдә, Сусликов, күрсәт үзеңнең кем икәнлегеңне, дип эчемнән генә аны котыртып торуымны сизеп алдым.

— Алыштырырга тырышырбыз,— ди пароходчылык башлыгы яр-

дәмчесе. Моңа кадәр ул Ливиядә пароходчылыкның вәкиле булып эшләде бугай. Кадрлар эшендә тәҗрибәсе әз әле.— Кабат кисәтәм, эш авыр булачак. Кем баш тарта, яшермичә әйтегез?

Тынлык. Син, иптәш начальник, күп очракта кешене төп башына утырта торган психология атлы нәрсәне белмисең икән әле. Мин баш тартам дип, беркем дә турыдан-туры әйтмәячәк. Аларның үз фикерләре, үз чамалары бар. Авырлык. Нәрсә соң ул? Сиңа авыр күренгән эш, аларга киресенчә, уен шикелле генә тоелуы бар. Алар әйбәтләп ял иткәннәр, өйдә яшәү аларны туйдыра башлаган, шуңа күрә экипаж кая барырга да риза. Сәяхәткә чыкканнан соң өч ай чамасы үткәч, менә шул чакта, сәбәпләр табыла башлаячак. «Капитанга аңлатсагыз әйбәт булыр иде, Миргазиян Закирович. Хатынның эше әйбәттән түгел. Бавыр дигән каһәре интектерә. Аны врачларга күрсәтәсе бар. Миңа ашыгыч алмаш соргагыз...» «Кызым быел унынчыны бетерә. Институтка имтихан биргәндә янында булырга кирәк иде. Хатынның андый эшкә һәвәслеге юк, миңа алмаш чакырыгыз инде, Миргазиян Закирович...» Авырлыктан качу менә шушындый дәлилле сылтаулар артына яшеренеп килә. Ә бу түрә хәзер бугаздан алмакчы, имеш. Шулай да ул бер гаҗәп акыллы гамәл башкарып куйды:

— Менә шушы кәгазьгә фамилияләрегез язылган. «Алексей Щусев»кә аның юлда озак йөрисен белеп барам», дип кул куегыз,— диде начальник ярдәмчесе.

Мин шатланам. Рәхмәт әйтәсем килә яңа башлыкка. Еракка карый белмәгән кешегә кул кую кирәксез бер рәсмилек, бюрократлык сыман гына күренәчәк. Әле аларга диңгез тубыктан. Чайкалудан гарык булып, тропик кояшына ысланудан, сагыну-җирсенүдән тәмам туйгач, аларның сәяхәткә үз теләкләре белән чыгулары онытылачак. Каләм белән язылганны балта белән юнып ташлап та булмый, диләр. Нәкъ менә үзләре теләп чыкканны оныта башлаган чакта мин аларга хәзер сырлаган имзаларын күрсәтермен!

Утыз өч имза кәгазь битендә җәйрәп ята. Адәм баласының язу ысулы, кулы әллә нинди яшерен серләр ача ала. Кәгазь битендә калган берничә сүз кешенең мактанчыкмы-тыйнакмы, шапшакмы-җыйнакмы, киреме-күндәмме, әллә чамадан тыш власть яратучымы — шуларның барысын да сөйләп бирә ала.

Башлык имзалы кәгазьне капитаныбызга тапшырды. Гетеның «Фаусты» искә килеп төште. Җаннарыбызны саттык...

— Тагын нинди сорауларыгыз бар? — диде Пархоменко.

— Борчылмагыз, Денис Петрович, без бит диңгезчеләр. Алты ай нәрсә ул безгә? Үтәр дә китәр,— диде капитан.

— Гражданин начальник, безгә, ватан өчен зур эш башкарырга барган героик морякларга, торгмортранс кибетеннән юлда ашар өчен ризык бирергә тиешләр,— диде моторист Сусликов һәм кузгалып ишеккә таба китүчеләргә аркылы төште.— Кем монда профсоюз эшмәкәре? Нишләп эшчеләр сыйныфы турында кайгыртмыйлар бу экипажда? Тиеш икән — бир сыйныфка!

— Азык-төлек теләсә кайсы кибеттә бар,— диде Пархоменко.— Сез ике тәүлектән Дубровникка барып җитәсез. Ике тәүлеккә ашамлык табу читенмени ул?

— Теләсә кайсы кибеттән алган ашамлык безгә бармый ул, гражданин начальник. Без — диңгезчеләр. Безне торгмортранс кибете тәэмин итәргә тиеш. Ферштейн зи?[1]

— Мин хәзер торгмортранс кибете директорына чылтыратам, ә сез экипажның исемлеген алып барырга онытмагыз,— диде пароходчылык башлыгы ярдәмчесе.— Хәерле юл, кораб килегез астында җиде фут су булсын!

---

[1] Ферштейн зи? (немецчә) — Аңладыгызмы?

«Хушыгыз» диясе урында Сусликов янә өстәде:

— Балык уылдыгы, ысланган колбаса, түрәләр генә ашый торган деликатеслар турында әйтергә онытмагыз, гражданин начальник!

— Фамилиясе кем бу нахалның? — диде капитан баскычтан төшкәндә.

## Дүртенче тәүлек. Жданов. 16.00

Торгмортранс кибете янында диңгезгә чыгасы корабларның баталерлары белән азык-төлек көтеп чиратта торабыз. Чиратта торучыларның яртысы миңа таныш түгел. Күңел түрендәге бәяләү ысулыннан бер гаделсезлек табам: экипажда күптән эшләүчеләрнең барысы да миңа яхшы күренә, яңалар, киресенчә, начарлар. Әллә кимчелекләрен генә эзлим, гел кире якларын гына күрәм. Тагын бер ачыш: экипажда күптән эшләүчеләрне мин «без» сүзенә сыйдырам, яңалар әлегә «алар». Һәр очракта «без» «алар»дан яхшырак, ышанычлырак тоела. Бу инде шулай ук психология.

— Кайдан җыйдың бу байлыкны? — Бакыр подносны хәтерләткән табак битле бер бәндә күршесенең корсагын сыпыра. Зур корсаклы ир өстендә күн тужурка. Җәлпәк биттә елмайганда бөтенләй йомылып бетә торган күзләр.

— Сырт бөгелгәнгә шулай күренә ул, дустым, Ышанмасаң, арт якка чыгып кара.

Икесе дә ихахайлап көләләр. Табак бит күршесенең җилкәсенә учы белән басты, пышылдап, колагына нидер әйтте. Тагын көлеп алдылар.

Боларга рәхәт. Бу ике кеше, билгеле, кайчандыр бер корабта эшләгән һәм, күренеп тора, тату яшәгәннәр. Бу хәл мине бераз куандырып җибәрде. Кадрлар бүлегендә утырганда табак битнең өлкән механик, күн тужурканың икенче механик икәнлеген абайлап алган идем. Болар, аллага шөкер, үзара тату яшәячәк. Их, шундыйлар күбрәк булсачы! Үзара кайгы-хәсрәтләрне, шатлыкларны бүлешеп яшәүгә ни җитә. Иминлек татулыктан туа. Курыкканым — ызгыш, аннан да начары — битарафлык. Битарафлык рухсызлыктан, вөҗдан юкка чыгудан килә. Җинаятьләрнең күбесе битарафлык туфрагыннан шытып чыга. Нилектән бөтен кеше дә бай рухлы, изге ниятле, иманлы була алмый икән? Комсызлык, хәйләкәрлек, икейөзлелек каян туа? Ни сәбәп аларны бетереп булмый икән?

Әнә «Академик Арцимович» корабында экипажны болгатып, тынгысызлык тудырып торган Сусликов бизнес ясап азаплана. Ул бер пачка крекерны казылыкка алыштырды. Крекерның килосы бер сум егерме тиен, казылыкныкы сигез сум тирәсе. Әйтерсең, ул ат хәтле алтын отты, шундый шат, шундый канәгать киләчәктә бергә яшисе юлдашын алдый алуына. Оттырган егетнең фамилиясе Петлюга. Бу мескенгә, һичшиксез, Украинаның мәшһүр атаманы исемен тагачаклар. Корабта, авыл жирендәгечә, кешегә кушамат тагу гадәте яшәп килә. «Академик Арцимович»та Сусликовның кушаматы «Кәҗә тәкәсе» иде. Гадәттә, халык биргән кушамат — экипажны мин халыкка саныйм — һәр очракта тапкыр була. Бер көнне Сусликовтан:

— Нигә сине «Кәҗә тәкәсе» дип йөртәләр? — дип сорадым.

— Помполит, имеш, үзең шундый гади нәрсәне дә белмисең. Корабка сарык төягәндә алдан кәҗә тәкәсен кертәләр. Аңгыра сарыклар шул тәкәгә ияреп керә. Мал суя торган бойняга да сарыкларны кәҗә тәкәсенә ияртеп кертәләр ди. Экипаж да, сарык шикелле, гел миңа ияреп йөри. Теләгәндә мин чыгып китәм, алар эләгеп кала.

Чыннан да, һәр тәртип бозуның, һәр вак-төяк җинаятьчел эшнең башында Сусликов торганы соңыннан мәгълүм була иде. Тикшергәндә ул ничектер һәрвакыт читтә кала, судан коры чыга белә иде.

Менә бүген Сусликов аркасында һәр дингезче ике кило казылык, бер кило сыр, ике пачка крекер һәм дүрт банка ит консервасы күтәреп торгмортранс кибетеннән кайта. Николай Ивановичны белмәүчеләр аны күкләргә чөеп мактый. Юлга ашамлык төяп йөрү — кытлык еллар мирасы. Хәзер бит инде интегеп капчык күтәреп йөргәнче янчыкка берничә сум акча салып кына чыгарга да була. Кытлык еллар мирасы безне җибәрми, һаман тота, һаман аркага капчык асып йөрергә мәҗбүр итә.

## Дүрт тәүлек элек. Мәскәү. Язучылар йорты. 19.30

Бу шагыйрәнең фамилиясе — татарныкы. Ә үзен кем белә, хәзер бер милләткә дә туры килми торган тарихи бердәмлек мираслары күп ич хәзер. Шагыйрә сәхнәдән шигырь укый. Ботларын кысып торган, теге 1812 елгы Ватан сугышы офицерлары киеп йөргән тыгыз рейтуз. Аягында елкылдап торган лаклы кара күн ботфорд. Җилкәсенә затлы пончо салган. Ул шагыйрә һәрчак кешене аяктан егарлык экстра яңа киемнәр кия. Бүген Язучылар йортында аның иҗат кичәсе. Ясалма нәзберек хәрәкәт, һәр сүзен сузып, бераз ыңгырашып, елаган шикелле итеп әйтә:

— Бү-үген, минем кичә-ә-әмне Була-а-ат Окуджа-а-ава алы-ы-ып бары-ы-рга тиеш иде-е-е. Була-а-т авыры-ы-ып китте. Ул больницада ята-а-а...

Белла Ахмадуллинаны тыңлаганда, ул бер вакыт тотар да шигырьләрен татарча укып китәр шикелле тоела.

Шашынып кул чабалар. Тыңлаучыларга татарларның кыргыйлыгын, алардагы «азиатлык рухын» сурәтләгән шигырьләрне татар фамилияле хатынның укуы ошый. Без үзебез дә ерак бабаларыбыз турында шыр надан, рабфактан соң докторлык диссертациясе яклаган Панкратова дәреслегеннән беләбез. Әллә ялкаулыгыбыз көчле, әллә шул безне кыргый итеп күрсәткән суррогат тарихны ятлау файдалырак? Бәлки куркаклыгыбыз, «тотса мәскәүләр якаң» дигән искәртү шулай үз тарихыбызга битараф булырга өйрәтә торгандыр? Хакыйкать юлы җиңел түгел бит ул. Каныбызда Иван Грозный зәхмәте, чукындыру шомы, культ шаукымы һаман яшәп, безгә һаман тәэсир итеп килә. Әнә залда шигырь тыңлап утыручы, үзләрен культуралы санап йөрүчеләргә мәчетне хатын-кыз боты белән чагыштыру кыргый наданлык булып тоелмый.

Кичә тәмамланды. Халык гардеробка ургылды. Шигырь тыңлаганда шундый зыялы, әдәпле күренгән кешеләр киемнәрен алырга элдерткәндә танымаслык булып үзгәрделәр. Фойегә чыгучылар арасыннан якташларымны эзлим. Язучылар йортына еш кына Гәрәй Рәхим килә. Сирәк кенә булса да монда мин Талха Гыйниятуллинны очратам. Җыелыш вакытында президиумда утыручы Вил Ганиев, Михаил Львовны күрергә була. Мәскәүдә дүрт елга бер тапкыр кинофестиваль уздырыла. Фестивальгә абонемент саткан чакларда начальниклардан тыш Мәскәүдә яшәүче барлык язучыларны күрергә мөмкин. Галия Хантимерова, Равил Бохараев, Илгиз Кәримов, Нурия Измайлова, Роза Хөснетдинованы, тагын әллә кемнәрне очратам мин андый көннәрдә. Бер-беребезгә сәлам бирәбез, якты йөз күрсәтәбез, билгеле. Ләкин, ни сәбәптер, якташлар белән озак сөйләшеп торырга көч җитми. Араданиндидер киеренкелек барлыкка килә һәм тизрәк аерылырга тырышасың. Яһүдләргә, әрмәннәргә карагыз Алар бер очрашса, аерыла алмыйлар. Бер ана балалары шикелле гөрләшеп яшиләр. Ә нигә юк безнең арада бердәмлек? Без нигә үзара уртак тел, уртак сөйкемлелек таба алмыйбыз?

Герцен урамына чыгып, бишенче троллейбуска утырам. Колакта һаман шигырь тавышы. Хәтергә бернинди бәйләнешсез «Во поле березонька стояла...» җырының авторы шагыйрь Ибраһимов килеп төште. Университетта без ул җырны рус халкыныкы дип өйрәнгән идек. Революциягә кадәр яшәгән рус шагыйрьләре антологиясендә ул җыр Ибраһимов-

ныкы икәнлеге күрсәтелгән. Шагыйрьнең үзен беркем белми, ә җыр яши. Ибраһимовның кем икәнлеген белергә теләп, мин шагыйрьләрдән сорашты, шагыйрьләргә багышланган барлык белешмәләрне, бар булган энциклопедияләрне карап чыктым. Шагыйрь Ибраһимов турында бер авыз сүз, бер тамчы хәбәр таба алмадым. Ә җыры яши. Шиһабетдин Мәрҗаниннең дә мирасы яши. Аның турында төрекләр, инглизләр, гарәпләр, французлар белә, ә без белмибез һәм белергә дә теләмибез. Белмәү битарафлык тудыра, ә битараф тәвә кошы шикелле, башыңны комга яшереп яшәү шундый тыныч, шундый рәхәт ул.

## Бишенче тәүлек. Жданов — Донецк арасындагы юл. 09.00

Бу шәһәрнең Диңгез буе райкомы бинасыннан сулдарак бер матур, тыныч мәйданчыгы бар. Мәйданны тирә-яктан бөдрә таллар урап алган. Каршыда, яр битендә, курорт зонасы. Аннан ары диңгез. Уң якта порт, порттан өстәрәк кадрлар бүлеге. Мәйданчыктан сул якка, шәһәр үзәгенә таба Нахимов проспекты сузыла.

Шул мәйдан уртасында безне Донецкигә илтәсе сары «Икарус» көтеп тора. Мәйданчык тулы кеше: экипажны озатырга килгән хатын-кыз, бала-чага, дуслар, туган-тумачалар. Мондый урынга, билгеле, үзен кая куярга белмичә, гайбәт сүз, тамашалы күренеш эзләп йөрүчеләр килми чә калмый. Алар да бар иде райком янындагы тыныч мәйданчыкта. Билгеле, җәмгыять эше белән шөгыльләнүче, профсоюз, остазчылык вәкилләре дә бар иде.

Уйчан сөйләшүләр. Елыйсы килгәнне басу өчен моңсу гына елмаюлар. Мондый вакытларда шаталак, кыйбласыз кешеләр дә кинәт җитдиләнеп, гомер буе акыл белән яшәгән затка охшап китәләр. Аяусыз киеренкелек. Озатышу озакка сузылган чакларда, бигрәк тә вокзалда, минем нервыларым чыдый алмыйча, өзгәләнә башлар кебек тоела. Сөйләшер сүз сөйләшенгән, әйтәсе киңәшләр әйтелгән. Ә поезд, ниндидер каһәрле битарафлык белән һаман тора, һаман кузгалырга теләми. Киеренкелек һаман көчәя, көтеп тору кайнар таш булып бәгырьләреңне пешерә башлый.

Мин инде озатышу газабын үзган кеше идем. Хәлем башкаларныкыннан җиңелрәк иде. Юлдашларымның муеннарына балалары асылынган. Хатыннары аларга шул кадәр тыгыз сырышканнар. Беләм бит, экипажда эт белән мәче шикелле торучылар да бар, нигә яшерергә? Алар да бүген ирләрен өзелеп ярата, алар да шушы мизгелдә ирләре өчен әһ тә итмичә үләргә әзер. Бәлки кирәктер хатының, балаларың белән аерылышу? Тансыклык тойгысы уяту, сагыну, пакьләнү өчен? Юк, кирәкми, ничек кенә булса да бергә-бергә, аерылышмыйча, бер-береңне ташлап китмичә яшәү яхшы. Аккошлар, кыр казлары ялгыз яши алмыйлар. Ирен югалткан ана аккош, хатынын югалткан кыр казы биеклеккә, болытлар өстенә менә дә таш булып җиргә төшеп бәрелә. Ә без аерылабыз. Таугa куптарып, кара гайбәт таратып, суд аша...

Мин ялгыз. Мине озатучы юк. Шушы турыда уйлый гына башлаган идем, бөдрә таллар артыннан Виталий Федорович Веденко килеп чыкты. Хатыны Анна Емельяновнаны култыклап килә. Икесе дә елмаялар.

—Без менә, Миргазиян Закирович, Аннушка белән сезне озын юлга озатырга килдек. Якындагы хәбәрне еракта ишетәсең бит аны. Кичә кич Рәисә Гаязовна Мәскәүдән чылтыратып әйтте.

Анна Емельяновнаның кулында зур төргәк. Елмаябыз. Ниндидер ямансу, үкенүгә охшашлы шатлык. Веденко моңа кадәр безнең экипажның өлкән штурманы иде. Бүгенге көндә сирәк очрый торган Колумбларга, Джозеф Конрад, Дрейк, әл-Мәҗитләргә охшашлы классик дин-

гезче ул. Укыган китапларның эчтәлеге турында серләшерлек, экипажда Виктор Конецкийга, Андрей Битовка гашыйк бердәнбер диңгезче иде. Алар капитан белән уртак тел таба алмадылар. Көндәлек эштә хәбәрдарлык,— билгеле, кирәк нәрсә. Ләкин чиктән тыш хәбәрдар булу өстәрәк утырган түрәнең котын ала. Виталий белән дә нәкъ шул хәл булды. Өстәвенә ул чиктән тыш туры әйтергә ярата торган кеше иде. Безнең капитан да сүз ара сүз чыкканда, мин туры әйтүчеләрне яратам, дип ант итә. Чын тормышта дөреслекне яраткан кешеләр дә туры әйтүчеләр белән эшли алмыйлар икән... Хәерле булсын инде. Бу сәяхәткә өлкән штурман булып капитан үзе тәрбияләгән кораб йөртүче Василевский бара. Нинди бәндә булып чыгар? Ә мин Виталийны оныта алмыйча газапланырмын әле. Их, чын дуслык...

Дусларның озатырга килүе зур куаныч икән. Бу куанычны мин Казанга барган саен татып кайтам. Шушы татлы тойгы йөрәктә озак яши һәм яшәүнең катлаулы чакларында авырлыкларны җиңәргә ярдәм итә.

— Диңгездә вакыт көнләп түгел, айлап үтә бит ул,— дип мине юатырга тырыша Виталий Федорович. Без аның белән күпме бәхәсләштек, күпме бәрелештек, ләкин якалашулар безне аермады, киресенчә, һаман якынайтты, һаман туганлаштырды. Ә бит кайбер кеше белән бәләкәй генә ызгыш та сине әллә кайларга ыргытып ташлый. Шуннан соң ул кешене төшендә дә күрергә теләмисең, очратканда әллә кайдан урап үтәсең. Адәм баласының мөнәсәбәтләре шундый четерекле, шундый катлаулы.

Веденко белән сөйләшеп торганда кемдер минем терсәгемнән тотып алды. Владимир Усманович Кырымчак икән. Без аның белән агачтан сыннар ясый идек. Уртак мавыгу, уртак язмыш якынайтты безне. Кырымчак паспорты буенча рус булып йөри. Әнисе һәм әтисе — кырым татарлары.

Тагын бер таныш кеше килеп кулымны кысты. Бусы — Виктор Иванович Кожушко, Украина компартиясенең Үзәк Комитетында сектор мөдире булып эшләүче зур җитәкче. Ул пароходчылыкны һәм Жданов шәһәр комитетын тикшерергә килгән икән. Моннан егерме биш ел элек «Чолым» пароходында Кожушко матрос булып эшләде. Домино уйнарга ярата иде. Ул чакта тәҗрибә шактый чамалы булган күрәсең, мин ул егетне якасыннан тотып доминодан аера идем дә каютасына сөйрәп кертә идем. Шундый тупас, антипедагогик юл белән мин аны читтән торып институт тәмамларга мәҗбүр иттем. Егерме биш елдан соң минем тупаслык Кожушкога игелек булып тоела башлаган, күрәсең, пароходчылыкка килгән саен минем турыда белешә дип сөйлиләр. Үзе миңа очраган саен рәхмәт әйтә. Югары, җаваплы урында диңгезчелекнең ачысын-төчесен татыган, вакытында бозлы палубада аркан сөйрәгән кешенең утыруы үзе бер куаныч. Их, шундыйлар күбрәк булса икән!

Озатучыларның ак теләкләре диңгезгә чыккач бик тә кирәк булачак. Алар алып килгән изге хисләр безгә ияреп китеп, күңелдә озак сакланачак. Игелек күрсәтә алу үзе нинди куаныч, аннан соң шул игелек кире әйләнеп кайтып сине кабат куандыра.

Шофер сигнал бирде. Балалар елавы кинәт көчәеп китте. Хатыннар ирләрен кочакларыннан ычкындырмыйлар.

— Кузгалырга вакыт,— диде капитан һәм үзенең корыч хатыны Инна Ивановнаны соңгы тапкыр кочаклады да автобуска кереп утырды. Без дә берәмләп керә башладык. Ниһаять, ишек ябылды. Сау бул, Жданов! Искә яшь чакта җырлаган җыр килеп төште:

Әдрән диңгез, зәңгәр диңгез, ай зәңгәр диңгез.
Култыклары йөз дә сигез, ай, йөз дә сигез...

Автобус Нахимов проспектына чыкты. Бөдрә таллар, кул болгаучы хатыннар, куллары белән күзләрен угалаучы сабый балалар — хәзер алар саташу шикелле генә булып, күз алдында сурәтләнеп калдылар. Моннан бер генә минут каршында басып торган кеше белән хәзер бары

тик телефон чылтыратып, яисә хат, я булмаса радиограмма аша гына сөйләшеп була. Ара һаман ерагая. Аерылышу мизгелен бушлык каплый башлады. Вакыт үткән саен бушлык калыная.

Бары тик җыр гына күпмедер аңлата ала иде безнең халәтне.

## Алтынчы тәүлек. Киев каласы. 08.40

Мөсәгыйть Хәбибуллин Киевне «Кияүкала» дип атый романында.

Мондый мәһабәт, иркен вокзал Мәскәүдә бармы икән? Мин белгән иң зурысы — Казан вокзалы. Аны төрле яктан биек-биек биналар чорнап алгангамы, күләмен чамалый алмыйм. Казан вокзалы ул Мәскәүнең башка урынына һич охшамаган үзе бер дөнья. Аның носильщиклары гына да ни тора! Бәләкәй тәгәрмәчле тимер арба белән чемоданнарыңны ташып йөрүче агай-эне, якты дөнья белән саубуллашканда, башкала мәчетенә йөзәр меңне васыять итеп калдыра. Казан вокзалында минә нинди шәхесләр эшли!

Донецк поезды белән Киев вокзалына килеп төшкәч, чемоданнарыбызны саклау камерасына тапшырдык. Мәскәү-Белград поезды төнге икедә килә. Унсигез сәгать вакытны без кайда булса да уздырырга тиеш идек. Ял итәселәре, бераз йоклап аласылары килсә дип, мин Елга флоты профсоюзы аша «Парус» исемле пансионатта утыз өч урын броньлап куйган идем. Экипажга шул турыда белгерттем.

— Башта, әйдәгез, Киевнең музейларын карап чыгыйк. Мондый мөмкинлектән файдаланып калырга кирәк,— дидем мин.— Ял итәсе килә башлагач, «Парус» пансионатына барып, бераз ятып алырбыз.

Диңгезчеләрнең күз карашларына, аларның сәер итеп муен кашып торуларына минә нинди мәгънә язылган иде: без, иптәш беренче ярдәмче, культурага каршы түгел, ләкин музейларың качмас. Безгә культураның югарырак сыйфатлысы — сыра, шашлык, чибәркәйләр белән әңгәмә, шундыйрак нәрсәләр хушрак. Тәкъдимемне алкышлаучы табылмады, һәм мин аның шулай буласын белә идем. Безнең этиләр халыкны рухи яктан баету, культуралы итү максаты белән революция ясадылар. Алар чын культураның Валентин Пикуль әсәрләре, Алла Пугачева җырлары, пиджак зыялылыгы белән чикләнер дип уйламаганнар, билгеле.

— Минем монда э-э-э, апам яши. Мөмкин булса, мин шуларга кунакка барыр идем,— диде дүртенче механик Вадим Лунгин.

— Минем дә Киевтә бертуган апам бар,— диде доктор Алексей Теунов. Моторчы Саша Чумак белән матрос Николай Дулевның да апалары Украина башкаласында яши, имеш. Их, дип уфтанып куйдым мин, яшьрәк булсам, минем апам да шушы матур шәһәрдә яшәр иде!

Шулай итеп, дүрт буйдактан колак кактым. Буйдак кешенең апасы кайда яшәмәс. Бусы табигый хәл. Әле капитаныбызның да сеңлесе Киевтә тора, имеш. Бу турыда Инна Ивановна беләме икән? дип уйладым мин һәм исемә төште: автобуска утырыр алдыннан гына капитанның корыч хатыны хәләл җефетенә, «Киевтә сеңеленә кертеп бирергә оныт-ма», дип бер төргәк тоттырды. Андый хатын белән яшәгән кеше сулга да, уңга да тайпыла алмый. Андый хатынга юлыккан кешенең яшәвендә бары тик бер маршрут — туры юлдан бару гына кала.

Экипажның өч чибәре Киевнең кибетләренә культпоход оештыра башлады. Хатын-кыз теләгенә алла үзе дә буйсына, ди француз әйтеме. Әйбер хатын-кызның үзенә генә түгел, аның күзенә дә кирәк.

Өлкән механик Горбаненко, диңгезчеләр телендә «бабай», «апасыз» кеше иде булса кирәк. Ул экипаж әгъзалары арасында агитпроп эшен башлап җибәрде.

— Сез, ахмаклар, юлга буш кул белән чыгарга уйлыйсызмыни? Ерак юлга сало алмыйча чыгу мунчага мунчаласыз барудан да ялгышрак. Дуңгыз маенда башка бернинди ашамлыкта юк махсус фермент

була. Шул фермент кешене арып-алҗудан, хәл бетүдән саклый. Сынап караганым бар — атнасына ике-өч тапкыр дуңгыз мае ашасаң, сагынуга да, җирсенүгә дә, ялгызлыкка да чыдап була. Киттек базарга дуңгыз мае алырга.

— Кемне тыңларга да белгән юк,— диде моторчы Сусликов.— Берсе музейга, маймылның кешегә әйләнгәнен карарга, икенчесе дуңгыз мае алырга кыстый. Гади совет кешесенә беркайчан да тынгы бирмиләр, әйдә дә әйдә! Кайда соң ул газеталарда язылган кеше хокуклары?

Киевкә килеп җиткәнче үк экипаж әгъзалары үзара укмаша башладылар. Күптән күзәтеп йөрим: башта үзара уртак тел, уртак мавыгу аркасында ике кешедән торган иң кечкенә төркем барлыкка килә. Мондый төркем, минемчә, иң бердәм, иң көчлесе. Мондый төркемнән сер чыкмый һәм, иң җаваплы, куркыныч, яисә иң җинаятьчел эшләр шушындый берәмлекнең кулыннан килә. Мин юрист түгел, шуңа карамастан, ике кеше эшләгән җинаятьне ачуы өч-дүрт кеше катнашкан җинаятьне фаш итүдән катлаулырак булырга тиеш, дип уйлыйм. Ике кешедән торган берәмлекнең бер кимчелеге бар — аңа информация җитенкерәми, шунлыктан алар өченче кеше эзли башлыйлар. Өч кешедән торган төркем көчле була, ләкин монда сер саклавы читенрәк. Дүрт кешедән торган берәмлектә капма-каршылыклар, бүлешүләр була башлый, шунлыктан ул тиздән таркала.

Коллективны яхшылап оештыру өчен шушындый вак төркемнәрдән торган берәмлекләрнең лидерларын үзара берләштерергә кирәк. Әгәр алар үзара уртак тел таба алсалар, экипаж бердәм һәм көчле була. Безнең йөз илле кешедән торган коллектив шундый бердәм, дип мактанучыга ышанмыйм мин.

— Мариманнар, мин сезгә бер бик кыйммәтле киңәш бирергә телим,— ди моторчы Сусликов.— Бушлай бирәм. Сезне яратканга күрә. Мин карун түгел, иң кыйммәтле фикерләремне дә коллектив белән бүлешәм. Беренче ярдәмче сезне музейга иске чабаталар карарга өнди, «бабай» базарга. Әйдәгез, мариманнар, җыелып сыра эчәргә барабыз. Ирләр эчемлеге ул. Сырада ир-егетлекне көчәйтә торган ферментлар бар. Иң әйбәт, иң акыллы сүзләрне сыра эчеп утырганда гына ишетәсең.

Сусликовның тәкъдимен беркем хупламады. Ни сәбәптер, әлегә аны урап узалар иде.

— Син, Миргазиян Закирович, менә бу горлопанга аеруча күз-колак бул. Ишеттеңме, ул экипажны сыра эчәргә кыстый. Сыра бит ул сылтау гына. Авызлары бер тисә, алар катыракка күчәчәк.

— Ишеттегезме? — диде Сусликов, каты җәбергә юлыккан кеше кыяфәтенә кереп.— Әле эшли дә башламаган, капитан инде тырнак астымнан кер эзли. Туры сөйләгәнгә яратмыйлар сине, Николай Иванович. Син, иптәш Сусликов, ялагайлана, начальствога яраша белмисең.

— Демагог,— диде капитан тәмам кызып китеп.— Әле рейс башланып та җитмәгән, бу разгильдяй үзенең кем икәнлеген күрсәтеп тә өлгерде инде.

— Аңа аудитория кирәк. Сез аңа бернинди әһәмият бирмәгез,— дидем мин капитанга. Михаил Александрович кулын селтәде дә Киевтә яшәүче сеңлесенә юл тотты.

Сусликов белән сүз көрәштереп, базар ясап азапланган арада экипаж әгъзалары юкка да чыгып куйды. Перронда без дүртәү калганбыз. Сусликовтан тыш аш пешерүче Тимофей Иванович Белов, дустым һәм яшьтәшем, матрос Степан Васильевич Петров — Ватан сугышы ветераны, утыз елдан артык өлкән рулевой булып эшләгән Чистай керәшене.

Безнең белән ботка пешереп булмаганны аңлагач, Сусликов та каядыр китеп олакты. Без өчәү калдык.

Узган ел Җиңү бәйрәмендә шушы ике ветеранны каютама кунакка чакырдым. Икесе дә карыша башладылар. Ничек инде ул безне башкалардан аерырга? Соң бит, башкалар сугышта катнашмаганнар, дим.—

Ул башкаларны санга сукмау булмасмы соң?— диде якташым Петров.
— Ничек инде башкаларны? Кайчакта үзең турында уйлау да зыян итми ул. Сез күзәтмисезмени, яшь буын вәкилләре үз-үзен кайгыртуны шактый алга куя, дим. Без андыйга өйрәнмәгәнбез, диләр.

Шул Җиңү бәйрәме көнне мин шушы ике дустыма ничектер бөтенләй яңача карый башладым.

Тимофей Ивановичның ял иткәнен, эшсез утырганын бер тапкыр да күргәнем юк минем. Инде егерме ике ел беләм һәм ул шул егерме ике ел эчендә үз теләге, үз кирәге, кыскасы, үзе өчен бармак кыймылдатканын да күргәнем булмады. Кайдан туа икән адәм баласында мондый сыйфат? Башка кеше, синң ничек кенә якын булмасын — барыбер чит кеше. Ул барыбер син түгел, аның бар җире аерым: теләкләре, тәне, тойгылары. Тимофейда исә мин-минлекнең, эгоизмның мыскалы, бер гена атомы да юк шикелле. Эшләве дә, яшәве дә башкалар — экипаж, семьясы, җәмгыять һәм ватаны өчен аның. Һәм тагын, мин ватан өчен жанымны бирергә риза дип, күкрәгенә суга-суга ватан милкен кимерүчеләрдән Тимофей шул ягы белән аерыла — ул үзенең башкалар өчен эшләгәнен белми. Бәлки нәкъ шушындый кешеләр аркасында без ипи ашыйм, кием кия, бәлки нәкъ шушындый кешеләр аркасында җылы йортларда яши торганбыздыр?

Кок Тимофей Белов сәгать биштә йокыдан тора, киенә, палубага чыгып, ашыкмыйча гына челем көйрәтә. Бу аның көн озынлыгына тиешле бердәнбер ялы һәм үз мәнфәгатенә тотылган вакыты. Шушы унбиш минут эчендә Тимофей уйлый. Аның нәрсә уйлавын белсә, алла белә торгандыр. Үзе турында, нәрсә теләгәнен, нәрсә кирәклеген сөйләргә аның хәзинәсендә сүз юк. Белми ул «мин», «миңа», «минем өчен» дигән сүзләрне.

Челемнән соң камбузга кереп, Тимофей электроплитканы кабыза һәм шушы керүеннән ул бары тик сәгать кичке тугызынчы яртыда, эш һәм ашау тәмамлангач, кино карар вакыт җиткәч кенә чыга. Көне буе ул нәрсәдер әрчи, чистарта, турый, бүлә, камыр баса, пычак үткенли, кыздыра, кайната, пешерә һәм амбразурага ташый.

Сәгать иртәнге унда матрослар, эшләрен ташлап, койрыкка җыелалар. Матросларга машина бүлегеннән чыккан моторчылар, токарь кушыла. Тәнәфес вакыты бу, тәмәке көйрәткән чак. Шул чакта кулына авыр корыч таба күтәреп диңгезчеләр янына Тимофей килә. Табада я сызык, яисә кимерергә әзерләнгән сөякләр. Кайчакта тавык муеннары, бүтәкәләр була. Төтенгә тыгылып ләчтит сатып утыручы диңгезчеләр алдына табаны бер сүзсез илтеп утырта:

— Тозы җиңел булмадымы икән?

Тимофей пешергән ашның тозы җиңел булмый. Бу турыда бөтен флот белә. Матрослар көне буе саф һавада авыр эш башкара, моторчының эше дә искиткеч авыр. Аларның күбесе яшь, үсәләр, калориягә мохтаҗлар. Американлылар диңгездә эшләүчеләрне унбиш сумга ашаталар, Чехословакия корабларында гына да көнлек рационга биш сум илле тиен түлиләр, ә безгә тамак туйдыру өчен Диңгезчелек министрлыгы тәүлегенә бер сум житмеш дүрт тиен түли. Корабта Тимофей Белов шикелле кок эшләгәндә шулай да тамак тук була. Белмим, аның сере нәрсәдәдер? Ул бит, югыйсә, үз акчасына сатып алып кумәк казанга өстәмә ит сала алмый инде.

Тимофей Ивановичның гаилә тормышын күзәтүчеләр аның ял вакытында да аш пешереп, семьясын ашатып, базардан азык-төлек ташып, хәтта идән юу эшенә кадәр үзе башкарганын әйттеләр. Мин сүз ара сүз чыккач Тимофейга ял вакытында санаторийга, ял йортына барырга киңәш бирдем. Кокның хәтере калды.

— Соң бит,— диде ул,— мин диңгездә чакта ашны хатын пешерә, ял вакытында мин пешерәм. Ул эш бездә урталай бүленгән.

Африка, Азия континентларында безгә ачлар очрый. Ач кеше күргән

көнне Тимофей Белов бәхетсез. Ул көнне кокның тамагына аш үтми, төннәрен йоклый алмый интегә. Андый чакларда Тимофей Иванович минем янга кереп сөйли: «Җир йөзендә бәрәңге, кәбестә утыртырлык күпме буш җир бар. Ә балык? Диңгезләрдә, күлләрдә күпме балык үрчетергә була. Миң бит аш пешерүче, мин беләм, дүрт миллиард ярым кеше туйдырырлык ашамлык бар җир йөзендә. Бар ул. Бераүләрнең комсызлыгы аркасында икенчеләр ачтан үлә».

Без «Алексей Щусев»ны кабул итеп алгач, туры Һиндстанга юл тотарга тиешбез, ә анда ач яшәүчеләр күп. Кайчакта мин Тимофей камбуздагы иң зур пычакны алып, ачлыкка каршы атакага ташланыр дип курка башлыйм.

Матрос Петровның керәшен татары икәнлеген миннән башка беркем белми. Аның паспортында милләте рус дип язылган. Чын русның русча акцент белән сөйләшүе күпләрне хәйран калдыра. Гомумән, Степан башка планетада туып, шунда тәрбияләнгән кешегә охшаган. Күзаллавы башка, гадәтләре башка һәм аның фикер йөртүе дә безнекенә охшамаган. Мәсәлән, безнең арада малга, данга, өстенлеккә һәм игътибарга битараф кеше булмый диярлек. Безгә һәрвакыт нәрсәдер җитми, нидер кирәк. Степан Васильевичка берни кирәкми. Ул белә, әгәр эшләп алган акчасын өйгә кайтармаса, хатыны гауга куптарачак. Ә аның үзенә акча бөтенләй кирәк түгел. Бар ул акча дигән нәрсәгә чүп итеп караучылар! Хәтта шундый кешеләр дә валютаны кулларына алу белән кара саранга әйләнеп китә. Ә Петров валютага да төкерә. Акча түләү йоласы, менә мин күпме акча чыгарып сала алам, димәк, мин шәхес, дип горурлану бөтенләйгә ят һәм таныш түгел Степанга. Түләсәләр дә, бер тиен түләмәсәләр дә эшләр иде Степан Петров. Өстәвенә бушлай булганда да эшен шулай ук яхшы, башкаларга үрнәк булырлык башкарыр иде.

Порттан чыккан чакта, куркыныч фарватердан барганда, бугазлар аша үткәндә рульгә Степанны куялар. Нинди генә тәҗрибәле булмасын, капитан Гремин кайчакта Босфорны узганда бер-ике градуска я сулгарак ала, янсә — киресенчә — тиешледән уңгарак. Борыласы урында берничә секундка алданрак, я булмаса, соңга калыбрак борылган чаклары була. Андый кечкенә үзгәлек, билгеле, кагыйдәне бозмый һәм корабның иминлегенә зыян китерми. Андый ялгышуларны Степан Васильевич кына кичерә алмый. Бу чакларда аңа кыенлык туа: капитанның командасын катгый үтәргә тиеш ул, ә команда ялгыш. Баш та тартып булмый, үтәве дә куркыныч. Өлкән рулевой Петров мыркылдый башлый һәм капитан үзенең ялгышуын шундук сизеп ала. Башка матрос шулай эшләп караса, Михаил Александрович аны шундук штурвалдан куып җибәрер иде. Петров — шәхес. Аның белән чутлашмыйча булмый.

Җиңү бәйрәме көнне мичтә тәгәрәтеп пешергән бәрәңге ашап утырабыз. Степан Васильевич учы белән уалап бәрәңгегә ябышкан көлне өреп очырды да:

— Мондый бәрәңгене Сергей Павлович ярата иде,— диде.

— Нинди Сергей Павлович ул? — дип сорады Тимофей Иванович.— Элек бергә эшләгән капитаныңмыни?

— Нинди капитан булсын, Королев.

— Әстәгъфирулла,— дим, авызым пешкәнен сизеп,— теге Гагаринны космоска озаткан Королев түгелдер бит?

— Шул үзе инде,— ди Степан тыйнак кына.

— Син аны кайдан беләсең? Берәр китаптан укыпмы?

— Мин бит аның кулы астында дүрт елга якын эшләдем, ракеталар сынадык.

Өч класс белемле матрос Петров миңа ракета очырту турында лекция сөйли һәм минем, политехник музейда академикларны тыңлаган кешенең, андый эчтәлекле лекцияне гомеремдә ишеткәнем юк иде.

Петров академик Королев төркемендә ракетага ягулык үлчәп, тутырып торган. Йөз грамм артык ягулык салсаң, я булмаса йөз грамм

салып житкермәсәң, авырлыкның дөрес булмавы аркасында ракета траекториясеннән читкә тайпыла икән. Кешесен сайлый белгән Сергей Павлович, безнең Петров башкарган эштә тиешледән бер генә микронга да тайпылыш булмый. Шушы әңгәмәдән соң Королевның даһи кеше булуына мин чын күңелдән ышана башладым.

Бер тапкыр сәяхәттән кайткач тикшерү кичке тугызлар тирәсендә генә тәмамланды. Проходнойга житкәндә төгәл төнге ун иде. Экипаж әгъзалары өйләренә таралып беткән. Өйгә чылтыратырга почтадагы шәһәрара телефонга юнәлдем. Проходной янында Петровның хатыны Валентина Степановна көтеп тора иде.

— Сез анда иремне күрмәдегезме? — дип сорый Петровның хәләл җефете тынгысызланып.

— Ул вахтада булырга тиеш,— дим. Хатын-кызлар каршында бер-беребезнең гөнаһларын яшерү безнең канда бит.

— Ул сәгать сигездә вахтадан алышынырга тиеш иде ич,— ди Валентина Степановна.

Без мадам Петрова белән корабка юнәлдек. Степан чыннан да вахтадан алышынган булып чыкты. Вахтадан алышынгач трапны төзәтергә керешкән, шуның белән мәш килеп азаплана.

— Әллә син тилеме? — дидем ачу белән.— Ни пычагыма шулай кыланасың? Проходнойга барып хатыныңны каршылаганнан соң тотынсаң, ни булыр иде? Гомумән, вахтадан алмашынгансың, хәзер ял итәргә тиеш.

— Вахтадан алмашынгансың...— дип мыркылдый башлады Степан.— Ватык трапны ташладылар да тизрәк хатыннарын каршыларга элдерттеләр. Әгәр ватык трапка басып төшкәндә берәрсенең муены сынса?

Чыннан да, швартовка вакытында буксир безнең трапны ватып киткән иде. Кайту ыгы-зыгысы белән без, командирлар, җаваплы кешеләр, трап турында онытып ташлаганбыз. Петров онытмаган, хатынын каршыларга да бармыйча, төзәтергә керешкән.

Менә бүген Киев вокзалында без тагын өчәү калдык. Корабтагы өч иң өлкән кеше.

— Әйдәгез, Киевнең музейларын карап чыгабыз,— дим дусларыма.

— Без Тимофей Иванович белән Киевне фашист гаскәрләреннән азат иткәндә Днепр кичеп плацдарм корган җирне карарга барабыз,— диде Степан Васильевич...

## Шул ук алтынчы тәүлек. Киев. 12.40

*Әрәмәгә чыксам, үлән сирәк,*
*Сахраларга чыксам, җир җиләк...*

Бер күренекле тарихчы миңа төрки кабиләләрнең Африкадан килгәнлеген сөйләде. Аның шундый мавыктыргыч, гаҗәп кызык дәлилләнгән гипотезасы буенча иң борынгы төрки кабиләләр Африкадан Европаның көньягына, аннан Евразия континентына, Чукотка, Аляска аша Үзәк һәм Төньяк Америкага таралганнар. Майя һәм ацтек телләрен галим Кнорозов утыз ел өйрәнде. Нурихан Фәттах белән Әбрар Кәримуллин шушы борынгы тылсымлы телнең мәгънәсенә беренче күрүдә үк диярлек төшенделәр. Юкатан ярыматавының таулары, елгалары, күлләре, гаҗәп хәл, безнең Татарстан төбәгендәге исемнәр белән аталып йөртеләләр.

Чит илләрдә йөргәндә миңа гел көтмәгән төбәктә төрки сүзләр очрый. Сахара чүлен караганда «сахра» сүзе искә төште. Хәзер Африка чүлен моннан бары меӊ ел элек яшел болыннар каплаган булган дип фаразлыйлар Европа галимнәре. Итальян телендә сабын — «сапоне», пыяла — «фиала», немец — «алемане». Ул телдә мин тагын әллә ничә

татар сүзе тапкан идем. Аппенин ярыматавында шактый еш төрки топонимнар очрый. Алар инде борынгы Рим дәүләте заманында ук шулай атала торган булганнар. Ул чорда андый топонимнар күбрәк тә булганга охшый.

«Китап яратучыларның гадәтләрен беләм мин. Алар очраган һәр юньлерәк китапны әләктерергә тырышалар. Мин үзем дә бар тапкан малымны картлык көнемдә юаныч бирерлек китаплар сатып алуга тотып бетерәм. Үтенәм, китапларымны беркемгә бирмә, яме». Бу сүзләрне мин Марк Туллий Цицеронның «Тоз күле» исемле утарында безнең эрага кадәр 67 елны язган хатыннан алдым. «Китабымны Лукцейга бир, ә мин сиңа Магнессидә яшәүче Деметрийнең әсәрләрен җибәрермен»,— ди ул икенче хатында.

Украина телендәге «яр», «мәйдан», «келәм» шикелле төрки сүзләр турында сөйли башласаң, озакка китәр иде. Мине төрки топонимнарның Мексикага, Перуга, Боливиягә барып җитүләре хәйран калдыра. Үзәк Америка бездән бик ерак, аның турында уйлап баш ватмаска да була. Мин, оятыма, язучы саналган кеше, шушы көнгә кадәр туган Исергәп авылымның урамнары исеме: Әтәмби, Ур, Балтач, Казан кешесе дигән сүзләрнең каян килеп чыгуын белмим. Аларның мәгънәләре бабаларымның тормышы, аларның күзаллавы турында сөйли, ә мин аңлый алмыйм. Туган телнең һәр сүзенә ерак бабаларыбызның шатлыклары, кайгы-хәсрәтләре, аларның теләкләре, яшәү ысуллары, зәвыклары язылган, ә без бу язуларга сукыр кеше шикелле карыйбыз. Һәр сүзнең яңгырашында тарих авазлары ишетелә, ә без чукраклар, ул авазлар безгә килеп җитә алмый. Ана теле сүзләренә язылган хакыйкать яшәргә комачаулап бәгырьләргә тиеп тормасын өчен, без борынгы сүзләрне җиңел генә яңага алыштырабыз. Шунысы кызык, яңа сүзләр тиз таушала. Әле мин мәктәпкә йөргән чакта гына «осовиахим», «ячейка», «мопр», «фирка», «инкыйлаб» сүзләре шундый популяр иде, бүгенге көндә алар теге Орхон-Енисей руник язмалардагы сүзләрдән дә ят яңгырый.

Туган авылым тирәсендә Чаукалык тавы, Карагыш кулы, Әҗәл чокыры, Даулы болын исемле урыннар бар. Алар, билгеле, бабаларым заманындагы вакыйгаларны хәтерләтә. Исемнәрдән тыш та туган җирнең газизлеген җан тоя, чөнки күзәнәкләребез анда үскән икмәктән, аның һавасыннан, суларыннан яралганнар. Китапларда туган Исергәбем турында бер сүз булмаса да, әгәр ул авылны юкка чыгарсаң, тарихта бер бушлык барлыкка килер, аның төгәллеге югалыр иде. Халык язмышы аша узган вакыйга юкка чыкмый. Татар халкының риваятьләре, мәкальәйтемнәре, әкиятләре, елга-суга, урманнарга, кырларга биргән исемнәре — барысы да тарих. Шуларның барысы бергә кушылудан искиткеч бай, матур бер образ — туган ил, ватан сурәте барлыкка килә. Ул сурәт изге һәм пакь. Сталин культы, торгынлык чорында без шул исемнәргә сеңеп калган изге сурәтләрне юкка чыгару белән шөгыльләндек. Туган җиребездә күпме калды хәзер борынгы тарихи исемнәр? Ул исемнәрне без нинди максат белән, ни өчен юкка чыгардык?

Киевнең борынгы ташларына басып йөрим. Тирә-юньдә — йортлар, агачлар, яр астында Днепр елгасы агып ята. Шуларның барысы да тарихка бәйле, алар күп гасырларның шаһитлары. Монда Аскольд кабере, Алтын Капка, Подол, Бабий-Яр. Шушы исемнәргә зур вакыйгалар сеңеп калган.

Һәр яңа шәһәр күңелемдә Казан сурәтен җанландырып җибәрә. Без радиодан Казан тапшырган җырларны тыңлап, Казан баскан китапларны укып үстек. Балачакның чиксез фантазиясе Казан каласын искиткеч матур, милли колоритлы әкияти шәһәр итеп ясап калдырган. Башкаламны мин алтмышынчы елларның уртасында, Истанбул, Каһирә, Афина, Рим, Лондон, Рио-де-Жанейро калаларыннан соң гына күрә алдым. Беренче очрашу, беренче мәхәббәт шикелле, мәңге җуелмаслык булып йөрәккә сеңеп кала. Казан каласының балачак фантазиясе

ясаган шәһәргә охшамаганлыгы тетрәндерде мине. Каланың гомуми панорамасында шәрык архитектурасының горурлыгы — мәчет манаралары, кәрвансарайлар, мавритан ысулындагы сарайлар нигәдер күзгә ташланмады. Шәһәрнең гомуми силуэтын таш чиркәүләр, колониаль-административ биналар каплап тора иде. Шулар арасында искиткеч гүзәл, татар халкының өмете сынмавын, аның горурлыгы исән икәнлеген исбат итеп торган Сөембикә манарасы. Казанны беренче күрүдә мине менә нәрсә тетрәндерде: каланы канга батырган Иван Грозный солдатларына һәйкәл куйганнар, ә 1552 елда Казанның азатлыгын саклауда корбан булган, соңгы сулышка кадәр көрәшкән батырларга һәйкәл юк!

Сәяхәттә мин колониаль стиль дип аталган архитектура үрнәкләренә аеруча күңел салып карап йөрдем. Һиндстанда, Канадада, Көньяк Африка Союзында инглизләрдән калган архитектура үрнәкләре. Урта һәм Көньяк Америка илләрендә испаннардан калган корылмалар. Алжирда, Тунисta французлар төзегән архитектура һәйкәлләре. Шуларны өйрәнгәннән соң Казанның архитектурасын аңлавы шактый җиңеләйде. Казан чиркәүләрендә, аның колониаль-административ биналарында Әстерхан ханлыгы, Төньяк Кавказ, Урта Азия, Кырым һәм Себернең язмышлары сурәтләнгән.

Иван Грозный гаскәрләре Казанны алгач, халкын кырып бетереп, талап, кала тирәсендәге авылларны кырык чакрым радиуста юкка чыгарганнан соң, барлык архивларны, елъязмаларны, тарихка бәйләнешле кәгазьләрне яндырганнар. Мәрҗани, Атласи, Гобәйдуллин шикелле тарихчыларның әсәрләре шушы көнгә кадәр тимер рәшәткә артында иде. Рус галиме Худяков язган «Казан ханлыгы тарихы буенча очерклар»ны да укырга рөхсәт ителми иде. Алтмыш елга якын безгә ялган тарих укытып, өч буынны ялганчы итеп тәрбияләделәр. Сталин, Берия юкка чыгарган миллионнар үлеп котылды. Исән калганнар ялганны кабул итеп, җаһил, икейөзле булып яшәргә мәҗбүр иделәр.

1988 елны мәктәпләрдә һәм югары уку йортларында тарих фәненнән имтиханнар булмады. Сталин культы, торгынлык дәверендә язылган тарих дәреслекләренең, кулланмаларның ялган булуын Үзәк Комитет халыкка белгертте. Чын, дөрес тарих язар көн килде. Шушы изге вазифаны татар галимнәреннән кем өстенә алыр икән?

1240 елның көзендә Бату хан Киевне алган. Дошман явы тарафыннан кала җимерелә, аның сарайлары, гыйбадәт йортлары, һәйкәлләре юкка чыга. Карап йөрим. Бату хан Киевне алганчы салынган чиркәүләрнең алтын гөмбәзләре кояш нурларында ялтырап утыралар. Әнә Киев Русен чукындырткан кенәз Владимир 989—996 елларда салдырткан Десятинная чиркәве. Киев-Печора лаврасы эчендәге 1113 елда салынган Берестовтагы Спас чиркәве. Михаил чиркәве, София соборы — шуларны саный торгач, ялгыштым, саннарын югалттым.

Мин өч мәчетле Исергәп авылында туып үскән кеше. Безне тәрбияләгән карчыклар ул чакта намазларын калдырмыйлар иде әле. Дини карчыклар тәрбиясендә атеист булып үстек. Атеист булган очракта дога ятлыйсы, тәһарәт аласы, намаз укыйсы, ураза тотасы юк иде. Атеист булуыма карамастан, чиркәүдән курку минем канымда шушы көнгә кадәр саклана. Безнең өйнең түр тәрәзәсеннән караганда өч чакрымдагы Репьевка авылының чиркәве күренеп тора иде. Ул чиркәүне алпавыт салдырткан, алпавытка җирне безнең авылдан кисеп биргәннәр. Җирсез калган авылдашларым, үлүдән куркып, төрле якка таралып беткәннәр. Исергәп халкы үзен таралырга дучар иткән аяусыз бер көч итеп чиркәүне күрә иде.

Киев чиркәүләре башка тойгы уята. Алар бу калага килгән кешегә: карыз безгә, күрәсезме, тарихыбыз нинди борынгы, халкыбызның культурасы нинди югары, нинди камил, дип сөйләп тора. Шундый ук фикерне житкерергә тиешле Болгар һәм Казан ханлыгы заманы мәчетләребез күптән җимерелеп беткән. Тарихта, Чыңгыз һәм Бату ханнар

һәр чолганган каланы җир белән тигезләп киткәннәр, дип язылган. Бату хан алган Киев каласының бар чиркәүләре исән. Алар соң ничек сакланып кала алганнар?

Урта гасыр калаларының күбесе зур елга ярындагы калкулыкларда. Днепрнең биек ярында утырган Киев нәкъ шуңа Казан каласын хәтерләтә. Урыны гына түгел, башка яклары белән дә бу кала безнең Казанга охшаган булырга тиеш. Киев Скандинавия белән Балкан илләре арасындагы сәүдә юлында, Казан исә Көнбатыш Европа илләре белән Урта һәм Ерак Азия арасындагы сәүдәне җанландырып торган. Киевнең чиркәүләре шул сәүдәнең керемен исбатлап утыралар, ә иң зур, иң көчле сәүдәдән кергән керемне исбатлаучы сарайлар, гыйбадәт йортлары, кәрвансарайлар җир астында ята. Казан ирекле заманында Идел буе мөселманнарының дини үзәге булган, Киев — башта славян мәҗүсиләренең, чукынганнан соң, борынгы Русь христианнарының үзәгенә әйләнгән.

Күзем туйганчы, хәлем беткәнче Киевне карарга ниятләдем. Шушы кала, Мәскәү, барлык рус шәһәрләре, җир йөзендәге барлык кеше яши торган урыннар аркылы мин Казанны, аның тарихын, аның язмышын өйрәнергә тырышам. Әнә Днепр елгасының биек һәм текә уңъяк ярында Киев-Печора лаврасы. Мин шуңа юнәлдем.

Монахларның монастырь салырга урын сайлый белүләре хәйран калдыра. Россиядәге монастырьлар тулысынча диярлек ныгытма рәвешендә, һөҗүмнән сакланыр өчен салынганнар һәм еш кына аның эчендә сугышка әзерләнү, сугыш белемен өйрәнү барган. Куликово кырында монгол-татар батырына каршы чыккан Ослябаның монах булуы, билгеле, очраклы хәл түгел.

Киев-Печора лаврасындагы чиркәүләр, чаң сугарга көйләнгән кыңгыраулы манаралар, калкулык битендәге таш диварлар ерактан караганда бу урынның чыннан да изге булуын исбатларлык искиткеч панорама барлыкка китерә. Җир астындагы мәгарәләрдә монахларның ачык табутка салынган мәетләре кибеп ята. Уйлап карасаң, лавра — монахлар өчен корылган гигант мавзолей. Менә ничек итеп христиан динен пропагандалый белгәннәр. Киев-Печора лаврасына Рәчәйнең төрле почмакларыннан дингә ышанучылар, гарип-гораба, тормыш ыгы-зыгысыннан арып гарык булган мескеннәр ташкын булып агылган. Алар бит гыйбадәт кылу өчен меңәр чакрымнан җәяү килгән. Шушында җаннарына шифа табып, терелеп кайтып китүчеләре әз булмаган, билгеле. Фәнгә таянып, лавраның шифалы булуыннан көлмәкче булам. Тормыш ыгы-зыгысыннан арып, хастага әйләнгән неврастеникка нәрсә кирәк? Кайгы-хәсрәтләрдән, эчке киеренкелектән арындырыр өчен врачлар нинди киңәш бирәләр? Урын алыштыру. Саф һавада җәяү йөрү. Бер генә айга булса да табигать кочагында яшәү. Саф һава сулап, табигатьнең гүзәл күренешләрен күреп, сандугач тавышларын тыңлап яланаяк Киевкә гыйбадәт кылырга баруның бүгенге көндә иң шәп ялга саналган туристик походтан ни аермасы бар? Аяусыз кырыс, иң таза кешене дә имгәтерлек авыр крестьян эшеннән бер айга булса да котылып тору үзе генә дә мескеннәргә ничек шифалы тоелгандыр?

Әле мин бала чакта гына Шәһре Болгар хәрабәләренә, Җүкәтауга, Буләргә, тагын әллә кайларга безнең авыл карт-корысы барып йөри иде. Җирдәге «аллаларның» мәрхәмәтсез булуы, алардан аяусыз изелү, көч җитмәслек зур салымнар түләү, газиз балаларының солдатка туктаусыз китеп торуы күктәге аллага мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр иткән.

Киев бакча эчендә утыра. Саргая башлаган моңсу көзге яфраклар артыннан күренгән йортлар шундый матур. Каланың мең еллыгын бәйрәм иткәндә борынгы корылмаларны төзәткәннәр, яңартканнар. Чиркәү гөмбәзләренә йөгертү өчен генә дә 24 кило югары пробалы чын алтын тотылган. Бу турыда Киевтә яшәүче һәркем белә.

Руслар иң ләгънәтле кешегә, «без рода, без племени»,[1] диләр.

[1] Без рода, без племени — нәсел-нәсәпсез (русча).

Тамырсызлык—искиткеч куркыныч рухсызлыкка алып бара торган нәрсә. Халкыбыз тарихына, гореф-гадәтләренә тоташкан тамыр аша бабаларыбыз буыныннан шифалы егәр килеп, рухи тормышыбызны тукландырып тора. Рухсызлык — хайванлыкка кире әйләнеп кайту өчен салынган шома һәм туры юл. Борынгыларның эзләрен күреп тормаганда без, ни сәбәптер, алга бара алмыйбыз. Ата-бабадан калган эзләрне югалту адашуга дучар итә. Тарихның артта калган юллары никадәр җете күренсә, алдагы офыклар да шулкадәр киңәйгән, киләчәккә юнәлгән була. Үткән заман тәҗрибәсе белән коралланмыйча сәламәт киләчәккә барып булмый.

Киев кенәзләренең күбесе кыпчак кызларына өйләнгән. Кенәз үзе үлгән, тәхеткә кыпчак хатыннан туып, шул хатын тәрбияләгән егет утырып кала килгән. Шушы чиркәүләрне салдыручыларның тәнендә ким дигәндә яртылаш кыпчак каны, күңелләрендә кыпчак зәвыгы булганга охшый. Киевнең алтын гөмбәзле храмнары күзгә шикелле борынгылыкны чагылдырып-күрсәтеп торалар.

Днепр ярында басып торам. Елганың сулъяк ярындагы урманнар офык артына кереп югала. Шул урманнар кайчандыр кыпчакларныкы булган. Аларның — атлы, русларның җәяүле гаскәрләре көчле саналган. Атлы сугышчылар теләгән калаларын җиңел генә алганнар һәм озак тукталып тормыйча, җиңел генә ташлап киткәннәр. Вак инешләр буенда барлыкка килгән славян кабиләләре, Днепр шикелле зур елгага ирешкәч, көч туплап, диңгезләргә таба юл тоткан.

Татар фольклорында Агыйделгә багышланган җырлар күп. Иделдән колак каккач, минем бабаларым Агыйдел ярына барып каты күз яше түккән, күрәсең. Ике көчле милләт бер төбәктә яши алмый. Кайсыдыр аңа хуҗа булып калырга, җиңелгән милләтне юкка чыгарырга тырыша. Тарих шул турыда сөйли. Инглизләр белән ирландлылар, Кытай белән Маньчжурлар, мисыр гарәпләре белән коптлар. Хуҗа булып калган милләт, җиңелгән милләткә яла ягар өчен, аның тарихыннан, гореф-гадәтеннән, аның һәр эшеннән гаеп эзли башлый. Гаеп, билгеле, табыла. Табылмаса, аны уйлап чыгарырга да була. Янкилар өчен, мәсәлән, негрлар шапшак, ялганчы, ышанычсыз, Көньяк Африка Союзы сегрегатлары өчен аборигеннар бөтенләй маймылга тиң. Җиңгән халыкның җиңелгәннәрне җәберләве, рәнҗетүе билгеле хәл. Шуңа күрә дә алар арасындагы сугыш аяусыз, соңгы сулышкача дәвам итә.

Кояш Днепрга каршы калкулыклар артына кереп яшеренә башлады. Түбә калайлары, каштан яфраклары канга буялган шикелле күренәләр иде. Бу кала минем дикъкатемне тарихка таба бора, авыр, катлаулы, куштаннар ишетсә, миңа яла ягарлык уйлар кузгата. Әле күптән түгел буш күренгән урамнар җанланып китте. Эштән кайтучылар урамга сирпелделәр. Янымнан узган кешеләрнең битләренә карап калам. Нинди токымнан килгән затлар сез? Нәселегез кайлардан, кемнән башланган? Сез, урам буйлап ашыгып өегезгә кайтып баручылар, чыбык очындагы бөре хәлендә генә бит. Шәҗәрә агачының тамырларына, төп буена, аның ботакларына сез ничек килеп тоташасыз? Инде күптән мине бер газаплы сорау борчый. Әнием ягыннан мин бабам Әхмәтҗанны, аның әтисе Мөхәммәтҗанны, Мөхәммәтҗанның әтисе Гайсаны, аның әтисе Шакирҗанны беләм. Шул Шакирҗан атлы кеше төрек сугышыннан ике медаль, бер орден тагып кайткан. Аның нинди дер чины да булган, күрәсең. Әни мәрхүмә аны майор дип йөртә иде. Бәлки булгандыр да, чөнки сугыштан кайткач, аңа җир һәм күпмедер акча, тагын әллә нинди өстенлекләр биргәннәр. Шул ерак бабам сугыштан батыр булып кайткач, эштән бизгән. Орденлы түшен киереп тик йөри икән. Авылдашларын да санга сукмый башлаган. Февральнең бер ачы буранында Шакирҗанның сырхау карчыгы иренең утын кертүен ялварып үтенә икән. Ә теге сугыш герое тик ята ди. Түзәр хәле калмагач, ерак әбием теге сугыш чукмарының түшеннән орден-медальләрен йолкып алган да урамга чыгарып то-

мырган. Герой сорыкорт: бар, орденнарымны алып кер, дип авыру хатынын урамга куа икән. Әбекәем куркаклардан булмаган, күрәсең, чыкмаган. Бабам бераздан урамга үзе чыкса, сугышчан бүләкләрдән җилләр искән. Шул вакыйгадан соң Шакирҗан батыр әкренләп эшкә җигелергә мәҗбүр булган. Әтием ягыннан мин бары тик бабам Юнысны, аның әтисе Ганине генә беләм. Ганидән соң меңләгән елларга сузылган караңгылык.

Шәҗәрәм атабыз Адәмгә, аның әтисе маймылга барып төртелә. Ә бит морза нәселеннән булган Әмирхан Еники ата-бабасын унбиш буынга хәтле белә.

* * *

Көне буе шәһәр карап йөреп арыдым. Экипаж янына барыр алдыннан бераз ял итеп аласым килде. Урам уртасыннан сузылган скверга кердем. Як-яктан ак тирәкләр сафка тезелеп киткәннәр. Уртада — сирень куаклары. Чәчәк түтәлләрен утыргычлар чолгап алган. Уртада мәрмәрдән ясалган фонтанга янәшә диярлек өч балбал, кыпчаклардан калган һәйкәлләр.

— Әй сез, ерак бабаларымны күргән-белгән балбаллар, сөйләгез әле алар турында. Үзегез кемнәр? Кем ясады, кем истәлегенә куйдылар сезне? Ничек шушы көнгә кадәр исән кала алдыгыз? Сквер Владимир тавына барып тоташа. Янәшәдә — Калинин мәйданы, урам аша гына Эчке эшләр министрлыгы идарәсе һәм шул мәгърур бинаның тәрәзәләре каршында гына өч таш сын. Соргылт таштан эшләнгәне зур, таза. Алар, һичшиксез, батыр, гайрәтле гаскәр башлыгына яки ханга якын кешеләргә куелган. Берсенең көбәсе, биленә аскан ук савыты, кылычы, читекләре — барысы да искиткеч затлы. Аграк таштан ясалганы үсмер егетме, әллә хатын-кызмы? Күкрәкләре, югыйсә, хатын-кызныкы, ләкин җилкәләр, баш һәм кием ирләрнеке. Бәлки ул ирләр белән сугышка йөреп тупаслана башлаган хатын-кыз — амазонкадыр? Аның да билендә кылыч, садак, ике кулы белән йола җамаягын эченә кысып тора. Өченчесе, кара таштан ясалганы, һичшиксез, хатын-кыз. Алар бер-берсенә аркаларын каратып, өчесе өч якка карап торалар. Искә «аркадаш» сүзе килеп төшә. Төркиләр иң якын, иң ышанычлы дусларын шулай атаганнар. Шушы сүзне ишетү белән күз алдыма дошман чолганышында калган ике батыр килеп баса. Уклар атылып беткән. Кылыч сынган. Соңге дошман тәнендә. Кулда бары тик кыска хәнҗәр генә. Тирә-якта тау булып өелгән дошманнарның мәетләре. Аркадашлар соңгы тамчы каннары калганчы бер-берсен дошманнан сакларга тиешләр. Киев шәһәренең скверындагы балбаллар күз алдыма шундый күрәшне китереп бастырды.

Алар чыннан да шундый булганнардыр, дип уйлыйм мин. Тамак, кием, торак мәсьәләсе аларны борчымаган. Алар табигать кочагында дала җиледәй ирекле, азатлыкта, Байкал күле белән Карпат таулары арасындагы киң сахраларда, төнге учаклар янында, кошлар сайраганын тыңлап, күктә йөзгән тилгәннәрне күзәтеп гомер уздырганнар.

Күзем соры таштан ясалган балбалның читегендәге бизәкләргә төште. Арчада Казанны карарга килгән туристларга сатар өчен тегелгән читекләрнең бизәкләре әле һаман шундый. Кинәт шушы таштан ясаган кешеләр белән эчем бушаганчы сөйләшәсем килеп китте. Әйтегез әле, шушы скверга килеп басканчы кайларда тордыгыз? Өчегез өч кабилә вәкилләреме сез, әллә тугандашлармы? Сезне үзара бер уртак сыйфат берләштерә — йөзегезгә бәреп чыккан гайрәт. Сез, билгеле, яшәүнең ачысын да, төчесен дә татып карагансыз. Җиңүгә дә, җиңелүгә дә битараф хәзер. Бәлки тынычлык шартында гына киләчәкнең буласын белә торгансыздыр? Их, балбаллар, яшәү әле һаман шулай катлаулы. Без, егерменче гасыр балалары, бомба шартлаудан, елгалар кибүдән, урманнар, үсемлекләр, җәнлекләр юкка чыгудан куркып яшибез. Озакламый

һава сулыш алырга ярамас, җир — ашын, елгалар балыкларын югалтыр дип куркып көн каршылыйбыз. Сезнең заманда адәм баласы өчен иң куркыныч нәрсә — җәя белән ук, сөңге белән кылыч. Җәя белән уктан, сөңге белән кылычтан саклану чарасын җиңел табып була. Адәм баласының бүгенге көн коралыннан котылу чарасы юк. Әле менә кичә генә Ждановтан Донецкигә килгәндә Новоселовка янындагы бер авыл аша уздык. Шул авылда бер хуҗа алты балбалны бер-берсенә яткырып куеп койма ясаган. Ул кыргыйга борынгы һәйкәлләрдән койма ясарга ярамаганны белгерткәннәр булса кирәк. Урам якка карап яткан таш кардәшләрегезнең битләрен балта белән юнып тигезләгәннәр. Сез бит, беләм, тарих йоткан халыкларның соңгы вәкилләре. Шул халыкларның җирдә яшәп китүләре турында безгә сөйләр өчен ташка әйләнгәнсез. Балбалларның битен юнган койма хуҗасы шикелле манкортлар үрчүдән туктамаса, сез дә юкка чыгачаксыз, без дә. Адәм баласының үзе генә түгел, таш сынын да үтерүчеләр очрый башлады бу дөньяда. Алар күп. Кай вакыт андыйлар власть башына менеп утыралар. Кырым ярыматавында сезнең нәселдән килгән бер халык яши иде. Аларны туган җирләреннән куып, исемнәрен тарихтан сызып ташладылар. Җимерү, юкка чыгару — кыргыйлык паспорты, ул бар, яши.

Сезнең, балбаллар, борынгы грек тарихчысы Геродотны укыганыгыз юктыр шул? Ул менә нәрсә яза: Скифларның патшасы Иданфирс фарсыларның гаскәр башлыгы Дарийга: «Без сезнең белән сугышырга теләмибез. Тынычлыкта яшисебез килә. Әгәр скифлар белән сугышасыгыз килүе тыелгысыз икән, ата-бабаларыбыз җирләнгән каберлекләрне эзләгез. Табыгыз шуларны, җимерегез. Шул изге каберлекләр өчен сугышырбызмы без, юкмы — күрербез. Ә болай, ирекле көндә сугышырга теләмибез».

Җир йөзен караңгылык каплагач, балбаллар белән саубуллашып, дусларым янына юнәлдем.

## Җиденче тәүлек. Мәскәү-Белград поезды. 20.50

Чоп станциясендә вагоннарны таррак күчәрле көпчәкләргә утырттылар. Сусликов комментарий ясый: «Рәчәй арбасы Европа җиренә сыймый. Күчәрләрне алыштырмаган булсалар, бәрелеп, Европа шәһәрләрен аударып бетергән булыр идек». Күчәр алыштырган арада таможнячылар һәм чик сакчылары документларыбызны тикшереп узды. Тикшерү тыныч кына үтеп китте дип торганда, мине күрше вагонга чакырдылар. Бу вагондагы беренче купеда өч моторчы: Саша Чумак, Петлюга һәм экипажның кәмитчесе Сусликов урнашкан иде. Ишекне ачу белән купе янында дөм шәрә басып торган Петлюганы күреп алдым. Куркудан буыннарым йомшарып китте.

— Нәрсә булды?

— Тентеделәр. Трусигыма кадәр салдырып карадылар. Туфлиемнең үкчәсен куптардылар, аналарын шулай итим! — Мескеннең куркудан ияге һәм аскы ирене асылынып төшкән. Үзе дер калтырый.

Мин тизрәк таможнячылар житәкчесенә йөгердем. Утызлар тирәсендәге чибәр генә бер кеше. Кыяфәте яһүдкә охшаган. Үзе шактый әдәпле сөйләшә — таможнячылар арасында сирәк очрый торган сыйфат.

— Шулай килеп чыкты. Без аны тентергә мәҗбүр булдык.

— Ә нигә сез бары тик аны гына тентедегез?

— Шулай килеп чыкты,— таможнячының сөйләшәсе килми иде. Ул күрше купега юнәлде. Мин дә тыгылдым. Минем нигә бары тик Петлюганы гына шулай мәсхәрәгә җиткереп тентегәннәрен беләсем килә иде.

— Ул егетнең ни сәбәпле шик уятуын мин белергә тиеш. Әгәр ул чыннан да гаепле булса, без аны кире Ждановка озатабыз.

— Гаебен таба алмадык. Шигебез урынсыз булып чыкты,— диде таможнячы. Аның миннән тизрәк котыласы килә иде, шуны сизгәч, ныграк бәйләнә башладым.

— Сез миңа сәбәбен аңлатырга тиешсез. Ул турыда белмичә мин барыбер туктамыйм.

— Башка беркемгә белгертергә ярамаган профессиональ сер дә була безнең эштә. Аңлаттым ич инде, ул морякны тикшерергә кирәк таптык дип.

— Юк, мин барыбер белергә тиеш.

— Ярый алайса. Сездән сер чыкмас дип ышанам. Алар бит купеда өчәү баралар. Шуларның берсе, бәрәңге борынлы кеше, без тикшергән чакта гел Петлюгага карый, йөзендә шундый киеренкелек билгесе. Без аларны берәр нәрсә яшергәннәрдер дип уйладык. Башта теге бәрәңге борынның әйберләрен җентекләп карап чыктык, аннан соң икенчесенекен. Наркотик яшергәннәрдер, дип уйлаган идек.

Бу эшнең Сусликов аркасында эшләнгәнен аңладым һәм, таможнячыга рәхмәт әйтеп, Николай Иванович купесына кердем.

— Син Петлюга турында таможнячыларга нәрсә сөйләдең? — дидем мин тентүнең нәкъ әләктән башланганлыгын абайлап.

Сусликовның бите бөрешеп бетте, күзләре йомылды. Аның көлүе шул иде.

— Мин бит, Миргазиян Закирович, шаярып кына, таможнячыларны үртәр өчен генә әйткән идем. Алар сүземне чынга санадылар. Комедия.

— Николай Иванович, бу комедия түгел, фаҗига. Шундый житди нәрсә белән шаяралармыни?

— Әллә ничек корылган бу дөнья: шаяруны чынга, чынны шаяруга саныйлар. Нигә гел миңа каныгалар бу экипажда? Туры әйтүемне яратмыйлар.

— Сусликов! Нинди туры әйтү турында лыгырдыйсың? Син бит киләчәктә бергә эшләргә тиешле егетне искиткеч катлаулы хәлгә куйгансың. Шундый нәрсә белән шаяралармыни?

— Чак кына берәр нәрсә булса, Сусликов гаепле.

Белградка килеп җиткәндә Петлюганың яңа кушаматы әзер иде инде.

— Әй, контрабандист, чыгар тизрәк чемоданны,— диде Саша Чумак тентү аша узган егеткә. Тегесе, әйтерсең, аңа мәсхәрәле сүз әйтмәделәр, вагон эченнән чемодан чыгарып, перронга куйды. Кинәт Петлюганың «контрабандист» сүзенә хәтере калмавының серенә төшендем: ул диңгезчеләрнең «Петлюра» кушаматы тагуыннан курка иде.

Белград вокзалында каршы алырга килгән Министрлык вәкиленең бездән тизрәк котыласы килә иде. Буш автобус янына алып килүгә:

— Төяләгез, башлагыз,— диде ул.— Шофер халкы көтеп торырга яратмый.

Көтеп торган автобуска чемоданнарыбызны төяргә керештек. Салонга кереп утыргач, капитаныбыз шофердан:

— Дубровникка кайчан барып җитәбез? — дип сорады.

— Дубровник башка якта,— диде русча сөйләшә белгән шофер.— Без бит бөтенләй башка шәһәргә, Скоплега барабыз.

— Скоплега?..

Вәкил ашыгудан, ачыклап тормыйча, Ленинградтан килгән туристларны каршы алучы автобуска күрсәткән икән. Туристлар да Мәскәү—Белград поезды белән килгән булып чыкты. Алар инде Скоплега барасы автобусны эзләп йөри иде. Вәкилебездән җилләр искән. Чемоданнарны кире бушатырга керештек.

— Капитан төпченмәгән булса, Скоплены да күреп кайткан була идек,— диде дөнья күреп йөрергә яраткан матрос Дулев.

Безне алырга килгән иркен салонлы зәңгәр «фиат» вокзал алдындагы мәйданның читенәрәк туктаган булып чыкты. Чемоданнарыбызны күтәреп шуңа таба юнәлдек.

Автобус урыныннан кузгалды. Белградның ак йортлары, Европага хас кешесез тротуарлар, Европага хас машиналарның тыгыз агымы һәм

шул агымда коры җир корабы, безнең зәңгәр автобус. Белград яңа уянып, җир йөзенең барлык шәһәрләренә хас көндәлек тормышын дәвам итә. Ирләр эшкә ашыга, хатын-кызлар — базарга, бала-чага, әле ачылып та җитмәгән күзләрен йодрыклары белән уып, мәктәпкә таба атлый. Автобус шәһәр читенә чыкты. Бакча ышыгына урнашкан ялгыз особнякләр. Ниһаять, алар да күздән югалды. Алда кыр-яланнар, печәннәре чабылып чүмәләгә өелгән көзге болыннар. Кырып алган солдат чәчен хәтерләткән камыллар өстендә кәтү йөри. Ургыч узганда җиргә ятып калган моңсу көзге чәчәкләргә кадәр нәкъ бездәгечә. Кешелек дөньясындагы илләрне бер-берсеннән бары тик политика, бары тик дипломатия тудырган үзгәлекләр генә аера микәнни? Кеше кайсы гына илдә, җир шарының кайсы гына почмагында яшәмәсен, аның эше башка илдә яшәүчеләрнең эшләреннән аерылмый. Җир шарының төрле кыйтгаларында яшәүче сабый балалар да гел бер төрле, аларның ятлары, читләре, дошманнары юк. Җир йөзендәге барлык балалар бер ана баласына охшаганнар.

Әнә, бәләкәй кеше шикелле ачы тавышлы карсак трактор артыннан хатыннар бәрәңге чүпләп бара. Яңа ачылган буразнага каргылдап кара каргалар килеп кунып тора. Җир башында сабыр гына учак пыскый. Зәңгәрсу төтен боргаланып күккә күтәрелә, эри, яшьлек көннәре шикелле эзсез югала. Җылымса көзге һава, төтен исе, күңелдә муллык хисе. Учны пешереп торган кайнар бәрәңгенең кытыршы кайнар кабыгын учта тәгәрәтеп, өрә-өрә ашыйсым килеп китте. Их, еракта калды без яккан учаклар! Чит ил бу. Тел ят. Тарих үзгә. Гореф-гадәтләр дә безнекенә охшамаганнар. Ләкин кыр-яланнар, ярылып пешкән кыр бәрәңгесе, буразнадан корт чүпләп йөргән каргалар, хәтта көзге һавага кадәр безнең Исергәпнекенә охшаган.

Автобуста баручы дусларымны күзәтәм. Әнә авылда туып үскән егетләрнең күзләре бәрәңге җирендә. Күзләрендә кайнар моң — җирсенү кичерешe. Их, бәрәңгеле яшьлек, сине мин зур сарайларга, зәңгәр ярлы Европа курортларына, аккошларга охшашлы кыйммәтле яхталарга утырып диңгез сәяхәтенә йөрүләргә дә алыштырмас идем. Без сине ничек ташлап китә алдык икән? Нигә ул чакта сагынырбыз, саргаербыз дип уйламадык? Юк, туган авылыбызны ташлап китүдә без гаепле түгел. Туган җирдән безне сугыш аерды. Без бит армиягә сугыш елларында алындык. Сугыш беткәч тә озак еллар кайту мөмкинлеге юк иде.

Һәм әкренләп чит туфракта тамыр җибәрдек.

— Җырлыйсы килә,— диде буйга ике метрлы, сабый табигатьле Николай Петрович Сайгаченко һәм, үзе сизмәстән, сузып җибәрде:

Дывлюсь я на небо та думку гадаю,
Чому я ни сокил, чому не летаю...

Сайгаченконың кушаматы «Танкер Манюня». Йөз ат көчле чыгырның аркан сөйрәргә көче җитмәгән чакларда Танкер Манюня, аягын палубага терәп, учына төкерә дә бот юанлыгы арканны бер үзе сөйрәп турачкага урата башлый. Андагы көч һәм андагы йомшаклык! Ничә ел шушы экипажда эшләп, ачулану, ызгышу түгел — кешегә каты тавыш белән дә сүз әйтә алганы юк. Тыштан караганда, әллә аю шикелле, аякларын киңгә аерып, әүмәк-тәүмәк атлап йөргәнгә күрә, дорфа күренә өлкән матрос Сайгаченко. Табигать андый көчле кешеләрне һәр очракта диярлек юашлык белән бүләкли. Андагы оялчанлык, күңел нәзберекләге.

Җыр аша, уртак моң аша кирә иде экипажга берләшү. Күптән ишеткәнем юк иде адәм балаларының бергә җыелып, бер тавыштан көй сузганнарын. Инде күптән күргәнем юк иде диңгезчеләрнең хисләрен уртак моңга тоташтырып, җан теләкләрен берләштерүләрен. Магнитофон тимердән ясалган, аның тавышы да, кешенекенә охшауга карамастан, барыбер тимер. Кешеләрне бергә җыелып җырлау бәхетеннән бәлки

шул магнитофон мәхрүм иткәндер. Кибетләрдә магнитофон сатыла башлагач, һәркем теләсә нинди җырчыны өенә чакыра ала, теләсә концерт, тели икән опера тыңлый ала үз өендә дип куанган идем мин. Чыннан да, нинди бөек мөмкинлек. Нәтиҗәдә, магнитофон адәм балаларын җыелышып җырлаудан мәхрүм итү белән генә чикләнмәде, тимер тамаклы җансыз җырчы сәүдә өчен, файда өчен Америка һәм Европа базарларында әмәлләнгән шлягерларны ташып, яшьләргә тарата башлады. Нәтиҗәдә, магнитофон кешеләрне бер-берсеннән аеру белән генә чикләнмичә, аларны милли моңнардан, туган җир куенында туган көйләрдән дә аерып ыргытты.

Юл боргаланып өскә, тауга таба үрмәли. Шофер безнең җырны бирелеп тыңлый. Ул да сәерсенә күмәкләшеп, бер көйгә, бер үк сүзләргә җырлый белүебезгә. Күмәк җыр — берләшүнең иң бөек ноктасы ул. Күптән ишеткәнем юк, җаваплы конференцияләрдә, җыелышларда, таралыр алдыннан хор белән «Интернационал»ны әле һаман җырлыйлармы икән? Мин бәләкәй чакта безнең авыл хатыннары эшкә дә җырлап баралар, җырлап кайталар иде. Көлтә ташыганда, йөк өстенә утырып печәннән кайтканда, ат саклаганда, авыл малайларының кыр-яланнарны яңгыратып җырлаулары искә төшә. Җыр ул — доганың бер төре. Ул синең өметләреңне яңартып җибәрә, теләкләреңә юнәлеш, җанга шифа бирә. Ләкин тора салып кына җырлый башлап булмый. Җырга тиешле кәеф кирәк. Магнитофон безне нәкъ шул ягы белән җәлеп итте: аның кәефсез чагы юк. Ул күндәм, илһам килгәнен көтеп тормый, бармак белән төрттең — җырларга керешә. Ләкин магнитофон нинди генә камиллеккә ирешмәсен, моно, стерео, квадрио, видео, ул адәм баласына хас иҗат бөеклегенә барыбер ирешә алмас. Магнитофон ул — бары тик күндәм кол, без кушканны үтәүче генә. Ул сине дә гади тыңлап утыручы тамашачы колдан арыга җибәрми бит.

Башта салмак кына боргаланып өскә күтәрелгән юл һаман текәләнә башлады. Сул якта тирән упкыннар. Алар һаман тирәнәя, инде аларның төпләре дә күренми. Юлны төрле яктан урап алган тау сыртлары, кыялар, монолит ташлар, үзара ярышып, болытларга үрелә. Тау түбәләренең иң биекләре болытларны тишеп, күккә китеп югала. Мәңге чиста, мәңге салкынча, кислородка сугарылган тау һавасы.

Безнең татар әкиятләрендә Каф таулары, сәмруг кошлары, күктә йөзгән лачыннар күп. Дала җирдә яшәгән татарларга алар кайдан килеп кергә алган? Кырым тауларын беренче күрүемдә үк алар миңа таныш иде. Моңа кадәр алар хисләремдә яшәгәннәр, күрәсең? Күңелемдә бала чактан бирле тауларны сагыну яши. Ә бит мин Ык буе үзәнендә туып үскән кеше. Татарлар Казан, Кырым, Әстерхан, Себер, Нугай татарларына бүленмәгән заманнарда туган булса кирәк бездәге тау ярату.

Шофер автобусны туктаусыз алга куа. Инде болытлар аста калды. Упкынга карап барганда агач кәүсәсенә эләгеп, бушлык өстендә асылынып торган машина мәетләре күренеп китә. Биеклектә йөрәк ашыгыбрак тибә башлый. Күзне йокы баскан. Колакларда сәер чыңлау. Як-яктан тау сыртлары белән читләнгән киң үзәнлеккә төшеп килгәндә шәһәр күренде.

## Сигезенче тәүлек. Босния һәм Герцеговина. 14.00

— Югославлар славян бит, әйеме? Аларның җиренә кем мәчет салган? — Шушы сорауны бернична диңгезче кабатлады.

— Шофер,— диде капитан сәерсенеп. — Әллә сез безне Төркиягә алып килдегезме?

— Сараево бу — Босния һәм Герцеговинаның башкаласы,— диде автобус йөртүче. Якынлашып килгән шәһәрдә мәчет манаралары калкып тору шоферга табигый күренә иде.

— Сез, егетләр, тарихны бөтенләй белмисез икән,— диде электромеханик Давыдов. Югославия ничә гасыр төрекләр кулы астында яшәгән. Алар арасында мөселманнар да бар. Черногорецлар булса кирәк, ачык кына хәтерләмим.

— Төрекләр бу илдә калганнармыни? — дип сорады матрос Дулев.

— Нишләп калдырсыннар, билгеле, куып җибәргәннәр. Алар, картларның сөйләвенә караганда, безнең Кубаньда да яшәгән булган. Кубань казаклары аларның җилләрен очырткannar,— диде өлкән механик Горбаненко.— Ә Югославиядән аларны генерал Скобелев куган.

— Скобелев? — Электромеханик Давыдов кычкырып көлде. — Скобелев Болгариядә сугышкан. Шипкада аңа һәйкәл куелган.

— Юк, миңа барыбер аңлашылмый,— диде боцман Савчук. — Төрекләрнең үзләрен куганнар, ә мәчетләрен калдырганнар. Шартлатырга динамит таба алмадылар микәнни? Аны бит трактор белән тарттырып аударырга да була. Үзләре батыр гына халык. Фашистларга каршы да ничек сугыштылар, ә шул төрек мәчетен җир белән тигезләргә кулларыннан килмәгән.

— Миргазиян Закирович, бу турыда сез нәрсә әйтә аласыз? — диде капитан Гремин.

— Мин Югославия тарихын белмим.

Сараево шәһәрендә бөек төрек архитекторы Хуҗа Синан проекты буенча салынган Хөсрәүбикә мәчете барлыгын беләидем. Безнең каршыда Хөсрәүбикәдән тыш тагы ике мәчет — Али-паша һәм Падишаһ гыйбадәтханәләре манаралары күккә ашып торалар. Бу хәл мине бераз каушатып җибәрде. Манаралар, үзара куышып, автобус яныннан узып киттеләр. Мин егетләргә мәчетләрне җимерергә көч җитмәүдән түгел, аларны архитектура казанышлары, культура һәйкәле итеп саклау турында аңлатырга керештем.

— Мәчеттә нинди архитектура булсын ди, помполит? Син динчеләр тегермәненә су коясың түгелме соң? — диде капитан Гремин сәерсенеп.— Ай-һай, әгәр парткомда мәчетләрне яклап сөйләвеңне ишетсәләр, саклан, эшеңнән дә төшереп ташлаулары бар.

— Татарлар белән төрекләр вась-вась бит. Билгеле, козгын козгынның күзен чукымый, ди рус әйтеме,— дип Сусликов касыгыма ук китереп тондырды.

Әле шушы көнгәчә патриотлык белән шовинистлык арасындагы чикнең кайдан узганын аңлый алганым юк. Күп вакыт патриотлык, әгәр ул, Сталин әйткәнчә, үзен «тигезләр арасында беренче» санаган милләт вәкиленеке булса, кайвакыт ярларыннан чыгып, чын шовинизм ташкынына әйләнеп китә. Шовинизм белән көрәшеп тә булмый диярлек. Син аңа кул күтәрә башласаң, шундук маңгаеңа кайнар тимер белән «милләтче» мөһерен сугып ташлыйлар. Соңгы елларда минем чиркәү төшерелмәгән фильм караганым юк диярлек. Язган китабыңа исә мәчет турында бер генә сүз кертеп кара әле...

Автобуста утыручыларга күз салып алдым. Мине аңлаучы гына түгел, аңларга теләүче дә юк иде экипаж әгъзалары арасында. Төрекләрнең үзләрен кугач, аларның мәчетләрен дә челпәрәмә китерү аларга бәхәссез аксиома тоела иде. Коллектив белән үз арамда күренмәс таш стена барлыкка килде. Киеренкелекне сиздe булса кирәк, капитан миңа ярдәмгә ашыкты:

— Ленинградта да бар ул мөселман мәчете. Мәскәүнең үзендә дә. Урта Азиядә аларның чиге-саны юк. Сезнеңчә, аларны да җир белән тигезләп ташларгамыни?

— Урыннарын да калдырмаска,— диде моторчы Сусликов. — Газета битләрендә мөселман динен тәнкыйтьлибез, ә үзебез шул басурманнарга дин тотарга рөхсәт итәбез. Мин аларны... — Николай Ивановичка фикерен әйтергә комачаулап, икенче механик Кизилов аның кабыргасына төртте.

— Җитәр инде. Башкаларга авыз ачарга да ирек бирмисең. Агрессор, экстремист син, Сусликов.

— Сез төрекләрне кыргыйга саныйсыз,— дидем мин.— Шул кыргый төрекләр дә, Константинопольне алгач, Айя Суфия храмын исән калдырганнар. Татар-монголлар да алла йортына тимәгәннәр. Мәскәүдәге Андроник монастыре, Владимир, Суздаль чиркәүләре барысы да исән.

Җавап бирүче булмады. Диңгезчеләрне Ленинградта, Мәскәүдә, шул ике башкалада мөселман мәчетләре булуы тәмам тетрәткән иде. Нинди эш бу, дип уйлыйлар иде алар, хуҗалар кая карый? Көчсезлек, җебегәнлек бит бу...

Сараево артта калды. Татар тәкъдирендәге шикелле упкыннар, гигант сөңге булып күккә кадалган таш кыялар, упкын төбеннән боргаланып аккан көмеш чишмәләр әкренләп кичке эңгер эченә кереп яшеренә башладылар. Баш өстендә асылынып торган бөркет оялары әле сүнеп өлгермәгән шәфәкъ яктылыгында аеруча тылсымлы күренәләр иде.

Мостар каласын узгач, без аска, Әдрән диңгезенә таба төшә башладык. Автобусның тыны җиңеләйде. Ул торган җиренә якынлашкан ат шикелле, күндәм генә үзәнлеккә таба тәгәри.

Дубровникның утлары күренгәндә төн урталары җитеп килә иде инде. Автобус диңгез буе тигезлегеннән портка таба ашыга. Уң якта Дубровник порты ачылды. Ерак диңгезләрдән килгән зур тимер кораблар кабыргаларын причал ташына терәп хәл җыялар. Портка керергә чират көтүче гигант көймәләр төнге утларын яндырып, шәүләләре белән янәшә йокыга талганнар.

— Әнә «Алексей Щусев» безне көтеп тора,— диде матрос Шулев.— Уң яктан санаганда өченче.

— Туры корабка барабызмы? — диде өлкән ярдәмче Василевский.

— Бераз йоклап, ял итеп алырга кирәк,— диде Михаил Александрович. Шоферга карап өстәде.— Сез инде экипажны кунакханәгә илтеп куегыз. Анда безнең өчен номерлар әзерләп куелган.

Автобус Дубровникның иң әйбәт отеле «Гарна Питка» бинасы янына килеп туктады. Тән оеган, аяклар камыр шикелле. Номерга керү белән, чишенергә дә өлгермичә, караватка аудык. Гомеремдә иң кыска тоелган төн иде бу.

## Тугызынчы тәүлек. Дубровник. 09.00.

Иртәнге чәйгә уяттылар. Шулкадәр торасы килми. Нишлисең бит, торырга, юынырга, чәйдән соң корабка барып, эшкә керешергә кирәк. Чәй янында утырганда әле күпләрнең күзләрендә йокы иде.

Әнә су өстеннән калкып торган гигант тимер хисар әкрен генә безгә якынлаша. Берничә минуттан без аның палубасында булачакбыз. Анда безне эш көтә. Хезмәт һәм вазифа, устав һәм тәртип саклау, җәмгыять эше һәм югарыдан төшерелгән күрсәтмәләрне үтәү, сагыну һәм кайтасы көннәрнең озынлыгы белән көрәш көтә безне ул корабта. Киләчәк көннәрнең билгесезлеге. Кораб дус, әйт әле, син безгә нәрсәләр әзерләп куйдың?Ниләр күрсәтерсең икән?

Әнә койрыкка урнашкан корылман. Анда каюталар. Триумфаль аркага охшаган ике мачтаң, алар юан, нык, чөнки кораб авыр техника, төрле контейнерлар ташырга көйләнгән. Форштевень очып барган кошның алга сузылган муенын хәтерләтә, трюм капкачлары киң, контейнер төяр өчен уңайлы. Әнә корылма өстендәге флаг күтәрү өчен көйләнгән чатлы өченче мачтада локатор антеннасы әйләнә. Локаторны туктатырга оныткannар. Койрыкта җилфердәгән флаг искергән, кояшка уңган. Без килүгә яңа флаг асарга кирәк иде, бәйрәм бит. Аларның да кайту юлына кузгаласы көннәре. Нишләп алар шун-

дый гади, иң тәҗрибәсез диңгезчегә дә аңлаешлы нәрсәләрне оныткаиннар? Хәлләре бик начар микәнни?

Якынрак килгәч, кораб тәнен баскан тутыкны күрдек. Бортлар, корылмалар, хәтта рангоутлар да кутыр баскан корчаңгы ат тәнен хәтерләтә иде. Тропик кояшы буяуларны ашап бетергән, шторм вакытында тозлы су грунтовканы юып ташлап, тимерне ашап кергән. Корабны эшкә индерү өчен күпме көч, күпме вакыт кирәк булачак! Тирәнтенрәк уйлап караганда, һәр кимчелекнең отышлы ягын табарга була. Озакка сузылган озын сәяхәттә сагынуны һәм төшенкелеккә бирелүне эш белән, бары тик җентекләп оештырылган югары нәтиҗәле хезмәт һәм актив, рухны баета торган күмәк ял белән генә җиңәргә була. Тутык белән көрәшүне, корабны эшкә индерүне экипажга сиздермичә генә шундый юлдан юнәлтергә кирәк.

Алда безне ерак юл көтә. Томанлы офыклар, яңа портлар, куанычлар, җаныңны чыгарырлык тайфун-торнадолар. Яңа кешеләр, очрашулар, ят гореф-гадәтләр, туган илгә кайтуны зарыгып көтүләр. Шуларның барысы да алдыбыздагы кораб эчендә посып торалар иде. Кораб, дускаем, афәтле җирләрне урап узсаң иде син?

Катер «Алексей Щусев»ның диңгез өстенә тия язып торган парад трабы янына килеп туктады. Узган елны бу корабта өч ай йөзгән идек без. Шушы кораб палубасында Равеннада торганда яңа ел каршыладык. Ул чакта капитан Гремин ялда иде. Без «Алексей Щусев»ның штаттагы капитаны Эдуард Дмитриевич Синько белән эшләдек.

— Тәмам эштән чыгарганнар мескенкәйне,— диде боцман Савчук.— Моны кире эшкә индерү өчен, ай-һай, егетләр, ким дигәндә ярты ел вакыт кирәк.

— Иң җиңеле башкаларны гаепләү,— дидем мин.

Безне көткән экипаж палубага җыелган. Үз гомеремдә авиациядә хезмәт иткәндә, сугыш елларында, бер таңнан икенче таңга кадәр эшләп арыган атлар, алҗып хәлдән тайган кешеләр күргәнем булды минем. Бу инде йончу гына түгел иде. «Алексей Щусев» теплоходының экипажы күбесенчә өрәкләрдән тора иде. Тугыз ай ярым ялсыз, бәйрәмсез, көнетөне, атналар, айларга сузылган сагыну, җил-давыллар, чайкалу, вибрация, аста дөбер-шатыр килеп машина эшләве, төнге авраллар, уяулык һәм тагын бер тапкыр уяулык, дип туктаусыз күрсәтмәләр килеп торуы. Гел таза ирләр җыелган җирдә шәфкатькә, назга, җенси тормышка сусау. Шундый шартларда иң башлап корычтай тәртип, сәгать механизмы дәрәҗәсендә оештырылган көндәлек хезмәт, кешелекле мөнәсәбәт, йомшак мөгамәлә һәм гаделлек кирәк. Тән аруына, җан, бәгырь аруы кушылганда энә очы чаклы гаделсезлек ат башы чаклы булып күренә башлый. Бу очракта дөреслек, хакыйкать үрнәк дәрәҗәсендә сакланырга тиеш.

Көндәлек тормышта, вак-төяк мәшәкатьләргә чумып яшәгәндә, без югары пафослы изге сүзләрнең мәгънәсенә әһәмият бирми башлыйбыз. Әгәр коллективта югары идеалларның яңгырашы сүнсә, никадәр тырышсаң да, әхлак һәм иман чисталыгын саклый алмыйсың. Без бит революция елларында яңгыраган «Азатлык, тигезлек, хакыйкать» шикелле бөек лозунгларны бюрократлардан таптатып харап иттек. Халык безгә ышанмый, безне тыңламый башлады һәм без шуңа зарланып, шыңшып йөрибез. Бөек сүзләр трибунадан гына кычкырылырга тиеш түгел. Аларның мәгънәсе тормыш һавасында яшәргә тиеш. Ничә тапкыр сынап караганым бар: озакка сузылган сәяхәттә шул бөек идеалларның исән саклануы һәркайчан рухи канәгатьлек китерә.

«Алексей Щусев»ның төп экипажы корабны безгә тапшырып, кайтып китәчәк. Өйдә аларны очрашулар, ял көтә, тулы сулышлы яшәү көтә. Өч-дүрт айдан сәяхәт авырлыклары онытылачак. Алар тагын диңгезне, корабтагы күмәк ялгызлыкны сагынып, кыбырсый башлаячаклар. Без Ждановта чакта ук, кадрлар бүлегендә үткәрелгән киңәшмә вакытында корабның һәм корабтагы мөлкәтнең һәр бөртеген

жентеклəп тикшереп кабул итү турында алдан сөйләшеп куелган иде. Шушы чиктән тыш йончыган кешеләр белән һәр төзексезлек, һәр сынган отвертка, һәр яньчелгән противогаз тартмасы турында бәхәсләшеп, акт төзи башласак, аларны туп-туры теге сарыга буялган йортка кереге дучар итәчәкбез.

— Михаил Александрович,— дидем мин капитанның колагына. — күрәсезме палубада безне көтеп торган кешеләрне?

— Күрмичә, мин бит сукыр түгел.

— Шундый кешеләр белән тапшыру-кабул итүне тиешле дәрәҗәдә оештырып булыр дип уйлыйсызмы?

Культура, эрудиция һәм зыялылык җитмәсә дә, бу кеше диңгезче иде. Капитан мине аңлады. Ул кабул итү-тапшыруның нинди нәтиҗәгә ирештерәчәген тулысынча күз алдына китерә алды.

— Өлкән комсостав, бер генә минутка катерда калып торыгыз әле,— диде капитан Гремин. Без, өлкән механик, өлкән ярдәмче һәм мин катердан трапка сикерүче экипаж әгъзаларына иярмичә, катерның койрыгына юнәлдек.

— Тизрәк кабул итегез. Ваклашмагыз. Күргәнсездер инде, аларның безнең белән бәхәсләшеп торыр хәлләре юк. Алҗыганнар. Озакка сузарга тырышмагыз.

— Соң бит, соңыннан, эшли башлагач, ул-бу чыкса, прокурор мине җавапка тарттырачак,— диде озак, төпченеп кабул итәргә әзерләнгән өлкән механик Горбаненко.

— Мине дә, Миргазиян Закировичны да тарттырачак. Аңлады-гызмы минем боерыкны? — диде Михаил Александрович.

Палубага менү белән, тукталып тормыйча, туры капитанның беренче ярдәмчесе Садовников каютасына юнәлдем. Моннан тугыз ай ярым элек эшне мин аңа тапшырган идем һәм ул миңа сәләтле политработник күренгән иде.

— Нихәл?— дидем бусаганы атлау белән.— Рейс ничек үтте?

— Чәнчелеп киткере рейслар! Алты айдан алыштырабыз, дип ант иттеләр. Тугыз ай ярым эшләдек. Сингапурга, Филиппин атауларына, Гонконгка барып кайттык. Өч тапкыр Һиндстанның барлык портларын диярлек әйләнеп чыктык. Өч баруыбызда да иң авыр чакка туры килдек. Парлы мунча анда. Ашау үтми. Йокы әллә кайчан качты. Тәэмин итүләре аннан-моннан, бер генә тапкыр эшне кайгыртып якты йөз белән карасыннар иде. Адәм актыклары! — диде Садовников пароходчылыкта утыручы түрәләр турында.

— Әйдә, биш кенә минутка капитан Синько янына кереп чыгыйк әле. Мин бит аның белән син килгәнче өч ай шушы корабта эшләдем,— дидем мин коллегама.

— Теләсәң, кер. Мин кермим, йомышым юк. Дөресен әйткәндә, гарык мин аннан.

Һәм мин капитан белән беренче ярдәмченең боткалары пешми башлаганны, араларыннан кара песи йөгереп узганын аңлап алдым. Бусы инде бөтенләй ярамый, бөтенләй начар нәрсә. Җитәкчеләр ызгышуы, алар арасында упкын барлыкка килүе экипажга өстәмә киеренкелек, өстәмә авырлыклар сала. Мин, ничек булса да, экипажның иминлеге, эшнең уңышлы баруы өчен түзәргә, капитан белән, командирлар һәм бүтән бер генә кеше белән дә мөнәсәбәтне өзмәскә, гауга кузгатмаска тиешмен.

Мин кергәндә капитаннар дустанә генә сөйләшәләр иде. Эдуард Дмитриевич колачын җәеп каршы алды. Кочаклаштык. Капитанның шәрә кабыргаларын кулым сизү белән йөрәгемә курку йөгерде. Эдуард Дмитриевич йончуның соңгы ноктасына җитеп, дистрофиягә юлыга башлаган иде. Бәлки безне дә шушы хәл көтә торгандыр?

Өч ай эчендә без капитан Синько белән дуслашып өлгергән идек. Аның йөзү тәҗрибәсе Греминныкыннан кимрәк иде. Белем ягыннан

Михаил Александровичны ул әллә кайларда калдырып узган. Безнең пароходчылыкта Синько шикелле белемле капитаннар күп дигәндә дүрт-бишкә җитә торгандыр. Инглиз, итальян, француз телләрен су кебек эчә. Немецчә сукалый. Минем белән эшли башлагач, татарча өйрәнергә тотынды.

— Хәзер инде татарча сөйләшкән кешене Казанның үзендә очратуы кыен. Нигә ул сезгә татар теле? — дим.

— Матур тел бит,— ди Эдуард Дмитриевич. — Нинди тирән, киң мәгънәле сүзләр бар.

Аның татар телен нигә өйрәнүен соңрак аңладым. Нәкъ шул чакта сәяхәттән кайтышлый без Истанбулга туктадык. Синько төрекләр белән татарча сөйләшергә кереште. Ә мин юләр, ничә тапкыр Төркиядә булып, алар белән үземнең туган телемдә сөйләшергә тартынганмын. Эдуард төрекләргә аларның телен өйрәнә башлавы турында белгерткән. Төрекләрдәге патриотлык — алар капитаныбызга бүләк ташый башладылар. Агент Эдуард Дмитриевич аша минем татар иканлегемне ишеткән һәм икенче көнне иртән каютама искиткеч югары сыйфатта басылган «Төрки халыкларның сәнгать тарихы» дигән алты томлы китапны күтәреп килгән. Әле һаман үкенәм һәм тиргим үземне. Мин ул китапларны алырга курыктым. Көнчелек безнең тормышка үрмәкүч оясы шикелле ябышкан. Ул безнең яшәү белән идарә итә диярлек. Мин курыктым. Нәрсәгә алыштырып алдың бу китапларны, дип таможнячылар бәйләнер, янәсе.

Һәр халыкның, теленнән тыш, бары аңа хас интонация, сөйләшкәндә кулланыла торган ишарәләре, мимикалары була. Капитан Синько шул нечкәлекләрне искиткеч тиз эләктереп ала да гаҗәп оста куллана белә иде. Тел белү — дуслашуның сиксән проценты. Чит ил кешесе белән элемтәгә керергә, аны аңларга, аны дус итәргә теләсәң, син аның туган телендә сөйләшергә тиешсең. Инглиз колонизаторларын җирле халык нигә өнәмәгән? Ул турыда мәзәк тә бар. Бер инглиз туристы: «Менә инде җиде ел Парижда гел шул киосктан газета-журналлар сатып алам, ә киоск хуҗасы шушы көнгә кадәр инглизчә сөйләшә белми», дип зарлана икән.

Чит ил кешесе белән сөйләшкәндә әгәр син аныңча күзаллый, аныңча тоя белмәсәң, аңлашу барлыкка килми.

Капитан Гремин белән өч ел эшләп, аның белән без өч тапкыр да чит ил портларында йөри алмадык. Ул гел корабта утыра. Шәһәргә чыгарга чакырсаң, анда минем нәрсәм калган, дип кенә җавап бирә. Эдуард Дмитриевич белән без Равенна, Венеция, Барселона, Таррагона, Валенсия, Аликанте, Касабланка, Бәйрут, Валлетта портларын баштанаяк айкап йөрдек. Венециянең барлык музейларын, һаррис-барны, аның данлыклы ресторannарын, шәһәрне урап алган атауларны: Мурана, Бурано, Торичеллоны карап чыктык. Шушы шәһәрдә ким дигәндә җитмеш тапкыр булып, Синько белән очрашканчы, монда әрмәннәр атавы Сан Ладзароны күргәнем юк иде. Равеннада торган чакта төнге дискотекага бардык. Байрон һәм Данте яшәгән йортны, Теодорих патша төрбәсен, Галла Плачидия мавзолеен, хәтта бу каладан йөз илле чакрымдагы Сан-Марино дәүләтен карап кайтырга өлгердек. Әгәр Синько белән эшләмәсәм, Барселонадан йөз утыз чакрымда урнашкан Сальвадор Дали музеен күрә алыр идеммени? Истанбулда безгә татарлар җыела торган төнге клубка кадәр күрсәттеләр. Миңа мәңге онытылмаслык хатирәләр бүләк иткән капитан белән без тагын очраштык.

— Минем шундый сирәк очрый торган эчемлекләрем бар,— ди Эдуард Дмитриевич.— Ә болары — китаплар. «Кама сутра»ны карап чык. Менә никадәр китап җыйдым. Аларны, билгеле, күтәрерлек түгел, калдырам.

Мин Греминга карыйм. Ул аларны бүген үк, Синькодан каютасын

кабул итеп алу белән диңгезгә томырачак. Әгәр аның чит телдә язылган китап укып утырганын күрсәләр? Әгәр тиешле оешмаларга аның чит ил эшләре белән кызыксынуын хәбәр итсәләр? Юк, ул совет корабының капитаны: уяулык, уяулык һәм тагын бер тапкыр уяулык.

Менә әле дә бер өстәл янына утырып сөйләшкән ике капитанны күзәтәм. Греминның өстендә диңгезчеләр формасы. Җиңендә укалы шевроннар. Стенадагы Эдуард Дмитриевич аскан картиналарга күзе төшкәндә аның чырае сытыла. Иртәгәдән каюта үзгәрәчәк. Корабтагы тормыш та йөз сиксән градуска үзгәрәчәк һәм сөйләшүләрнең темасы бөтенләй башка булачак. Их, бер генә тәүлеккә булса да Синько белән Джозеф Конрад әсәрләре турында, Моби Дикның астын өскә китереп, сюрреалистлар турында, экзистенциализм философиясен тикшереп, шуларның барысы турында тамак карлыкканчы бәхәсләшеп, бер тәүлек, бары бер генә тәүлек яшисе иде. Әнә Синько ничек киенгән: аягында «пума» кроссовкасы, искиткеч кыйммәт тора ул аяк киеме, Михаил Александрович аны үлсә дә алмаячак. Капитан Синько банан чалбар кигән, өстендә зәңгәрсу соргылт юка тукымадан теккән илле кесәле, җитмеш җиде молниялe авангард модалы куртка. Соң бит капитанлыкка ирешүчеләрнең күбесе мәңгелек канунга — урындагы кешеләрнең торгынлык саклауларына ябышып, яңалыктан өркеп, яңа сүзгә, яңа карашка юл бирмичә картаялар. Иртәгә бу каютада торгынлык, югарыдан төшерелгән күрсәтмәләр сулышы хөкем итә башлаячак.

— Миргазиян Закирович,— диде капитан Гремин сөйләшүдән туктап. — Эдуард, экипажларны җыеп митинг үткәреп тормыйк, ди. Алар ике сәгать эчендә тапшырып бетермәкче була. Кабул итеп алу өчен сезгә күпме вакыт кирәк?

— Ун минут,— дидем мин. Михаил Александрович кашын җимерде, Эдуард Дмитриевич рәхәтләнеп елмайды.

— Солидный кеше түгел комиссарым,— диде капитан Гремин.— Кабул итү вакытында шулкадәр җентекләп, шул кадәр дикъкать биреп тикшерергә кирәк, ә Миргазиян Закирович...

— Әгәр без аның белән эшләгән булсак, экипажны болай арытмый идек,— диде Эдуард Дмитриевич безнең капитанның сүзен бүлеп.

Кайчакта тәкъдир бер-берсе өчен яратылган кыз белән егетне кавыштырмый. Тәкъдир кайвакыт бергә эшләр өчен яралган капитан белән беренче ярдәмчене дә кушылдырмый. Бар ул шундый каһәрле бер көч, һичшиксез, бар...

Каютама әйләнеп кайттым.

— Кайсы портларда нинди үзгәлекләр, нинди катлаулы проблемалар очрый? Чит ил портларында кемнәргә таянырга, интернациональ эш алып бару өчен кемнәрне чакырырга һәм кемнәрдән сак булырга? Шуларны кыска гына итеп сөйләп бирегез әле,— дидем коллегама. Ул миңа җавап кайтармады. Синько янына кереп, аның хәлен белеп чыккан өчен Садовников ачу тота иде.

Син бит, дускаем, Михаил Александровичны шул кадәр бәхетле итә алыр идең, дип эчемнән генә офтанып куйдым. Бергәләп Валентин Пикульны укып шатланыр идегез. Джинс, банан чалбар киеп йөрүчеләрне битәрләп, джаз тыңлаучыларны сүгеп ләззәтләнер идегез. Их, тәкъдир!

Тапшыру-кабул итү турында тиз генә акт төзеп, кул куйдык. Актның бер нөсхәсен капитанга кертеп тапшырырга юнәлдек. Садовников мине коридорда көтеп торды. Синько белән йөзгә-йөз очрашмаска нәзер әйткән иде булса кирәк. Мин аны керик дип кыстап тормадым инде. Безнең каютага ике буфетчы кыз кереп, әсбапларны барлап чыкты. Машина бүлегендә мотористлар, токарь, механиклар бер-берсенә эшләрен тапшыра. Палубада, матрослар, подшкипрскидә, буяулар саклана торган кладовкада ике боцман, штурманнар мәш килеп навига-

ция приборларын, карталарны, корабның кассасын һәм кораб документларын бер-берсенә тапшырып йөриләр. Кыямәт көне. Җиде миллионлык кораб һәм унбер миллион сум торган йөк, ниһаять, безнең кулда.

Без — миллионерлар...

Эдуард Дмитриевич, хәзер инде капитанлык куәтен, аның бөеклеген, дәрманын Греминга биргән гади кеше, катерга утырып азапланучы экипажына боерык бирә:

— Ярга чыгу белән катерны кире җибәрегез. — Аны ишетүче юк диярлек. Һәркем үз чемоданы, төргәкләре белән мәшгуль.

— Эдуард Дмитриевич, катер зур, сез аңа барыгыз да сыясыз,— ди безнең капитан.

— Юк, икенче рейс белән ярга чыгам,— ди Синько, һәм мин экипажның чатнап икегә аерылганын сизеп алам. Катерга утырып китүчеләр экипажның яртысыннан күбесе — беренче ярдәмче Садовников яклы кешеләр. Капитан яклылар корабта калды.

Ара бозылу һәркайчан бер пүчтәк кенә нәрсәдән башланып китә. Сәяхәттән кайтып, бераз ял иткәч, шушы турыда уйлап карасаң, син шул сукыр бер тиенлек вакыйганың шундый аяусыз гауга кубуга сәбәп була алуына ышана да алмыйсың. Менә әле дә ике акыллы, икесе дә тәҗрибәле, ихтирамга лаеклы диңгезчеләр нәрсәнедер бүлә алмыйча, бер-берсен куралмыйча, үзара дошманга әйләнгәннәр. Адәм баласының психологиясе шундый катлаулы. Белмим, без аны өйрәнә, аңлый алыр хәлгә ирешербезме икән?

Ишек шакыдылар.

— Рәхим итегез.

Озын буйлы, матур таза егет, китәсе экипажның боцманы Владик Тарковский, аңа ияргән ипи пешерүче кыз каютама килеп керделәр.

— Без, Миргазиян Закирович, киңәш сорап килдек,— диде боцман хәл-әхвәл дә сорашып тормыйча.— Без Миңзифа белән сәяхәт вакытында язылыштык. Капитан безнең никахны кораб журналына теркәде.— Боцман туктап тын алды.— Эш менә нәрсәдә, Миргазиян Закирович, Миңзифаның этисе аңа руска кияүгә чыгарга рөхсәт итмим, дип алдан кисәтеп куйган. Миңзифа этисеннән курка. Өйгә кайтып тормыйк, туп-туры берәр якка китик, ди.

— Нишләп соң син, сеңелем, язылышкач кына курка башладың?

Миңзифа югалып калды. Мескен тотлыга, җавап эзли, таба алмый.

Егет таза, чибәр, күкрәкләр, куллар — бар җире сокланырлык. Җавап менә шунда. Мин аны аңлыйм. Кыз да сылу. Өстәвенә, Миңзифаның үзен-үзе саклый белүе, намусы, горурлыгы турында ишеткән идем.

— Без өйләнешкәндә Миңзифаның этисе ерак иде,— дип аңлата кияү. — Ә хәзер аның янына кайтып, күзенә күренергә...

— Курыкмагыз,— дидем.— Миңзифаның этисен аңларга була. Дөрес, Советлар Союзындагы милләтләр бер семья булып яшиләр. Гаилә тормышында ике милләт вәкиле арасындагы катлаулылыклар, гадәттә, милли гореф-гадәтләрне ихтирам итмәүдән туа. Әгәр сез, Владислав, татар гореф-гадәтләренә ихтирам белән карасагыз, кызын яратып, аңа хыянәт итмичә яшәсәгез, Миңзифаның этисе бәхилләячәк.— Нотыгымның очына чыга алмый калдым. Катер әйләнеп кайтты. Яшьләрне катерга чакырдылар.

Капитан ягын тотучы диңгезчеләрне күзәтәм. Гауганың сәбәпчесе — өлкән механик — искиткеч тупас, дорфа кеше. Эшне миннән кабул итеп алганда ук Садовников аны экипаждан куарга ниятләгән иде. Капитан өлкән механикны яклаган булса кирәк. Радиостанция башлыгы, боцман, өлкән матрос, дүртенче штурман, өлкән моторчы һәм буфетчы кыз. Төгәл ун кеше капитан ягында калган. Экипажның өчтән бер өлеше дә юк. Коллегам коллективның житмеш про-

центын үз ягына аудара алган. Бу бит әле күләм генә. Радиостанция башлыгы — партоешма секретаре, боцман — профком председателе, дүртенче штурман — комсорг һәм өлкән моторчы — халык контроле председателе. Помполит өчен чын җиңелү бу. Ничек инде үзеңнең барлык таянычларыңнан колак кагарга?

Катер кузгалды. Безгә кул болгыйлар. Саубуллашу гудогы бирдек. Җавап гудогы яңгырады. Дөбердәп брашпиль әйләнергә тотынды. Якорь чылбыры салмак кына судан чыгып клюзга керә, барабан аша үтеп, якорь тартмасына коела. Ниһаять, якорь күренде. Якорьга ябышып чыккан ләм шыбырдап суга төшә. «Алексей Щусев» хәрәкәткә килде.

Сау бул, Җир! Яшә, тынычлык!



## Уникенче тәүлек. Хиҗаз. Җиддә порты. 13.00

Җиддә портында йөк бушатабыз. Моторчы Сусликов бүген мәгърифәтче. Ул халык агартучы ролендә палубага җыелган дингезчеләргә лекция сөйли.

— Бу порт,— диде ул һәм дөбер-шатыр килеп борын эчен бушатты.— Бу порт — мариманнар, мөселман динен тотучыларның җыела торган урыны. Шушында җыелгач, аларның барысын да чишендереп, шәрә калдыралар ди. Штанын салдыртып карамыйча, кешенең мөселманмы, түгелме икәнлеген белеп булмый, аңладыгызмы?

— Ә хатын-кызның мөселманмы-түгелме икәнлеген ничек беләләр? — дип сорый матрос Дулев.

— Синнән сорап.— Николай Иванович матроска ачулы караш ташлый.— Салага, сүзне бүлмә. Тикшереп бетергәч, аларны сафка тезәләр дә Мәккә дигән шәһәргә мукәйләтеп алып баралар, ди. Мәккә — аларның изге шәһәрләре. Шул шәһәрнең зиратына мөселманнарның алласы Мөхәммәт күмелгән. Шуның табуты җир белән күк арасында асылынып тора ди.

— Берәр төрле магнит белән тоттырып куйганнардыр аны,— дип төзәтеп куйды Сусликовны моторчы Петлюга.

— Әй син, контрабандист, салака башың белән өлкән кешенең сүзен бүләсең. Тагын бер сүз ычкындырсаң, куып җибәрәм. Хаҗ кылучылар шул табут тирәсендә такмак әйтеп, арып егылганчы биниләр ди. Биеп арыгач, һәр кешегә бер тере сарык бирелә ди. Шул сарыкны суеп, битләрен канга буйыйлар да бер утыруда аның итен ашап бетерәләр ди. Статистика хаҗ кылучылар арасында ел саен унбиш процентка якын кеше корсаклары ярылудан үлә дип күрсәтә. Ит ашалып беткәч, аларга чалма өләшәләр ди. Әнә, причалда йөргән чалмалыларның барысы да хаҗда булып кайткан кешеләр.

Төшке аштан соң палубага җыелган кешеләр — Сусликовның шәкертләре. Алар дикъкать белән тыңлап утыра. Дөрес, тыңлаучылар Сусликовка тулысынча ышанып та бетми. Алар бернәрсәгә дә тулысынча ышанмыйлар. Беренчедән, алар Сталинга инанып яшәгән буынның балалары. Безнең эти-әниләр шикелле фанатик рәвештә буйсынып ышансак, нәкъ алар шикелле алданырбыз, дип куркалар. Икенчедән, тыштан ышанган булып кыланып, эчтән инкяр итү аларга чиктән тыш файдалы. Бу очракта рәхәтләнеп бурычсыз, кыйбласыз яшәргә була. Бу очракта сиңа берни изге түгел. Төкер бар нәрсәгә, тет, тапта.

Ышанмасалар да, алар Сусликовны бирелеп тыңлый, чөнки гарәпләрне, аларның көнкүрешен, гореф-гадәтләрен, тарихларын белмиләр. Дөрес, алар мәктәптә тарих укыдылар. Экипажның утыз өч кешесе арасында укыганны хәтерендә калдырган өч-дүрт кеше бармы икән? Белем урынына аттестат, диплом алып чыктылар алар. Түштә значок. Дөрес, кызык та түгел иде ул тарих дигән нәрсә. Вавилон чоры —

сыйныфлар арасындагы көрәш. Мисыр заманы — шул ук хәл. Россия тарихында да изүчеләр һәм изелүчеләр арасындагы мәңгелек көрәш. Изү һәм изелү, сугыш һәм тынычлык, азатлык һәм басып алу турында алар күп ишеттеләр мәктәп елларында, ләкин аерым вакыйга, тарихи шәхес, конкрет факт, ни сәбәптер, истә калмаган.

Мөселманнар яшәгән төбәкләргә тәре походлары ябырылуы, колонизаторларга каршы кулга корал тотып гасырларга сузылган канлы сугышлар, кемнеңдер тәхеткә менүе, кемнеңдер төшүе — андый нәрсәләрне саный башласаң... Тарих онытылган, хәтердә мөселманнарның торгынлыгы, мөселман өммәтеннән булган кешенең берьюлы берничә хатынга өйләнүе — хәтердә шулар гына сакланып калган. Хәзер алар гарәпләрне үз күзләре белән күрәләр. Кызыксыну кабынып китә. Кайдан башларга? Мәктәп тарихы тулысынча диярлек онытылган, шуңа күрә Сусликов сөйләгәнне кызыксынып тынлыйсың.

Без Җиддә портында контейнерлар бушатабыз. Бристоль, Гамбург, Антверпен, Роттердам, Бремен, Дюнкерк портларында төялгән контейнерлар. Аларның эчендә нәрсә генә юк: йорт җиһазлары, киемсалым, магнитофон, радиоалгыч, телевизор, суыткычлар, ясалма климат аппаратлары, төзү материаллары, җиңел машиналар. Акча күп. Акчаны кая куярга да белмиләр Согуд гарәпләре. Өстәвенә, ул акча — эшләп, интегеп тапкан эш хакы түгел. Согуд гарәбе, шушы илнең гражданы булган өчен генә түләнгән акча, шунлыктан, аласы әйбернең хакына карап торган юк. Әле күптән түгел чүлдә күчмә яшәгән бәдәвиләр товарларның иң затлысын, иң кыйммәтлесен ала. Мин үземнең Татарстаным турында уйлап куям. Эчем ачытып китә. Без дә бит туган җиребезнең карыныннан миллион, йөз миллион тонналар нефть чыгардык. Аны чит илләргә валютага саттык. Нефть суырылып беткән җирләрдә балчык белән сылап ясалган бараклар һәм таптап, нефтькә буяп пычратылган, юкка чыгарылган табигать, кипкән елгалар, агачы киселеп беткән урманнар калды. Җиреннән кара алтын чыгару нинди файда китерде Татарстанга?

Кайчандыр чүлдә чатыр корып яшәгән гарәпләр Зәңгәр Ривьера курортларында ял итә. Аларда да дәвалану түләүсез. Согуд гарәпләре дәваланырга Швейцария, Франция һәм Италия шифаханәләренә йөри. Юл чыгымын, шифаханә хакын һәм дару өчен дәүләт түли. Урта диңгез ярларыннан, Босфордан, Атлантик океанның матуррак урыннарыннан Согуд гарәпләре, җир сатып алып, дачалар сала башлады.

Минут саен порт капкасыннан контейнеровоз пассажир лайнеры калдырып киткән контейнерларны чүл ягына ташып тора. Чүлдә, борынгы кәрван юлларында җиңел машиналар агымы.

Җиддә портын мин беренче тапкыр 1958 елда күрдем. Ком басып киткән бәләкәй генә ике причалдан тора иде порт ул чакта. Шуның берсенә хаҗ кылырга килүчеләрне ташый торган пассажир пароходы, икенчесенә агачтан ясалган җилкәнле көймәләр — самбуклар туктый иде. Кала үзе ике-өч катлы саман йортлардан тора иде. Бары тик сырлап эшләнгән ишек, тәрәзә капкачлары, художник Верещагинның «Тамерлан ишеге» дип аталган картинасындагы бизәкләргә охшашлы сәнгать игътибарга лаек иде. Егерме биш ел эчендә монда бөтенләй яңа шәһәр үсеп чыккан. Японнар яңа порт төзегән. Японнарның өлгерлегенә исем китә. Кая карама, алар нәрсәдер төзи. Сүәеш каналын киңәйтүдә алар, Гыйракта, Күвәйттә, Мозамбикта, Сальвадорда, тагын әллә кайларда. Кара эшкә алар Көньяк Корея, Филиппин, Пакистаннан килүчеләрне җигә. Японнар үзләре проект төзү, техника ягын һәм житәкчелек итүне өсләренә ала.

Гарәпләр турында дусларым Сусликов сөйләгәнчә хәбәрдарлар. Аларның ураза тотуын, өч-дүрт хатынга өйләнүен һәм бабага утыртылганлыкларын беләләр.

Японнар турында мин, Хәсән, Халхин-Гол сугышлары чорында

ишетә башладым. Ул чакта газета битләре японнарны сурәтләгән карикатуралар белән тулган иде. Япон самурае — атныкы шикелле ыржаеп алга чыккан эре тешле, тәбәнәк буйлы, кәкре сыйраклы, биленә озын кылыч аскан бер ташка үлчим нәрсә. Үсмер чак хатирәләре, аның риясыз ышанулары гомергә диярлек сакланып кала. Мин японнарны һаман шул карикатурадагыча күз алдыма китереп йөрдем. Юрий Нагибинның япон режиссеры Акира Курасава турындагы мәкаләсе мине көтмәгәндә тетрәндерде. Акира Курасава самурай нәселеннән икән. Ул үзе дә самурайларча тәрбияләнгән. Япон режиссерының сәнгатькә тугрылыгын, аның намусын, чынбарлыктан тайпылмас булуын Юрий Нагибин самурайлыкка бәйли. Шул ук фикерне Всеволод Овчинников һәм Владимир Цветовның китапларында очратырга була.

Японнарның җыйнаклыгы, эшне сыйфатлы башкарулары патриотлыкка бәйле. Японнар күзлегеннән караганда патриот — хезмәт сөючә, тыйнак, намуслы һәм ул беркайчан да үзенең ватанга тугры булуы турында шапырынмас. Мин патриот — дип орден-медаль дә сорамас һәм җыелышта президиумга да менеп кунакламас. Ул бары тик тыйнак кына, тырышып, һәрвакыт сыйфатлы итеп эшли бирер. Безнең татарларда патриотлык бөтенләй башкача сыйфатлана.

Утызынчы елларның икенче яртысын мин яхшы хәтерлим. Безнең авылның баш патриоты, ячейка секретаре булып эшләүче Тыңкыш Гәрәй җыелыш саен трибунадан: мин совет власте өчен җанымны бирергә риза, дип күкрәгенә суга-суга әтәчләнә иде. Митинг вакытларында Исергәп авылында миннән башка бер генә дә ватанын сөюче, бер генә дә хөкүмәткә тугрылыклы кеше юк, дип кычкыра иде. Фәлән агай контра, төгән агай кулак тегерменәнә су коя, дип Тыңкыш Гәрәй авылыбызның иң тырыш, иң эшчән кешеләрен сөргенгә җибәрә торды. Тыңкышның үз хуҗалыгы таралып ята. Аның төп эше авылдашларын куркытып, йорт саен кереп эчеп, сыйланып йөрү иде. Исерек чакларда авылның баш патриоты: «Мин Исергәп авылының соңгы контрасының тамырына балта чапмыйча туктамыйм»,— дип мактана иде. Чыннан да, шул ялкау, шаталак һәм мәнсез кеше аркасында авылның иң-зыялы, иң тырыш кешеләре кулак рәтенә кертелеп, туган җирләреннән сөрелделәр. Һәм иң талантлы игенчеләрнең тар-мар булуыннан авыл шушы көнгә диярлек мантый алмый.

Төш вакыты җитте. Йөк бушату дәвам итә. Порт территориясенә салынган мәчет манарасыннан азан тавышы яңгырады. Кран эштән туктады. Кранчы причалга төшеп намазлык җәйде. Машина йөртүчеләр моторларын сүндереп, җиргә төштеләр. Докерлар палубага намазлык җәеп, кыйбла якка, причалдан бары тик кырык чакрымда яткан Мәккәгә таба карап, башларын ия төшеп, намаз укырга керештеләр. Намаз укучылар арасында Согуд гарәпләре юк иде диярлек. Вәдәвиләр, Мөхәммәт пәйгамбәр нәселеннән саналган сәетләр, ыруглар башлыгы шәехләрнең чыбык очлары, зәңгәр канлы гарәпләр монда бөтенләй юк иде. Үзәк Африка негрлары, төрекләр, Пакистан пуштуннары, индонезиялеләр, Сомалидан килгән суахиль кабиләсе вәкилләре, хәтта кытайлар — намаз укучылар арасында кемнәр генә юк иде. Егерменче гасырның соңгы казанышларына таянып төзелгән Җиддә портында Урта гасыр горефе идарә итә иде.

Күз алдыма ислам диненең иң гайрәтле чагы — сигезенче-уникенче гасырлар килеп басты. Испаниядәге Кордова каласыннан Индонезиягә, Шәһри Болгардан Занзибарга кадәр таралган ислам дине мөселманнарны тәүлегенә биш тапкыр намазлыкка бастыра, җомга саен мәчеткә җыя, елына бер ай ураза тоттыра. Җир шарының төрле почмакларыннан Мәккәгә хаҗ кылырга агылалар. Шәригать кануннары туган көннән алып, ләхет эченә кереп, башың белән кыйбла якка карап сузылып ятканчы, мөселманнарның һәр эшен тикшереп, һәр гамәленә юнәлеш би-

реп, хуплап яисә тыеп тора. Җир шарының өчтән ике өлешендә диярлек дәүләт чиген үтеп чыгу өчен бердәнбер паспорт, бердәнбер чит илгә чыгу визасы — «лә илаһы илаллаһ».

Әнә бездән биш йөз метрга урнашкан пассажир причалына туктаган ак лайнердан хаҗ кылырга килүчеләрне төшерәләр. Кораб өстендә Индонезия флагы җилферди. Хаҗ кылу өчен егерме мең чакрымнан килгәннәр. Цик алар дингә ышанмыйча гына яши алмыйлар икән соң? Бу дөньяда бит диннән ышанычлырак нәрсәләр бар? Патшага ышану көлгә әйләнде. Сталинга ышану канга буялды. Адәм баласына турыдан-туры зыян китерә алмый торган көчкә ышану гына озак яши. Кеше ни сәбәптер кыйбласыз яши алмый. Кыйбласызлыктан рухсызлык туа. Кыйбласыз дингә генә түгел, коммунистик идеалга да төкерә башлый. Ул аны да таптый, җимерә. Кыйбласызлар алласы — аракы, урлашу, уйнаш. Кыйбласызлар һәм ясалма кыйблалылар җәмгыять өчен иң куркыныч бәндәләр.

Җиддә портында безне ярга чыгармадылар. Хәтта причалга төшеп корабның батып торуын карарга да рөхсәт итмәделәр. Бу илнең тормышы, кешеләренең яшәү ысуллары безнең өчен сер булып калды. Сер кешене шомландыра. Шуңа күрә экипаж әгъзалары моторчы Сусликовны дикъкать белән тыңлыйлар иде.

## Ундүртенче тәүлек. Кызыл диңгез. 20.30

Кичке аштан соң җыелыш, лекция-фәлән булмаган көнне диңгезчеләр бассейн янына җыела. Су коеналар, шау-гөж килеп бер-берсен бассейнга ыргыталар. Бу уен да тиздән туйдыра, алар тезелешеп палубага яталар. «Ипи һәм тамаша!» дигән Юлий Цезарь. Аларга тамаша кирәк. Сусликов, киресенчә, тамашачылар аудиториясенә мохтаҗ. Коллектив дикъкатен яулыйсы, экипажда иң күренекле кеше буласы килә. Эш белән яуларга ул ялкау, акыл белән яуларга — наданлык комачаулый. Николай Иванович шикелле кешеләр теләкләрен үтәмичә калмый. Сусликов коллективны тел белән яуламакчы була. Ул һәрвакыт кеше җыелган җирнең уртасында, һәркайчан тыңларга теләүчеләргә акыл сата. Җәмгыятьтә сөйләргә теләүчеләрдән тыңларга теләүчеләр күбрәк булганлыктан, Николай Иванович теләгенә ирешү юлында.

— Хатыннарыгыз бәбигә узганда нинди ашамлыкка ымсыналар? — дип сорый ул.

Сорау аларга сәер тоела. Мондый сорауны бит көн саен ишетеп тормыйсың. Читтәгеләр Сусликовка якынрак килеп ята. Әлегә беркемнең дә чишеләсе килми. Кем белә, бәлки бу бушбугаз сиңнән көләр өчен биргәндер сорауны? Җавап бирүче юк. Җавап кирәк тә түгел Сусликовка. Жим бу. Ул аудиторияне кызыксындыра алды. Аңа шул җиткән.

— Хатыннарның юньлеләре андый чакта тозлы кыяр, тозлы кәбестә, селедка тели. Минем хатынга, чабаталы аристократкага я ананас, я булмаса кош сөте табып китер. Әле менә сәяхәткә китәр алдыннан гына болай ди: үләм, Николашка, әгәр ананас таба алмасаң, мине башка күрә алмыйсың, ди. Сатулаша башладык. Ананас таба алмасаң, әфлисун да ярап торыр дигәч, эзләргә чыгып киттем. Хатыннарның бит салпы ягына салам кыстырып кына тормасаң, тизрәк партоешмага йөгерәләр. Кибетләрне урап чыктым — чөгендер консервасы, томат соусына салган скумбрия. Әгәр минем хатын сораганны тапмый кайтсаң, ул сине берике атнадан тереләй гүргә тыга. Кинәт котелок бер акыллы фикер уйлап тапты: бала минеке булса, фифочкам я сырага, я булмаса көмешкәгә ымсыныр иде, грузинныкы яисә чит ил кешесенекеме әллә? Үтерәм стерваны! Әфлисун урынына бер яртыны алдым да өйгә таба элдерттем. Кибеттән чыгу белән «Академик Арцимович» корабында бергә эшләгән егетне очратам. Фамилиясе харап — Перечепидорога! Перечепигә баш-

танаяк сөйләп бирдем минем фифочкамның әфлисун теләгәнен. Ул әйтә, исең китмәсен, хатыннарның барысы шундый, ди. Минеке, мәсәлән, ди, торна ите теләп интекте. Сыттык бит теге яртыны Перечепи белән. Ул әйтә, без, ди, Мароккодан нәкъ менә әфлисун төяп кайттык, ди. Йөк хуҗасы һәр борынга бер тартма бирде, ди. Әфлисун бушаткан корабның экипажын, беләсез, порт капкасыннан тентеп чыгаралар. Проходной аша үтә алсаң, теләгән кадәр ал, ди Перечепи. Әләксәң, миңа үпкәләмә, сиңа берсүзсез статья чәпиләр, ди.

Киттек Перечепи белән. Портка кердек. «Академик Арцимович»ны эзләп таптык. Перечепи биргән әфлисуннарны кесәмә, куеныма тутырдым да проходнойга юнәлдем. Мин портка кергәндә капканы ир кеше саклый иде. «Арцимович»та кесәмә әфлисун тутырып азапланган арада каравыл алышынган, сакка бер ирдәүкә баскан. Күргәнегез бардыр ул ирдәүкәләрне? Безгә нәкъ арестантларга караган шикелле карыйлар. Ир-атның да инде төрлесе була. Алар арасында да курвалар җитәрлек. Ирләрнең кайберсе белән, алла сакласын, бергә бәдрәфкә дә кермәс идем мин. Шулай да ир-ат белән, әгәр бик тырышсаң, уртак тел табып була. Бигрәк тә сыра ятучылар белән.

— Сыраның кешеләрне бер-берсенә якынайта торган сере бармыни? — дип сорый матрос Дулев.

— Ә син, салака, ничек уйлыйсың? Сыра саткан җиргә ирләрнең иң асыллары гына җыела. Шундый ирләрнең үзара еш очрашып торулары тәрбия эшенә, хәтта токымга уңай тәэсир итә,— дип аңлатты Сусликов.— Мин бит сезне бер тапкыр кисәттем инде, сүзне бүлдермәгез, дип. Тагын бер тапкыр бүлдерсәгез, баста, поезд китәчәк.

— Юк, Николай Иванович, әһәмият бирмә син аларга. Сөйләп бетер инде,— диде радиостанция башлыгы Носенко.— Без бит тыңлыйбыз.

— Проходнойга якынлашып килем. Кесәм тулы әфлисун. Сакта ирдәүкә торганын күргәч, буыннарым йомшарып китте. Борылып китәргә дә соң. Ул мине күрде, көтеп тора башлады. Сакчыга таныклыгымны суздым. Карап та тормады. Яле, ди, кесәләреңә нәрсә яшердең, күрсәт әле, ди? Аулаграк җирдә булса, мин аңа нәрсә чыгарып күрсәтергә белер идем. Проходной бит. Без сызгырды — син конвертта, пичәтләп үк куячаклар, сакчыны мыскыллаган өчен. Нишләргә? Бәреп чыгып, урам ягына йөгерер идең, хатынның буе ике метр, мускуллары, теге штангист Жаботинский бар иде бит, нәкъ шуныкы шикелле.

— Күрсәтергә теләмәсәң, хәзер каравыл башлыгын чакырам,— ди.

— Эксперт чакыртыгыз,— дим.— Кесәмдә әфлисуннар башка сорттан.— Шушы сүзне ишеткәч, шул кадәр шатланды ирдәүкә. Сакчылар торган җиргә янәшә бер ишек бар бит анда. Шул ишекне ачып җибәрде дә, мине шул бүлмәгә төртеп кертеп, өстемнән бикләп тә куйды. Телефон шалтырата башлады. Каравыл башлыгын чакыра.

— Тизрәк килегез,— ди.— Карак тоттым. Кесә тутырып әфлисун алып чыга.— Тавышында шундый шатлык, әйтерсең, Сусликовны түгел, шпион тоткан. Урлашкан кешене тоткан өчен аларга биш сум премия бирәләр бит. Хатын, билгеле, шул биш сумга шатлана. Менә премия кешене нишләтә! Тәбегә эләккән тычкан шикелле әрле-бирле чабып йөрим. Ишек бикле, тәрәзә юк. Идән тактасын каерып күтәрмәкче булам — кая ул. Каюк, Николай Иванович, сохари киптерергә дә өлгермәдең ичмасам, дим. Без, чын ирләр дим, хатын-кыз аркасында менә шулай харап булабыз, дим. Күпме чабаланганмындыр, белмим. Кинәт башка бер уй килде. Арзан эш бит. Сусликов атлы кеше өч сумлык әфлисун өчен төрмәгә утырырга тиеш түгел, дим. Шушы фикер башка килү белән котелок та эшли башлады. Ашарга. Алар килеп җиткәнче ашап бетерергә! Башка юл юк сиңа, иптәш Сусликов. Алар килгәнче ашап бетерә алмасаң, крышка сиңа, каюк. Ашарга тотындым. Чәйнәп тә тормыйча, кабыгы-ние белән корсагыма озатам. Кирәк чакта бугаз шул кадәр киңәеп китә икән. Еланныкы шикелле. Кай чакта бугаз аша бөтен әфлисун да үтеп

китә. Биш-алты минут эчендә өч-дүрт килоны сыптырып ташладым. Сизмәдем дә диярлек. Эч күбә башлаган иде, басымны киметтем, эч шинде. Авызымны сөртеп, почмакка барып сырышуым булды — ишек ачылып китте.

— Менә ул әфлисун карагы! — ди теге ирдәүкә. Үзе шундый шат.— Яле, кесәләреңне әйләндереп күрсәт. Әйдә, әйдә! Безнең вакытыбыз юк, тизрәк кылан!

Бүлмәдә сакчыдан тыш каравыл башлыгы, милиционер, өстәвенә таможнячы. Ажур. Туп-туры төрмәгә озатырга була. Милиционер портфеленнән кәгазь алып беркетмә төзергә кереште. Ә мин шундый юаш, шундый гади кыланам. Бер сум егерме тиенлек ирләр трусигын күргәнегез бармы? Хәзер мин шул трусиктан да гади, беркатлы. Кесәмнән бер пачка «стюардесса» сигареты, бер кап шырпы, кулъяулык, квартирамның ачкычын, пәке, авыздан аракы исе килмәсен өчен суыра торган ментол, таныклыгымны чыгарып салдым.

— Кесәләрем бушады,— дим.— Әгәр берәр нәрсә таба алсагыз, сезнеке. Мәрхәбә!

Вахтер хатын, теге ирдәүкә, башта кызарды, аннан соң күп-күмгәк булып күгәрде.

— Чыгар әфлисуннарыңны, хәшәрәт! — дип кычкыра.— Я, әйт, кая куйдың?

— Нинди әфлисун ул? — дип гаҗәпләнгән булам. Күземне челт-челт йомып, каравыл башлыгына, милиционерга, таможнячыга карыйм.— Совет законнары үзенең гражданнарын яклый,— дигән булам.— Закон бер гөнаһсыз кешегә яла ягарга рөхсәт итми. Яла яккан өчен мин сезне судка бирәм.

Ирдәүкә идән такталарын күтәрергә азаплана, почмакларны, ишек өсләрен капшап карый. Бернәрсә дә таба алмагач, акылыннан шашып үкереп җибәрде!

— Кая әфлисун?

— Трусигым эченә яшердем. Карыйсызмы? — дигән булам.— Карагыз. Биш сум премия аз акча түгел, сезнең урында мин карар идем.

— Ашаган ул әфлисуннарын. Мин сезне чакырып йөргән арада ашап бетергән бегемот! Врач чакыртып, корсагының суын алдырырга кирәк. Эче тулы әфлисун бу дуңгызның.

— Рәхмәт сезгә, гражданка, дөрес киңәшегез өчен,— дигән булам.— Вахтерны судка бирер өчен сиңа экспертиза биргән справка кирәк булачак. Зинһар өчен чакыртыгыз,— дим,— экспертны.

Каравыл башлыгы белән милиционер мине юаталар, ирдәүкәне гафу үтенергә кыстыйлар. Катлаулы эш бит, диләр, мондый җаваплы эштә, диләр, билгеле, әзме-күпме ялгышлык ычкынмыйча калмый. Сез инде, гражданин, вахтерны да гафу итәргә тиешсез. Рыцарьлык күрсәтегез.

— Рәхмәт сезгә килеп коткаруыгыз өчен,— дим.— Сез булмасагыз, мин нишләр идем?

Алар мине судка бирмәскә үгетли. Ирдәүкәне гафу үтенергә кыстыйлар, ә тегесе һаман үз сүзен кабатлый.

— Ашап бетергән, троглодит! Йоткан, аждаһа!

Чыгарга рөхсәт иттеләр. Тыйнак кына кайтып киттем.

— Кайтышлый «Оныт кайгыларыңны» исемле сыраханәгә дә кермәдегезмени? — дип сорый өченче электромеханик Бабенко.— Кереп чыккансыздыр әле?

— Юк, туры өйгә кайттым. Ну, мин әйтәм, күрсәтәм бу чабаталы аристократкага! Подъездыма кайтып керсәм, хатынымны ашыгыч ярдәм белән алып чыгып азапланалар. Бала тудыру йортыннан килгәннәр. Шулай итеп, тәрбия бирергә дә өлгерә алмый калдым.

— Кайткач та өлгерерсең әле,— ди боцман Савчук.— Кайткан көнне үк, дөрес, кул бармый торгандыр. Бер-ике көн үткәч, тәрбия өчен хатыныңның шүрлегенә менеп төшү зыян итми торгандыр?

— Малайлар яклый аны,— диде Николай Иванович шундый боек тавыш белән.— Әниләренә бер сүз әйтеп булмый, бүре балалары шикелле, шунда ук ташланалар.

## Унсигезенче тәүлек. Карачи. 11.00



Ун минут алдан киткән булсам, бүген Карачида үткәрелгән гашүрә бәйрәмен күрә идем. Бу бәйрәм бары тик ислам диненең шәһит тармагын тотучылар арасында гына үткәрелә. Руслар аны шахсәй-вахсәй дип атап йөртәләр. Күп атамалар рус аша кергәнлектән безнең атеистик эшләрдә татарча да бу бәйрәм шулай атала шикелле.

Шәһәргә минем белән радист Носенко һәм дүртенче механик Лунгин барырга тиеш иде. Шуларның әзерләнеп чыгуларын көтә башладым. Тугызынчы унбиш минутта Носенко чыкты. Мин аны дүртенче механикны чакырырга җибәрдем. Шул чак ачык иллюминатордан капитанның тавышы ишетелде:

— Миргазиян Закирович, бер генә минутка керегез әле!

Капитан каютасына юл тоттым.

— Морфлот вәкиле иптәш Храпченко,— диде Михаил Александрович, түрдә утырган кешегә күрсәтеп.— Ә бу безнең беренче ярдәмче Миргазиян Закирович Юнысов.

— Сез, иптәш Юнысов, шәһәргә чыгарга җыенасызмыни? — диде морфлот вәкиле.

— Инде шәһәрдә идем диярлек. Менә капитан чакырып кертте,— дидем мин.

— Консул бүген беркемгә дә шәһәргә чыгарга рөхсәт итми. Бөтен дипкорпус бүген өйдә утыра. Мине портта торган совет корабларының диңгезчеләрен кисәтеп куярга җибәрделәр.

— Йомыш белән дә чыгарга ярамыймыни?

— Беркемгә дә. Категорически. Бүген шахсәй-вахсәй бәйрәме. Урамда кан коюы, үтереш. Битләрен тырныйлар. Күбесе шәрә. Кайберәүләр тәннәрен пычак белән тишеп, шул тишеккә богау йозагы элеп куйганнар. Күзләре тонган, әгәр аларның кулларына эләксәң, исән калырмын дип өметләнмә.

— Сез бит әле менә портка кадәр исән-сау килеп җиткәнсез. Беркем тимәгән сезгә.

Вәкил җавап таба алмыйча бер тын югалып торды.

— Консулның боерыгы шундый. Категорически. Бүген беркая барырга, корабтан чыгарга ярамый.

Бәхәсләшеп тору файдасыз иде. Тыю, рөхсәт итмәү бернинди дәлилгә, акылга һәм бернинди чынбарлыкка таянмый. Әгәр бер зуррак урында утыручы түрәгә чынбарлык аңлашылмаса, ул шундук «категорически тыела» дигән фәрман тудыра. Тыю, патша заманындагы иң күп таралган хикмәтле чара, революциядән соң бер тын тукталып торды да кабат тормышыбызны төрле яктан каплап китте. Мәсәлән, чит ил портларында шәһәргә чыгар өчен өч кешедән торган төркемгә җыелырга кирәк. Шул төркемдә ике дус кеше булырга тиеш түгел. Башкача, шәһәргә чыгу катгый тыела. Логика сорый: нишләп төркем тик өч кешедән генә торырга тиеш? Әгәр ике, я булмаса дүрт, яисә биш кеше бергәләп чыксалар? Нинди дә бер зур түрә-бюрократ: «Чит ил портларында диңгезчеләр бары тик өч кешедән торган төркем белән генә чыга алалар, башкача чит илдә йөрү катгый тыела», дип күрсәтмә биргән дә, хәзер шушы боерык тайпылышсыз үтәлә. Бездән чит ил диңгезчеләре көлә, бармак белән төртеп күрсәтеп мыскыл итә. «Өчәүләп, бер-берсенә берегеп йөриләрме? Билгеле, совет моряклары...»

— Иптәш Храпченко, Миргазиян Закирович — ислам дине буенча белгеч. Ул биш ел «Наука и религия» дигән журналда бүлек мөдире бу-

лып эшләгән. Бәлки аңа шәһәргә чыгарга рөхсәт итәргә кирәктер? Шәхсәй-вәхсәй турында аның язасы килә торгандыр. Безнең ил укучылары өчен аны белү кирәк бит. Рөхсәт итик, ә?

Вәкилне аңлап була иде. Ул да бит, нәкъ безнең шикелле, консулның боерыгын үтәргә тиеш. Бер түрә биргән боерыкны икенче түрә үзгәртә алмый, аның кануны шундый.

Дүртенче механик белән радистны чакырып керттем:

— Чишенегез, егетләр,— дидем мин.— Бүген шәһәргә чыгарга ярамый. Катгый. Чалбар эзләп вакыт үткәрмәсәк, китеп өлгерә идек.

— Нигә ярамый? — диде Лунгин. Аның йөзенә ризасызлык, рәнҗү билгесе чыккан иде.

— Морфлот вәкиленнән сорагыз. Консулның боерыгы шулай,— дидем мин.— Бүген Карачида шәхсәй-вәхсәй бәйрәме. Андый бәйрәм совет кешесе өчен куркынычлы санала.

— Нәрсә соң ул шәхсәй-вәхсәй? — диде дүртенче механик.

— Мин дә аның нәрсә икәнлеген белмим, аңлатыгыз әле, Миргазиян Закирович,— диде радиостанция башлыгы.

— Сусликовтан сорагыз. Ул бар нәрсәне белә,— дидем мин.

— Лыгырдык ул Сусликов,— диде радист.— Аның сүзенә ышансаң...

Өлкән буын гашүрә бәйрәменең нәрсә икәнен белә дә торгандыр? Ислам дине ике тармакка: сөннәтләргә һәм шиһитләргә бүленә. Шиһитләр Мөхәммәт пәйгамбәрнең кияве хәзрәти Галине рәсүл белән бертигез ихтирам итеп, аны бертигез санап йөртәләр. Башка хәлифләрне: Әбү Бәкер, Гомәр, Госманны алар хәлифлеккә лаек түгел дип баралар. Гашүрә бәйрәме хәзрәти Галинең улы Хөсәеннең һәлак булган көнендә матәм рәвешендә уздырыла. Менә мин хәзер шул бәйрәм турында морфлот вәкиле Храпченко сөйләгәнне тыңлап утырам.

— Узган елны без шушы шәхсәй-вәхсәй көнне, өйдән чыгарга куркып, фанатикларның урамда йөргәннәрен консулчылык тәрәзәсеннән карап утырдык. Белмим, ул көнне күпме кеше үзен-үзе үтергәндер? Көне буе диярлек канга баткан фанатиклар үз-үзләрен кыйнап йөрделәр.

Без килер алдыннан гына Карачидагы консул алышынган. Шәһәргә чыгуны тыйган кешегә кадәр консул булып Әгерҗе районында туып үскән Йолдыз Хәлиуллин дигән бер татар эшләгән. Мәскәүгә кайткач, мин Хәлиуллин белән очраштым. Пакистан чынбарлыгын, билгеле, ул тирәнрәк белә иде. Гашүрә бәйрәме турында да ул бөтенләй икенче төрле, үз күзе белән күргәннәрне, аның кагыйдәләрен миңа аңлатып бирде. Курыкканга куш күренә, ди татар мәкале. Курку үзе, гадәттә, белмәгәнлектән, я булмаса аңламаганлыктан килеп чыга.

Капитан каютасыннан чыкканда сәгать төгәл ун иде. Диңгезчеләрнең тәмәке көйрәтергә туктый торган чаклары. Мин туры тәмәке тарта торган җиргә юнәлдем. Шунда җыелган диңгезчеләргә Сусликов гашүрә бәйрәме турында аңлатып азаплана.

— Белә торгансыздыр инде мөселманнарның кайсы урыннарын кисеп ташлауларын? Менә шул «чыпчык» кисүне бүген, шәхсәй-вәхсәй бәйрәмендә башкаралар. Урамнан узган һәр ир затының штанын салдырып, шул «чыпчык»ны карыйлар. Әгәр киселмәгән булса — кырт, шундук пычак белән өзеп ыргыталар...

Кичке аштан соң кино карарга җыелган диңгезчеләр белән политинформация уздырырга туры килде. Мин аларга ислам динендәге йолалар һәм аның кайбер кануннары турында сөйләдем. Күңел салып тыңладылар. Бары тик Сусликов кына мин әйткәннәргә ышанып бетми иде булса кирәк. Аның күз карашы шундый шикле иде: «Әйдә, якла мөселманнарны. Син бит үзең мөселманнардан».

Сусликовның ислам динен аңламавы табигый хәл. Ул аны өйрәнмәгән. Үз күзе белән күргәннәре, аның шактый надан булуы аркасында, бик нык үзгәреп, кара кеше күзаллавына әйләнеп үзгәрә. Ә бит дингә каршы көрәш алып баручылар арасында да Сусликовлар җитәрлек.

## Унтугызынчы тәүлек. Карачи. 15.00



Җиддәдә шәһәргә чыгарга рөхсәт булмады. Советлар Союзыннан килгән кешеләрне калага чыгарырга ярамый дигән боерык Климовичның «Ислам дине» исемле китабыннан соң бирелгән. Җиддәдән соң без Аден портына туктадык. Анда торганда ярга чыгарга теләүче булмады. Бүген диңгезчеләрнең күбесе шәһәргә барырга теләп. Кемдер Карачида күннән теккән киемнәр арзан икән дип ишеткән. Экипажның өчтән бер өлешен кораб сакларга калдырганнан соң, инструкция буенча, калага барырга теләүчеләрне өчәр кешедән торган төркемнәргә бүлдем дә, кызыл почмакка җыеп, инструктаж үткәрдем.

— Бу илдә Әфганстанга җибәрү өчен «дошман»нарны әзерлиләр,— дидем мин.— Пакистан — АКШ империалистларының иң ышанычлы иярчене. Аннан соң, сез шәрык илләрендә хөкем сөрә торган гореф-гадәтләрне начар беләсез. Шуңа күрә, шәһәрдә йөргәндә уяулык сакларга тиеш. Беркем белән дә контактка кермәгез. Әгәр провокациягә юлыксагыз, шундук менә шушы телефон номеры белән Советлар Союзы консуллыгына чылтыратыгыз.— Төркем башлыкларына консуллыкның телефонын өләштем.— Шәһәрдә йөргәндә күргәннәрегезне корабка кайту белән миңа сөйләргә онытмагыз.

Менә хәзер без өчәр кешедән торган төркемнәр белән порт капкасыннан чыктык та шәһәр үзәгенә таба юл тоттык. Тирә-юньдә ят кешеләр, чит тормыш, ниндидер безгә билгесез мохит. Урамда машиналар. Мондый илләрдә җир йөзендә ясалган һәр машина төрен күрергә була. Җир шарының төрле почмакларына машина ташыр өчен соңгы елларда махсус кораблар ясый башладылар. Алар диңгезгә агызган гигант сандыкларны хәтерләтәләр. Шуларның карнына бишәр мең җиңел машина сыя. Әгәр АКШ, Япония, Көнбатыш Германия шикелле машина ясауда өлгер илләр һаман күбәя торса, җир йөзендә аны куяр урын калмас дип куркам мин.

Нефть кризисы башланганнан соң, зур машиналар Кувейт, Төркия, Ливия һәм безнең Грузия шикелле җирләргә агыла, АКШ һәм Европа миллионерлары, ни сәбәптер, бәләкәйрәк машинага утырып йөри башлады. Зур, кыйммәтле машиналар хәзер инде байлыкларын күрсәтеп шапырынып яшәүче сәнәктән көрәк булган нуворишларда гына диярлек.

Машиналарга карап, бу илгә кемнәрнең товарлары күбрәк керүен чамалап йөрим. Яңарак машиналарның күбесе японныкы. Пакистанны да яулап алырга өлгергән. Японнар җир йөзендәге халыкларны алдынгы европалыларга һәм артта калган азиатларга бүлүне тар-мар итте. Техника прогрессы, промышленность товарларының иң затлылары Япониядә чыга, алар күп яктан алдынгы Европа илләрен һәм АКШны узып китә башладылар.

Йөк машинасының рулендә хатын-кыз утырганын мин бары тик үзебезнең илдә генә күрәм. Пакистанда исә җиңел машиналар эчендә дә хатын-кыз күренми. Гомумән, урамда гел ирләр, хәтта бала-чага арасында да кызлар заты күзгә чалынмый. Бу инде шәригать тәэсире. Бу илдә шәригать кануннары дәһшәтле. Ул кануннар хатын-кызны өйдә, учак һәм бала янында тота.

Йөк машиналарыннан күземне ала алмыйм. Көнкүреш сәнгате йөк машиналарын калайдан чүкеп ясаган бизәккә төреп ташлаган. Яшәүнең тоташ агым булуын, җир йөзендәге барлык вакыйгаларның үзара бәйләнешле икәнлеген, язмышның илаһи көч кулында булуын исбатлаучы гарәп орнаментлары. Йөк машиналарының кузовларын каплаган орнаментлар күзеңнең явын алырлык. Андагы бизәкләрнең башы да, ахыры да юк. Яшәүнең дә шулай. Тормыш тоташ. Кеше туа, шатлана, михнәт күрә, әкренләп картая, гүргә керә. Гүргә кергәннәр урынына яңалар килә. Алар да шатлык һәм михнәт аша шул ук юлны үтеп, китеп баралар. Яшәү тукталышсыз тоташ агым. Мондагы йөк машиналарын каплаган

бизәкләр шул турыда сөйли. Америка, япон, немец һәм швед дизайнерлары көч түгеп, машиналарны үзләренчә матур итеп эшләгән. Машина ясаганда алар техниканың иң соңгы казанышларына таянып эш иткән. Без ясаган машина кемгә дә ошар, дип ышанганнар. Шәрыкнең меңеллар яшәп килгән гореф-гадәте дизайнерларның эшләренә төкереп, үз иҗатын, үз зәвыгын эшкә ашырган. Сәнгать бит ул халыкның канында, аның көндәлек эшендә туктаусыз яшәп килә.

Пакистанлыларның йөк машинасын мәчет бинасын бизәгән шикелле бизәүләреннән акыл кычкырып килә. Эшләнеп беткән эшне бозып яңадан әмәлләү ахмаклык бит инде. Ахмаклык һәм өстәмә чыгым. Чөнки шул калай чүкеп бизәк ясап утырган кешегә акча түләргә кирәк. Көнбатыш зәвыгына, аның тәҗрибәсенә таянып эш иткәнгә күрә безгә бу шулай тоела. Шәрык сәнгате исә файдага буйсынмаган. Шәрыкчә караганда, файда һәм сәнгать бер-берсенә буйсынмый торган капма-каршы категорияләр. Файда турында уйлаган архитектор Әл-Һамбра комплексын, Таҗ-Махал мәчетен, файда эшләргә теләгән рәссам Герат мәктәбе миниатюраларын иҗат итә алмас иде. Дөрес, гел файда турында гына баш ваткан художник Венециядәге Дожлар сараен, Джоконда портретын, Моисей һәм Давид сыннарын да тудыра алмас иде. Сигезенче һәм уникенче гасырлар арасында ислам ренессансы чорында Шәрыктә бик күп шедеврлар туа. Аларның алымнары башка, ә нәтиҗәләре — кешегә шатлык, рухи ләззәт бирү. Матурлык яшәүдә ышаныч, оптимизм тудыра, аның төп кирәклеге шунда. Европа инде күптән матурлыкны файдага җикте. Шәрыкта бу ике көч әле бер-берсеннән аерым.

Пакистанда ата-бабадан калган гореф-гадәтнең исән булуы, аларның көндәлек тормышка актив катнашуы күзгә бәрелеп тора. Гореф-гадәтләрне без тар-мар иттек һәм алар урынында вакуум барлыкка килде. Америка прагматизмы бу илгә дә үтеп керә башлаган, ул әле гади халыкка кагылмаган, буржуазия һәм түрәләр катламына гына тәэсир итеп тора.

Без, татарлар, рус культурасыннан үрнәк алырга тырышабыз. Мин инде утыз елга якын русларның чит илләрдә үз-үзләрен тотуын күзәтеп йөрим. Азия җирендә алар — европалылар. Европада — азиатлар. Социаль психологиядә бу хәл маргиналлык дип атала. Ике арада калу.

Россиягә культура Петр Беренченең корыч йодрыгы, ул чит илдән китергән Европа остазларының чыбыркылары белән кертелгән. Россиядә һәр яңалык өстән, боерык юлы белән килгән. Культура гына түгел, фән, техника яңалыклары да шулай. Көчләп керткән культурага каршылык әле шушы көнгә кадәр сүнеп өлгермәгән. Халык күңелендә, аның гадәтләрендә әле шушы көнгә кадәр негатив каршылык көче яши.

Тарих дәреслекләрендә Петр Беренче — Россия империясенең горурлыгы. Аның һәйкәле революциянең бишеге саналган Ленинградның үзәк мәйданын бизи. Ленфильмда төшерелгән кино башлангычы символ булып иң башта Петр Беренченең ат менгән сыны килеп чыга. Үзгәртеп кору, хәбәрдарлык чорында язылган тарих дәреслеге корыч императорның чын йөзен күрсәтер дип өметләнеп көтәм мин.

Петр Беренче чорында империянең халык саны икеләтә кими. Ирләр гомере уртача утыз дүрт яшь, хатын-кызларныкы егерме сигез яшь була ул идарә иткән заманда. Бар завод-фабрикалар хәрби заказ үтәп, тулысынча сугыш өчен эшлиләр. Россиядә эшләнгән товарларның сыйфатлары шул кадәр түбәнәя ки, аларның бер генә мыскалы да дөнья базарында көндәшлеккә каршы тора алмый башлый. Бу император идарә иткән дәвердә туктаусыз сугыш, яулап алулар, туктаусыз ачлык, солдат хезмәте. Мөстәкыйль фикер йөртергә омтылучы, демократиягә йөз тоткан шәхесләрне Иван Грозный үз кулы белән үтерсә, Петр Беренче заманында демократия һәм мөстәкыйль фикер йөртүгә урын да калмый. Петр Беренченең иң зур җинаяте халык инициативасын тәмам юкка чыгаруда. Ул чорда һәр гамәл, һәр эш югарыдан төшерелгән фәрманга нигезләнеп, камчы тоткан чиновник кулы астында эшкә ашырыла. Петр Беренче — Россия бюрократизмы-

на нигез салучы. Бюрократизм исә, яңарыш чорының иң аяусыз, иң каты дошманы. Бүгенге демократия өчен барган көрәштә без уртача алганда сиксән процентка Иван Грозный һәм Петр Беренче мирасы белән көрәшәбез. Бүгенге көндә демократия буенча безнең ил шактый ук артта калган. Сәбәпчеләре — Грозный, Петр, Сталин.

Без, культ һәм торгынлык заманыннан соң дөнья тәрәккыятендә үз юнәлешебезне, үз урыныбызны таба алмыйча, сукырлар шикелле, караңгылыкта кармалап юл эзлибез. Шул караңгылыктан без бары тик хакыйкать компасы ярдәмендә генә чыга алырбыз дип ышанам. Шуңа күрә, җаным-тәнем белән яңартып кору, хәбәрдарлык ягында.

Карачи каласының урамнарында минут саен Тукай заманындагы татар тормышына килеп төртеләм. Әнә ботакларын ярты чакрымга җәйгән мәһабәт чинар агачы төбендә бер төркем ир тезләрен кочаклап утырганнар да нәрсәдер көтәләр. Шәрык түземлеккә, көтәргә, фатализмга өйрәтә. Шәрык сабыр. Шәрык кешесе кыбырсыну, ашыгып яшәү белән теләккә якынлашып булмаганны белә. Ашыгу, кабалану аңа ят сыйфат. Язмыштан узмыш юктыр, дигән бабаларым. Тәкъдиреңә нәрсә язылган, бәхетеңә ни тиешле, сиңа шул булачак ди шәрык. Һәм әнә, өч дистәгә якын таза, яшь ир яңгыр көткән игенче шикелле, нindидер мифик үҗәтлек белән киләчәкне көтә. Аларның мускулларын, һөнәрләрен, сәләтләрен арзанга сатып алып була. Аларның тамакларын туйдыр, шул тамак хакына алар көнетөне эшләргә әзер. Мескеннәрнең куллары эш сагынып күптән сызлый. Йөк машинасын капларга бизәк кирәкме, мәчет манараларын күккә күтәрерлек көч кирәкме — монда аны шундук табып була. Шәрык кешесе зарланмыйча, берсүзсез көне-төне эшли белә. Ислам — кешене эшкә өндәү дине.

Җирләрен алпавытлар тартып алганнан соң, бабаларым Ташкент, Донбасс, Сучан ягына эш эзләп китә торган булган. Пакистанда да шул ук хәл. Пакистанлыны ачлык куып җитә башласа, ул, туган илен ташлап, Сөгуд Гарәбстанына, Кувейтка, Европа илләренә китеп бара. Кайсылары, акча туплагач, кире әйләнеп кайта. Күпләр исә чит туфракка ятып мәңге тынычлана. Чит мохитта ата-баба васыятен үтәргә мөмкинлек булмый. Тамыр әкренләп корый. Исән калган тамырлар аша ят матдә кереп, ана сөте белән сеңгән сыйфатларны эретә, агулый, юкка чыгара. Үз халкыннан аерылган, җирле халыкка кушыла алмый торган килмешәк барлыкка килә. Бу төрдә милләт сыйфаты да, халыкка хас бөтенлек тә булмый. Тамак тук, өс бөтен, җан һәм иман ачы кытлыкта, алар туктаусыз сыкрап яши. Җанның нигә сыкраганын белеп булмый. Фаҗигале язмыш.

Корабтан чыгуга ярты сәгать узды. Әле безгә бер генә хатын-кыз заты очраганы юк. Ялганлыйм икән — очрыйлар. Чит илдән килгән турист хатыннар. Ара-тирә, кибеткә барышлый, асрау кыз йөгереп уза. Шәһәр йортларының беренче катында тоташ кибет. Сәүдә шәрыктәгечә — кайнар, җор, тормышны күп яктан үзенә буйсындырган. Сәүдәгәрләр, билгеле, ир затыннан. Ширбәт, хәлвә сатучылар, ресторанннарда аш китереп торучылар, урам чатында хат яздырырга теләүчене көтеп утыручылар — шуларның барысы да ирләр. Бездә бит җир казуны, тимер юл төзәтүне, трамвайтроллейбус йөртүне хатын-кыз башкара. Ә монда бар эш ирләр кулында.

Пыяла витринадагы кызыл агачтан, палисандрдан ясалган бизәкле өстәлләр, йөз ел буена туктаусыз хуш ис тарата торган сандал агачыннан ясалган челтәрле тартмалар. Шәрыкнең нечкә билле комганнары яныннан узганда ихтыярсыз туктап, бер тын сокланып карап торам. Коръән аятьләре белән бизәлгән декоратив тәлинкәләр. Артыш агачы тамырыннан эшләнгән озын аяклы чиләннәр, укыганда китап куярга көйләнгән җыелмалы өстәлчекләр. Кибет каршына тротуарга өч бармак калынлыгы фарсы келәме ташлаганнар. Җәяүлеләр рәхәтләнеп шуны таптап уза. Бала-чага шикелле, әйләнеп килеп, тагын бер мәртәбә уздым кыйммәтле келәмгә басып. Аякларга шул кадәр рәхәт. Шул кыйммәтле йомшак тукымага басканда эчтә горурлык уянып китә.

— Малны ничек исраф итә кыргыйлар,— дип сукранып куйды боцман Савчук.— Соң бит бер-ике атнадан шушындый кыйммәтле нәрсәне таптап эштән чыгарачаклар. Кибет янынннан узганда күрсеннәр өчен чыгарып җәйгәннәр бит инде, витринага элеп куйсалар ни булган?

Мин келәмне тротуарга нигә җәйгәннәрен боцманга юри аңлатмыйм. Пакистанда келәм туку буенча мең еллык тәҗрибә сакланып килә. Тузанда ятып тапталганнан соң келәм йомшара, кабарып китә, буяу төсләре үзара тигезләнәләр. Мондый келәмне илле ел туктаусыз таптап торсаң да туздыра алмыйсың. Мин аларны Европа илләренең данлыклы музейларында күрәм. Мондый затлы келәмнәрнең күбесенә инде бишәр, алтышар йөз ел, ә үзләре әле һаман яп-яңа күренә.

Ишек янынннан узганда күреп алдым: кибетнең түр як стенасына карасу-кызыл фонга ак арыслан-киек сурәтләре һәм зәңгәрсу тәвис кошлары төшкән Бәлүҗстан келәме. Нәкъ шушындыйны мин Неапольнең Каподимонте музеенда күргән идем. Әгәр көядән саклап тота белсәң, мондый келәм төсен дә, сыйфатын да үзгәртмичә мең ел саклана. Истанбул портында торганда Салих Уйгыр атлы бер стивидор мине келәм сайларга өйрәткән иде. Идәндә яткан келәмгә ботинка үкчәсе белән басып, авырлыгыңны шул үкчәгә күчерәсең дә, келәмне бораулап бернича тапкыр бөтерелеп аласың. Әгәр келәмдә яньчелгән урын калмаса, келәм югары сыйфатлы була.

— Әйдә керик әле,— дидем мин боцманга. Савчук авызын учы белән каплап, көлеп куйды.

— Нәрсәгез калган анда?

— Әнә теге түрдә эленеп торган келәмне туйганчы карыйсым килә.

— Аны караудан ни файда? Юләрләнмәгез, андый кыйммәтле нәрсәне барыбер сатып ала алмыйсыз, нигә вакыт үткәреп, ымсынып йөрергә?

Утыз ел авыз ачып карап йөрүем миңа берәр файда китердеме икән? Кайбер кеше әйберне сатып алып үзенеке иткәч кенә куана, ләззәт таба белә. Мине, киресенчә, үз квартирамдагы әйбер башта гына куандыра. Тиздән ул мәшәкать китерә, яши торган урынымны тарайта башлый. Музей экспонатлары исә квартирамда урын биләмичә, сиңа саф куаныч, эстетик ләззәт биреп торалар.

— Һау матч?— диде боцман келәмгә бармагы белән төртеп күрсәтеп.

Кибет хуҗасы җавап бирергә ашыкмады.

— Кванте коста? Вифель костет? Хач пара?[1] — диде боцман бар белгән чит тел сүзләрен берьюлы чыгарып салып.

— Отто ченто милля долларо[2],— диде кибет хуҗасы көтмәгәндә итальянчага күчеп. Билгеле, ул келәмне сораганның ярты хакына сатачак иде. Ләкин малны үз хакына сатып алу өчен, беренчедән, сәүдәгәрнең туган телендә сөйләшергә, аның янына керү белән дога кылырга, хәл-әхвәлен, сәүдәгәр семьясының иминлеге, сәүдәләрнең ничегрәк баруы, яшь буынның әдәпсез үсүе, мөселманнарның шәригать кануннарын тотмый башлавыннан зарланырга кирәк иде. Шулай ашыкмыйча гына сөйләшеп утырганда хуҗа сиңа сарык йонының елдан-ел кыйммәтләнә баруын, пуштун кабиләләренең Әфганстан чиге аша үтеп йөри алмаулары турында әйтеп бераз зарланырга тиеш. Шуннан соң, хезмәтче китергән кофены бергәләп эчәргә, долларның һаман төшүе турында бернича сүз әйтеп тагын зарланырга, шуннан соң гына сатулаша башларга тиеш син.

Кибет хуҗасы безнең кесәдә келәм алырга җитәрлек акча юклыгын өч секундтан абайлап алды. Һәм без аның өчен юкка чыктык.

— Күпме сорый ул?— Савчук көлемсерәп миңа карый.

— Сигез йөз мең доллар.

— Сигез йөз меңгә мин Урта диңгездә утрау сатып алам, я булма-

[1] Инглиз, итальян, немец һәм төрек телләрендә «күпме тора?» дигән сүзләр.
[2] Сигез йөз мең доллар (итальянча).

са алтыннан ясалган «Мерседес» машинасын. Сезнең эш стажыгыз күпме, Миргазиян Закирович?

— Эшли башлаганыма кырык ике ел тулды.

— Шул кырык ике ел эшләп алган акчаларыгыз да җитми торгандыр шушы бер келәмне сатып алырга?

— Беркая тотмыйча җыеп килгән булсам, бәлки җитәр иде.

Үзәк урамны калдырып, уңга борылдык. Бу урамдагы йортларның фасадларына рәсемнәр элгәннәр. Фән, мөселман дине рәсем ясауны тыя, шунлыктан шәрыктә рәсем сәнгате юк дип аңлата. XVI гасырда, диннең иң каты чорында хәзерге Пакистан төбәгендә «Моголлар мәктәбе» дип аталган рәсем ясау ысулы барлыкка килә. Ул заманда безнең тарихта фаҗигале хәлләр булмаса, Мирсәет Гали Тәбризнең, Әбдас Саматның һәм башка рәссамнарның пейзаж фонына төшерелгән күп фигуралы рәсемнәрен белер идек без. «Бабырнамә» китабының иллюстрацияләрен сәгатьләр буе карап утырырга була. Андагы кабатланмас гүзәллек, андагы хис һәм хыял дөньясы! Шул рәсемнәрне караганнан соң бик озак сурәт уяткан әкияти мохитта яши бирәсең.

Һәр заман үзенә хас ысул тудыра. Без барган урамның йортларына буйдан буйга рәсемнәр ясап элгәннәр. Бу полотноларны буяу белән язмаганнар. Рамдагы джут киндере өстенә ниндидер кара сумала җепләр сузылган. Урыны белән җепләр юаная, кирәк чакта салмак кына нечкәрә, бөтерелә, урый, өзелер хәлгә җитә. Шушы кара сумала җепләр искиткеч үзенчәлекле сурәтләр тудырган. Әнә ботакларын ярты чакрымга сузган фил агачлары моңаеп утыра. Салмак кына елга агып ята. Камыш арасында килбәтсез озын аяклы челәннәр йөри. Якынрак килеп карасаң, күрәсең: рәссам бары тик ике генә төс — чем-кара сумала һәм алтын буяу кулланган. Шушы ике төснең үзара төрле нисбәттә катнашуы, җепләрнең юанлыгы һәм нечкәлеге искиткеч характерлы, матур тойгылы сурәтләр пәйда итә алган.

Сәнгать дөньясыннан шушы полотноларга охшашлы алымнар эзләп карыйм. Күз алдымнан төрек рәссамнарын: Балабанны, аның сабан тартып барган гаҗәеп үгезләрен, Асылъяр, Гөнәп иҗатын үткәреп җибәрәм. Пакистан рәссамнары кытай, яисә япон художникларының алымын куллана торганнардыр? Я булмаса, Шам, Гыйрак рәссамнары тәэсиреннән тугандыр бу ысул? Япон һәм кытай сәнгатендәге нәзбереклек, иероглиф тәэсиреннән туган тылсымлы пластика түгелме бу? Япон һәм кытай сәнгатенең тәэсире бераз сизелә, ләкин тагын нииндидер шушы көнгә кадәр миңа очрамаган ысул бар бу полотноларда.

Хәтеремә Нурихан Фәттахның «Фест дисбесе» турындагы язмалары килеп төште. Безнең татар сәнгате, әдәбиятыбыз ябылыбрак яши. Русның унтугызынчы гасыр азагы, егерменче гасыр башындагы ренессансы, Лев Толстой, Достоевский, Чехов, сәнгатьтә Врубель, Валентин Серов, Нестеров шикелле талантлар безнең дикъкатьне тулысынча җәлеп иткән. Шулардан ары китеп башка ил язучыларын, башка халыклар сәнгатен авыр үзләштерәбез. Көнчыгыш Азия халыкларының сәнгатенә будда диненең мәшһүр «дүрт адымы», спираль юлдан мәңге камиллеккә, мәңге югарыга омтылу сеңеп калган. Менә кайлардан эзләргә кирәк бу ысулның тамырын. Герат мәктәбеннән, «Бабырнамә»дәге иллюстрацияләрдән эзләргә кирәк бу сәнгатьнең үзенчәлеген.

— Закирович,— диде боцман ачы үпкә белән.— Шушындый пүчтәк нәрсәләр тирәсендә этенеп, вакыт үткәреп йөрсәк, төп башына утырып калачакбыз. Без бит күн пальто алырга чыктык. Онытлыгызмыни?

Базарның көмешчеләр сәүдә итә торган өлешенә чыктык. Тар, озын өстәлләр тирәсендә алар бизәнү әйберләре ясый һәм шулар белән сату итә. Бала чактан таныш ярым ай рәвешендә эшләнгән көмеш һәм алтын алкалар. Кызыл, ак ахак, фирәзә. Анар кашлы балдаклар. Сөннәр, кыпчаклар заманыннан сакланып калган үлән яфраклары, кыр җәнлекләре төшкән беләзекләр. Муенсаларның нииндиләре генә юк мон-

да! Кечкенә генә өстәл янында азык-төлек төрер өчен көмештән кәгазь ясаучы оста. Ул бармак очы хәтле генә көмеш пластинканы үгез тиресенә төрә дә агач чүкеч белән тирене тукмарга тотына. Мең, ун мең, йөз мең тапкыр суга. Ниһаять, оста үгез тиресен ачып җибәрә. Нинди могҗиза бу! Үгез тиресе эчендә юрган итеп өстеңә ябынырга җитәрлек ялтырап, күзеңнең явын алырлык көмеш фольга. Туй күчтәначләрен, хөрмәтле кунакларга дигән азык-төлекне Пакистанда шул көмеш кәгазьгә төреп йөртәләр. Көмеш эчендә ашамлык бозылмый, искерми икән. Әгәр ашамлыкны төргән фольгасы-ние белән ашасаң, җитмеш чирдән дәва дип сөйлиләр.

Болары — алтынчылар. Алтыннан ясалган бизәнү әйберләренең саны-хисабы, очы-кырые юк. Алтыннар тау-тау өелеп ята һәм сатып алучы күренми. Базарны төрле яктан вак кына кибетләр чорнап алган. Шуларның берсенең эченә кердек. Карачи каласының сере ачылды. Менә кайда икән хатын-кызлар! Байбичәләр, сәүдәгәр, түрә хатыннарыдыр инде болар? Аларның киенүләре, кыланышлары татар хатыннарыныкын хәтерләтә. Ябырылып алтыннан ясалган бизәнү әйберләрен карап йөриләр. Урта Азиядә дә, әгәр кесәгә акча керсә, хатын-кыз алтын алка, йөзек, беләзек ала башлый бит. Монда да шулай икән.

— Без, Закирович, болай тукталып торсак, беркайчан да теге күн пальтолар сатыла торган җиргә барып җитә алмаячакбыз. Сез бит гел кирәкмәгән нәрсә карап вакыт уздырасыз.

Агач сыннар, көмеш савытлар, кеше биеклеге сылу комганнар яныннан узганда күземне йома башладым. Күз алдымда осталарның өлгер куллары, шул кулларның искиткеч йөгерек хәрәкәтләре тора. Бу дөньяда осталыктан да бөек, аннан да күркәм нәрсә бар?

## Егерменче тәүлек. Һинд океаны. 19.00

Курс — Һиндстанның иң зур порты саналган Бомбейга. Ашыгабыз. Ике көн эчендә барып җитеп, йөкне бушата башламасак, анда забастовка башланачак. Кораб океан өстен сөреп алга бара. Коридорда нииндидер ят ис сизгән идем, ул ис монда, рубка эчендә дә аңкый икән. Тукта әле, бу бит күн исе. Кичәдән бирле шушы ис бөтен корабны чорнап алган. Кичә Карачида диңгезчеләр күн пальтолар сатып алганнар иде, шуның исе. Кичә кич бер-берсенең каютасына кереп Карачида алган күн киемнәрне карап йөрделәр. Товар иясен табар, ди татар. Кемнең нинди пальто алганын карап, аның гадәтләрен, зәвыгын, юмарт һәм саран булуын ачыклап була. Кайберәүләр, арзанлыкка кызыгып, иләнүе җитмәгән күннән теккән пальто алганнар. Саран ике кат түләр диләр, андый күн, яңгырга эләксә, катып сына башлаячак. Моторчы Сусликов үзенә күн чалбар, хатынына күннән теккән камзул алган. Карарга кергән кешеләргә күрсәтеп, аңлата:

— Дулаганда кигерергә. Бар бит теге дурдомда «тынычландыра» торган күлмәк. Шуның урынына.

Күперчектән төшкәч бассейнга су коенырга киттем. Эссе. Юеш тропик һавасы тын юлына тыгыла, әлсерәтә, хәл бетә. Диңгезчеләр бассейнда су коенып чыкканнар да спардекта моцион ясап йөргән ипи пешерүче кыз Людмиланы күзәтәләр. Люда кичә Карачида күн чалбар сатып алган иде. Бүген шуны киеп чыккан. Чалбар аңа шактый тар. Кыз ботларын чалбар эченә көч-хәл белән генә тыга алган булса кирәк. Чалбар кыса. Кызның ботлары киптерергә аскан казылыкны хәтерләтә. Егетләрнең ләчтите Люданың чалбары тирәсендә әйләнә.

— Ничек түзә икән ул, ә?— ди өченче электромеханик Бабенко.— Бу эсселеккә шәрә килеш көчкә түзеп була, ә ул күн чалбар киеп чыккан.

— Люданың чалбар эченә яшергән байлыгы ярты сәгатьтән биф-

штекска әйләнәчәк,— ди Сусликов.

— Көн кием модага керде,— дип аңлата доктор Теунов.— Язучылар, кинорежиссерлар, артистлар хәзер көн пиджак киеп йөри. Көн кием дәрәҗәле санала. Безнең Люда да үзен шәхес итеп сизәр өчен көн чалбар киеп чыккан.

— Шәхес итеп сизәр өчен?— дип сорый Сусликов.— Чалбар көне тәкә тиресеннән эшләнгән. Люда шул тәкәне тәне белән тоеп йөри. Доктор кеше мондый гына теорияне белергә тиеш инде.

Людмилалар буынын аңларга тырышып карыйм. Алар миңа нәкъ теге ерак галактикаларда яшәүче җан ияләре шикелле тоела. Кыланышларын күзәтәм. Логика көчсез. Бу очракта гомер буе җыйган тәҗрибәмне кулланып булмый. Ата-бабадан калган гадәт буенча бездә затлы киемне бәйрәмдә, кунакка, театрга-киногa барганда кияләр иде. Эшкә таушалган киемне, йорт арасында йөргәндә иске-москы да ярый иде. Яшь буын киемне кибеттән алып кайту белән эшкә кия башлый һәм ул аны тәмам искергәнче салмыйча киеп йөри. Таушалганны ташлый. Киенүнең мәгънәсе дә аңлашылмый миңа. Егерменче гасырда, социалистик илдә без феодаллык чорындагыча киенәбез. Язучылар, журналистлар өстендә көн пиджак. Сәүдәдә эшләүчеләр чит илдә тегелгән дефицит кием юнәтә. Җитәкче иптәшләр каракүл якалы ратин палто киеп йөриләр.

Джакарта портында торганда Индонезиядә яшәүче халыкларның гореф-гадәтләрен өйрәнеп йөрүче бер инглиз этнографы белән танышкан идем. Ул миңа бер кызык нәрсә сөйләде. Индонезиядә яшәүче кайбер кабилә вәкилләренең киемнәренә карап, аның байлыгын, кайсы авылдан булуын, нинди токымнан, буйдакмы, түгелме икәнлеген, хәтта нинди эштә эшләвен белергә була. Урта гасырларда кием паспорт һәм анкета ролен уйнаган дип аңлатты инглиз галиме. Бу гадәт әле бездә дә сакланып калган. Европа илләрендә кешенең баймы, ярлымы икәнлеген, аның торагын, ял вакытындагы шөгыленә карап кына белә аласың.

Бассейн янында ял итеп ятучы диңгезчеләр Сусликовны үрти. Николай Ивановичның мактанасы килә. Егетләр аның сүзләренә ышанмаган булып кыланалар. Ул хәзер кызып китте һәм менә мактана башлаячак.

— Сине, Николай Иванович, бик иртә өйләнгән дип сөйлиләр. Өйләнгәнче кызлар белән йөреп тә кала алмагансыңдыр?— дип сорый өченче электромеханик Бабенко.

— Минме? Мин сезнең шикелле Людмиланың көн чалбар балагына яшеренгән казылыкларына карап ач бүре шикелле ымсынып ятмадым. Минем кулдан үткән кызларны саный башласаң...— Сусликов кеткелдәп көлә һәм нягеи сыпырып куя. Шушы минутта ул үзен инглиз артисты Лоуренс Оливье шикелле чибәр һәм аристократ кыяфәтле итеп тоя. Ә үзен бакчага карачкы итеп утыртсаң, һавадагы кошлар урап очарлар иде. Кеше мактанганда кулыннан килмәгән эшләрне эшләгән итеп, эшкә ашмаган теләкләрен ашкан итеп күрсәтергә тырыша.

— Син инде, Николай Иванович, кызларның нинди кылларына чиртергә кирәклеген беләсең,— ди доктор Теунов һәм Сусликовка сиздермичә генә егетләргә күз кыса.— Чибәр кызларны ничек үзеңә каратуың турында яшьләргә сөйләргә кирәк. Синең шундый бай тәҗрибәң әрәм булып ятмасын иде.

— Мин инде ул эштә, егетләр, ас идем, чемпион идем.— Сусликов күзләрен йомып елмаеп җибәрә. Бәрәңгегә охшашлы кызыл борын өскә таба күтәрелеп ике ыржаеп торган тишекне күрсәтә. Николай Ивановичның битенә урлап каймак ашаган мәче канәгатьлеге чыга.— Мин кызлар белән танышкан кичне йолдызлар турында сөйли идем. Алар бит биектәге нәрсәне ярата. Андромеда йолдызлыгының альфасында галимнәр кеше кулы белән төзегән каналлар барлыгын исбат иткән, дип башлап җибәрә идем. Йолдызлар фәнен беркем белми, хәтта астро-

номнар үзләре дә. Ул турыда нәрсә сөйләсәң дә бата. Шулай сөйлим дә туктап үйга чумам. Гашыйк булган кеше шулай үйга чумарга да тиеш бит инде. Психология фәне шулай куша.

Икенче очрашуда мин аларга композиторлар турында сөйлим. Бүгенге көн композиторлары ни сәбәп Бетховен, Моцарт, Шуберт,— шуларга тагын берничә яһүд фамилияләрен өстим,— чыгарган көйләргә тиң көй чыгара алмыйлар дип сорыйм? Билгеле, андый катлаулы сорауга беркем җавап бирә алмый. Мин болай дим: без ашаган азыкларда калий аз, шул җитми композиторларга теге классиклар дәрәҗәсенә җитәргә.

— Николай Иванович, бәхәскә әле бүгенге көндә иҗат итүче берике композиторның фамилиясен әйтеп карагыз әле,— ди радист Носенко.

— Кемгә кирәк аларның фамилияләре? Сезнең күбегезнең кесәгездә вуз дипломы. Ә нәрсә беләсез? Шул ук урта белемлеләрдәге наданлык сездә. Ә урта белемлеләрдә өч класс бетергәннәр наданлыгы. Безне бит уртак наданлык берләштерә. Әгәр дә югары белемле саналганнар чыннан да югары сыйфатта белсәләр, урта белемлеләр урта сыйфатта, совет халкы бер-берсен бөтенләй аңлый алмас иде. Наданлык көчле булганлыктан гына без бер-беребезне аңлап, аралашып яши алабыз.

— Бусы бит, Николай Иванович, икенче тема. Син безгә чибәр кызларны ничек эләктереп алуың турында сөйли башлаган идең,— ди өченче электромеханик Сережа Бабенко.

— Маркони минем сүзне бүлдерде,— ди Сусликов һаман тынычлана алмыйча.— Композиторларның фамилияләрен дисеңме? Шулар турында сүз чыкса, мин үзем белән бергә хезмәт иткән малайларның фамилияләрен әйтәм, я булмаса, уйлап чыгарам: Форштейнзиберг, Ширпотребьян, Мунчалашвили, дим. Яһүд белән әрмән фамилиясе ышанычлырак тоела. Алар миңа ышаналар. Чөнки мин аларның миләренә пудра сибеп сүз аралаш диярлек Сократ болай дигән, Платон тегеләй әйткән дигән булып, борынгы галимнәрнең сүзләрен мисал итеп китерәм. Парапсихология дигән фән турында ишеткәнегез бармы сезнең? Юк, билгеле. Мин нечкә сыйракларга шул фән турында сөйлим. Болары икенче очрашуда.

Өченче очрашуда АКШ миллионерлары турында сөйлим. Мин аларга болай дим: миллионерларның күбесе мендәрләренә мамык урынына акча тутыралар, дим. Аларның машиналары нинди икәнлеген, дачалары, су коена торган бассейннары, алар ашаган ашлар турында сөйлим. Өченче кичтән соң кыз җитлегә. Ул хәзер кызарып пешкән алма хәлендә. Ботагын чак кына селкеттең — кыз синең кочагыңа килеп төшә.— Николай Иванович туктап иренен ялап ала. Битләр кызарган, борын тишекләре киңәеп киткән. Иҗат процессы бит — әсәрләнгән.

— Их, егетләр! Кыз кочуның тәмен беләсезмени сез? Сезгә бит тәти күлмәк белән джинс чалбар җиткән. Шуларны кызларга күрсәтеп кайтсагыз, шуның белән күңелегез була да тынычланып йокларга ятасыз. Ә мин буйдак чагымда кыз кочу буенча профессор, юк, академик идем. Кызлар мине күрү белән һушларыннан яза, башларын югалтып, кочагыма ташлана иде. Исемнәрен язып бармавыма үкенәм. Ничә йөз чибәр минем кулдан үтте. Их, яшьлек!

— Син бит, Николай Иванович, миллионерлар турында сөйләгәннән соң нәрсә эшләвеңне әйтмәдең әле,— диде матрос Дулев.— Алмагачны селкеттең, алмасы синең кочагыңа төште. Шуннан соң нәрсә эшли идең? Минем шуны беләсем килә.

— Маймыч сез, егетләр. Хәтерегез калмасын, минем белән чагыштырганда вак балык сез. Миллионерлар турында мин нигә сөйлим? Чөнки һәр кыз үзенең булачак ирен зур урында эшләүче, акчаны көрәп ала торган бай кеше итеп күз алдына китерә. Аңа яңа күлмәкләр, туфлиләр кирәк. Аның машинага гына утырып йөрисе, дачасына кайтып ял итәсе килә. Шуңа күрә сөйлим мин миллионерлар турында.

Композиторлар турында үземнең культуралы булуымны күрсәтер өчен сөйләдем. Йолдызлар турында — галимлегемне. Кыз житлегеп беткәч мин аңа әйтәм: «Жанкисәгем,— дим,— күз нурым, мин хәзер синнән башка яши алмыйм.— Кыз өлгерде, ашыгырга кирәк. Шушы мизгелне ычкындырырга ярамый.— Туйны кайсы көнгә билгелибез? Син бит әле мине әти-әниең белән дә таныштырмадың. Кайсы көнне туганнарың белән таныштырасың?» Туй ясыйсы көнне билгеләп куябыз. Эш кызның әти-әнисендә. Ә без инде туй житкәнне көтеп тормыйча, ирле-хатынлы бергә кунып яши башлыйбыз.— Николай Иванович тагын туктый, кибә башлаган иреннәрен тагын ялап ала. Аның сулыш алуы ешаеп киткән. Ул хәзер экстазда.— Их, егетләр! Ул кызлар күзендәге сихер! Бергәләп үткәрелгән төннәр!

— Кызның әти-әнисе белән бәйләнгән көнне нәкъ үзең куйган тозакка килеп эләктең, Николай Иванович,— ди моторчы Чумак, утызларга житеп килгән тәжрибәле буйдак.— Арзан хәйлә. Ялган — ялган инде ул, ничек кенә бөтерелеп йөрсәң дә кыз тирәсендә, иртәме, соңмы, ялганың барыбер ачыла.

— Бүлмә өлкән кеше сүзен, сантый,— ди Сусликов ачуланып.— Кем тәрбияләгән сине, троглодит! Редиска! Тиздән кызның әти-әнисе белән очрашасы көн килеп житә. Мин ул көнне көтәм. Тарихи көн булып истә кала ул очрашу. Кыз да, билгеле, дулкынланып көтә. Семьяда үзеңне ничек тотарга миңа киңәшләр бирә. Әтисенең нәрсә яратканын, әнисенең йомшак якларын ачып сала. Әти-әнисе белән сөйләшеп, никах мәсьәләсен хәл итәсе очрашуга мин юри карачкы шикелле киенеп барам. Бездә бит киемгә шундый зур әһәмият белән карыйлар. Ул көнне мин юри клоун булып киенәм.

— Син, Николай Иванович, башка көннәрдә дә клоуннан ким булмыйсың,— диде боцман Савчук.

— Ял кетәгеңне, сантый! Редиска! Клоунга охшаган кеше нәкъ син үзең инде. Мин кызның семьясына юнәләм. Мине каршы алу белән кызның кәефе кырыла. «Син нигә болай начар киендең?»— ди ул мескенкәй минем тактиканы аңламыйча. «Эштән кайтышлый гына кердем,— дигән булам.— Киенеп торсам, соңга калырмын дип курыктым. Соңга калып килгән кешене яратмыйлар», дип ялганлыйм жанкисәгемә.

Алар мине табын әзерләп көткән булып чыга. Өстәлдә ожмах сые. Кремльдә чит ил президентларын каршы алганда да шулай әзерләнә алмый торганнардыр әле. Кызны кияүгә бирү бит ул, беләсез, проблема. Хәзерге көн егете өйләнмичә дә бергәлекнең рәхәтен ала белә. Минем хөрмәткә кызның әтисе галстук тагып жибәргән була. Әнисенең өстендә пан бәрхет күлмәк. Кәмит. Әби буласы кешенең аркасыннан сөеп: «Сез әле кызыгыздан яшьрәк күренәсез»,— дип, иреннәннән суырып үбәм. Аларның икесе дә тораташ хәзер. Шок хәлендә. Мескеннәрнең күзләрендә сорау: «Кызым, син мактаган егет шушы буламы инде? Бу бит нахал. Кара әле, кызым, нинди тәрбиясез егет алып килгәнсең өебезгә». Кызның балтасы суга төшкән. Мескен нишләргә дә белми.— Николай Иванович сөйләвеннән туктап, бассейнга чума. Судан чыккач, палубага сузылып ята.

— Сөйләп бетер инде,— ди Сергей Бабенко.— Иң кызык жирендә өзден.

— Сез аңларлык эшмени ул кыз ярәшү!— ди Сусликов һәм чалкан яткан жиреннән торып киерелә, кырын ята.— Сезне бит хатыннарыгыз борыныгыздан сөйрәп ЗАГСка китергән. Ә мин өйләнгәнче ким дигәндә житмеш жиде кыз белән тәжрибә ясап карадым.

— Сөйлә инде,— ди боцман Савчук.— Кызның әти-әнисе белән нәрсә турында сөйләшәсез сез?

— Алар мине табынга чакыра. Мин, билгеле, аракыны рюмкага салганнарын көтеп тормыйм, өстәлдәге шешәне эләктереп алам да

голт-голт шуның авызыннан йотам. Балык уылдыгын башкаларның алдыннан тартып алып, кашык белән ашый башлыйм. Лач-лоч чәйним, кикерәм. Йортның стеналары селкенерлек итеп танавымны сеңгерәм, җиңем белән борынымны сөртеп ташлыйм. Әби-баба буласы кешеләр нишләргә белмичә кызларына карыйлар. Минем булачак кәләшем бөгелеп төшкән, әти-әнисенә күтәрелеп карарга да ояла. Нишлисең, минем план шундый. Кызны кызганып, үзеңне әдәпле тота башласаң, тоталар да кызны миңа сылап куялар. Җанашым өстәл астыннан аягыма басып карый, терсәге белән кабыргага төртә. Ә мин башка кунаклар алдына куйган закускаларны үрелеп алам да авызыма тутырам. Беркемгә бер сүз әйтергә ирек бирмим.

— Мәҗлестән арт саныңа тибеп чыгармыйлармыни соң үзеңне?— дип сорый матрос Дулев.— Николай Иванович, син бераз арттырып та җибәрә башладың шикелле.

— Минем урында синең шикелле сары томшыклы чыпчык баласы утырса, алар нәкъ шулай эшләрләр иде.— Сусликов «тәрбия» эшенә багышланган хикәясен дәвам итә.— Озатырга чыккач, хәләл җефетем булачак кешедән сорыйм: «Әти-әниең риза шикелле. Туйны шул алдан билгеләнгән көндә ясыйбыз инде, әйеме?»— Кит,— ди ул, бөгелеп төшеп.— Күземә күренәсе булма, адәм актыгы!» Ә миңа аның нәкъ шул сүзләре кирәк тә. Үзем һаман башымны юләрлеккә салып сөйләшәм: «Без бит инде бөтенләй килешеп беткән идек. Бәхетле гаилә тормышы. Алмадай чибәр балалар. Нишләп минем белән шулай сөйләшәсең? Мин бит сине өзелеп яратам», дигән булам. «Күземә дә күренәсе булма,— дип бөгелеп төшеп елый җанашым.— Ерткыч! Фашист син! Палач!»

Икенче кичне мин инде йолдызлар турында башка кызга сөйли башлыйм. Бусы белән дә нәкъ шушындый финал.

— Соң алай гел чәчкә утлап кына йөри алгач, нигә өйләндең соң?— дип сорый өченче электромеханик Бабенко.

— Бусы инде башка хикәя,— ди Сусликов.— Бу турыда сезгә кәеф булганда бер сөйләрмен әле.

Диңгезчеләр ялына башлый. Бер тын ялындырып, бәясен күтәргәч, Николай Иванович үзенең өйләнүе турында сөйләргә керешә.

* * *

— Хатын белән шул ук тәҗрибәне ясадым мин,— дип башлый ул.— Башта йолдызлар турында, аннан соң композиторлар, миллионерлар... Сүз ара сүз чыкканда, борынгы акыл ияләренең афоризмнарын, үзем уйлап чыгарган хикмәтләр булса да, кыстыргалап тордым. Эш шулай шома гына алдан төзегән план буенча бара торды. Кызның әти-әнисе белән танышып мәҗлес тә килеп житте. Табын янында танавымны чистартып утырдым, кирәк чаклы кикердем, эчемә җыелган газларны да чыгарып бетердем. Кеше алдына куйган затлырак ашамлыкларны тартып алып ашап утырдым. Мәҗлес бетте. Озатырга ни сәбәптер кыз үзе чыкмады, аның абыйсы чыкты, минем булачак кайнагам. Чыгу белән тәмәке көйрәтеп җибәрдек.— «Син егет, безгә бик ошадың,— ди бит миңа бу кеше.— Әти-әнигә дә бик ошадың. Без шундый гади кешене яратабыз. Сеңелебез ялгышмаган, тормыш кора алырлык акыллы, булдыклы кешене сайлаган». «Бәлки дөрес сайлагандыр да,— дим аркама салкын тир бәреп чыкканын сизеп.— Мин сезнең сеңелегезгә өйләнә алмыйм, гафу итегез». «Ничек инде өйләнә алмыйсың? Әгәр көчең житмәсә, без сиңа ярдәм итәрбез»,— ди булачак кайнагам һәм йодрыгын веранда рәшәткәсенә, нәкъ минем күз алдыма китереп куя. Ә ул йодрыкны күрсәгез иде! Зурлыгы ике потлы гер чаклы бар. «Йогышлы чирем бар»,— дим һәм үзем тизрәк ычкыну ягын карыйм. «Нинди йогышлы чир ул?»— дип сорый җанашымның абзасы. «Чехотка,— дим.—

Ачык форма. Эчем тулы микроб. Заразный мин». «Ерунда,— ди тимер йодрыклы кеше.— Дүрт-биш укол кададың, бетте-китте. Шундый чиргә әһәмият биреп торырга. Туй шул сез билгеләгән көнне була торгандыр бит инде, әйеме?» «Юк, юк,— дим бераз арткарак чигенеп.— Врачлар миңа өйләнергә рөхсәт итми. Мин өч тапкыр сифилис белән авырдым. Йогышлы мин. Өстәвенә мин әле псих. Кешегә ташланам. Ышанмасагыз иртәгә язу алып килеп күрсәтәм». «Ерунда,— ди булачак кәләшемнең абыйсы.— Сифилис тә булдымы авыру. Өйләнгәч бетә ул,— ди, үзе, шаярган булып, йодрыгы белән касыгыма төртә. Тын ала алмыйча бөгелеп төштем шаярып кына төртүеннән. Саубуллаш, Николай Иванович, якты дөнья белән. Бу сине теге дөньяга озатачак, дип уйлыйм.— Хәзер инде псих булмаган кеше юк. Заманасы шундый,— дип юата бу мине.— Ярый, иртәгәдән без туйга әзерләнә башлыйбыз. Пока». Шул йодрык кода булып өйләндертте безне,— дип йомгаклады Николай Иванович «тәрбия» темасына багышланган хикәясен.— Инде ике малаем бар. Олысы, Витюня, әле уголовник кына, ә икенчесе инде, алты яшьлек кенә булса да, чын башкисәр-пират. Өченчесе кыз булыр дип өметләнеп көтеп торган идем, анысы да бандитлар токымыннан булып чыкты. Картлар, сугыш булыр алдыннан ир бала туа, дип юрыйлар. Минем малайларым сугыш булмаса да дөньяның астын-өскә китерерлекләр. Ә хатынны беләсез инде. Аның теленә бер эләксәң, инфарктсыз котыла алмыйсың. Еланныкы шикелле агулы тел. Аннан бөтен күршеләр куркып тора. Менә шундый хатын эләктердем мин, егетләр. Диңгездә чакта гына бераз тын алып яшәргә була. Сәяхәттә йөргәндә дә әле аның агулы сүзләре эфир аша мине куып житә.

— Сайлаган сазга, очраган базга, ди безнең татар әйтеме,— дим мин Сусликовка.— Савытына күрә капкачы.

Хатыны исенә төшкәч, аның кәефе бозылды. Әллә ишетмәде, әллә аңламады минем сүзләрне. Сусликов бассейнга чумды да морж шикелле пошкырып йөзеп китте.

Океан өстендә йолдызлар яна башлады. Су өстен серле тропик төне каплаган. Диңгезчеләр, урыннарыннан торып, каюталарына тарала башладылар. Мин дә каютама кереп йокларга яттым.

Йоклыйсы килми. Нигәдер шул экипажга жанлы каһәр булып тагылган Сусликов турында уйлыйм. Бәхетсез ул. Үзе бәхетсез булганлыктан, юлында очраган башка кешеләрне дә, үзенең бәхетсезлегенә үч йөзеннән, начарлык эшләргә, аларга авырлыклар китерергә тырыша.

Игелек жирдә ятмый, дигәннәр ерак бабаларым. Адәм баласы эшләгән әшәкелекләр дә жирдә ятмыйча, бер вакыт жәза булып, әшәкелек эшләгән кешенең үзенә кире әйләнеп кайта булса кирәк. Начарлыкка каршы начарлык эшләп ята торган ниндидер көч бар жир йөзендә. Дингә ышанучылар ул көчне аллаһы тәгаләгә санап йөриләр. Әшәкелек ул, теге Австралия аборигеннарының коралы томагавк шикелле, әйләнеп кайтып, кире хужасына бәрә. Адәм баласының һәр эше, һәм мөнәсәбәте эзсез югалмый. Алар ниндидер катлаулы комбинацияләр аша үтеп, тормыш юлына кире килеп чыгалар.

## Утыз беренче тәүлек. Һугли елгасы. 21.00

Калькутта портына барабыз. Караңгы төшеп килгән чак. Әгәр Һиндстан ярыматавының төньяк өлеше дә диңгез, яисә даладан торса, Тимерказык йолдызы нәкъ офык читендә булыр иде. Офыкның көньягында Көньяк тәресе яна. Алар дүртәү. Моннан караганда шуларның өчесе күренә, дүртенчесе офыкка күмелгән. Туган ил Һималай таулары, чүлләр, елгалар артында калды.

Радиоалгычымны кабызам. Радио дулкыннары татар көенә тартым бер матур моң алып килде. Бенгал кызы жырлый. Халкымның борынгы

көйләрен мин венгр җырларында, Шотландия, ерак Корея җиренд ишеткәнем бар. Менә бүген бенгал кызының җыры шул кадәр әнием җырлавын хәтерләтә. Күп халыкларның борынгы көйләре бер-берсенә якынрак булган. Әллә аларның теләк-өметләре үзара шулай якын булган, әллә безнең ерак бабаларыбыз бер-берсенә сырышыбрак яшәгән. Мәктәп тарихында без халыкларның үзара сугышуларын, кан коюларын, яулап алуларын өйрәнәбез. Андрей Боголюбскийның тәнендә җитмеш биш процент кыпчак каны аккан. Иван Грозныйга кадәр татарлар белән руслар арасында шактый тыгыз дуслык яшәгән. Уртак гореф-гадәтләр, уртак көйләр шундый чакларда барлыкка килгән булса кирәк. Әбиемнең мөнәҗәт көен армия хезмәтенә эләккәч, кабат ишеттем. Шул көйгә рус малайлары «Хазбулат удалой» дигән җырны җырлыйлар иде. Венеция портында торганда берәү миңа Коръән көендә борынгы рим легионерларының поход маршлары сакланып калган, дип сөйләде. Без хәзер композиторлар чыгарган көйләрне җырлыйбыз. Композиторлар гади халык вәкилләре шикелле бер-берсенең йөрәк җылылыгын сизә алалармы икән соң?

Бенгал кызы, тоеп торам, мәхәббәт турында җырлый. Бенгалиядә элек яшь кыз белән яшь егет, нәкъ бездәгечә, су юлында очраша торган булган. Бенгал егете мәхәббәт турында язган хатын баш түбәсенә чүлмәк утыртып судан кайтучы чибәр кызга укка тагып җәядән ата торган булган. Сукмакка кадалган укны күргәч, кыз тукталмыйча барырга һәм барган җиреннән башкаларга сиздермичә укны юлдан күтәреп алырга тиеш булган. Укны алганда әгәр аның чүлмәгеннән бер тамчы суы җиргә тамса, ул тамчы киләчәк күз яшенә юрала торган булган. Уңган кыз җирдә яткан укны, карап торучыларга сиздермичә, барган җиреннән уң аягының баш бармагы белән эләктереп һавага чөя һәм кулы белән эләктереп ала торган булган. Элекке заманда өлгерлекне, хәрәкәтләр матурлыгын менә нинди юл белән тәрбияләгәннәр!..

Кояш рәхимсез кыздыра. Каршыда бакча күрдем дә тизрәк агач күләгәсенә ашыктым. Бакчаның үзәк мәйданындагы чәчәк түтәле янына чокыр казыганнар. Чокыр янындагы кызгылт балчык әле кибеп тә җитмәгән. Шул балчык өстендә күлмәге балтырына җитеп торган бер ябык кеше утыра. Машина килеп туктады. Машинадан өч кеше чыкты. Икесе ир кеше, берсе хатын. Ирле-хатынлысы европалылар. Аларның йөзләренда муллык тудырган тәкәбберлек. Андый тәкәбберлекне Европа илләрендә йөргәндә табигый саныйсың, һиндстанда исә ул тышка бәреп чыга, канәгатьлек, яши белү билгесе булып әллә кайдан күзгә ташланып тора.

Ниндидер тамашага әзерләнәләр. Халык һаман өстәлә. Машиналар, җәяүлеләр һаман килеп тора. Чокыр янына туктаган зур ак машина эченнән ике ак халатлы кеше чыкты. Шуның берсе балчык өстендә утыручының пульсын санап карады, кан басымын үлчәде. Аңа нәрсәдер әйттеләр. Ак күлмәкле кеше ашыкмыйча гына чокыр төбенә төшә башлады. Мин якынрак килдем. Чокыр төбенә ак тукыма җәелгән. Ул шул җәймәгә чалкан сузылып ятты.

Әллә ул берәр җинаять эшләгәнме? Әллә аны җәзага тартып, тере килеш җиргә күмәләрме? Җиргә күмсәләр, бу кешенең йөзе шундый тыныч булыр идеме?

Унбиш минут чамасы вакыт үтте. Хәзер аның буыннары йомшаган, тынычлыкка сугарылган. Кояшта кызынып йоклап яткан мәче тынычлыгы нәкъ шундый була.

— Хәзер ул йөрәк тибүен туктатты,— диде янымда басып торучы европалы инглиз телендә.— Ул хәзер анабиоз хәлендә. Кышын озакка сузылган йокыга талган җәнлекләр шикелле яши белә алар.

Мондый туристларны җир шарының теләсә кайсы почмагында очратырга була. Яшьли алар җиң сызганып эшли, акча җыя. Пенсиягә

чыгар вакыт җиткәндә мая житәрлек җыелган, шәһәр читендә вилласы, автомобиле, яхтасы, ябык клубта урыны — барысы да бар.

Мал да, дан да кызыктырмый пенсиягә чыккан европалыларны. Алар сәяхәткә чыгып китә. Ел саен яңа җир. Һәр сәфәр алдан уйланган, җентекләп тикшерелгән, юлда кирәк булачак белешмәләр тәртипкә салынып, чемоданга бикләп куелган. Хәтта кием-салым да, эссе төбәкләрдә кияргә кыска чалбар, челтәрле тукымадан тегелгән кыска җиңле блузка, салкынрак җирләрдә кияр өчен йон свитер, куртка, аяк киемнәре — барысы да җентекләп сайлана. Юлда йөргәндә алар һәр урынның колоритын истә калдырыр өчен халык сәнгатеннән сувенирлар, борынгы хәрабәләрдән ташлар, экзотик агач яфраклары, җимеш төшләре, отель этикеткалары җыя. Чокыр тирәсенә күбрәк шундый туристлар җыелган иде.

Казылган җир янына кыска саплы сапер көрәге тоткан ике солдат килеп басты. Менә алар чокырга балчык ыргытырга керештеләр. Адәм баласын тереләй җиргә күмәләр. Сорнай уйный башлады. Аның тавышы анасын югалткан сабый бала елаганын хәтерләтә иде. Янымдагы америкалы, кыска хаки чалбар, шул ук тукымадан теккән кыска җиңле гимнастерка кигән кеше лач-лоч сагыз чәйни. Күз алдыбызда кешене тереләй җиргә күмәләр. Ни өчен? Фән өченме? Аның өчен галимнәр күпме ак күсе, күпме эт суя. Әле күптән түгел АКШта ЛСД дигән даруны сынаганда күпме кешене юләрләр йортына озатырга туры килгән. СПИД авыруын — бүгенге көндәге иң куркыныч, бернича елда кешелек дөньясын юкка чыгара алырлык чирне фәнни тәҗрибә вакытында таралган дип яза башладылар. Менә хәзер күз алдымда тәҗрибә өченме, әллә бары тик тамаша өчен генә кешене тереләй җиргә күмәләр.

Күмә башлаганда сәгатемә карарга онытканмын. Соңыннан янымда торучылардан сорап карадым. Берәүләр — ярты сәгать, икенчеләр — кырык минут булды диде. Көтеп торганда вакыт әкрен үтә бит ул. Бәлки шуңа күрә озак тоелгандыр? Сорнай туктады. Барабан кага башлагач, теге ике солдат чокырга тутырган туфракны кире өскә ыргытырга тотынды. Ашыгалар. Көрәк ташка тиеп чыңлаганда сискәнеп китәсең. Гүрдән чыккан кешене һәркемнең үз күзе белән күрәсе килә. Арттарак торучылар безне этә башлады. Балчык ыргытырга урын калмады. Полицейскийлар безне читкәрәк куа.

Кызгылт балчык эченнән тырпаеп торган аяк бармаклары күренде. Күгәреп беткән җансыз соргылт бармаклар. Казучылар көрәкләрен ташлады. Туфракны куллары белән як-якка этәрәләр. Ниһаять, «мәет»нең бите күренде. Солдатның берсе аның битендәге балчыкны сыпырып төшерде. Мескенне култыклап алдылар, чокыр эченнән сөйрәп чыгардылар. Врачларның берсе «мәет»нең күлмәк изүен ычкындырып җибәрде, икенчесе йөрәк тибүен тыңларга кереште. «Мәет» күзен ачты. Исән!

Нинди зур, нинди чиксез мөмкинлекләр туплаган табигать безнең тәнгә һәм җаныбызга. Адәм баласы һава суламыйча ярты сәгать җир астында ятып карады. Исемә кашалот карнына эләккән Норвег гарпунчысы килеп төште. Ул хакта җир йөзендә чыга торган барлык газеталар шау-гөж килгәннәр иде. Кашалотның корсагын ярып, йотылган гарпунчыны кире чыгаралар. Үт суына мескен диңгезченең тиресе генә пешкән була.

Һиндстан йоглары атны үтерерлек aгуны эчеп, тамак, ашказаны һәм эчәгеләре аша шул агуның бер генә молекуласын да үзләштермичә чыгарып җибәрә алалар. Алар күз карашы белән үлән үсүенә тәэсир итә, җирдә яткан әйберләрне шул ук күз карашы белән хәрәкәткә китерә ала. Безнең тәндә, безнең рухта, ихтыярда шундый зур мөмкинлекләр тупланган. Аны хәрәкәткә китерә, куллана гына белмибез. Гомер буе нәрсәдәндер куркып, гомер буе кемгәдер буйсынып, рәсми сафсатага шиксез ышанып, ни кушсалар, шуны эшләп, көч-хәл белән вакыт уздырабыз. Һәм шул безнең телдә «яшәү» дип атала.

Һиндстан миңа адәм баласының яшерен мөмкинлекләрен ачып күрсәтте. Аларның күбесе уянмыйча, кулланылмыйча безнең белән гүргә керә.

## Утыз җиденче тәүлек. Калькутта. 19.00

Диңгез эше, йөзүче вазифасы безне тагын әллә кайларга илтәчәк, әллә нәрсәләр күрсәтәчәк. «Алексей Щусев» экипажындагы утыз өч кеше туганнан бирле гел бер төрле юлдан барганбыз. Ясле, балалар бакчасы, мәктәп, армия хезмәте, институт, ниһаять, диңгезчелек һөнәре. Егерме белән утыз арасында — гаилә. Кырыклар тирәсендә фатирлы булу. Тотанаклы яши белүчеләр кырыктан соң җинел машина ала. Чын-чыннан саран, һәр тиенен санап кына көн күрүчеләрнең иллене узгач машинадан тыш дачасы да була. Без шуңа күнеккәнбез. Шушы юл безгә табигый тоела.

Бүген мин Калькутта урамнарында бөтенләй башка тормыш күреп йөрим. Бу калада миллионнар урам ташында дөньяга килә. Ясле, бакча, мәктәп еллары — аларның берсе дә юк бу мескеннәргә. Аларның гомерләре шул ук урам ташында ачык һавада уза. Институт еллары да шул ук урам ташында. Түшәм урынына йолдызлы күк, идән урынына — таш тротуар. Түшәк тә, ястык та шул ук таш. Гомер буе аларның аягы — аяк киеме, тәннәре чиста күлмәк күрми. Даими юлдашлары — ачлык һәм ялангачлык.

Көндез консуллыкка барганда шушы урамнар машиналар һәм атлар карамагында иде. Караңгы төшү белән алар башкача җанланды. Әнә тротуарда кара-каршы утырып ир белән хатын нәрсә турындадыр мавыгып сөйләшә. Дикъкать биреп, чын күңелдән тыңлыйлар бер-берсен. Димәк, гаиләдә татулык, аңлашу яши. Яңа тәпи йөри башлаган бер шәрә малай тыныч кына бармагын суыра. Шул шәрә малай янындагы нәни кыз курчак уйный. Алар арасындагы унбишләр тирәсендәге арык хатынның кулында имчәк баласы. Бер кулы белән баласын кочаклаган, икенче кулы белән консерва банкасында пешкән ботканы болгата. Унбиш яшендә картая башларга өлгергән хатын тынгысызланып юлга карый — ирен көтә булса кирәк. Әнә шул ук урам ташында утыручы яшь егет каршысында урнашкан кызның кулын кысып торткан да, күзенә карап, дөньясын оныткан. Икесе дә чибәрләр. Матурлыкны — яшьлек бүләген, ач яшәү, ялангачлык, урам ташында төн үткәрү дә җиңә алмаган. Яшь кыз белән яшь егет, дөньяларын онытып, бер-берсенә сер сөйлиләр.

Нинди җирдә, кай очракта гына тумый бу мәхәббәт! Алтын сарайлардагы тәхеттә, чүлдә, сугыш кырында, шахта карнындагы авыр эштә, төрмәдә һәм менә урам ташында. Мәхәббәт көче бернәрсә белән дә исәпләшми, юлында очраган киртәлекне җимерә ала. Аңа тәхет тә, төрмә камерасы да сукыр бер тиен. Аның урыны йөрәктә.

Нинди хикмәтле ил бу Һиндстан! Бу илдә яшәү фәлсәфәгә сугарылган. Аларның диннәре, көнкүрешләре, эшләре, теләкләре — шуларның барысы да фәлсәфәгә төрелгән. Юк, бу ил кешеләренең фәлсәфәсе бездәге шикелле сүз көрәше, фикер ярышы гына түгел. Ярлылар үз көчләре белән яшәргә кирәкле нәрсәне таба алмагач, язмышларын тәкъдир кулына тапшырганнар. Ачлар бер тапкыр туйганчы ашау бәхетен күктән көтә. Бу мескеннәрнең гомерлек юлдашы — сабырлык. Көтә, өмет итә белү аларның каннарында, сулыш алуларында. Һиндстанда яшәүче кабиләләрдә мин үземнең ерак бабаларымны, «сабырлыклар саф алтын бит...» мөнәҗәтен көйләүчеләрне таныйм. Нәрсәдәндер юаныч таба белә бу кешеләр. Яшәү өчен кирәкле бер генә нәрсәләре юк мескеннәрнең, ә күз карашларында — өмет, йөзләрендә, хәрәкәтләрендә юану билгесе тынычлык. Без нилектән күршебез тәрәзәсе ишегалдына, безнеке урам

якка чыккан булса, үзебезне кимсетелгән санап, рәнҗи, күршебезгә теш кайрый башлыйбыз? Бездә нигә бердәмлек, бер-беребезгә игелек теләү, яхшылык күрсәтү юк? Нигә? Ерак бабаларыбыз андый булмаган бит. Кайдан кергән безгә көнләшү, вакчыллык, бер-беребезне күрәлмау? Боларның барысы да безгә чит гадәтләр — кемнән йоккан алар? Андый әшәкелекләрне ни сәбәптән кабул иткәнбез? Ят тарих тарткан чанага утырып бару дәверендә әкренләп, ятлар җырына күнегүебезне гарәп, фарсы һәм һиндлеләрне күзәткәннән соң гына аңлый башлыйсың. Милләтнең әшәкесе-әйбәте, яхшысы-яманы булмый. Милләт үзенең тарихта узган юлын чагылдыра, шуны хәтерләтә. Күркәм гадәтләр начарга алышына икән, тарих сине авыр шартларга куйган булып чыга. Аның сере шунда гына.

Калькутта урамнарында төн кунучыларны карап йөргәннән соң, адәм баласының нигә шулай тиз үрчүен аңлый башлыйсың. Бәлки кеше затын шушы талымсызлык, тиз үрчү саклап калгандыр? Фил, мамонт, арыслан киек, кит балыгы белән чагыштырып караганда, адәм баласы шактый йомшак, шактый көчсез бит. Эволюция дәверендә динозаврлар, кылыч тешле юлбарыслар табигать көченә каршы тора алмыйча юкка чыкканнар, адәм баласы калган? Ә сугышлар? Сугыш та юкка чыгара алмаган афәт затын...

Кичә эсселек басыла төшкәч, мин «Изгеләр бакчасы»н карарга бардым. Бездә чүлмәк гөле саналган фикус шушы бакчада күкләргә тия язып үсеп утыра. Агач ботакларына тутый кошлар кунаклаган. Чәчәккә күмелгән үзәк мәйданына, бездәге Мактау тактасын хәтерләткән «Изгелек юлы»ның схемасын ясап элгәннәр. Башта изгелек юлында кешенең начарлыклары белән көрәшүен, шуларны җиңеп, яхшылыкка баруын күрсәткәннәр. Шушы бүлектәге сурәтләрне: адәм баласы ялгыша, чөнки аның табигатендә дә даими яхшылык белән начарлык көрәшә; яхшылык җиңсен өчен кеше начарлык белән туктаусыз алышырга, аны бетерергә тиеш, дип аңларга була.

Яңа туган сабый. Аның бурычы — таза һәм матур булу. Бала мәктәпкә йөри башлаган. Аның бурычы — тырышып уку, әти-әнисенең сүзен тыңлау, остазлары әйткәнне үтәү. Ул инде яшь егет, студент. Аның бурычы — фәннәрне үзләштерү, һөнәргә өйрәнү, җәмгыять эшенә катнашу. Хәзер ул яшь түрә. Аның бурычы — тырышып эшләү, вазифасын гадел, тугры башкару, гаиләсе өчен мул, төгәл тормыш кору, балалар тәрбияләп үстерү. Гомер буе дөреслектә яшәп, савап казанып яшәгән картның мәетен яндырырга илтәләр. Инде учак яна, төтен белән изге кешенең җаны җәннәткә күтәрелә. Җирдә калган балалар әтиләре үткән изге юлны дәвам итә. Һиндләрнең гади телендә «көрәш» сүзе юк. Бәхетле булу өчен тулысынча нәфестән арынырга һәм күпкә үрелмәскә, күпне теләмәскә кирәк. Аларның яшәү фәлсәфәсе шушы сызымга сыеп бетә диярлек.

«Изгелек юлы»н карап үткәннән соң, мәет яндыра торган учакка юлыктым. Тирә-якка сызык исе таралган. Учак аша адәм баласын соңгы сәфәргә озаталар. «Юлчы» күмерләнгән, озакламый ул көлгә әйләнәчәк. Учак тирәсенә мәрхүмнең туган-тумачасы, балалары җыелган. Тынлык. Башлар аска иелгән. Күзләр җирдә. Башка дөньяда аларның уй-хисләре. Беркем еламый. Тынлык елаудан көчлерәк тәэсир итә икән.

Кемдер үксеп еларга тотынды. Тукта әле, елаган тавыш агач башыннан ишетелә ләбаса! Күтәрелеп карасам — бохар күгәрчене. Шушы тавышны мин беренче тапкыр Урта Азиядә ишеткән идем. Борынгыларның: «дөнья белән саубуллашканда кешенең җаны кош булып авызыннан очып чыга», дип ышануы искә төшеп куйды. «Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңелем кошы...» дигән бөек Тукай. Чыннан да, күпләргә, бик күпләргә дөнья — читлек. Читлек рәшәткәләре — эш, теләк, гаилә, юл тапмаган сәләт, тагын әллә ниләр. Яшәешне үзгәртергә көчем җитми һәм бәлки үлгәнче шул читлектән чыгарга дәрманым җитмәс тә? Нәрсә-

дер куркыта. Тыныч тормыш телисең, ә сайлаган юнәлешең, кыйблаң гел авырлыкка, катлаулы һәм тынгысыз якка гына алып бара. Берни эшли алмыйсың...

Бары бүген күргәннәр генә дә кинәт авыр тоела башлады. Алардан ничек арынырга? Исемә күршебез Бәдигыльҗамалттәй килеп төште. Мена кем бәхетле яши белә иде. Авыл читенә чыкканы да юк иде аның. Учак яга, аш пешерә, кер юа, өен җыештыра, колхоз эшенә йөри һәм бала тудыра иде. Йорт һәм колхоз эше, семьясы һәм күршеләре — аның офыгы шуның белән чикләнә иде. Бер җайне капка төбендә сөйләшеп утырганда сүз ара сүз чыгып, кемдер тегермән ташын су әйләндерүе турында сөйләде.

— Бәй, көлмисезме сез миннән ахирәтләр? — дип сорады Бәдигыльҗәмалттәй. — Ул бит ни, тегермән ташын су әйләндергәч, он юеш булырга тиеш. Соң нишләп тегермәннән кайткан он коры була?

Аңгыралыктан да, наданлыктан да түгел иде күрше хатынның күп нәрсәне белмәве, аңламавы. Аңа сүз мохитыннан читтәге нәрсәләр кирәк түгел иде. Йорт һәм колхоз эше, балалары турында кайгырту, гаилә тынычлыгын саклау — аңа шул җиткән иде. Бу хатынның күңеле ак кәгазьне хәтерләтә иде. Шундый саф, шундый ак иде аның дөньяга, җәмгыятькә булган мөнәсәбәте.

Корабыма кайтырга чыкканда караңгы төшкән иде инде. Күктә ялгыз атауга охшашлы кара болыт. Шуңа таба ай йөзеп бара. Ай болыт эченә чумып чыкты. Тагын бер болыт һәм, ниһаять, тоташ стена булып өерелеп килгән кара болытлар айны минут эчендә йотып юкка чыгардылар. Җир йөзен шомлы караңгылык каплады. Дымлы кайнар һава электр кырына сугарылган иде. Тәндә авыр тынгысызлык. Йөрәк леп-леп тибә башлады.

Порт капкасыннан кергәндә күктәге елгалар ярларыннан чыкты. Җиргә тоташ су стенасы бүселеп төште.

## Кырык беренче тәүлек. Мадрас. 13.20

Кромондел ярына урнашкан Мадрас каласын мин аеруча зур дикъкать белән карап йөрдем. Колониаль режим Һиндстанга шушы ярлар аша килеп кергән. Газета битләрендә «басып алу», «колониаль режим», «буйсындыру», «апартеид», «агрессия» шикелле сүзләр туктаусыз җемелдәп торсалар да, империализм олтаны астында яшәүче халык аны үз күзе белән күрә алмый. Колониаль режимның үзен түгел, тәэсирен генә тоя алабыз. Аны да махсус өйрәнгән, аңлаган кеше генә белә ала.

Ост-Һинд компаниясе сәүдәгәрләре товарларын саклап тоту өчен 1639 елны Куум елгасы тамагына урнашкан Мадраспатинам исемле авыл янынннан алты йөз фунт стерлингка Һиндстан җирен сатып алалар. Шул сатып алган җиргә алар Сент-Джордж исемле ныгытма коралар. Идел буендагы Васильсурск һәм Түбән Новгород ныгытмалары да нәкъ шул юл белән төзелгән була. Ныгытманы һәм шул ныгытма эчендәге товарларны сакларга Англиядән гаскәр килә. Ост-Һинд компаниясе сәүдәгәрләре сату итү эшен шымчылык белән бергә алып бара. Алар артыннан ярыматауга гаскәр үрмәләп керә.

Һиндстанны яулап алуда инглиз гаскәрләре катнашмый диярлек. Бу үтеп керү татар тарихындагы хәлне хәтерләтә. Кабиләләр арасындагы көрәш, тәхет өчен барган ызгыш, дошман ягына күчеп, үз иленә сугыш алып килү, уч алу — мәгълүм хәрәкәтләр монда да тулысынча кулланыла. Сент-Джордж ныгытмасын төзүгә кырык ел тулганда Һиндстан ярыматавының бөтен җирен инглиз колонизаторлары дагалы итеге таптый башлый.

Безнең эраның алтмыш бишенче елында үлгән Борынгы Рим философы һәм әдибе Луций Анней Сенека Луцинийга язган хатында болай

ди: «Башка халыкларны буйсындырып, өстенлектә яшәү беркайчан да ышанычлы булмый. Яулап алу белән шөгыльләнгән халык мантымый». Һиндстаннан инглиз колонизаторларын куып чыгардылар. Һинд халкы азат яши. Колонизаторлар олтаны астында яшәгән халык тиз генә мантый алмый әле. Политик һәм экономик яктан бу мәсьәлә күптән ачыкланган. Психологик яктан колонизаторлыкның халык рухында күп еллар төзәлә алмаслык җәрәхәт калдыруын гына без әле өйрәнмәгәнбез. Килмешәкләргә буйсынып яшәгәндә халыкның горурлыгы сына, бердәмлеге таркала, бу очракта куштаннар, сатлык җаннар үрчи. Колониаль көнкүреш имансызларга чиксез мөмкинлекләр ача.

Сент-Джордж нygытмасы эчендә, элекке инглиз генерал-губернаторы сараенда музей ачылган. Зур, иркен залларда алтын йөгертелгән рамнарга куелган инглиз корольләренең, Һиндстан халкы канын койган генералларның портретлары эленеп тора. Түшләрдә орден, җилкәләрдә алтын эполетлар — шуларның барысы да җирле халыкны кырган, таптаган өчен бирелгән.

Ярлы чиновниклар, бөлгән дворян балалары Һиндстанда бераз хезмәт иткәч, Англиягә баеп кайта торган булганнар. Нәкъ шул хәл Мәскәү дәүләте заманында булган. Колониаль түрәләрнең баю бәрабәренә җирле халык бөлгән, хәерчеләнә барган.

«Идарә ит, Британия! Идарә ит диңгезләрдә! Инглизләр беркайчан да кол булмаслар!» — дип башлана Британия империясе гимны. Башка халыкларны коллыкка төшерүчеләрнең беркайчан да кол буласылары килми. Чөнки алар коллыкның нәрсә икәнлеген башкалардан яхшырак белә. «Бүлгәлә һәм хакимлек ит!» Колонизаторларның төп шигаре бу.

Кешелек тарихы тоташ ул. Шуңа күрә, Һинд океаны ярындагы Мадраска килеп, үз халкыңныкына охшаган язмышларны күрү, шуны аңлау офыкларыңны киңәйтә.

## Кырык дүртенче тәүлек. Һинд океаны. 18.20

Муссон җиле айлар буе бер юнәлештә исә бирә. Юнәлешен үзгәртер алдыннан туктый. Без Мадраска килгәндә муссон җиле туктаган чак иде. Һава тыныч. Кораб торбасыннан чыккан төтен ак багана булып һавада утырып кала да, озак таралмыйча тора. Океан өстеннән аңгыра дулкыннар тәгәри. Алар сафка тезгән солдатлар шикелле, тигез ара тотып, бер-берсеннән калышмыйча көнчыгыштан көнбатышка таба ашыга. Янибыздан узганда йөгерек дулкыннар ашыгыч кына корабны кыйнарга да вакыт таба. Бер зыянсыз, бер гөнаһсыз барган җиреннән кыйналган кораб рәнҗи, әүмәк-тәүмәк килә һәм ыңгырашып куя. Юләр дулкыннар яр янында сайлык сагалап торганын белми. Сайлык аларның сафларын боза, ызгыш кузгата. Гомумән, сай тормышта ызгыш һәрвакыт көчлерәк була. Океан ярына бәрелеп тар-мар килгән дулкыннарда киңлектә йөзгәндәге бердәмлек тә, ул чактагы сабырлык та юк. Ватылып, эре тамчыларга, ярга чәчелгән су бөртекләренә әйләнер алдыннан алар үкерә, гауга куптарып, бер-берсенә ташланырга, дөмбәсләргә өлгерә. Күңелгә бер уй килә: бары тик иркенлектә, азатлыкта гына тату яшәп була икән. Кысынкылык ызгыш, бер-береңне күрәлмау тудыра. Деградациянең башы — кысынкылык.

Мадраста торганда автобуска утырып ярдан җитмеш чакрымда яткан Дак тауларын карарга бардык. Яшел үзәннәр белән телгәләнгән ак түбәле күкшел таулар. Ерактан караганда таулар шулай күренә. Якынлашкач, тауларның ак түбәләре кызгылт калкулыклар, тропик урманында үскән гигант агачлар артына кереп яшеренде. Автобус һаман югарыга үрмәли. Белградтан Дубровникка барган чак искә төшә. Анда да таулар, ләкин табигать мондагы ташларны, юл буенда үскән агачларны бөтенләй икенче төрле итеп яраткан. Үзенчәлегеңнең иге-чиге юк, табигать!

Юл кыя итәгендә өзелеп туктады. Автобустан чыктык. Боцман Савчукның көндәлек боерыклары эченә җыелган икән. Җиргә төшү белән алар тышка бәреп чыкты.

— Дулев, ашамлыкларны бушата башла. Саграк кылан, анда пыяла банкага тутырылган азыклар бар. Ә син, Петлюга, ботак җыеп кил. Учак яга башларга кирәк. Тизрәк кылан, ишетәсеңме? Әй, Сусликов, син кая таясың? Табын янына иң беренче булып килеп утырасың. Әйдә, бәрәңге әрчи башла.

Без — электромеханик Давыдов, өлкән ярдәмче Василевский һәм мин, тизрәк кыя өстенә таба үрмәләдек. Тауга менү кешене балачакның саф куанычларына кайтара. Тау сыртына менеп карасам, киләчәк өмет-багланышларым күренер шикелле тоела миңа.

Давыдов Казахстанда туып үскән. Ул тауга менүнең серләрен белә. Хәрәкәте салмак, сак һәм ышанычлы. Василевский ашыга, кай чакта аның аягы бушлыкта асылынып кала. Мин Давыдов баскан эзгә басып, ул кагылган куакларга тотынып барам. Тормышта һәркайчан тәҗрибә үрнәге кирәк. Тауга менү безнең тормыш юлында туктаусыз очрап торган көрәшне хәтерләтә. Һәр адымны уйлап, чамалап басарга кирәк. Яшәүнең көрәш икәнлеген тауга менгәндә ачыклыйсың.

Ниһаять, биек кыяның түбәсенә менеп җиттек. Биеккәрәк менгәч, офык киңәйде, яңа үзәннәр, яңа тау сыртлары ачылып китте. Алар, үзара ярышып, төньякка таба тезелеп киткән. Берсеннән берсе матур. Көрәнсу, соргылт, яшел, кызгылт, фирәзәнең йөз төрле үзгәлекләре, кыяларның яңгырлар белән юылган пакьлеге күңелдә кайнар соклану уята. Мондагы биеклекләр, чиксезлек, төсләр җемелдәвен тасвирлау өчен гадәти сүзләрнең көчсезлеген тоя башлыйсың. Тауга менү балачак куанычларына кайтару белән генә чикләнеп калмый. Тауга менү яшәү офыкларыңны киңәйтә. Василевский сумкасыннан бинокль чыгарды. Диңгезгә карый.

— Егетләр, карагыз әле, яшел чаткы! — дип кычкырып җибәрде өлкән ярдәмче.

Яшел чаткы күргән кеше бәхетенә ирешә, дигән ышану яши диңгезчеләр арасында. Бинокль кулдан кулга күчә башлады. Күпме карасак та, без Давыдов белән бәхет китерә торган чаткыны күрә алмадык.

— Таудан караганда океан өстендәге рәшә күренә икән,— ди Давыдов.

Чыннан да, океан өстендә үтә күренмәле сыек пәрдә асылынып тора иде. Давыдов бинокльне миңа суза. Мадрас каласы яр буенча чәчеп ташлаган чуерташларны хәтерләтә. Океан белән күк йөзе еракка, бик еракка китеп үзара кушыла һәм күкшел томанга әйләнеп юкка чыга. Бинокльне тауларга таба борам. Автобус торган таш платформа моннан караганда күренми. Ул кыя төбенә яшеренгән. Упкынның теге ягындагы тагын да зуррак итәгендә яшел үлән каплаган тигез алан. Яшел үлән арасында соргылт ташлар аунап ята. Кинәт шул ташларның берсе кыймылдап алды. Нилектән бу? Икенче таш кыймылдады, өченче һәм дүртенче таш. Ташлар кинәт хәрәкәткә килделәр. Аңлашылды. Ял итәргә яткан тау кәҗәләре читтән караганда таш булып күренә икән. Табигатьнең даһи бер җайланышы.

Көтүдән читтәрәк алгы аяклары белән ташка басып сакчы тәкә тора. Көтүнең икенче ягында да ташка басып торган сакчы. Аяклар озын, гәүдә шундый җыйнак. Очка таба салмак кына нечкәреп килгән авыр пар мөгез кирәк чакта ышанычлы коралга әйләнә. Сакчы тәкәләр якякка борылып һаваны иснәп тора. Менә ничек була икән ул чын җаваплылык һәм гаделлек! Тынгысызлык туды, ахры, сакчыларның гәүдәләре озынаеп киткәндәй булды, муен алга сузылды. Һава иснәү ешайды. Сакчының берсе тавыш бирде, ахры. Ял итеп ятучы тау кәҗәләре дәррәү аякларына бастылар. Юлбашчы тәкә көтүдән аерылып алга чыкты. Ул дикъкать белән сакчылар күрсәткән якка карый, иснәнә, тоягы белән җир тырный.

Юлбашчы алга сикерде. «Очтык! Калышмагыз миннән!» Юлбашчы артыннан ургылган тау кәҗәләренең гәүдәләре җәядән ычкынган укны хәтерләтә иде. Көтүне ике барс куа иде. Алар ял итеп яткан көтүгә җилгә каршы түшләре белән шуышып якынлашканнар икән. Сизгер сакчылар хәвефне сизеп, юлбашчы вакытында дөрес юнәлеш сайлап өлгерде. Тау кәҗәләренең нинди оста, нинди тиз афәттән котылулары сокландырды мине. Без, адәм балалары, үзебезне хайваннардан акыллырак саныйбыз. Бу фикердә ялгышлык зур. Хайваннар алдан план корып, оештырып бер-берсен үтерми. Алар табигатьне үзгәртеп, үз җайларына көйләми. Киресенчә, үзләре табигать шартларына җайлашырга, ярарга тырышалар. Юлбашчы сайлау эшен, әйтеп тә торасы юк, искиткеч зур гаделлек белән үткәрәләр. Яз җитү белән юлбашчылыкны дәгъвалаган яшь тәкә урман эчендәге аланлыкта юлбашчы карт тәкә белән очраша. Көрәш ачык. Билгеле, иң зирәк һәм иң көчле җиңә. Күп очракта көрәш үлем белән тәмамлана. Җанмы, властьмы, шуның кайсын сайлыйсың? Шушы аяусыз ярышта җиңеп чыккан иң көчле, зирәк, тәвәккәле юлбашчы вазифасын үти башлый. Шушы көннән алып ана җенесләрнең мәхәббәтләре аның тарафында һәм ул нәсел калдырырга хокуклы. Токым буыннан буынга яхшырып торырга тиеш. Табигатьнең таләбе шундый.

Нишләп андый гаделлек кешеләрдә юк икән? Хәйлә белән, интрига, гаделсезлек белән тәхеткә менүчеләр бүгенге көндә дә аяк атлаган саен очрап тора. Италиядә, мәсәлән, хөкүмәт башлыгы ай саен диярлек алышына. Италиялеләр көлә: «Алар, үзара ызгышып, тәхет көрәше белән мавыгулары аркасында безгә яшәргә комачаулык китерә алмый»,— диләр. Италиядә экономика хөкүмәт кулында түгел, закон да конституция карамагында. Ә бездә бит хезмәт ияләренең, һәр кешенең язмышы бик озак юлбашчы кулында булды. Сталин дәвере, әшәкелекләре, корбаннары безгә сабак булмас микәнни? Ә Брежнев чоры? Ул үзе чин алу, түшенә орден тагу белән мәшгуль булса, безнең язмыш идарә дилбегәсен эләктергән намуссызлар кулына керде. Илдә ялган, ришвәт, үтәмәскә бирелгән вәгъдә хөкем сөрде...

Кыя итәгеннән:

— Ит пеште, чәй кайнады. Әй, өстәгеләр, тизрәк төшегез! — дип кычкырдылар.

Аска төшү кыен булды. Ә бит власть биеклегеннән төшү мең тапкыр газаплырак. Бу дөньяда кемнең үз ирке белән югарыдан түбәнгә төшкәне бар? Өскә үрмәләү, югарыга омтылудан сукыраю көнкүрешебездәге табигый хәл.

## Сиксән тугызынчы тәүлек. Эйвонмоут, Бристоль. 07.30—23.00

Инглиз йорты тышкы яктан кырыс күренә. Белмәгән кеше аның эчендә дә шыксыз дип уйлый. Бизәк тә, тантаналы колонналар, мәрмәр, гранит ташлар, бронза һәм төрле затлы материаллар инглиз йортының тышкы ягында сирәк очрый. Инглизләрнең «Йортым — ныгытма» дигән әйтемнәре бу халыкның өенә бикләнеп, аралашмыйча, җәмгыятьтән читтә яшәвен генә аңлатмый. Инглизнең торагы, чыннан да, ныгытма. Тышкы яктан ул сиңа кашын җимереп карап тора. Сак бул, ди якын килмә, чит кеше тормышына борыныңны тыгарга уйласаң, белеп тор, хуҗам тынычлыгын, мөстәкыйльлеген саклый белә! Тышкы яктан инглиз йорты сине ишек-тәрәзәсе, түбәсенең ныклыгы, төзеклеге белән җәлеп итә.

Инглиз йортының эченә керсәң... Тукта әле, тышкы яктан шыксыз, кырыс күренгән шул йортмы икән бу? Өйалдындагы комфорт ук сине хәйран калдыра. Әгәр син зонтик тотып кергән булсаң, аны куярга җиздән чүкеп ясаган ваза, аяк киемеңне утырып алыштырырга уңайлы тәбәнәк урындык. Кулыңдагы төргәгеңне, сумкаңны куярга махсус тум-

ба, плащыңны эләргә буш чөй, баш киемеңне куярга киштә, карарга күзге — барысы да үз урынында, җайлы, кул астында. Аяк киемен салгач, йорт эчендә кияргә үкчәсез чүәк эләктерергә күнеккәнбез. Ә монда мех куныччы, җинел, аягыңны сөендерерлек, аңа ял бирерлек йомшак туфли. Тагын шуңысы күзгә ташлана — монда бер генә дә артык әйбер юк һәм, шул ук вакытта, кирәкле һәммә нәрсә бар. Эйвонмоут стивидорының өйалдына керү белән туктап карап тордым: алар иске-москыларын кая куя икән?

Кайчакта, кирәксез әйберләр теңкәңә тигәч, тормышта иң тансык сыйфат — пөхтәлек икәнен аңлый башлыйсың. Мода үзгәрә. Әйбер тиздән үзенең кирәклеген югалта, ә пөхтәлеккә беркайчан да ихтыяҗ бетми. Эти, әниләребез шушы хакыйкатьне тулысынча аңлаган. Караңгы, артта калган саналган татар авылында туып үстем мин. Белмим, безнең авылны нигә караңгы, артта калган санадылар икән? Ул авылда шапшак йорт барлыгын хәтерләмим. Чисталык, пөхтәлек әниләрнең канында иде. Шушы хакыйкатьне Британ атауларына килеп, инглиз йортын караганнан соң гына аңлай алдым мин.

Инглиз йортының бәдрәфе турында диссертация язар идем. Һәр кран төзек, тыныч, хуш ис килеп, ялтырап тора монда. Эш беткәч, кнопкага басасың — күбекләнеп агып чыккан су унитазны тазалап юып агып китә дә шуннан соң бер тамчы исрафка аккан су күрмәссең. Мәскәү — башкалабыз. «Прогресс һәм тынычлык башкаласы» дип горурланып атыйбыз исемен. Бу каладагы уку йортлары, музейлар, театрлар турында уйлаганда йөрәгемдә горурлык уяна. Шушы дөнья күләмендәге мәшһүр культура үзәгендә теләсә кайсы илдән килгән кешегә горурланып күрсәтерлек өч җәмәгать бәдрәфен беләм. Сигез миллион кешеле каладагы җәмәгать бәдрәфләре — йөзебезне кызартырлык!

Инглиз йортының горурлыгы — камин. Камин ясар өчен ул акчасын да, бүлмәдәге урынын да кызганмый. Бу илдә яңгырлы көннәр аяз көннәрдән ешрак була. Тышта салкын яңгыр сибәли. Җил ыжгыра. Эштән кайтканда яңгырда чыландың. Арыдың, күшектең. Кәефең әйбәттән түгел иде өеңә кайтканда. Кайту белән учак ягып җибәрдең. Кәнәфигә чумып утырдың. Күз алдында шытырдап утыннар яна, бүлмәңә камин учагында биегән ялкыннардан серле яктылыгы таралды. Шуңа өстәп кечкә аштан соң бер генә йотым шотланд виские белән эчеңне җылыттың. Дөньяда сиңа башка нинди рәхәтлек кирәк?

Адәм баласы белән маймыл арасында ут табу, ут куллана белү стенасы тора. Учак ярату — ерак бабаларыбызның мирасы. Кеше башта учак янында кыргый җәнлекләрдән сакланган. Ут — адәм баласына тәэсир итә торган тылсымнарның иң көчлесе. Утка карап утырганда нинди генә уйлар килми! Ут тылсымы әллә кайларга, миллион ел артка һәм ерак киләчәкләргә алып китә. Өйдә учак. Урамнарда электр уты. Англиядә яңа ел кеткәләр...

Автобус килеп туктады. Пассажирлар тротуарга коелды. Көтеп торучылар кереп утырды. Беркем ашыкмый, кабаланмый. Кибетләр ачык, эчләре буш. Бәйрәм алдыннан безнең кибетләрдә — кыямәт, монда исә прилавка каршында көтеп торучы да күрмәссең. Бәлки безнең бәйрәм тирләп-пешеп, үләр хәлгә житеп әзерләнү аркасында ямьлерәк була торгандыр?

## Җитмешенче тәүлек. Эйвонмоут. 08.00

Англиянең баш сәгате Лондондагы Биг-Бен суга, даң-доң, даң-доң. Тәүлек алмашынган чак. Без «ура» кычкырып бокал күтәрәбез. «Яңа ел белән, яңа бәхет белән!» Нәрсә икән ул «яңа бәхет?» Бәхетнең искесе ни төсле икән? Әгәр бәхетнең теләсә кайсысын сайлап алу мөмкинлеге булса, мин аның искесен, балачак бәхетен сайлар идем...

Утыз җиденче ел. Без икенче класста укыйбыз. Көзен ишелеп ашлык уңды. Утыз бишенче елны, хәтеремдә, ачлык иде. Утыз алтынчы елны да ипигә туеп яшәүчеләр авылыбызда бары тик берничә генә йортта иде. Утыз җиденче елны Исергәп мәктәбе тарихында беренче тапкыр чыршы бәйрәме уздырылды. Революциягә кадәр безнең Исергәп халкы яңа елны нәрсә икәнен аңласа да, беренче гыйнварьда чыршы бизәүне белмәгән әле. Бездән өч чакрымда Тәпеч исемле рус авылы (язучы Анатолий Ананьевның әтисе туган авыл) бар. Без шул авылда чыршы бәйрәмен үткәргәнне ишетеп белә идек. Утыз җиденче елда беренче гыйнварьны чыршы белән каршыларга дигән фәрман килгән. Гореф-гадәтләрне үзгәртү, «яңалыкка» күчү, культура революциясе еллары иде. Халыкның гореф-гадәте мең еллар буена тамчылап, микъдарлап туплана. Шуларны берьюлы үзгәртү мөмкин түгел. Үзгәртергә яңаларны каян аласың? Гореф-гадәтләрне беркем дә уйлап чыгара алмый, аны тормыш, яшәү ысулы үзе эзли, таба, сайлап ала. Әмма... «кара халык»ның әкиятләре, җырлары, бәет чыгару, мөнәҗәт әйтү — боларның барысы да бер көнне иске гадәткә саналып чүплеккә очты. Җыеннар, бәйгеләр, карга боткалары, өмә итеп өй юулар, киндер агартулар, аулак өйләр, кич утырулар һәммәсе дә яңа тормышта урын таба алмады. Чыршы бәйрәме үткәрү — яңалык билгесе һәм ул ел саен эшкә ашырылырга тиеш иде. Югарыдан төшерелгән фәрман шундый.

Исергәп мәктәбе тарихындагы беренче чыршы бәйрәмендә Кыш бабай итеп, белмим ни сәбәптер, мине билгеләделәр. Өстемә фельдшер Галия апаның ак халатын кидерделәр, мамык сакал тактылар һәм, иң мөһим деталь, кулыма күсәк тоттырдылар. Нигә кирәк булгандыр инде ул күсәк, алла белсен. Узган елны шәһәр җирендә Бөгелмәдәме, Казанның үзендәме, чыршыга ут кабып, Кыш бабай янган булган. Шул уңайдан, район мәгариф бүлеге янгыннан саклану чарасын күрергә, чыршы янында пожарник торырга тиеш дигән карар чыгарган. Мин, Кыш бабай, күсәк тотып, пожарник Гайфи янгын сүндергәндә куллана торган тимер ыргак тотып, бәйрәм тәмамланганчы чыршы янында басып тордык. Ярый әле Тукаебыз бар. Ул тәрәккыяткә ияреп чыршы киләсен белгән, күрәсең, Кыш бабай ролендә нәрсә эшләргә белмичә, тәмам аптырап беткәч, тарих укытучысы Шаһгалиев Гали миңа Габдулла Тукайның «Ак куян, йомшак куян»ын укырга кушты. Шигырь нәкъ чыршы бәйрәменә багышланган шикелле тоелган иде ул чакта.

Корабта бәйрәм үткәрү нәкъ шул Исергәп мәктәбендәге беренче чыршыны хәтерләтә. Бәйрәм алдыннан пароходчылыктан фәрман килә: «уяулыкны көчәйтү өчен, бәйрәм көннәрендә кораб сакларга өстәмә вахта билгеләргә, тикшерүне өлкән командирларга йөкләргә, язу машинкаларын, вак калибрлы винтовкаларны бикләп, пломба астында сакларга, шәһәргә чыгып йөрүне тыярга, тәртип саклауны иң каты режимда тәэмин итәргә. Бәйрәм көннәрендә тәүлек әйләнәсенә янгын сүндерүче уяулык күрсәтергә тиеш. Шушы күрсәтмәне эшкә ашыруыгыз турында пароходчылык башлыгына хисап бирергә тиешсез».

Бюрократик чаралар бәйрәм тантанасын челпәрәмә китереп ташлый. Беренче чиратта өстәмә вахта, язу машинкаларын бикләү, пожар инвентарен хәзерләү. Диңгездә бәйрәм шундый була.

Әгәр шул күрсәтмәдәге барлык өстәмә вахталарны билгеләп, алар кушкан бар эшләрне башкарсаң, бәйрәм итәргә кеше калмас иде. Фәрманны әзерләгәндә күрсәтмәнең үтәп булмаслык икәнлеген түрәләр яхшы белә. Алар бу эшне тикшерүчеләр өчен эшли. Әмергә язылмаган, кәгазьгә теркәлмәгән эшнең бер тиен тормаганлыгын алар яхшы беләләр. Һәр боерык, һәр күрсәтмә кәгазьгә теркәлеп бара. Эшнең иң кыйммәтле ягы — шул теркәлү.

Корабка килгән күрсәтмәнең күз буяр өчен кирәк булганлыгын беләбез, ләкин берни эшләп булмый. Син дә әмер язарга, өстәмә вахталар билгеләргә һәм фәрманны эшкә ашырырга тиеш. Шунлыктан, бәй-

рәм көннәрендә диңгезче тормышының тоткыннар тормышына охшашлыгы тагын да катырак сизелә башлый.

Бәйрәмебез Мәскәү вакыты белән үткәрелгәнгә күрә, инглизләрнекеннән өч сәгатькә алданрак башлана иде. Бәйрәм итүдән тәмам арып, төнге өчләр тирәсендә экипаж йокларга ятты. Экипаж ятты, ә мин тәртип саклауда идем. Таң атканчы вахталарны тикшереп йөрергә туры килде. Сабанга җигелгән атка нинди бәйрәм булсын? Мин, вазифа сабанына җигелгән кеше, үземне ат шикеллерәк хис итә идем.

Бәйрәм хөрмәтенә вахтага эләкмәгән диңгезчеләр төшкә кадәр йоклар, дип уйлаган идем. Сәгать сигезенче яртыда ашханәгә керсәм, ни күзем белән күрим — бөтен экипаж иртәнге чәйгә җыелган. Корган планнарны үзгәртергә туры килде. Боларга бит инде нинди дә булса мавыгу табарга кирәк. «Икмәк һәм тамаша!» дигән Юлий Цезарь. Борынгы Рим чорындагы лозунг әле һаман көн тәртибеннән төшкәне юк.

Иртәнге чәйдән соң дүрт кеше доминога утырды. Сигез-тугыз кеше чиратка бастылар. Боларны хәзер урыннарыннан экскаватор белән дә куптарып алып булмаячак. Биш-алты диңгезче телевизор карый. Раштуа товарларына реклама ясыйлар. Реклама бетте, королеваның семьясы белән чиркәүгә бәйрәм гыйбадәтенә баруын күрсәтергә керештеләр.

Йөзү эшендә иң куркыныч кеше — үзен кая куярга белми йөрүче. Андый кеше, кыбырсынып йөри торгач, я читкә тайпыла, я берәр ярамас эш эшләп ташлый. Аннан тыш кыбырсып йөрүченең кәефе, шул кәефнең коллективка йогуы да куркыныч. Эшен яратып, бирелеп башкаручы вакытлыча гаиләсеннән, якыннарыннан аерым яшәвен, диңгез тормышының шыксызлыгын онытып тора. Сагыну, җирсену күбрәк ял иткән вакытта барлыкка килә. Күңел сыну, төшенкелек сагынудан башланып китә. Әгәр шушы хаста озакка сузылса, бер вакыт кешегә берни кирәкми башлый. Эш туйдыра, бергә эшләүчеләрне күрәсе дә килми. Йөзү эшенең авырлыгы, аның аяусызлыгы нәкъ шушы сыйфатында.

Үзләрен кая куярга белмичә йөрүчеләргә берәр юаныч табарга иде. Китап укырга, әдәбият сөяргә өйрәтергә күпме тырышып карадым. Күпме көч түктем төрле мавыгулар уятырга. Чын әдәбиятны, классиканы экипажның ун проценты тирәсе, дүрт-биш кеше ярата. Унга якынына халык «әфьюне» — ишек ярыгыннан күргәннәрне тасвирларга «саргылт әдәбият», Валентин Пикуль һәм Юлиан Семенов әсәрләре кирәк. Валентин Распутин, Виктор Астафьев, Андрей Битов, Фазыл Искәндәр ише язучыларга аларның тешләре үтми. Мәктәптә аларны әдәбият сөюче итеп тәрбияли алмаганнар, гаиләләрендә чын китап яратучы булмаган һәм алар әдәбиятны гайбәт ишетү, сагыз рәвешендә кабул иткәннәр. Ни тырышсаң да, хәзер аларның зәвыгын үзгәртә алмыйсың. Димәк, бишалты диңгезчене экипаждан аерып читкә алып китәргә кирәк иде. Мин трансляция бүлегенә кердем. Радиодан Алла Пугачеваның җырын тапшыралар. Боргалануларын күрмәгәндә, мин аны тыңлый алам. Җыр бетте. Микрофонны тоташтырып белдерү ясадым:

— Шәһәр карарга теләүчеләр, комсомол секретаре матрос Дулевка әйтеп, языгыз. Егерме минуттан экскурсиягә китәбез.

Каютама кереп киенә башладым. Биш минуттан ишек шакыдылар.

— Мөмкинме?

— Рәхим итегез,— дидем Сусликовның тавышын танып.

— Хәшәрәтләр,— дип башлады Николай Иванович хәл-әхвәл дә сорап тормыйча.— Белдерүне сез ясадыгызмы?

— Әйе, мин ясадым.

— Безгә валюта түләмәгәнне беләсезме?

— Без рождество вакытында килдек. Банклар эшләми иде, шуңа күрә агент валюта китерә алмады.

— Эшчеләр сыйныфы турында безнең администрация шулай кайгырта инде!

— Валюта сиңа нигә кирәк, Николай Иванович? Бүген кибетләр эш-

ләми. Опера тыңларга уйладыңмы әллә?

— Опера карарга, Миргазиян Закирович, мин сары йорттан чыккан кеше түгел. Еланыма капиталистлар ясаган чабата кирәк иде. Хатынкыз бит ул, сез дә өйләнгән кеше, беләсез, маймылланмыйча яши алмый.— Николай Иванович кесәсеннән дәфтәр бите чыгарып миңа сузды.— Менә, карагыз — маймыл чабатасы.

Дәфтәр битенә үкчәсенә озын шнур беркетелгән туфли рәсеме ясалган иде. Гаҗәп хәл, мин студент чакта нәкъ шушындый «бродяга» аталган аяк киеме модада иде. Ул тагын әйләнеп кайткан микән ни?

— Син, Николай Иванович, шәһәргә чыгып интегеп йөрмә. Мин егетләрне музейга алып барам.

— Һи! Гарык мин сез күрсәткән музейлардан. Теге «Академик Арцимович»та эшләгән чакта Басрадан ике маймылның агач башыннан төшеп җирдә яши башлаган урынын карарга барган идек. Өйгә кайткач, дусларыма шул хакта сөйләгән идем, көлкегә күтәрделәр. Ышанмыйлар.

— Нинди маймыл турында сөйлисең син, Николай Иванович? Без бит ул чакта мифик атабыз Адәм белән анабыз Һава яшәгән җирне карадык. Тигр белән Евфрат кушылган җирне, гарәпләрнең әл-Гүрнәсен.

— Барыбер маймыл инде. Минем хатын, мәсәлән, макакадан яралган, безнең өлкән механик шимпанзедан.

«Өлкән механиктан эләккән икән моңа», дип уйлап куйдым.

— Ярый, Николай Иванович, гафу ит. Мин ашыгам. Шәһәргә барырга теләүчеләр көтә торганнардыр инде.

— Мин дә хәзер киенеп чыгам,— диде Сусликов һәм ашыгып каютамнан чыгып китте.

Күз алларым караңгыланды аның безгә иярүенә. Ялгыштым. «Шәһәргә чыгып интегеп йөрмә»,— дип әйтмәгән булсам, бу кешене бульдозер белән дә кузгатып булмас иде. Ул бит һәркайчан гел киресен эшли. Ялгышлык ычкындырдым, их!

Трап янында мине матрос Дулев белән доктор Алексей Теунов көтеп торалар иде.

— Моторист Сусликов иярмәкче була,— диде кораб врачы.— Бөтен эшне бозачак инде ул.

— Сусликов тагылса, мин бармыйм,— диде матрос Дулев.— Аннан корабта да туйган инде.

— Алай ярамый, егетләр,— дидем мин һәм үгетләргә керештем.— Сез аңа әһәмият бирмәскә тырышыгыз. Экипажның игътибары гел Сусликовта, гел аның тирәсенә җыелалар, гел шуны тыңлыйлар, билгеле, ул үзен алланың кашка тәкәсе итеп күрә башлады.

— Николай Иванович, без бит гел җәяү йөрергә чыгабыз,— диде матрос Дулев.— Кара, үкенерсең.

— Син, салака, Николай абыеңның җәяү йөргәне юк дип беләсеңмени! Син штан төбеңдәге «ботканы» учлап ашап утырган чакта ук, абзаң маршбросокта кырык чакрымны алты сәгатьтә үтә ала иде. Мин менә юри иске ботинкамны кидем. Барыбер ыргытасы.

— Николай Иванович, чит илдә кем шундый ботинка киеп чыга? Синең бит артыңнан ияреп йөрерләр. Карагыз әле, болай да ул клоунга охшаган, ә хәзер бөтенләй циркач. Сал ботинкаңны, ки юньлерәк нәрсә,— диде доктор.

Тәҗрибәсезрәк чакта Сусликовка:

— Бар, ботинкаңны алыштырып чык,— дип әмер биргән булыр идем.— Әгәр ботинкаңны алыштырмасаң, шәһәргә алмыйм. Икенең берсе.

Егетләр миңа карыйлар. Көтәләр. Мин уйлаган, баш ваткан булам. Чынында бу ысул Сусликовның үзен уйландырыр өчен кулланыла.

— Я, Николай Иванович, ничек уйлыйсың? Ярыймы шушындый ботинка киеп Европа илендә шәһәргә чыгарга? Бәйрәм көнне, яңа ел башында. Яңа елны ничек башласаң, ел шулай үтә диген ырым бар.

Билгеле, син андый сафсатага ышанмыйсың инде, әйеме?

Чыннан да, Сусликов көтмәгән иде болай эшләвемне.

— Ояла белми бит ул,— диде доктор.— Күзенә төкерсәң дә чыраен сытмый. Вөҗданы юк. Кеше фикере, кешелекле мөнәсәбәт аңа бер тиен тормый.

— Кысылма, док. Син бит помполит алдында шулай кыланасың. Ярарга, куштанланырга тырышасың беренче ярдәмчегә. Синнән курыкты дип уйлый күрмә тагын. Бу ботинка аягымны кыра. Шуңа күрә алыштырам,— диде Сусликов кереп китәр алдыннан.

Ниһаять, Сусликов яңа туфли киеп чыкты. Без кузгалдык.

Кыш. Яңа елның беренче көне, ә монда нәкъ апрель җылысы. Көньяк Атлантика ягыннан искән җил атауга йомшак җылы һава ташый. Бүселеп төшәргә торган соры болытларның итәкләре җиргә тия язып бара. Җир йөзе аксыл томанга төренгән. Мәшһүр Англия томаны куе, калын, җил исүгә карамастан, таралмый һәм күтәрелми. Тирәякта җете яшеллек. Томан пәрдәсе табигатьнең төсен йомшартып, бераз тоныклландырып күрсәтә һәм, шунлыктанмы, ул сиңа шәфкатьлерәк карый шикелле тоела. Җирнең һәр адымын, хәтта һәр карышын җентекләп эшкәрткәннәр. Бу эшкәртүнең бездәгедән аермасы шул: кеше кулы тигән җирдә табигать бер тамчы үзгәртелмәгән. Вак квадратларга бүленгән яшел болыннар, ерактан караганда ямаулыкка охшашлы карасу яшел урманчыклар, арчан куаклары, калкулык битендә моңаеп утырган карт иманнәр киләчәктә дә кеше кулы тимәсенә ышанып тыныч кына утыра бирәләр. Бу җирнең беренче булып промышленность революциясен башлап җибәрүенә ышанасы килми. Калкулык битендә сарык көтүе. Көтүчесе күренми. Юк ул монда көтүче. Көтү йөргән болын җиңел ток җибәрелгән тимерчыбык белән вак квадратларга бүленгән. Квадратның берсендә көтү йөргән арада башкаларында үлән үсеп, яңарып тора. Сарыклар җирдән ярты метрда асылынып торган тимерчыбыкка якынлашырга курка. Сарык асрау арзанга төшә — көтүче яллап торасы юк, кышка печән әзерләп интегәсе дә юк. Бары тик шул көтү йөргән җирнең үләнен генә тапталудан саклый белергә кирәк. Гомумән, җирне, урманнарны, аерым үскән агачларны, елга-чишмәләрне саклый белү — менә кайда бит ул безнең иң зур, иң ышанычлы байлык.

Англиянең пейзажы инглиз холкын хәтерләтә. Синең белән сөйләшкәндә ул һәр очракта ара саклый. Әшнәлеккә дә ашыкмый, дошман итеп сине читкәрәк этәргә дә тырышмый. Салмак кына елмаеп тыңлый ул сине тыңлый, үз фикерен, сорамасаң, һич әйтми, ачылмый, тугарылмый. Бу илдә үз фикерен кискен, катгый итеп әйткән кешене тәрбиясезгә саныйлар. Хәтта бәхәскә кергәндә дә фикереңә, карашыңа урын калдыра белә бу илдә яшәүчеләр. Белмим, шуңамы, инглизләрне без тәкәбберbegә санап йөрибез.

— Без инде Бристольны күрдек,— дидем мин юлдашларыма.— Бүген Клифтонны карыйбыз. Хәзер бу ике шәһәр үзара кушылып бетә язганнар. Клифтон борынгырак. Без анда бик күп кызык нәрсәләр очратырбыз.

Юлдашларым бер-берсенә карашып алдылар.

— Еракмы соң ул Клифтон? — диде матрос Дулев.

— Итегемне беренче тапкыр кигән идем,— диде доктор Теунов.— Ничектер йөрергә уңайсыз булып чыкты. Аягымны кырмаса инде.

— Балда,— диде Сусликов.— Кем юлга яңа аяк киеме киеп чыга? Үзе кешегә акыл биргән була.

Башта терминал, аннан соң калай секцияләрдән җыйган гигант пакгауз артта калды. Пакгаузны җете кызыл һәм карага буяганнар. Бу инде ерактан аерылып торсын өчен шулай. Ниһаять, шлагбаум. Порт саклаучы яныннан уздык. Күптән диңгезче булып эшлибез, шуңа карамастан, чит илләрдә пропуск тикшермичә портка кертеп һәм чыгарып торуларына күнегеп җитеп булмый.

— Документыңны тикшергәндә сакчы сине үзенә буйсындыра, шул чакта ул үзен өстен сизә. Бездәге тикшерүнең сере шунда,— дип аңлатты доктор.

— Юк сүз,— диде Николай Иванович.— Тикшерүнең файдасы булмаса, сакчылар төкерер иде документыңа. Пропускны оныткан чакларда ничә тапкыр сынап караганым булды — өчлекне суздың — капканы киереп ачып җибәрәләр.

— Минем, ничә ел эшләп, андый сакчыга юлыкканым булмады,— диде доктор Теунов.

Порт юлы безне Лондон белән Бристоль арасына салынган магистраль автострадага китереп чыгарды. Гаҗәп киң һәм уңайлы иде автострада. Америкада һәм кайбер Европа илләрендә асфальтка алюминий оны катнаштыралар. Шунлыктан юл гаҗәп шома, тигез һәм нык була. Юлның киңлеге як-яктан кара-каршы сигезәр машина барырлык итеп эшләнгән. Үзәк линия суфлер будкасына охшашлы миниатюр калфак астына яшеренгән электр уты белән яктыртылган.

— Беләсезме юл нигә шома? — дип сорады матрос Дулев.— Аны кабул итеп алучы комиссия машинага бер стакан суны утырта да зур тизлек белән уза икән. Стакандагы су әз генә түгелсә дә, кабул итмичә, тигезләргә кушалар икән.

— Миргазиян Закирович, ишеттегезме? — диде Сусликов.— Бу бит корабтагы идеологик эшнең тиешле рәвештә алып барылмаганын күрсәтә. Космополитизм. Капиталистлар төзегән юлны мактый. Син, салака, аларның юлны нигә шулай шома итеп төзүләренең серен гел кире яктан аңлаттың. Капиталистлар ясаган машина шундый начар була, әгәр дә безнең юлдан бер-ике тапкыр үтсә, кырыла да төшә. Аларның төкерек белән ябыштырып әмәлләнгән машиналары ватылмасын өчен юлны шулай ясыйлар. Дөрес аңлаттыммы?— диде Николай Иванович миңа карап.

— Синең, Николай Иванович, беркайчан да ялгышканың юк. Белмим, ничек Мәскәүгә берәр югары урынга чакыртып алмыйлар икән?

— Борыны аркасында,— диде матрос Дулев.— Гадәттә алкоголикларның борыннары шушындый була. Борыны кызыл булу аркасында күтәрелә алмый безнең Николай Иванович.

— Карагыз әле, егетләр,— диде кораб врачы.— Юл салганда җәяүлеләр турында да онытмаганнар. Нинди киң, нинди әйбәт җәяүлеләр өлеше.

Чыннан да өч-дүрт машина янәшә барырлык асфальт юлның бер өлеше автострададан бордюр белән аерып куелган иде. Без шуннан бара башладык. Ял көне булгангамы — юл буш. Ара-тирә офыкта машина калкып чыга, безгә якынлаша һәм мизгел эчендә тавышсыз-тынсыз юкка чыга.

— «Остин»,— ди Теунов яныбыздан узган машинага күрсәтеп.— Күптәнге марка. Инглизләр, консерватор буларак, машина маркаларын яңартырга ашыкмыйлар.

— Безнең яннан узган машина «симка». Америка машинасы,— ди Дулев.

Алар икесе дә машина алырга акча җыя. Шуңа күрәме, машиналар яныннан тыныч кына узып китә алмыйлар. Без Сусликов белән аларның нинди маркадан икәнлекләрен дә белмибез һәм аны белергә тырышмыйбыз да. Мин һаман юл белән кызыксынам. Һәр йөз метр саен баганага төрле белешмәләр, рекламалар элгәннәр. Шуларны укып барсаң, якын-тирәдәге шәһәрләрдә, бөтен Англиядә нәрсәләр барлыгын, нәрсә ашарга, нәрсә эчәргә, нинди кием-салым сатып алырга кирәклеген белергә була. Мине тагын бер нәрсә хәйран калдырды: мал-туар кермәсен өчен, автостраданы як-яктан тимерчыбык челтәр белән киртәләп алганнар.

Алда Эйвон елгасы аша салган күпер күренде. Диңгез суы төшкән

чак иде. Бристоль култыгында су унбер метрга күтәрелә. Су күтәрелгән чакта диңгез елгага агып керә, елга ярларыннан чыгарлык булып мул сулыга әйләнә. Ә хәзер ул шундый кечкенә булып калган, як-якта ләм баскан инеш төбе ачылган иде.

— Бу бит, егетләр, Шекспир каласы Страдфорд яныннан аккан елга,— дидем мин иптәшләремә.

— Шекспирны ничә мәртәбә укырга җыенып карадым, берничә бит уку белән күз йомыла,— диде матрос Дулев.— Аны нигә бөек драматург дип атап йөртәләр икән?

— Кешелек дөньясына хас барлык тойгыларны, кешеләргә хас төрле характерларны ачып күрсәтә алганы өчен,— дидем мин.

— Әгәр китап итеп басарга рөхсәт итсәләр, мин Шекспирның төшенә дә кермәгән характерларны сөйли алыр идем,— диде Сусликов. — Мин «Запорожье» исемле пароходта Манукян атлы повар белән эшләгән идем.

— Николай Иванович, син бу турыда әллә ничә тапкыр сөйләдең инде. Куян дип капитанга песи ите ашаткан повар бит ул Манукян.

— Салака, гел өлкәннәр сүзен бүлә! Кытайда өлкәннәрнең сүзен бүлгән өчен ыштаннарын салдырып очлы казыкка утырта торган булганнар,— диде Сусликов. Николай Иванович сүзен әйтеп бетерергә өлгерә алмый калды. Яныбызга бездә «бобик» аталып йөртелгән ачык машина, «лендровер» килеп туктады.

— Стоп! — Руль полицейский кулында иде. Шуның янында утырган икенче полицейский кулын күтәреп туктарга ишарә ясады.

— Туктарга куша,— дидем бераз алгарак киткән матрос Дулевка.

— Бу юлдан йөрергә ярамый,— диде полицейский.

Инглиз теленең бер үзенчәлеге бар. Бу телдә гарәп, төрек, фин, поляк һәм башка милләтләр сөйләгәндә тиз аңлыйсың, инглизләрнең үзләрен аңлавы шактый кыен.

— Нишләп ярамый? — дидем мин гаҗәпләнеп.— Җәяүлеләр өчен махсус юл бит.

— Юлның бу өлеше ватылган машиналар туктар өчен салынган,— диде полицейский. Нәкъ шушы мизгелдә юлның бу өлешенең ни өчен кирәклеген аңлап алдым. Үзәк автострада буларак, юл стратегик роль уйный иде һәм аның бордюр белән бүленгән өлеше сугыш вакытында кулланылырга салынган иде.

Полицейскийләрнең өсләрендә зәңгәрсу соры җыйнак костюм, шул ук төстәге плащ һәм кокардалы фуражка. Икесе дә утызлар тирәсендә. Синең белән елмаеп кына сөйләшәләр һәм үзләрен шактый нәзакәтле тоталар. Англиягә элек килгән чакларда да мин аларны күп тапкыр күзәткән идем. Бу юлы минә алар белән эш итәргә дә туры килде.

— Хушыгыз,— диде шофер белән янәшә утырган полисмен.— Яңа ел котлы булсын!

Машина урыныннан кузгалгач, ул безгә тагын бер тапкыр борылып карады. «Лендровер» көчле машина. Ул минут эчендә юкка чыкты.

— Нишлибез, егетләр? — дидем юлдашларыма таба борылып.

— Ярамый, диделәр бит. Бу юлдан чыгарга кирәктер,— диде Теунов.

— Ә кая чыгарга? Якын-тирәдә бернинди юл күренми. Чыгарлык та түгел бит әле, як-яктан челтәр белән әйләндерелеп алынган,— диде матрос Дулев.

— Закон тәртә бит ул,— диде Николай Иванович.— Кай якка борсаң, шул тарафка борыла.

— Минә сиңа уңайлы юл,— диде кораб врачы.— Минә сиңа җәяүлеләр өчен эшләнгән махсус юл.

Тирә-юньдә тынычлык хөкем итә. Сарыклар тыныч кына үлән утлап йөриләр. Вак куаклар, ялгыз имәннәр әкрен генә үсә бирәләр.

Юлны кыр-яланнардан аерган тимер челтәр аша чыгып кара әле? Кемнеңдер хосусый милке булган җиргә аяк басачаксың. Җир хуҗасының нинди кеше икәнлеген кем белә? Бәлки ул кин күңелле булып чыгар, болынын таптап йөргән өчен бер нәрсә дә әйтмәс? Әгәр ул хосусый милкен корыч кулы белән аяусыз саклаучы хуҗа булып чыкса? Ул гадәт бит әле бездә социализм заманында да тулысынча бетерелмәгән. Күршеңдәге, я булмаса башка җирдәге бакчага койма аша кереп кара әле?

— Их, егетләр, каптык без. Англиянең законнары шундый каты дип сөйлиләр. Хәзер бозучылар саналачакбыз,— диде доктор Теунов.

— Я, кисәттеләр, бу юлдан йөрергә ярамый, диделәр. Алар инде безне күптән онытканнардыр. Нәрсә әйтсәң дә, юл дәүләтнеке. Дәүләтнеке — бездәгечә караганда, беркемнеке дә түгел,— диде Сусликов.— Минемчә, юлдан барырга кирәк. Әгәр челтәрле койма аша чыксак, хуҗа бер сүзсез безнең арт санга пуля утыртачак.

— Юлның үзәк сызыгын аркылыга үтәргә ярамый. Баганага шулай язганнар иде. Автострада башка юлга кушылганчы барабыз да, шул юлдан берәр сукмакка чыгарбыз,— дидем мин.

Кузгалып киттек. Ләкин җәяү баруның тәме югалган иде инде. Бу бит Англия! Николай Иванович «закон — тәртә» диде. Европа илләрендә, киресенчә, «закон — закон ул» дип аны бозып булмаганлыкны белгертәләр.

— Әләлә! — диде Сусликов юлга күрсәтеп.— Таныйсызмы? Безне төрмәгә алырга киләләр.

Чыннан да, теге «лендровер» янбызга килеп туктады. Полисменнарның икесе дә машинадан төште.

— Без бит бу юлдан йөрергә ярамый дип кисәтеп куйдык,— диде теге элек безнең белән сөйләшкән полисмен.— Аңламадыгызмыни?

Юк, ул безне куркытырга теләми иде. Хәтта бу сүзләрне әйткәндә аның чырае да сытылмады, әмма аның сүзләрендә закон катгыйлыгы, корыч тәвәккәллек сизелә иде. Закон үтәлергә тиеш. Ул үтәлү, эшкә ашырылу өчен чыгарыла. Шушы хакыйкатьне син ни сәбәптер Россия чынбарлыгында, Рәчәйдә яшәүчеләр авызыннан ишеткән очракта аңлап бетерергә ашыкмыйсың. Хәзер безнең каршыда инглиз кешесе, Англия полисмены басып тора иде, һәм без шушы кеше аша законның нәрсә икәнлеген, гомеребездә бәлки беренче тапкыр, аңлауга ирештек. Каян кергәндер аларга кануннарга ихтирам белән карау? Колонияләр белән идарә итү дәверендә, аларны тыңлатырга тырышып, үзләре дә тыңларга өйрәнделәрме икән? Әллә гомер гомергә спорт белән шөгыльләнеп, спорттагы катгый кагыйдәләр аша законны аңладылармы икән? Бездәге «закон — тәртә» урынына Англиядә «закон — закон ул» диләр.

— Кайсы илдән сез? — дип сорады машина йөртүче беренче тапкыр телгә килеп.

Туган ил һәр очракта газиз. Бөртек кадәрле генә вөҗданың булса да, ялгышларың аның өстенә ягылмасын, начарлыкларың аны пычратмасын, дип тырышасың. Алар бездән җавап көтәләр иде. Юк, безнең милиционерлар шикелле дорфа «мин сиңа!..» кыяфәтендә түгел, тыныч һәм икеләнүсез, безнең җавап бирәчәгебезгә ышанып көтәләр иде.

— Советлар Союзыннан,— дидем мин теләр-теләмәс кенә һәм шундук уйлап алдым: «Болар инде безнең илдә гел шушындый сүз тыңламый, кагыйдә боза торган кешеләр яши дип уйларга тиешләр...»

Алар бер-берсенә карашып алдылар.

— Документларыгыз бармы соң? — диде теге шофер түгеле. Мин полисмен сүзен татарчага «документларың» дип тәрҗемә итәм, ә ул «пейперз» — «кәгазьләрегез», диде.— Шикләнүдән түгел. Без сезнең Советлар Союзыннан булуыгызга ышанабыз. Кем икәнлегегезне ачыклау өчен.

Чит илләрдә шәһәргә чыгу өчен пропуск язып бирәләр. Эйвонмоутка килгәч, мин пропуск турында сүз кузгаткан идем, агент: «Англия — ирекле ил, җинаять эшләмәгән, хокуклы кеше анын җирендә рәсми кәгазьсез йөри ала»,— диде. Менә бит нинди хәл килеп чыкты!

— Документларыбыз юк,— дидем.— Алмадык. Пароходта калды. Сезнең агент: Англиядә документсыз йөрергә була дип ышандырды.

— Утырыгыз,— диде полисмен һәм арттагы утыргычта яткан ике портфельне алып багажникка яшерде.

— Алар бит безне төрмәгә илтә! — дип чыелдап җибәрде Сусликов һәм юл читенә таба чигенә башлады.

Эт оясында көчле, ди татар әйтеме. Каршылык күрсәтү бернәрсә бирмәс иде. Без дүртәү, сан ягыннан алардан ике тапкыр күбрәк, ә алар — коралльт. Өстәвенә, закон алар ягында. Без чит ил законын боздык. Мин башлап кабинага кереп утырдым.

— Юк, мин утырмыйм,— диде Сусликов.— Мин бит әйттем, юлга кермик, дип. Син, Миргазиян Закирович, мине керергә мәҗбүр иттең. Син безгә баш, әгәр төрмәгә утыртып куйсалар, җавап бирәсең.

— Утыр тизрәк, балаболка,— дидем мин Сусликовка. Чит кешеләр карап торганда сүз көрәштереп, бәхәсләшеп торуы шундый уңайсыз иде.

— Әнекәем, кайгырма, хуш,— диде Дулев машина урыныннан кузгалып киткәч.— Николай Иванович, ялкынланып яндың син. Хәзер инде өч малаең ятим, хатының — тол. Передача да китереп булмый бит чит ил төрмәсенә, ерак.

Җиде-сигез минут чамасы бардык без. Автобус тукталышына җиткәч, шофер тормозга басты. Тукталыш буш. Англия халкы бәйрәм итә.

— Автобус менә шушында туктый,— диде шофер янындагы полисмен.— Әгәр кире Эйвонмоутка кайтырга теләсәгез, тукталыш әнә теге якта. Яңа ел котлы булсын, рус диңгезчеләре.

Машина урыныннан кузгалып киткәндә без әле җиргә дә төшеп өлгермәгән идек. Без җавап биргәнче машина күздән югалган иде инде.

— Сүземне аңладылар,— диде Сусликов.— Әгәр бәйләнә башлаган булсалар, совет кешесен законсыз җәберләгән өчен, мин аларга, колонизатор калдыкларына, күрсәтә идем.

Безгә көлке булып китте. Чөнки беребез дә эшнең болай тәмамлануын көтмәгән идек.

— Ул бездә генә кулыннан эш килмәгән ялкауны, я булмаса, власть яраткан күркәне милиционер итеп билгеләләр,— диде доктор Теунов.— Англиядә полицейский булып урнашу өчен, югары белемнән тыш, синең холыклы булуың, хакыйкать яратуың һәм мәрхәмәтле икәнлегең турында алты рекомендация кирәк. Бу эшкә кешене чиктән тыш җентекләп сайлыйлар.

— Мине башка ягы хәйран калдырды,— диде Дулев.— Алар безгә нәкъ сабый балаларга караган шикелле карадылар. Әгәр без боларны машина белән китереп куймасак, үз аяклары белән килә алмаслар, дип уйладылар шикелле.

Чыннан да, башка илләрдә чит ил кешесенә булган мөнәсәбәт хәйран калдыра мине. Бездә, чит ил кешесенең кем булуына карамастан, аңа түбәнсенеп карыйбыз, һәр очракта чит ил кешесенең дәрәҗәсе безнекеннән берничә сортка югары исәпләнә. Аларга иң яхшы кунакханәләр, алар өчен оештырылган аерым кибетләрдә иң затлы, иң дефицит товарлар. Өстәвенә, безнең иң затлы рухи байлык: Зур театрга, Моисеев ансамбленә, корал палатасына билетлар иң беренче чиратта, кешеләребезне мәхрүм итеп, аларга бирелә. Англиядә, киресенчә, чит ил кешесенә, Дулев әйткәнчә, бала-чагага караган шикелле карыйлар. Алар чит ил кешесен «континенттан килгән кеше» дип йөртәләр. «Аннан нәрсә көтәргә — ул бит континенттан килгән кеше». «Нишлисең, бу бит континент гадәте».

# Җитмешенче тәүлек. Эйвон елгасы күпере. 18.40

Теуновның итеге аягын шулкадәр кырган иде, хәзер ул йөри алмый башлады.

— Менә шулай ул затлы йөрсәң,— диде Сусликов.— Армиядә аякка урарга ыштыр бирәләр. Ыштыр урап җибәрсәң, аяк киеме беркайчан да кырмый. Рус халкы нәрсә киярга, нәрсә эшләргә, ничек яшәргә белгән шул.

Күпер астына кереп ташка утырдык. Доктор итеген салды. Аның сул үкчәсенең кырылган җире башта куыкланган, хәзер инде сытылып чыккан.

— Бердәнбер чара, сине носилкада алып кайту,— дидем кораб врачына.— Әйдәгез, юанрак таяк эзләп карыйк.

— Алай кайтырга мин бит әле акылдан язмаган,— диде Теунов.

— Минем туфлине киеп кара әле, Алексей,— диде матрос Дулев.— Итегеңне үзем киеп җибәрим.

Алар аяк киемнәрен алмаштылар. Дулевның туфлие иркенрәк иде булса кирәк, күпер астыннан чыккач, титаклап булса да, доктор атлый башлады. Хәзер инде порт күренә иде. Кызыл тасма, урак-чүкеч төшкән торба безне чакыра, тизрәк кайтырга өнди иде шикелле. Сусликов фәлсәфә куерта:

— Безнең каралыкны әйтәм. Англияне алдынгы илгә санап йөриләр. Аның халкы дөм кыргый икән. Машиналары нинди? Шуны юарга иренәләр, куллары коргыры. Ә атны кадерлиләр. Ничек итеп кыра, чистарта теге кәнтәй хатын. Балаларын дөрес тәрбияли. Нәкъ минем шикелле. Мин дә теге газеталарда язган, телевизордан тапшырган тәрбия кагыйдәләренә төкердем дә үземчә карый башладым. Әнә күрдегезме, Николай Ивановичның методикасы Европа илләренә таралып өлгергән.

— Николай Иванович, син дә, инглиз хатыны шикелле, ярдәм итмичә, мөстәкыйльлеккә өйрәтәсеңмени балаларыңны? — дип сорады доктор Теунов.

— Мөстәкыйльлек. Педагогика. Өйрәнгәннәр әллә нинди фәнни сүзләр белән башны диңкетергә. Ул сүзләрнең мәгънәләре нинди — беркем белми. Әгәр мин үз ысулымны язып китап итеп бастырсам, шул китапка карап бала тәрбияли башласалар, әрәм тамаклар да, тәртипсезләр дә калмас иде.

— Син, Николай Иванович, безгә теория тондырасың. Чынбарлыкта нидән гыйбарәт тәрбияләү методикаң? Безгә шул хакта сөйлә,— диде доктор Теунов.

— Соң бездә бит миллионлаган тәрбиячеләр. Яследә, балалар бакчасында, мәктәптә ун ел, пионер лагерьларында, үзешчәнлек түгәрәгендә — кая карама — тәрбиялиләр. Әгәр малай тәрәзә ватса, я булмаса, берәрсенең йортына ут төртсә, бакча мөдирен дә, мәктәп директорын да, пионер вожатыен да чакыртмыйлар. Бала җинаять ясаса, мәктәпкә аның эти-әтисен җилтерәтеп китерәләр. Димәк, закон эти-әнидән башка кешенең тәрбиясенә төкерә. Закон аларның берсен дә тәрбияче итеп санамый. Шушы хәлне аңлагач, малайларны дөрес юлга куюны тулысынча үз кулыма алдым.

— Нәтиҗәсе ничегрәк соң? — диде Теунов.

— Нормаль. Өлкән улым, Гриша, инде тәрбияле егет. Хәзер инде ул алдатмый. Ул хәзер сине үзе алдый ала. ПТУда трамвай йөртергә өйрәнә. Озакламый трамвай капитаны булачак. Сигезенчедә укыганда әсәрләнеп кайткан. «Әти,— ди,— мин дә синең шикелле моряк булам», ди. «Төшер штаныңны», мин әйтәм. Тотып ярдым. Шуның файдасы тиде. Хәзер инде диңгез ягына борылып та карамый. Шул чакта мин аңа: «Григорий,— дидем.— Әгәр кеше булып яшисең килсә, трамвай йөртергә өйрән. Автобус катлаулырак ул. Юлда

йөргәндә уңга да, сулга да борыла. Автобус артка да чигенә. Әллә кайларга китеп бара ала. Шуңа күрә, автобус йөртүчеләр еш кына ялгышып торалар. Ялгыштың — авария. Авариядән соң машинаны ремонтка җибәрәләр, хуҗасын — төрмәгә. Трамвайны бер якка да борасы юк. Юлга бер тапкыр куйганнар, гел алга таба гына чаптырасың».

— Тукта әле, Николай Иванович, бу бит һөнәр сайлау турында. Ә син безгә тәрбия турында сөйләмәкче идең,— диде Теунов.

— Әйе, тәрбия турында. Менә сине, клизма белгечен, мәктәптә дә, институтта укыганда да тәртипкә өйрәтмәгәннәр. Тәрбияле кеше өлкән кешенең сүзен бүлми, ә син кетәгеңне ачасың да, кеше нәрсә сөйләгәнен тыңлап тормыйча, кычкырасың. Онытытым инде, нәрсә турында сөйли идем әле?

— Малайларыңны тәрбияләү турында,— диде Дулев ярдәмгә килеп.

— Әле менә сәяхәткә китәр алдыннан гына кече малаем, Егор, елап кайткан. «Ни булды?»— дип сорыйм. «Володя Рыженков мәктәптән кайтканда башыма портфель белән тондырды», ди. «Төшер штаныңны,— дим,— ят». Карыша дуңгыз баласы. Идәнгә сузып салдым да кара көеп чыкканчы арт санын эшкәрттем. «Бу дөньяда Сусликовлар нәселенә кул тигерерлек кеше булырга тиеш түгел», дим. Ике көн үттеме икән тәрбия биргәннән соң, Егоркам мәктәптән авызын ерып кайтып керде. «Нәрсә булды?»— дип сорыйм. «Канау буеннан барганда Володька Рыженковны төртеп суга төшердем»,— ди шпана. «Менә егет,— дидем.— Бу нәкъ Сусликовларча. Мә, конфет сатып алып аша». Малайның кулына өч сум акча тоттырдым. Үзе маңка гына малай, ә болай чын ир-егетләрчә кылана. Мин биргән өч сумга бер шешә барматуха сатып алган. Өйгә исереп кайтты. Тагын тәрбияләргә туры килде. «Әти биргән акчага конфет кына алалар», дип аңлаттым. «Бормотуханы үзең эшләп тапкан акчага алырсың». Әнисе: «Малаең үзең шикелле алкоголик була»,— ди. Мин алкоголикмыни? Компаниядә эчмәгән бәндәне мин кешегә санамыйм. Минем бит исереп, аунап ятканым юк. Егорка акыллы малай. Киләчәктә дә югалып калмаска тиеш. Хатын гына боза. «Син аларны кыйнап имгәтеп бетердең инде»,— ди. Берни булмый ул адәм баласына. Кыйнау кешене чыныктыра гына. Ата-ана кулы тимәгән бала чирләшкә була. Әнә түрә-кара балалары көчкә аякларын сөйрәп йөри. Кыйнау җитмәгәнгә шулай ул. Егоркамның башы эшли. Мин аны акыл белән эш итә торган урынга урнаштырам. Әнә бажаем иҗат эшендә. Буш шешәләр кабул итеп тора. Теләсә эшли, теләмәсә «буш ящиклар юк» дип ишегенә язып элә дә келәте эченә кереп сузылып ята. Анда телевизорга кадәр бар. Эш хакы турында сөйләп тә торасы юк. Профессордан күбрәк ала. Ял көннәрендә йөзәр сум төшерә. Ул юри кабул итми, чират җыелганын көтә дә шешәне арткы ишектән чиратсыз ярты хакка алып утыра. Кайчакта дусты белән паркларга чыгып, куак астыннан җыеп йөриләр. Чумарасын шул. Бажаем озакламый пенсиягә чыгарга тиеш. Аның урынына Егорканы куярга исәп. Малайның котелогы эшли. Аңа шундый баш белән эшли торган урын кирәк...

Яңгыр туктады. Кояш күренде. Британия күгендә сүлпән генә яңа ел кояшы йөзә иде. Һәм кинәт юллар җанланып китте. Велосипедка атланган балалар, ат менгән ирләр, ат менгән хатыннар, эт иярткән кешеләр саф һавада сәйран чигеп йөри башлады. Моннан ярты гына сәгать элек Англия җирендә кеше заты күренми иде, хәзер инде бу илнең барлык халкы ял итәргә саф һавага чыкты.

— Күрдегезме Англияне? — диде трап саклаучы матрос корабка кергәндә.

— Алдынгы ил. Культуралы милләт. У-уф, саз ерып, ничә чакрым җәяү йөрдек икән?

— Көне буе корабта домино уйнасаң, нәрсә күрер идең? — диде вахтадагы матрос.

— Англиянең юллары, яшел чирәмнәре, йомшак һавасы чүп! — дип эчен бушатты Николай Иванович.

## Җитмеш дүртенче тәүлек. Гамбург. 20.30

Аңлатырга тырышу, дәлилләр, үгет-нәсихәт — юкка түгелгән көч. Һәркемнең үз дөреслеге дөрес, үз кадере кадер, үз теләге теләк. Чит ил портларында тукталганда мин диңгезчеләргә, кинога барудан музейләргә йөрү кирәклерәк, кыйммәтрәк, дип аңлатырга тырышам, ә аларга кино кирәк. Ниндилегенә карамастан, башка телдә булса да, сеанс вакытында нәрсә турында сүз барганын аңламасалар да.

— Без бит киноны һәр көн корабта карыйбыз,— дип аңлатып карыйм. Чыннан да, һәр кичне чәйдән соң егерме сәгать утыз минутта кызыл почмак стенасындагы тишектән яктылык көлтәсе күренә дә ашханәнең түр стенасына аскан җәймәгә кеше сурәтләре төшә. Шәүлә кешеләр үзара сөйләшәләр, әллә нинди катлаулы проблемалар хәл итәләр. Кайчагында әйбәт фильм да очрап куя, ләкин бик сирәк, елына өч-дүрт тапкыр гына. Әйбәт фильмнарның саны шуннан артканы юк диярлек. Экранга чыккан кинофильмнарның сыйфаты начар булуын һәр кич кино карый башлагач кына аңлап аласың. Экраннан экранга күчеп йөри торган дежур мәхәббәт, таушалып беткән коллизия, кысыр конфликт. Күп фильмнарда шпион куалар. Тамашачылар өчен үбешәләр, җинаятьче эзәрлеклиләр. Кайвакыт экранда ярты сәгатькә якын эшләп торган трактор, яисә автомашина күрсәтелә. Тамашачыларның талымсызлыгы хәйран калдыра мине.

Диңгезче елына ике йөзгә якын фильм карый. Тиздән кино карау гади бер гадәткә әйләнеп китә. Әйбәт фильм белән начар фильм арасындагы аерма әкренләп югала. Тамашачылар кинофильмның сюжетына, аның идеясенә, хәтта эчтәлегенә дә әһәмият бирми башлыйлар. Режиссура төгәлме-түгелме икәнлеген аеру, оператор эшен, артистларның уйнавын аңларга теләгән кеше юк. Авыз ачык, аскы ирен асылынып төшкән, күзләрдә йокы катнаш ниндидер тоныклык. Җинаятьче артыннан милиция куа башласа, я булмаса ызгыш кубып, эш йодрыклашуга ук барып җитсә, тамашачы уянып киткәндәй итә, гауганың ничек тәмамланганын көтеп бер тын түземсезлек белән карап утыра. Сәяхәт вакытында кино карау эч пошуны тамаша белән басуга әйләнә.

— Егетләр,— дим кино башланыр алдыннан.— Бүген карарга җыенган фильм искиткеч начар. Аны караудан эстетик ләззәт ала алмассыз, анда берниндн яңа фикер, яңа информация дә юк, әгәр бассейнга кереп су коенсагыз, я булмаса, палубага чыгып саф һавада ял итсәгез, мең тапкыр артык булыр.

— Безнең культурно ял итәсебез килә,— ди кем дә булса.— Үзең теләгәнчә ял итәргә дә ярамыймыни инде?

Залга күз ташлыйм. Чыннан да, фильмның начар икәнлеген аңларлык өч-дүрт диңгезче аны карарга килмәгән булып чыга. Дипломлы кешеләр күбәйгән саен белемлеләр һәм зыялылар һаман әзәер микәнни?

Бүген бер төркем диңгезче шәһәр карарга чыкты.

— Егетләр,— дим юлдашларымның бергә җыелуларын көтеп алып.— Күреп торам, кинотеатр эзли башладыгыз. Сезнең арада немецчә белүче юк, кайсы кинотеатрда нинди фильм барганын да белмисез. Начар кино карап вакыт әрәм иткәнче, әйдәгез, музейга барыбыз. Музейларда үткән заман тормышы сурәтләнеп калган. Анда вакыйгалар, шәхесләрнең язмышлары. Талантлы рәссам кеше язмы-

шының шундый мөһим мизгелен тотып ала белә, шул мизгел аша рәсемдәге шәхеснең бөтен яшәвен аңларга була. Гамбург Көнбатыш Германиянең культурасы тупланган кала, аны безнең Ленинград белән чагыштырырлык. Кайбер кеше Европа шәһәрләрендәге культура һәйкәлләрен, мондагы музейларны килеп карар өчен гомер буе акча туплый һәм озак еллар ашаудан, киемнән йолкып җыйган шул акчасын түләп Европага килә, мондагы музейларны карап кайта.

Озак үгетлим. Диңгезчеләр дәшми. Чит илдә кино карарга рөхсәт ителми, әйдәгез, музейга, киттек, дисәм берсе дә карышмаячак. Алар минем арттан күндәм генә ияреп китәчәкләр. Тик мин аларның үз теләкләре белән, үзләре сайлап баруларын телим. Алар дәшми.

— Соң бит инде без музейларны карадык,— ди электромеханик Давыдов, экипажның иң культуралы, иң белемле диңгезчесе. Өстәвенә ул минем иң якын дустым. — Портка кергән саен музейга бардык. Туры әйткәнгә хәтерегез калмасын, Миргазиян Закирович, халыкның кино карыйсы килә. Кинога барудан тыясыгызны белсәләр, беркем шәһәргә чыкмый иде.

— Саша, бар, билет алып кил,— дим сүлпән генә һәм иптәшләремнең мине кызгануларын сизеп алам. Дөрес, алар мине ярата, ихтирам итә, ә үзләрен, үз теләкләрен миннән көчлерәк яраталар. Чыннан да нинди бөек көч ярату дигән нәрсә!

Билет алуны мин юри Давыдовка тапшырам. Беренчедән, ул партоешма секретаре, икенчедән, әгәр кино начар булса, «халык»ның рәнҗүе аңа төшәчәк. Давыдов касса залына кереп китә дә бераздан кулына билетлар тотып килеп чыга. Без кино залына юнәләбез. Европа илләрендә киноны теләсә кайсы өлешеннән карарга була: теләсәң уртасыннан, теләсәң азагыннан һәм телләгән хәтле утырырга була. Рәттән өч-дүрт сеанс кара, сиңа беркем бер сүз әйтмәячәк.

Фойеда көтеп торган яшь егет юлны кесә фонаре белән яктыртып безне залга алып керә. Аяк астында йомшак келәм. Зал буш диярлек. Аулак урыннарда, колонналар төбендә караңгыда үбешер өчен махсус кергән яшь-җилбәзәк, йокы туйдырырга килгән йортсыз сукбайлар. Йомшак креслоларга чумып урнашабыз.

Беренче мизгелдә экранга карарга куркып утырам. И ходаем, күрсәт безгә таң йолдызыдай нурлы чын сәнгатьне! Яшәүнең мәгънәсенә багышланган хакыйкатьне күрсәт! Сәнгать урынына төрле халтураларны караудан туйдым. Телевизор халтурасы теңкәмә тигәндә тәрәзә каршысына утырып урамга карыйм. Урамда сәнгать юк, дип йөрибез. Анда — тормыш, чын тормыш һәм чын кешеләр. Әнә бер яшь, матур хатын баласын коляскада тартып бара. Хатынның өстендә Голландиядәме, Көнбатыш Германиядәме тегелгән алты йөз сумлык пальто, аягында Австрия итеге. Бала бишеге дә кайдадыр башка илдә, Чехословакиядәме, Венгриядәме ясалган. Чит илдә ясалган коляскадагы бала бездән, ике көпчәкле бәләкәй арбада, кабык бишектә үскән кешеләрдән бәхетлерәк буламы икән? Ә үзеңне, бала анасы, шундый кыйммәтле киемнәр бәхетле итә аламы? Бар нәрсәң дә матур, сеңелем, затлы, кыйммәтле, ә үзең бишек җырын беләсеңме икән? Ә бала сөйгәндә әйтә торган назлы сүзләрне? Озакламый балаң тәпи йөри башлар, аңа әкият сөйли алырсыңмы икән? Бала тартып барган хатын күздән югала. Мин бала чагыма кайтам. Бәләкәй чакта киеп йөргән киемнәрнең берсе дә хәтеремдә калмаган, ә әниемнең бишек җыры, ул сөйләгән әкиятләр шушы яшемә кадәр татлы моң булып йөрәк түрендә яши. Мин аларны әле һаман сизеп торам. Әйтерсең, шул бишек җыры, шул әкиятләр белән әниемнең назлый белә торган куллары, шифалы сулышы, кайгыртуы яши.

Әнә урта яшьләрдәге өч ир йөгерә-атлый тәрәзә каршымнан үтә. Аяк атлауларында тәвәккәллек, киләсе мизгелдә эшкә ашасы өмет. Кая ашыгасыз сез, агай-эне? Әнә уртада барганы кесәсеннән

акча чыгарды. Яшел кәгазь — өч сумлык. Як-яктагылар да кесәләрен актарырга тотындылар. Акчалар, берләшеп, уртада барган ир кулына керде. Аңлашылды. Менә нигә ашыгасыз икән! Соң бит сезнең өйдә хатыныгыз, балаларыгыз бар. Менә син, акча саный башлаган ир, малайны ияртеп урманга барганың бармы? Тауга менгәнең? Кибеттән кайтучы карчыкның сумкасын күтәреп, аны озата барганың? Әгәр син шул ләззәтләрне татып карамагансың икән, нәрсә ул уртак акчага алып эчәсе вәсвәсәле эчемлек?

Мин бүген кино карап утырам. Экранда диңгез яры. Комлык. Тәрәзәләре диңгезгә карап торган җиңелчә йорт — бунгало. Ике чибәр кыз йокыдан уянып, шәрә күкрәкләрен учлары белән сыпыргалап нәүмиз таратып яталар. Әнә, берсе юрганын бөтенләй ачып ташлады. Өстендә бары тик табигать теккән күлмәк кенә. Кыз караватыннан төште, икенче кызның юрганы астына чумды. Бер-берсенең тәннәрен сыйпыйлар. Аңлашылды.

Дөрес, без фәрештә түгел. Адәм балалары. Ләкин без бит хайван да түгел. Килешәсезме? Ир белән хатын арасында күрергә, белергә ярамый торган татлы, дулкынландыргыч сер — сер булып калырга тиеш. Хатын-кызның тәнен күрә, аңа кул тигерә алмый зарыгуда бөек хакыйкать бар. Шул бөек зарыгу безне ир-егет итә, кирәк чакта сөйгән ярың өчен үлемгә барырга өнди. Җенесләр арасындагы мөнәсәбәтнең кадере, бөеклеге аның сергә төрелгән булуында.

Гарәп илләрендә хатыннар әле һаман тәннәрен бөркәнчек астына яшереп йөри. Торгынлык, каралык бит инде бу, әйеме? Европа илләрендәге менә шушындый фильмга юлыкканда Европа хатыннарын бөркәнчек астына кертү турында закон юклыгына уфтана башлыйсың. Узган сәяхәттә без Ливиядә булган идек. Триполи шәһәрендә аяк атлаган саен бөркәнчекле хатынга юлыгасың. Диңгезгә чыккач, өлкән штурман Василевский сөйләп утырды: «Бөркәнчекле хатын яныннан узганда күкрәгеңдә кинәт кайнарлык кабынып китә. Җир йөзендәге иң чибәр, иң сылу кыз нәкъ шушыдыр дип уйлыйсың. Их, бер генә мизгелгә шуның битен күрергә, дип газапланасың».

Экрандагы кызлар да искиткеч сылу иде, ләкин, арадагы сер юкка чыкканлыктан, матурлык арзанланды, сылулыкның кадере югалды...

Ике таза, матур егет бунгалоның ишеген шакый. Ачык изүле ак күлмәк, кыска чалбар кигәннәр, икесе дә кара күзлектән. Кызлар бер тын посып утырдылар да торып киенә башладылар. Егетләрне керттеләр. Менә алар дүртәүләп озынча матур стаканнардан тоник катнаш джин эчәләр. Көлеп кенә сөйләшәләр, бер-берсенә күз сирпеп кенә карыйлар.

Ниһаять, алар дүртәүләп яр буена чыкты. Җыйнак причалга бәйләп куйган ак яхтага кереп утырдылар да җилкән күтәрделәр. Саф зәңгәр күк. Көләч кояш. Диңгез өстеннән канатларын җәеп ак яхта оча. Бу дөньяда ир-егетне тетрәндерерлек өч бөек матурлык бар: диңгездә ак җилкәнле кораб, чабып барган дөлдел ат һәм зифа буйлы матур кызның көянтә асып судан кайтуы...

Диңгез җиле яхтада баручыларның чәчләрен туздыра. Менә алар чишенә башладылар.

— Давыдов, — дидем электромеханикка.— Мин сезне урамда көтәм. Тынчу монда, һава җитми.

— Мин дә чыгам,— диде Александр Николаевич.— Афишада башкача күренгән иде бит.

Кемдер мыркылдап алды. Кемдер әйтте: «Акча түләнгән бит, карап бетерик инде...» Дүрт-биш минуттан кино караучылар урамда иделәр инде. Дәшмиләр. Бер-берсенә күтәрелеп карарга куркалар. Без корабка таба юл тоттык.

«Их, Европага бүген «Кара йөзләр»дәге мәчет картлары кирәк. «Көфер почмагы» кирәк Европаны кире кешелеккә кайтарырга. Әгәр

закон чыгарып, Европа илләренә шәригать кануннарын кертсәң, мондагы тормыш болай шапшак тоелмас иде!»

Давыдов тәмәке кабызды, йотлыгып суыра.

— Хатыннардан аерылып, монах шикелле яшәгәндә менә шушындый нәрсә күрсәтү... Садизм бит бу. Кешенең иң авырткан ярасына тоз сибү.

## Җитмеш дүртенче тәүлек. Гамбург. 20.40

Кинотеатр каланың Альтона дип аталган өлешенә, Гете урамына урнашкан иде. Без Макс Брауэр проспектына чыктык та, сулга борылып, Аутоверландунг метро станциясенә кердек. Эскалатор салмак кына җир астына шуыша. Аяк астында, басмалардан да аста, тимер сырлы көпчәкләрнең әйләнгәне ишетелә. Басмалар арасыннан яктылык чагылып китә. Эскалатор тәкъдир үҗәтлеге белән безне җир астына суыра. Без һаман аска, һаман тирәнгә төшәбез. Безгә янәшә эскалаторда кешеләр өскә күтәрелә. Нәкъ тормыш мәйданындагы шикелле. Җәмгыятьнең өскә, югарыга күтәрә торган басмасына эләксәң, һаман үсәсең. Һаман югарыга, боерык кына биреп утыра торган урынга күтәреләсең. Әгәр инде язмышың түбәнгә төшерә торган басмага бастырса, һаман аска, һаман караңгылыкка шуышасың. Ул җайланышның нинди булуында эше юк. Аңа гөнаһлы да, гөнаһсыз да бер, фәрештә дә һәм иблис тә. Күтәрелергә тиешлене күтәрә, төшерелергә тиешлене төшерә.

Гамбург немец каласы бит. Метро да немецләрнеке. Безнең Мәскәү метросын патша сарайлары шикелле итеп эшләгәннәр. Җир асты сараенда кеше бары тик ярты гына минут торганлыгы турында беркем уйламаган. Чыннан да, утыз ел метрода йөреп кайсы станция залының нинди икәнлеген мин көчкә генә күз алдыма китерә алам. Ә немецләр метро төзүгә башкача караган. Монда тәртип, уңайлылык. Метрода бер адым буш урын, бер артык кирпеч, кирәкмәгән бизәү күренми. Мәскәү метросындагы алтын путал, мәрмәр, мозаика, җиз скульптуралар юк монда.

Поезд килеп туктады. Вагон эченә кердек.

— Кара ничек эшләгәннәр,— диде Давыдов сокланып.

— Теге түрәләр йөри торган махсус вагон эчендәге шикелле,— диде боцман Савчук.

Чыннан да, метро вагоны аерым купеләрдән тора иде. Утырырга уңайлы, йомшак креслолар, басып торучылар өчен иркен платформа. Чыннан да, метрода йөргәндә станциядә бер-ике минуттан артык торылмый, ә вагон эчендә кай чакта сәгатьләр буе барасың.

— Күрәсеңме мондагы аерманы? — диде электромеханик Давыдов.

— Вагонның уңайлылыгын әйтәсеңме? — дидем мин.

— Юк, монда бездәге шикелле китап укып баручы юк.

Поезд Кенигштрассе станциясенә туктагач, вагоннан чыктык та өскә күтәрелдек. Тирә-якта төнге Реепербан — Гамбург каласының иң гөнаһлы, иң азгын өлеше. Тоныкын кына янган урам фонарьлары астыннан чынаяк тротуардан әкрен генә атлыйбыз. Өйдән, хатыннардан, балалардан аерылганга ике ай ярым вакыт узды. Сагындыра, җирсетә башлаган вакыт. Җан сагынуыннан тыш тән сагынуы бар. Бусы хәтәррәк. Аны аңлый да алмыйсың. Тән сагынуының газаплары астыртын — канда, күзәнәкләрдә яши.

«Венера студиясе» дигән белдерү янында кинәт туктадып калдык. Үтә күренмәле алсу пәрдә аша тәрәзәдән өстәл әйләнәсенә җыелып утырган хатыннарның гәүдәләре күренә. Тәмәке көйрәтәләр. Үтә күренмәле тәрәзә пәрдәсе, үтә күренмәле газ тукымадан тегелгән пеньюар. Басынкы гына музыка уйный. Йорт эчендәге, урамдагы һава күзгә күренми торган вак тузанга, микробларга охшашлы матдәгә сугарылган. Тоныкалсу төсләр, махсус сексуаль музыка касыкка,

гөнаһлы тойгылар тупланган җиргә бәрә. Баш әйләнеп киткәндәй була. Әхлакка, тугрылыкка, биргән вәгъдәләргә төкерәсе килеп китә. Чынбарлык ниндидер кызгылт томан артында. Һәм без тизрәк бу гөнаһлы урыннан таярга тырышабыз.

Бусы Тулуз Лотрек картиналарындагыча «Мулэн руж» дип атала. Шул ук алсу томан һәм вәсвәсәле музыка.

Стриптиз залы «Табу». Ишек төбендә монах киеменә охшашлы кара постау куртка кигән кансыз ак битле ябык егет безнең юлга аркылы төште.

— Өр-яңа порно. Дүрт, дүрт кенә марка. Шәрыкчә. Филиппиннән китерелгән яшь гүзәл җарияләр. Нәрсә ул ир-егеткә дүрт марка. Дүрт марка — рәхим итегез!

Ул беләкләребездән шытырдатып тота, сөйри. Кулы, нәкъ тимер ыргак шикелле, шәфкать белми торган корыч кул.

Төнге дансинг «Сафо». Шул ук алсу яктылык. Шул ук гөнаһ саркыткан төчкелтем музыка, башларын артка ташлап, чалкан ята язып партнерлары кочагында йөзүче биючеләр сурәте. Баруыбызны тизләттек. Барыбер күренәләр. Тәрәзә пыяласы артында гына шәрә күкрәкле, тузган чәчле, гөнаһлы җирләрен бармаклары белән генә каплап утырган хатын-кызлар... Сусау газабына түзә алмыйча боргаланып, киерелеп утыручы гәүдәләр, киерелеп ачылган юеш кызыл иреннәр, кая карама, шәрә ботлар. Гөнаһ хисе урамга агып чыккан, тротуар ташлары гөнаһлы азгын сулыш тарата. Тәрәзәләрдән урамга төшкән вәсвәсәле яктылык, юлыңа каршы төшеп торган оятсыз рекламалар, шуларга түзә алмыйча таш диварлар ыңгыраша шикелле тоелып китә. Мондагы һәр нәрсә, хәтта яктылык, хәтта музыка тавышы, урамдагы һава, хәтта күктәге йолдызлар вөҗданыңны бугазлап, еракка яшеренгән, иман каршында тез чүккән азгын тойгыларыңа юл биреп, оятсыз өметләреңне җанландырырга әзер тора. Мондагы һәр нәрсә хатыныңа тугрылыклы булырга тырышуыңа, кешелек сыйфаты саклавыңа каршы көйләнгән.

Яр буена төшеп катер эченә кереп утыргач кына киеренкелектән арынып, иркен итеп сулыш алып җибәрдем. Сан-Паулиның утлары кабына-сүнә язмышлар хәрабәсен яктырталар. Музыка елый. Анда ниндидер фаҗигале йола, кара йөзләр ярминкәсе сурәтләнә. Елга суы безне төнге кәсеп белән шөгыльләнгән кварталдан бүлде. Биек таш йортлар, таш җәйгән урамнар караңгылык эченә кереп югалды. Эльба елгасы гигант каланың яшерен серләрен, анда яшәгән миллионнарның гөнаһларын мыштым гына диңгезгә ташый. Диңгез ул нәрсәне дә яшерә белә... Диңгез куенында — гасырлар сере.

Таң атканда без якорь күтәреп, юлга чыктык. Шәһәр утлары тоныкланган. Урамнар буш. Гамбург төнге җәнҗалдан соң ял итә. Узган төнне бер кулдан икенче кулга күчкән пычрак акчалар хуҗаларының уянганын көтеп ята.

Сау бул, Гамбург! Син, гигант кала, көрәшче улың, фашистлар кулыннан вафат булган Эрнест Тельманны хәтерлисеңме? Плетцензее төрмәсендә һәлак булган икенче бер көрәшче, бөек шагыйрь Муса Җәлилнең ташларыңа басып йөргәне булдымы икән? Синдә туып үскән, оятсызлыкка, түрәлеккә һәм фашизмга каршы соңгы сулышына кадәр көрәшкән язучы Вольфганг Кеппенне хәтерлисеңме икән син?

Сау бул, Гамбург, эшчеләр сыйныфы, Эрнест Тельман каласы!

## Сиксән беренче тәүлек. Антверпен. 09.15

Бу шәһәрдә мин моңа кадәр бары тик бер генә тапкыр булдым. Вакыт әрәмгә китте ул чакта. Безнең төркемгә ике кыбырсык эләккән

иде. Шуларның күңелен күреп йөри торгач, шәһәрне дә юньләп карый алмый калдым. Хәзерге Бельгия, урта гасырларда Фландрия дип аталган әкияти ил тарихын дәвам иттерә. Фламанд сәнгате. Рубенс. Геда. Снейдерс. Данлыклы Фламанд натюрмортлары. Өстәлгә диңгездән әле яңа тотып алып кайткан балыкларны таратып ташлаганнар. Еланга охшашлы минога, зур акайган күзле диңгез алабугасы, чуртан, сөләйман балык һәм шулар арасында кыскычларын өстәл читенә асылындырган диңгез кысласы — омар, өстәлнең бер читенә табигатьнең гаҗәеп бер җан иясе устрицалар өеп куйганнар. Алар шулкадәр ачык, шулкадәр җентекләп язылганнар, фламанд рәссамнарының талантына, аларның буяу сайлау серенә исең-акылың китеп карап торасың. Икенче бер натюрмортта урман кошлары. Уртада канатларын җәеп кыр тавыгы ята, бүдәнә, көртлек, кыр үрдәге, тагын әллә нинди бүгенге көндә кырылып беткән урман, кыр кошлары, шулар янында аучының мылтыгы һәм патронтажы. Ашыкмыйча гына тәмләп, ашамлыкның матурлыгына сокланып, кулларына алгач, төрле яктан әйләндерә-әйләндерә карап ашарга яратканнар булса кирәк бельгиялеләрнең урта гасырларда яшәгән бабалары. Геда атлы рәссамның «Кара бөрлегән бәлеше — иртәнге аш» исемле натюрморты әле дә күз алдымда. Кара бөрлегән бәлеше янына графин белән затлы шәраб та куйганнар. Приборлар ике кешегә куелган һәм ике көмеш бокалга шәраб агызылган. Бәлештән кисеп алынган ике сынык әле тешләнмәгән дә, бокалның берсе авып калган, өстәл янында утыручылар ашыгып күрше бүлмәгә бикләнгәннәр. Шушы кыйммәтле савыт-сабадагы затлы ашамлыклардан мөһим, алардан да ләззәтле вакыйгага сыйланырга әзерләнгән кешеләрне каядыр алып киткән.

Борынгы художниклар яшәү тәмен күрсәтә белгән. Бигрәк тә фламанд рәссамнары. Антверпенга керү турында ишетү белән, музей карарга яратучыларны кодалый башладым. Доктор Теунов риза булды, үгетли торгач, электромеханик Давыдовны күндердем. Бу юлы инде, теге килүдәге шикелле, көне буе тугызынчы размерлы күкрәкчә эзләп вакытны әрәм итмәячәкбез. Туйганчы фламанд художникларын карыйм бу юлы. Күңелем булганчы, күзем туйганчы карыйм. Шулай алдан план корган чакларда әнием мәрхүмә «алла боерса» дип әйт ди торган иде һәм мин дингә артык ышанып җитмәсәм дә, әнием әйткәнгә ышанганга күрә, шул тылсымлы сүзне һәркайчан кабатлый идем. Бу юлы шул ырымны кабатларга онытканмын, күрәсең.

Иртәнгене ашаганнан соң тиз генә киендем дә Антверпенның тарихи һәйкәлләрен һәм мәшһүр музейларын теркәгән исемлекне эзләргә тотындым. Кирәк буласын белеп, алдан әзерләп куйган идем ул исемлекне. Кая яшергәнмен икән соң? Каютамның астын өскә китереп барлык китапларны, өстәл тартмаларын, рундукны, тумбочкаларны, барлык кесәләремне тикшердем. Әгәр шул язуны тапкан булсам, без инде күптән шәһәр үзәгендә йөрер идек. Исемлеккә кул селтәп, иптәшләремне алып юлга чыгарга тәвәккәлләп кенә өлгергән идем, телефон чылтырады. Мондый чакта акыллы кеше трубканы алмый. Үземнең юлга җыенганда трубканы күтәрмәм дип ничә мәртәбә ант иткәнем булды.

— Тыңлыйм,— дидем трубканы кулыма алып.

— Кер әле бер генә минутка,— диде капитан тавышы. — Ярый әле китеп өлгермәгәнсең. Мин сине көтәм.

Трубканы аппарат өстенә куйгач сүгендем инде. Дөресен әйткәндә, сүгенергә сәбәбе дә юк иде. Эш кешеләре бит без. Нәтиҗәсе әллә ни югары булмаса да, бер җигелгәч, гомер буе шул эшне ат шикелле сөйрибез инде.

— Миргазиян Закирович,— диде Михаил Александрович каюта ишеген ачу белән. — Мин бүген шәһәргә чыгарга ниятләдем.

— Күптән кирәк иде,— дидем эчемнән сыкрап.

Элек, житмешенче елларның азагына кадәр, капитан белән беренче ярдәмче шәһәргә бергә чыгалар иде. Житмеш тугызынчы елны министрлыктан фәрман килде: чит ил портларында торганда, даими рәвештә, корабта я капитан үзе, яисә капитанның беренче ярдәмчесе булырга тиеш. Шушы ике кешенең корабтан берьюлы чыгып китүе катгый рәвештә тыела. Приказларның, күрсәтмәләрнең уннан тугыз өлеше кирәклектән түгел, житәкчеләр чиктән тыш үрчеп киткәнлектән барлыкка килә. Диңгез флотында идарә итүчеләргә, аллага шөкер, кытлык юк.

— Нинди йомыш белән? — дидем. — Бәлки сиңа мәшәкатьләнергә кирәк тә түгелдер? Сине интектереп йөрткәнче, үзем генә үти алмыйммы?

Гремин сүгенеп жибәрде.

— Хатынга күлмәк алырга барам. Сез бит инде үзегезнекеләрне баштанаяк киендердегез, ә мин бу сәяхәттә аңа бернәрсә алмадым әле.

— Алай булгач, чыннан да, үзеңә чыгарга кирәк. Мондый жаваплы эшне ышандырып үз өстемә алудан куркам мин.

— Боцман, Антверпенда андый размер була, диде. Инде бит кермәгән кибет, эзләмәгән шәһәр калмады. Алтмышынчы размерлы күлмәк беркайда да табылмады,— диде капитан пошынып.

— Капиталистик илләрдә ирләр хатыннарын ач тота. Минем хатын кырык дүртлене кия, ә Европада аңа ким дигәндә кырык алты-кырык сигезенче размерны алырга кирәк. Ул ягын да онытма, Михаил Александрович. Инна Ивановнага ким дигәндә алтмыш икеле күлмәк кирәк.

— Бүген соңгы тапкыр эзләп карыйм,— диде капитан.— Юк икән, баштан чыгарам. Юк нәрсәне эзләп вакытымны күп әрәм иттем инде.

Капитан хәләл жефетенә «Монтана» фирмасы теккән күлмәк алып кайтырга тиеш иде. «Монтана» теккән киемнәрне жир шарының кайсы төбәгендә дә табып була, ләкин нигәдер, алтмышынчы размерлы күлмәк Советлар Союзыннан башка бер жирдә дә очрамый.

Китәр алдыннан капитан миңа сейф ачкычын тапшырды. Як-ягына карап алгач, пышылдап диярлек әйтте:

— Минем хатынга яраклык күлмәкнең монда да юклыгын беләм. Бер төрле чират уздыру өчен генә барам инде. Инна Ивановна моторчы Чумакның әнисе белән әшнә. Әгәр сәяхәттән кайткач Чумак әнисенә: «Безнең капитан чит ил портларында торганда шәһәргә чыгып йөрмәде»,— дип әйтсә, Иннуля мине тере килеш тотып ашаячак.

— Алай булгач, Михаил Александрович, Чумакны үзең белән алып чык. Ул эзләп карасын алтмышлы күлмәкне.

— Чыннан да, шулай итик әле. Рәхмәт сиңа, Миргазиян Закирович, киңәшең өчен.

Капитан шәһәргә чыгып китү белән телефон чылтырады.

— Ливиягә илтәсе йөкнең хужасы килде. Капитанны күрергә теләде,— диде икенче ярдәмче.

— Капитан шәһәрдә икәнен әйттеңме соң?

— Әйттем. Аның сезнең белән сөйләшәсе килә.

— Керсен, көтәм.

Берничә минуттан озын чандыр гәүдәле, арзанлы йомшак тукымадан теккән соры костюм кигән бер кеше каютама килеп керде.

— Рәхим итегез,— дидем мин өстәл каршындагы кәнәфидән урын күрсәтеп.— Нәрсә эчәсез? Аракы, сыра, шәраб, кока-кола, шифалы су?

— Мөмкин булса, шифалы су,— диде бельгияле.

Суыткычтан су алып стаканнарга агызган арада кунагымны жентекләп тикшерәм. Бездә мондый ябыклык бары тик авырулар арасында гына очрый. Төссезлек, тирән жыерчыклар һәм тоташ чал чәч кунакның бик жаваплы эштә эшләве, я булмаса, авыр тормыш кичерүе турында сөйли.

Иң башлап кунак кесәсеннән визит карточкасы алып миңа сузды.

Укып чыктым. Доктор Морис Фромм, Бельгия дәүләт Корыч кою компаниясенең президенты.

— Сез нинди телдә сөйләшәсез?— дип сорадым инглизчә.

— Французча, инглизчә, немецчә. Испан, итальян һәм, билгеле, нидерланд телләрендә дә сөйләшергә була,— диде ул тыйнак кына елмаеп.

Европа илләрендә югары белемле кешенең ике-өч чит тел белүе очраклы хәл түгел. Мондагы тел белүнең дә бездәге тел белгән өчен ун процент өстәмә эш хакы алучылардан аермасы зур. Безнең илдә тел белү күбрәк укып өйрәнү, белгәнлекне диплом аша раслауга бәйле. Чит илләрдә исә тел белүне эшендә куллану алга куелган. Шунлыктанмы, Европа илләрендә урта белемлеләр дә чит телдә сөйләшеп аңлаша алалар. Югары белемлеләр турында әйтәсе дә юк.

— Каршы килмәсәгез, итальянча сөйләшер идем,— дидем.— Инглизчә мин укырга яратам, итальянча исә — сөйләшергә.

— Сез илтәсе егерме дүрт контейнерда безнең Ливиядәге заводка консервация ясарга кирәкле материаллар. Триполига килү белән контейнерларны вәкилебез кабул итеп алачак. Мин сездән шул кешегә берничә сүз тапшыруыгызны үтенеп сорар идем — диде Корыч кою компаниясе президенты.

— Мин тапшырасы сүзләр дәүләт сере түгелдер дип уйлыйм,— дидем.

— Түгел. Эш менә нәрсәдә. Без шул заводны ябып консервацияләү эшен башкарырга компания вәкилен җибәрергә тырышып карадык. Ни сәбәптер, әлегә вакытлыча шунда бару өчен виза алып булмады. Хатлар цензура аша үтә һәм, ни өчендер, күбесе адресатка барып җитми. Йөкне алырга килгән кешенең фамилиясе Канн, Джозеф Канн. Сез аңа менә нәрсә тапшырыгыз: заводны ничек булса да май аена кадәр консервацияләп өлгерергә кирәк. Әгәр алучы табылса, сатып җибәрергә дә ярый. Май аена кадәр анда алты каравылчыдан тыш беркем калмаска тиеш. Менә шушы сүзләрне очрашу белән рәхим итеп, Джозеф Каннга тапшырыгыз.

— Борчылмагыз, тапшырырмын,— дидем мин.— Заводның ябылуы сер түгелдер бит? Дөнья базарында корычның хакы төшә башладымыни?

— Хак төшүдән түгел,— диде Морс Фромм.— Хәзер анда эшләр кеше юк.

— Гаҗәп,— дидем мин бу хәлнең сәер булуына хәйран калып.— Капиталистик илләрдә иң таралган нәрсә — эшсезлек. Ничә миллион һөнәр иясе эш таба алмыйча интегә, ә сез кеше юк дип завод ябып ятасыз.

— Корыч кою заводының ябылуы — экстраординар хәл. Ул заводны без Мисырдан килеп эшләүчеләрне күздә тотып корган идек. Анда сигез ел буе Мисыр гарәпләре эшләде дә. Мисыр белән Ливия арасында мөнәсәбәт бозылгач, Муаммар Кадаффи мисырлыларны Ливиядән куып җибәрде. Шуның аркасында, заводта эшләр кеше калмады.

— Ә Ливия гарәпләре?

— Алар бит нефть саткан акчага яши. Эшлиселәре килми. Аннан соң ливиялеләр арасында эшчеләр дә оешмаган әле. Халыкның күбесе авыл җирендә мал тоту, иген игү белән шөгыльләнә.

— Ә Бельгиядәге эшсезләр?— мин шүрлектәге китапка төртеп күрсәттем.— Менә бу кулланмада сезнең илдә дүрт процент ярым эшче эш таба алмый дип язылган.

Морис уйга калды. Бераздан ул елмаеп җибәрде.

— Бу турыда без уйлап карадык инде. Чыннан да, эш таба алмый йөрүчеләрне Ливиягә җибәреп булыр иде. Ләкин, Африка иленә җибәреп эшләтү өчен аларга Бельгиядәгегә караганда ким дигәндә өч-дүрт тапкыр артыграк түләргә кирәк. Икенчедән, алар белән эш чыгарып булуга ышанып бетмим мин. Билгеле, эшсезләр арасында яхшы һөнәр ияләре дә бар, ләкин алар әз. Эшсезләрнең күбесе брак ясый,

начар эшли торган ялкаулар. Алар арасында эшләмәс өчен ач яшәргә, ялангач йөрергә риза кешеләр дә житәрлек. Андыйлар гомер буе сукбайлыкта, кая туры килсә шунда кунып, нәрсә эләксә, шуны ашап йөри. Сездә андыйлар юкмыни?

— Юк,— дидем мин һәм моторчы Сусликов турында уйлап куйдым. Әгәр эшсез яшәргә закон рөхсәт итсә, Николай Иванович, чыннан да, нәкъ Морис әйткәнчә яшәр иде.

— Мин шуны аңлап бетермим,— дидем, кунагымның стаканына шифалы су агызып.— Халкыгызның миллионга якыны эшсез, шул ук вакыт Бельгиядә артта калган илләрдән килеп ялланган миллионга якын кеше эшли. Ул урыннарга нигә үз эшсезләрегезне урнаштырмыйсыз?

— Гадәттә, чит илләрдән җыелган эшчеләр иң кара, иң авыр эшләрне башкара. Эш хакы әз төшә торган урыннарда да алар. Бельгиялеләр андый эштән баш тарта.

— Эшсезләре дәме?

— Сез миннән бик катлаулы нәрсәләр турында сорыйсыз,— диде Фромм елмаюдан туктап.— Мин бит корыч кою белгече. Эшкә урнашу, эшчеләр хәрәкәте белән профсоюз шөгыльләнә. Профсоюз лидерлары һәм социологлар белә торганнардыр бу турыда.

— Мине менә нәрсә кызыксындыра,— дидем сорауны читләтебрәк бирергә кирәклекне аңлап.— Әйтик, заводларыгызда корыч кайнатучы булып эшләгән кеше эшсез калды ди. Аның урам себерүче булып урнашырга мөмкинлеге бар. Урнашамы ул андый эшкә?

— Юк, урнашмый.

— Ә ничек ачка үлми ул?

— Эшсез калганы өчен пособие ала. Корыч кайнатучының пособиесе урам себерүче айлыгыннан зуррак. Ул, шуңа күрә, урам себерергә урнашмый.

— Әгәр урам себерүче айлыгына эшсезләрнең пособиесен өстәп түли башласаң, әлеге корыч кайнатучы ул эшкә урнашыр идеме?

— Сез, әфәндем, җавап табып булмаслык сораулар бирәсез,— диде Морис Фромм.— Андый эшне сез, коммунистлар гына башкара аласыз. Чөнки сездә айлык билгеләү дә, эшкә урнаштыру да, житештерү технологиясен үзгәртү дә партия кулында. Бездә алай түгел. Мин илебездәге иң зур корыч кою компаниясе президенты. Корыч кайнату буенча нәрсә теләсәм шуны эшли алам. Билгеле, әгәр ул эш технологияне яхшыртуга, табышны күбәйтүгә юнәлтелгән булса. Эшсезләргә пособие түләү, забастовканы туктату эшендә мин көчсез. Бу эш белән профсоюз идарә итә. Менә хәзер Ливиядәге иң зур табыш бирә торган заводыбыз ябылды. Мин берни эшли алмыйм. Моннан ике ай элек долларның курсы үзгәрде. Америка долларының курсы үзгәрү безнең компаниягә берничә дистә миллион зыян китерде. Мин шулай ук бернәрсә эшли алмадым. Сезнең пропаганда — капиталистлар эшчеләрне изә, үзләре эшләмичә сорыкорт булып яши, дип коткы тарата. Эшче җиде сәгать эшли да кайтып китә. Атнасына ике тәүлек ял. Ял иткәндә ул эш турында уйламыйча рәхәтләнеп яши. Ә мин, капиталист, төнге йокымнан уянган чакларымда да ничек итеп инфляциягә каршы тору, чимал кыйммәтләнүгә нинди чара күрү, забастовканы ничек туктату, технологияне ничек яңарту турында уйлап баш ватам. Эшченеке белән чагыштырганда минем тормыш тәмуг.— Президент Фроммның йөзенә әчке газаплану чыккан иде.

— Ә сез нигә соң, президентлыгыгызны ташлап, мартен каршына корыч кайнатучы булып басмыйсыз? Эшчеләр шикелле рәхәтләнеп яшәр идегез,— дидем.

— Сезгә ничә яшь?— диде компания президенты.

— Илле алты.

— Миңа да илле алты. Без яшьтәшләр икәнбез әле. Менә шушы яшегездә диңгезчелекне ташлап, әйтик, токарь булып эшләргә тәвәккәл-

лек житәме сезнең?

— Мин бит эшемнән канәгать. Әгәр токарь булып эшләү капитан ярдәмчесе булып торудан әйбәтрәк тоелып ымсындырса, уйлап та тормыйча токарьлыкка өйрәнә башлар идем,— дидем.

— Юк, мин ышанып бетмим,— диде капиталист.— Безнең яшәешне язмыш идарә итә. Әтием корыч кою эше белән шөгыльләнгән. Шул ук эш белән бабам һәм аның әтисе шөгыльләнгәннәр. Алар эзеннән хәзер менә мин барам. Билгеле, эш хакым эшченекеннән зуррак. Хезмәт катлаулылыгы, авырлыгы, җаваплылыгы да эшченекенә караганда күп мәртәбә артык. Шул ук вакыт мин барыбер эшчедән күбрәк ашый алмыйм. Киресенчә, аңа караганда әзрәк тә, арзанрак та ашыйм, чөнки инде менә ун елдан артык вегетариан аш белән генә тукланам. Киенүем дә гади эшченекеннән кыйммәтрәк түгел, чөнки мине бала чактан ук гади киенергә өйрәттеләр. Арзанлы гади кием вакытны әз ала. Андый кием эшләргә дә уңайлырак. Эшчедән бердәнбер аермам — бакчалы булуымда. Эштән соң шунда чәчәк үстерәм. Ялым шул. Чәчәк күргәзмәләрендә җиде тапкыр Бельгиянең беренчелеген алдым. Башка илләрдә булган күргәзмәләрдә дә катнашканым бар.

Бельгия миллионеры Морис Фромм стакан ярым шифалы су эчте. Ул чыгып киткәч, уйлап карадым: яраткан эш белән шөгыльләнү өчен берәр оранжерея тоткан кешегә чәчәк үстерүче булып ялланырга гына кирәк булган аңа. Әңгәмә вакытында ул бары тик бер серен — банкта ничә миллион акчасы барлыгын һәм ничә мең эшченең аның файдасына эшләвен генә яшерә килде.

Капитан шәһәрдән кайтканда караңгы төшеп килә иде инде. Сейф ачкычын аңа тапшырганда Михаил Александровичның битенә карамаска тырыштым. Хатынына күлмәк таба алмау аның кәефен шулкадәр бозган иде, ачкычны өстәлгә кую белән, тизрәк аның каютасыннан чыгып киттем.

## Бер йөз җитмеш дүртенче тәүлек. Бискай култыгы. 22.30

Моннан дүрт-биш көн элек буфетчы кыз Таня белән ипи пешерүче Людмила яши торган каюта яныннан узып барганда бер сәер тавыш ишетеп, туктап калдым. Ишек шакыдым. Җавап юк. Ишекне ачып җибәрсәм, диванда мендәрен күкрәгенә кысып кочаклап, буфетчы Таня Карамзина, стеналарны дер селкетеп, балавыз сыга.

— Таня, нәрсә булды, әллә берәрсе җәберләдеме?

— Юк, Закирыч, беркем җәберләмәде.— Үзе тагын да ныграк үксергә тотынды.

— Әллә берәр җирең авыртамы? Нигә елыйсың?

— Миргазиян Закирович, әһәмият биреп тормагыз, озакламый туктыйм. Язмышымны кызганып елыйм мин.

— Нинди кызганыч язмыш булсын ди ул синдә? Яшь, таза, тамагың тук, өстеңдә генерал кызлары күрми торган затлы кием, әниеңә ай саен ярдәм итеп торасың. Тагын ни кирәк сиңа? Нәрсә җитми?

Кызга нәрсә җитмәгәнен беләм. Дубровниктан кузгалып киткәнгә бер атна да үтмәде, Таня белән бер каютада яшәүче ипи пешерүче кызның моторчы Саша Чумак белән боткалары пешә башлады. Билгеле, дусты шундый кавалер белән йөргәндә мескен Таня үзен ялгыз хис итә иде. Ялгызлык тойгысы белән интеккән кешегә башка берни кирәкми.

— Таня, тукта, син юкка күз яше түгәсең,— дидем мин һәм урындык алып буфетчының каршына утырдым.

— Юкка?— Сөрмәгә буялып пычранган күзләрен күтәреп Таня миңа карый.— Классташларымның барысы да кияүдә. Ирләре бар. Бала үстерәләр. Ә мин?..— Кыз, бөгелеп төшеп, үксергә тотынды.

— Күңелең яткан кеше очраткач, син дә чыгарсың әле. Кай җирең башкаларныкыннан ким? Әйт, кайсы җирең?

— Юкка гына юатмакчы буласыз, Закирыч. Миңа кем өйләнсен?

— Син эшчән, юмарт, ялганлый белмисең. (Үзем эчемнән генә уйлап куям: бәлки шушы ялганлый, үзеңне күрсәтә белмәү комачаулый торгандыр кияү табарга?) Төскә-биткә матур.

— Ә минә болар?— Карамзина кулы белән гәүдәсен сыпырып күрсәтте.— Иртәнге чәйгә май алырга кергәч, кладовойда үлчәнеп караган идем, йөз илле өч килограммга җиткәнмен. «Таня, сиңа өч таза ирнең дә көче җитәрлек түгел»,— дип көлә Бусленко.

— Бусленко сүзенә ышанасыңмыни син? Ул бит — коры куык. Өстәвенә вакчыл, көнче. Бәлки ул сиңа шаярып кына әйткәндер? Таня, син мин әйткәнгә ышанырга тиеш. Әгәр сиңа өлкән матрос Сайгаченкодай егет очраса, бер минут та уйлап тормыйча өйләнәчәк.— Үзем эчемнән генә уйлап куям: бу дөньяда өйләнү кануннарыннан да аңлашылмасрак нәрсә бармы икән? Буе ике метрлы, алтын холыклы өлкән матрос Сайгаченко иренең кендегенә дә җитмәгән, карсак, явыз холыклы ике балалы хатынга өйләнгән. Таня минем сүзне аңлап бетермәде булса кирәк, тирән итеп сулыш алганнан соң:

— Сайгаченконың хатыны бар шул,— диде.

Өйләнү, кияүгә чыгу нигә елдан-ел катлаулана бара? Белмим, бәлки ялгыша торганмындыр? Патриархаль тормыш белән бергә кешедәге тоташ, монолит бер кисәктән торган шәхеслек тә китеп югалды. Безнең яшәеш вак-вак кисәкләрдән торган кыйпылчыкларга бүленә башлады. Эштә без кеше кушканны шундук үтәргә әзер торган кемсә, эш урынына барып-кайтып йөргәндә — пассажир, җәмгыятьтә — активист, гаиләдә — хатынның (яисә иренең) сүзен тыңлаучы тугры партнер, дуслар арасында, киресенчә, хатын сүзенә төкереп, мин-минлек байрагын тотып, типтереп яшәүче баламишкин. Өстәвенә, егерменче гасыр кешесенең мавыгулары да бар бит әле. Яшәү вазифасының шушындый мөстәкыйль кисәкләргә бүленүе безне эчке, рухи яктан да вак-вак кисәкләргә тураклап бетерә һәм шул кисәкләр арасында туктаусыз ызгыш, капма-каршылык чыгара. Шушы капма-каршылыклар тормышта үз юлыңнан, үз кыйблаңа баруга, чынбарлыкны аңлауга бик көчле каршылык күрсәтә.

Диңгезче кызлар ярга чыккач, кайда эшләүләрен яшерә, безнең Таня исә беркатлы, эчендәгесе тышында. Аның корабта эшләве, кыз башы белән ир-ат арасында яшәве егетләргә куркыныч тоела. Алар аны азгын, күп кеше кулыннан үткән кызга саныйлар булса кирәк. Соңгы көннәрдә, җае чыккан саен, буфетчы кызга шул турыда аңлатырга тырышам. Шулай Татьяна зарларын тыңлаган арада моторчы Петлюганы күздән югалтканмын икән. Каютама кереп, бер минут көттермичә Союзга, хатыны, балалары янына озатуны тыкырдата башлагач кына, бу кешенең күңелендә ачы кризис башланганын аңлап алдым.

Сәяхәтнең өченче аенда моторчы Петлюга япон монахы Кун Фу системасында күнегү белән шөгыльләнергә тотынган иде. Самбо, джиюджитсу шикелле спорт белән шөгыльләнү өчен махсус рөхсәт кирәк. Йөзү вакытында спорт белән мавыгучыларга кулыңнан килгән кадәр ярдәм итәргә тырышасың. Шөгыльләнсен генә. Спорт сәяхәтнең авырлыгын җиңәргә ярдәм итәчәк.

Петлюга бассейн янындагы спорт мәйданчыгына ике багана утыртты да, шуларның арасына эченә ком тутырган капчык асты. Бөтен буш вакытын шул капчыкны кыйнап үткәрә башлады. Инде икенче көнне үк өлкән штурман Василевский моторчының күнегүен туктатып, «дошман» капчыкны алып ташлаган иде. Өлкән штурман һәм капитан белән сөйләшеп, моторчы мавыгуын дәвам итәргә ярдәм иттем. Петлюганың күңеле булды. Вахтадан алышыну белән Петлюга ботдек палубасына менә, чишенеп трусиктан гына кала, «дошман»ын кыйнарга

тотына. Кашын жимереп, кычкыра-кычкыра, йодрыклары канга батканчы кыйный мескен капчыкны. Йодрыклары җәрәхәтләнгәч, терсәкләре, җилкәсе, тезе белән дөмбәсли ком тутырган капчыкны. Тез-терсәкләр да авырта башлый, күрәсең, кыйнауның азагында «дошманына» тибәргә тотына. Капчыкның иң өске өлешенә, битенә чамалап тибә. Аяклар да арый, хәзер ул мескенгә баш түбәсе белән, сикереп, бер юлы ике аягы белән тондырырга керешә.

— Әй, контрабандист, үтердең бит, нигә үлгән кешене тукмыйсың?— дип авыз ералар карап торучылар. Петлюга үртәүчеләргә колак салып тормый. Бәлки ул аларның сүзен ишетми дә торгандыр, шул кадәр ярсыган, чын-чыннан транска кергән.

## Ике йөз сиксән дүртенче тәүлек. Жданов порты. 16.00

Тикшереп җаныбызны алган комиссияне озатырга чыктым. Елмаям. Кулларын кысам. Иң башта траптан санитар врачы төште. Аның артыннан чик саклаучылар, таможнячылар, биология инспекциясе вәкиле, трансфлот диспетчеры һәм үзенең кайда эшләгәнен белгертми торган бәндә. Тикшерү вакытында ул бер эшкә дә катнашмыйча читтән генә карап йөрде. Алар өчәү иде. Икесе әле пароходта, комиссия эшен бетерү белән юкка чыкты. Ләкин мин аларның кайда йөргәннәрен, кемнәр белән сөйләшкәнен сизеп торам.

Мин монда эшли башлаган елларны комиссия артыннан корабка диңгезчеләрнең хатыннары, балалары ургыла иде. Сәяхәттә озак йөреп кайткан корабны оркестр белән каршы алу гадәте дә бар иде. Кит тоту флотилиясен, гадәттә, оркестр, лозунглар белән каршы алалар иде. Причалга кадәр, дөресен әйтергә кирәк, эшнең авырлыгына чыдый алмый дөнья белән саубуллашкан мәетләрне катер белән ярга озата иделәр, шуннан соң тантанага күмелеп, ярга төшәләр иде. Утыз ел эчендә күп нәрсә үзгәрде. Хатыннарны портка кертү өчен проходнойга диңгезчеләрнең гаилә исемлеген дүрт нөсхә илтергә кирәк. Ул исемлекне җентекләп тикшерәләр, тикшерү тәмамлангач, хатыннар паспортларын тапшырырга тиеш, шуннан соң исемлектәге мәгълүматны паспорт белән чагыштырып яңа тикшерү башлана. Кавышканда инде мескен диңгезче хатынының шатланырга, ирен кочарга хәле беткән була.

Бу дөньяда һәрнәрсә үзгәреп тора. Шул үзгәрүләр тормышны яхшыртыр, яшәүне җиңеләйтер, дип өметләнеп көтәсең. Ә яшәү министрлыктан яңа боерык килгән саен, тормышны җиңеләйтү турында директив органнарның карарлары тормышка ашырыла барган саен катлаулана, авырая бара. Озын, ялыктыргыч сәяхәттән кайткач, гаиләң белән очрашуы шундый күңелле иде. Хәзер аны да юкка чыгардылар. Отчет кәгазе үрчегән саен диңгезчелекнең борынгы финикийләрдән, Колумб, Магеллан заманыннан тупланып килгән гореф-гадәтләре, аның йолалары юкка чыга бара. Кәгазь ташкыны елдан-ел үрчи. Отчетлар тикшерелеп беткәч, ялга әзерләнә башлаячакмын. Кадрлар бүлегендә миңа тиешле ял көннәрен хисаплап әмер язачаклар. Шуннан соң самолетка билет табу мәсьәләсе алга килеп басачак.

Өч-дүрт көннән иптәшләрем белән саубуллашу. Җиде ай бер дулкын сыртында чайкалган, бер кояшта пешеп, бер казаннан аш ашап, бер кораб палубасында кавышуны зарыгып көткән кешеләр белән аерылышу көтә мине. Без бер үк давылда кыйналып, сине йотарга торган бер үк упкын өстендә яшәп, үзара якынайдык. Өч-дүрт көннән мин шулардан аерылам.

Ниһаять, хатыным, кызым, туганнарым белән очрашам. Алар мине зарыгып көткәннәр. Мин дә бит шушы очрашуны җиде ай түземсезлек белән көттем. Кавышулар өчен генә дә юлда очраган барлык

газапларны кичерергә әзер идем. Сәяхәт вакытында кавышуны зарыгып көтсәң дә, гаилә тормышыннан әкренләп бизә башлагансың икән. Син инде ялгызлыкка күнегеп киткәнсең диярлек.

Корабтан аерылгач, иң беренче сине урамнарның киңлеге, шәһәрнең зурлыгы, андагы кешеләрнең күплеге өркетә. Син бит буе йөз илле, киңлеге егерме биш адымлы яшәү мәйданына күнеккәнсең, сиңа шул табигый тоела башлаган. Киңлек, җирдәге ирек сине чын-чыннан куркыта, шунлыктанмы, ярдагы беренче төн йокысыз үтә, җанда — тынгысызлык. Икенче тетрәндергеч хәл — квартираңдагы әйберләрнең күплеге. Каютаңда бары тик үз әйберләрең, сабын савыты, электробритва, теш щеткасы, алмаш кием, яраткан китапларың. Квартираңда нәрсә генә юк! Монда өч кеше әйбере тупланган, өстәвенә табак-савыт, йорт җиһазлары, кер юар өчен тотылган тагарак, кофе тегермәне...

Тагын бер үзенчәлек: аяк атлаган саен хатын-кыз киеменә килеп төртеләсең, иннек-кершәнгә, пудрага могҗиза күргән шикелле аптырап, исең китеп карап торасың. Башта өеңдә хатын-кыз киеме булу сине куандыра. Менә бит ул чын тормыш нинди була, дип, сабыйлар шикелле, шатланып йөрисең. Бернич көннән үз әйберләреңнең йорт җиһазлары, хатын-кыз әйберләре арасына кереп югалуын аңлап аласың. Эзлисең, таба алмыйсың әйбереңне. Бу хәл нервыларыңа тия башлый. Шундый чакларда исеңә диңгез, корабың, яшәргә шундый кулай каютаң килеп төшә. Юк, әле син аларны сагынмыйсың. Каютада эзләгән әйбереңне табу уңайлырак булса да, гаиләдәге җылылык, мондагы җан рәхәтлеге юк, дип тынычланасың.

Кунак булып яшәү тиз туйдыра. Озак кунак булырга безнең тормышта шартлар да юк. Хатыныңның кырыкка бүленергә җитеп, йөк аты хәлендә бернич вазифаны сөйрәп баруын күрү сине айнытып җибәрә. Әз генә булса да ярдәм итәргә тырышасың. Эштән кайтуына аңа тәмлерәк аш пешереп торасың килә. Кибеткә элдертәсең. Метрода сине кысалар. Троллейбус, тукталышта тукталмыйча, сиңа пычрак яңгыр суы чәчрәтеп уза. Кибетләрдә — чират. Антверпенда азык-төлекне йорт саен таратып йөрүче сатучылар искә төшкәч, озын чират тору шундый ялыктыргыч тоела.

Мең газап чигеп, ит, бәрәңге, суган һәм ашка тәм кертер өчен, Елисей кибетеннән алган кальмар түшкәләрен күтәреп өеңә кайтасың. Карасаң — ваннаның торбасы тыгылган. Аны тазартырга кирәк. Бүлмәнең обойлары каралган икән, яңаны ябыштырырга ашыгасың. Обойдан соң тәрәзәләрне буйыйсы, аннан соң бүлмә паркетларын лак белән каплыйсы... я алла, тавык та чүпләп бетерерлек түгел икән бу йорт эшен. Өстәвенә, бер-ике сәгать каләм дә тибрәтеп аласы килә. Көндәлек тормыштагы мәшәкатьләр сине колга әйләндерә. Өч ай ялда булып, туган авылыңа да кайтып килә алмадың, хәтта якын дусларың белән дә очраша алмадың. Шушы коллыктан котылуның бердәнбер юлы — тизрәк диңгезгә качу.

Иң аянычлысы — китәргә җыена башлагач, ярда яшәгәндәге мәшәкатьләр капыл онытыла. Хәтердә гаилә тормышының җылылыгы, рәхәтлекләре генә кала. Туганнарың, дусларың хәзер шундый газиз. Аларны ташлап китәргә теләмичә җан сыкрый. Әйберләреңне җыя башлыйсың. Күз алдыңа юлда очраячак авырлыклар килеп баса. Ирекле көннән туган җиреңне ташлап китәсең — бу дөньяда сәяхәткә йөрүдән дә каһәрле эш бармы икән?

Соңгы тапкыр, дисең, соңгы мәртәбә... Бу юлы да сәяхәттән исән-сау кайта алсам, ташлыйм мин бу эшне, китәм. Тыныч тормышка ни җиткән? Ташлыйм мин йөзү эшен! Валлаһи, ташлыйм! Билләһи, диңгез ягына башка борылып та карамыйм! Гаилә җылысы, тыныч түшәктә йоклау, җирнең ышанычлы катылыгын тоеп йөрү... Мин, атабабам шикелле, я сугышта, яисә җылы түшәгемдә үләргә тиешмен.

Төкерәм мин давыл кошларына! Альбатрослар миннән башка очсыннар. Неаполитан култыгының нәфис зәңгәрлеген миннән башка күзәтсеннәр. Босфорның сихри матур таңнары миннән башка атсын. Үкереп торган кырыгычны параллельләр минсез котырсыннар. Диңгез җиленең тозлы тәме, аның биткә сылана торган нәзберек назы кирәкми миңа. Диңгез үзе дә кирәкми. Җитте!

Тукран тәүбәсе. Ышанмагыз диңгезчеләр антына. Диңгезченең йөзү эшен ташлыйм дигән тәүбәсен уйнашчы хатыннар антына тиңләп карагыз. Югыйсә алданасыз.

Сәяхәттән кайтуыма әле өч ай да үтмәде. Шул ялыктыргыч озак, озынга сузылган көтүләр, җелегеңә үтеп керә торган сагынулар, чайкалу вакытында кинәт түшәмнең идәнгә әйләнеп китүләре, корабтагы төрмә кысынкылыгы, пароход артыннан күбекләнеп кильватер юлы калуы, акчарлаклар тавышы төшләремә керә башлады. Төштә алар миңа бәйрәм булып тоела. Өнемдә дә сәяхәт саташулары... Әллә бу дөньяда сихер булуы дөресме икән? Кешене сихерләп гашыйк итеп була дип сөйлиләр, әллә бу сафсата да хакмы? Дуслар үгете, хатынымның сукрануы, әти, ташла диңгезне, калдырып китмә, үзең исән килеш ятим итәсең ич безне, дип кызымның ялваруы да ярдәм итә алмый. Бөкрене ләхет төзәтә, ди мәкаль.

Яшәү тукталып тормый. Бу дөньяда без мосафирлар гына. Җир йөзенә вакытлыча килеп чыккан юлчылар гына ич без. Чемодан кайда? Зарланма, чемодан. Нигә миңа шундый шелтәле караш ташлыйсың? Мин читтә йөреп, туган җиремнең, туган халкым татарларның югалган, җиргә күмелгән тарихларын эзлим ләбаса. Әгәр балигъ булуымны көтеп тә тормыйча, армиягә алып китмәгән булсалар, мин, Нурихан Фәттах, Әбрар Кәримуллин шикелле, тарихыбызны үз төбәгебездән эзләр идем. Тәкъдирем шундый күрәсең. Ераккарак китеп, читтәнрәк карасам, бәлки ерак бабаларым күмелгән курганнарның барысын да күрә алырмын? Бәлки халкымның яшәешен чит халыклар тормышы белән чагыштырып карасам, милләтемнең хәлен дөрес аңлый, аңлата алырмын? Әйдә, чемодан, тагын бер тапкыр йөреп кайтыйк әле...

Мәрхәмәтле, җылы оямнан китүемә ун көн дә тулмады. Тагын хәрәкәт. Тропик һавасы шундый эссе — җир йөзе тоташ мунча тоела. Котып бозлары тагын шатыр-шотыр килеп корабның тимер тәнен дөмбәсли. Босфордагы таң ату сихере әллә нинди әкияти галәм ача. Һавада, гигант канатларын җәеп, альбатрос — хөррият кошы асылынып тора. Әнә мачталарның очында яшькелт очкыннар — Изге эльм уты бии...

Еракларга киткәч, туган җиреңне ярату нилектән шулай сафлана, шулай көчәя, ачыклана икән? Миңа моны кем аңлата ала? Кем?

*1982—1987*

*«Николай Щукин», «Ростов-на Дону» кораблары, Мәскәү.*

# ПОЭЗИЯ

## Кави Латыйп

### Мин синеке

Күкрәүләрем,
тетрәүләрем белән
мин синеке,
туган җир-туфрагым.
Сине сөйгәнгә дә —
ясамадым ялгыш адым.

Үзеңә гел турылыклы булып калдым.
Ябыштым теш-тырнагым белән.
...Шаһит моңа һәрбер үлән.

Мин —
Туган җир кадерен беләм...

### Аңларсың

Йөрәкне шул өшетә:
син — яхшылык,
ә ул начарлыктан чыгып эш итә.

Ихласлыктан туган
ялгыш бер адымны
күз алдында күпертә, биш итә.
Һәм үзен пәһлевандай хис итә.

Ә син кәрлә булып каласың.

Һәм йөртәсең
тик яхшылыктан ялраган
күңел ярасын.

...Кара уйлыларга яхшылык эшли калсаң,
Кави Латыйпны аңларсың...

### Ялган чәчәкләр

«Гөл сибәрләр юлларыма»—
дигән идең уйларыңда.
Нык ялгыштың уларыңда...
Син калага килгәч, «шатлык»тан
төн йокламый,
Үзара талаштылар.

Ә инде авылыңа озатканда,
кулларыңа ялган чәчәкләр тоттыргач,
килештеләр, яраштылар.
Өсләреннән тау төшкәндәй,
бер-береңә караштылар...

Ә такси өчен
синең янчыктан санаштылар.

---

Кави ЛАТЫЙП *(1927) — шагыйрь, татар, рус, чуваш телләрендә басылган шигырь һәм проза китаплары авторы. Татарстанның атказанган культура хезмәткәре. Казанда яши.*

## Җәза

Кайчак
кеше белмәс,
кеше ишетмәс
хәлгә калам:
бер сөенеч өчен —
икеләтә җәзам!

## Айналайн

*Олҗас Сөләйменовка*

«Елан шәраб эчмәс,
адәм — эчәр!»
Шулай диде чал чәчле бер мишәр...

Елан күрсә,
этиемә берәү шәраб бирсә,
әйтә иде әнием: «Айналайн!» —
кочкан килеш мине,
дүрт яшьлек малаен,—
Саклар өчен
мине елан чагудан,
этигә шәраб аяк чалудан...

Казакъ якларында йөргән әниемә
«Айналайн» сүзе
бик тылсымлы булган.
Олжас туган...

## Күз тидердем

Үземә үзем күз тидердем,
дусларымны көендердем...
дошманнарны сөендердем...

Кая барырга белми йөрдем:
исереккә сәлам бирдем...

## Әйтәләр...

Пәрәвезгә эләккән күбәләк...
Әйтәләр:
«Җиһан киң,
түгәрәк,
мөбәрәк...»

## Гел эзләнү

Гел эзләнү,
гел уйлану.
Һич кенә дә юк җанга тынычлык.
Әллә шулмы
ныклык,
кырыслык?..

## Яши белә...

Елан икән ул,
дөньяны агулар өчен туган икән ул.
Ә үзен: «Мин кеше»,— ди.
Гомер буе агу чәчеп,
ничекләр итеп
кемлеген төшенми?..

Төшенә, әлбәттә,
әмма бик оста яшерenә.

Битлек киеп яши белә...

## Берәү

Берәү җирләнде — күмелде.
Диңгездәй яшь түгелде.

Аннары сүгелде,
нәләт укылды.

Диңгез-яшь кипте.
Күңелгә нәфрәт дуены утырды.

## Ишек шакыды...

Әҗәл килде,
ишек шакыды,
чакырды.
Янына чыкмадым.
Китеп баргач, иркен суладым.

Ә таң аткач,
күршем үлгән, дип ишеттем.
Тетрәп киттем,
үземне гаепле хис иттем:

«Нигә төнлә әҗәл янына чыкмадым,
үзенең башына сукмадым?!»

## Кем белсен?..

Тирә-як тып-тын булып калды.
Газраил аны тартып алды.
Ул, бәлки, анда кирәктер?
Ә бәлки, тормыш җиз иләктер?
Кем белсен?
...Тынлык кына сөйли дөресен.

## Өзеп әйтте

Ерактан, бик ерактан
тавыш килгән иде,
гүя хәбәр биргән иде.

Өзеп әйтте агай «намаз»ын:
«Ишеттем, балам, Җир-ананың
мәңгелек авазын».

# Фирая Зыятдинова

## Уйлану

Көрәш барган мәңге Җир йөзендә,
Көрәш бара һаман: кем кемне?
Элек ачык булган күп нәрсәләр
Зәңгәр томан белән өртелде...

Көрәш бара һаман җир йөзендә:
Күпме корбан, күпме күз яше!
Аклык җиргә салып тапталгачтын,
Җир йөзендә нигә мин яшим?

Бутәннәрнең җаны кыйналганда
Нигә минем җанга тынычлык?!
Кеше исемен йөрткән адәми зат,
Кешеме син, әллә ерткычмы?

Тормышны ал буяуларга мандык,
Җир шарына Байрак күтәрдек...
Ә аннары, Байрак күтәргәннең:
«Син — дошман!»— дип, җанын үртәдек.

Үртәдекме?! Тәмугларга салдык,
Сират күперләрен кичердек.
«Дөреслек!» — дип янган изге җанның
Рухы безне ничек кичерер?

Көрәш бара мәңге Җир йөзендә,
Көрәшләрнең була төрлесе.
Байрак күтәргәнгә каршы көрәш —
Иблислекнең кара билгесе.

Көрәш бара һаман Җир йөзендә,
Туктамас ул көрәш, мин беләм.
...Акрын-акрын ачыла Илем күге,
Китә болыт Илем күгеннән.

Фирая ЗЫЯТДИНОВА — *ике шигырь китабы авторы. Казанда яши.*

## Минем җырым

Минем җырым — язгы ләйсәннәрдә,
Минем җырым — Кояш нурында.
Минем җырым бөре булып тула
Кушкаенның җылы куенында.

Минем җырым — яшел үзәннәрдә,
Минем җырым — тугай-болында.
Минем җырым борыла-сырыла аккан
Инешемнең көмеш чыңында.

Минем җырым — кошлар сайравында,
Минем җырым — бөдрә талларда.
Минем җырым эзләп табар мине,
Китсәм дә мин әллә кайларга...

Минем җырым — минем йөрәгемдә,
Күңелемнең чыңлый түрендә.
Минем җырым — Сагыш, Моң һәм Сөю,
Минем җырым — Яшәү турында!

## Җирне сагынып...

Күккә мендем.
Йолдызларга җиттем —
Йолдыз буранына уралдым.

Җирне сагынып,
Кире Җиргә төштем —
Уйлар буранында югалдым...

## Әгәр дә...

Әгәр дә мин
Сөям икән
Җирне,
кукне,
кешеләрне
Шашып-шашып;

Әгәр дә мин
Яшим икән
Язын

Ярларына сыймый аккан
Елга кебек ташып,

Димәк,
Мин — Кеше,
Мин — исән,
Мин — тере!

Димәк,
Юкка тудырмаган
Җирем мине!

## Гомер ике килми...

Таллар тора оеп,
Су агышын тыңлап.
Тыңлаулары рәхәт —
Сулар ага чыңлап.

Таллар тора боек,
Үз көйләрен көйли:

«Сулар кире акмый,
Гомер ике килми!»

Гомер ике килми?..
Ә кем аны белми?
Җанда бер уй иңри:
«Ә үз көең нинди?»

Гомер ике килми...

# Әмирхан Еники

# ХАЛЫКНЫҢ КҮЗЕН АЧА БЕЛҮ ДӘ КИРӘК

**Күренекле әдип, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Әмирхан ага Еникигә 2 мартта 80 яшь тулды. Шул уңайдан язучы белән уткәрелгән әңгәмә тәкъдим итәбез.**



*— Әмирхан ага, Сез халкыбызны борчыган проблемаларны күтәреп матбугатта даими рәвештә чыгышлар ясап киләсез. Соңгы елларда тел һәм аның яшәеше хакында да үз уйларыгыз белән уртаклаштыгыз. Биредә дә сүзне шуннан башлыйк әле: татар теленең киләчәк язмышына Сез ничек карыйсыз? Кайберәүләр аның хәле мөшкел диләр, мондыйларга ничек җавап бирергә?*

— Әйе, туган телебез турында миңа язгаларга туры килде. (Соңгысы «Казан утлары»ның 1988 елгы 9 санында басылган иде). Ләкин анда язылганнарны яңадан кабатлап торуның кирәге бармы икән? Телебезнең авыр хәле бәхәссез, киләчәге шактый хәвефле, әкренләп югалу куркынычы да юк түгел, — билгеле, моңа күз йому гафу ителмәслек сансызлык булыр иде. Дөресен генә әйткәндә, соңгы 25-30 ел дәвамында туган телебезгә карата булган игътибарсызлык, нигилистик мөнәсәбәт аны бүгенге аяныч хәлгә китереп тә җиткерде.

Хәзер инде без аның киләчәк язмышы турында борчылырга мәҗбүрбез. Телне саклап калу өчен ниндидер ашыгыч чаралар күрергә кирәк,— әгәр соңга калмаган булсак... Әмма хәзерге шартларда безгә үз телебезнең хәлен җиңеләйтү ансат булмаячак. Чөнки, бердән, рус теле безнең тормышыбызда һәр җәһәттән өстенлек итә, икенчедән, балаларны кайсы телдә укыту мәсьәләсе элеккечә ата-ана ихтыярында кала. Бер караганда, бу принцип бик гадел дә, бик демократик та кебек, мәгәр туган тел файдасына түгел... Икеләнмичә әйтергә була ки, үзләре татарча укымаган яшь ата-аналар балаларын, билгеле, рус мәктәпләренә бирәчәкләр. Ә андыйлар елдан-ел күбәя бара, димәк, телебезнең киләчәк язмышын да шулар хәл итәчәк. Татар теленең киләчәгенә ышанмыйча карау да әнә шуннан килә, минемчә... Нишләргә кирәк соң? Бәлки яшьләрдә милли аң уянуын көтәргә кирәктер?.. Юк, аң уянганын көтеп яту донкихотлык булыр иде. Тел бит буыннан-буынга күчә торган нәрсә, әгәр дә бу күчеш берничә буынга өзелеп торса, телне саклап калу, ихтимал, мөмкин дә булмас. Димәк, безнең үзебезгә тизрәк уянып, ашыгыч радикаль чаралар күрергә кирәк булачак.

...Без милли республикада яшибез. Безнең сайлап куйган Югары Советыбыз бар, хөкүмәтебез бар. Шулай булгач, безнең республика шартларында төп халыкның теле, рус теле шикелле үк, бер үк хокук белән файдаланылырга тиеш. Моның өчен татар телен дәүләт теле итеп республиканың Конституциясенә кертергә кирәк (хәзергә әле анда рус теле генә дәүләт теле итеп беркетелгән). Бу чара телебезне саклауда законлы гарантия булачак. Кәгазьдә генә түгел, гамәлдә дә!.. Ә дәүләт телен белү һәркем өчен зарури булырга тиештер инде — бигрәк тә һәрбер татар кешесе өчен... Мәсьәлә шулай куела икән, димәк, татар балаларын туган телдә тәрбияләү һәм укыту да башкача хәл ителергә тиеш. Беренчедән, бөтен җирдә ана телендә укыту дүртенче класска чаклы мәҗбүри булырга тиеш. Икенчедән, урта мәктәпне бетереп чыкканда татар укучыларының өлгергәнлек ат-

тестатына туган тел белән әдәбиятны да кертергә кирәк. Өченчедән, Казан вузларына керүче татар яшьләре шулай ук туган телдән һәм әдәбияттан имтихан бирергә тиешләр. Бер-берсенә бәйләнгән бу чаралар туган телебезнең тормышта тоткан урынын һичшиксез ныгытачак. Иң мөһиме — киләчәк буын туган теленнән мәхрүм булмаячак. Кайберәүләрдә, рус телен өйрәнүгә моның зарары булмасмы, дигән уй туарга мөмкин. Миңа калса, һич зарары булмаячак, чөнки рус телен укыту да башлангыч класслардан алып, мәктәпне бетереп чыкканчыга кадәр әүвәлгечә дәвам итәчәк. Гомумән, рус телен белмичә калу куркынычы юк — татар халкы ике теллегә әйләнде инде дисәк тә була.

Икенче төрле сорау да туарга мөмкин: татар телен дәүләт теле иткәч, русларны да татарча укыту кирәк булмасмы икән? Минемчә, кирәк булмас, чөнки укытып маташудан барыбер мәгънә чыкмаячак. Татарстанда яшәүче халыкның яртысы диярлек руслар, рус теле дә дәүләт теле, безнең республикада ул моңарчы нинди урын тоткан булса, моннан соң да шул урында нык торачак — бәс, шулай булгач, рус кешесенә татар телен өйрәнеп азапланунын ни кирәге бар? Өйрәнмәячәк ул аны... Инде кызыксыну йөзеннән өйрәнергә теләүчеләр табыла икән, рәхим итсеннәр! Моның өчен аларга бөтен шартларны тудырырга кирәк.

Без үзебезне кайгыртырга тиешбез. Милли горурлык хисе булган халык үз тамырына үзе балта чапмас. Ятлар колагына бәлки бик үк ягымлы ишетелмәгән «татар» исемен йөртүче безнең күпне күргән, күпне татыган чыдам, тырыш, уңган, ватанпәрвәр халкыбыз ике телне дә камил белергә тиеш. Әмма иң газизе аның өчен туган теле — вәссәлам!

— *Милли горурлык хисе дидегез. Хәзер бездә аңа төрлечә караш яши. Ә сез бу хакта ничек уйлыйсыз?*

— Милли аң, милли горурлык һәрбер халыкта бар, тик ул берәүләрдә ачыграк, көчлерәк, ә икенчеләрдә яшеренрәк, зәгыйфьрәк чагыла. Безнең татарлар, минемчә, менә шул икенчеләр рәтенә керә. Бәлки, бу аларның таралышып, башка халыклар белән аралашып яшәвеннән килә торгандыр.

Әмма милли аң, милли горурлык — бик табигый, бик кирәкле сыйфат, аны милләтчелек белән һич тә бутарга ярамый. Халыклар арасындагы дуслыкка да аның һич зарары юк — дуслыкны бит күп очракта ике арадагы тигезсезлек боза.

Милли аңын, милли горурлыгын югалткан халыкны мин мескен халык дияр идем — андый халык милли хосусиятләрен дә тизрәк югалта, тизрәк башкаларга яраклаша-буйсына ук башлый. Билгеле, мондый хәлнең бик ерактан килгән тарихи сәбәпләре булырга мөмкин, әйтик, кайчандыр бер халыкның икенче халыкны басып алуы нәтиҗәсендә; әмма бу очракта да милли аңын, милли горурлыгын югалтмаган халык үзен милләт буларак та саклап килә алган. Татар халкының үз тарихы да шуның бер мисалы түгелме?!

— *Сез ничек уйлыйсыз: Казанны татар шәһәре дип әйтеп буламы?*

— Казан — татар шәһәре, ул шулай танылган, шулай яшәп тә килгән. Дөрес, руслар кулына күчкәннән соң ул инде саф татар каласы булудан туктый. Берничә гасыр дәвамында төзелгән чиркәүләре, монастырьлары, рус стилендәге таш йортлары белән ул Россиянең башка күп шәһәрләренә охшап кала. Шулай да әле безнең Казанны бу гасырның утызынчы елларына кадәр татар шәһәре дип тә атарга мөмкин иде. 1925 елны беренче мәртәбә Казанга килгәч, мин моның шулай икәнен аеруча нык сизгән идем. Чөнки татарларның иң зур күпчелеге ул чакта шәһәрнең аерым төбәгендә — Болак аръягында оешып яшиләр иде, мәчетләре, мәктәп-мәдрәсәләре, базарлары да шул якта иде, һәм бу якта йөргәндә үзеңне чынлап та татар дөньясына килеп кергәндәй хис итә идең... Мәгәр бу аерма күптән инде бетте. Казан тарихи йөзен бөтенләй үк югалтып бетермәсә дә, ул инде урбанизация нәтиҗәсендә башка бик күп шәһәрләр төсле үк стандарт бер шәһәр булып калды. Татарстанның башкаласы булса да аның архитектурасында татарныкы, яисә башка кайсыдыр милләтнеке дип әйтерлек бер нәрсә дә юк. Бары халкының милли составы ягыннан гына аны рус һәм татар шәһәре дип атарга була.

— *Хәзер безнең әдәбиятның яңа күтәрелеш ясавы өчен нинди шартлар кирәк? Нәрсәләр эшләү кирәк?*

— Махсус шартлар кирәк микән? Әдәбият теләсә нинди шартларда да яшәвен дәвам итә. Бу шартлар әдәбиятның активлыгы өчен уңай яки уңайсыз булырга мөмкин. Мәсәлән, безнең әдәбият утызынчы еллардан башлап, сиксәненче елларның урталарына чаклы бик тар, кысан шартларда яшәп килде һәм шушы озын дәвер эчендә ул асылда рәсми политикага буйсынган, үзгәреп торган конъюнктурага хезмәт итүче булып кала бирде. Тик аерым язучыларның аерым әсәрләре генә бу гомуми кагыйдәне ара-тирә бозгалады. (Һәм моның өчен каты тәнкыйтькә дә дучар булдылар).

Хәзер исә шартлар бик нык үзгәрде, мәйдан да киңәйде, хөрлек тә артты. Бигрәк тә язучының үзендә Чехов әйткән эчке хөрлек хисе уянды. Ә бу — иҗат итүнең беренче шарты. Ләкин язучыларның активлыгы хәзер үзгәртеп кору китереп чыгарган проблемаларга күчеп, аеруча публицистикада чагылыш тапты. Теге яки бу темага мәкалә язмаган әдип, шагыйрь, тәнкыйтьче калмады диярлек. Куанычлы күренеш!

Әмма тормышның үзендәге тирән үзгәрешләрне ачкан чын әдәби әсәрләрне күрмибез әле. Миңа калса, моңа артык гаҗәпләнергә дә туры килми. Чөнки хәзерге тормыштагы үзгәрешләр шул хәтле тирән, катлаулы һәм каршылыклы ки, моны белү, аңлау, тою өчен һичшиксез күпмедер вакыт кирәк булачак. Ашыгырга ярамый. Чын язучы конъюнктурадан бик нык сакланырга тиеш. Бердәнбер максат — бары чын дөреслек! Без шуңа бик сусадык.

— *Әмирхан ага, Сезнең 1965 елда ук язылган «Әйтелмәгән васыять»егез шундый алдан күрүчән сүзләр белән тәмамлана: «...Ә син учагын карый тор, учагын! Учагында ут сүнмәсен!» Шул уңайдан бүгенге авыллар язмышы белән милләт язмышы арасынданиндидер бәйләныш күрмисезме?*

— Дөрес, авыл язмышы белән милләт язмышы арасында бәйләнеш бар. Милләткә хас күп нәрсәләр — туган тел, гореф-гадәт, әхлак кагыйдәләре күбрәк авылларда саклана. Авылларның кимүе милләтнең зәгыйфьләнүенә китерүе бик мөмкин. Мәгәр милләт язмышын авыл язмышы белән генә бәйләп карау дөрес булмас иде. Авыл кимесә дә, халык кимеми — ул, әнә, шәһәрләргә тула. Миңлебай карт әйткән учак авылда сүнсә, ул яңа урында — шәһәрдә кабынырга тиеш. Әнә, Европа илләрендә халыкның иң зур күпчелеге шәһәрләргә тупланып беткән, әмма учаклары сүнмәгән, учаклары, киресенчә, гөрләп янып тора. Моннан нәтиҗә: халыкларның милләт буларак яшәүләре торган урыннарына карап кына йөрми. Иң мөһиме, халык кайда гына торса да, үз язмышына үзе хуҗа булырга тиеш. Менә шул чакта учаклар сүнмәс, сакланыр!

— *Татар халкының шәһәрләшүенә мөнәсәбәтегез ничек?*

— Шәһәрләшү бөтен ил күләмендә бара һәм барлык халыкларга да кагыла ул. Котылгысыз процесс. Иске шәһәрләр өзлексез үсә, яңалары һаман туып тора. Кем исәбенә? Билгеле инде, башлыча авыл исәбенә. Шуңа күрә дә бит шәһәрдә торучылар елдан-ел арта, авылда калучылар исә кими бара. Бу хәлнең җитди экономик сәбәпләре бар, әлбәттә. Ләкин аларына тукталып тору минем эшем түгел.

...Шәһәрләр аеруча яшьләрне үзенә суыра. Шәһәрдә тору алар өчен кызыклы, җиңелрәк (квартир да ала калса), төрле ихтыяҗ-теләкләрне үтәү өчен мөмкинлекләр дә күбрәк. Дөрес, кеше монда табигатьтән ераклаша, начар һава сулый, кысылып һәм ашыгып яшәргә мәҗбүр була. Ләкин ул моны уйлап тормый, ул авылдан туйган, шәһәр кирәк аңа...

Мәгәр бу мәсьәләнең бер ягы гына әле. Шәһәрләшү (урбанизация) халыкның рухи дөньясына да бик зур йогынты ясый. Чөнки ул инде үзенең табигый җирлегеннән аерыла, яңа шартларга ияләшергә, төрле милләт кешеләре белән аралашып яшәргә тиеш була. Менә шундый шартларда аңа, әйтик, безнең татар халкына, үзен милләт буларак саклар өчен, үзенең рухи таләпләрен канәгатьләндерер өчен нәрсә кирәк? Беренче нәүбәттә ул үзенең бөтенлеген һәм бердәмлеген сакларга тиештер инде, аннары туган телен сакларга, балаларын шул телдә тәрбияләргә, ата-бабадан килгән әйбәт гореф-гадәтләрен югалтмаска, ниһаять, милли әдәбиятыннан һәм сәнгатеннән аерылмаска тиештер. Хәлбуки, шәһәрләшү шуларның барысыннан да аерылуга, аннары әкренләп югалтуга да китерүе мөмкин. Куркыныч әнә шунда. Мисал өчен үзебезнең Чаллыны алырга мөмкин. Кыска гына вакыт эчендә ул 500 меңлек шәһәргә әйләнде. Күпме татар яши хәзер анда! Ләкин шул халыкка үз телләрендә мәктәп тә юк, матбугат та юк, театр-мазар да юк... Бу бит милли политикада Ленин принципларын тәмам бозу дигән сүз! Шәһәрләшү үзе ул хәтле үк куркыныч нәрсә түгел. Ә менә шәһәрләшү аркасында милли тигезлекне, милли хокукларны югалту — зур куркыныч! Бигрәк тә интернационализм битлеге астында. Сүз дә юк, интернационализм халыклар өчен бик кирәкле нәрсә, тик ул буш сүзгә һәм алдауга әйләнмәскә тиеш.

— *Әдәби әсәрләр халкының аңына, фикерләвенә бик тәэсир итә. Ә Сез үзегезнең кайсы әсәрегез күбрәк тәэсир итте дип саныйсыз?*

— Белмим, ачык кына әйтә алмыйм... Тәэсир итү ягыннан төрлесе булгандыр. Укучылар да бит бер төрле генә түгел. Берәү яратканны икенчесе яратмаска мөмкин. Шулай да минем әйберләргә карата шундыйрак бер хәлне күзәтергә туры килгән иде: каты тәнкыйтькә очраганын укучылар ничектер кызыксынып кабул иттеләр (мәсәлән, «Рәшә» повестен). Хәер, без кичергән заман өчен бу гомуми бер күренеш иде. Начар тәнкыйть яхшы реклама булды.

— *Әмирхан ага, Сез моннан унөч ел элек (1976 елда) яшьләр белән әңгәмә*

*вакытында әдип өчен иң мөһим сыйфат хакында сүз алып барып болай дигән иде-гез: «...халык күңелен бик нечкә сизә алу, халыкның иң түрендә яткан өмет-теләкләрен «күрә» алу кодрәтенә ия булу». Халыкның күзен дә ача белү кирәк.*

*Әдәбиятыбызның соңгы еллардагы күренешләренә әнә шул ноктадан карап фи-кер йөртсәк, нинди(рәк нәтиҗәләр чыгар иде икән?..*

— Моннан 13 ел элек әйткән сүзләремне дөрес дип саныйм, кирәксә, яңа-дан да кабатлый алам. Ләкин соңгы еллардагы әдәбиятка, шул әйткәннәрдән чы-гып, бәя бирүне өстемә ала алмыйм, чөнки барлык әсәрләрне дә укып барырга, кызганычка каршы, һич өлгереп булмады. Артык кубәеп китте укыр нәрсәләр — күзләр генә чыдасын!

Шулай да, кайчандыр әйткәнннәргә өстәп, минем шуны да әйтәсем килә: за-манның әдәбиятка таләбе үзгәреп тора, һәм әдәбият шуңа яраклашырга тиеш бу-ла (теләпме, теләмичәме,— анысы икенче мәсьәлә). Менә хәзерге үзгәртеп кору да язучылар алдына гаять җитди сораулар һәм проблемалар китереп куйды. Без хәзер 60-70 еллык тарихыбызны өр-яңадан карау, өйрәнү, аңлау процессын кичә-рәбез. Бу һич тә җиңел эш түгел... Без үзгәртеп коруны бик хуплап каршы алсак та, иске карашлардан һәм гадәтләрдән бик авырлык белән, әкренләп кенә арына-быз. Гади халыкның күпчелегендә исә бу иске караш, гадәтләр, минемчә, тагы да тирәнрәк утыра. Ә бит ул канга сеңгән нәрсәләрдән арынмыйча торып, үзгәр-теп кору куйган максатларга ирешү гаять авыр булачак. Димәк, үткәндәге хәл-ләргә халыкның күзен ачу, фикерен уяту һәм бүгенге катлаулы проблемаларны дөрес аңлауда аңа ярдәм итү — менә без кичергән заманның әдәбият алдына куй-ган таләбе шул... Һәм, әйтергә кирәк, язучылар бернинди өндәүне көтеп тормый-ча, бу бик җаваплы эшкә җиң сызганып керештеләр. Барлык жанрларга караган-да да публицистиканың беренче сафка чыгуы — шуның ачык бер мисалы. Әмма эш-ләр җиңелдән түгел, фикерләр дә бер түгел, искенең яңага каршы торуы да бик көчле — кыскасы, гаять катлаулы, авыр көрәш бара... Күрәсең, мондый чакта язу-чыга «халык күңелен нечкә сизү» өстенә, аны, ягъни халыкны, үз иманыңа ышан-дыру да бик кирәк...

*— Илебездә Яңарыш процессы бара. Шул уңайдан Сез ничек уйлыйсыз: бү-генге җәмгыятебездә ул процессның җиңүен тәэмин итәрдәй нык иманлы, рухи яктан таза һәм актив көчләр ни дәрәҗәдә исән, тере? Ягъни бүгенге җәмгыять-нең рухи яктан тазалыгы турында Сез ни уйлыйсыз?*

— Җәмгыятьтә таза көчләр бервакытта да бөтенләй үлеп бетми, нинди генә авыр хәлдә калсалар да, уңай шартлар туу белән, алар яңадан терелә башлый. Үзгәртеп кору менә шуны ачык күрсәтте: үзгәреш башлану белән, аның яклы көч-ләр бик тиз хәрәкәткә килде. Бигрәк тә интеллигенция бу яңарыш өчен көрәш-тә зур активлык күрсәтеп килә. Әмма шулай да җәмгыятебезнең рухи тазалы-гы, тулаем алганда, әйбәт, канәгатьләнерлек дип әйтергә иртәрәк әле. Моны шул ук үзгәртеп коруның авыр баруы, күп каршылыкларга очравы үзе дә күрсәтеп тора. Хикмәт нәрсәдә?.. Хикмәт шунда ки, Сталинның мәкерле явызлыгы ничә-мә миллион кешенең башына җитү белән бергә, гомумән халыкны рухи колга әйләндерде. Иман качты, кешегә ышану бетте, фикер сүнде, ихтыяр сынды, бары җанны билән алган курку да, шул тиранны аллага тиңләп, аның итекләренә та-быну калды. Әнә шундый сукыр коллыкка төшү нәтиҗәсендә кеше мөритләрчә ярар-га, яраклашырга, башын сакларга тырышты. Хәтта Сталинның явызлыгын күреп торган, килешә алмаган кешеләр дә намусларын көчли-көчли башларын ияргә, тешләрен кысарга мәҗбүр булдылар. Моның ише гомуми коллыкка төшү тарих-та күрелмәгән алдау аркасында булды: янәсе, Сталин тарафыннан ниләр генә эш-ләнмәсен, болар барысы да ил бәхете өчен, социализм өчен! — һәм халык шушы ялганны кул чабып кабул итте, шушы ялганга ышанып, Сталинның канлы җи-наятьләрен акларга, ә үз вөҗданын тынычландырырга тырышты.

Билгеле инде, мондый тирән сеңгән рухи коллыктан кеше тиз генә чыга алмый. Моның өчен вакыт кирәк, иҗтимагый шартларның үзгәрүе кирәк. Хру-щев вакытында Сталинның шәхес культы фаш ителсә дә, аның зарарлы йогын-тысын бетерү өчен радикаль чаралар күрелмәде. Тормыш иске эзеннән бара бир-де. Ә инде шактый озакка сузылган Брежнев заманнарында рухи торгынлык яңа-дан көчәйде, тормышның бөтен тармакларына үтеп керде, хәтта бу рухи гарип-лек яшь буынга да күчте. Һәм хәзер дә әле очрап торган бөтен ямьсез эшләр, әхлакый бозыклыклар, һәртөрле җинаятьләр — барысы да — Сталиннан мирас булып калган көчләү һәм алдау юлы белән халыкны «җитәкләп» маташуның нәтиҗәсе ул.

Бу рухи торгынлыктан ничек итеп чыгарга соң, ничек итеп җәмгыятьнең рухи тазалыгын тәэмин итәргә? Үзгәртеп кору моның ике чарасын күрсәтте. Бе-ренчесе — җәмгыятьтә иҗтимагый гаделлекне булдыру; икенчесе — җәмгыять тор-мышын хәбәрдарлык һәм демократия нигезендә төзү... Сез әйткән «таза көчләр»-

гә әнә шулай гына юл ачылыр дип ышанырга була.

*— «Демократия» дигән сүзне без бик еш кулланабыз. Ләкин чынлыкта әле без аның «нәрсә белән ашала торган әйбер» икәнлеген аңлый гына башладык бугай... Сезнең бу хакта ниндирәк фикерләрегез бар?*

— Дөрес, демократиянең нәрсә икәнен без әле татып караганыбыз юк. Ләкин без инде демократиягә йөзебез белән борылдык, хәзер әкренләп шуңа таба барабыз. Күптән түгел Конституциягә кертелгән кайбер үзгәрешләр, сайлау тәртипләрен үзгәртү буенча кабул ителгән карарлар әнә шул юлда беренче адымнар... Мәгәр тулы демократиягә без тиз генә, ансат кына ирешербез дип ышанырга, минемчә, иртәрәк әле. Тормышта бер генә нәрсә дә тәмам җитлегеп, әзер килеш тумый — аңа ныгыр өчен күпмедер вакыт кирәк булачак.

Бу уңай белән мине дә уйландырган кайбер моментлар бар. Мәгълүм булганча, XIX партконференциядә яңадан сайланачак Советларның председательләре партия комитетларының беренче секретарьлары булсын иде дигән теләк рәвешендә бер пункт кабул ителде. (Бу пункт тикшерелгәндә делегатларның күпмеседер аңа каршы да булганнар). Монда иң элек шундый сорау туа: карарның бу пункты безнең хәзерге Конституциягә сыя микән?.. Ягъни Советларга депутат булып сайланган партиясез кешене алдан ук Совет председателе булу хокукыннан мәхрүм итмиме?.. Әгәр итсә, бу — демократияне бозу булмыймы?

Конференция карарында теләк рәвешендә генә әйтелгән тәкъдимнең тормышта даими законга әйләнеп китүе бик мөмкин. Чөнки бу очракта халыкка күптән сеңгән психология төп рольне уйнаячак. Чыннан да, коммунистны югары, җаваплы урынга сайлау ул инде гадәткә кергән нәрсә. Каршылар булмаячак — булса да, алар азчылык тәшкил итәчәк. Димәк, иң югарыдан алып, түбәнгә чаклы, бөтен җирдә яңа Советларның председателе итеп партия комитетларының беренче секретарьлары сайланачак — бу көн кебек ачык, шикләнергә урын юк. Ихтимал, кайбер очракта, әйтик, шәһәр күләмендә Советның председателе итеп фиркасыз да сайланыр, ләкин бу инде кагыйдәдән чыгарма гына булачак.

...Әмма председательлекне дә кулына алган секретарьлар кемнәр алар, барысы да лаек кешеләрме? Моңарчы бит һәр өлкәдә, һәр шәһәрдә, бигрәк тә район җирендә беренче секретарь төп җитәкче, төп «хуҗа» иде. Халык та инде аларны күптән шулай дип таный, алар үзләре дә шул рольне башкарырга күптән өйрәнеп беткән. Бигрәк тә торгынлык заманында формалашкан секретарьлар өчен бу бик табигый хәл иде. Хәзер менә шундый секретарь Совет председателе дә булып алгач, ике җитәкчелекне дә үз кулында туплап, өйрәнелгән гадәт буенча, иске заман китмәс микән дигән шик туа. Һәм нәтиҗәдә без чын демократия урынына ярымдемократик, ярым бюрократик, авторитар бер власть алмабызмы икән?

...Әйе, демократиянең бездә зур сынаулар үтәсе бар әле. Әмма ул кирәк, ул зарур — ансыз һич тә мөмкин түгел.

*— Бүгенге кеше язмышы Табигатьтән башка һич тә күзаллanмаска тиеш. Шул уңайдан Татарстан табигате бик нык уйландыра...*

— Моңарчы кешелек дөньясы өчен беренче зур куркыныч булып атом коралы санала иде. Хәзер инде, галимнәрнең әйтүенә караганда, беренче урынга экология куркынычы күчте. Чөнки атом коралы кеше кулында, ул аны худка җибәрүдән тыела ала, теләсә, юкка да чыгара ала. АКШ белән безнең дәүләт арасында ирешелгән килешү атом коралын киметергә, ахыр чиктә бөтенләй бетерергә дә мөмкин икәнлеген ачык күрсәтте.

Ә табигатьне без озак еллар дәвамында туктаусыз кысрыклап киләбез, бозабыз, талыйбыз — шул рәвешчә без аны әкрен-әкрен һәлакәт чигенә китереп җиткерәбез. Бу хәвефне сизсәк тә, туктый белмибез. Табигать бит ул ни булачагын алдан ук безгә кычкырып тормый. Әмма инде чигенә килеп җиткәч, безнең башларыбызга бөтен коточкыч һәлакәтен китереп каплаячак. Арал диңгезе белән булган хәл — шуның бик ачык бер мисалы. Һәм андый хәлләр күп җирләрдә безне хәзер сагалый.

Алыйк үзебезнең Татарстанны... Аның табигате дә бик мөшкел хәлдә — күп регионнарга караганда да, территориябез әллә ни зур да түгел, ә аның җир-суларына төшкән йөк гаять авыр булса кирәк. 40-50 ел буе нефть чыгару күпме басу-кырларыбызны ертып, бозып, пычратып бетерде, күпме чишмәләрне корытты, коелардан сулар качты, яшел болынлы саф елгаларны үлек суларга әйләндерде. Болар яңадан терелерме, иске хәленә кайтырмы — без моны ачык кына белмибез. Табигатьне болай бозу-имгәтүнең кешеләргә тискәре, начар йогынтысын без әле исәпкә дә алмыйбыз.

Соңгы ун-унбиш ел эчендә республикабызның төп елгасы Камага да күтәрә алмаслык йөк төште. Чаллыдан алып Чистайга чаклы, күп булса 100-120 кило-

метр арада, гигант заводлар корылды, зур-зур шәһәрләр барлыкка килде, аларда яшәүче халыкның саны миллионнан артып китте. Йөк исә һаман арта бара. Алабуга янында, кираксез дип табылган трактор заводы урынына, икенче автомобиль гиганты салына. Менделеевскида яңа химия производстволары төзеләчәк... Һәм болар барысы да Каманың суын эчәчәкләр, тотачаклар, пычракларын шунда агызачаклар — йә, бу кадәр йөкне безнең батыр елгабыз күпмегә чаклы күтәрә алыр икән?! Мин инде аның ике ягындагы кырлар, урманнар турында әйтеп тә тормыйм — алардан иртәме-соңмы киек-җәнлекләр һәм кошлар качып бетәрләр дип уйлыйм... Әле бит җитмәсә, шушы тыгызлык арасына, елганың нәкъ өстенә заманның иң хәвефле объекты,— атом электростанциясе дә төзелеп ята.

Иң аянычы шунда ки, болар барысы да халыкка әйтмичә, халыктан сорамыйча эшләнә. Каядыр югарыда, әйтик, Госпланда яки министрлыкта утыручылар тоталар да Татарстанның фәлән җиренә фәлән нәрсә салырга дип карар чыгаралар. Һәм меңләгән кешене, йөзләгән техниканы туплап сала да башлыйлар. Халык исә белми дә кала. Ләкин бит әле безнең үз хөкүмәтебез дә бар, Татарстанның җир-сулары аның карамагында, аңа тапшырылган. Теге яки бу объектны салыр алдыннан аның белән сөйләшәләрме, аның ризалыгын алалармы, әллә аңа боералар гынамы? Бу гаять мөһим мәсьәлә... Хәлбуки, бер генә төзелеш турында да мин Татарстан хөкүмәтенең үзе чыгарган карарын, яисә халыкка җиткергән үз фикерен ишеткәнем юк.

Хәзер менә атом электр станциясе турында бәхәс бара. Җәмәгатьчелек борчыла (Чернобыль аның күзен ачты). Җәмәгатьчелек ул станциянең ни өчен Татарстан җирендә салынуын аңламый — ул аңа каршы. Мәгәр ничә елдан бирле корылып яткан, инде күпме акча исраф ителгән төзелешне туктатып булачакмыни?! Бер заман ул салынып та бетәр, эшли дә башлар. Чернобыль шикелле шартламас та, бәлки, тиеш тә түгел. Әмма халыкның күңеленә шом кереп калды, атом аның өчен гомумән бик куркыныч нәрсә, ул аңардан һәрдаим шомланып, нинди дә булса мәкерле зарарын көтеп яшәргә мәҗбүр булачак. (Җәяләр эчендә әйтәсем килә: Көнбатыш Европаның Татарстан шикелле җире аз, халкы күп илләрендә, мәсәлән, Бельгия, Голландия, Даниядә, атом станцияләре кору закон белән тыелган дип ишеткәнем бар.)

Кыскасы, экология куркынычы хәзер беренче урынга чыкты. Ничек итеп бу куркынычтан сакланырга? Ни өчен һәм бу хакта күп сөйләнсә дә, нәтиҗәсе бер дә сизелми диярлек?.. Монда бер парадокс бар: бездә җир-сулар, урманнар, барлык табигать байлыклары гомумдәүләт милке булып санала. Ә дәүләт милкенә сан юк, дәүләт милкен теләсәң күпме туздырырга, әрәм-шәрәм итәргә, хәтта эштән чыгарып ташларга да ярый. Мондый мөнәсәбәт булганда, табигатьне, билгеле, саклап булмаячак. Бары тик һәр авыл, һәр район, һәр өлкә яки республика үзенә тигән җир-суларга чын хуҗа булып танылганда гына һәм шул җир-сулар өчен җаваплылыкны да аларга йөкләгәндә генә экология куркынычыннан, ихтимал, котылып булыр. Тереклек дөньясын саклау — кешенең үзен саклау — бу хакыйкатьне онытырга берәүнең дә хакы юк.

*— Татарстаннан читтә бик күп милләттәшләребез яши. Әйтик, Башкортстан җирендә генә дә алар 1 миллионнан артык. Андыйларның киләчәк язмышын Сез ничек итеп күзаллыйсыз?*

— Бу бик җитди мәсьәлә, уйландыра һәм борчый торган мәсьәлә. Әйе, татар халкының бөтен Союзга таралып яшәве милләт буларак үзен саклау җәһәтеннән аның хәлен бик нык читенләштерә. Билгеле, моның ерак тарихтан килгән сәбәпләре дә бар, әмма революциядән соң бу таралу аеруча көчәйде. Мәсәлән, гражданнар сугышы вакытында һәм ачлык елында күпләп читкә китүләр, колхозлаштыру вакытындагы сөрүләр, сугыштан соң төрле якка эшкә җыеп җибәрүләр — әнә шул тараланың ачык күренешләре... Шулай да егерменче елларның ахырына кадәр без бөтен бер халык идек әле, үзара бәйләнешләр дә дәвам итә иде, татарлар тупланып яшәгән җирләрдә ана телендә мәктәпләр бар иде, хәтта театрлар да эшли иде. (Бу культура учакларын санап тормыйм — алар күпләргә билгеле).

Сталин хакимлеге урнашкач, татар халкы милләт буларак таркала башлады, бәйләнешләр өзелде, бердәмлек бетте. Соңгы 30 ел дәвамында бу таркалу процессы аеруча көчәйде. Хәзер инде күп җирләрдә ана телендә укыту бетте, ә газета, китап, театр кебек нәрсәләр турында әйтеп торасы да юк — алар инде сагынып сөйләргә генә калды... Хуш, моның нәтиҗәсе нәрсә соң? Минем күзәтүем буенча, татарларның руслар арасында яшәүчеләре әкренләп руслаша, Казахстанда торучылар — казахлаша, Үзбәкстанда—үзбәкләшә... (Аеруча бу шунда туып үскән яшьләргә кагыла). Шул ук вакытта алар чын руска, казахка яки үзбәккә дә әверелеп җитмиләр кебек. Ата-бабадан килгән җепләр өзелә, нигез таркала. Әнә шун-

дый язмышка дучар безнең халык...

...Сез менә Башкортстанны да телгә алдыгыз. Башкортстан — минем туып үскән җирем, аның хакында сөйләү миңа бер дә җиңел түгел. Башкорт халкына хөрмәтем зур, бервакытта да башкортка карата кимсетү сүзе әйткәнем юк. Бала чактан ук аралашып үскәнгә күрәдер инде, мин татар белән башкортка бертуган халык итеп карый идем. Һәрхәлдә, алар арасында зур аерма күрми идем. Ләкин бу һич тә башкорт халкын үзенә аерым, башка бер халык итеп танымау дигән сүз түгел. Киресенчә, мин башкортны үзенә аерым бер халык дип саныйм, шулай булган ул, шулай яшәп килгән, тик дин берлеге, тел якынлыгы аркасында һәм бер үк җирләрдә яшәгәнгә күрә татар белән башкорт бер-берсенә шактыйнык якынайганнар, аралашып, кәсеп итешеп, кыз бирешеп тә бергә гомер сөргәннәр... Менә шул тугандаш ике халыкның арасына соңгы вакытларда салкын кара күләгә төшүенә мин, әлбәттә, бик борчылам, гаҗәпләнәм, дөресен генә әйткәндә, аңлап та бетермим. Мәсәлән, татар авылларын башкортка әйләндереп язу яки татар мәктәпләренә башкорт телен кертергә тырышу нигә кирәк булды икән? Мин ишеткәнемне әйтәм, әгәр ялгышсам, гафу итсеннәр!..

Башкортстан да күп милләтле республика, ләкин сан ягыннан өч халык күпчелек тәшкил итә. Болар — башкорт, татар, рус... Күптән бергә яшиләр, бергә икмәк үстерәләр, нефть чыгаралар, завод-фабрикаларда эшлиләр... Мәгәр үзләренең милли ихтыяҗларын үтәү ягыннан алар тигез шартларга куелганмы, бер үк мөмкинлек белән файдалана алалармы?.. Мәсәлән, ни өчен туган телне укытуда, китап чыгаруда, театр ачуда, радио-телевидениедән сөйләүдә, әйтик, русларга бирелгән мөмкинлек татарларга да бирелми?.. Мондый чикләү кайдан, кемнән чыга?..

Һәрбер халыкның, саны күпме булуга һәм кайда яшәвенә карамастан, үзен милләт буларак сакларга да, милли ихтыяҗларын үтәүгә дә тулы хакы бар. Бу хакта соңгы вакытларда иң югары партия трибунасыннан кат-кат әйтелде дә инде... Хокуктан тулы файдалану өчен бер генә нәрсә кирәк: һәр эштә, һәр җәһәттән тигезлек!.. Бары бөтен яктан тигезлек кенә милли мөнәсәбәтләрдәге гаделсезлекне, киеренкелекне бетерергә ярдәм итәчәк.

Башкорт һәм татар — ике мөстәкыйль милләт. Берсе яшьрәк, икенчесе картрак, әмма үзләренең хәзерге аң-белем, культура дәрәҗәләре ягыннан тигезләнделәр дип әйтерлек. Шулай булгач, алар арасындагы борыннан ук килгән дуслык-туганлык тагы да ныгый төшәргә тиеш иде. Иманым камил, хәзерге ике арадагы киеренкелек түбәннән, халыкның үз арасыннан чыккан нәрсә түгел, ә каяндыр югарыдан яки бер катлам кешеләр тарафыннан ясалма рәвештә китереп чыгарылган вакытлы бер низаг булса кирәк! Һәм ышанам ки, башкорт дуслар да, татар туганнар да уртак тел табарлар, бөтен чи төеннәрне чишәрләр, татулыкка, һичшиксез, ирешерләр... Ике халыкның да рухи тазалыгы өчен! Үзгәртеп кору шартларында башкача булуы мөмкинме соң?!

— *Яңарыш чорында дөньядагы барлык демократик көчләрнең берләшергә омтылуы күзәтелә. Аларның гомум кешелек максатлары өчен, тынычлык өчен берләшүе бара. Шул җәһәттән безнең партия һәм хөкүмәт җитәкчеләребезнең дә дингә карашлары мәгълүм. Ә Сез, язучы кеше, бу турыда нәрсә уйлыйсыз?*

— Диннең әхлак кагыйдәләре аллага ышану белән бәйләнгән. Ә ышану бер үк вакытта аллага сыену һәм алладан курку да ул... Һәр дин алланың барлыгын үзенчә аңлаткан һәм алла исеменнән үзенең гамәли (шәригать) кануннарын да төзегән.

Менә ислам дине дә шундыйларның берсе. Аның да ниндидер гамәлләрне үтәүне таләп иткән, ниндидер эшләрдән катгый рәвештә тыйган үз кануннары бар. Фарыз гамәл һәм хәрам эш, савап һәм гөнаһ дигән төшенчәләр дә әнә шул кануннар белән бәйләнгән.

Татар халкының ислам динен кабул итүенә дә 1 000 елдан артып китте. Шушы озын дәвер эчендә шәригать кушкан яки тыйган гамәлләрнең күбесе, әхлак кагыйдәсе буларак, халыкның гореф-гадәтенә дә кереп калган. Мәсәлән, дин мөселман кешесенә хәмер эчүне тыйган, һәм халык авылда аракы саттырмаган. Яки татар халкы пакьлекчисталыкка өйрәнгән — моны да шәригать таләбенең бер нәтиҗәсе диярга була. Шулай ук шәригать талау, урлау, алдау, яла ягу кебек начар эшләрдән тыйган; кешеләргә карата шәфкатьле булырга, җан ияләрен кызганырга өндәгән... Һәм халык та яхшысын үтәргә, начарыннан тыелып яшәргә тырышкан. Шуның белән бергә ул дин аркасында милләт буларак бөтенлеген дә саклаган.

...Инде менә җитмеш ел без алласыз һәм динсез яшибез. Мәктәптән үк безгә алла юк, дин зарарлы дип тукыдылар һәм без шуңа ничектер бик ансат кына ышандык та. Бу да бит үзенә күрә бер азатлык иде. Әмма бу «азатлык» бер ише бәндәләрне бөтенләй бәйдән ычкындырды. Утызынчы елларның башларында бөтен җирдә диярлек мәчетләрне яптылар, күбесенең манараларын кисеп яки ишеп төшерделәр, эчендәге

китапларын чыгарып яндырдылар, ә муллаларын читкә сөрделәр. Кемнәр эше бу?. Һәрхәлдә, халык эше түгел, халык якын да бармады. Шулай ук чын укымышлы кешеләрнең дә монда һич катнашы юк. Асылда бер төркем кара надан, фанатик вәхшиләр эше иде. Ихтимал, шулар нәтиҗәсендәдер, бездә атеизм өндәүләре халыкка юньләп тәэсир итә алмады, иске әхлак кагыйдәләрен яңа бер чыны-яхшырагы белән алыштыра алмады. Аның каравы, диннең моңарчы төрле бозыклыклардан, ярамаган эшләрдән тыеп килүе бетте диярлек. (Моның мисалларын китереп тору кирәк микән — бик мәгълүм нәрсәләр). Ләкин шул ук вакытта халыкның күпмедер өлешендә «алла» дигән бер кодрәт иясенә ышану һаман да әле сүнеп бетмәгән — киресенчә, соңгы елларда бу ышануның көчәюе ачык сизелеп тора. Диннән бөтенләй надан, «аллаһе әкбәр» дип бит сыйпаудан башканы белмәгән хәзерге кешеләрнең күбесе шәригать кушканны ничек булса да үтәргә тырыша. Шул рәвешчә кеше, изге бурычымны үтәдем дип, үзенә җиңеллек таба, күңелен тынычландыра. Моны мин табигый бер хәл дип карыйм, чөнки кеше дигәнең элек-электән үк үзенең авыр, мәшәкатьле һәм гөнаһлы тормышында һәрвакыт нәрсәдәндер юаныч табарга, күңелен нәрсә беләндер тынычландырырга мохтаҗ булып килгән. Аллага ышануның бүгенге көндә дә кешеләрдә саклануы, хәтта көчәюе бәлки нәк шул табигый ихтыяҗдан килеп чыга да торгандыр... Башкасы юк бит, табылмады... «Совет кешесенең мораль кодексы» дигән нәрсә булды, ләкин гамәлдә ул кодексны адым саен боздылар — шуннан соң халыкка нәрсә кала — йә сыналган искегә кайту, йә бер нинди «кодекссыз» яшәү?! Хәер, бу философлар темасы, алар баш ватсыннар.

Минем бары, бүгенге үзгәртеп кору таләпләреннән чыгып, дингә һәм дин тотучыларга мөнәсәбәт турында гына кыскача әйтеп үтәсем килә. Без аллага ышануны һәм дин тотуны кешенең вөҗдан эше дибез. Шулай икән, кешегә вөҗданы кушканны эшләргә тулы ирек һәм мөмкинлек бирелергә тиештер инде... Хәлбуки, дин тоту формаль рәвештә конституция белән рөхсәт ителгән булса да, җирле власть органнары соңгы елларга кадәр дингә ничек тә аяк чалырга тырышып килделәр. Әгәр бу тенденция киләчәктә дә сакланса, бездә чын демократия була алмаячак һәм кешенең гражданлык хокукы да тулысынча сакланмаячак. Динлегә дә, динсезгә дә мөнәсәбәт һәр җәһәттән бер төсле булырга тиеш. Аларның берсен (динлесен) түбән санап, икенчесен өстен куюы дөрес булмаячак. Гражданнар буларак алар тигез хокуклы, ә аллага ышану наданлыктан гына булмаган шикелле, аллага ышанмау да бары тик укымышлы булудан гына килгән нәрсә түгел. Берәүнең аллага ышануы һәм дин тотуы, икенчесенең исә алланы танымавы һәм дин тотмавы демократик җәмгыятьтә табигый хәл булып саналырга тиешле.

Инде әхлак мәсьәләсенә килгәндә, таләп һәммәсенә дә бер: яхшылыкка омтылу, начарлыктан тыелу, миһербанлыкка өндәү, кансызлыкка каршы тору — рухи тазаруга мохтаҗ җәмгыятьтә һәркемнең намус бурычы ул!..

...Югарыда мин хәзерге халыкның дин мәсьәләсендә бик надан булуын әйткән идем. Һәм гаҗәп тә түгел — берәүнең дә бит дин сабагы алганы юк. Менә шушы гомуми наданлыктан файдаланып, мәчет тирәсендә кулдан язылган ниндидер догалыклар сатучы яки чакырган җиргә барып «Коръән укырга» әзер торучы, үзе дә үтә надан кешеләр йөри дип ишеткәнем бар... Әгәр дә дин тоту, шәригать гамәлләрен үтәү җитди эштән санала икән, аның чын укымышлы, мәдәниятле, халык җанлы әһелләре дә булырга тиештер инде. Кем кайгыртырга тиеш моны — мин әйтә алмыйм, әмма халыкның рухиятен һәр төрле чүп-чарлардан сакларга кирәктер дип уйлыйм. Фәндә дә, диндә дә, гомумән һәрбер эштә ялган, яраклашу, фальсификация булмаска тиеш дип беләм.

**Күп санлы укучыларыбыз һәм язучылар җәмәгатьчелеге исеменнән әдипне юбилее белән котлыйбыз, аңа нык сәламәтлек, яңа иҗат уңышлары телибез.**

# ЧОРЛАР ЧАТЫНДА

Татар поэзиясендә үзенчәлекле иҗаты белән ачык танылып торган шагыйрьләрнең берсе — Әнвәр Мортаза улы Давыдов. Ул 1919 елның 21 мартында Куйбышев өлкәсенең Камышлы авылында туа. Дүрт-биш яшьтән ул язу таный, китаплар укый ала. Унике яшьлек чагында Камышлы район газетасында беренче шигырьләре басылып чыга. Бәлки, туган якларындагы таулар борынына терәлеп үткән Сок суы, йә Сок ярында кайнап үскән бөдрә таллар, йә кинәт иркен җәелеп каядыр — еракларга үрелгән болыннар Әнвәр дигән малай күңелен үзләренә иярткәннәрдер һәм аны шигъри күңелле, моңлы иткәннәрдер. Тик тормыш юлы әдәбиятка таба гел туры гына бара алмый шул.

Әнвәр Давыдов тиздән язуын һәм Камышлы авыл хуҗалыгы техникумында укуын бүлеп, эшләргә — өйләренә ярдәм күрсәтергә мәҗбүр була. Аннан ул Новосибирск шәһәрендә «Советская Сибирь» газетасында, Үзбәкстанга барып, башта рус, соңрак үзбәк газетасында хезмәт күрсәтә. 1939—1940 елларда Мордва АССРның Ләмбрә районында рус теле һәм тарих фәннәре укыта, шуннан хәрби хезмәткә алына. Бөек Ватан сугышының башыннан ахырына хәтле ул катлаулы көрәш юлы уза. 1946 елда туган авылы Камышлыга кайтып, андагы район газетасының редакторы булып эшли. Шул ук вакытта иҗат эшен көчәйтеп җибәрә, шигырьләр, поэмалар яза. 1950 елда «Беренче бөртек» исемле беренче китабы чыга.

Чагыштырмача кыска булган иҗат гомерендә (шагыйрь 1968 елның 23 июнендә Казанда вафат була) аның татар һәм рус телләрендә егерме китабы басылган. Тик шулай да аның иң тулы һәм иң бай эчтәлекле китаплары үзеннән соң дөнья күрделәр. Менә аларның кайберләре.

**Дәверләр диалогы** — шигырьләр һәм поэмалар тупланган китап, 1969 елда чыкты.

**Йокысыз төннән соң** — роман-симфония, 1972 елда чыкты.

**Түгәрәк бәхет** — проза әсәрләре, 1984 елда чыкты.

**Кояшлы көн хакына** — шигырьләр һәм поэмалар, 1979 елда чыкты.

Шагыйрьнең «Дәверләр диалогы» дигән китабына өлкән шагыйребез Сибгат Хәким кереш сүз язган иде. Аның кереш сүзе шундый сүзләр белән башлана:

«Бездә, Казан артында, зәвык белән, җыйнак, пөхтә итеп киенгән кешене спай кеше диләр.

Әнвәр Давыдовның күзләре яшькелт, өстенә ятып торган костюмы да, галстугы да шул төстән чыгып сайланган. Шулай киенергә ярата иде ул. Мин аны һәрвакыт каядыр сөялеп, уйга бирелгән хәлдә күз алдына китерәм. Себер трактында, юллар чатында... Яңа район, аның кешеләре турында соңыннан «Себер тракты» шигырьләре мәйданга килде. Сугыш елларында Смоленск тирәсендә пилоткадан, кояшта агара төшкән гимнастеркадан юл кырыенда басып торгандыр. Чөнки аның биографиясе мондагы авыр сугышлар белән бик нык бәйләнгән...» Әйе, тормышның чиксез күп мәшәкатьләрен кичергән, шул сәбәптән иртәрәк тә чирләргә өлгергән Әнвәр Давыдов хәтта авыр хәлен безгә сиздерми, һәрвакыт шат күренә, югары зәвык белән киенә; атлау, кул селтәве белән дә янәшәсендә барган кешеләрдән аерылып тора иде. Бу аның үзен культуралы тотышыннан, аңа гына хас хәрәкәт алымнары һәм интеллигентлыгыннан килгәндер. Ул шигърияттә дә шулай, каләмдәшләреннән үзгә. Давыдовча үзенчәлекле булып танылды. Аның «Ташу», «Чорлар чатында», «Күмер көйри» кебек поэмалары, «Йокысыз төннән соң» исемле роман-симфониясе һәм күпләгән шигырьләре моңа ныклы дәлил була ала.

Ә. Давыдов асылы белән табигать баласы, нечкә лирик шагыйрь иде:

*Кояш батты. Апрель башындагы*
*салкынчалык төште урамга.*
*Суык миллион көмеш энә белән*

*тиресләрне типчи юлларга.*
*Аяк асты хәзер саркыды инде*
*һәм кыштырдап тора туң белән.*
*Юашланып калган гөрләвекләр*
*чылтырыйлар кичке моң белән.*

Тик шагыйрь бу өлкәдә иркенләп эшләргә өлгермәде. Башта аның лирик омтылышларын сугыш бүлде, аннан соң сугыш какшаткан илне, хуҗалыкны аякка бастыру еллары аны публицистикага этәрделәр. Аннан соң да халыкның көндәлек мәшәкатьләре, туып торган яңа эшләр кимемәде. Шагыйрь аларга да публицистик тавышы белән кушылуны кирәк санагандыр, чөнки ул тормышта һәр көн, һәр сәгать, һәр минут актив көрәшче иде. Иҗатта да шулай туктаусыз эзләнде, фәлсәфи тирәнлеккә, форма төрлелегенә омтылды. Бу юлда аның югалтулары да булды, әмма лирика публицистика һәм фәлсәфи поэзия драматизмын бергә оста үреп бирә белүе — аның шигърияттә табышы. Шушы хакта уйланганда беренче булып минем хәтергә «Чорлар чатында» поэмасы килде. Күптән язылган бер мәкаләмдә укучы игътибарын мин шул поэманың кечкенә бер өлешенә юнәлтергә уйлаган идем:

*Әнә өскә үрелә гигантлар:*
*озын куллы тимер краннар,*
*кирпеч-кирпеч салып, кемнәргәдер*
*рәхәт җылы тормыш коралар.*

. . . . . . . . . . . . . . .

*Каядыр яз,*
*гөлләр җилдә уйный,*
*ә аларны*
*сагалыйлар салкын кыраулар.*
*Ләкин яз җиңелми.*
*Язга алмашка җәй килмичә булмый.*
*Болыннарда, бакчаларда*
*кешеләргә шатлык көенә чыңлый*
*зәңгәр, ал кыңгыраулар.*

Бирелә озын куллы тимер краннарны җырлаган публицистик тавыш яшәү һәм үлем фәлсәфәсенә күчте һәм зәңгәр, ал кыңгыраулар чыңына — лирикага әйләнде. Бу Ә. Давыдов поэзиясенә бик хас күренеш, әле публицистик ялкын, әле фәлсәфи уй көчәя, йә, алда әйткәнчә, алар бергә үрелә һәм нәтиҗәдә — шагыйрь укучы күңеленә рух күтәренкелеге бирә. Бу катлаулы тормышта кешенең рухын сынау ихтималы бик күп шул, аны сындырмау, аны күтәрү, аны яшәтү — җиңел генә түгел. Ә. Давыдов менә шушы җиңел булмаган изге эшкә алынган язучы.

Аның иҗатында күп кенә ирекле шигырь үрнәкләре дә булды. Берәүләр ирекле форманы кабул итте, икенчеләр кабул итмәде, тик ни генә булмасын, ул форма шул чордагы татар поэзиясенең колачын киңәйтүгә, фикерен тирәнәйтүгә уңай тәэсир ясады. Бигрәк тә яшь язучылар ул чакта Ә. Давыдов янына җыелдылар, аңардан өйрәнделәр, әдәби мәйданда адымнарын ныгыттылар. Тәҗрибәле шагыйрь аларны аңлый да белде, аклый да белде: җыелышларда, газета-журнал битләрендә җылы сүзен әйтеп яшьләрне шигъриятнең югарырак биеклекләренә озатты... Әдәбиятыбыз мәнфәгатен шәхси тормышларыннан өстен куеп яши алган язучыларыбыз соңгы елларда сизелерлек азайды. Арабыздан киткәннәре бик тә сагындыра.

Журнал укучыларга бу санда Әнвәр Давыдов архивыннан берничә шигырь тәкъдим итәбез. Алар арасында ирекле шигырь дә, төзек калыпта эшләнгәннәре дә бар— кыскасы, алар шагыйрьнең иҗат юнәлешен күзалларга мөмкинлек бирәләр. Рус шагыйре Ярослав Смеляковка атап язган шигыренә ул хат та өстәгән һәм аларны аңа җибәргән. Бу төгәл билгеле. Каршы җавап алганмы, юкмы? Шуны гына ачыклап булмады.

*Әнвәр Давыдовның якташы,*
*иҗатта аның шәкерте*
**Рөстәм МИНГАЛИМ.**

# Әнвәр Давыдов

## Буран

Мин кайчандыр бураннарны
Бик ярата идем.
Янган йөрәгемне
Буран җиленә каршы тота идем,
Сүрелсен дип.
...Тик ул сүрелмәде.
Аның януына
Тәнемдәге сызлау кушылды.

...Хәзер,
Буран кузгалдымы,
Сыкрау тулы җанны,
Йөрәкне
Буран кочагына чыгарып
Ыргытасым килә.
Һәм әйтәсе килә сөенеп:
— Мә, ал! Ал, буран,
кайчандыр
бик ярата идем сине.

*1963.*

## Тәкърлек өе

Күптән
шулай бер төндә
тәрәзләр каршыннан үткәндә,
сөйләдең миңа:
— Монда фәлән тора иде,— дидең.
...Дәвам иттең тәрәзгә күзең юнәлтеп:
— Булып чыкты бит ул халык дошманы!
Кулга алган чакта —
үзем пүнәтәй,
үзем обыскать итештем аны.
Белсәң иде,
шкаф тулы китап,—
һәр бит саен чыга червонец.
Менә ничек безне алдап
йөргән бит ул,
чын сволочь!
Сүзләреңә ул чакта ышанмадым.
Алар —
чиркандыргыч,
лайлалы
хәшәрәтләр кебек,
салкын чымырдау гына
калдырып тәндә,
шуып төштеләр
караңгы төнгә.

Шулай булган иде.
Һәм син бүген,
авызың читләренә чыгарып селәгәй күбеген,
шул ук кеше хакында
җыелышта болай дидең:
— Менә фәлән.
Гаҗәп кеше иде,
үйлый иде гел халыкны, илне.

Үзе утка кереп
коткарыр иде сине.
Юкка харап итте аны дошманнар!

. . . . . . . . . . . . . . . . . . .

Ышанам,
хәзер с ү з е ң ә ышанам.
Ләкин ышанмыйм үзеңә.
Салкын лайлалы хәшәрәт кебек,
тәкәрлек өенә кереп
яшеренгән синең асылың.
Яшеренгән шундый оста.

Сытасы иде, басып
бу тәкәрлек өен.
Әмма безнең
аяклар чиста.

*1960—64*

## Тарихка карата

Тикшермәдем, мин тарихчы түгел.
Минем ата-бабам йөреткән
Татар исеме ялгыш исем диләр,
Без болгарлар, диләр, электән.
Ләкин тарих битләреннән миңа
Күптән карап килгән усал күз
Үзеннән һич мине ычкындырмый,
Күпмый миннән татар дигән сүз.
Шуңа күрә кат-кат кайтам инде,
Татар, синең үткән юлыңа.
Артык исем китми чыңгызларның
Алтын кылыч тоткан кулына.
Мин теләмим яулар юлындагы
Тузаннарның күзем каплавын;
Бик күрәсем килә шул яудагы
Ябай бер кешенең атлавын.
Ул булгандыр, бәлки, кысык күзле,
Ямьсез йөзле, чандыр яңаклы...
Монгол, татар, үзбәк — башкагамы,
Тик бу чорда барыбер кемгәдер ул —
Бабай булу өчен яраклы.
Походларда кипкән какча күкрәк
Тере йөрәк утын саклаган.
Ирке юкка ачы әрнү белән
Атлаган ул, һаман атлаган.
Европаң да аңа кирәк түгел,
Кирәк түгел урыс капкасы,
Туган даласына сыенасы да,
Җиргә нәсел ясап ятасы.
Ятасы да юкса, булмаган шул.
...Күз теккән ул безнең көннәргә,
Океанда батып баручыдай —
Хыялында кораб күргәндер...
Шул кешеме «явыз татар» булган?..
Минем анда нинди эшем бар?
Аннан ерагырак торыйм, дисәм,
Минем болгар дигән исемем бар.
Әмма никтер, минем әле никтер
Эшем бар күк шушы татарда.
Күңел бармый чыңгыз-батыйлардан
Пычрак алып аңа атарга.

Татар, татар, син бүген дә юлда,
Көчең әле тора бөркелеп.
Тик исемеңне ерак гасырлардан
Өстерисең авыр гер кебек.
Варислыкка хакың юктыр синең,
Ни алдың син Чыңгыз-Мамайдан?..
...Әйе, алар
Европага таба
Тәкәббрана адым атлаганда
Рөхсәт сорамаган әнә теге
Кызыл галстуклы малайдан.

Малай бүген тарих битләреннән
Әрнеп укый: «Явыз татар», дип.
Ә этисе ерак Днепрда
СССРны саклап һәлак булган,—
Икесе дә алар «татар!» бит.
Мин дә татар,
Мин качмаска булдым
Тарих ябыштырган атымнан...
Бу исемнән күз алдына килә
Зур юл үткән йөнтәс атында —
Авыр малахаен төзәткәләп,
Күзен төбәп ерак офыкка,
Тузан аша үз язмышын күзләп
Тетрәнүче ябай, ертык карт...
Һәм мин аны нәләтләргә тиеш,
Авыр исемем — аның мирасы...
Үткәннәрнең калын тавын ярып,
Ах,
Бүгенгенең бөек яктысыннан
Тик бер кәррә аңа бирәсе!

# Ярослав Смеляковка

*Рус белән тормыш кичердек сайрашып,*
*тел, лөгать, гадәт вә әхлак алмашып...*

Г. Тукай

*Вы, прадеды наши, в недоле,*
*мукою запудривши лик,*
*на мельнице русской смололи*
*заезжий татарский язык.*

Я. Смеляков

(«Русский язык» шигыре буенча)

Сөендереп безне, өскә үрелә
Шәһәрләре Ватан-Рәсәйнең,—
«Мать-Россия»ның дим, йә «әнкәйнең»;
Башкортчалап әйтсәк — «әсәйнең».

Халык белән тулы урамнары,
Нинди телләр монда яңгырамый,—
Һәр агымга монда иркен үзән,
Һәм артыгын беркем дауламый...

Без бер кырдан чөнки,— бер үк сука
Тоткасыннан кулда сөялләр.
Аз булганмы безнең уртак атлар?!
Булмаганмы уртак иярләр?!

Кем онытыр соңгы походларны,
Без сугышкан Волхов урманын?
Кем онытыр Брест, Сталинградта
Иңгә-иң басып торганын?

Мин шуларны уйлыйм, каләм тотсам,
Мин аларны саф-саф күрәмен.
Сезгәме соң моны аңламаска,
Аңлаучыга Байрон йөрәген.

Бабаларыгыз, имеш, минем телне
«Он иткән» үз тегермәнендә.
Рәнжемәсме Пушкин, намусына
Һич саксыз тел тидергәненә?!

Ул фин, тунгус, калмык куанырлык
Энҗеләрен тезгән чагында
Кемнедер «он итү» исәбенә
Сый куймаган уртак табынга.

Сез әйткәнчәмени телен шулай
Әвәләгән бөек рус халкы,—
Бер телдән бер батман он тарттырган,
Икенчедән — чүпрә бер тамчы!?[1]

Минем хөрмәт, караш башка төрле
Рус халкының моңлы теленә.
Яхшы аңлыйм, яратам ул телне,
Бик яратам әнкәм телен дә.

Мең ел элек әнкәм-әткәм теле
Яңгыраган Идел буенда.
Ул гөрләгән, йә ул челтерәгән,
Ялтыраган Идел суында...

Һәм барган ул олы диңгезләргә,
Чишмә булып, саклап асылын.
Ерып чыккан патша Рәчәендә
Тарлавыгын ничә гасырның.

Бөек Пушкин, бөек Лермонтовтан
Нур игътибас иткән Тукайның
Моңнарына кушылып, ярты Шәрык
Көйләгән бит үзенең сорнаен.

Саклык белән алып үз иңенә
Яңгырашын бөек теленнең,
Безнең тел дә күрше халыкларга
Ирештергән сүзен Ленинның.

Сөякләребезне Дахау миче
Көл иткәндә — калды, тере ул!
Җәлил җырын җиргә яңгыратты —
Син «он иткән» минем телем ул!

Кичерегез, үзегез дә менә
Гади генә минем тел белән
Тезгән шигыремә төшендегез,
Карап хәтта җансыз өлгедән.

«Тел!» — ишетсәң, нинди мөлаем ул;
«Язык!» — тора шундый зыңгылдап.
Телләр алар бик киң күңелледәр,
Берсен-берсе ала тик зурлап.

Юкса — «Владыки и те исчезали
Мгновенно и наверняка,
Когда невзначай посягали
На самую суть языка»[2].

*1967.*

---

[1] Вы взяли немецкого малость,
Хотя бы и больше могли,
Чтоб им не одним доставалась
Ученая важность земли.

Я. Смеляков. «Русский язык»

[2] Я. Смеляковның шул ук шигыреннән.

*Хөрмәтле Ярослав Васильевич!*

*Сәлам Сезгә Казаннан, үземнән, бөтен гаиләмнән. Татьяна Валерьевнага да безнең кайнар сәламне һәм хөрмәтебезне тапшырыгыз.*

*Күптән Сезне күргәнем юк. Журнал һәм газета битләреннән фотоларыгызны карыйм, моңланып куям. Сезнең белән очрашканнан соң озак вакытлар узып өлгергән, узган вакыт эзе бездә калган. Мине күрсәгез, Сез аптырап куяр идегез, бу елларда тышкы кыяфәтем белән мин нык бирештем. Ярый, бу тышкы үзгәреш кенә. Бигрәк тә Сездә фәкать тышкы гына үзгәреш булу ачык күренә. Сез соңгы елларда яшьләрчә дәрт белән күп һәм әйбәт яздыгыз. Рус шигыре кабатланмас аһәң белән Сезнең каләм очында яңгырап торды. Поэтик куәтегез хакында әле тагын күпләгән яхшы сүзләр яза алыр идем, тик бу берәүгә начар сүз әйтер алдыннан юри генә әйткән юату булып аңлашылыр дип шикләнәм. Чыннан да, бүген мин Сезгә «начар» сүз әйтергә телим.*

*Сүзем Сезнең «Рус теле» дигән шигырегез турында. Ул шигырь — телнең ныклыгын, яшәүчәнлеген, аның халык язмышында уйнаган ролен һәм башка якларын ачу ягыннан гаҗәп тирән язылган. Тик рус теленең формалашуын, аның башка телләр белән мөнәсәбәтен аңлатканда Сез «искәртмәстән» күңел рәнҗетерлек мәгънәсезлекләр дә җибәргәнсез. Яшермим, шигырегезне беренче кат укыганда минем телемне мыскыл итүегез өчен генә күңелем рәнҗеде, ә кат-кат укыгач, бөек рус теле өчен, Сезнең шәхси поэтик телегез өчен дә күңелгә бик кыен булды. Нинди дә булса бер телне он итү хисабына барлыкка килгән, йә шул хисапка гына баеган тел тарихта юк, рус һәм татар телләре мөнәсәбәтенә бу бигрәк тә кагыла. Истә тотыгыз: татар теле — басып алучы монголлар теле түгел. Сезгә, татар әдәбияты һәм сәнгате декадасын оештыручыларның берсенә, безнең моннан мең ел элек туган әдәби мирасыбыз барлыгы, аның безгә монголлар килгәнче булган чорда туганлыгы һәм татар телендә язылганлыгы билгеле булырга тиеш. Ул телне басып алучы монголлар да, Грозный басымы да он итә алмады. Ул тел һаман үсте, баеды, башка халыкларга да уңай тәэсир ясады. Халык көчләүләргә дучар булган саен, үз теленә сакчыллык-кайгыртучанлык белән карый. Моңа мисалны монгол басып алулары чорыннан алып күпләп китерергә була. Грозный һәм аның тарафдарлары татарларны көчләп чукындырган чордан да моңа бик ачык мисаллар бар, кайсыдыр вакытта күпчелек татар әдәбиятчылары төрек, фарсы телләре йогынтысына бирелсәләр дә, чукындырылган татар арасыннан чыккан язучылар (мәсәлән, Яков Емельянов) иҗатта чиста татар телен саклаганнар. Археологларның һәм тарихчыларның соңгы еллардагы тикшеренүләре катгый раславынча, татар теле, телнең әдәби формалары беркайчан да аны он итәргә теләүчеләргә бирешмәгән. Рус теле һәм әдәбиятының татар теленә, татар әдәбияты формаларына тәэсире булу — бәхәссез. Телләр үсешенә марксистик караш турында уйларга да өлгермәгән яшь Тукай тел һәм халык мөнәсәбәтләре турында төгәлрәк әйткән:*

> *Рус белән тормыш кичердек сайрашып,*
> *тел, лөгать, гадәт вә әхлак алмашып.*

*Әлбәттә, поэтик җанландыру аша әйткән фикеремне кичерәйтеп, гадиләштереп күргәнсез дип, Сез миңа каршы килә аласыз. Әмма укучы — ни язылган, шуны һәм нәкъ шулай кабул итә. Сез бит фикерне ике төрле кабул итәргә мөмкинлек калдырмый идегез, башкаларга да киңәшегез шушы иде.*

*Немецчадан акыллылык алды дигән фикерегез дә күңелдә рус теле өчен борчылу тудыра. Рус телен бик яраткан хәлдә, рус язучылары, рус шагыйрьләреннән үрнәк алу мөһимлеген аңлаган дусларым белән бергә булган хәлдә дә мин телем башка телләрдән чеметемләп акыл сорады дип әйтә алмыйм. Тел ул үзенә җитәрлек дәрәҗәдә акыллы булса, башка телләр белән аралашып, дөньядагы фикер, фән, сәнгать үскән дәрәҗәдә байый бара. Телләр арасындагы мондый аралашуда, аларның һичберсе ягыннан да, Сезнең шигырьнең ике строфасында сизелгән агрессивлык булмый.*

*Ә телләр үзенең асылына кул сузганны кабул итә алмавы турындагы строфагызны мин гомерем ахырына хәтле кабатларга әзер.*

*Сезгә тәкъдим иткән шигыремдә мин үз уемны яздым. Дөрес аңларсыз дип уйлыйм. Кайчан да булса тагын бер-ике кечкенә шигыремне тәрҗемә итүегезне сорасам, әгәр Сезнең вакыт булса, каршы килмәссез.*

*Җавап язсагыз, шатланырмын. Әгәр Сезне күрергә, сөйләшергә, Сезнең белән киңәшләшергә туры килсә, миңа тагын да зур шатлык булыр иде.*

*Сәлам һәм ихтирам белән*
**Әнвәр ДАВЫДОВ.**

ПУБЛИЦИСТИКА

## Фәйзи Галиев

# АВЫЛЫМ ГАДӘТЛӘРЕ

*Күп еллардан бирле, ягъни кырык ел буена, үземнең туган-үскән Түбән Шашы авылында колхоз председателе булып эшләгәнлектән, авыл халкы тормышындагы зур үзгәрешләр минем күз алдымда барды. Авылның культурасы үсте, караңгылыкта яшәгән крестьян өенә радио, телевизор, телефон кертелде, газдан файдалану мөмкинлеге туды. Эш кораллары камилләште. Соңгы елларда транспорт шартлары яхшыру авыл халкының юл йөрүен дә арттырды. Бәйрәмнәр күбәйде, төрле һөнәр кешеләренең аерым бәйрәмнәре гамәлгә кертелде. Авылга медицина килде, сәүдә эше яхшырды.*

*Санап киткән шушы хәлләр кешеләрнең мәңгелек гореф-гадәтләренә йогынты ясамый калмый. Яңа гадәтләрнең уңай якка барганнары белән беррәттән, тискәре якка тартучылары да юк түгел.*

*Яңа гадәтләргә карата җитәкчеләр аерата сизгер булырга тиешлеген әйтәсем килә. Чөнки кешеләрнең әйбәт гадәтләре, аларның хезмәткә мөнәсәбәтенә дә йогынты ясамый калмый. Эшне акча табу чыганагы итеп кенә карамаска, аннан ләззәт табып, аннан башка яшәү мөмкин түгел, дигән фикер тәрбияләргә кирәк.*

*Минем «Икмәк язмышы» дигән язмаларым «Казан утлары»нда басылып чыккач, кайбер укучылар миңа хатлар салды. Әлеге язмалар, билгеле бер дәрәҗәдә, шул хатларга җавап та булыр дигән өмет белән калам.*

### Үткән көннәр

Безнең Түбән Шашы авылы революциягә кадәр «капчыклы» Шашы дип аталган, чөнки авылдан-авылга хәер сорашып йөрүчеләр күп булган. Хәтта башка авылдан хәер сорашучылар да: «Без яндык, Түбән Шашыныкы без»,— дип әйтә торган булганнар. Кайвакыт безнең авыл кешеләре, хәер сорашкан чагында, үз авылларын әйтми торган булганнар. Котдус абый Күәм авылына кунакка барган, кунак булган йортка безнең авылның Мөхәммәди Барие хәер сорап килеп кергән. Аңа бер сынык ипи биргәндә йорт хуҗасы: «Син, энем, кайсы авылныкы?» — дип сораган. Егет бөтенләй башка авылны әйткән. «Әй, уңай булып калды»,— дип сөйли торган иде Котдус абый. Соңыннан бер колхозга тупланган Күнгәр, Югары Шашы, Күшәр, Мөндеш, Мокшы, Ташчишмә авыллары да шундый ук авыр шартларда яшәгән. Тимер юлдан, урманнан ерак урнашканлыктан, тормыш итү аеруча кыен булган. Җире күбрәк авыллар җирләрен, болыннарын сатып, көннәрен авыштырып барганнар. Вятка губернасына чыгып, рус авылларында көтү көтеп тә йөргәннәр. Безнең авылның Ширияздaнов Нурияздан абый, малай вакытта ук, бездән ерактагы рус авылында көтү көткәнен бик әрнеп, уфтанып сөйли торган иде. Җирләре аз кешеләр ачлы-туклы гомер иткән. Әнә шундый шартларда яшәгән авылларыбыз. Октябрь революциясе өчен, кулларына корал тотып сугышканнар. Габдрахманов Шәрип, Галиев Әхмәтхан, Мөхәммәтҗанов Хафизлар озак еллар гражданнар сугышында булуларын, Казанда элекке генерал-губернатор Сандецкий йортында Татарстан хөкүмәте бинасын саклаула-

---

Фәйзи ГАЛИЕВ — *Арча районының «Искра» колхозы председателе, РСФСРның атказанган агрономы. «Икмәк язмышы» исемле китап авторы. Язманы әдәби эшкәртүче — Гариф Ахунов.*

рын, Урта Азиядә басмачылар белән көрәшуләрен сөйлиләр иде. Авыл Советының беренче председателе Мөхәммәтҗанов Хафиз, секретаре Галиев Әхмәтхан була. Безнең авыллар Кышлау волостена кергән. Волость конторы — Югары Шашы авылында. Кулак куштаннары шушы волостька Совет власте урнаштыру өчен җибәрелгән бертуган Хәкимовларны (Кышлау авылы кешеләре) терелей җиргә күмеп үтерәләр. Башта бик каты кыйныйлар, берсе чыгып качкан була, аның артыннан авылның иң оста йөгерешчесен җибәреп, тотып алып кайтып, абыйсы янына кабергә салалар. Авылларыбыз тарихында әнә шундый кара көннәр дә бар.

Беренче колхоз 16 кешедән төзелә, ул тарала, яңабаштан төзелә. Безнең авылда колхозга кермәгән бер кеше 1937 елга кадәр яшәде, ул Гыйльфанов Әхмәтгали атлы кеше иде. Үзенең тормышы да фәкыйрь иде. Ниндидер бер тискәрелеге аркасында колхозга ышанмыйча озак йөрде. Соңыннан хатыны Хәдичә апай, балаларым белән мин колхозга керәм, дип, гариза бирде.

Авылыбыз халкы күмәк тормышта 1930 елның языннан бирле яши. Иң элек атларны берләштерделәр. Аларны лапаслары зуррак булган кешеләргә — Шәрифҗан абый, Бәдри абый, Мөхәммәтгали абый, Мәрдән Кәриме, Шагали абыйларның лапасларына җыеп авылыбызның мал-туар яраткан кешеләрен ат караучы итеп куйдылар. Бу вакытта без, малайлар, җыйналган атларны карап йөрергә ярата идек. Соңыннан эш коралларын, амбарларны да берләштерделәр. Авыл халкы бу үзгәрешләрне шактый ук авырдан кичерде. Кешеләр әүмә-сәүмә фикер белән яшәделәр. Авылда күмәкләшү вакытында тимерчелектә рус кешесе эшли иде. Аңа ярдәмгә чүкеч сугучы итеп яшьләрне куйдылар. Бераздан Гвоздев Иван Иванович безнең авылдан китте. Авылыбыз халкының беренче тимерчесе булып Шагалиев Муллагали һәм Һадиев Барилар эшли башлады. Күмәк тормыш авыл халкына бергә эшләү гадәтләрен алып килде. Бу баштарак сәер тоелса да, соңга таба бик ямьле эшкә әйләнеп китте. Сәләтенә карап аерым төркемнәр, звенолар оешты. Звено белән звено арасында социалистик ярыш барлыкка килде. Әле дә хәтеремдә: кызылга буялган тактада иң өстә самолет рәсеме, аннан астарак автомашина, аннан астарак трактор, аннан астарак ат, аннан аста җәяүле кеше, аннан да аста ташбака сурәте төшерелгән иде. Иң яхшы эшләгән звено яки бригада самолет турысына языла, иң начары ташбакага атланып бара. Шуның өстенә яхшы эшләгән звено янына урак урганда кызыл флаг, начар эшләгән звенога чыпта флаг кадап куялар. Ә уңыш бүлгәндә, яхшы эшләгән кешегә уңышны дугаларына флаг кадаган кызыл олаулар белән, гармуннар уйнап, өләшәләр. Ә без, малайлар, шундый олауларга тагылып йөри идек. Заһидулла, Мөхәммәтгали абыйларга олавы-олавы белән капчык керттеләр. Ә Мәрдән Кәриме дигән кешегә Фаяз аты дип аталган бәләкәй чатан атка курчак капчыклар салып, авылның бер кәтәнә кешесе Усман абый кертеп бирде. Ахырдан сүзе күп булды: зурлап китергән ашлыкны алучылар, олаучыларны чәй эчәргә дә чакырмаган булып чыкты, ә Кәрим абый Усман абыйны чакырып, чәй эчертеп, сыйлап чыгарган.

Авылда яңа бәйрәмнәр барлыкка килә башлады. 8 март, 1 Май, Октябрь бәйрәмнәре. Бу бәйрәмнәрдә халык клубка җыелып доклад тыңлый, соңыннан спектакль карый, концерт тыңлый. Башта бу тантаналарга ирләр генә йөри торган иде. Соңыннан хатын-кызлар да кушылды.

Ниһаять, авылга кино килде, тавышсыз кино. Ул киноаппаратларны хәрәкәтләндерүче динамикларны, кинога бушлай кертқән өчен, малайлар, чиратлашып әйләндерәләр иде. Әле дә хәтеремдә: без — малайларны санап, бүрекләребезне алып калып, киномеханик кертеп җибәрә иде. Киномеханик фильмның эчтәлеген сөйләп бара.

Колхозлашу чорында мал-мөлкәтне яшереп калдыру, аны акчага әйләндерү очраклары да булгалаган. Шулай Әхмәтов Абдулла абзый колхоз төзелү алдыннан, атын сатарга авыл Советына рөхсәт язуы сорарга барган, авыл Советында хисапчы Галиев Вәли: «Акчама ат сатып алып, колхозга ат белән керәм, дигән имзанамә калдырсаң гына, атны сатарга рөхсәт кәгазе язабыз»,— дигән. Абдулла абый имзанамә биреп, атны сатып җибәргән. Колхозга керү өчен гариза күтәреп килгәч, хисапчы аңа: «Синең, ат белән керәм, дигән имзанамәң бар. Ат алып кил, аннан колхозга алырбыз»,— дигән. Абдулла абый: «Имзанамәне Әтнә базарына алып барып карармын, шул кәгазьгә ат бирүче булса, алып килермен, ә акчасын ашап бетердек инде»,— дигән.

Колхозлар төзелеп, беренче сабанга чыккач, Гомәрев Гыйлаҗга ике ат белән тырмаларга кушалар. Үзләренең аты һәм күршеләре Гайнетдин абый аты. Гайнетдин абый чәчәргә билгеләнгән. Карап кына тора икән малайны. Гыйлаҗ чыбыркы белән бер суккан Гайнетдин абый атына, ике суккан, чыдаган теге, өченче сугуы булган — абзаң, тубалын ташлаган да, малай янына йөгереп килгән. «Ник үзегезнең атка сукмыйсың, минем атка гына сугасың?» — дип малайның колагын борырга тотынган.

Ел азагында, барлык керем-чыгымнарны исәпләп бетергәч, идарә җитәкчеләре, гомуми җыелышта колхозчылар алдында отчет ясап, уңыш бәйрәме үткәрәләр иде.

Башта икмәкне, саламны аванс тәртибендә биреп барып, ел азагында өстәмә уңыш бүлеп, алдынгыларга бүләк өләшеп өч көн бәйрәм игълан ителә иде. Яшьләр өйләнү мәҗлесләрен шушы чорга туры китерә башладылар.

Авылда клуб, китапханә барлыкка килде. Культура учаклары өйдәш рәвешендә булса да эшли иде. Безнең авылда китапханә Хәйруллина Фәсәхәт, икенче тапкыр, Хәсәнова Асия йортында оештырылды. Беренче клуб сугышның соңгы елларында гына, авыл яшьләре иске мәчетне яраклаштыргач кына эшли башлады. Китапханәләрдә, мәктәп биналарында, зуррак йортлы кешеләрнең өйләрендә наданлыкны бетерү курслары ачылды. Анда хәреф танымаучыларны укырга-язарга, исәп-хисапка өйрәттеләр. Әнигә ияреп мин дә бу укуларга барам, әниләр укыганны карап кына тора торган идем. Дингә ышанучылар, без шайтан сабагын укымыйбыз, дип киреләнәләр. Ләкин алар бик аз, күпчелек укуга бик ихлас йөрде, наданлыгын бетергәч, авыл мәктәбендә укучылар, хәтта югары уку йортларына барып җитүчеләр булды.

Авыл китапханәләренә радиоалгычлар куелгач, халык радио тыңларга ачылды. Иң беренче радиоалгычны Югары Шашы авылында укытучы Кәрим абый алып кайткан. Ул вакытта кеше аңа ышанмады. «Кәрим үзе сөйләп, гырмафун җырлата торгандыр», диделәр. Шуның өчен Казанга кеше җибәрделәр. Казан студиясеннән Абдулла абыйның: «Хафиз, ишетәсеңме, бу мин, Абдулла?» — дигән сүзләреннән авыл халкы әле дә көлеп сөйли.

Көн саен булып торган шундый үзгәрешләргә иләнеп матур гына яшәп ятканда Германия фашистлары безнең илгә бәреп керде.

Бу фаҗигале чорда кумәк тормышта яшәп өйрәнгән гадәтләр авылга зур файда күрсәтте. Кыен хәлдә калган гаиләләргә ярдәм итәләр, авырган вакытларында, бербереснә су кертәләр, утын кисешәләр. Эвакуация белән ерак калалардан кайткан рус халкын, аның балаларын да авылым халкы, туганы кебек, якын күрде, караңгы чырай күрсәтмәде. Аларга түрдән урын биреп, сырма-ястыкларын, ризыкларын уртаклашып яшәделәр. Мин ул чакта комсомол оешмасы секретаре идем. Төрле милләт кешеләре арасындагы дуслыкка без бик сөендек. Сугыш бетеп, алар авылдан киткәндә, матур итеп озаттык, күз яше белән елаучылар да булды. Милләтләр дуслыгын мин беренче мәртәбә үзебезнең авылда, аннары фронтта очраттым.

## Бәйрәмнәр

1930 нчы елны миңа биш яшь тулганда, сабан туе бәйрәменә бер атна кала, әни мине җитәкләп, авылыбызның тегүчесе Сабира апага алып барып, күлмәк-ыштан тегәргә бирде. Әле дә хәтеремдә, Сабира апа күзлек киеп, минем янга тасма метрын алып килеп, буемны, билемне, муенымны үлчәде. «Бик зур булгансың икән инде»,— дип сөйләнүе миңа ифрат ошады. Моңарчы әти-әнинең искергән күлмәкләреннән кулдан гына теккән күлмәк-ыштан киеп йөргән малайга бу бик зур вакыйга булды. Тукымасы чия төсле иде. Әни сарык йонынnan ак оекбаш бәйләде, әти кечкенә генә чабата ясап бирде. Шулай итеп, мин сабан туен тулы хәзерлек белән каршыладым. Оныта язганмын, әни кечкенә генә бер капчык та тегеп биргән икән әле — анысы йомырка җыярга. Сабан туе көнне иртән караңгы белән үк әни мине уятты, кемнәргәндер бүләкләр бирергә тиешлеген әйтте, тамагымны туйдырып, күршебездәге Котдус абыйның малае Габделхәйне җитәкләп, сабан туе бүләге алырга чыгарып җибәрде. Әни: «Менә бу кешеләрне калдырмагыз, алар безнең туганнар, алар сиңа йомырка бирергә тиешле»,— дип аңлатты. Габделхәйнең үз туганнары бар. Шулай итеп, без әниләр әйткән кешеләргә кереп йөри башладык. Иң элек — Һади абыйларга. Аның хатыны Кәшифә апай суган кабыгында кайнаткан сап-сары ике йомырка бирде. Аларның күршесе Фәриха апа да миңа йомырка бирде. Кайтканда, арып бетеп, берничә мәртәбә егылып та алдым. Зуррак малайлар йомыркаларыгызны алмасын, күрсәтмәгез! — дип, әни бик кисәтеп куйган иде. Шуңа мин капчыкның авызын бер дә ачмадым. Арып-талып өйгә кайтып җиткәндә, әни капка төбендә көтеп тора иде. «Кара, минем зур улым кайтып килә икән, кая әле, улым, капчыгыңны карыйм әле»,— дип ачып җибәрсә, капчык эчендәге ике-өч чи йомырка ватылып, конфет-прәннекләр белән буталып беткән. Мин елап җибәрдем. Әни мине юатып, өйгә алып кереп китте. Мин урынга ятып, йокыга талдым. Шуннан соң сабан туйларында күп катнашырга туры килде. Ләкин берсе дә бу беренчесе шикелле тәэсир итә алмады.

Көндезге ашны ашагач, авылның дәрәҗәле ир-атлары колга алып, сабан туе бүләге җыярга чыктылар. Без, малайлар, алдан йөгереп барып: «Байлар өйдәме?» — дип кычкырып, йорт хуҗасына, бүләген әзерләргә хәбәр итеп йөри идек. Бүләккә кем нәрсә бирә ала: күлмәк, алъяпкыч, сөлге, тастымал, йомырка, акча, прәннек,

хәтта чабата биргән кешеләр дә була торган иде. Беркем дә бүләк җыючыларны буш калдырмый. Ә яңа өйләнешкәннәр, күбесенчә сөлге бирә торганнар иде. Нәзер әйткән кеше кисәтеп куя: «Бу бүләгемне җәяүле йөгерештә иң артта килгән кешегә бирерсез»,— ди. Артка калган атка адарынучылар аеруча күп була. Комиссия нәзер бүләге бирүчеләрнең үтенечен гел үти. Ул көнне авыл шау-гөр килә, кунаклар җыела. Тирә-күрше бер-берсе белән капка төбендә сөйләшеп, көлешеп утыра. Безнең ише малайларны авыл чирәмендә яланаяк чабыштыралар. Күрше Гарифҗан абый, безнең урам малайларын җыеп, Куңгәр зираты ягына басуга алып барып чабыштыра, алдан килгәненә авыл башындагы карама агачының бәрчәсе белән, аннан соң килгәненә берәр ботагын өзеп, иң артта килгәненә бер генә бәрчәсен биреп, бүләк тапшырып, безне әтиләргә бик мактый торган иде. «Менә син сабан туенда балалар чабышына барасың»,— дип, җитезләрне сайлап алалар. Бәйрәм алдыннан чабыш атларын урамнар буйлап йөртеп чыгалар. Бер бәйрәмдә Хәмидулла абыйның ала атын Фәйзиев Фәтхерахман абый йөртергә чыккан иде. Авыл халкы бу атны танып, бик горурланып карап калды. Сабан туенда һәр авыл үз кешесе, үз аты өчен борчылып, аның алдан килүен теләп тора иде. Кич белән яшьләр гармуннар уйнап, җырлап, авылны шаулатып торалар иде.

Сабан туе бер елны Пләтән урамы дип йөртелгән урамның югары башында — басуда булды. Ни өчен анда булгандыр, хәзер генә әйтә алмыйм, чөнки безнең авыл бик матур инеш буена утырган, шунда үткәрү кирәк иде. Корырак җир булганы өчен сайлаганнардыр.

Бәйрәм программасында хәзер дә элекке уеннар калды: капчык киеп чабышу, бауга элеп куйган төрле бүләкләрне күзе бәйләнгән килеш кайчы белән кисеп алу, бүрәнәгә атланып капчык белән сугышу, таяк, бау тартышу, җыр-бию ярышлары, кашыкка йомырка салып йөгерү. Ат чабышы, җәяүле чабыш, ниһаять, иң соңыннан — көрәш. Бер елны сабан туенда авыл мулласы батыр калды. Башка авыллардан да кешеләр килгән иде. Ләкин Зарифны җиңүчесе булмады. Ул — юантык кына, кыска буйлы, тәп кук таза кеше. Бу бәйрәмнең җәяүле чабучылары бик нык истә калды. Без, малайлар, чабышны карарга, ярты юлга кадәр бардык. Иң алда Хафиз абый, аннан Мифтах абый, аның артыннан безнең әти белән бертуган Фәтхерахман абый килә, алардан соң да бик күп кешеләр бар. Бервакыт Фәтхерахман абыйны бер-бер артлы уза башладылар. Карасам — абый кирегә йөгерә, артка кала башлагач, мәйданга керергә хурланган. Җәяүле чабучылардан иң артта зурлар төркемендә Югары Шашы авылыннан Шияби дигән кеше килә, бер кеше аннан арттарак калырга тырыша, ә ул аны куа, бар, уз, ди, ни өчен алай булуын аңламадым. Һәр сабан туенда берничә кеше, иң арттан килүчегә, дип нәзер әйтә, шул бүләкне алырга тырыша икән бу.

Сабан туеннан соң кичкә таба авыл тына, егетләр эшлияле-чуклы, кыңгыраулы-шөлдерле атлар белән урам әйләнеп йөриләр. Әнә шунысы хәтердә бик калган...

Авылда кунак килмәгән бер генә йорт та булмый торгандыр. Безнең як авыллары сабан туен атнасы-атнасы белән, төркемнәргә бүленеп бәйрәм итәләр иде. Бер авыл сабан туе үткәргәндә, икенче авыллардагы туганнарына кунакка бару мөмкинлеге туа.

Кунаклар яхшы атлар, матур тарантаслар белән авылдан авылга йөриләр, ат җайгына бара, чаптырмыйлар, тарантаска кунак кызлар утырган, тарантас башында — авылның бер чибәр егете, түбәтәйле, чибәр киемле гармунчы егет өздереп гармун уйный, авыл кешеләре, бала-чага, капка төпләренә чыгып, аларны карап кала, күзәтеп торалар. Урам әйләнүче атлар шулкадәр күп була, күпер яныннан югары урамның аргы башына кадәр сузыла. Ә бит бу — гади нәрсә түгел, бу — атларны, дирбияләрне сынау. Икенчедән, халыкның тырышлыгына, бәйрәмгә нинди әзерлек белән килүенә, киенә белүенә дә күргәзмә. Тула оекны бер генә җыерчыксыз, шома итеп киеп кара! Чабатаны тугызлыдан, унберледән үреп кара! Иң мөһиме — егетләр кыз күзәтә, кызлар егетне күреп кала. Кичләрен авылыбызның кибет тау башы урынында яшьләр уены була. Бу әлеге көнгә кадәр саклана. Бирегә авылның олы кешеләре дә килеп, яшьләр уенын, җырбиюне карап, музыка тыңлап китәләр иде. Яшьләр берсен-берсе шул уеннарда таба.

Икенче көнне кунакка йөрешү башлана. Бер кешегә башка авылдан туганнары килсә, аны авылдагы башка туганнары да чакыра, гомумән, кунакка алу гадәте бик таралган иде. Кунак алган йортка хатын-кызлар аерым, ирләр аерым йөриләр. Хатын-кыз табынына эчемлек кую юк, тыелган эш булып санала иде. Ирләр мәҗлесендә күбесенчә әчеткән бал була. Соңга табарак аракы килеп керде. Ләкин аракыны да компсызланып эчү юк, аракы салган стаканны биргәч, кунакны кыстап, биш-алты җыр җырлыйлар, кешеләрнең җырга осталыгы, сүзгә тапкырлыгы сынала иде. Бәйрәм ризыкларыннан иң элек токмачлы итле аш, аннары туралган ит белән бәрәңге, аның янына бәләкәй савыт белән уып ясалган керән куела. Өченче ризык булып, күпчелек очракта, ярма бәлеше (борай яки дөге ярмасыннан) чыга. Хуҗабикәләр, берсен-

нән-берсе уздырып, бәлешне зур итеп, капкачын бик матурлап, бөреп ясыйлар. Хуҗабикә бәлешнең капкачын түгәрәкләп кисеп, кечкенә кисәкләргә бүлеп, һәркемнең алдына, аштан бушаган тәлинкәләренә сала, бәлеш эчен аерым кашык белән бүлеп, шулай ук аш тәлинкәләренә сала. Шуны бераз ашагач, бәлешнең эченә янә дә май сибеп, кешеләргә өстәп чыгалар. Бәлешнең төбе иң тәмлесе санала, бераү дә өлешсез калмый. Бераздан зур таш кәстрүл белән өрек суы чыга. Чәй янына бавырсак, кош теле, кәләвә, корт кебек ризыклар куела. Кунаклар китәсе көнне саубуллашу чумары дигән аш пешерәләр, аның хакында төрле мәзәкләр йөри, кунакларның шаянрагы, миңа сездә ошады, саубуллашу чумарын бүген ашамыйм әле, иртәгә ашармын, дип көлдерә торган булган.

Туганлыкны тану авылда, сугышка кадәр, бик көчле иде. Югарыда әйткәнемчә, ул тәрбия малайларга буяулы йомырка бирүдән үк башлана. Барлык бәйрәмнәр дә туган-тумачалар белән бергә үткәрелә. Туганнардан башка авылда бер тантана да узмый иде.

Игеннәр өлгерер алдыннан җыен бәйрәме үткәрелә. Бу бәйрәмнең үзгәлеге шунда, сабан туе кебек авылдан читкә чыгып төрле ярыш уеннары, көч сынашулар гына булмыйча, башка төрле кечке уеннар күбрәк була торган иде. Кунаклар да күбрәк килә. Монысы басуда игеннәр торышына карап йөри: иркенрәк яки тыйнаграк. Гомумән, элек барлык бәйрәмнәр табигать шартларына бәйле иде. Игеннәр начар үсеп, ачлык киләсе сизелеп торса, уйнап-көлеп, күңел ачып йөрүләр әләкми шул инде. Басуларда игеннәр матур булып үсеп утырса, халыкның күңеле шат, бәйрәме олы булган. Күңел ачуларның игеннәр уңышына бәйлелеге миңа ифрат та мәгънәле тоела. Балалар икмәк кадерен кечкенәдән үк аңлый башлый. Күз көне өйләнү, тормыш кору өчен кәләш сайлау, егет күзәтү кебек эшләр дә шушы бәйрәмнәрдә хәл ителгән. Авылдагы кичке уеннар: әйлән-бәйлән, уртага алып биетү, җырлату, җәза бирү, йөгерешү, «өченче кеше артык» дигән уеннар халкыбызда күптәннән килгән. Һәр уенда җәза бирү кебек шарт була иде. Җыр-биюгә сәләтсез яшьләрне: «Ярый алайса, әтәч яки кәҗә булып кычкыр!» — дип җәзалыйлар иде. Уенны җанландырып җибәрү өчен кайбер шаян егетләр, үзләрен сәләтсез күрсәтеп, кеше көлдерү өчен, тавык булып кытаклап йөриләр, яшьләр эчләре катып көлә иде.

Хуҗалыктагы зур эшләрне башкарган чакта өмә җыю гадәткә кергән иде. Бер йортта эшләүчеләр аз булса яки гаиләдән берәрсе авырып китсә, өмә игълан итәләр, ураклары беткән яшьләр өмәгә җыела. Өмә ясалган йортта, эштән соң, ярдәм иткән яшьләрне сыйлап, биеп-җырлап та утыралар.

Иген эшләре беткәч, крестьян халкы мал-туар симертү белән шөгыльләнгән. Терлекне көннәр салкынайткач, ноябрь айларында суя торган булганнар. Әле мин белгәндә дә каз өмәләре үткәрелә иде. Бу чорда туганнары, күршеләре белән берләшеп, бер көнне бер йортның казларын суеп, чистартып, юып куялар иде. Эш тәртибе болай: суеп, йонын йолкып бетергәч, матур итеп киенгән кызлар, каз түшкәләрен көянтә башына бәйләп, инешкә алып төшәләр. Егетләр, инеш буена килеп, көтеп тора. Каз өмәсе булган йортта ул көнне «каз коймагы» пешерәләр, күрше-күлән аны авыз итми калмый. Яшь-җилкенчәккә уеннар үткәрү мөмкинлеге дә бирелә иде. Озын сүзнең кыскасы — эш тә эшләнә, күңел дә ачыла, егет белән кыз вәгъдәләшә дә ала.

Ә кыш көннәрендә кибәннәрен сугу өчен туган-тумача, күрше-күләннәрен җыеп өмә ясаганнар. Ашлык сугуга олылар да катнашкан, өлкәннәр тәҗрибәсе яшьләргә күчкән.

Йорт салу өчен агач алып кайту, бура күтәрү кебек эшләр дә туганнары, күршеләре белән өмә рәвешендә үткәрелгән. Унар-егермешәр олау берьюлы җыелган. Өмә үткәрергә хуҗа еллар буе әзерләнеп торган. Күмәк эшләү мисаллары әле колхозларга хәтле үк булган, авылның иң күркәм сыйфатларыннан саналган. Күмәк тормышка күчкәч, сугышка кадәрге елларда, бу матур гадәтләр тагын да арта төшкән иде.

Иген эшләре беткәч, безнең авыл яшьләре, ат алырлык акча эшләү өчен, Астраханьга, Брянскига, Дятково дигән хрусталь заводына, Донбасс шахталарына киткәннәр. Алар язын яңадан авылга кайткан. Әле дә хәтеремдә: безнең күршебез Гатаулла абзыйның Әсәт атлы улы читтән кайткан иде. Читтән кайтучыларның авыл малайларына, күршеләренә күчтәнәч алып кайту гадәте бар иде. Аларның хәлен сорашырга туганнары, күршеләре керә иде. Без, кунакның хәлен белергә дип кергәч, безгә Әсәт абый икешәр конфет биреп чыгарды.

Бәйрәмнәр хакында, төрле очраклар уңае белән җыйналган мәҗлесләр хакында сүз кузгаткач, авылыбыз халкының исерткечкә мөнәсәбәтен дә әйтеп китмичә ярамас. Хатын-кызлар эчемлек булган мәҗлестә бөтенләй дә катнашмый иде. Өмәләр эчемлексез уза иде. Тамак ялгап алганнан соң сөйләшеп утыру, күңел ачу, җырлау башлана. Соңгы елларда, табынга эчемлек кую гадәткә кергәч тә, әле аракы күпләп куелмады. Әлегрәк, кешеләрнең әйтүенә караганда, 20-30 кешелек ирләр мәҗлесенә

бер чирек, ягъни өч литр әче бал куелган, аның да күбесе кала торган булган. Авылның олы кешеләре, гыйбадәт кылучылар бөтенләй эчмәгән. Олы кешеләр эчмәгәч, яшьләр дә үзләрен тыйнак тоткан. Безнең авылда һәм, гомумән, татар авылларында кибетләргә аракы кертмәгәннәр. Аракы эчеп урамга чыгу бик ямьсез хәл саналган. Әгәр исен сизсәләр, шундук ул кешенең әтисенә җиткергәннәр. Ә әти кеше ул чакларда зур абруйга ия булган. Берәр егет эчеп өенә кайтса, бөтен авылга даны чыгып, фәлән кешенең улы аракы эчә икән, дип, хәйран калып сөйләгәннәр. Читтә йөреп, аракы эчәргә өйрәнеп кайткан егетләргә кыз бирмәгәннәр, алар өйләнә алмыйинтеккән, эчү гадәтен ташларга мәҗбүр булган.

Бәйрәм уздыру, кунакларны утырту тәртибе дә бик төгәл булган. Әле мин белгәндә дә шулай иде. Таза хәлле кешеләрнең өч өе, уртачаларның ике өе булган. Берсе — аш өе, икенчесе ак өй, өченчесе — семья башы йоклый торган кече өй. Мондый йортлар безнең авылда дүрт-биш кенә кешедә булган.

Кунак табыны чиста-пөхтә итеп җыелган өйнең идәненә әзерләнгән. Башта идәнгә йорт хуҗасы үзе суккан дурба-палас, аның уртасына үзләре суккан бик матур шакмаклы ашъяулык җәйгәннәр. Стена буена тезелеп, корама көрпә өстенә утырганнар. Түр башына — олы яшьтәге кунаклар, аның янына — урта яшьтәгеләр, иң түбәндә, ишек катында яшьләр утырган. Кунаклар җыелып беткәч, олы кешегә сүз бирелә. Ул мәҗлеснең нинди уңай белән үткәрелүен аңлата, вәгазь сүзләрен әйтә, мәҗлесне башларга рөхсәт бирә.

Мәҗлестә олы кешеләрнең күргән-белгәннәрен, башыннан кичкән авырлык-җиңеллекләрен сөйләтеп, уен-көлке сүзләр дә әйтешеп утырганнар. Ә яшьләр, шул гыйбрәтле сүзләрне аек баштан тыңлап, сабак җыйган. Табынга ризык чыккан саен, аның ләззәтен, хуҗа хатынның уңганлыгын мактау әле мин катнашкан мәҗлесләрдә дә була торган иде. Кунаклар, хуҗаларга рәхмәт әйтеп, таралалар.

Хәзерге чорда да миңа кунакта булырга туры килгәли. Табын ризык белән тулы, ирләр, хатын-кызлар бергә җыела. Берсендә хәтта өйләнмәгән яшьләр дә килгән иде. Мәҗлес ачык дип игълан ителүгә, шатыр-шотыр шешә ачарга тотындылар. Берсе аяк өсте басып, тост әйтте. Ирләре дә, хатыннары да стаканнарны күтәреп, эчеп җибәрделәр. Шундук яңадан эчтеләр. Көтмәгәндә, һәммәбезне сискәндереп, чырылдавык тавышлы юан бер хатын җырлап та җибәрде. Йорт хуҗасы кайнар аш чыгарырга йөри, ә мәҗлес халкы, бием керәбез, дип, дәррәү кузгалды. Әллә ниткән карлыккан тавыш белән чит ил телендә пластинка үкерә башлады, бию дигән дөбердәү башланды, кыскасы, ата — улны, ана кызны белми. Шушы кыланыштан соң, табын янына кереп утырдылар да, тиз генә рюмкаларга аракы салып, тагын эчеп җибәрделәр, ашка күтәрелеп караучы да булмады. Тагын җырлый башладылар, мәҗлес бик ямьсез төс алды.

Икенче бер мәҗлестә тамада сайлап куйдылар. Өстәлдәге эчемлекләр дә, ризыклар да теге мәҗлестәгедән ким түгел иде. Иң элек хуҗа аяк өсте басып нинди уңай белән мәҗлес җыйналуын әйтте. Аның 50 яшьлегенә килгән идек. Тамада юбиляр хакында кыска гына сөйләде. Шаян сүзләр әйтеп көлдереп тә алды. Шуннан берсеннән-берсе тәмле ризыклар өстәлгә чыгып торды. Эчемлек хакында башта берәз гына сүз булды да аннан кунакларның үз иркенә куелды. Алар күпчелек вакытларын кызыклы вакыйгалар сөйләп үткәрделәр. Кунакларның берсе баянчы икән, аның уйнавын үтенделәр, җыр җырладык, бераздан, коридорга чыгып, биеп тә керлек. Концерт залында утырып, ял итеп кайткан шикелле, хуҗага, аның хатынына кайнар рәхмәтебезне әйтеп таралдык.

Кунаклар саны күп түгел, барлыгы сигез пар иде. Чыгып киткәндә, хуҗа, хатыны белән икесе, безнең рәхмәтебезгә каршы: сезгә дә бик зур рәхмәт инде, бик зурладыгыз,— дип әйтеп калдылар. Ә юбилярны котлап китергән бүләкләребезне бәләкәй өстәлгә куйдылар. Мин үземә ике очракта да сабак алдым.

## Туй йолалары

Безнең авылларда туйны хәзер дә бабаларыбыздан калган йолаларга турылыклы рәвештә алып барырга тырышалар. Элегрәк кызларны күреп өйләнү булмаган. Шулай да егетләр дә, кызлар да, яучылый башлагач, нинди юллар беләндер, берсен-берсе карарга юл тапкан. Безнең авылныкы Гайнетдин абый Шәмсеруй апай белән бик озак гомер итте. Аларның бер-берсенә һәркайчан ягымлы карап, елмаеп кына сөйләшүенә авыл халкы исе китә торган иде. Алар бер-берсенә: «сиңа әйтәм, әй»,— дип кенә йөриләр иде. Гайнетдин абзый элеккеге туйларны миңа болайрак аңлатты. Ир баласы балигъ булып, өйләнер вакыты җиткәч, егетнең ата-аналары кыз күзли башлый. Кыз нинди нәселдән — һәммәсен төпченеп, тикшереп чыгалар. Күңелләренә хуш кил-

гән кыз хакында улларына әйтәләр. Шуннан егет үзе, хәйләсен табып, кызны күрә, буен-сынын күздән үткәрә, сөйләштереп карый. Гайнетдин абзый үзе, мәсәлән, узып баручы кеше булып, Шәмсеруй яшәгән йортка су эчәргә кергән, кызны сөйләштергән.

Шулай бер мәлне, Гайнетдин абзый белән капка төбендә сөйләшеп утырганда, Казаннан кунакка кайткан ике кыз узып китте. Өсләрендә — ачык якалы, җинсез, тездән югары күлмәк, ялан аякка босоножки кигәннәр. Гайнетдин абзый: «Менә, энем, кара инде боларны, бар җире дә шәрә бит,— диде.— Һичнинди серләре дә калмаган. Безнең чакта бары да — гаҗәеп сер булып тоела иде. Өйләнеп кыз куенына кергәч, тәмам исерәсең. Аннан да гүзәл зат юктыр кебек...»

Көз айлары җитеп, игеннәр җыйналып беткәч, егет нәселенең дәрәҗәле кешесе, кызны сорап, яучы булып бара. Яучы кеше бер аягындагы чалбар балагын чыгарып килеп керә. Сөйләшә башлаганчы ук аның ни өчен килгәнен абайлап алалар. Шуннан, ризалык биргәнче, кыз белән сөйләшергә бераз вакыт калдырып, егетне өйрәнергә тотыналар. Минем әнинең Сабира исемле апасын Чембулат авылыннан сорарга килгән яучыдан соң, әти, таякка таянып, Чембулат ягына чыгып китә. Юлда моңа сукачылар очрый. Арадан берсе кияү буласы егет Габделгани икән. Аның белән сөйләшеп тора. Әти Габделгани турында тулы мәгълүмат җыеп кайта. Чембулат авылы кешеләре Габделганине яманламыйлар. Егет сүзне дә чамалап кына сөйләшә. Кызыбызга кияү булырга лаек, дип, яучы икенче килгәч, ризалык биреп җибәрәләр.

Яучы алдым-бирдем, кодаларны кайчан китерү хакында да сөйләшә. Риза булышкач, егет ягы кодалары, егетнең туганнары, атлар җигеп барып, кунак булып, никах укытып кайталар. Кияүне, кыз янына кергәнче, берәү ишекне ачтырмый «интектерә». «Минем апай йөз алтын, ишек бавы бер алтын»,— дип төрле шаян сүзләр әйтә. Кияү аңа бүләк бирә, ишекне ачалар, булачак килен егетенә чәй эчертә. Шул чагында егетнең тапкырлыгын тикшерәләр. Бүлмәнең икенче ягында кызлар җыйналып тора, алар егет утырасы урын каршысына көзге куеп, үзләре бүлмә ярыгыннан кияүнең битен, буен-сынын, көлүен, ашаганда колагы селкенәме-юкмы икәнен күзәтеп, тикшереп торалар. Тапкыррак егетләр, кергәч тә көзгегә сөлге элеп, аны каплап куйган. Кызлар да авыз ачып тормый, егетләрнең утыра торган көрпә астына төрле сыбызгылар кыстырган. Егетләрнең тапкырлары тикшермичә утырмый. Ә кайберләре, игътибар итмичә, кинәт утырса, көрпә астындагы сыбызгылар сызгыра, бүлмә артындагы кызлар көлешә башлый.

Чәй эчкәч, кызны озатырга килгән кызлар, урын җәеп, саубуллашып чыгып китәләр. Урын җәйгән өчен кызларга кияү бүләк бирә. Кияү, ике яки дүрт кич йоклагач, кайтып китә. Шуннан һәр атнаны җомга көнне кич килеп, атна саен яңадан ике кич кунып китә. Дүртәр-алтышар ай кияүләп йөриләр. Бер-берсенә ияләшеп бетсен өчен шулай иткәннәр. Вакыты җиткәч, киленне бик матур атлар, тарантаслар белән тантаналы рәвештә алып кайталар. Егет йортында туй башлана. Егет ягы кыз ягыннан кодалар чакырта, яңадан бик зур бәйрәм ясап, килен төшүне билгелиләр. Бу йолалар авылыбызда әле дә тулысынча саклана. Кияүләп йөрү гадәтләре генә төшеп калды. Аңа вакыт юк. Хәзер туйларны зур итеп уздыралар. Киләш өендә кияү кайткан көнне яшьләр туе, иртәгесен олылар туен ясау гадәт булып керде. Хәзер никахны, авыл Советына барып, тантаналы шартларда теркиләр. Яшьләр Бөек Ватан сугышында һәлак булган авылдашларыбыз һәйкәленә чәчәк салалар, рәсемгә төшәләр, болары — хәзерге заманның яңа һәм матур йолалары. Мин кырык ел буена җитәкче булып эшләгән дәвердә бер туйда да сугыш чыгарып, туйны бозу очраклары булмады.

Әгәр килен колхозда эшләсә, мәҗлескә колхоздагы оешмалар исеменнән бер җитәкче бара, яшьләрне тәбрикли, бүләкләр тапшыра. Хәтта башка авылга киткән киленнәребезгә дә, әгәр алар алдынгылар икән, тәбрикләп, бүләкләр тапшырып кайтабыз. Бу — киленнең дәрәҗәсен күтәрергә ярдәм итә.

Бөек Ватан сугышыннан соң, халыкның көнкүреше авыр чакта, кызны туйсыз бирү гадәте булып алды. Ул очракта кыз һәм егет икесе киңәшкәч, ата-аналары яучы җибәреп, килешү ясагач, риза булып өйләнешәләр. Бу очракта да, хәлле хәленчә, туганнарны чакырып, никах мәҗлесе сымак тантана үткәрелә иде.

Сугыштан соңгы авыр елларда, атасы сугышта үлеп калган кызларны кияүгә биргәндә, миңа да шаһит булып баргаларга туры килде. Кияүгә китүче кыз белән әнисенең кочаклашып елаулары үзәкне өзә иде. Бу авыр елларда малайларын өйләндергән яки кызларын кияүгә биргән кешеләр, ата-баба йоласын тулысынча үти алмауларына бик борчылалар иде.

Кайбер ата-аналар: «Балалар, бераз гына сабыр итегез әле, бер-ике елдан, тормышлар көйләнгәч, өйләнешерсез»,— дип киңәш бирәләр, әмма көтеп тору мөмкинлеге булмаганлыктан, кызны турыдан-туры егет өенә алып китү очраклары да, кыргыйларча өйләнү гадәтләрен дә очратырга туры килде.

Кыз урлау. Бу төр өйләнү — бик катлаулы. Моны аңлау минем өчен табышмак

булып калды. Шулай бер кызны, арбага салып урлап алып китеп баралар икән, кыз кычкыра: «Коткарыгыз, мине урлыйлар»,— ди. Авылның бер кешесе, атны туктата да, ник кыз баланы ризалыгыннан башка алып китәсез? дип, егетләрне орыша башлый. Кызга: «Әйдә, сеңлем, төш», дигән. Кыз исә: «Өйдән бер чыккач, калмыйм инде»,— дигән.

Сугыштан соңгы авыр елларда кереп калган бу кыргый гадәтләр озакка бармады. Никахлашу-өйләнешүнең иң матур якларын файдаланып, яңача өйләнешү гадәткә керде. Мәҗлескә чакырулы кешеләр алдан ук открытка ала. Хәзерләнергә, эшеннән рөхсәт алырга, өйләнешүчеләр өчен бүләк сайларга вакыт була. Туйга кунаклар да, кәләш белән кияү дә махсус киемнәр тектерә. Кияү алтын балдаклар сатып ала.

Төрле милләтләр белән катнаш туйлар да ешая башлады. Алар арасында ошап бетмәгән гадәтләр дә очраштыргалый. Шулай бер туйда ике студент өйләнешә. Егет — безнең авылныкы, кыз — башка районнан. Бераз утыргач, шәһәрдән кайткан яшьләр, ду килеп, төрле тавышлар чыгарып: «Горько!» «Әче!» — дип кычкыра башлады. Шул вакытта егет торды да: «Кадерле кунаклар, сезнең нәрсә таләп иткәнлегегезне беләм мин. Ләкин таләбегезне үти алмыйм, әти-әни алдында үбешеп тору килешми. Аларга ихтирам йөзеннән мин бу гадәттән баш тартам»,— диде. Авыл кунаклары егетне хупладылар. Шулай итеп, безнең авылга олы кешеләр алдында кочаклашып-үбешү гадәте кермәде.

Элегрәк елларны туй бүләге бик тыйнак иде, хәзер арта бара. Кайберләре, ишетүем буенча, җиңел машина да бүләк итә икән. Безнең авылыбызда мөстәкыйль тормыш башлау өчен кирәкле нәрсәләр бирәләр: урын-җир әйберләре, мендәр, юрган... Безнең борынгы бабалар урын-җир генә түгел, хәтта комган, чиләк, ләгән, табагач, таба, балта шикелле әйберләр дә биреп җибәрә торган булганнар, яшьләрне дөрес юлга юнәлткәннәр. Хәзерге кайбер ата-аналарның балаларын байлыкка батырулары яшьләрнең тормышка карашын җиңеләйтә, эшне-хезмәтне яратмауга алып килә дип исәпләргә кирәк.

## Гаилә кору, йорт алып бару

Элек гаиләдә күп кеше яшәү табигый саналган. Безнең авылның бер йортында 22 кеше бер гаилә булып яшәгән. Хөснетдин дигән бу кешенең Әүхәдулла, Лотфулла, Хәйрулла дигән уллары, өйләнеп, балалары зур булганчы бергә торганнар. Өлкән хуҗа табынга утырмый торып, беркем дә утырмаган. Әле дә авылыбызда 10-12 кешеле гаиләләр бар. Унар бала китергән хатын-кызларыбызның балалары тырыш, эш сөючән булып үсәләр. Андый йортта балалар берсен-берсе бага. Өйдәге башка эшләрнең дә күбесен балалар башкара. Мөстәкыйль тормыш кора башлагач та бу балалар югалып калмый, үрнәк хуҗа булып чыга.

Фәизов Фәтхерахман гаиләсе, аның хатыны Нәсимә башкаларга үрнәк булып тора. Ун бала үстерделәр. Балалары барысы да эшчәннәр, һөнәрлеләр. Балаларының балалары да эшкә өйрәнеп үсә.

Минем малай чагым, үсмер чагым, җитәкче булып эшләгән чорым, күршебез Котдусов Кашшаф абый, хатыны Нәгыймәбикә апайлар белән үтте. Котдус абыйның балалары Кашшаф, Габделрәүф, Габделхак, Муллахаҗи, Нуриаздан, Габделхәй — алты бала — бик эшчән булып үскәннәр. Нәгыймәбикә апай ягы да күп балалы: Нәгыймәбикә, Хәбибрахман, Гарифулла, һадия, Нәсимә, Сәгыйдәбану — алты бала. Кашшаф абый да, Нәгыймәбикә апай да 7-8 яшеннән ата-аналарына ярдәм иткәннәр. Кашшаф абый колхозның иң яхшы атын җикте. Авылга кайткан лобогрейка, ургыч, чәчү машиналары белән беренче булып ул эшләде. Чалгы белән печән чапканда, һәр көнне бер гектар җирне чабып барды, норма 0,30 га иде. Ватан сугышында катнашты. Сугыштан соң идарә атларын карады. Колхоз председателе булып эшләгәндә, бу кеше белән бергә булу мине күп нәрсәгә өйрәтте. Колхоз идарәсенә моңарчы пычрак аяк белән керәләр иде. Безнең барыбызны да аяк киемен салып керергә өйрәтте ул. Шул гадәт әле дә саклана. Идарә бинасында тәмәке тартуны да ул бетерде. Нинди гадел кеше булган Кашшаф абый! Аның хатыны Нәгыймәбикә апай үткен, гадел, эшчән, таләпчән иде. Колхозның иң авыр эшләрендә йөрде: амбарда капчык ташыды, Арчадан, илле чакрымнан орлык алып кайтуда катнашты. Бервакытта да ыңгырашмады, каушап калмады. Гаиләдә алты бала үсте: Габделхәйдәр ун яшеннән колхозга булышты. Хәзер Казан авиация заводында — иң оста токарь; Габделбарый да, колхоз эшендә ныгып, армиягә китте, майор дәрәҗәсенә иреште; Ясминә әле дә колхозда эшли; Габделкави институт бетерде, Казанның «Оргсинтез» берләшмәсендә — цех начальнигы; Өммегөлсем техникум тәмамлады, Минзәлә районында бер колхозда экономист булып эшләде, хәзер — авыл Советы председателе; төпчек уллары Габделфатих — Түбән Кама шәһәрендә шәһәр Советы председателе ярдәмчесе.

Болар үскәндә, бик авыр иде. Сугыш вакытында шундый бер вакыйгага тап бул-

дым. Нәгыймәбикә апай кирәк тота алырдай барлык балаларын да бакчага алып чыккан. Ул вакытта әле бәрәңге бакчасын кирәк белән казый идек. Болар янына укытучы килде. Габделбарый берничә көн мәктәпкә бармаган. Тегесе әйтә: җибәрә алмыйм, ди. Әгәр вакытында бәрәңге утырта алмасам, ничек туйдырырмын мин аларны? Шулай да укытучы китми, баланы җибәрүне таләп итә. Шуннан Нәгыймәбикә апай: «Сеңелем, мин баламны надан калдырырга ярамаганын да беләм»,— дип елап җибәрде. Укытучы, башын иеп, китеп барды.

Нәгыймәбикә апай белән Кашшаф абыйның бер-берсенә мөгамәләсе дә бик ягымлы иде. Кашшаф абый кайтмыйча, Нәгыймәбикә апай ашамады, йокларга ятмады. Кашшаф абый эшкә киткәндә, иртәме-соңмы, кайнар ризык ашатмыйча җибәрмәде. Балаларына да, атагызга әйтермен, яки берәр әйбер аласы булса, атагыз ни әйтер бит, дип, әти кешенең дәрәҗәсен һәрвакыт саклады. Кашшаф абыйның вафатыннан соң, олы улы Габделхәйдәр Нәгыймәбикә апайны Казанга алып китте. Нәгыймәбикә апай шунда кыш чыкты. Яз көне кайтты: «Тора алмыйм шул, Казанда бары да әйбәт, кибетләре дә йорт астында гына, ди. Кашшафымны сагынып кайттым. Кичә зиратка төшеп мендем, аның белән сөйләштем әле»... Балаларының барысының да хәлләрен сөйләп чыкты, ничә оныгы бар, барысының да исемен әйтеп сөйләде. Балаларында тора алмавын, авылны, күршеләрне сагынуын тезеп китте. Балаларының укып, һөнәр алып, шәһәргә күчеп, авылдан китүләрен бер дә өнәмәде. Ә кызы Ясминә үзебезнең авыл егете Исламга чыгып, авылда яши. Бик тату торалар, Нәгыймәбикә апай да үлгәнче шунда тәрбияләнде.

Буыннан-буынга күчеп бара торган яхшы гадәтләрнең нәрсә аркасында саклануын менә бу гаилә мисалында да төшенергә була, минемчә. Кызганычка каршы, соңгы елларда безнең авылыбызда да бу мәсьәләдә тискәре гадәтләр күренә башлады. Хәзер авылда яшәү өчен мөмкинлек зур. Дәүләт бала өчен ял бирә, акча бирә. Бакча, мәктәп, институтларның ишеге ачык. Ата-анадан ерак яшәү мөмкинлеге бар. Акча тапса, йортка бирәсе юк, үзе тота. Бу исә яшь кешедә үз-үзен ярату тойгысы уятмый калмый. Ата-аналарның да кайберләре, үзебез колхозда күп чиләндек, дип, баланы эшләтмәү ягын карый. Болар барысы да ялкаулыкка юл ача.

Элек кешеләр бер-берсеннән көнләшеп яшәгән. Күршесенекеннән яхшырак ат булдыру уе крестьянның җанын кимергән. Колхоз тормышында да яхшы мәгънәсендәге көнчелек кирәк, минемчә. Колхозчының йортын үзеннән салдыру яхшы. «Минеке» дигән карашны иҗтимагый мәнфәгать өчен файдаланырга иде! Хуҗалыкларга йорт салу өчен ссуда тәртибендә акча бирелә, төзелеш материалларын китерү өчен транспорт әзер. Колхоз төзегән йортларда кешеләрне торгызып карадык, кайбер кешеләр бик ярата йортны, карый, икенчеләре исә аркылы ятканны буйга алып салмый, идарәгә йөгерә. Крестьянның үзе яшәгән йорты өчен, аның төзеклеге өчен җаваплылыгы бетә бара. Андый тискәре гадәтләргә каршы бердәм көрәшергә кирәк.

Авыл халкы өч төрле милек белән эш итә: дәүләт милке, колхоз милке, шәхси милек. Дәүләт милке колхозларда күп түгел: больница, китапханә, клуб, мәктәп, балалар бакчалары — дәүләт хисабындагы милекләр. Аның җаваплы кешеләре бар, ул милекне саклау уңайрак. Авыл халкы бу төр уңайлыклардан бик теләп файдалана.

Авылда элек авыруларны дәвалау им-томчы яки үләнче карчыклар ярдәмендә барган. Им-томы — начар нәрсә, әмма үләненә ышанырга да була. Безнең авылда әле соңгы елларда да Нурмөхәммәт абый Закиров болыннан, елга башларыннан, басудан, урманнардан төрле үләннәр җыеп, чәчәген, тамырын, яфрагын, орлыгын алып, авыруларны дәвалау өчен куллана иде. Даруларны ул үзе ясап бирә иде, нәрсәдән икәнен берәүгә дә әйтми иде. Шулай бер вакыт: нишләп нәрсә белән ничек дәвалавыңны башкаларга чишмисең? дидем. Тиешлечә ясамасалар, агуланырга мөмкин, шуңа күрә мин аны әйтмим, дип җавап бирде. Шулай ук безнең күрше Ары авылында, тайган, сынган сөякләрне дәвалап, урынына утыртучы бар иде, кешеләр шуңа йөри иде. Бала тудыру тулысы белән авылдагы кендекче әбиләр кулында иде. Алар яшь аналарга, йөкле хатыннарга киңәшләр дә бирәләр иде.

Авылда медицина учаклары була башлау, авыл халкының холкына бик зур йогынты ясады. Тормышлар яхшыра барган саен, кирәкле ризык куллану, ризыкны әзерләү нык үзгәрде. Туклану тәртибен генә алыйк. Безнең авылларда элек-электән арыш, бодай, солы, карабодай, ясмык, арпа, борчак, тары иккәннәр. Кешенең туклануында арыш ипие зур урын тоткан. Мич төбен пумала белән чистартып, ипине шунда салганнар. Икенче урында солы оны тора иде. Аңардан бәйрәмнәрдә — коймак, ә гадәти көннәрдә тәбикмәк пешерәләр. Мич төбенә салып пешерелгән солы күмәче дә бик тәмле була торган иде. Балалар, сохари ашаган кебек, шуны кимерәләр. Төшне чыныктыра, сез аны ашагыз, дип әйтә иде өлкәннәр. Солы кесәл ясарга да ярый. Солы кесәлен сөт белән ашый идек. Борчак, карабодай оныннан да коймак бик тәмле була торган иде.

Безнең авыллар тирәсендә, ун чакрым җирдә, алты су тегермәне: Кышлау, Күшәр, Иске Өҗем, Ташчишмә, Иске Ашыт, Ташкичү дигән авылларда. Ә җил тегермәне бишәү: Түбән Шашы, Күнгәр, Олы Әтнәдә — ике, Яңа Шашыда иде. Җил тегермәннәре бастырып кына тарта, ә су тегермәннәрендә күп төрле эш башкарыла иде. Мәсәлән, Күшәр тегермәнендә иләтеп бодай тарта торган ике таш, бастырып тарта торган ике таш, шуның өстенә карабодай, солы ярдыра торган ярма ташы, аның өстенә йон теттерү өчен дә файдалану кораллары бар иде. Авылларга электр кергәч, электр тегермәненә күчтек. Халык, айлар буена җил көтеп, җил булмагач, ашлыгын су тегермәненә күчереп йөрү мәшәкатеннән котылды.

Ләкин электр тегермәннәрендә ашлык кистеребрәк тартыла, су тегермәнендә тарткан кебек мамыклы булмый. Металл кискечләр онның эрелеге-ваклыгын да үзгәртте. Ашлыкның элек кабыгы салдырылып кына алына торган иде. Ә кистереп тарта башлагач, кабык астындагы аксым күбрәк көрпәгә китә.

Басуларда игелә торган культуралар төре дә кимеде. Уңышны азрак бирә торган борай бөтенләе белән бодайга алмаштырылды. Ясмык та бетте, борчак кына калды. Тары, карабодай игү кыскарды. Солы ризыклары да кимеде, бетте, дип әйтсәк тә ялгыш булмас. Ул фураж культурасына әйләнде. Күпләп арпа игелә, ул да фураж культурасына әйләнде. Арыш та үзенең өстенлеген бодайга калдырды.

Шуның аркасында гасырлар буена, буыннан-буынга күчеп килгән туклану рәвеше бозылды, медицина белгечләрен борчый торган хәл туды. Элегрәк, язга чыгу белән: «Зәңгелә булмый, балалар, барыгыз!» — дип, кулларына пычак тоттырып, ата-аналары балаларын акбаш, кузгалак, кякы ашарга чыгарып җибәрәләр иде. Кыргый җиләк-җимешләрне балалар җәй буе сабагыннан өзеп ашый торганнар иде. Ә шомыртны тоз кушып, болгатып, симертеп, яки шикәр комы белән сикертеп ашау гадәте бар иде. Карчыклар, кышка дип, киптерәләр яки как коялар иде. Хәзер варенье кайнату, шикәр белән кушып банкаларга тутыру гадәткә керде. Ягъни җиләк-җимешне табигый хәлендә ашаудан читләштек. Шомырт, балан, миләш куллану гомумән кимеде.

Мин малай чакта, бәрәңге безнең авылда бик аз кулланыла иде. Ул вакытта аның сортлары да уңышны аз бирә иде. Ә Бөек Ватан сугышы чорында бәрәңге бердәнбер ризык булып кешеләрне үлемнән саклап калды. Элегрәк, мин кечкенә вакытта, бәрәңгене ризыкка кулланганда, чиста итеп юып, кабыгы белән пешерү гадәте бар иде. Соңгы елларда бәрәңгене әрчеп, кабыгын башта ук чистартып пешерү гадәтенә күчелде. Тормышлар яхшыргач, бәрәңге дә элекке куллану гадәтен югалтты. Элек тозга ярып пешереп, ипи белән ашала торган иде. Хәзер бәрәңге майсыз-каймаксыз ашалмый.

Элегрәк безнең авылда яшелчә үстерү бик аз хуҗалыкларда гына иде. Соңгы вакытта помидор, кәбестә, кишер, кыяр, чөгендер, суган куллану бик күпкә артты. Моңа сөенергә кирәк.

Безнең авылыбызда, мич ризыклары пешергәндә, салат оны куллану киң таралган иде. Бервакыт, мин кечкенә чакта, бәләкәй чанага бер капчык арыш салып, әни белән икебез Назир бай тегермәне дигән су тегермәненә бардык. Шунда бер кешенең тарткан оны ком төсле сары иде. Үзе ара-тирә шул сары онны кабып та ала. Мин гаҗәпләнеп карап тордым да: «Әни, нишләп ул кеше ком ашый?» — дип сорадым. Әни көлеп җибәрде. Ул кеше дә көлде, мә, син дә ашап кара, диде «Әйем, мин нишләп ком ашыйм?» — дидем. Шуннан ул кеше «комны» ничек ясавын сөйләде. Арышны бүртерәләр, ул шыта. Шул шытымлы көенчә киптереп, тегермәндә тарткач, салат оны килеп чыга икән. Мә, дигәч, әни дә әйткәч, мин татып карадым. Сары он бик тәмле — баллы иде. Мин шуны әле дә оныта алмыйм. Әни аны миңа үзебездә дә берничә мәртәбә ашатты. Авылда сөт ризыгы күп ашала иде. Гадәттә сөт үз хәлендә, кайнатмаган көе икмәк яки бәрәңге белән ашала иде. Куе сөтнең өстен кашык белән җыеп алып, гөбегә салып, май языла. Болгату өчен махсус таяк ясала, таякның түбән ягы «канатлы» була иде. Шул май суын без, балалар, көтеп алып, эчә торган идек. Сыек сөттән катык оетыла торган иде. Катык көндәлек ризык иде. Җәй көне, кар базыннан алып чыгып, ипи белән ашый торган идек. Катык малайларның кул-аякларындагы җәрәхәтләрен дәвалау өчен дә кулланыла иде. Җәй көне яланаяк йөргәнлектән, аякларга «чеби» чыга. Ягъни җилдә тире ярылып, җәрәхәт барлыкка килгән вакытта аякларны әниләр юдырып, кич йокларга ятканда, катык белән майлап яткыра торган иде. Хәзер бу вазифаны махсус дарулар алмаштырды. Табигый шартларда кырда, урман-болыннарда, елга-тугайларында үсә торган җиләк-җимеш, хәтта кузгалак, акбашлар да бакчада үстерелә. Аларның тәмнәре дә үзгәрде. Ашлама үзгәртте аларны. Кайвакыт шәхси таләпләрен алга куеп, дөньяны аңламыйча кыланучылар да очрый башлады. Шулай бер эшем төшеп, ерак бер шәһәрдәге шәхси-индивидуаль бакчага бардым. Хуҗасы бакчада иде. Аның белән сөйләшеп торганда, күршеләре бер мичкәдән апара сыман сыекча ташый башлады. Җиләккә ашлама си-

бәләр, диде хуҗа. Нәрсә, нинди ашлама? Кибеттән ипи сатып алалар да, аны әчетеп, ашлама итеп сибәләр икән. Мин бик аптырадым, гаҗәпләндем, яннарына бардым, сораштым. Бик ихластан сөйләп бирделәр. Аларны тыңлаганнан соң, кәефем китте. «Сез бик зур ялгышлык эшлисез. Без, крестьян халкы, бу икмәкне үстерү өчен, күпме көч түгәбез, аны алтыннан да кадерле исәплибез, хезмәтебезне аяк астына салып таптыйсыз икән. Сезне хөкем итәргә кирәк!» — дидем.

Икмәккә булган кыргый карашка мин түзеп тормаска, кискен чаралар кулланырга кирәк саныйм. Сугышта йөргәндә икмәкнең нинди кадерле икәнен күрдем мин. Сугыш вакытында авылыбызда ачтаң үлгән кешеләрне күрдем. Уйлап карасаң, икмәккә туйганга да күп түгел, 1955 еллардан соң гына ипигә тиенә башладык, оныттырлыкмы?!

Аннан соң, барлык ризыкларны да юллаучы, иң кирәкле нәрсәбезгә — суга булган мөнәсәбәт тә тискәре якка үзгәрде. Безнең авылларыбызда, җиде авылда да, илленче елларга кадәр бер генә дә артезиан коесы юк иде. Авыл халкы чишмәдән һәм кулдан казылган кое суыннан файдалана иде. Хәзер җиде авылга — 12 скважина. Бик аз гына кеше чишмә һәм кое суына йөри. Җитәкчегә авыл кешеләренең ничек киенүе, ашау-эчүе, йорт төзүенә игътибар итәргә, киңәш тә бирергә туры килә. Дәлилле итеп, мисаллар белән. Әйтик, бер мәлне авылларда сууткәргечләр куя башладылар. Газеталарда колонкадан су алуның уңайлыгы хакында сүз куерды. Без дә күп уйлап тормадык, авылларыбызга унике километр озынлыгындагы торбалар сузып, су керттек. Көннәрдән бер көнне, Күшәр авылында, сулар ничек? дип, сөйләшеп торганда, безнең колонка суында ит пешереп булмый, пешсә дә, кып-кызыл булып кала... дигән сүз ишеттем. Шуннан әлеге суларны анализга җибәрдек. Гаҗәпләнерлек нәтиҗәләр кайтты. Барлык сулардан 15 төрле анализга җавап алдык. Шуларның барысын исәпләп, катылык яки йомшаклыкның миллиграммнардагы эквиваленты чыкты. Баксаң, Югары Шашы, Күнгәр, Түбән Шашыдагы су гына тиешле таләпкә җавап бирә икән. Кое-чишмәләрне яңадан карап, ремонтлап чыктык. Нәтиҗә ясап шуны әйтәсем килә, элек мөмкинлек булмаганлыктан, барлык ризыклар да, хәтта су да, табигать ничек бирсә, шулай, натураль хәлдә файдаланыла иде. Хәзер кеше кулы тимәгән, үзгәртелмәгән, борычланмаган, серкәләнмәгән, тозга яки шикәргә манылмаган бер ризык та ашалмый.

Без үзебезнең йортта икмәкне үзебез салабыз, токмачны үзебез басабыз. Сыерсарык, кош-корт асрыйбыз. Гомумән, крестьянча яшәргә, ата-бабаның гасырлар буена килгән яхшы гадәтләрен ташлап бетермәскә тырышабыз. Мин бик яшьтән колхоз председателе булып сайландым. Эшли башлаган гына чор иде, райондагы бер җыелышта, бер колхоз председателен, эше алга бармаган өчен, бик каты тиргәделәр дә, барыбыз алдында аны милиция алып чыгып китте. Шуны мин бик авыр кичердем. Куркудан күз алдым караңгыланып, башым авырта, һава җитми башлады. Басуга чыгып авызымны ачып, җилгә каршы һава йотып тордым. Шулай авырып үләрмен микәнни, дип, врачларга бардым. Миңа карлыган ашарга кушып кайтардылар. Мин шул хәлне өйгә кайткач хатыныма сөйләдем. Ул аны күңеленә якын кабул итте. Шулай бер көнне колхоз эшләре белән озак йөреп өйгә кайтсам, өстәлдә ике чиләк карлыган тора. Ул шул ике чиләк карлыганны 22 километр ераклыктагы Мари авылыннан көянтә белән күтәреп алып кайткан. Аның бу яхшылыгын һич кенә дә оныта алмыйм. Шундый гадәтләре өчен аңа карата ихтирамым бик зур. Шул елны мин карлыган ашый башладым. Икенче елны карлыганны үзебез утыртып, 4 ел буе ашадым. Мин аны аш алдыннан ашый идем. Врачлар, ашаганнан соң кирәк иде, ялгышкансың, диделәр. Димәк, нинди яхшы ризыкны да тәртипсез ашау файдага китерми икән.

*(Ахыры бар).*

# ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

*Бәхәс дәвам итә: «Заман һәм шигырь»*

## Галимҗан Гыйльманов

# ЗАМАН ТОЙГЫСЫ БАРМЫ?

Поэзия хакындагы бу сөйләшүдән ике хакыйкать ачыклана бара. Беренчесе: бүгенге тәнкыйтьтә татар поэзиясенең асыл йөзе күпчелек очракта һәвәскәр шагыйрьләр иҗаты белән билгеләнә икән. Икенчесе: бүгенге поэзия тәнкыйте «ялкынсыз», «тешсез», «предметсыз» икән... Яңарыш, үзгәреш чорының рухын үзенә сеңдерү генә түгел, поэзия тәнкыйте хәтта элгәрерәк яулаган позицияләреннән дә чигенебрәк куйды кебек. Ләкин бу хәлне бер яклы гына аңлату дөрес булмас. Монда әле газета-журнал редакцияләренең «әдәби-тәнкыйть политикасы», шагыйрьләрнең тәнкыйтькә карата үтә «сугышчан» позициясе бар. Күпчелек очракта комплементарлыкка нигезләнгән мондый «политика» тәнкыйтьне генә түгел, шигъриятнең үзен дә ярлыландыра.

Газета-журнал битләрен ачып карауга, күңелдә бер сәер тойгы урнаша: гүя әдәбиятсәнгать белән шөгыльләнүче бүлекләрдә серле исемлек бар. Дөресрәге, ике исемлек — тәнкыйтьләргә ярый торган шагыйрьләр, тәнкыйтьләргә ярамый торганнар... Үзгәреш-ләр чоры да бу исемлекләргә әллә ни үзгәреш кертә алмады. Тәнкыйтькә мохтаҗ дип саналган шагыйрьләр исемлегендә беренче Р. Байтимеров тора. Аннан — С. Муллагалиев, Р. Рәкыйпов, Р. Закиров һ. б. Күрүебезчә, әлеге исемлеккә эләккән шагыйрьләрнең күбесе — СССР Язучылар союзы әгъзасы түгел. Димәк, һәвәскәрләр. Бу очракта да шигъриятнең асылы ялгыш кабул ителә. Профессионал икән — тәнкыйтьләнергә тиеш түгел, янәсе... Юк, мин ниндидер «тоталь тәнкыйть» хакында сүз алып бармыйм. «Предметлы тәнкыйть», «дәлилле тәнкыйть» хакында сүзем. Ә мондый тәнкыйть бүген нәкъ менә профессиональ шагыйрьләр өчен кирәк. Бигрәк тә озак еллар буе шигъриятебезнең күз нуры булып калган исемнәр өчен. Кайбер танылган шагыйрьләребез иҗатында күзәтелгән таптану, поэтик тоемның кимүе, хисләрнең үтмәсләнүе бүгенге поэзия тәнкыйтенең дә билгеле чагылышы ул. Сер түгел, һәркем белә, һич югы сизенә; Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Роберт Әхмәтҗанов, Р. Мингалимов, Р. Гатауллин кебек билгеле шагыйрьләребез иҗатына бүген кискен сүзләр әйтергә, шуның белән аларның оебрак киткән күңелләрен уятып җибәрергә кирәк. Шулай ук И. Юзеев, Ш. Галиев, Ә. Баянов, К. Латыйп, М. Шабаев кебек могтәбәр әдипләребез иҗатыннан билгеле дәрәҗәдә канәгатьсезлек бар. Яңарыш чорында, тарихи-мәдәни мирас, туган тел һәм мәктәп мәсьәләләренең соң чиккә җитеп актуальләшкән бер вакытында өлкән шагыйрьләребезнең күләгәдә кала килүен күңел кабул итми. Ә бит гел шулай булган: иҗтимагый-мәдәни хәрәкәт башында һәр тарихи дәвердә дә шагыйрьләр торган: Тукай, Такташ, Җәлил, Туфан...

Һәвәскәрләр мәсьәләсенә әйләнеп кайтыйк. Безгә алдан ук ачык билгеләп куярга кирәк. Кем ул — һәвәскәр? Профессионал кем? Кемдер бу сорауларда наивлык күрер. Әмма хәл катлаулырак. Беренче ситуация: әйтик, берәү Язучылар союзына тәнкыйтьче буларак кабул ителде ди. Әмма, бер юка гына китап чыгару белән чикләнеп, әлеге «тәнкыйтьчебез» шигъэрият дөньясына аяк басарга ашыга. Башкаларны тәнкыйтьләү күп эш, күп көч сорый, аннары шактый ук мәшәкатьле дә (артыннан күп сүз йөри), борчулы да... Нигә шигырь язып карамаска?! Шулай итеп поэзия офыгында урта кул шагыйрьләр пәйда була. Без аларны профессионал дип әйтә алабызмы?

Икенче ситуация: берәү гомер буе композиторлар белән аралашып яши, алар иҗат иткән музыкага текст яза, бу четерекле эшнең бөтен нечкәлекләрен белә. Шуңа күрә дә аның җырлары популяр, аларны көн саен диярлек радиодан, телевидениедән тапшырып торалар... Аерым әсәрләр хәтта республика, бөтен ил күләмендәге конкурсларда җиңеп чыга... Р. Байтимеров — әнә шундый кеше. Үз жанрында ул профессионал түгелмени? Шул ук вакытта бик билгеле профессионалларыбыз җыр жанрында һәвәскәр булып кала бирә. Бу хәлне нинди рамкаларга яраклаштырырга?

Тагын бик күп төрле ситуацияләрне искә алырга мөмкин булыр иде. Бу очракта гомуми сүз белән генә чикләник:профессиональлек Союз билетына карап түгел, ә үзе сайлап алган иҗат өлкәсенә, иҗат язмышына яраклы рәвештә билгеләнергә, бәяләнергә тиеш. Әгәр дә язучы чынлап торып башка иҗат өлкәсенә күчә икән, ул анда да бөтен шарты буенча тулы сынау үтәргә тиеш.

Бу шигъриятькә янсә прозага күчкән тәнкыйтьчеләргә дә, прозада, драматургиядә каләм сыный башлаган шагыйрьләргә дә бердәй кагыла. Һәм икенче әдәби төрдә иҗат итә башлаган һәр каләм иясенең яңа китабы (һәрхәлдә, беренчесе) Язучылар союзы каршындагы шушы төргә караган махсус иҗат секциясендә каралырга, бәяләнергә тиеш.

Жанрлардагы һәвәскәрлек белән катлаулырак. Шулай да, тәнкыйтьчеләргә монда да эш җитәрлек. Шагыйрьләрнең кайсы поэтик формада, стильдә уңышлырак эшләвен иң тәүдә алар күрергә, аңлатырга тиеш ләбаса.

Бу өлкәдә татар әдәбият белемендә һәм әдәби тәнкыйтендә берни дә эшләнми дисәк, һич ялгыш булмас. Әдәби төрләргә, жанрларга, жанр формаларына игътибар совет әдәбиятында бермә-бер артты. Әдәби форманың әһәмияте әчтәлек әһәмияте белән тигез карала башлады. Ә татар әдәбият галимнәре һәм тәнкыйтьчеләре һаман әле эчтәлек, тема белән генә эш итәләр, әдәби форма хасиятләренә, димәк, әдәби осталыкның асылына үтеп керә алмыйлар. Т. Галиуллинның баллада, поэма жанрларына багышланган берничә хезмәтен исәпкә алмаганда, бу юнәлештә эшләгән эш күренми. Форманы, осталык мәсьәләсен игътибар үзәгенә кую белән, югыйсә, күп нәрсә (шулай ук идея-тематик эчтәлеккә кагылышлы мәсьәләләр дә) ачыкланырга тиеш ләбаса. Әйтик, бүгенге тәнкыйтьчене шундый сораулар борчырга тиеш иде: ни өчен И. Юзеев каләменнән күләмле әсәрләр уңышлырак чыга? Ни сәбәпле Р. Фәйзуллин поэмалары укучыны канәгатьләндерми? Татар әдәбиятында сонет жанрының тернәкләнеп китә алмавын ничек аңлатырга? Соңгы елларда дөнья күргән лирик, публицистик, патетик, трагик һ. б. күптөрле «поэма»ларны чын мәгънәсендә поэма дип атап буламы? Синтетик жанрлар татар поэзиясенә хасмы? һ. б. һ. б.

Бер мисал. Узган ел Рәшит Әхмәтҗановның «Бишташ» исемле поэмасы дөнья күрде. Әмма әле ул поэма булып җитешмәгән иде. Аерым поэтик балкышларына, уңышлы кисәкләренә дә карамастан, бер нык умырткага утырмаган, бер төп идеягә буйсынмаган бу әсәр, басылып чыгу белән, укучыларда каршылыклы фикерләр тудырды: берәүләр аны үтереп мактады, икенчеләр шагыйрьнең поэма жанрында ясаган беренче көпшәк адымы итеп кабул итте. Эш шунда иде ки, Рәшит Әхмәтҗанов, каләмдәшләре Р. Фәйзуллин, Р. Гатауллин кебек, уңай мәгънәсендә Шигырь Шагыйре иде. Аның бөтен поэтик фикерләү рәвеше, образлы сөйләме, дөньяны күзаллавы шигырь масштабына яраклашкан. Ул шулай формалашкан, шулай билгеле бер үсеш юлы үткән, үз иҗат лабораториясен тудырган. Поэма жанрында ул — һәвәскәр.

Рәшит Әхмәтҗанов соңгы вакытта поэма жанрында да уңышлы гына әсәрләр тудырырга сәләтле булуын күрсәтте. Аның «Аучылар китебендә» исемле соңгы поэмасы һәвәскәрлектән профессиональлыкка күчә баруын күрсәтте. Һәрхәдә, анда инде поэманы поэма итә торган төп сыйфатлар бар. Димәк, шагыйрь «Бишташ» поэмасына карата әйтелгән фикерләрне кабул иткән. Бу очракта тәнкыйть үз эшен эшләгән.

Әдәби формаларның җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнелмәве, поэтик әсәрләрнең бары тик идея-тематик яктан, гражданлык җегәрлеге ягыннан гына бәяләнүе татар шигъриятенең алгы сафларында булырга тиешле кайбер шагыйрьләрнең икенче, өченче планда калуына китерде. Г. Хуҗи белән К. Мостафин, мәсәлән, татар әдәбиятында чын бәяләрен алмый киткән әйдәүче баллада шагыйрьләре иде. Аларга бу жанрда И. Юзеев белән Ш. Галиев кенә тиңләшә аладыр. Әмма тәнкыйтьнең салкын битарафлыгы, баллада кебек романтик жанрларга карата булган шикләнүле мөнәсәбәте (реализмнан читкә өстери, янәсе) аркасында соңгы ике шагыйрь дә бу жанрдан читләштеләр һәм чак кына үзләренең чын йөзләрен югалтмый калдылар. Аларга икенче сулыш ярдәмгә килде — И. Юзеев зур күләмле әсәрләрдә — поэма, драма, трагедияләрдә үзен кабат ачты, Ш. Галиев балалар әдәбиятында уңышлы эшли башлады.

Шул рәвешле, тәнкыйть һәр шагыйрь язмышында билгеле бер роль уйный. Ул артык «сугышчан»мы янсә бөтенләй битарафмы, комплементармы янсә билгеле бер кампания нәтиҗәсеме — шагыйрь аны шунда ук тоя, җилкәсенә өреп торган тәнкыйть сулышына үз сулышын көйли.

Һәвәскәрлек һәм профессиональлек хакында сүз башлагач, балалар шигърияте хакында да берничә сүз әйтми мөмкин түгел. Бездә бик сәер традиция бар: өлкәннәр өчен бер-ике шигырь китабы чыгарып өлгергән шагыйрь чираттагы китабын балалар өчен бастыру мәҗбүри дип саный. Шул рәвешле ясалма, көпшәк шигырь җыентыклары пәйда була. Парадокс шунда: өлкәннәр өчен язган әсәрләре белән Союзга кергән шагыйрьнең сабыйлар өчен язган китабын балалар әдәбияты секциясендә тикшерү хакында уйлап та карамыйбыз. Ә бит көн кебек ачык: шулай булганда гына Татарстан китап нәшрияты чишеп булмастай бик күп «башваткыч»лардан котылачак.

Сер түгел, 70 нче елларда, 80 нче еллар башында татар балалар поэзиясе, Ш. Галиев, Р. Миңнуллиннарны искә алмаганда, әллә ни майтара алмады. Соңгы елларда гына татар баласы Рафис Корбанов дигән үзенчәлекле шагыйрьне ачты; Л. Лерон, Г. Садә, Н. Измайловалар да үзләренең мөлаем әсәрләре белән куандырып торалар.

Балалар әдәбиятында күзәтелгән торгынлыкның сәбәбе ачыкланды инде. Аерым алганда, балалар поэзиясе тәнкыйтенең бөтенләй булмавы, балалар әдәбияты фәненең җитди эшләмәве поэзиянең бу җаваплы өлкәсенең чикләрен юуга, аның критерийларын чәчеп-таратып бетерүгә китерде. Иң аянычлысы: балалар өчен язылган дежур, төссез китаплар күбәйде. Яшь талантларның кызыклы язмалары урынын өлкәннәрнең китап киштәләрендә озак ятачагы алдан ук билгеле китаплары кысрыклады... Шул рәвешле, профессиональ һәвәскәрләр бу юлы да һәвәскәр профессионаллардан өстен булып калды.

Бүгенге поэзия тәнкыйтенең тагын бер зәгыйфь ягы хакында әйтми мөмкин түгел. Аңа төпле, дәлилле анализ моменты җитми. Бездә шундый гадәт бар — анализ булдымы — янәсе, бу язма артык фәнни, артык академик. Үзебез күрә торып, белә торып укучы фикерләве дәрәҗәсеннән дә түбәнәебез түгелме? Бүгенге укучыны купшы сүз, куе эмоциональлек, кызыл пафос белән (үзләрен бер үк вакытта шигърият белән дә бәйләгән яшь тәнкыйтьчеләр шушы юлдан баралар) яисә салкын фикер, соң дәрәҗәдә төгәл, коеп куйган фәнни стиль белән генә (кайбер ИЯЛИ галимнәренең язмалары күз уңында тотыла) ышандырып булмый инде. Аңа эмоциональ җылылык та, аналитик тәнкыйть тә бер үк дәрәҗәдә кирәк. Шушы ике юнәлешнең органик синтезын табу мөһим. Кайбер тәнкыйтьчеләребез үз иҗатларында нәкъ әнә шушы моментны канун итеп алганнар. Мәсәлән, С. Маннапов, Ф. Зөлкарнәев кебек тәнкыйтьчеләр тәнкыйди анализны академик стильгә түгел, бәлки эссе стиленә көйләгәннәр. Җиңел дә кабул ителә, төпле анализ да җитәрлек. Икенче бер юл да бар. М. Вәлиев, мәсәлән, тәнкыйть мәкаләләрендә публицистик башлангычны көчәйтү аша укучы белән якын мөгамәлә урнаштырды. Заманча.

Әмма газета-журнал битләрендә укучыга тәкъдим ителгән күпчелек рецензияләр, тәнкыйть мәкаләләре бик примитив һәм дәлилсез. Шушы сыйфатларның барысын берьюлы үзендә туплаган бер генә язманы алыйк. Ул — Г. Садәнең «Җиләкле тәрәзәләр» китабына рецензия. (Кара: «Татарстан яшьләре», 1988, 27 март). Менә берничә өзек: «Анда йөз дә сигез шигырь тупланган...», «Җыентык «Бүгенге көн тагын матур булыр!», «Яңгыр җырлап узды», «Күңел тулы куаныч» дигән бүлекләрдән тора...» һ. б. Ә менә бу юлларны теләсә нинди шагыйрь иҗатына карата да кулланып була: «Ана һәм бала, туган йорт һәм туган туфрак, вакыт һәм көрәшкә багышланган гомер, кешелеклелек һәм чын ирлек, хәрәкәт һәм намуслы хезмәт, мәхәббәт һәм нәфрәт — менә шуны фәлсәфи төшенчәләр, категорияләр шагыйрьнең игътибарын җәлеп итәләр һәм аның иҗатының тематикасын билгелиләр».

Мондый «предметсыз» тәнкыйтьне, стандарт тематиканы (аңа әдәби әсәрләрдә күзәтелгән бөтен темалар да кереп беткән) гомуми рәвештә санап чыгуны бүгенге укучы кабул итми инде.

Эш бит шигырь җыентыкларына кергән шигырьләр санында яисә анда бирелгән бүлекләр күләмендә түгел. Бүгенге поэзия тәнкыйте һәм шагыйрьнең әдәбиятта тоткан урынын билгеләргә, аның иҗат манерасын ачыкларга, алдагы иҗат юлында отышлырак алымнарны төсмерләргә, шуның белән аңа ярдәм итәргә тиеш. Ә тегe яки бу шагыйрь иҗатының үзенчәлеген билгеләү өчен, аны тудырган поэтик традицияне, хәзерге яшәү, үсү мохитын, әдәби фонын күрсәтеп бирү сорала. Тематик анализ белән генә чикләнмичә, тарихи, социаль, социологик, психологик, фәлсәфи, поэтик анализ ясау сорала. Ягъни бүгенге тәнкыйтьче каләме әдәбиятның фундаменталь мәсьәләләрен яктырта белергә тиеш.

Шулай да, миңа калса, шагыйрь иҗатына бәя биргәндә, тәнкыйтьче иң элек шуңа игътибар итәргә тиеш: аның иҗатында заман тойгысы бармы? Бу таләп идея эчтәлегенә дә, сәнгатьчә осталыкка, әдәби формага да бердәй кагыла. Шушы күзлектән карaганда, бүгенге татар поэзиясенең алгы сафында кемнәр бара соң? Һичшиксез, М. Әгъләмов, Зөлфәт, К. Сибгатуллин, Р. Харис, Рәшит Әхмәтҗанов... Актуаль поэзиясе белән соңгы вакытта Х. Әюпов, Р. Зәйдуллин, Р. Юнысов, Н. Измайлова, Г. Моратовлар игътибарны җәлеп итте. Шул. Азрак шикелле.

Яшь шагыйрьләр белән хәл ничек тора? 80 еллар уртасында илебездә башланып киткән зур үзгәрешләр, хыялый, хәтта күпмедер бунтарь чынлык, тарихи оптимизм рухы әдәбиятка яңа шигъри буын бирергә тиеш иде кебек... Өметләр акланмады. Яңа, өметле исемнәр эзләп, яшьләр әдәбиятының көзгесе булырга тиешле «Идел» альманахының 1987 елгы санын актарам. Исемнәр күп. Әмма югарыда куелган таләп югарылыгында (заман тойгысы) булганнар берничә генә. Алары да ир уртасын узган кешеләр...

Булсын соң! Тарихи хакыйкатьне, тормыш хакыйкатен бүген ир уртасы кешеләр әйтергә тиештер, күрәсең.

Менә Хатыйп Касыймов иҗаты. Аның «Кадерен белеп кенә» дигән әсәрен укыганда авылда яралган җанның иң нечкә кыллары өзелеп китәрдәй булып тартыла; аларның оч-очларыннан кан саркып чыгар сыман...

*Анда еллар кар-буранга,*
*Салкыннарга бай иде.*
*Кыр тутырып иген иктек —*
*Тик буралар сай иде.*

Ындыр табагы тутырып иген алып та, икмәккә интеккән елларга ишарә бу.

Алга таба сурәтләр тагын ачыктыралар. Игенче оптимизмын, җир кешесенең психологиясен моннан да отышлырак итеп биреп була микән:

*Ярый әле ихтыярым*
*Көчле булган үйлардан.*
*Тәм таба белдем яшәүдән,*
*Кан тамса да куллардан...*

Күпчелек профессиональ әдипләр көнләшерлек иҗат бу!

Гомумән, «Идел»нең 1987 елгы саны алдагыларына караганда уңышлырак. Шигърияткә дә күбрәк урын бирелә бара (11 шагыйрь, 1986 елда өчәү генә иде), яңа исемнәр, кызыклы иҗатлар тәкъдим ителә. Иң мөһиме — поэзия актив гражданлык позициясенә баскан. Заман тойгысы сизелеп үскән. Бу хәл «Идел» шигъриятенең киләчәген өметле итә. Ул гына да түгел, «Идел» альманахыннан айлык журналга күчү чоры җитте шикелле. Ел саен бер тапкыр күренеп кала торган бу альманах кына яшь язучыларыбызның ачылып китүенә ярдәм итә алмый. Яшь тәнкыйтьчеләр өчен дә мәйдан тар. Газета-журнал редакцияләрендә оешкан «монополияләргә» үтеп кергәнче, аларның каләмнәре үтмәсләнеп, куәтләре суынып, дәртләре басылып өлгергән була. Һичшиксез, бүген яшьләрнең, һәвәскәрләрнең үз журналлары, үз мәйданнары, димәк, үз сүзләре булырга тиеш. Суга кермичә йөзәргә өйрәнеп булмый бит.

Әмма, шул ук вакытта, суга керү белән океан колачларга тырышуның да ямьсез нәтиҗәләргә алып килүен әйтәсе килә. Бер генә мисал.

«Казан утлары»ның 1988 елгы 3 нче санында Сәгыйть Хафизовның тәнкыйть мәкаләсе дөнья күргән иде. Бу язма журнал укучыларында каршылыклы фикерләр уятты. Юк, төрле шагыйрьләр иҗатыннан чүпләп алынган аерым шигъри юлларның охшашлыгы хакындагы фәлсәфәсе белән генә түгел. Теге яки бу шагыйрь иҗатыннан берничә юл алып, аны икенче бер шагыйрь әсәрендәге берничә юл белән чагыштырып карау үзе үк бернинди җитди тәнкыйть рамкасына сыймый. Чөнки һәр сурәт, һәр образ бары тик бөтен бер әсәр, бөтен бер иҗат контекстында гына карала ала. (Югыйсә, тарантас белән йөк арбасын тәгәрмәчләре түгәрәк булган өчен генә охшаш дип игълан итү кебек хәл килеп чыга). Иң кызыгы һәм кызганычы шунда: әле кайчан гына «елак» (ягъни хисси, моңлы, лирик) поэзиягә «каш җыерган» («Казан утлары», 1986 ел, 12 сан) С. Хафизов инде килеп фәлсәфи поэзияне пыран-заран китерә. «Акыл шигырендә сюжет, образ, картина юк,— дип белдерә.— Фәлсәфә ярдәмендә драматизм тудыру мөмкинлеге бөтенләй чикле», «Сәнгать законнарына артык буйсынмый верлибр...» — диюгә кадәр барып җитә тәнкыйтьче.

Әле бер ел элек кенә хисси шигърияткә шик белдергән әдәбиятчы инде килеп шул ук хис поэтикасын абсолютка менгереп куя. Ягъни ул, үзе дә сизмәстән, бер чиктән икенчесенә ташлана. Югыйсә әдәбиятның үсеш юлы, асыл сыйфатлары белән, иҗади процесс барышы белән аз гына таныш булган һәр кеше һич икеләнми әйтә ала: Зур Әдәбиятка традицион шигырь дә, иркле шигырь, верлибр да, актив гражданлык поэзиясе дә, интим-лирик шигърият тә, күтәренке шартлы романтик поэтика да, элегик аһәң дә бердәй дәрәҗәдә кирәк. Акыл да, хис тә, фәлсәфә дә кирәк. Х. Туфан шигърияттен генә алыйк. Ул үзенең иҗади фикерләве белән фәлсәфи шагыйрь. Әмма аның фәлсәфәсе интим-лирик настроениеләрне дә үзенә тирән сеңдергән. Поэзияне стандартка көйләргә тырышу, индивидуаль үзенчәлекләрне төп законнардан читкә тайпылу дип игълан итү татар поэзиясен инде ничә мәртәбәләр аянычлы хәлләргә китереп җиткерә язды. Шуны онытмыйк.

# ЫШАНЫЧ — ТАЛАНТЛАРДА!

Шигъриятебезнең бүгенге торышы, иҗтимагый абруе җәмәгатьчелекне канәгатьләндерәме?

— Юк, канәгатьләндерми.

— Бер-берсенең үкчәсенә басып килгән кимчелекләр әсәрләргә ябырылганмы?

— Ничек кенә әле!...

Мондый сорау һәм җавапларны әллә ни кадәр суза алыр идек. Әмма кимчелекләр санаудан гына: «Шигырь бүген әйдәп баручы көчен югалтты» дигән нәтиҗә чыгарырга ашыкмыйк. Юл барабыз. Алга барабыз. Ягъни каршылыклар эчендә кайныйбыз. Туарылдырып рәхәтләндерә торган билгесезлекләре һәм катлаулы каршылыклары көннән-көнгә кими барган, әкиятләрдәге юлдан түгел, ә һәр адымда мәсьәләләре катлаулана, глобальләшә барган юлда — тормыш дигән юлда без. Мондый юлда тормыш агышы китереп чыгарачак мәсьәләләрне чишүгә кешене эмоциональ-интеллектуаль, әхлакый әзерләү чараларының иң нәтиҗәлеләреннән берсе — бүгенге поэзия һәм гомумән әдәбият-сәнгать. Ягъни бурычлар катлаулану белән шигъриятнең дә базары күтәрелә булып чыга. Әйе, поэзияне, сәнгатьне югары накалда тота алырлык саллы сәбәпләр аз түгел безнең бүгенге көнебездә. Һәм бу ихтыяҗ, минемчә, телевизор тамашалары белән генә капланып калырлык түгел.

Бүгенге татар поэзиясе зур сынаулар кичерә. Җәмгыятебез, «үзгәртеп кору» дип аталган, тарих юлында сирәк очрый торган чорга килеп керде. Әдәбиятның да, тормышыбызның да, шәхеснең дә җитлеккәнлеге шул тарихи бурычларны үтәүгә өлгергәнлек дәрәҗәсе белән билгеләнә. Безнең шигъърият исә бу тарихи сынауга сафлары ныгыган хәлендә түгел, киресенчә, күп еллар буенча тәҗрибәле остаз да, акыллы җитәкче дә булып килгән лидерлары — Х. Туфан, С. Хәким кебек юл салучылары, киңәшчеләре дөньядан үткән көннәрендә килә. Ләкин шигъриятебезнең каушау төсмерләре күрсәткәне юк әле. Киресенчә, үзенә хас җитдилек һәм әшлеклелек белән, сизелерлек җанлылык күрсәтә ул, матур казанышлар дип бәяләнерлек әсәрләрне мәйданга чыгаруында дәвам итә.

Минә дискуссия материалларындагы «обоймаларда» исемнәре генә күренгәләгән ике яшь шагыйрь иҗаты — Ркаил Зәйдуллин һәм Ләис Зөлкарнәй. Алар үсмерлектән чыгып килгән көннәрендә — унҗиде яшьләрендә үк инде шигырь сөючеләр игътибарын казана алган иделәр. 1984 елда, әле студент көннәрендә, беренче җыентыклары дөнья күрде. Р. Зәйдуллинның картларча саллы-акыллы, зур поэзиябезгә хас рәвештә, ярсу кайнарлыклары күзгә бәрелеп тормаслык итеп яшерелгән, осталарча эшләнгән — «җырлап торган» шигырьләре... Җирлегеннән аерылган тал тамырының сагышлы гаме, күзләре дымлы булган карт этсез калган дөньяның моңы... һ. б. Яшь кенә егетнең кемгәдер иярмәстән, үзе тапкан — үзе иҗат иткән, моңлы да, гаҗәп кешелекле дә шигъърият дөньясы иң таләпчән укучыны да канәгатьләндергәндер.

Әмма аның шәриге Л. Зөлкарнәйнең беренче җыентыгына минем үземнең мөнәсәбәтем каршылыклы булды. Теге, үсмер шигырьләренә күбрәк гашыйк булганмын да, аңардан «фәлән дә фәлән»нәрне көткәнмен, күрәсең. Ә ул — катлаулы эзләнүләр ягына, мине борчыган авыр ассоциатив шигырьләр ягына авыша да тора. Юкса, эпоска ярашырлык, «космик», күңелгә шундый үз шигъри сурәтле строфалары бар бит үзенең:

*Кояш болыт салга ятып,*
*Офыктан китте агып,*
*Җилкәненең ал шәүләсе*
*Һаман бетми югалып...*

Шундый ике-өч строфадан торган «йөрәккә кабып», «ух» иттерерлек антологик шигырь көтәсең... Строфаның ике юлы — классик антологик шигырь, ике юлы алтынчы класс малаеның стенгазета язмасыннан алынган диярсең,— поэтик әзлеклелек югалган:

*Кояш ул минем кебек*
*Түгел йокы капчыгы —*
*Мендәрләрен җиллләтә*
*Офыкка алып чыгып.*

Шулай, төрле катламнарга үтеп, шигырьнең «җеп очын» югалтуларны күрәсең

дә, кәеф кырыла: «Талантың кайсы ноктада ачылып китте, шул кадакка сук инде син, туган»,— дип уфтанасың... Менә шулай бәхәсләшә-бәхәсләшә укып, бу егеткә хәтта бераз үпкәләп тә йөргән идем...

1988 елда бу егетләрнең яңа җыентыклары дөнья күрде. Л. Зөлкарнәйнең «Кар өстендә алмалар»ын кулга алам. Юк, ул җиңел юл сайламаган. Әмма егетләр үсә. Өч-дүрт ел арасында инде шигъриятнең Такташлар — Туфаннар камытына кергәләрлек тәҗрибә туплаганнар, тормыш каршылыклары белән бил алышып караганнар:

*...Күтәрергә теләп түгел,*
*«Батырам!» — дип,*
*Баш калкыткан саен,*
*Сукты саллы дулкын...*

Иҗатны кешелекле олы идеал өчен килешүсез көрәш авазы итү — тормышыбыздагы үзгәртеп кору авазы шул бит инде ул.

«Шәһәрдә яңгыр», «Дүңгәләк» циклы, «Осланда кояш», «Тәрәзәсе ватык купеда», «Айну» һ. б. тормышыбыз кебек мул, алмаздай балкыган образлар калейдоскобы. Аларда нәфис пәрәвездәй әсәрне челтәрләгән, күзгә төртеп тормый торган сызлаулы моң белән, олы, якты идеалларның шигъри синтезы. Болар — өлкән агайлар казанышлары белән ярышып яши алырлык, башкалар әле әйтә алмаган шигъри сүз — Ләис шигыре...

Ул 1988 елда Р. Зәйдуллинның да «Күрәзә» дигән яңа җыентыгы дөнья күрде. Ул катлаулы образлар эзләп интекми, иң гадәти сүзләрне югары накаллы шигырь итеп оештыруның серен белә. Күп еллар буена талкынып таушалган темаларга да газаплы борчылу, ачулы нәфрәт хисләрен йөкли. Менә Г. Тукайга багышлап язылган, «Кавышу» шигыре:

*Озак баралмассың, Озатырлар!*
*«Изге затка — зират. Ят, йокла».—*
*Кат-кат кабатлады «ят яраткан»*
*Төртеп екты аннан ястыкка.*

*Өлешенә тигән көмеше дип,*
*Кешнәп куйды шул чак тук мәйдан.*
*Һәр шигыре, һәрбер сүзе өчен*
*Түләү таләп итте Тукайдан.*

Тукай фаҗигасе, шагыйрь бөеклеге, обывательләрнең Тукайга мөнәсәбәте, ташка чокып язылгандай, чын сәнгать дәрәҗәсендә гәүдәләндерелә. Яшь шагыйрь тормыштагы сорылык, караңгылык, җансызлык күренешләренә каршы килешүсез көрәш позициясенә баскан.

«Хатирәләр», «Без очарга әзерләнгән идек», «Әрәмәлек», «Ана», «Ностальгия» һ. б. кебек фәлсәфи уйланулы әсәрләре дә шундый ук, көйрәп торган шигъри юллардан төзелгән. Башка әсәрләре дә шул югарылыкка якын.

Мондый казанышларны танымау мөмкин түгел, күрмәмешкә салынып үтеп китеп кенә була. Л. Зөлкарнәй шигырьләре кебек үк, Р. Зәйдуллин әсәрләре дә үзләренең эзләнү, тәҗрибә җимеше иканлекләрен әллә кайдан ук искәртеп торалар. Бу үзенчәлекләре — киләчәктә авторларны көткән тагын да зуррак, күләмлерәк поэтик ачышларның юл маяклары, хәбәрчеләреме, әллә шагыйрьләрнең стиль үзенчәлеге генәме — анысын вакыт күрсәтер.

Бүгенге шигъриятебезнең алгы сызыгында атлаган М. Әгъләмов һәм Зөлфәт беренче адымнарыннан ук экспериментлар белән әллә ни мавыктырмадылар. Ритмик чуарлыкларга мөнәсәбәттә, чатаклыкларга карата сизгерлектә, Тукай, Такташ, Туфаннар традициясенә турылыклы булдылар. Бу сыйфатның җиңел генә бирелмәгәнен, кыйммәт бәягә килгәнен аларның иҗат язмышларында да күреп була. Әмма алар кыенлыкларга бирешмәстән, үзләренең шагыйрьлек бурычларына турылыклы калып киләләр. Соңгы, сынаулы елларда бу шагыйрьләр дә яңа иҗади югарылыклар яуладылар дип әйтергә нигез бар. Аларның бу казанышлары да үзгәртеп кору процессы белән бәйле икәне бәхәс уятмаска кирәк.

Бүгенге шигъриятебез симфониясендә Зөлфәт авазы шактый еллар ишетелмичәрәк торды. Әмма соңгы вакытларда газета-журнал битләрендә күренгән әсәрләре шагыйрьнең таланты сүрелмәгәнен, тоныкланмаганын, яңадан ялкынлануын искәртәләр. Дөрес, элеккеге күп буяулы, давыллы-өермәле шигырьләр урынына без хәзер кырык яшен тутырган ир затка хас рәвештә, җитди һәм берникадәр басынкы, сабыр дулкынланулы уйланулар белән очрашабыз:

*Кузы Көрпәч белән Баянсылу*
*Каберенә бүген тез чүктем.*
*Бөек итеп яратырга, ахры,*
*Соңардым мин, артык кичектем!..*

Рухларны пакьләүче тылсымлы көч, поэтик камиллек, самимилек Мөдәррис Әгъләмов иҗатында да югары, илһами накалда дәвам иткәнен күрәбез. 1987 елда аның шигъри энҗеләрдән тезелгән дип әйтерлек «Киләчәккә кайту» дигән балладалар, поэмалар җыентыгы дөнья күрде. «Тукайдан хатлар» поэмасы поэзиябезнең яңа зур казанышы булып яңгырады:

*...Курку белмәс кыю Курсавиның*
*Юлларыннан китәр һәр сабыйның,*
*Сулыш юлларына баса-баса*
*Егерменче гасыр якынлаша.*

*Җирдә апрель... Язгы тантана...*
*Россия — йорт. Түбә кыегында*
*Боз сөңгеләр, аннан — кан тама...*

Кеше язмышы, халкыбыз язмышы гына түгел, ил тарихының каршылыклы глобаль күренеше, аның мәгънәсе һәм аңа мөнәсәбәт һ. б. иң гадәти берничә юл шигырьгә сыйдырылган. Бу юллар гына түгел, поэма бөтенләе белән шундый сыйдырышлы, афоризмнардай яңгырашлы, камил дә, нәфис тә шигъри җөмләләрдән тора.

*Башкаларга акча булып кына*
*Агып бара хезмәт көндәгечә...*

Лирикага әйләндерелгән тарихи халәтнең сурәтләре (соңгы цитатада, политэкономия дә бар), ярсу кайнарлыклар, ачыргаланулы, өзгәләнүле фәлсәфи-поэтик ачышлар. Болар әдәбият тарихында көн дә кабатлана торган нәрсә түгел.

Күптән түгел шагыйрь илебезнең 30—80 нче еллар тормышын чагылдырган «Заман язган язмыш» дигән яңа баллада иҗат итте. Чорның катлаулылыгы һәм авырлыклары да, тормыш һәм шәхес язмышы да, кеше кичерешләренең күп төрлелеге һәм тирән фәлсәфи уйланулар, гомумиләштерүләр дә зур булмаган менә шушы бер шигъри әсәргә сыйган. Моңардан ул әсәрнең шигърилек табигате һәм функциясе зарар күрмәгән генә түгел, ә киресенчә, мул бизәклелек, күп төсләр белән балку, җанлылык, дәртлелек кебек сыйфатлары үткенәя генә төшкән. Мондый зур уңышларга ирешүнең сере, аларга илткән тылсымлы көч бер генә: олы идеаллар һәм чын тарихи прогресс өчен көрәшне үзеңнең яшәү рәвешең итә белү! Ягъни үзгәртеп кору чоры бездән көткән, бездән сораган сыйфат!

Менә тагын бер чын шагыйрь, зур шагыйрь — Рәшит Әхмәтҗанов. Аның уңай бәя алган «Бишташ» поэмасында менә мондый юллар бар:

*Утырам ташлар өстендә,*
*Күздә яшь яңа кипкән.*
*Кулмәкне, ашар икмәкне*
*Сугышлар талап киткән.*

*Шатлыгым — «бишташ» уены.*
*Ә кайгым — ачлык, ачлык.*

*Ачлыктан котылу өчен*
*Урманга кереп качтык.*

*Урманнан чыкканчы, кайгы*
*Таш булып калган катып...*
*Ташлар өстендә утыра*
*Балачак чәчәк атып.*

Сугыш чоры сабыйлары балачагының лирик сурәтен, кешелекнең әле шыткан гына орлыкларында да шундый героик чыдамлылыгын моннан да төгәлрәк һәм гүзәлрәк итеп әйткән шагыйрь безнең әдәбиятта моңарчы булдымы икән?

*...Бездә яши шундый бер өстенлек*
*Уттан алда мөмкин балкырга.*
*Бөек халкым — давыл кочагында,*
*Минем җаным шунда — Халкымда!*

Әйе, безнең шигъриятнең тормышчанлыгы да шунда: ул героика җыры, көрәш чакыруы, көрәш гөрелтесе, көрәш коралы, көрәш җимеше!

Әйе, бүгенге поэзиябезнең шактый гына казанышлары бар. Шулай ук аның яңачалык җитешмәү, фикерләүдәге торгынлык, дөньяны һәм кеше рухын сурәтләүдә кыюсызлык кебек кимчелекләре дә юк түгел. Әмма болары тулаем поэзиягә хас күренеш түгел, аерым авторларга, бәлки аерым төркемнәргә генә хас чир. Шигъриятнең дәрәҗәсе нинди чирләр барлыгы белән түгел, беренче чиратта, ирешелгән, күрсәтә алган казанышлары белән билгеләнә.

Мәсгут ГАЙНЕТДИНОВ.

## МӨГАМӘЛӘ ТУРЫНДА

Китапларның сатылмавын автордан, я сатучылардан күрәләр, шуны исбат итмәкче булалар. Мактанып әйтү түгел, ничә елга бер мәртәбә юка гына булып чыккан китапчыкларымның мин бер генә данәсен республиканың бер генә районыннан да соратып таба алмадым. Дусларыма, туганнарга хәтта бүләк итә алмадым. Ә бит кемнәрнеңдер китаплары тузанга күмелеп магазин яки складларда ята. Китап бастыру өлкәсендә нәшриятка менә шуны искә алып эш итәргә иде. Халык таләбен истә тотып эшләгәндә тормышыбыз матурлана барып, партиябез алга куйган бурычлар тизрәк үтәлер.

Ни өчен В. Высоцкий исән вакытында бер генә шигырен дә матбугатта бастыра алмады? Ә соңыннан инде калын китабы чыкты һәм аның исеме пароходларга бирелде? Бу сорауны мин узган ел Мәскәүдә булган чагымда кайбер язучыларга да бирдем. Ләкин төгәл җавап ишетмәдем. Кайберәүләр: «Мөгамәлә шундый иде», генә диделәр. Ә бит ул «Мөгамәләне» кем тудыра?

*Агач башын җил борыр,*
*Адәм башын сүз борыр,*

дип бик урынлы әйтелгән данлы «Идегәй» әсәрендә. Безнең заманда кайберәүләр акны кара дип, һәм киресенчә исбат итәргә тырышып әнә шулай адәм башын боралар, бутыйлар. Яки менә талантлы композитор Сара Садыйкованы ни өчен җитмеш яшенә кадәр союз члены дип йөртә алмадык, үзешчән дип атадык?

Һәр өлкәдә яңача уйларга, яңача фикер йөртергә, яңача эшләргә кирәк. Моны «үзебездән башларга кирәк» дип көн дә кабатлыйбыз. Ләкин сүздән ерак китә алмыйбыз.

**Рамазан БАЙТИМЕРОВ.**

*Бәхәскә укучы кушыла*

## КАРА КҮМЕР КАЛМАСЫН!

Г. Рәхимнең 6 санда (1988 ел) басылган мәкаләсе турында әйтергә телим. Р. Харисның «Шигырь турында шигырь» дигән әсәрен бу язма авторына кабат укып чыгарга кирәк булгандыр. Анда «шигырь — күңел чәчәге генә түгел» дип язылган ләбаса, ә язманың авторы шагыйрьне күңел чәчәге дип әйтмәүдә гаепли.

Әгәр авторның анализ методы белән эш итсәк (ул болай ди: «билгеле булганча кешенең канынннан бик аз микъдарда гына тимер алып була, димәк, ул тимердән микроскопик каләм дә ясап булмый... Хакыйкатьне бозып күрсәтү аркасында бу образ җитди кабул ителми») кеше организмында күңел дигән орган кайда, аннан, ягъни кешенең кай җиреннән чәчәк үсеп чыга?

Бу кадәрле тырышып лириканы тирес белән бутасак халык җырларыннан ни калыр иде?

Без начар якларны тормыштан эзләргә өйрәнеп киттек бугай. Начар якны табу, күрә белү бер дә авыр түгел, яхшыны күрә һәм күрсәтә белергә кирәк. Миңа, мәсәлән, беркайчан да «Бакчачыга» шигыре кысыр ботак белән тулган мескен алмагач булып, «Кыска җил» — тыныч төндә аза кубып көн эзләүче рәвешендә күренгәне юк. Бәлки аларны һәркем үзенчә аңлыйдыр?

Шулайдыр!

Бу язманы укыгач күршем Зәйнәп апаның сугыш елларында каенанасы белән авыр торганын сөйләгәне исемә төште. «Керне атнага бер юсам — ялкау дип, көн дә юсам — сабын бетерәсең»,— дип сүгә иде бианам, дип искә ала иде ул.

Шигырь язучылар күп булса да, шагыйрьләр күп түгел безнең. Журнал аларга саграк карасын иде. Бу язмадагы алымнар белән дәвам итсәгез, шигърияттән кара күмер калырга мөмкин.

**Л. НУРЕТДИНОВА,**
Сарман.

# ӘДӘБИЯТ ТУРЫНДА СӨЙЛИК!

«Казан утлары» журналы — әдәби-нәфис һәм иҗтимагый-политик журнал. Шуңа күрә, әдәби әсәрләр, әйе-әйе, иң беренче чиратта әдәби әсәрләр укырмын дип ачам мин аның битләрен һәм, журналны укучы буларак, аның турында үз фикеремне әйтергә уйлыйм.

Журналның тәнкыйть бүлегендә бәхәс бара. 1988 елгы икенче санда шагыйрь Марс Шабаевның «Тәшсез чикләвекләр...» исемле мәкаләсе дә чыкты. Тик бу мәкалә әдәби тәнкыйть тә, әдәби әсәр турындагы бәхәс тә түгел. Сүз бары тик Язучылар союзындагы һәм нәшрияттагы җитешсезлекләр турында, үзешчән авторлардан ничек котылырга белмәү турында бара. Дөресрәге — үзешчәннәрне яманлауга корылган мәкалә бу.

Мәкаләнең авторы Илдар Юзеевны юмартлыкта, Шәүкәт Галиевне тиешсез кешенең китабын бастырып чыгаруда, Аяз Гыйләҗевне тиешсез кешене Язучылар союзына кабул итүдә гаепле саный. Шуның нәтиҗәсендә башка сәләтсезләр дә Союзга үрмәлиләр, язучы һөнәренең абруе җуела бара, ди. Сорау туа, нигә бу мәсьәләне коллектив җыелышына куймаска? Куелган, тикшерелгән булса, артык сүз ясап, журналга чыгаруның ни кирәге бар?

Бәхәс булса, бәхәс тә әдәби әсәр турында булырга тиештер. Әгәр тәнкыйть булса, ул әдәби әсәргә анализ ясарга, теге яки бу әсәрне нәрсә яхшы яки начар иткәне ачыкланырга тиеш. Әнә шундый мәкалә яшь язучыларга файдалы булыр иде.

Мәкаләнең авторы сигез йөз яшь язучы турында сүз алып бара. Шул сигез йөз яшь язучы арасыннан сәләтле яшьләр бармак белән генә санарлык, калганнары картлар, сәләтсез үзешчәннәр, һәм әдәбиятны чүпләү хисабына шул үзешчәннәргә бик күп дәүләт акчасы туздырыла, ди. Аларны теге язучы тегеләй, бу язучы болай атаган дип, мәкаләдә аларга карата бик күп исемнәр дә куллана: графоманнар, һәвәскәрләр, үзешчәннәр, мөтәшагыйрьләр, язу җене кагылганнар, сукыр черкиләр, мәчет картлары, мүкләкләр, бәхетсез җаннар, лилипутлар. Күрдегезме, профессионал булмагач, никадәр исем күтәрергә туры килә икән аларга!

Кемнәр соң алар әнә шундый исем күтәреп йөрүчеләр?

Газета-журналлардан, үзләренең китапларын укып (аларның китапларын чыгару очрагы бик сирәк) белүем буенча, алар да шул ук язучылар. Тик алар Язучылар союзында әгъза түгел, нәшриятта да эшләмиләр, профессионал дигән исемнәре дә юк. Алар колхозларда, заводларда, мәктәпләрдә эшлиләр, кайберләре хәрби хезмәттә, һәм алар үзләренең төп эшләреннән башка язучылык эшенә дә бирелгән кешеләр. Алар һәвәскәр түгел, һәвәскәр автор булмый. Үзе яңа әсәр иҗат иткән кеше автор гына була.

Мин укытучы кеше. Үзешчән авторларның шигырь китапларын да укырга туры килгәне бар. «Кызлар җыры», «Беренче карлыгачлар» кебек күмәк җыентыкларны да укыганым бар, мәгәр берсендә дә яманларлык шигырьләр очратканымны хәтерләмим.

**Габдулла МОЗАФИН,**
Казан.




# ЯҢА СҮЗЛЕК

Бу сүзлекне җәмәгатьчелек күптән көтә иде. Чөнки 1966 елда Мәскәүдә чыккан «Татарча-русча сүзлек» сирәк китапларның берсенә әйләнгән иде инде. Егерме ел эчендә телнең сүзлек составында да үзгәрешләр булган, сүзлек төзүчеләребезнең дә, гомумән, лексикография фәненең дә тәҗрибәсе арта төшкән.

Яңа «Татарча-русча сүзлек» авторларының (Ф. Ә. Ганиев, И. А. Абдуллин, М. Г. Мөхәммәдиев, Р. Г. Юналиева) һәм редакторының (Ф. Ә. Ганиев) исемнәре фәнни җәмәгатьчелеккә яхшы таныш. Аларның һәрберсе «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»н төзүдә катнашып, татар һәм төрки тел белеменең актуаль мәсьәләләрен хәл итешә килеп, зур тәҗрибә туплаган галимнәр.

Татарча-русча сүзлекләр төзүнең берничә йөз еллык тәҗрибәсен файдаланып төзелгән бу басманың нигезен алда әйтелгән «Аңлатмалы сүзлек» тәшкил итә. Анда исә актив кулланылыштагы 25 меңгә якын сүз теркәлгән.

Сүзлек киң катлам укучыларга атап чыгарылган, ул һәрвакыт кул астындагы китап булачак. Төп максаты исә — татар сүзләренең русчага дөрес һәм төгәл тәрҗемәсен бирү. Шуның белән рәттән анда сүзләрнең грамматик һәм мәгънәви табигатен һәм билгеле беренче сүзе кергән фразеологик берәмлекләрне теркәү дә күз алдында тотылган.

Сүзлеккә киң кулланылыштагы актив лексика тупланган. Алдагы сүзлекләрдә булган кайбер искергән сүзләр төшереп калдырылган. Шактый гына яңа сүзләр дә өстәлгән. Иҗтимагый тормышка чагыштырмача яңарак килеп кергән: исәпләү машинасы, лавсан, кримплен, поролон, остазлык, яңарыш, коллектив подряд, компьютер, рентабельле, кубәйтү аппараты, хәбәрдарлык, торгынлык, үзидарә кебек сүзләр дә урын алган.

Яңа сүзлекнең бер уңышлы ягы итеп анда фразеологик берәмлекләр күплеген күрсәтергә мөмкин. Аерым сүзләрнең фразеологиясе аеруча бай. Мисал өчен: авыз, авыр, акыл, ачу, аяк, баш, күз, тамак, тын, ике, төп, төн, тел, йөрәк, кул һ. б. сүзләр кергән фразеологизмнар анда бик мул бирелгән.

Сүзлек татар теле турында гына түгел, татар халкының тарихы, гореф-гадәтләре, культурасы, аш-суы, милли бәйрәмнәре, дини ышанулары һ. б. турында да мәгълүмат туплаган. Төзүчеләр аерым төшенчәләрне русча җыйнак аңлатма рәвешендә бирә барганнар. Мәсәлән, дөлдөл, Питрау, Покрау, чәкчәк, сират күпере, әдрәс, әлбә, әлиф, җыен һ. б. төшенчәләрнең тәрҗемәсе шундый.

Әдәби телебезнең баю, камилләшү чыганакларыннан берсе дип татар теленең диалектлары һәм аерым сөйләшләре санала. Сүзлектә диалекталь сүзләр шактый теркәлгән. Алар арасында инде күптән әдәби телебездә актив кулланылышта йөргәннәре дә бар. Мәсәлән: болгавыр, катканак, коен яңгыр, колакай, комаяк, корык, кулагай, кылау, кысланкы, кәй, кукшел, күлдәвек, тигенгә, тигәнә, тудык, тудыка, тәү, төмсә, пима, төнәгән, пырдымсыз, төпкел, төрчә, мокыт, ыктымат һ. б.

Күп сүзләрнең диалекталь чыгышы күрсәтелмәгән. Димәк, төзүчеләр, нигездә урта диалекттан кергән бу сүзләрне әдәби тел лексикасына тулысынча кереп беткән дип санаганнар: көлчә, кәшәкә, беркавым, күренде, күзләвек, күлләвек, тоҗым, мәл, онта һ. б. Шулай да әдәби телебездә урын алырдай кайбер диалекталь сүзләрнең яки мәгънәләрнең әле керми калуын да күрсәтеп үтик: мәсәлән, кылтаерга (кыланчыкланырга), кондырак, калгырга һ. б.

Сүзлек белән танышу тагын бер фикергә китерә. Без бик күп сүзләребезне оныта барабыз икән, булганнарын саклый белмибез, аларны яңа сүзләр һәм алынмалар белән алыштырабыз. Катаракта сүзе кергәнче халыкта кылау сүзе йөргән икән; франт сүзе урынына бездә кәрбәз сүзен кулланганнар; каштан — кәстәнә булган икән, капюшон — дигәнебез көрәпәлә булган икән; цикорий урынына күнаяк, һиндыба дигәнбез; акула дигәнебез күпек балыгы дип йөртелгән; креслога күшек дигәннәр. Инде тире урынына да мех дия башлаганбыз. Засада урынына элек поскын, осетр урынына бикрә дигән сүзләр кулланылганнар.

Моңа хәтле чыккан сүзлекләрдән аермалы буларак, сүзлек үзенең яңача төзелүе белән дә игътибарны җәлеп итә. Иң зур яңалыклардан берсе: фигыль төп формасы инфинитив (-рга, ргә) белән бирелгән. Үзенең мәгънәсе һәм кулланылышы ягыннан ул тулы-

сынча рус инфинитивына тәңгәл килә.

Ә моңа кадәр чыккан татар сүзлекләрендә фигыль инфинитивның -мак, -мәк формасы, икенче зат боерык фигыль формасы (фигыль тамыры), исем фигыль формалары белән билгеләнеп килгән. Хәзерге татар кешесенең аңында -у-ү формалы фигыльләр саф фигыль формалары булып түгел, исем фигыль буларак кабул ителәләр. Шуңа күрә сүзлек төзүчеләрнең һәм редакторның күпчелек төрки тел сүзлекләрендә кулланыла торган инфинитив формасын алуы, бәлки, үзен аклыйдыр да.

Сүзлекнең икенче яңалыгы шуннан гыйбарәт: анда беренче тапкыр буларак лексик берәмлекләргә морфологик характеристика бирелә, ягъни теге яки бу сүзнең кайсы сүз төркеменә каравы күрсәтелә. Бу — бик әһәмиятле, катлаулы һәм җаваплы мәсьәлә. Сүзлек төзүчеләр, нигездә, аны уңышлы һәм фәнни яктан дөрес хәл иткәннәр. Төрки телләрдә, шул исәптән татар телендә, сүзнең формаль яктан билгеле бер сүз төркеменә каравы шактый кыен билгеләнә. Ә сүзлек төзүчеләр биргән грамматик характеристика туган телне укыту процессында һәрвакыт кирәк булып тора.

Сүзлектә шактый күп сүзләр беренче тапкыр хәбәрлек (предикатив) сүзләргә кертеп каралганнар. Алар арасында әйе, юк, бар, харам, хәтәр, хөрти, хәзер, хозур, тиеш һ. б. күрсәтергә була.

Сүзлекнең тагын бер үзенчәлекле ягын билгеләп үтик. 1966 елгы сүзлектән аермалы буларак, сүзләрнең мәгънәви характеристикасы анда тагын да камилләшкән, мәгънәләре ачыкланган, баеган, төгәлсезлекләр бетерелгән. Аерым сүзләрнең мәгънәләре шактый күп күрсәтелгән. Әйтик аерырга, аерылырга сүзләренең 15 мәгънәсе, алырга сүзенең 23 мәгънәсе, баш сүзенең — 15, барырга сүзенең — 16, килергә — 14, кара сүзенең — 13, кисәргә сүзенең — 15, корырга сүзенең — 10, салырга сүзенең — 27, сугарга сүзенең — 17, торырга сүзенең — 14, тотарга сүзенең — 17, төп сүзенең — 17, төшерергә сүзенең — 19, төшәргә сүзенең — 24, чыгарга сүзенең — 21 һ. б. мәгънәсе теркәлгән.

Сүзлек белән танышкач, укучы тагын бер яңалыкка игътибар итәр дип уйлыйбыз. Тезмә сүзләр һәм фразеологик төзелмәләр төгәл аерылган һәм соңгылары искиткеч бай бирелгән. Ә моңа кадәр алар катнаштырып бирелә иде. Яңа сүзлектә сүзлек мәкаләсе өч кисәктән тора; баш сүз бирелә, аның мәгънәләре теркәлә, аннан тезмәләр китерелә, шуннан соң фразеология теркәлә.

Күп сүзләргә стилистик характеристика да төгәл бирелгән. Сирәк очракларда гына кайбер шик уянып куя. Әйтик, күрекле, күреклесез сүзләренә «диалектальь» дигән искәрмә бирелгән; риваять сүзенең дә «искергән» дигән искәрмәсе белән килешәсе килми; хосусан, хосусән сүзләрен дә рәвеш кенә дип әйтеп булмас иде, алар күбесенчә кереш сүз буларак кулланылалар. Югыйсә, юкса сүзләре дә теркәгеч итеп каралган, гәрчә алар үзләренең бөтен хасияте белән мөнәсәбәтле сүзләр рәтеннән саналалар. Өстәвенә сүзе рәвеш дип бирелгән, теркәгеч сүз дип әйтү дөресрәк булыр иде.

Төзүчеләр телара сүзлекләр өчен тагын бер яңалык кертеннәр. Рус һәм татар сүзләренең омоним очракларында к, г янына калынлык билгесе өстәп, тирән тел арты авазларын биргәннәр: аркъа — арка, болгъар — болгар, казакъ — казак, къарта — карта һ. б. Орфографиянең хәзерге хәлендә бу нәрсә татар сүзләренең яңгырашын күзалларга мөмкинлек бирә.

Сүзлек телебездә қ, ғ авазларын бирү өчен хәрефләр кирәк икәнен тагын бер кат искәртә. Бер генә мисал: комказыгыч дип укып китәсең, шуннан соң алфавит буенча комкор килә. Ничек укырга? Қомқор дипме, әллә язылганчамы? Аннан соң комкорсак (пескарь) китә. Анысын ничек укырга: қомқорсақ дипме, әллә язылганчамы? Шуны сизептер, алга таба сүзлектә җәяләр эчендә татар сүзләренең татарча әйтелеше бирелә: кон (къон) һ. б.

Орфографиягә бәйле тагын бер момент. Телебездә рус теленнән калькалаштырып шактый сүзләр ясалган. Шулардан бер ишесе к ү п сүзе белән формалаша. Матбугат битләрендә алар еш очрый һәм язуда төрлелек яшәп килә; к ү п сүзенә иллюстрация биргәндә, төзүчеләр бу мәсьәләне дә хәл иткәннәр — аны икенче тамырдан аерым биргәннәр: күп миллионлы, күп милләтле, күп санлы һ. б. Баш сүз буларак тасвирлаганда бу принцип сакланмаганын да күрсәтеп үтик.

Аерым сүзләрнең сүзлектә язылу рәвеше белән бәхәсләшергә дә мөмкин булыр иде. Әйтик, чөлли — чүлли түгелме? Локма сүзе дә лыкма дип (бер лыкма ризык капканым юк) әйтелми микән?

Сүзлекнең тагын бер үзенчәлеген күрсәтергә мөмкин. Анда телдәге төп сүзләр генә түгел, ә сөйләмдәге кайбер регуляр формалар да теркәлгән. Дөрес, күбесе лексикалашкан хәлдә яши. Мәсәлән: агар, исемле, исемендәге, нишләмәк, сап-салкын, сап-сары һ. б. Әмма алар сүзлеккә рус телендә теге яки бу яңа лексик берәмлек булып тәрҗемә ителгән очракта гына кертелгәннәр.

Сүзлек татар теле белән эш итүче галимнәр тарафыннан төзелгән. Татарча мәгънәләрне рус теленә тәрҗемә итүне бары мондый галимнәр генә төгәл эшли ала. Шулай да аерым очракларда рус теле белгеченең дә кулы керсен иде дигән теләк уяна. Мәсәлән, кышлау сүзе белән китерелгән тезмәдә «з и м о в а л о е домашнее животное» диелгән. Мичкә сүзенә китерелгән мисалда «ложка д е г т ю в бочке меда» дип теркәлгән. Орып сүзе л и в м я дип тәрҗемә ителгән, ләкин бу сүз рус телендә үзе генә

кулланылмый, «ә л и в м я л ь е т» рәвешендә йөри. Бурлы сүзе гнедочалый дип, ә ненке каен диган сүзтезмә «береза повислая» дип тәрҗемә ителгән: лаякыл сүзе вдребезги дип тәрҗемә ителгән, исерек булу сүзе белән бергә килеп, ул «быть пьяным вдрызг» рәвешендә йөри кебек. Сакау кешене дә картавый дип тәрҗемә итү дөрес булмастыр. Тарихилык та историчность түгел, ә историзм булмыймы икән?.. Нәсер сүзе проза в стихах диелгән, белүемчә, стихотворение в прозе дип йөриләр иде элек.

Сүзлек белән танышканда, күңелгә тигән тагын бер күренешне әйтер идем. Аерым сүзләрне караганда, төзүчеләр аның тәрҗемәсен бирмичә, икенче сүзгә җибәрәләр. Арчырга дигән сүзне карыйсың, ә сине әрчергә дигән сүзне карарга җибәрәләр. Асат дигән сүзне карыйсың, аның русчага ничек тәрҗемә ителәсен беләсең килсә, ансат сүзен карарга кирәк. Фән өчен бу әһәмиятле, ә практик куллануда уңайсызлык тудырмас микән?

Кайбер очракларда актив кулланылыштан төшкән сүзләрнең мәгънәсен аңлау өчен иллюстратив фразеология дә җитеп бетмәгән кебек. Әйтик, кавырсын сүзе. Кавырсыны да катмаган дигән фразеология бар бит. Кәлимә сүзе — бер кәлимә сүз дә әйтмәү, күтәрәм сүзе — күтәрәмгә калырга дигән фразеологияне искә төшерә. Сырларга сүзенең бизәү мәгънәсен сырлап тормаска кебек тезмәдә биреп булыр иде кебек. Сәрпинкә сүзенең мәгънәсе дә сәрпинкә яулык тезмәсендә ачыграк чагылыр иде. Чуак сүзенең мәгънәсе дә телебездә әбиләр чуагы дигән тезмәдә генә сакланып калган, ә ул тезмә китерелмәгән. Чиру сүзе дә Кырым чирүе хәтле тезмәсендә сакланып калган бит.

Сүзлектә күп телләрнең һәм халыкларның татарча-русча атамалары бирелгән. Бу бик кирәк. Тик кайберләренең урын алмавын да искәртеп китәргә мөмкин: молдаван, швед, шотланд, эвенк, эрзя, эфиоп һ. б. Кайбер очракларда аларның язылышы буенча икеләнеп тә калырга туры килә: португалмы әллә португальмы, уйгурмы — уйгырмы, корей телеме, әллә корея телеме?

Кайбер урыннарда русча сүзлек нигез булган кебек тәэсир дә кала. Әйтик, татарларда белоручка мәгънәсендәге «ак кул» юк. Адашкан пуля да рустан кергән — шальная пуля-дан. Алтын күз дә рус теле аша кергән. Ба дигән ымлыкны да руслар әйтә. Кисет сүзен дә тәмәке янчыгы дигән сүзебез барында кертергә микән? Кисея сүзенең дә татарча өрфия дигән матур эквиваленты бар. Хай ымлыгы да татарныкы түгелдер. Авыру баштан сәламәт башка — бусы да руслардагы «с больной головы на здоровую» дигән фразеологизмның калькасы бит.

Сүзлек нормативлык функциясен дә үтәячәк дип уйлыйбыз. Шуңа күрә сүзнең дөрес язылышын күрсәтү дә әһәмиятле һәм сүзлек бу функцияне тулысынча үти ала. Күптән кабул ителгән кайбер рус сүзләренең (мәсәлән, самавыр, гармун, карават һ. б.) татарча фонетик үзләштерелгән вариантын китерү, әлбәттә, дөрес. Бәхәсле язылыш: инкяр — инкарь формаларының беренчесе алынуын да билгеләп үтик. Әмма фидакарь сүзенең язылышы инкяр сүзе кебек үк булса да, ни өчендер элеккеге язылыш сакланган.

Сүзләрнең мәгънәләре татарча һәм русча төгәл билгеләнгән. Телне нечкә тоюны таләп итә торган бу катлаулы эшне төзүчеләр, редакторлар югары фәнни-теоретик дәрәҗәдә башкарып чыкканнар.

Сүзлектә бирелгән кайбер сүзләрнең телдә актив яшәвен күзалдына китерүе кыен. Әлбәттә, бу мисаллар булмаудандыр. Ә сүзлекнең күләмен һаман кыса килгәннәр. Мәсәлән, агачсыл, агаччыл, агит-масса, иртәлек (утренник), параличланырга, озаккача һ. б. сүзләр контекст эчендә төгәлрәк кабул ителерләр иде.

Кинәт искә төшеп киткән сүзләрне табар өчен, мин сүзлекне күп тапкырлар ачып карадым. Нигездә сүзне эзләп аның мәгънәләрен таба алуыма шатлана-шатлана укыдым. Шулай да кайбер сүзләр урын алмаган икән әле: интернат, мәктәп, шәфкать туташы, әшерәшер, хуҗабикә, чукынган, алагаемга, ат алу, аннан, анда, башлам, билгелелек, бетем, чыр (итеп кычкыру), төррә (сарык куганда) һ. б. Ә бит бу сүзләрне без шактый еш кулланабыз.

Кайбер алынма гарәп-фарсы сүзләрен дә сүзлектән табып булмады. Әйтик, матбага, мәкам, мәрхүмә, мөгаллим, мөхтәрәмә, нашир, хәтем кылу, шәех һ. б. сүзләр.

Телебездә рус һәм рус теле аша Көнбатыш Европа телләреннән кергән йөзләгән алынма яши. Бу сүзлектә дә алар шактый урын алып торалар. 1966 елдагы сүзлек белән чагыштырганда, аларның саны кимегән: тар кулланылыштагылары төшеп калган. Һәм бу дөрес тә, чөнки яңа сүзлек актив кулланылыштагы сүзләрне генә бирүне максат итеп куйган. Кызганычка каршы, сүзлектә әлеге дә баягы алдан билгеләнгән күләмне арттырмас өчен, актив кулланылып йөргән кайбер рус алынмалары теркәлмәгәннәр. Мәсәлән, вакансия, мандарин, химикат, хроника, шампунь, шашлык һ. б. байтак сүзләрне алыштырырдай сүзләр бездә юк. Алар телдә ныклы урын алганнар һәм сүзлектә аларның булуы кирәк иде.

Шул ук вакытта аерым фонетик диалектизмнарны, әдәби телдә синоним варианты булганнарын кертүнең хаҗәте бар микән? Әйтик, кәмә (диал. көймә), кәнди — кәнти (савыт), комак (кумак), кулса (кольцо), өке (мәче башлы ябалак), өлгәшергә (өлгерергә), өлтерәп торырга (кунакчыл булырга) һ. б. Кайчак бик искергән сүзләр дә урын ала төсле: тәнбиһ (предупреждение), фөкарә (бедняки), тимсах (крокодил) кебек сүзләрне күз алдында тотып әйтүем.

Бу сүзлеккә кызыклы ике кушымта да бирелгән. Шуларның берсе — Татарстан АССРның географик атамалары исемлеге. Анда торак пунктлары, күл, елга исемнәре тупланган һәм аларның русчасы бирелгән. Шул рәвешле бирү бик кирәк иде, юкса авылларыбызның исемнәре гел русчага күчеп бара бит. Әле җитмәсә матбугатта колхоз-совхоз исемнәреннән башка авыл исемнәрен бөтенләй дә күрми башлаган идек. Авыл исемнәренең болай беркетелеп калуы тарих өчен дә әһәмиятле.

Сүзлекнең практик әһәмиятен арттыра торган тагын икенче кушымта бар. Бусында актив кулланыла торган татар исемнәре тупланган һәм аларның русчага транслитерациясе бирелгән.

Сүзлекне редакцияләү эшендә нәшрият редакторлары Р. Юнысов һәм Д. Шакировның да хезмәтләрен билгеләп үтәргә кирәк.

«Татарча-русча сүзлек» укучылар кулына килеп керде. Туган телебезгә ихтирам арту, аның сфералары киңәю, халкыбызның аңлы катламы туган тел белән гаять тирәнтен кызыксыну шартларында, мәктәпләрдә яшь буынга туган телне укыту яхшырырга тиеш бу заманда сүзлек игелекле хезмәт күрсәтер дип уйлыйбыз.

**Флера САФИУЛЛИНА,**
филология фәннәре кандидаты.

# ЧӘЧӘКЛӘР КИТЕРЕГЕЗ АҢА

**Нуруллин И. Фатих Әмирхан. Татарстан китап нәшрияты, 1988.**

Элек-электән шулай килә: кешелек үзенең үткәннәрен аңларга, аны бүгенге көн биеклегеннән бәяләргә омтылып яши. Тарихны иҗат итүдә вакыт һәм халык катнаша дибез икән, бу аерым шәхесләрнең җәмгыять үсешендәге ролен дә тану дигән сүз. Тарих һәм шәхес — аерылгысыз. Үзеңә кадәр яшәгән күренекле шәхесләргә карата кызыксынуның арта баруы — тарихны, андагы табу-югалтуларны, казаныш һәм хаталарны аңларга омтылуның бер дәлиле.

Әнә шундый ихтыяҗ әдәбиятта биографик жанрны барлыкка китергән. Дөрес, аның теориясе шушы көнгә чаклы тиешенчә эшләнеп җитмәгән. Ләкин андый жанр бар, яши, укучыда зур кызыксыну уята. Сүзебезне раслар өчен дөньяның даһилары турында менә дигән китаплар язган Ромен Роллан, Андре Моруа, Стефан Цвейг, Ирвинг Стоун һәм башкаларны күрсәтү дә бик җитә. Заманында Максим Горький тәкъдиме белән ачылган «Атаклы кешеләр тормышы» сериясе генә дә бу сафка никадәрле талантлы исемнәр өстәде! Шулар арасында үзенең «Тукай» дип исемләнгән китабы белән Ибраһим Нуруллинның да күренүе татар совет әдәбияты өчен үзе бер горурлык.

Безнең әдәбиятта документаль биографик жанр әле уянып кына килә, дисәк, шәт, хата булмастыр. Шулай булса да аның матур гына үрнәкләре бар инде. Муса Җәлилнең тормышын, иҗатын һәм сугышчан юлын өйрәнеп, Рафаэль Мостафин патриот-шагыйрь турында «Өзелгән җыр эзеннән» дигән бик тә кирәкле китап язды. Мансур Хәсәновның — әдип Галимҗан Ибраһимов, Хәсән Хәйринең — шагыйрь Һади Такташ, Барлас Камаловның— драматург Мирхәйдәр Фәйзи, Гөлшат Зәйнашеваның композитор Сара Садыйкова турындагы китаплары да нур өстенә нур булды.

Шуларга быел «Атаклы кешеләр тормышы» сериясеннән тагын бер хезмәт өстәлде: «Фатих Әмирхан». Бу китап безнениләр белән шатландыра, нинди уй-фикерләргә этәрә соң?

Мулла гаиләсендә туып-үскән, Тукайларны үз даирәсенә туплаган, катлаулы язмыш иясе Фатих Әмирхан турында күләмле әсәр язу ансат эш түгел, әдипнең формалашуын, характерын, сәяси карашларын, иҗтимагый һәм әдәби эшчәнлеген укучыга тарихи фонда дөрес итеп күрсәтеп бирергә кирәк.

Китап белән танышып чыкканнан соң, әйтә алабыз: Ибраһим Нуруллин документальлекне, фактлар дөреслеген алга куеп эш иткән. Автор кулында иң көчле корал — тарихи дөреслек, кире каккысыз дәлилләр. Булачак әдипнең социаль чыгышы, нәсел-нәсәбе һәм шәҗәрәсе аеруча тәфсилләп язылган. Уку барышында без Яңа бистәнең барлыкка килү тарихы, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе ачылу, «Әльислах» газетасының оешуы кебек әһәмиятле вакыйгалар хакында байтак мәгълүмат алабыз. Фатихның яшьтән үк татар шәкертләрен берләштерә торган оешма төзү уе белән яшәвен, тора-бара шәкертләр хәрәкәтенә җитәкчелек итүен, милләт хадиме булырга теләвен, большевик С. Гассардан дәресләр алуын беләбез. Болар бар да укучының танып-белү офыгын киңәйтә, аны акрынлап каһарман яшәгән социаль һәм рухи мохиткә алып керә.

Фатих Әмирханның тормышы шома юлдан җиңел арбадай тәгәрәп кенә бармаган икән. Әтисе Зариф, шәһәрнең танылган мулласы, улын «начар» йогынтылардан аралап калырга тырыша. Мондый каршылыклар тора-бара сәяси төс ала, ата белән ул арасына упкын булып ята. Шу-

ңарга тагын кетмәгәндә шәхси бәхетсезлек килеп өстәлмәсенме: паралич сугудан Фатихның аяклары икесе тиң хәрәкәтсез кала. Мондый хәлләрдән соң егет Шәмсениса исемле кызга булган мәхәббәтен дә йөрәк түренә «күмәргә» мәҗбүр... Әдип тормышындагы драмаларны, язмышының шуңа бәйле сикәлтәләрен Ибраһим Нуруллин ышандырырлык итеп, психологик яктан нигезләп яза.

Бу унайдан шулай да бер мәсьәләдә автор белән бәхәсләшәсе килә. Аның фикерләрен кире кагу түгел, ә бәлки тулыландыру, ачыклык кертү нияте белән. Ф. Әмирханның «Авырулар галәмендә» дигән очеркын анализлаганнан соң И. Нуруллин бер урында мондыйрак сөземтә чыгара: «Инде килеп, кетмәгәндә башына төшкән фаҗига Фатихны кимсетелгәннәр һәм фәкыйрьләргә якынайтты да куйды! Дөрес, аның бәхетсезлеге социаль сәбәпләргә бәйләнмәгән. Табигать «бүләге». Әмма бәхетсезлек — бәхетсезлек инде. Моннан соң ул үзе кебек авыруларга гына түгел, бәлки ачлыктан тилмерүчеләргә дә, туклыктан ни кыланырга белми торган байларга да икенчерәк күз белән карамый булдыра алмый иде». Шушы фикере белән артыграк мавыгып, автор «хәтта авыруы да Ф. Әмирханның революцион-демократик карашларын ныгыткан икән» дигән нәтиҗәгә килә. Алдарак исә (81 бит) әдипнең нәфис әдәбиятка, хыял һәм сурәт дөньясына йөз тотуы да билгеле бер дәрәҗәдә шушының белән аңлатылган иде. Болар бар да дөрес, әлбәттә. Әмма И. Нуруллин бу очракта кулындагы пумаласын бер генә төскә манa түгелме? Язучылык эшенә тотынуның да сәбәбен шул җәһәттән чыгып кына аңлату беренчел факторга — Фатих Әмирханның табигый талантына, кешеләрне һәм типларны аңлаудагы нечкәлегенә күз йомып карау булыр иде. Тормышта бәхетсезлеккә дучар ителгәннәр күренә тора ул, тик моңа карап кына аларның һәммәсе дә әдиплек сукмагыннан китми ич.

И. Нуруллинның теле төзек, матур, образлы, аңлаешлы. Бу исә документаль әсәр укуны җиңеләйтерә, беренче битләрдә үк туган кызыксыну хисен ахыргача әйдәп бара. Тәнкыйтьче һәм әдәбият галиме буларак, автор Ф. Әмирханның публицистикасын, проза һәм драматургиясен бәяләүдә үзен аеруча иркен сизә, әдипнең тәнкыйди реализм юнәлешендә үсүе һәм иҗтимагый-политик карашлары ягыннан революцион демократ булып җитешүе турында кызыклы гына күзәтүләр ясый. Тик шунысын да әйтергә кирәк, нәкъ менә бу мәсьәләләрдә И. Нуруллинның теле, фикер сөреше артыграк фәнниләшеп китә. Яхшымы бу, начармы? Китапның төп максатына хезмәт итә һәм укылыш ягына зыян китерми икән, миңа калса, мондый алымның да яшәргә хакы бар. Бары тик чама хисен генә югалтмаска кирәк.

Фатих Әмирханның тормыш һәм иҗат юлын күздән кичергәндә автор истәлекләргә, тарихи чыганакларга һәм архив материалларына еш мөрәҗәгать итә, аларны мозаика бизәкләредәй тезеп, чор һәм вакыт сурәтен ясый. Чагыштыру, фараз кылу, вакыйгаларны социаль фонда тикшерү кебек алымнар да анализ мөмкинлекләрен киңәйтә, әсәргә киң сулыш бирә. Фараз кылу димәктән, беллетристикадан аермалы буларак, документаль әсәрдә геройның халәте рухиясен ачып бирүдә, аны гәүдәләндерүдә автор фантазиясе нык кына чикләнгән бит. Ф. Әмирханны күреп белмәгән кеше аның хакында ничек язарга тиеш: әдип биографиясендәге «ак таплар»ны әйләнеп узсынмы ул, әллә мәгълүм фактларга таянып, хыял көчен дә иркенләп эшкә җиксенме? Бу өлкәдә тәҗрибәсе зур булган язучы сүзенә колак салыйк. Андре Моруа «Биографик жанр төрләре» дигән хезмәтендә мондыйрак фикер әйтә: әгәр ихтыяҗ туа икән, документаль әсәргә фараз итү элементлары да үтеп керергә мөмкин. Чынлап та, беренчел чыганакларга гына ябышып яту аз, алар психологик һәм тарихи дөреслек җирлегендә кайчак авторның хыялы белән дә сугарылырга тиеш. Менә шул чакта хакыйкать, могҗиза туа. Флобер сыман: «Бовари — мин ул!»— дип әйтә алу хокукы яулана.

Максим Горький һәм башка кайбер язучылар шикелле, татар әдибе Фатих Әмирхан да Бөек Октябрь революциясенең асыл мәгънәсен аңлауда каршылыклы хисләр кичерә. Шул көннәрдә язган публицистик мәкаләләреннән күренгәнчә, ул большевикларның мәсләген хуплый, әмма аларның уй-ниятләре барып чыгасын шик астына ала. Моңа гаҗәпләнәсе юк, чөнки Ф. Әмирхан, Россия әле социалистик революциягә әзер түгел, дигән карашта торган була. Ачлык һәм НЭП еллары граҗданин рухлы әдипне тагын да уйга сала, фикер каршылыкларына китерә. Эш шуңа кадәр барып җитә ки, кайбер сүзләре өчен бер як аны «контрреволюционер» дип атаса, икенче як «большевик» дип гаепли. Бу урында И. Нуруллин әдипнең иҗтимагый-политик карашларын, революцияне аңлаудагы каршылыкларын саллы, ышандыргыч дәлилләр белән нигезләп бирә, иҗатында исә һәрвакыт революцион демократик позициядә торып калуын исбатлый.

Китапта бүгенге көн үзгәртеп коруларына ифрат аваздаш булган кыю, заманча рух яшәү куандыра. Укып китик: «...үткен күзле, сизгер колаклы һәм зирәк акыллы Әмирхан совет аппаратына үтеп кергән бюрократизмны да, сүз белән эшнең

аерылу очракларын да, кайбер җитәкче работникларның дәүләт малына кул сузуларын, ришвәтчелеккә бирелүләрен дә, чекада эшләүче аерым кешеләрнең артык узынып китүләрен дә күреп торган. Күреп кенә калмаган, бәлки, көндәлегенә теркәү белән генә чикләнмичә, теләсә кайда, теләсә кем алдында нәфрәтләнеп сөйли торган булган».

Менә бит ничек заманча яңгырый бу сүзләр! «Дөреслек — дару шикеллерәк: үзе ачы була, ләкин сәламәтләндерә»,— ди Бальзак. Ләббәйкә дип торучы ялагай, икейөзле кешеләргә караганда Тукай, Әмирхан кебек туры сүзле затлар җәмгыятькә файданы күбрәк китерәләр. Бүгенге көндә, ягъни социализмны ныгыту, камилләштерү өчен көрәш барган тарихи көннәрдә гадел сүзгә, үзтәнкыйтькә, ачыктан-ачык сөйләшүгә барлык капкаларның киң ачылуы бер дә юкка түгел.

Интернационализм буш җирлектә барлыкка килми. Башка милләтләрнең культурасын чын-чынлап үзләштерү өчен иң элек үз халкыңның культурасын һәм тарихын яхшы белү зарур. Зур Ватаныбызны ярату өчен иң әүвәл үзең туып-үскән төбәкнең чын патриоты булырга кирәк. Биографик жанрда язылган әсәрләр менә шушы олы максатка хезмәт итә. Минем уемча, язучы исемен йөрткән һәр кеше үз халкының күренекле бер улы турында үз китабын язарга тиеш. Башка халыклар бу эшне, күз тимәсен, өлгерлек һәм җитезлек белән башкаралар. Әле безгә Ленин белән якыннан аралашкан күренекле революционерыбыз Мулланур Вахитов турындагы әсәрне чуваш язучысы М. Юхма бүләк итте. Рәхмәт аңа! Ләкин шул рәхмәтне әйткән чакта йөзебезгә кызыллык та куна түгелме? Кайда үз егетләребез, аларның кулыннан килмәс эш идемени бу? Әдипләребез сафына караш ташлаганда менә шушы сорауларга да җавап табасы килә. Вакыт һаман алга баруында — ашыкмасак, эшләрне оештыра белмәсәк, күп нәрсәләрне югалтуыбыз бар. Үзләре исән чакта Бакый Урманче, Нәкый Исәнбәт биографиясеннән күп кенә нәрсәләрне куен дәфтәренә теркәп калу мөмкиндер. Шиһаб Мәрҗани, Сәлих Сәйдәшев, Хәсән Туфан, Якуб Чанышев кебек шәхесләрнең тормыш юлы һәм эшчәнлеге турында сөйләгәндә халкыбыз язмышындагы ничаклы сәхифәләр калку суратта ачылып китәр иде. Киләчәктә Татарстан китап нәшриятының «Атаклы кешеләр тормышы» сериясендә әнә шулар хакындагы китаплар белән дә очрашасы килә. Моңардан әдәбият һәм культурабыз отачак кына.

Бу кечкенә генә мәкаләдә «Фатих Әмирхан» китабына җентекле анализ ясау максат итеп куелмады. Исәп — яңа китап уңаеннан сөенче алу һәм күңелдә туган кайбер уй-фикерләр белән уртаклашасы килү иде.

Ибраһим Нуруллин, әдип сүзләрен бераз үзгәртеп, үзенең китабын: «Чәчәкләр китерегез аңа, кешеләр!» дигән сүзләр белән тәмамлый. Бик тә хаклы, мәгънәле сүзләр! Безнең әле халкыбыз тормышында тирән эз калдырган, кылган эше-гамәле белән үлемсезлек яулаган күп кенә шәхесләргә чәчәкләр китерәсебез бар. И. Нуруллинның бу хезмәте исә Фатих Әмирханга китерелгән чәчәк бәйләмнәренең иң күркәменнән саналырга хаклы.

**Рашат НИЗАМИЕВ.**

# Гарәп әлифбасы нигезендә татарча уку-язу

## Җиденче дәрес

Иске татар язуының үзенчәлекләре, аның кагыйдәләре алдагы дәресләрдә язылганнар белән генә чикләнми, әлбәттә. Алар шул дәвердәге татар грамматикасының барлык өлкәләрендә дә чагылыш тапкан. Бу дәрестә сүз шуларның кайберләре — кеше исемнәре, кушымчалар һәм бәйлекләрнең язылышы хакында барачак.

Иске татар телендә кеше исемнәренең язылышы һәм укылышы шактый үзенчәлекле. Мәгълүм булганча, борынгы бабаларыбызга гарәп язуы һәм ислам дине керү татар антропонимиясенә, ягъни кеше исемнәренә дә зур йогынты ясый. Гарәп-фарсыдан кергән кеше исемнәре татарларда XVIII йөзнең икенче яртысында аеруча киң таралыш ала башлый һәм саф төрки-татар исемнәрен икенче планга кысрыклап чыгара. Шуны истән чыгармаска кирәк: гарәптән кергән кеше исемнәре язылышы асылда гарәп теле кануннары җирлегендә башкарылган һәм ишетелгәнчә язуга нигезләнмәгән. Андый исемнәрне уку һәм язу түбәндәге кагыйдәләргә нигезләнгән.

1) Ахырында *«дин»* сүзе булган исемнәрдә әйтелмәсә дә, *«дин»* сүзе алдында ال язылган һәм ул кушып язылганда الدين рәвешен алган. Составында әлеге الدين булган исемнәрдә الدين алдыннан «т» авазы ишетелсә дә, ул язылмаган. Әмма хәзерге орфографиядә الدين -эддин дип түгел, ә *этдин* формасында, ягъни «т» тартыгы да куелып языла: Хөснетдин, Шәйхетдин һ. б.

гайнетдин-عين الدين гыйлаҗетдин-علاج الدين

камәретдин - قمر الدين камалетдин-كمال الدين

мифтахетдин-مفتاح الدين кответдин-قطب الدين

2) Ахырында «алла»- الله сүзе булган исемнәрдә, «алла» сүзе алдында *уау* ишетелсә дә, язылмаган.

габдулла-عبد الله галиулла - على الله гатаулла - عطاء الله

гарифулла-عارف الله гыйззәтулла-عزت الله зиннәтулла-زينت الله

кәлимулла-كليم الله лотфулла-لطف الله нигъмәтулла-نعمت الله

3) Ике сүздән торган кушма исемнәрдә икенче сүзнең беренче хәрефе тәшдидле булганда, аның алдыннан ال язылган. Ләкин ул ال укыганда әйтелмәгән. Шунысын да истән чыгармаска кирәк: кушма исемнәрдә икенче сүзнең беренче хәрефе тәшдидле булса да, ягъни ул хәреф ике кат әйтелсә дә, хәзерге татар орфографиясендә аның берсе генә языла. Мәсәлән: Габдерахман, Габдерәшит, Габдерәзак, Габдерәхим.

ГАБДЕРАХМАН-عبد الرحمن ГАБДЕРӘШИТ-عبد الرشيد

ГАБДЕРӘЗАК - عبد الرزاق ГАБДЕРӘХИМ-عبد الرحيم

4) Ике сүздән торган кушма исемнәрдә (сүзләрдә) икенче сүз башында ل ишетелеп тә, шул ل нән соң «ай» хәрефләре» дип аталган хәрефләрнең берсе килсә, шул ل алдыннан әлиф (ا) язылa. Гарәп алфавитында ر، ز، س، ت، ل، ن، ش، ص، ث، ض، ظ، ط، د، ذ хәрефләреннән тыш калган бөтен тартыклар «ай хәрефләре» дип аталалар.

ГАБДЕЛКАДЫЙР - عبد القادر ГАБДЕЛКАЮМ-عبد القيوم

ГАБДЕЛКӘБИР - عبد الكبير ГАБДЕЛКӘРИМ-عبد الكريم

ГАБДЕЛХАЛИК - عبد الخالق ГАБДЕЛХАК-عبد الحق

Гарәптән кергән кайбер исемнәр һәм сүзләр әлиф (ا) белән укылсалар да, сүз ахырында йай (ى) язылган. Мәсәлән:

ГАЙСА - عيسى ; МОРТАЗА - مرتضى ; МУСА - موسى ;

МОСТАФА - مصطفى ; ЯХЪЯ - يحيى ; ТӘКЪВА - تقوى ;

ДӘГЪВА - دعوى ; ХӘТТА - حتى ; ФӘТВА - فتوى .

Гасырлар дәвамында телебезгә фарсы теленең дә йогынтысы булган. Ул турыда биредә киң мәгълүмат бирү мөмкин булмаганга күрә, кайбер сүзләрнең язылышы турында искәрмә бирү белән чикләнәбез. Мәсәлән, фарсы теленнән кергән кайбер сүзләр «ә» (ه، ـه) сузыгы белән язылсалар да, «и» дип укылалар.

ЯКИ - ياكه ; БӘЛКИ - بلكه ; ЧӨНКИ-چونكه; ГУЯКИ-گوياكه ;

ХӘЛБУКИ-حالبوكه; МӘГӘР КИ - مگركه ; ТАКИ - تاكه ; ХӘТТА КИ-حتى كه .

Хәзерге вакытта гамәлдә булган кагыйдәләр белән чагыштырганда иске татар телендә кушымчаларның язылышында да кайбер үзенчәлекләр бар. Мәсәлән, *-лар, -ләр* кебек күплек кушымчалар язуда ишетелгәнчә бирелмәгән. Әйтик, قارادیلار *-карадылар* ишетелә, قارادیلر язылa, بارالار *-баралар* ишетелә, بارالر язылa, ягъни *-лар, -ләр* кушымчалары калын сүзләрдә *лар*, нечкәләрдә *ләр* ишетелсә дә, язуда асылда لر рәвешендә генә язылa. Хәзерге кагыйдәләр буенча *-лар, -ләр* күплек кушымчалары м, н авазларыннан соң, ишетелгәнчә *-нар, -нәр* рәвешендә язылa, ә иске татар язуында бу кушымчалар һәрвакытта *-лар, -ләр* булып язылган.

БАРГАННАР - بارغانلر ; БУЛГАННАР - بولغانلر ; КИЛГӘННӘР - كيلگه نلر ;

КУШЫЛГАННАР - قوشلغانلر ; СИПКӘННӘР - سيپكه نلر; ЧӘЧКӘННӘР - چه چكه نلر .

Хәзерге кагыйдәләр буенча сүзләрдәге саңгырау авазлардан соң килгән *-ты, та, тә, тан, тән* кушымчалары иске язуыбызда *ды, да, дә, де, дан, дән* булып язылган. Мәсәлән:

БАШТА – باشدا  ТАШТА – تاشدا  АТТЫ – آتدی

КАПТЫ – قاپدی  ЧАПТЫР – چاپدر  КИТТЕ – کیتدی

СҮТТЕ – سوتدی  ХАТТАН – خاتدن  СУГЫШТАН – سوغشدن

ТӨПТӘН – توپدن  КҮПТӘН – کوبدن  ЭШТӘН – اشدن

Иске татар язуы җөмләдә сүз тәртибенең гадәти төзелештә булуы һәм бәйләүче ярдәмлекләрнең күплеге белән үзенчәлекле. Түбәндә иске язуыбызда синтаксик бәйләнешне белдерү өчен кулланылган ярдәмлекләр бирелә.

вә – و ; һәм – هم ; әммә – اما ; ләкин – لکن ; яки – یاکه ; гүя – گویا ;

яисә – یا ایسه ; яхуд – یاخود ; хәлбуки – حالبوکه ; әгәр – اگر ; янә – ینه ; ки – که ;

гәрчә – گرچه ; мәгәр – مگر ; фәкать – فقط ; дәхи – دخی ; таки – تاکه ; бәлки – بلکه ;

хәләнки – حالنکه ; бәс – بس ; шөйлә – شویله ; ушандак – اوشانداق ; чөнки – چونکه .

Иске татар теленә хас булган морфологик үзенчәлекләрнең берсе — исем фигыльнең *-мак -мәк* кушымчасы белән ясалган төрен һәм шуңа ук юнәлеш һәм урын-вакыт килеше кушымчалары ялганган форма куллану. Мәсәлән:

АШАМАК – آشامق  ЭЧМӘК – اچمك

АШАМАГА – آشامغا  ЭЧМӘГӘ – اچمگه

КИЛМӘК – کیلمك  ТИБРӘНМӘКТӘ – تیبره نمکته

КАЙТМАК – قایتمق  ЙӨЗМӘКТӘ – یوزمکته

Хикәя фигыльнең *-ды, -де* кушымчасы белән ясалган үткән заман формасына *-гы, -ге* кушымчасы ялганган сыйфат фигыль куллану да иске язуыбызның морфологик үзенчәлекләреннән санала. Мәсәлән:

БАРДЫГЫ – باردیغی  БИРДЕГЕ – بیردیگی

КАЙТТЫГЫ – قایتدیغی  КҮРДЕГЕ – کوردیگی

УТЫРДЫГЫ – اوتردیغی  ӘЙТТЕГЕ – ایتدیگی

Иске татар язуында тыныш билгеләре кулланылмаган диярлек. Шуңа күрә борынгы текстларда кызыл юл, сорау, өндәү билгеләре, күп нокталар, куштырнаклар, сызык һәм башка тыныш билгеләре очрамый. Татар язуы тарихында тыныш билгеләре турында беренчеләрдән булып күренекле язучыбыз Муса Акъегетзадә язып чыга. «Хисаметдин менла» исемле әсәрендә (1886 ел) ул тыныш билгеләре куюның әһәмиятен билгеләп уза. Шуннан соң Г. Госманов, Ф. Садыйков, К. Насыйри кебек язучылар, мәгърифәтчеләр бу эшне дәвам итеп Октябрь революциясенә кадәр үк татар пунктуациясе кагыйдәләрен булдыруда мәгълүм эш башкаралар.

Бу санда журнал укучыларга уку-язу күнекмәсе буларак 1915 елда Казанда атаклы татар галиме һәм мәгърифәтчесе Шиһабетдин Мәрҗани юбилеена багышлап чыгарылган «Мәрҗани» исемле китаптан галимнең тарихи хезмәтләре турындагы бер өзекне тәкъдим итәбез.

## مرجانی نڭ تاریخی خذمتلری

(өзек)

مرجانی حضرتلری تاریخی اثرلرن نیچك یازغان ؟

مرجانی حضرتلرینه اشله‌نولمه‌گان تاریخمزنی اشله‌وی آسان اش بولماغان. کتابلر قولونده بولماغان، بیگراکده اول وقتده باصولغان منبع‌لر آز بولغان. ئلی یاری آثارغه بخارا و سمرقندده تحصیللری زور فائده بیرگان. آندن اول تورلی کاغذلر یازوب آلوب قایتقان. شو-لاردن هم تورلی تاریخی مقصد بله‌ن سیاحتلرنده کورگان اثر و داکو-مینتلرنی یازغان، کوچرگان کاغذلردن مرجانی حضرتلرینڭ مجموعه‌لری یاصالغان. نی طابقان، نینڭی خط آلغان، نینڭی کتابده عجب سوز، فائده‌لی نرسه‌لر طابقان، نینڭی آنچه کورگان، نینڭی کتاب حاشیه‌لرنده یازولر کورگان، شولارنڭ همه‌سنده، شول مجموعه‌لرینه ترکه‌گان.

مرجانی بر اثرن ده توب توغری آقغه یازماغان. ئلوك اول پلان توزگان، آندن صولڭ بر تورلی قصقه غنه یازوب چقغان، صوڭندن اوزایتوب آقغه یازغان.

مرجانی‌نی تاریخقه هوسلی، مؤرخ یاصاوچی شی، ایڭ اوّلی طبیعت در. آنڭ زور خاطره‌سی، خاطرگه بنا قلونغان بو تاریخ علمینه بیك زور فائده ایتکان. صوڭندن بخارا، سمرقند کبی اول وقتده‌غی کتاب او-یاسنده اون یل‌دن زیاده طرووی بر ده شیکسز مرجانی‌غه تاریخمز-نی ترولتورگه زور سببچی بولغان. آنده، مرجانی حضرتلرینڭ بیوك بختلرینه قارشی، قاضی ابو سعید سمرقندی شکللی دردلی عالملرنڭ بولوی، بر ده شیکسز مرجانی‌نی تاریخ بله‌ن شغلله‌نوگه تارتقانلر.

مونڭ اوستونه حسین افندی فیضخانف کبی شاکردینڭ بولوی، بیگراکده آنڭ علم اویاسی بولغان پیتروغرادده اونیورستیتده تعلیمی زور فائده ایتکان بولور. نه ایسه استاذ مرجانی حضرتلرینه تورلی سیراك اوچری ترغان مسلمان کتابلری بله‌ن فائده‌له‌نو اوچون بو شاکر-

دینڭ بیك زور یاردملری تیگان بولورغه کیره‌ك. مثلا ویلیامینوف زیرنوف هم برنچی مرتبه ابن خلدون بله‌ن طانشدروچی اوشبو شاکردی بولوی احتمال طوطوله‌در. مرجانی‌نڭ کتبخانه‌سنده ماتیریاللر آراسنده حسین فیضخانف قلمی بله‌ن یازولغان تاریخقه دائر بایتاق یازولر بار.

لکن تاریخ بله‌ن شغلله‌نورگه ایڭ زور معاونت ایتوچی بلکه زمان بولغاندر. مرجانینڭ ملا بولغان زمانلری، قازانده علوم شرقیه‌نڭ اونیورستیتده ایڭ زور ترقی ایتکان وقتی ایدی. غوتوالد، رادلوف، نهایت پرافیسور نیکالای فیرسوف‌لر شول زمانده ایدی. بولارنڭ مصلحتلری قازانده شرق تللری شعبه‌سی بولووی مناسبتی بله‌ن بولغان. قازانده تورلی تاریخقه دائر سیبزدلر، همه‌سیده مرجانی‌نی تاریخقه تارتالر، مرجانی‌نی کونلاشدره‌لر ایدی. مرجانی کبی بر آدم نیچك ایتوبده، روس وطنداشلریمزنڭ بزنڭ تاریخمزغه خذمتلرن کوروب طروب، اوزی شوڭارغه طوطونمه‌سون، اشله‌مه‌سون؟

مرجانینڭ مؤرخلك اوچون حاضرلگی بار ایدیمی صوڭ؟ بار ایدی. اول بتون شرق مؤرخلرین تیکشرگان، آلارنڭ اصولن آڭلاغان، بلگان ایدی. ابن خلدون کبی تاریخده «میتودولوغ»، آنڭ هر وقتده یول کورسه‌توچی یولدوزی ایدی. فارسی، عربی، ایسکی تورکچه تللرنی چن چنلاب بله ایدی. منه بو ده شرق خلقلرینڭ تاریخی بله‌ن شغلله‌نو اوچون برنچی شرطدر.

ع. عزیز.

Сүзлек: مَنْبَعْ — чыганак; تَحْصِیلْ — уку; حَاشِیَه — комментарий; مُؤَرِّخ — тарихчы; بِنَا قلونغان — нигезләнгән; زِیَادَه — күп; تَعْلِیمی — укуы; دائِر — кагылышлы; مُعَاوَنَتْ — ярдәм; عُلُومُ شَرْقِیَه — Көнчыгыш фәннәре; تَرَقِّی — прогресс; شُعْبَه — бүлек.

*Дәресләрне Җәүдәт Миңнуллин һәм Рәшит Кадыйров алып бара.*

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

11 январьда Татарстан Язучылар союзының ачык партия җыелышы булып узды. Татарстан Язучыларының чираттагы XI съездына әзерлек мәсьәләләре тикшерелгән бу җыелышта республика Язучылар союзы идарәсе председателе урынбасары Г. Рәхим белдерү белән чыкты. Фикер алышуларда С. Баттал, М. Хәсәнов, Б. Гыйззәт, К. Тимбикова, Р. Батулла, Н. Хәсәнов, Ә. Рәшитов, Ә. Гаффар, М. Галиев, Р. Низамиев, Р. Зәйдуллин, Л. Лерон һ. б. катнашты.

## ЯЗУЧЫЛАР КИҢӘШӘ

24 январьда Татарстан Язучылар союзында Идел буе һәм Урал яны автономияле республикалары арасында милләтара бәйләнешлар проблемасына багышланган региональ киңәшмә булды. Анда РСФСР Язучылар союзы идарәсе председателе, Социалистик Хезмәт Герое, Ленин премиясе лауреаты С. В. Михалков, РСФСР Язучылар союзы идарәсе секретарьлары Э. Ю. Зимин, Н. Е. Шундик, Татарстан, Башкортстан, Мари, Мордовия, Удмуртия, Чувашия АССР Язучылар союзлары идарәләре председательләре һәм әлеге республикаларның әдәби журналлары баш редакторлары, «Литературная Россия» атналык газетасының милли әдәбиятлар бүлеге мөдире М. Н. Ломунова, Татарстан язучылары катнашты.

Т. А. Миңнуллин (Казан), Н. Ф. Рыбаков (Йошкар-Ола), Д. М. Бүләков (Уфа), П. В. Афанасьев (Чабаксар), С. А. Самсонов (Ижевск), Г. И. Пинясов (Саранск), Р. Харис (Казан), Б. Рафиков (Уфа), А. Тимиркаев (Йошкар-Ола), М. Юхма (Чабаксар), Р. Мөхәммәдиев (Казан), М. Гафуров (Уфа), Н. Әхмәдиев (Әлмәт), Р. Баимов (Уфа) үз чыгышларында әлеге регион автономияле республикаларында яшәүче һәр милләтнең культурасын үстерү, милли телләрен саклау, халыкларыбыз арасындагы үзара бәйләнешларны тагын да ныгыту проблемаларын күтәрделәр, мондый очрашуларны даими үткәрергә дигән уртак фикергә килделәр.

Киңәшмә эшендә партиянең Татарстан өлкә комитеты секретаре Р. Р. Идиатуллин катнашты.

## ЯШЬЛӘР ӨЧЕН ЯҢА ЖУРНАЛ

КПСС Үзәк Комитеты, татар һәм рус телләрендә айлык әдәби-нәфис һәм иҗтимагый-политик «Идел» журналы чыгару турында карар кабул итте. Ул комсомол өлкә комитеты һәм республика Язучылар союзы тарафыннан чыгарылачак.

Хәзер журналны чыгаруны оештыру, редакция коллективын туплау, яңа басманың идея-художество йөзен билгеләү эше алып барыла. «Идел» журналының баш редакторы итеп Р. С. Вәлиев сайланды.

## ФӘРИТ ЯРУЛЛИН ХӨРМӘТЕНӘ

Татар совет музыкасының алтын хәзинәсенә беренче татар балеты бүләк иткән композитор Фәрит Яруллинның тууына 75 ел тулды.

16 январьда Татарстан Композиторлар йортында Фәрит Яруллин истәлегенә багышланган музыкаль кичә уздырылды. Анда композиторның дуслары һәм әсәрләрен беренче башкарган сәнгать осталары катнашты. Композитор турында кереш сүзне сәнгать фәннәре кандидаты Ч. Бәхтиярова сөйләде. Кичәгә килүчеләр сәнгать фәннәре кандидаты Х. Гобәйдуллин, «Шүрәле» балетында Сөембикә образын беренче булып иҗат иткән Татарстанның атказанган артисткасы А. Гацулина, композитор Ә. Бакиров, дирижер Х. Фәзлуллин, балет солисты К. Гайнуллин, шагыйрь М. Хөсәен чыгышларын кызыксынып тыңладылар. Соңыннан композитор әсәрләреннән зур концерт булды.

Киев шәһәрендәге «Халыклар дуслыгы» китапханәсе каршында татар әдәбиятын сөючеләрнең «Болгар» исемле клубы эшләп килә. 18 декабрьдә әлеге клуб композитор Фәрит Яруллинга багышлап кичә уздырды. Аны клуб җитәкчесе Ә. Кашапов ачып җибәрде. Я. Яруллинның тормыш һәм иҗат юлы турында китапханә мөдире В. Полищук, композиторның кызы Наилә Яруллина әтисе турында истәлекләр сөйләде. Соңыннан музыка белгече Г. Сабитова җитәкчелегендә әзерләнгән концерт булды.

6 январьда Мамадыш районының Югары Сөн культура йортында язучы Р. Низамиевның «Язмыштан көчлерәк» роман-хроникасы буенча укучылар конференциясе уздырылды. Әлеге әсәр «Казан утлары» журналының былтыргы соңгы ике санында басылып чыккан иде. Фәрит Яруллинның тормыш һәм иҗат юлын сурәтләгән бу әсәр композиторның якташлары арасында зур кызыксыну тудырды. Чыгыш ясаучылардан Н. Гарипова, Г. Хаҗиева, Т. Мортазина, Р. Хәев һ. б. иптәшләр әсәр турында үз фикерләрен әйттеләр. Очрашуда катнашкан автор әсәрнең язылу тарихын сөйләде һәм укучыларның күп санлы сорауларына җавап бирде.

## РӘССАМНАРЫБЫЗ БҮЛӘГЕ

Татарстан рәссамнары республикабыз Культура фондына 50 дән артык картина бүләк иттеләр. Рәссам Р. Имашев Кабарда-Балкар АССРның халык шагыйре Кайсын Кулиев портретын бүләк итеп, аны атаклы шагыйрьнең туган җиренә җибәрүне үтенде. С. Лывин, А. Симбирин, Э. Зарипов, В. Аршинов, М. Усманов, Ш. Шәйдуллин, Ф. Вахитов, И. Рафиков, А. Родионов, Ә. Тумашев, Х. Хәйдәров, И. Колмогорцева, М. Мавровская һәм башкалар бүләк иткән хезмәтләрдә республикабыз тормышы, аның хезмәт кешеләре, лирик һәм индустриаль пейзаж, әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре, халкыбызның тарихы, көрәш сәхифәләре ачык чагыла.

## ЖУРНАЛ БҮЛӘГЕ

Билгеле булганча, «Ялкын» журналы Абдулла Алиш исемендәге премия булдырган иде.

Декабрь аенда яңа лауреатларның исемнәре билгеле булды. Узган ел «Ялкын» журналы битләрендә актив чыгыш ясаган авторлардан — язучылар Р. Батулла «Ак бүре» әкияте, Р. Мостафин А. Алишның фашистлар тоткынлыгындагы тормышын чагылдырган документаль язмасы, шагыйрь М. Әгъләмов «Ил хәтере — вакыт күпере» дигән язмалар циклы, рәссам И. Вәлиәхмәтов журналны бизәүдәге иҗат уңышлары өчен премиягә лаек дип табылды.

## ШАГЫЙРЬ ИСЕМЕНДӘГЕ ПРЕМИЯ

Шагыйрь Габдерәхим Утыз Имәни Чирмешән төбәгендә яшәгән, шунда рухи яктан ныгыган, иҗат иткән. Шуны истә тотып, классик шагыйрьгә хөрмәт йөзеннән, районның «Ленин юлында» газетасы редакциясе Утыз Имәни исемендәге премия булдырды. Ул газетада басылган иң яхшы материаллар, әдәби әсәрләр өчен һәр елны матбугат көнендә тапшырылачак.

## ИҖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ

Проза һәм публицистика секцияләренең 24 январьда узган берләштерелгән утырышында Флүс Латыйповның «Кырагай» һәм «Вөҗданыңнан сора» исемле китаплары тикшерелде. Фикер алышуда катнашучылар: М. Хәсәнов, Г. Ахунов, В. Нуруллин, Р. Ишморатова, С. Сабиров, Б. Камалов, Ә. Гаффар, М. Хуҗин, Ф. Бәйрәмова, Р. Низамиев, М. Галиев һәм башка иптәшләр авторның иҗади эшчәнлегенә нигездә уңай бәя бирделәр.

Ф. Латыйпов бертавыштан СССР Язучылар союзы членлыгына тәкъдим ителде.

## СЕРГЕЙ ЧАВАЙНГА БАГЫШЛАП

1988 елда мари әдәбиятына нигез салучы, ялкынлы интернационалист Сергей Григорьевич Чавайнның тууына йөз ел тулды. Шушы данлы дата уңае белән Мари китап нәшрияты рус телендә «Халык җырчысы» дигән зур күләмле җыентык бастырып чыгарды.

Җыентыкта мари язучыларының әсәрләрен татар теленә даими тәрҗемә итеп килгән шагыйрь З. Нуриның «Чавай чишмәсе», С. Шакирнең «Минем яраткан шагыйрем» дигән мәкаләләре һәм аларның мари әдибенә багышланган шигырьләре урнаштырылган.

## ХЕЗМӘТЛӘРЕН ХӨРМӘТЛӘП

Совет театр сәнгатен үстерүдә күп еллар буена нәтиҗәле эш алып барганы өчен Татарстан АССР Театр эшлеклеләре союзы, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1989 ел, 23 январь Указы нигезендә, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

Музыка сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Татарстан АССР Композиторлар союзы идарәсе председателе, композитор Мирсәет Яруллин, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1988 ел, 21 октябрь Указы нигезендә, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

Совет әдәбияты өлкәсендәге хезмәтләре өчен язучы Мария Елизарова, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1988 ел, 21 октябрь Указы нигезендә, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМ

Совет театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Г. Камал исемендәге Татар дәүләт театры артисты Габделфәрт Шәрафиевка, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1989 ел, 23 январь Указы белән, «Татарстан АССРның атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

СССР Дәүләт куркынычсызлыгы комитеты 1988 елда чекистлар тормышын чагылдыручы әдәби әсәрләргә, кино һәм телефильмнарга конкурс игълан иткән иде. Күптән түгел конкурс йомгаклары мәгълүм булды. Анда А. Гыйләҗев белән А. Литвинның Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «Августның алтысына кадәр» романы кызыксындыру дипломына һәм истәлекле бүләккә лаек булды.

# САБА КӨМЕШЧЕЛӘРЕ

Мондагы табигать оста куллы рәссам төшергән гаҗәеп бер рәсемнән сайлап алынган күренешләрдән тора сыман. Таза бүрәнәләрдән салынган җыйнак авыл йортларын бер яктан калкулык урап алган. Әйтерсең, ул авылны кырыс җилләрдән саклар өчен махсус шулай урнашкан. Аз гына астарак бормаланып аккан инеш аша рәшәткәле басма-күпер сузылган. Яр буйлап мәһабәт өянкеләр тезелгән. Өянкеләр шавында талгын гына аккан инеш ямь-яшел тугайлыклар аша уза. Анда кер чайкарга төшкән авыл хатын-кызлары әле хәзер дә инеш төбеннән көмеш йөзекләр, балдак-алкалар таба икән.

Тенеки авылы көмешчеләре монда, элек-электән, үзләре ясаган бизәнү әйберләрен инеш комы белән юып ялтырата торган булган.

Хәзер дә авылдагы күп кенә йортларның хуҗалары — элекке осталарның нәсел җебен дәвам итүчеләр — сине өенә яки алачык-сарайга алып кереп, ата-бабадан калган ядкарьләрен — эш коралларын күрсәтергә мөмкин: менә алар, янәсе, коллективлаштыру чорларыннан бирле кеше кулы тимәгән, кагылмаган, җуелып калган һәм югалган байлык... Ул чакта күп осталарын җуйган авыл. Байтагы — җитмештән артык кеше — Тенекигә Бөек Ватан сугышыннан кире әйләнеп кайтмаган.

Саба көмешчеләре кәсебенең ни дәрәҗәдә борынгыдан килүе турында да сүз әйтү кирәктер. Әйтик, 1987 елда табылган ярым ай рәвешендәге кызыл сатинга ялтыравыклы тәңкәләр тагылып ясалган затлы хәситә — бу төбәктә таралган кәсепнең юл башын тагын да төгәлрәк ачыкларга мөмкинлек бирә. Анда, мәсәлән, үрдәк сурәте чүкеп ясалган бер тәңкә мәҗүсилек авазларын чагылдыра һәм бу хәситәнең тууы XII—XIII гасырларга туры килүен тәгаенләргә мөмкинлек бирә. Шундый ук табылдык җәүһәрләрнең берсендә «Зәрбе Болгар» — «Болгарда сугылды» дигән язулы тәңкә дә бар. Димәк, Саба көмешчеләрендә сакланган бу гаҗәеп һөнәрнең тамырлары Болгар дәүләтенең үсеш чорларыннан ук килә дияргә тулы җирлек бар.

Революциягә кадәр, йорт-җирләрен калдырып, осталар ерак җирләргә — көмешкә чыгып китә торган булганнар. Оренбург, Казахстан далалары буйлап узган бу оста һөнәрчеләр, шул якларның чибәр кызларын шатландырып, төрле затлы чулпылар, беләзекләр, алкалар һәм балдак-йөзекләр ясаганнар, ягъни халык телендәгечә әйтсәк, «ак эш» белән шөгыльләнгәннәр. Шулай ярты ел чамасы юл гизеп йөргәннән соң, алар туган якларына әйләнеп кайткан, язгы кыр эшләренә керешкән, крестьян тормышының бетмәс-төкәнмәс эшләренә кереп чумган. Ләкин авыр эш көненнән соң да осталар яңадан кулга эш коралы алган, имән өстәлләрдәге сандалларда чүкү, кою белән шөгыльләнгән.

Шушы гасыр башларында элекке традицияләр җирлегендә яңа бер эш — каралтынлау кәсебе туган. Бу ысулның соңгы осталарыннан берсе Хәбибрахман Ганиев аны үзенең туганнан туган абыйсы — юлгизәр һөнәрче Габдулла Латыйпов шәхесе белән бәйли. Г. Латыйпов әлеге ысулны гасыр башында Саба якларына килеп чыккан бер Әстерхан татарыннан өйрәнеп калган. Хәер, борынгы Болгарда киң таралган каралтынлау ысулының юлбашын Әстерханнан эзләү һич тә дөрес булмас иде. Бу очракта да бизәкле читекләр белән бәйле парадокс килеп туган булуы бар: кайчандыр XVI гасырда Казан осталары тарафыннан Урта Азиягә таратылган бизәкле читекләр XVIII гасырда безнең якларга «Бохара читекләре» булып кире әйләнеп кайткан бит! Каралтынлау ысулының язмышы да шуңарга охшаш.

Тенеки авылы көмешчеләренең күп кенә эшләре бүген Татарстан сынлы сәнгать музеенда саклана, күргәзмәләрдә йөри, меңләгән кешеләрнең күз карашын иркәли.

Әйе, сабалыларның данлы һөнәре сүнеп калмаган, димәк! Сүнеп калмаган, әмма ул үзенең яңа осталарын, яшь осталарын — дәвамчыларын көтә.

**Р. ШАҺИЕВА,**
Татарстан сынлы сәнгать
музее фәнни хезмәткәре.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** XIX гасырда Казан күренешләре. Печән базары. Иске открыткадан репродукция.

**Ю. ФИЛИМОНОВ** фотолары.

# ИГЪТИБАР! ЯҢА ЖУРНАЛ «ИДЕЛ»

Татарстан язучыларының һәм яшьләренең күптәнге хыялы тормышка ашты — быелның июль аеннан Казанда татар һәм рус телләрендә яшьләр өчен әдәби-нәфис, иҗтимагый-политик, рәсемле **«Идел» журналы** чыга башлый. ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты һәм Татарстан Язучылар союзы органы буларак, журнал беренче нәүбәттә яшьләр тормышын гәүдәләндерүче әсәрләргә — повестьлар, хикәяләр, шигырьләргә киң урын бирәчәк, аның битләрендә бүгенге яшьләрне борчыган сәяси, тарихи, әхлакый, экологик, тәрбияви, спорт, сәламәтлек һ. б. мәсьәләләр яктыртылачак. Музыка, сәнгать белән кызыксынучылар журнал битләреннән яңа җырлар, популяр ансамбльләр турында язмалар, рәссамнарның яңа әсәрләреннән репродукцияләр, төрле уеннар, кызыклы һәм мавыктыргыч башка язмалар табачак.

Шунысын да искәртеп куябыз, «Идел»нең татарча һәм русча басмалары бер-берсен тулысынча кабатламый, аларның һәр икесендә оригинал әсәрләр басылу, аерым язмаларның гына тәрҗемә ителүе күздә тотыла.

Инде бүгеннән сез яңа журналга языла аласыз. Ул газета һәм журналларның Бөтенсоюз каталогына кертелде.

**Татарча басманың индексы — 73951.**


**Русча басманыкы — 73952.**

**Бер елга язылу бәясе 4 сум 80 тиен. 1989 елның икенче яртысы өчен (июльдән башлап) 2 сум 40 тиен.**

Әлегә журналның тиражы чикләнгән, 1990 елның беренче саныннан ук алырга теләсәгез, бүгеннән элемтә бүлекләренә мөрәҗәгать итәргә киңәш бирәбез.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



**КАЗАН УТЛАРЫ**
**(ОГНИ КАЗАНИ)**

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)